# казан утлары

8

АВГУСТ · 1969

# Казан утлары

АЙЛЫК ӘДӘБИ ҺӘМ ИҖТИМАГЫЙ-ПОЛИТИК ЖУРНАЛ
ТАТАРСТАН ЯЗУЧЫЛАРЫ СОЮЗЫ ОРГАНЫ
КЫРЫК СИГЕЗЕНЧЕ ЕЛ ЧЫГА

**8**

АВГУСТ
1969

## Бу санда:

ЛЕНИН ӘДӘБИЯТ ТУРЫНДА

Партия оешмасы һәм партияле әдәбият . . . . 3
Рус телен чистарту турында . . . . . . . . 6

ЛЕНИН — БӨЕК ЯКТАШЫБЫЗ

И. ВОЛОБУЕВА. Кокушкинода. Казан университеты. Шигырьләр . . . . . . . . . . . . 7

РОМАН, ПЬЕСА, ШИГЫРЬЛӘР

Г. ӘПСӘЛӘМОВ. Яшел Яр. Роман . . . . . . 10
Х. ӘЮПОВ. Сау бул. Ялгызлык. Минем хисләр. Уйламаска тырышасың. Уеннар. Таш эти. Мәхәббәт. Иске яулык. Алдану. Шигырьләр . . 113
С. КАЛЬМЕТОВ. Көнбагыштан башланды. Комедия 117

ЯШЬЛӘР ИҖАТЫ

М. СИРАҖИ. Җәйге яңгырлы юлдан. Бу йөрәгем... Көнгә ачык тәрәзәләре. Соңлаган мәхәббәт. Шигырьләр . . . . . . . . . . . . . 125
Р. ХУҖИН. Ташлар. Тумыштан ук. Кайчак. Төн. Юлларга карлар яуган. Шигырьләр . . . . 126
Ә. ГАДЕЛ. Кошлар кайта. Чам. Яңгын сүндерүчеләр. Шигырьләр . . . . . . . . . . . 128

ЛЕНИН — БӨЕК ЯКТАШЫБЫЗ

Ә. РӘШИТОВ. Ленин яшьлегенә шаһит җирләр . 129

ЗАМАНДАШЛАРЫБЫЗ

Г. МӨХӘММӘТШИН. Райком секретаре . . . . 140

КПССның
ТАТАРСТАН
ӨЛКӘ
КОМИТЕТЫНЫҢ
ГАЗЕТА ҺӘМ
ЖУРНАЛЛАР
НӘШРИЯТЫ
КАЗАН

ТАТАРСТАН КИТАП НӘШРИЯТЫНА 50 ЕЛ

С. САБИРОВ. Данлы юл . . . . . . . . . . . 149

ӘДӘБИ ТӘНКЫЙТЬ

А. ӘХМӘДУЛЛИН. Драматургия уйлана, эзләнә . 152
Р. БАТУЛЛИН. Витаминнар хакында . . . . . 160

ИҖАТ ПОРТРЕТЫ

Ф. МИҢНУЛЛИН. Туган җир җылысы . . . . . 166

ЯҢА КИТАПЛАР

Г. РЯБКОВ. Алыпкулның сигезенче улы . . . . 178
Ф. УРМАНЧЕЕВ. Халкыбызның уен-бию җырлары. 183

Кыска рецензияләр . . . . . . . . . . . . . 187

Газета укучыларыбыз игътибарына . . . . . . 189

Әдәбият һәм сәнгать яңалыклары . . . . . . 191

**Редакциягә килгән кульязмалар кире кайтарылмый**

Редакциянең адресы: *Казань, ул. Баумана, 19. Дом печати, 2 этаж.*
Телефоннар: Баш редактор — 2-68-21, җаваплы секретарь — 2-39-52,
бүлекләр — 2-39-52.
Хатлар өчен: *Казань, почтамт, почтовый ящик 63. Редакция «Казан утлары».*

Баш редактор: **Зәки Нури.**
Редколлегия: **Хәй Вахит, Шәүкәт Галиев, Әмирхан Еники, Ләбибә Ихсанова, Шәйхи Маннур, Рафаэль Мостафин, Газиз Мөхәммәтшин, Рәфикъ Нәфиков, Атилла Расих, Гали Халит, Сибгат Хәким, Нил Юзиев, Мирсәй Әмир.**

Производствога бирелде 12/VI-1969 ел. Басарга кул куелды 25/VII-1969 ел. ПФ 05027.
Кәгазь форматы 70×108¹/₁₆. Учетн.-изд. табак 12,2. Басма табак 12(16,8). Тираж 82046 экз.
Заказ В-327. Бәясе 50 тиен.

ТАССР Министрлар Советы каршындагы Матбугат идарәсенең Камил Якуб исемендәге матбугат комбинатында басылды. Казан, Бауман урамы, йорт 19, 1969 ел.

# ПАРТИЯ ОЕШМАСЫҺӘМ ПАРТИЯЛЕ ӘДӘБИЯТ[1]

Россиядә социал-демократик эшнең октябрь революциясеннән соң туган яңа шартлары партияле әдәбият мәсьәләсен нәүбәткә куйдылар. Легаль булмаган матбугат белән легаль матбугат арасындагы аерма, крепостнойлык, самодержавие Россиясенең шушы күңелсез мирасы, югала башлый. Аның әле үлеп беткәне юк, һич юк. Безнең министр-премьерның икейөзле хөкүмәте әле шундый башбаштаклана ки, «Известия Совета Рабочих Депутатов»[2] «легаль булмаган рәвештә» басыла, ләкин хөкүмәтнең комачауларга хәленнән килми торган нәрсәне ахмакларча «тыярга» маташуыннан хөкүмәт өчен хурлыктан башка, аның үзенә яңа мораль ударлардан башка һичнәрсә чыкмый.

Легаль булмаган матбугат белән легаль матбугат арасында аерма яшәгәндә, партияле һәм партиясез мәхәббәт мәсьәләсе чиктән тыш гади һәм чиктән тыш фальшь, гарип төстә хәл ителә иде. Бөтен легаль булмаган матбугат партияле иде, оешмалар тарафыннан чыгарыла, партиянең практик эшчеләре группалары белән тегеләйме яки болаймы бәйләнешле группалар тарафыннан алып барыла иде. Партиялелек тыелганга күрә бөтен легаль матбугат партиясез иде, ләкин теге яки бу партиягә «тартымлы» иде. Гарип союзлар, нормаль булмаган «бергә яшәүләр», фальшь пәрдәләр котылгысыз иде; партия карашларын чагылдырырга теләгән кешеләрнең ирексездән әйтеп (термәүләре белән ул карашлар дәрәҗәсенә үсеп җитмәгәннәрнең, асылда, партия кешесе булмаганнарның уйлап җиткермәве яки фикер куркаклыгы аралаша иде.

Каһәр төшкән чор, эзопча сөйләүләр, әдәби холоплык, коллык теле, идея крепостнойлыгы чоры! Рус җирендәге бөтен җанлы һәм саф нәрсәне буып торган бу кабахәтлеккә пролетариат чик куйды. Ләкин пролетариат хәзергә әле Россия өчен азатлыкның тик яртысын гына яулап алды.

Революция әле тәмамланмаган. Әгәр царизмның **инде** революцияне җиңәргә көче **җитми** икән, революциянең **әле** царизмны җиңәргә көче **җитми**. Һәм без шундый заманда яшибез ки, ачык, намуслы, туры, эзлекле партиялелек белән подпольедагы, пәрдәләнгән, «дипломатияле», бормалы «легальлекнең» табигыйлеккә каршы булган шушы бергә кушылуы һәркайда һәм һәрнәрсәдә сизелә. Табигыйлеккә каршы булган бу кушылма безнең газетада да сизелә: Гучков әфәнде либераль-буржуаз, уртачыл газеталарны бастырудан тыючы социал-демократик тирания турында күпме генә үткен теллеләнмәсен, ә факт шулай да факт булып кала, Россия социал-демократик эшчеләр партиясенең үзәк органы, «Пролетарий»[3], шулай да **самодержавие**-полиция Россиясенең ишегеннән керә алмыйча тышта кала.

Ничек кенә булмасын, ә революциянең яртысы безнең барыбызны да хәзер үк эшне яңадан юлга салуга керешергә мәҗбүр итә. Хәзер әдәбият, хәтта «легаль» рәвештә дә, $^{9}/_{10}$ өлешкә партияле була ала. Әдәбият партияле булырга тиеш. Буржуаз гореф-гадәтләрнең киресенчә, буржуаның предприниматель, сәүдәгәр матбугатының киресенчә, буржуаз әдәбият карьеризмның һәм индивидуализмның, «барин анархиз-

мының» һәм табыш kyуының киресенчә,— социалистик пролетариат партияле әдәбият принцибын алга сөрергә, бу принципны үстерергә һәм аны мөмкин кадәр тулырак һәм бөтенрәк формада тормышка ашырырга тиеш.

Партияле әдәбиятның бу принцибы нидән гыйбарәт соң! Социалистик пролетариат өчен әдәбият эшенең аерым кешеләргә яки группаларга табыш коралы була алмавыннан гына түгел, гомумән ул пролетариатның гомуми эшенә бәйсез, индивидуаль эш була алмый. Бетсен партиясез литераторлар! Бетсен үтә-кеше литераторлар! Әдәбият эше гомуми пролетар эшнең бер өлеше булырга, бөтен эшчеләр сыйныфының бөтен аңлы авангарды тарафыннан хәрәкәткә китерелүе бердәм, бөек бер социал-демократик механизмның «тәгәрмәччеге һәм винтчеге» булырга тиеш. Әдәбият эше оешкан, планлы, берләшкән социал-демократик партия эшенең состав өлеше булырга тиеш.

«Һәрбер чагыштыру аксый», ди немец мәкале. Минем әдәбиятны винтчек белән, җанлы хәрәкәтне механизм белән чагыштыруым да аксый. Хәтта, ихтимал, мондый чагыштыруга каршы: ул ирекле идея көрәшен, тәнкыйть иреген, әдәби иҗат иреген түбәнәйтә, үлекләндерә, «бюрократлаштыра» һ. б., һ. б. ш. дип тавыш күтәрүче истерикалы интеллигентлар да табылыр. Эшнең асылында, андый тавыш күтәрүләр буржуаз-интеллигент индивидуализмының чагылышы гына булыр иде. Бәхәс юк, әдәбият эше механик тигезләүгә, нивелировкага, күпчелекнең азчылык өстеннән хөкем сөрүенә иң аз бирелә. Бәхәс юк, бу эштә шәхси инициативага, индивидуаль һәвәсләкләргә күбрәк иркенлек, фикергә һәм фантазиягә, формага һәм эчтәлеккә иркенлек тәэмин итү һичшиксез кирәк. Болар бар да бәхәссез, ләкин болар бар да тик шуны гына исбат итәләр ки, пролетариатның партия эшенең әдәбият өлеше пролетариатның партия эшенең башка өлешләре белән шаблонлы рәвештә тиңләштерелә алмый. Болар бар да буржуазиягә һәм буржуаз демократиягә ят һәм сәер положение: әдәбият эше һичшиксез һәм мәҗбүри рәвештә социал-демократик партия эшенең башка өлешләре белән аерылгысыз бәйләнгән бер өлеше булырга тиеш, дигән положениене һич тә кире какмый. Газеталар партиянең төрле оешмаларының органнары булырга тиешләр. Литераторлар партия оешмаларына әлбәттә керергә тиешләр. Издательстволар һәм складлар, магазиннар һәм уку заллары, китапханәләр һәм һәртөрле китап сәүдәсе — болар барысы да партиянеке булып, аңа отчет бирергә тиешләр. Бу эшнең бөтенесен оешкан социалистик пролетариат күзәтеп торырга тиеш, аның бөтенесен контроль астында тотарга, бу эшнең берсен дә калдырмыйча, бөтенесенә җанлы пролетар эшнең җанлы агышын кертергә, шулай итеп, Россиядәге: язучы языштыргалый, укучы укыштыргалый, дигән иске, ярым-обломовча, ярым-сәүдәгәрчә принципның һәртөрле җирлеген калдырмаска тиеш.

Без, әлбәттә, азиатча цензура һәм Европа буржуазиясе тарафыннан шакшыландырылган әдәбият эшен болай үзгәртеп кору берьюлы гына була алыр, димибез. Без ниндидер бертөсле системаны яки мәсьәләнең берничә карар белән хәл ителешен алга сөрү фикереннән еракбыз. Юк, бу өлкәдә схематизм турында сүз бигрәк тә аз булырга мөмкин. Эш шунда ки, безнең бөтен партиябез, бөтен Россиядәге бөтен аңлы социал-демократик пролетариат бу яңа бурычны аңласын, аны ачык итеп куйсын һәм һәркайда, һәр җирдә аны хәл итүгә керешсен. Без, крепостной цензура тоткынлыгыннан котылып, буржуаз-сәүдәгәр әдәби мөнәсәбәтләр тоткынлыгына төшәргә теләмибез дә һәм төшмибез дә. Без полициядән азатлык мәгънәсендә генә түгел, бәлки капиталдан азатлык, карьеризмнан азатлык мәгънәсендә дә; — алай гына да түгел: буржуаз анархистлык индивидуализмыннан азатлык мәгънәсендә дә азат матбугат тудырырга телибез һәм тудырырбыз.

Бу соңгы сүзләр парадокс булып яки укучылардан көлү булып күренер. Ничек! дип кычкырыр, бәлкем, берәр интеллигент, азатлыкның ялкынлы тарафдары. Ничек! Сез әдәби иҗат шикелле шундый нечкә, индивидуаль бер эшнең күмәклеккә буйсындырылуын телисез! Сез эшчеләрнең тавыш күпчелеге белән фән, философия, эстетика мәсьәләләрен хәл итүләрен телисез! Сез абсолют-индивидуаль идея иҗатының абсолют азатлыгын инкарь итәсез!

— Тынычланыгыз, әфәнделәр! Беренчедән, сүз партияле әдәбият турында һәм аның партия контроленә буйсынуы турында бара. Һәркем аз гына да чикләүсез бөтен теләгәнен язарга һәм сөйләргә ирекле. Ләкин һәрбер ирекле союз (шул исәптән

партия) партиягә каршы карашларны тарату өчен партия фирмасы белән файдаланучы членнарны куарга да шулай ук ирекле. Сүз һәм матбугат ирекле тулы булырга тиеш. Ләкин союзлар ирекле дә тулы булырга тиеш бит. Мин сиңа, сүз ирекле хакына, ни теләсәң шуны кычкырырга, ялганларга һәм язарга тулы хокук бирергә бурычлымын. Ә син миңа, союзлар ирекле хакына, фәләннәрне һәм фәләннәрне сөйләүче кешеләр белән союз төзергә яки союзны бозарга хокук бирергә бурычлысың. Партия ирекле союз ул, һәм әгәр ул үзен партиягә каршы карашлар таратучы членнардан арындырмаса иде, ул, котылгысыз рәвештә, башта идея ягыннан, ә аннары материаль яктан да таркалыр иде. Ә инде партияле белән партиягә каршы булган нәрсә арасындагы чикне билгеләү өчен партия программасы хезмәт итә, партиянең тактик резолюцияләре һәм аның уставы хезмәт итә, ниһаять, халыкара социал-демократиянең, пролетариатның ирекле халыкара союзларының бөтен тәҗрибәсе хезмәт итә, ә бу пролетариат даими рәвештә үз партияләренә бик үк эзлекле булмаган, бик үк саф марксист булмаган, бик үк дөрес булмаган аерым элементларны яки агымнарны кертә килде, ләкин шулай ук даими рәвештә үз партиясендә периодик «тазартулар» да үткәрә килде. Бездә дә партия э ч е н д ә шулай булачак, буржуаз «тәнкыйть ирекле» яклы әфәнделәр: хәзер бездә партия берьюлы массовый партиягә әйләнә бара, хәзер без ачык оешмага кискен күчеш кичерәбез, хәзер котылгысыз рәвештә безгә күп кенә (марксизм карашынча) эзлексез кешеләр, бәлкем, хәтта кайбер христианнар, бәлкем, хәтта кайбер мистиклар да керер. Безнең ашказаныбыз таза, без таштай нык марксистлар. Без бу эзлексез кешеләрне сеңдерәчәкбез. Партия эчендә фикер ирекле һәм тәнкыйть ирекле беркайчан да бездән кешеләрнең партияләр дип аталучы ирекле союзларга берләшү ирекен оныттыра алмас.

Икенчедән, буржуаз индивидуалист әфәнделәр, без сезгә шуны әйтергә тиешлебез: сезнең абсолют азатлык турындагы сүзләрегез бер рия генә. Акча властена нигезләнгән җәмгыятьтә, хезмәт ияләре массалары хәерче булып, ә бер төркем байлар әрәмтамак булып яшәгән җәмгыятьтә, реаль һәм чын «азатлык» була алмый. Сез үзегезнең буржуаз издателегездән азатмы соң, язучы әфәнде! Сездән рамкаларда һәм картиналарда порнография, «изге» сәхнә сәнгатенә «өстәмә» рәвешендә фахишәлек таләп итүче буржуаз публикагыздан азатмы соң! Бу абсолют азатлык буржуаз яки анархистча фраза гына бит (чөнки, дөньяга караш буларак, анархизм эче тышка әйләндерелгән буржуазлык ул). Җәмгыятьтә яшәп тә җәмгыятьтән азат булу мөмкин түгел. Буржуаз язучының, художникның, актрисаның азатлыгы пәрдәләнгән (яки риячыл пәрдәләнә торган) бәйлелек, акча капчыгына, сатып алынуга, сөяркәлеккә бәйлелек кенә ул.

Һәм без, социалистлар, бу рияны фаш итәбез, фальшь вывескаларны кубарып ташлыйбыз — сыйнфый булмаган әдәбият һәм сәнгать булдырыр өчен түгел (бусы тик сыйныфсыз, социалистик җәмгыятьтә генә булырга мөмкин), бәлки риячыл-азат, ә эштә буржуазия белән бәйләнгән әдәбиятка каршы чыннан да азат, а ч ы к т а н-а ч ы к пролетариат белән бәйләнгән әдәбиятны куяр өчен.

Бу азат әдәбият булачак, чөнки аның сафларына яңадан-яңа көчләрне җыючы инде комагайлык түгел һәм карьера түгел, бәлки социализм идеясе һәм хезмәт ияләренә теләктәшлек булачак. Бу азат әдәбият булачак, чөнки ул рәхәткә туйган героиняга түгел, эч пошудан һәм симезлектән җәфа чигүче «өстәге ун меңнәргә» түгел, бәлки илнең чәчәге, аның көче, аның киләчәге булган миллионнарча һәм ун миллионнарча хезмәт ияләренә хезмәт итәчәк. Бу азат әдәбият булачак, кешелекнең революцион фикеренең соңгы сүзен социалистик пролетариатның тәҗрибәсе һәм җанлы эше белән җимешләндерәчәк, үткәннең тәҗрибәсе (социализмның примитив, утопик формалардан алып үсешен төгәлләгән фәнни социализм) белән хәзергенең тәҗрибәсе (эшче иптәшләрнең хәзерге көрәше) арасында үзара даими тәэсир булдырачак.

Эшкә керешик, иптәшләр! Безнең алда кыен һәм яңа, ләкин бөек һәм игелекле бурыч — социал-демократик эшчеләр хәрәкәте белән тыгыз һәм өзелмәс бәйләнештә әдәбият эшен киң, төрле яклы, төрле рәвешле оештыру бурычы. Бөтен социал-демократик әдәбият партияле булырга тиеш. Барлык газеталар, журналлар, издательстволар һ. б. хәзер үк үзгәртеп төзү эшенә тотынырга, бөтенләе белән тегеяки бу нигезләрдә партиянең теге яки бу оешмасына керүләрен хәзерләүгә тотынырга тиешләр. Тик шул чакта гына «социал-демократик» әдәбият чыннан да шундый булачак, тик шул

чакта гына ул үзенең бурычын үти алачак, тик шул чакта гына ул буржуаз җәмгыять рамкасында да буржуазия коллыгыннан котылырга һәм чыннан да алдынгы һәм ахырынача революцион сыйныф хәрәкәте белән кушылырга булдыра алачак.

«Новая Жизнь». 12 сан.

13 ноябрь. 1905 ел.

Имза: Н. Ленин

---

Искәрмәләр:

[1] **«Партия оешмасы һәм партияле әдәбият»** — Ленин. 4 басмадан тәрҗемә. 10 том, 29—34 битләр. Бу мәкалә беренче тапкыр «Новая Жизнь» газетасының 12 нче номерында, 1905 елның 13 ноябрендә. Н. Ленин имзасы белән басылды.

[2] **«Известия Совета Рабочих Депутатов»** — Петербургның эшчеләр депутатлары Советының рәсми органы; 1905 елның 17 (30) октябреннан 14 (27) декабрена кадәр чыгып килде; Советның эше турында информацияләр бирә торган бюллетень характерында иде. Газетаның даими редакциясе юк иде, ул рөхсәтсез төрле буржуаз газеталар типографияләрендә басылды. Аның 10 номеры чыкты. 11 нче номеры басылган чакта полиция тарафыннан конфискацияләнде.

[3] **«Пролетарий»** — легаль булмаган атналык большевистик газета. РСДРПның Үзәк Органы; партиянең III съезды карары буенча чыгарылды. Партия Үзәк Комитетының 1905 елгы 27 апрель (10 май) пленумы карары белән ҮОның җаваплы редакторы итеп В. И. Ленин билгеләнде. «Пролетарий» 1905 елның 14 (27) маеннан 12 (25) ноябрена кадәр Женевада чыгарылды; 26 номеры чыкты. Редакциянең эшендә В. В. Воровский, А. В. Луначарский һәм М. С. Ольминский даими катнаштылар. «Пролетарий» иске, ленинчы «Искра» линиясен дәвам итте һәм большевистик газета «Вперед» эшен тулысынча дәвам итте.

Ленин Россиягә киткәннән соң күп тә үтмәстән, 1905 елның ноябрендә «Пролетарий» газетасын чыгару туктатылды, соңгы ике (25 һәм 26 нчы) номеры В. В. Воровский редакциясендә чыкты.

# РУС ТЕЛЕН ЧИСТАРТУ ТУРЫНДА

(Буш вакыттагы, ягъни җыелышларда речьләр тыңлагандагы уйлар)

Рус телен без бозабыз. Чит сүзләрне кирәксезгә кулланабыз. Аларны ялгыш кулланабыз. Недочеты яки недостатки, яки пробелы дип әйтергә мөмкин чакта, нигә «дефекты» дияргә!

Әлбәттә, гомумән укырга һәм бигрәк тә газеталар укырга күптән түгел генә өйрәнгән кеше аларны тырышып укый башласа, ул газетача сөйләм әйләнмәләрен ирексездән үзләштерә. Ләкин нәкъ менә газета теле бездә шулай ук бозыла башлады. Әгәр күптән түгел генә укырга өйрәнгән кешегә, яңа бернәрсә дип, чит сүзләр куллану гафу ителерлек булса, литераторларга инде моны гафу итеп булмый. Безгә чит сүзләрне кирәксезгә куллануга каршы сугыш игълан итәргә вакыт түгелме икән!

Дөресен әйтим, әгәр чит сүзләрне кирәксезгә куллану минем ачуымны китерә икән (чөнки бу безнең массага йогынты ясавыбызны кыенлаштыра), газеталарда язучыларның кайбер ялгышлары инде мине бөтенләй чыдап тормаслык хәлгә китерүе мөмкин. Мәсәлән, «будировать» сүзен дәрт кузгату, хәрәкәткә китерү, уяту мәгънәсендә кулланалар. Ләкин французча «bouder» (будэ) ачулану, кабарыну дигән сүз. Шунлыктан будировать чынында «ачулану», «кабарыну» дигән сүз була. Сүзнең нижегородча-французча кулланылуын күчереп алу — французча укыган булса да, беренчедән, өйрәнеп җитмәгән, ә икенчедән, русчаны бозып сөйләгән рус алпавытлар сыйныфының иң начар вәкилләреннән иң начар нәрсәне күчереп алу була.

Рус телен бозуга каршы сугыш игълан итәргә вакыт түгелме икән!

Беренче тапкыр 1924 елның 3 декабрендә

«Правда» газетасының 275 нче санында басылган

Имза: Н. Ленин




## *ЛЕНИН—*
## *БӨЕК ЯКТАШЫБЫЗ*

**Ирина Волобуева,**

рус шагыйрәсе.

### Кокушкинода

Күптән инде, моннан элек, җәй көннәре,
Кайткан чакта тузан баскан тыныч юлдан,
Җилләр тарантаска бәрелеп уйнаганнар,
Гүя сабый кул чәбәкләп барган сыман.

Ә кыш көне салкыннарда туңып яткан
Үрле-кырлы юлдан барган чакта җилеп,
Шыгырдаган чана табаннары карда,
Зур ачудан тешләр шыкырдаган кебек.

Бабасының йорты моңсу талгынлыкта
Каршы ала иде башын иеп элек.
Моңа кадәр кайтарганнар яшь сабыйны,
Бүген менә кайтты сөрген булып егет.

Тик син аны каты хөкем итмә инде,
Көтмә аннан үкенү, тәүбә сүзләре дә!
Сайлап алды оныгың синең бөек юлны —
Дәрт ялкыны Володяның күзләрендә.

Кимсетелгән, изелгәннәр көрәшчесе
Юлын сайлап алды! — Үлемсезлек юлын.
Михайловский төннәренең Пушкинындай,
Тоташтырды егет таңга лампы нурын.

НУРИ АРСЛАНОВ тәрҗемәсе.

# Казан университеты

Ак кына, пакь кына бинаны
Багана тезмәсе бизәкли,
Шәһрәтле орденын, һәр җирен
Шәһәрдә һәрбер йорт хөрмәтли.
Күпертмә бизәкләр өстенә
Кушылып калкыган ак катлар,—
Әйтерсең, өелеп куелган
Шаккаткыч калын, зур китаплар.
Ничә яшь буынның күргән ул
Үзенә ут йотып кергәнен,
Хәтерли аларны үстереп,
Тормышка юл ачып биргәнен.

...Менә ул җиденче зур бүлмә.
Унҗиде яшендә, тирәннән
Яшь Ленин хаксызлык — коллыкны
Канечкеч хокуктан өйрәнгән.
Борынгы парталар артыннан
Күргән ул киләчәк ил көнен;
Казанга караган, күзәткән
Заводлар һәм өйләр төтенен.
Байларның талавын белгән ул,
Ярлылар газабын күргән ул.

Иленең язмышы хакында
Сызланып утырган чагында,
Пенснэ җентекләп аны да
Күзәтә кафедра янында:
«Шушымы хөрлекне ярата,
Коткыны иң башлап тарата?»

Котыра шымчылык, кансызлык
Гайрәтле буынны өркетеп.
Ә яшьләр көчләрен бер итеп
Володя янына туплыйлар.
Әйтерсең, аларны ишетеп
Томнары тыелган Маркс та,
Герцен һәм Чернышевский да
Яшьләрнең җыенын хуплыйлар.

Патшаны тетрәткән бөркетнең,
Хакыйкать яклаган егетнең
Әнә шул бертуган энесе!
Йөрәккә дәрт биргән һәр сүзе,
Ярсулы гадәте һәм йөзе,
Нык атлап йөреше-барышы,
Сашага охшаган барысы.
Сашаның туганы, кечесе,
Яшьләрнең иң кыю кешесе,
Бүген ул аларның — башында,
Уйлый ул яңа юл хакында!

Студентлар аңардан дәрт алган
Беренче җыенны ачарга,

Гасырлар буенча изүче
Тиранга протест ясарга.
Көчле бер өермә булып ул
Баскычтан югары атылган,
Дуслары дәртләнеп чапканнар
Володя Ульянов артыннан.

Ул чакта кем белгән бу йортта
Ленинның ярсынып йөрүен,
Ялкынлы елларда шушыннан
Мәңгелек үрләргә менүен.
Бикләнгән ишекне йодрыклар
Каккалап күкрәткән чагында,
Рәсемгә ясалган патшалар
Акайган җыелыш залында...
Шкафлар, шүрлекләр селкенеп
Таҗ-тәхет хәлендә булганнар:
Патшалар кан белән яздырган
Законнар калтырап торганнар.

Киң ишек ачыла ватылып,
Егетләр керәләр атылып,
Революцион штурм зур залда,
Штурм гөрелди урамда.
Явызлык ялчысы — инспектор
Яшь көчләр керүгә ишектән,
Җыенның ил хакын яклавын,
Изүдән һәркемне саклавын,
Ут кебек таләбен ишеткән.
Студентлар ил өчен сызланып,
Истибдат хакимны фаш иткән.

Күрше йорт ишеге алдына
Солдатлар тын гына үтәләр,
Мылтыклар корылган, әзерләр,
Каушаган түрәнең, хәзергә,
Башлагыз, дигәнен көтәләр...

Ә менә тотылып алынган,
Яшь килеш зинданга ябылган
Арестант киемле Ульянов
Яши ил халкына ышанып:
Котырган тираннан үч алып,
Чыныгыр чаклары җитәр, ди,
Ватанны ул азат итәр! — ди.

. . . . . . . . . . .

Мәгърифәт нурыдай ак кына
Бинаны зур орден бизәкли,
Аны хөр, куәтле дәүләттә
Һәр шәһәр, һәр авыл хөрмәтли.
Күпертмә бизәкләр өстеннән
Кушылып калкыган ак катлар,—
Нәкъ менә хөрлекне яклаган,
Ил һәм фән җиңүен раслаган
Ленинчыл иң бөек китаплар!

МӨХӘММӘТ САДРИ тәрҗемәсе

**Габдрахман Әпсәләмов**

# ЯШЕЛ ЯР[1]

РОМАН

## 8



Иртәгесен түгел, аннан соңгы көнне дә түгел, әмма күпмедер вакыт үткәч, Гәүһәр гүя әкренләп йокысыннан уяна башлады. Вакыт әкренләп савыктыра бугай. Гәүһәр балаларга күбрәк игътибар итә. Әлбәттә, балалар моны сизмичә калмады, ләкин алар үз фикерләрен кинәт үзгәртмиләр икән. Хәзергә бары тик боз астындагы агым гына бара, әмма Гәүһәр бу кадәресенә дә бик шатланды. Бу вакытта инде декабрь караңгылары үткән, кышкы каникуллар да узып киткән, көннәр күзгә күренеп озыная башлаган иде. Яктылык һаман арта бара, бу яктылык гүя әкрен генә күңелгә дә күчә. Ә язгы гөрләвекләр күңел төбендәге соңгы керләрне дә агызып китәр. Хәзер Гәүһәр мәктәпкә дәртләнебрәк йөри, яңакларында беренче алсулык күренде. Иртә белән класска кергәндә укытучының йөзендәге бу алсулыкны бигрәк тә балалар сизделәр. Аларга бит, уйнагыз, көлегез, дип әйтергә кирәкми, алар моны үзләре беләләр. Гәүһәр аларның яңгыравыклы тавышларын ишетеп, эченнән шатланып туя алмады. Бигрәк тә аңа Зилә белән Акназар ошады. Бу ике бала бер партада утыралар. Аларны әле Ләмига бер партага утырткан булган. Гәүһәр аларның бер тапкыр да сугышканнарын яки ачуланышканнарын күрмәде. Дәресләрен дә бик ару беләләр, Гәүһәр бер тапкыр да аларга кисәтү ясамады. Акназарның әнисе бар, әтисе каядыр киткән, Акназар аны белми дә. Зиләнең әнисе белән бабасы гына бар, әтисе төзелештә үлгән. Акназар белән Зилә ян күршеләр, бер-берсенең өйләрендә дә булалар. Зилә бик көләргә ярата, көлгән чакта тавышы көмеш кыңгырау кебек чыңлый. Дөрес, аларда ниндидер күзгә күренмәгән үзгәреш бара, сүз арасында әле Зилә, әле Акназар уйга кала. Бала өчен бу бик характерлы түгел, шуңа күрә Гәүһәр моңа игътибар иткән иде, күңеленнән боларның өйләренә барып карарга кирәк дип беркетеп куйды, тик үз хәле хәл булганга, вакыт кына таба алмады.

Гәүһәрнең чырае яктыруы Миләүшәне дә канатландырып җибәрде. Мәктәп коридорларында аның шат тавышы ешрак ишетелә башлады, кичләрен Гәүһәр янына да ешрак кереп чыккалады. Алар озак-озак сөйләштеләр. Миләүшәнең сүзләре күбрәк әлеге дә баягы Вилданы тирәсендә. Вилданы төшендә дә химия белән мавыга икән. Миләүшәне көтеп химия кабинетында сәгатьләр буе утыра.

[1] Ахыры. Башы 6—7 саннарда.

Бу үтә беркатлы мәхәббәт мажараларыннан, билгеле, Гәүһәр үз-алдына елмаеп та куя. Әле бик күп нәрсә, бик күп нәрсә Миләүшәгә ал да гөл булып күренә, нәкъ жырдагы кебек, соңыннан байтак үзгә-рер, тормышның шигъриятен үтеп, прозасы башланыр. Шулай да беренче мәхәббәттән нәрсәдер гомер буена кала бит, вакытлы нәрсәләр югала, бетә, ә асылы һаман күңелдә яши, бер дә тоныкланмый да, сүрелми дә. Ул әл, егерме һәм кырык ел үткәч тә Миләүшәнең шушы шат көлүен ишетсә, Гәүһәргә нинди күңелле булыр иде...

Менә шундый күңел уяна башлаган көннәрнең берендә Яшел Яр шәһәренә ярым онытылган филармония артисты Алчын Локман килеп чыкты. Урамда афишаларны күргәч, Гәүһәр бер мәл уйланып торды. Алчын инде аны оныткандыр. Артистлар тормышында андый танышлар аз буламыни? Бер тапкыр Гәүһәр ире белән ниндидер бер мәжлескә барды. Әзрәк башка киткәч, Алчын үзенең артистлыгын күрсәтә башлады, күп сөйләде, күп жырлады. Аның тавышы бик ягымлы, кайбер хатын-кызларга әчтән уфтану өчен шул житә калды, күз атучылар да булды. Гәүһәр ире янында гына утырды, иренең кулын ычкындырмады. Билгеле, Алчынның жырлавы аңа ошады, төскә-башка да Алчын чибәр генә, тик буйга гына әзрәк кыскарак. Кайткан чагында Жәгъфәр көлеп:

— Хатын-кызларны тилертергә күп кирәкми икән,— диде.—Кәрлә артист бөтенегезнең башын әйләндерде бит.

— Миңа карата әйтми торгансыңдыр,— диде Гәүһәр.— Миңа аның жыры гына ошады. Болай әллә нәрсәсе юк, күзләре хәтта майлы.

Жәгъфәр башын артка ташлап көлде, шуннан соң бер тапкыр да Алчынны телгә алмады. Радиодан жырын ишеткәндә я мыскыллы итеп көлде, я гамьсез калды. Ә Гәүһәр аны тагын бер-ике тапкыр концертларда күрде. Алчын ничектер жиңелрәк сөйләште, озата барырга да әзер иде, ләкин Гәүһәр ишетергә дә теләмәде, ирле хатыннарны озата йөрсәң, күзеңне ачырмаслар, диде көлеп. Шуның белән аларның танышлыклары да бетте. Соңгы бер-ике ел эчендә Гәүһәр аны бөтенләй очратмады. Алчын да, билгеле, аның монда икәнен белми торгандыр. Концертына бәлки барганда да ярар, Гәүһәрнең болай да беркая да чыкканы юк бит.

Ял көне Гәүһәр, Миләүшә белән Вилдан һәм Бибинур РДКга концертка киттеләр. Килгәннән бирле Гәүһәрнең монда булганы юк иде әле. Культура йорты ярыйсы зур булса да, төзелешендә дә, бизәлешендә дә беркадәр зәвыксызлык, авылчалык сизелә, өс киемнәрен дә кайсы салган, кайсы пальтодан, шәлдән килеш утыра. Кешеләр гүя ял итәргә дә килмәгән, бала-чагалар да байтак. Гәүһәргә ничектер бераз уңайсызрак булып китте. Дөрес, аның классыннан балалар юк иде югын, шулай да ничек күз йомасың. Хәер, монысы өйрәнмәгәнгәдер, югыйсә әнә Миләүшә белән Вилдан, хәтта Бибинур да үзләрен бик иркен тоталар, фойеда да бик күңелле йөриләр, залда да тыныч утыралар, күргән-белгәннәре белән дә уен-көлке кушып сөйләшәләр. Кеше бөтен нәрсәгә күнегә, соңыннан бер нәрсә дә кирәкми икән. Гәүһәрнең беркадәр художниклык сәләте булганга, мондагы кимчелекләрне ачык күрде.

Концерт ике бүлектән иде, күңелле генә тәэсир дә калдырды. Кайбер артистлар арзанлы алымнарга күбрәк игътибар бирәләр булса кирәк, ничек тә булса халыкны көлдерергә, кул чаптырырга, бис кычкыртырга тырышалар. Бу Гәүһәргә бөтенләй ошамады. Аннары кайберсе кием-салымга да игътибар биреп житкермәгәннәр, күрәсең, монда ничек булса да ярар дип уйлаганнардыр. Репертуарларында да беркадәр талымсызлык сизелә, һәрхәлдә, Гәүһәр булса, кайбер номерларны рәхәтләнеп төшереп калдырыр иде. Ә, гомумән, концертка килүе

өчен Гәүһәр үкенмәде, күңеле ачылып китте, иң мөһиме, халык арасына чыкты, бу бикләнеп ятудан мең мәртәбә яхшырак бит.

Алчын Гәүһәрне күрмәде бугай. Ул үзен бик иркен тотып, халыкның яхшы каршы алуына күнеккән хәлдә, аз гына кылана төшеп җырлады. Төп җырлары яхшы — тирән эчтәлекле, зәвыклы иде. Кул чабып сәхнәгә кат-кат чыгара башлагач, ул да түзмәде, халыкның бер өлешен кытыклап көлдерергә генә исәп тотылган җырлар җырлады. Гәүһәр кызарып утырды. Алчынны күрсәм, үзенә әйтәм әле, дип уйлады. Хәзер хәтерли, Алчын бу җырларны ул чакта мәҗлестә дә җырлаган иде. Мәҗлес мәҗлес инде, үз кешеләр арасында ни җырласаң да ярый, әмма сәхнәдә бераз чама кирәк.

Өенә кайтып йокларга яткач та Гәүһәр әле беркадәр вакыт Алчын турында уйланды. Төскә-башка Алчын бер дә үзгәрмәгән кебек, бераз юанайган гына шикелле. Еллар үтә бит. Гәүһәр исенә төшерде, Алчын бер тапкыр аны кара роза, кара аккош дип атаган иде бугай. «Кара роза, кара аккош, кара елан...» дип уйлады Гәүһәр. Аңа күңелсез булып китте.

Икенче көнне кич белән, бер дә көтмәгәндә, Гәүһәрләргә Алчын үзе килеп чыкты. Гәүһәр аны ничек каршы алырга да белмәде, бик уңайсызланып кына исәнләште, киемен салырга кушты, өстәл янына чакырды, үзе дә, иңенә шәлен салып, каршы якка утырды. Кичә Алчынга ерактан, залдан караган иде, хәзер ул ике адымда гына. Юк, Алчын шактый үзгәргән икән, йөзенә җыерчыклар да чыккан, чәчендә көмеш бөртекләре дә бар. Филармония артистының тормышы — чегән тормышы, дип сөйлиләр, дөрес булса кирәк.

— Мин, Гәүһәр ханым, барысын да ишеттем, барысын да беләм. Әлбәттә, сезнең бәхетсезлеккә мин көенергә тиеш идем, әмма чынын әйткәндә, мин шатландым гына. Мин сезне беренче күргәннән бирле... Чын, чын, гаҗәпләнмәгез. Сезнең тормышыгыз башка бер кеше белән бәйләнгән булганга... Хәзер сез... мин сезгә чын йөрәгемнән әйтергә тиешмен...

Гәүһәр көлеп җибәрде.

— Алчын, дөресен әйткәндә, мин сездән мондый сүз көтмәгән идем,— диде аннары.— Без бит аяк өсли генә танышлар. Минем бәхетсезлегем мине пычракка ташламады.

— Гәүһәр ханым... Мин сезгә алай карамыйм, киресенчә, сез минем алдымда буй җитмәслек югары, мин сезнең бәхетсезлектән файдаланырга уйламыйм. Мин сезне яратам!

— Юк, Алчын, мыскыл итмәгез. Мин сезгә яхшы караштa. Шул карашымны саклап калыйм.

Алчын белә идеме, юкмы, ләкин хатын-кыз мәхәббәт турында болай иркенләп сөйли ала икән, димәк, ул инде бу турыда җитәрлек уйлаган.

— Юк, Гәүһәр ханым, юк! Мин сезнең монда икәнегезне белгәч, төн уртасында сезгә килергә уйлаган идем, иптәшләр генә тотып калдылар.

Алчын урыныннан торып бүлмә буйлап йөренә башлады.

— Тынычланыгыз, Алчын. Сез яшь кеше, сезнең бәхетегез алда әле. Юк белән башыгызны ватмагыз. Чәй эчәсегез килсә, хәзер самовар куябыз.

— Рәхмәт, мәшәкатьләнмәгез. Мин сезнең отказны ишетергә теләмим. Яшермим, миңа күз атып йөри торган бер кыз бар. Ул хәтта минем алдымда... Ә мин... сезнең янга йөгереп киттем. Мин сездән башка...

Гәүһәр бераз уйланып торды, аннары мөмкин кадәр сабыр тавыш белән:

— Сез начар пьеса уйныйсыз,— диде.— Минемчә, үз-үзен хөрмәт иткән бер кыз да...

— Юк, юк, чын, Гәүһәр ханым, һич ялганламыйм.

— Алай булса, барыгыз аның янына! Хәзер үк! Югыйсә мин сезне куып чыгарам...

— Гәүһәр ханым, мин ике ут белән уйнамадым. Минем күңелем сездә генә иде...

— Барыгыз, Алчын! — дип кабатлады Гәүһәр нык итеп һәм, ниһаять, Алчын чыгып киткәч, беренче тапкыр кычкырып көлде. Зәбирә түти мич алдында ут йотып утыра иде, Гәүһәрнең кычкырып көлүен ишеткәч, олы якка чыкты.

— Гәүһәрем, ни булды? — дип сорады куркып.

— Чукындылар! — диде Гәүһәр.— Иреннән аерылган икән, икенчесенең ачык кочагын күргәч, хәзер атылыр дип уйлыйлар. И бу ирләр!..

Зәбирә түти әле булса куркуыннан арына алмый иде.

— Котымны тәмам алдың.

— Соң үзең уйла, Зәбирә түти. Бу хәтле үзенне зурга кую, бу хәтле үз-үзенә ышану. Сөйләшүләре — артистларныкы, монда алар көн саен күнеккән, ә калганы барысы да үз-үзенә ышану, шапырыну.

— Шулай да, Гәүһәрем, болай кырт бору яхшымы икән. Хәтере калыр бит егетнен.

— Юк, Зәбирә түти, монда кискен итеп, ике уйларга урын калдырмый торган итеп әйтергә кирәк. Акылы булса, соңыннан рәхмәт әйтер.

— Ай алла, Гәүһәрем, утын ярасыңмыни! Йомычкаларың кая очканын да карамыйсың.

Зәбирә түтинең күзләрендә очкыннар кабына башлаган иде. Тагын чак кына булса, чәчрәп түгелергә әзер. Ул Гәүһәрдән, аның биргән җавапларыннан да бик канәгать. Шул ук вакытта ул кешечә гаҗәпләнә дә белә. Ай-һай кеше белән болай сөйләшергә, җитмәсә шундый четерекле мәсьәлә турында... Күрәсең, бәгыре җитәрлек янган да, көйгән дә. Зәбирә түти болай ук түгелдер дип уйлаган иде. Аның Гәүһәргә мәхәббәте бермә-бер артты.

— Үзең уйла, Зәбирә түти: югыйсә аягына егылырга торган кызы турында сөйли. Минемчә, алар үзара эрләшкәннәр, шуннан бусы, ә алаймы, алай, дип монда йөгергән. Менә мин кем, дип үзен күрсәтергә булган.

Зәбирә түти ике кулын селкеп алды. Артистлар хатын-кыз күңелен аздыра дип сөйлиләр, әмма бу кадәресенә хәтта Зәбирә түти ышанмады. Ул Гәүһәргә гаҗәпләнеп карады, арттырмыймы? Әле яңа гына аягына басып килгән, караңгы төннән соң әле яңа гына баш-күз ала башлаган кешегә күп кирәкме соң? Гәүһәрнең дә ярсуы үтте булса кирәк, ул ничектер боегып, кечерәеп калды. «Менә хәзер елый инде», дип Зәбирә түтинең коты очты. Юк, еламады, ниндидер көч белән кайгысын йотты, ахрысы. Чырае, күз карашлары кырысланды. Шулай байтак вакыт эндәшми торгач, кинәт көлемсерәп җибәрде:

— Зәбирә түти, кара инде, идәнебезне ничек пычратып киткән.— Ул өстәлгә корылган ашъяулыкны күтәрде.— Өстәл асты тагы...

— Ботинкасының олтаны ике бармак калынлыгы, үзләре сырлы. Ул ботинкасын бик күрсәтергә теләгән иде дә, син карамадың...— Гәүһәрнең эндәшмәвен күргәч, үзе үк сүзен очларга ашыкты.— Хәзер корытып алам. Иртәгә барыбер юасы.— Зәбирә түти урыныннан торды, чатанлап кече якка чыкты, мич астыннан чүпрәк алды, аннары Алчын пычратып киткән идәнне сөртте.

Гәүһәр үз бүлмәсенә кереп китте. Ул инде чемоданнарын да бушаткан, бүлмәсен дә җыештырган иде. Әле күптән түгел генә шыксыз вокзал почмагын хәтерләткән бүлмә хәзер карашны үзенә тартып тора

Стеналарда, бу якта да, олы якта да, Гәүһәрнең үзе эшләгән рәсемнәре. Ул рәсемнәрне Зәбирә түтинең рөхсәте белән элде.

— Җаның ни тели, шуны эшлә,— дигән иде Зәбирә түти.

Элек бүлмәдә тәбәнәк кенә тимер карават тора иде. Күптән түгел генә Гәүһәр башы ялтыравыклы, биек сеткалы тимер карават сатып алды. Өстән караватына ал чәчәкле япма каплады, мендәрләре өстенә челтәрле җәймә җәйде. Кием эләргә гардероб, карарга зур көзге булмавы бик начар иде, Гәүһәр көзгеле гардероб та алып җибәрде. Стенага газета астына элеп торткан күлмәкләрен барысын шул гардеробка җыйды. Төрле вак-төяк әйберләр дә алып кайткач, бүлмә бөтенләй ямьләнеп китте.

Болар барысыннан да бигрәк Зәбирә түтине шатландырды, димәк, Гәүһәр төпләнергә уйлый. Ялгызак карчык кешегә тагын ни кирәк? Гәүһәр үзенең холкы-фигыле белән дә аңа бик хуш килде, борынын чөйми, өй эшенә кулы ята, әллә ни таләпчән түгел, кирәкмәгән кешене бер дә өйгә китерми. Элекке тормышын Зәбирә түти дә сораштырмый, Гәүһәр үзе дә аңа кагылмый. Ләкин яхшы өйдән чыкканы күренеп тора. Хәер, элегрәк Зәбирә түти башкачарак фикердә иде, Гәүһәрне үз киемен генә белә дип уйлый иде. Аның фаҗигасен тирәнрәк аңлагач, бигрәк тә өй эчен бизәп җибәрүен күргәч, карчыкның карашы да тамырдан үзгәрде.

## 9

Алчын Локман икенче көнне үк Яшел Ярдан китеп барган. Моны ишеткәч, Гәүһәр көләргә дә, кайгырырга да белмәде. Мәхәббәт турында шулай сайраган, тавышына шундый мелодраматик төс биргән кешенең, көн күрде, кояш алды, дигән шикелле бик тиз китеп баруы Гәүһәргә бөтенләй аңлашылмый иде. Ул Алчынны әллә ни югары санамаса да, аның бу кадәр җиңел карашлы булуын башына да китермәгән иде. Әнә Билал Шәнгәрәев күпме йөрде бит. Аны акылсыз эше өчен күпме генә хурласаң да, мәхәббәткә шулай беркатлы карый дип гаепли алмыйсың. Шуның өстенә, ул Гәүһәрнең авыр хәленнән файдаланырга да тырышмады. Алчын Гәүһәрнең дөньясы караңгы чакта килде, өстәвенә, бер дә көтмәгәндә килде. Шулай ук ул Гәүһәр шулкадәр тиле дип уйладымы икән? Әллә үзенең исеменә, шөһрәтенә шулкадәр таяндымы икән? Кызык бу кешеләр, уйларга кирәк урында уйныйлар. Тик кайчагында гына Гәүһәр моннан тирән серләр эзли, Алчын кебек кешеләр болай тупас кыланмас, монда нәрсә дә булса бардыр, дип шиккә кала. Ләкин үзеннән Гәүһәр канәгать, ул үзенең дәрәҗәсен, абруен саклап калды, әйтәсен бер дә боргаланмыйча әйтте. Ахыр килеп Алчынның нинди адым атлавы — анысы аның үз эше, әмма Гәүһәр аңа өметләнергә урын калдырмады. Шушыларны тагын бер мәртәбә тирәнтен уйлагач, ул балаларына тагын да якыная төште.

Классындагы Акназар Аралбаев исемле баланың беркадәр сәер гадәтләренә Гәүһәр игътибар иткән булса да, үз вакытында моның нәтиҗәсен ясый алмады, бала һаман үзалдына кала бирде, аның яхшысын да, яманын да күрмәделәр. Чамадан тыш берәр нәрсә эшләсә, билгеле, Гәүһәрнең ихтыярыннан тыш та бу нәрсә өскә калкыр иде. Акназар алай шау кубарырлык бер нәрсә дә эшләмәде.

Дәрестән соң Гәүһәр Акназарга калып торырга кушты.

Менә алар буш класста икәү генә утыралар. Гәүһәргә күптән инде сер түгел: теге вакытта тәрәзә төбенә чәчәк куеп киткән бала шул Акназар Аралбаев булган. Димәк, аның күңеле яхшы, тик андагы яшел үрентеләрне генә корытмаска кирәк. Тормыш ул балага болай да каты бәрелгән. Акназар төннәр буе этисен көткән, ә ул нигәдер улы янына килмәгән. Бу бала каршында беренче аңлашылмас нәрсә бул-

ган. Шуннан соң мондый аңлашылмас нәрсәләр өелеп кенә торган. Ләмигага Акназар бик иялэшкән булган, ул да китеп барган. Бала элекке укытучысына булган мәхәббәтен яңа укытучысына күчергән, аның рәсем ясавын яр буенда яшеренеп күзәтеп торган. Укытучының рәсем ясавы балага бик ошаган, чөнки Акназар үзе дә рәсем ясый икән. Ләкин шуннан соң Гәүһәр рәсемнәрен бөтенләй онытты, телгә дә алмый башлады. Акназар, яшеренеп, нихәтле күзәтсә дә, Гәүһәр бервакытта да стенага элгән савытын ачмады, гүя аны бөтенләйгә бикләгән иде...

Ишек төбендә кемдер шыпырт кына йөренә. Зиләдер инде. Теге вакытта тәрәзә төбенә чәчәк куйганда да урамның икенче ягында шул кызчык кул изәп басып тора иде бит.

— Мин, Акназар, сиңа бер нәрсә күрсәтергә йөридер идем,— диде Гәүһәр, рәсемле китап карап утырган балага.— Син рәсемнәр яратасыңмы?

— Әллә тагы,— диде Акназар, китабын тиз генә ябып.

— Алайса, әйдә безгә кереп чыгабыз. Анда рәсемнәр карарбыз.

Акназар теләр-теләмәс кенә риза булды. Урамда көн кояшлы иде, һава җылыткан, борынга яз исе килеп бәрелә, кәҗәләр, сыерлар кояшта җылыналар, кайдадыр казлар каңгылдый. Урамның теге ягыннан, бу якка бер дә карамагандай иттереп, кечкенә портфеле белән уйнап, Зилә бара. Гәүһәр аңа карап елмаеп куйды. Кайчандыр ул да шулай букчасы белән уйнап йөри иде. Нихәтле гомер узган! Шулай да бер нәрсә дә онытылмаган, юк кына нәрсәдән бар да яңара. Бер тапкыр, яз көне, шулай букчасы белән уйнап кайтканда, кемдер юри казып калдырган һәм кар суы тулган базга батты. Тәмам чыланган аягын баздан тартып алганда, кемнендер чыркылдап көлүе ишетелде. Гәүһәр үзе дә сизмәстән, нәни йодрыгын күтәреп, тирә-ягына каранды...

— Акназар, Зиләне дә дәшәбезме? Ул да безгә керсен, бергәләп рәсем карап утырырсыз,— диде Гәүһәр.

— Өенә кайтсын,— диде бала сүрән генә.

Менә алар тар тыкрыкка борылдылар, аннары бәләкәй капкадан ишек алдына керделәр. Аякларына ябышкан карларны бусага төбендә каз канаты белән сыпырдылар. Аннары май кебек җылы өйнең ишеген ачтылар. Зәбирә түти мич алдында күренми, ахрысы, каядыр чыгып киткән. Менә яхшы! Югыйсә Акназар аңардан азрак шүрли төшә торган иде, чөнки көз көне казларын куганы бар. «Тукта, мин сине!» дип Зәбирә түти бармак та янаган иде ул чакта. Акназар аңа телен генә күрсәткән иде.

— Киемеңне, киез итекләреңне сал, портфелеңне менә монда куй,— диде Гәүһәр, үзе дә өс киемен чишенде. Аннары икенче бүлмәгә кереп китеп, такта стена аркылы гына сөйләште.— Ял итәсең килмиме, Акназар?

— Юк.

— Өенә кайткач, нишлисең?

— Урамга чыгам.

— Кайчан ашыйсың?

— Ашыйм шунда.

Бераздан Гәүһәр иске журналлар күтәреп чыкты. Акназар, башын күтәреп, стенадагы рәсемнәрне карый иде. Урман аланнары, яр буйлары, ялгыз наратлар, чәчәкләр. Акназар тәрәзәдән караганы бар, элек бу рәсемнәр берсе дә юк иде. Рәсемнәре матур, тик мәктәп тормышыннан бер дә юк икән.

Гәүһәрнең, билгеле, мәктәп тормышыннан да рәсемнәре бар иде, тик аларны стенага элмәде. Акназарга болай күрсәтергә әзерләп куйды. Хәзер Акназарның рәсемнәрне үтә кызыксынып каравын күргәч, аз

гына көлемсерәде. Тик ошыймы дип турыдан-туры сорамады, малайлар моны яратып бетермиләр.

— Болар Казан тирәләре.

— Әнә теге имәнне яшен суккандыр инде, әйе бит?

— Әйе.

— Безнең Кама буенда да яшен суккан бер имән бар. Тик ул яфрак, ботаклары да башкачарак.

Чәчәкләр Акназарны, күрәсең, кызыксындырмады, ул өстәл янына утырып, Гәүһәр биргән журналларны карый башлады. Гәүһәр чәй куярга чыкты.

Чиләктә су беткән иде. Коега чыгып су алганчы, аннан самовар куя-куя байтак узды. Акназар башта журналларны карады, аннары тәрәзә янында кыштырдау ишетеп башын күтәрде. Зилә икән. Ул күзләре һәм куллары белән Акназарга ниндидер ишарәләр ясый иде.

— Нәрсә бар анда? — диде Гәүһәр, кече яктан кереп.

Зилә юк булган иде инде.

— Бер нәрсә дә юк,— диде Акназар, кызарып.

Гәүһәр үз бүлмәсенә кереп китте. Нәкъ шуны гына көтеп торган шикелле, Акназар күз ачып йомганчы бишмәтен киде дә, бүреге белән портфелен эләктереп, өйдән чыгып та китте. Зәбирә түти капчык күтәреп кайдандыр кайтып килә иде. Акназарга нидер әйтте. Акназар аңа карамыйча йөгерде.

Гәүһәр, иңбашына шәл ябып, ишек алдына чыкканда — капка ябык, ишек алды тыныч иде. Тиз генә капканы ачып урамга карады, аннары арт капкадан башын сузды, ник бер җан иясе булсын. Аптырап өйгә борылганда, чоланнан чыгып килгән Зәбирә түтине күрде.

— Зәбирә түти, Акназар кая китте?

— Бәй, мин каян белим,— диде хатын, чолан ишеген ачып.— Өйгә кер тизрәк, салкын тидерәсең ич.

— Зәбирә түти, Акназар кайда дим? — дип кабат сорады Гәүһәр.— Хәзер генә өйдә иде, бер минутта юк булды.

— Кемне әйтәсең әле? Чибәр Талиянең башкорт малаенмы?

— Әйе, шул Акназарны.

— Ул хәзер генә урамга чыгып китте. Мин аны уйнап ишек алдына кергәндер, дип торам тагы. Таш астыннан чыккан нәрсә.

— Мин аны чакырып китергән идем. Үз бүлмәмдә рәсемнәремне чемоданнан алган арада качып та киткән. Рәсемнәремне күрсәтмәкче идем үзенә.

— Ярар, юк нәрсәгә кәефең китмәсен, Гәүһәрем. Малай халкы яхшылыкны беләмени... Син самовар да куеп җибәргәнсен. Озаграк тордым шул. Кибеткә төшкән идем, казларыма җим алдым.

Зәбирә түти өс киемен салды да җиңнәрен сызганды, аннары кулларын юды. Гәүһәр күңелсезләнеп тәрәзәдән карый башлады. Шулай Акназар белән эшне ансат кына җайлармын дип уйлаган иде, бала барысын челпәрәмә китерде. Баланың икенче минутта нәрсә эшләвен берәү дә белми шул, бигрәк тә Акназар кебек шук малайның. Әлбәттә, рәсемнәргә ул шатланыр иде, ул рәсем ярата, үзе дә рәсем ясаштыргалый бит. Ясаштыргалый... Гәүһәр аның белән кызыксынганы бармы соң? Юк бит!

Гәүһәр хәзер үк Акназарларга барырга уйлады, киенергә дип чәй янына да килде, ләкин кинәт бу уеннан кире кайтты, иң яхшысы, иртәгә барыр. Аңарчы әле мәктәптә Акназарны да күрер, бәлки чакырып та китерер...

Зәбирә түти бик тиз табын әзерләде, шаулап торган самоварын китереп утыртты, аннары башындагы озын ак яулыгын рәтләп яшь киленнәрчә колак артына кайтарып бәйләп, самовар янына утырды, Гәүһәрне дә дәште.

— Үземнең дә тамагым бик кипкән,— диде ул, хуш исле кайнар чәй ясый-ясый.— Көндез мичкә тәгәрәткән бәрәнге ашаган идем, шул сусавымны китергән, ахрысы.

Гәүһәр, беркадәр вакыт уйланып, дәшмичә утырды. Йөзе болай да ябык, уйга калгач, бу ябыклык ничектер ачыграк та күренә. Ишек алдына чыкканда шәле иненә ничек ябылган булса, хәзер дә шулай, хәлбуки өй җылы, бик тәмле булып чәй исе таралган. Гөлләр башларын калкытканнар, озакламыйча чәчәк атарлар. Казанда Гәүһәрнең гөлләре юк иде, ә монда гөлсез өй бик ямьсез булыр төсле.

— Я инде, Гәүһәрем, болай балтасын югалткан агай кебек исәпкә калып утырма, чәй янында күңелле булырга кирәк, аннары чәйнең дә сихәте арта.

— Кызык син, Зәбирә түти,— диде Гәүһәр, чак кына елмаеп.

— Шулай ходай яраткан инде, Гәүһәрем. Мәнә син дөньяда күбрәк яшәрсең, күбрәк күрерсең, шуннан бу дөньяга үзеннең дә исең китәр әле.

— Әллә тагы... Зәбирә түти, син Талияне беләсеңме?

— Кайсы Талияне әйтәсең? Чибәр Талиянеме?

— Әйе, Акназарның әнисен.

— Белмичә, Яшел Яр кызы ич ул. Тәпи йөри башлаган чагыннан бирле беләм.

— Нинди кеше соң ул?

Зәбирә түти кулын селекте, бер минут чамасы чынаяктагы чәенә карап торды, мөгаен, күп нәрсәләр аның күз алдыннан үтеп киткәндер. Гәүһәр бит Яшел Ярда ярты ел, Зәбирә түти — гомер буе. Ул Яшел Ярның кечерәк авыл чагын да, район үзәгенә әверелгән елларын да, ниһаять, шәһәргә әйләнә башлавын да белә. Мондагы кешеләр дә аңа бала чактан ук таныш, серләре дә аңа сер түгел. Тик күп вакытта сөйләми генә ул. Табигате белән кеше тикшереп тел чарларга яратмаганга, ул күп нәрсәне белми дә иде кебек. Баксаң, һәр авыл хатыны кебек, аның белмәгән нәрсәсе юк.

— Ходай кешегә буй бирсә, акыл бирми ди, Талия дә шуның шикелле,— диде аннары Зәбирә түти.— Төскә-башка дисәң, исләрең китәр, холкы — ташка үлчим. Әтисе мәрхүм Гапсаттарга охшаган. Авыр туфрагы мәрхүмнең җиңел булсын, ут ягып кычкырышалар иде. Бөтен тирә-күрше тыңларга чыга торган иде. Без, балалар, исебез китеп тора идек. Каян шулхәтле сүз чыгарырга кирәк!.. Талия нәкъ әтисе инде, хәтта аннан да уздыра. Әтисе аның, ни әйтсәң дә, өе тирәсендә генә шаулый торган иде, ә монысы кая барса, шунда. Хәзер бит элекке заман түгел, хатын-кыз да күп йөри, күп җирдә була. Шул теле аркасында Талия бер җирдә дә төпләнеп эшли алмый, хәзер аңлап алалар үзен. Тормышын да рәтләп төзи алмый. Баштарак бер башкортка кияүгә чыкты. Башкорты болай бик әдәпле иде, берәүгә бер кычкырмас, берәүнең бер хәтерен калдырмас. Тик курай тарта, озын көйгә салып җырлар җырларга ярата торган иде. Мескен, Уралкаен бик сагына торган иде. Без бит Урал тауларын җырда гына ишетеп беләбез, безнең өчен ул җыр гына, ә Аралбай аңа инәем ди торган иде. Мин үзем аның җырын бик яратып тыңлый идем. Татар да җыр белә, татар да борынгы җырларны ярата, әмма башкортның күңеле киңрәк, ахрысы. Аралбай җырлый башласа, бөтен тыкрыгыбыз аякка баса иде. Без бит җырлаганда кычкырырга яратмыйбыз, башкортның каян тавышы чыга диген. Болай эштә, тормышта Аралбай басынкы иде, машинасын да бик иплән йөртә торган иде. Шофер иде. Хәзер ат бетеп бара бит, шофер кешегә һәркемнең йомышы төшә. Шул беркемне борып кайтармый иде, тик хатынга гына әйтә күрмәгез, ди торган иде. Сөйләшүе гел татарча, тик кайчакта гына бармай, килмәй дип кыстыра иде. Кучы бит шуны Талия. Аннары тагын кемгәдер чыккан иде, дүрт-биш ай

тордыларны икән, канга батып сугышып аерылдылар. Хәзер өченчесен йортка кертергә йөри ди. Ата кулы күрмәгәч, малае да... Ата-ана булмагач, бала, билгеле, инде, төрле якка иярә. Күршеләре ул малайдан бик зарланалар...

Әллә кайдан көткәнең кайчак үзеңнең өеңнән чыга икән. Гәүһәр икенче көнне көтә-көтә алҗып бетте.

## 10

Акназарның көтмәгәндә качып китүе Гәүһәрне уйланганнан күбрәк куркуга салды. Башта ул моңа бала шуклыгы, бала беркатлылыгы итеп карады, иртәгә кабат чакырыр да эше бетәр, дип уйлады. Акназарны ачуланмады, йомшак кына итеп, хәтта елмаеп, нигә кичә качтың? Мин сиңа рәсемнәремне күрсәтергә уйлаган идем, диде. Акназар: «Кирәге бар иде», дип әйтмәсә дә, күз карашы шуңа бик якын иде. Гәүһәр аптырап калды. Ике тапкыр Акназарларның өенә барып, әнисен очратмады. Өченче тапкыр баруында бер карчык, Талиянең кардәше булса кирәк, Гәүһәрне кызганып:

— Кеше баласы артыннан йөрисең дә йөрисең,— диде.— Талиягә синең килүеңне әйткән идем, аларга шуның өчен акча түлиләр, тагын килер әле, ди. Мин үзем мәктәп күрмәсәм дә, укытучыга алай карамыйм, хәзерге яшьләрне белмәссең тагы. Зинһар, үзеңә генә әйтәм, кешегә сөйләмә, бу араларда Талиябез кияүгә чыкты, кеше күрергә вакыты да булмагандыр. Малае да бер разбойник инде, бер дә әйткәнне тыңламый, берничә көн инде кунарга да кайтмый, күршеләрдә кунып йөри...

Бу хәбәр Гәүһәрне бик куркытты. Ул шунда ук күршеләренә керде. Олырак яшьтәге бер хатын аны каршы алды. Өйдә тагын бәлтерәп беткән бабай гына бар иде. Укытучыны танygач, хатын бик ягымлы итеп:

— Әйдүк, әйдүк, түрдән уз,— диде.— Хәзер самовар куеп җибәрәм.

— Юк, юк, апа, зинһар, мәшәкатьләнмәгез. Мин бер генә минутка.

— Укытучыны чәй эчерми чыгарырга ярыймы соң, кызым. Исемеңне белмим.

— Гәүһәр исемле булам, бабай.

— Гәүһәр дисеңме? Бик яхшы, бик күркәм исем. Алайса Зиләбез сине мактый инде. Һич авызыннан төшерми. Кем, килен, самоварың куйдыңмы? Шундый кадерле кунакны чәй эчерми җибәреп буламы! Менә мин үзем йөри алмыйм инде. Сиксән җиде белән барам. Җәйгә чыксам, рәтләнермен дип торам әле. Былтырлары кибеткә хәтле баргалый идем. Быел бирештем шул.

— Зилә кайда соң? — дип сорады Гәүһәр.

— Килен, Зилә кайда? Кибеткә-фәләнгә җибәрмәдеңме?

— Урамдадыр, әткәй.

Чәй эчкән арада Гәүһәр, ниһаять, Акназар турында сорады.

— Кеше баласы турында, Гәүһәр, начар сөйләп булмый инде. Бу көннәрдә Талия кияүгә чыккан бугай, өйләре бик зур түгел, Акназар бездә кунып йөрде.

— Кем турында сөйлисең, килен?

— Акназар турында, әткәй.

— Ә-ә, Акназар... Ут малай. Яхшы ата кулында булса, бик башлы малай чыгар иде аңардан. Атасы юк шул.

— Ир балага ата кирәк,— диде хатын да.— Ни хәл итәсең. Аралбае болай бик кешелекле иде дә, Талиянең холкы бераз чуаррак.

— Чуар гына түгел, килен, артыгы белән. Җәй көне шулай бер кисәткән идем үзен, шундый яшелле-кызыллы булды, син әле тончык-

мадыңмыни, ди, сакалымны хурлады. Кешенең ак сакалын хурлагачны кая күргәнең бар? Шундый кеше ул, ходай күрсәтмәсен. Менә бала... Анасы яхшы булса, бала аңа аркан борылыр идеме? Юк. Бала күңеле бик тирән сизә.

Икенче көнне дәрестән соң Гәүһәр Зиләгә беразга калып торырга кушты. Зилә, әлбәттә, карышмады, ләкин бик сагайды. Ул инде укытучының кечә үзләрендә булуын белә иде. Акназар аның янында бик бөтерелде, ул нәрсәдер әйтергә теләде бугай, ләкин укытучыдан оялды булса кирәк, чыгып китте.

— Зилә, бабаң ничек? — дип сорады ахырда Гәүһәр,— син бабаңны кыерсытмыйсыңмы?

— Юк.

— Аңа кычкырмыйсыңмы?

— И-и! Ул үзе дә бер дә әрләми. Мин аны яратам.

— Әниеңне дә яратасыңдыр инде.

— Яратам.

— Аңа авыр шул, Зилә. Әнә бабаңны да, сине дә карарга кирәк, житмәсә больницада да эшли әле.

— Әнине больницада да яраталар, ул кемгә дә ачуланмый. Әнә Талия апа гына бөтен кешегә кычкыра...— Зилә ярамаган сүз әйтеп ташлавын аңлады булса кирәк, башын аска иде. Шуннан соң, Гәүһәр никадәр генә тырышса да, Зилә артык сөйләмәде, Акназар турында да бернәрсә дә әйтмәде. Кызарып, аска карап торды. Гәүһәр Зиләнең Акназар турында күп нәрсә белүен аңлады, ләкин нихәтле сораштырса да, бала эндәшмәде. Тагы бер-ике сорау бирсәң, еларга тора. Баланы елату ярамый, аннары бөтен эш бозылып китүе мөмкин. Гәүһәр Зиләгә кайтырга рөхсәт итте.

Кызчык, портфелен алып, класстан әкрен генә чыгып китте, аннары коридорда аның йөгергән аяк тавышы ишетелде. Бераздан Гәүһәр тәрәзә янына килде. Зилә ялгыз гына мәктәптән чыкты. Спорт мәйданчыгы янында аның катына Акназар йөгереп килде һәм алар чатта күздән югалдылар.

Гәүһәрнең күз карашы уйчан иде. Хәзер инде яшерен-батырын түгел, Акназар, бала булса да, үз эченә бикләнеп йөри, сабакташлары әкрен-әкрен аннан читләшәләр, ул үзен ялгыз сизә. Аның беркеме дә юк, ул даладагы ялгыз тирәк, кайсы яктан җил катырак иссә, шул якка бөгелә, башкача аның бер чарасы юк.

Гәүһәр шул ук көнне Акназарның әнисенә хат язды. Талия килмәде. Икенче хатка да шул ук җавап, дөресрәге, бертөрле дә җавап юк иде. Гәүһәр ни уйларга да белмәде. Яшь ананың шундый гамьсезлеге аны чиксез гаҗәпләндерде. Баланың өч-дүрт көн бөтенләй кунарга кайтмавы аны бер дә борчымыймы икән? Хәзергә ул күршеләрендә куна, ә бераз үсә төшкәч? Хәзер үк инде ул әнисен санга сукмый, ә соңыннан?

Гәүһәр мәктәп директоры янына керде, нәфрәтен яшермичә, Акназарның әнисе турында сөйләп бирде. Бибинур апа бик дикъкать белән тыңлады. Талия аларның мәктәбендә җиде классны тәмамлаган. Соңгы вакытларда Бибинур Талияне бөтенләй күздән югалткан. Аның семья тормышы турында бик аз белә. Дөрес, кычкырышулары турында ишеткәләгән, Яшел Яр — кешеләрнең семья тормышлары тоташ сер булып кала торган зур кала түгел.

— Тагын бер тапкыр, Гәүһәр, барып кара. Укытучылар балаларның өйләренә йөргән өчен акча алмыйлар, ләкин бала язмышы аларга кадерле.

Гәүһәр шул ук көнне Талияләргә барды, ләкин тагын ананы очратмады, икенче көнне Талия үзе мәктәпкә килде. Өсте-башына тел тидерерлек түгел, район үзәгендә хәтта артык модный киенгән. Хәзер кичке-

нә калаларда да яхшы кисенәләр, шулай да чамасын беләләр. Талия гүя моны искә дә алмаган. Үзем матур булгач, киемем генә кеше хуры булмас, дия иде шикелле аның күз карашы. Хәер, Гәүһәр аның киеменә артык игътибар итмәде, Зәбирә түтинең нәфрәтләнеп әйткән сүзләре, Рәми бабайның рәнҗүләре әле аның колагы төбендә. Ул Талиягә урындык тәкъдим итте, үзе дә аңа каршы утырды.

— Балагыз бик сәләтле, укырга да, рәсем ясарга да... Аңа хәзер бөтен нәрсә җиңел бирелә, шуңа күрә дәрес хәзерләүгә бөтенләй көч куймый диярлек. Иптәшләре белән аралашмый, үз эченә бикләнеп бара. Минемчә, аны бу хәлдә калдырырга ярамый, югыйсә бик күңелсез бетүе мөмкин. Ишетелгән хәбәрләргә караганда, ул берничә көн кунарга да кайтмаган икән...

— Аһ! — диде Талия, тирән эчке кичерешкә охшатып.— Мин боларны белмиммени! Минем инде болай да башым каткан... Әтисе кире беткән бәндә иде. Мин, хатын-кыз кеше, нишли алам... Колониягә озатырга кирәк аны, тимер сак астына! Минем артык көчем җитми, теләсә нишләтсен үзен, минем башка бер эмәлем дә юк...

Теләсә нинди очракта да ана баласына карата мондый авыр сүзләрне әйтмәс, дип уйлаган иде Гәүһәр. Ул белгән кадәренчә, Акназар андый өметсез малай түгел бит. Әлбәттә, ул шаяра, арттырыбрак җибәргән чаклары да бардыр, ир бала бит ул, көче, энергиясе ташып тора, ләкин аңардан кул селтәү, аны колониягә озатырга теләү — моны Талия малайның үзенә дә әйтә торгандыр! — бу бит коточкыч. Гәүһәр моны беренче тапкыр ишетә. Ул үзенең барлык уй-тойгыларын ышереп, Талиягә ана вазифасы, ана мәхәббәте турында сөйләде. Хатын-кызга бала тәрбияләү, бигрәк тә ир бала тәрбияләү, җиңел эш түгел, мәктәп белән, укытучылар белән берлектә булганда гына...

— Аһ! — диде Талия, күзләрен әйләндергәләп,— минме бу турыда уйламаган... Мең уйлаган, башым менә чуен кебек, дың-дың итә... Ходаем, нишләргә инде миңа? Мәктәп тә бер ярдәм итми. Кая барып бәрелергә дә, кемнән ярдәм сорарга да белмим. Шундый бәйдән ычкынган дөньяне тәрбияләү хатын-кыз эшемени? Әйткән сүзеңне тыңласа иде, ичмасам. Югыйсә бер сүзеңне колагына элми, мәктәптән кайта да чыгып китә. Күршеләрнең Зилә исемле бер башкисәр кызлары бар, гел шуның белән. Мин ул кызны...

— Туктагыз әле, Талия... Зилә, минемчә, бик акыллы кыз, бабасы белән әнисе дә яхшы кешеләр.

— Ходаем, шулар да яхшы булса! Ул тончыгуны белмәс явыз карт, больницада кеше астын чистартудан артыкны белмәгән килене...

— Юк, Талия, яхшы кешеләргә яла якмагыз. Сез үзегезнең балагыз турында сөйләгез.

— Аның турында мең сөйләгән инде.

— Акназарның әтисе кайда? Аны күреп булмыймы? Без чакыртыр идек.

— Һ-һ-һ! Койрыгын күтәрде дә очты, бар, эзлә, хәзер, табарсың...

— Алимент ала торгансыздыр бит?

— Алды ди менә... Аның унбиш-егерме сумы... Айгыр хәтле малайны ашатырга...

— Ул вакытта Акназарның хәзерге әтисе белән сөйләшергә рөхсәт итегез.

Гәүһәр Талиянең ай саен Аралбайдан акча алып торуын белә иде, шулай ук Талиянең яңа ире барлыгы да аңа билгеле. Шуларны искәртмәстән әйткәч, Талия бер минут тын калды, матур йөзе коточкыч үзгәрде, сөрмәләнгән күзләре түгәрәкләнде. Бу укытучы Талияләрнең өенә генә килеп калмаган, ул күршеләрдән дә... Тукта, Талия аларга күрсәтер әле, ник ишекләрен ачуларына үкенерләр. Бу укытучы да күп

җиргә борынын тыкмасын, югыйсә кемлеген бик тиз әйтеп бирерләр үзенә.

— Анысы тагын нәрсәгә? — дип сорады Талия ачу белән.— Бүген килгән кешенең кемнәндер баласында ни эше бар?! Төкерә ул аңа.

— Туктагыз әле, Талия. Минемчә, ул акыллыдыр. Өйләнгән икән, бала турында белми булмас. Белә икән, ул ихтыярн рәвештә аны уллыкка ала, аның тәрбиясе турында да кайгыртырга тиеш.

— Кайгыртты ди менә. Кеше баласыннан янтыгы авырта ди менә.

— Болай булмый бит, Талия. Акназарга тәрбия кирәк. Бергәләп шул турыда уйлашыйк.

— Ярар, алдан баш ватарга... Пычагым да булмас әле үзенә, ничек торды, шулай тора бирер.

Талия белән артык сөйләшеп торуның мәгънәсе юк иде. Гәүһәр моны бик яхшы сизсә дә, әле байтак утырды, тавышын бер дә күтәрмәде, ачуы бик килгәндә дә эчкә йотты, ул бер генә минутка да үзенең укытучы икәнен онытмады. Мәсьәлә артык катлаулы, аны ордымбәрдем хәл итәргә ярамый, төрле яклап карарга кирәк. Ул Талиянең аналык хисләрен дә, горурлыгын да, халык арасындагы яхшы исемен дә телгә алды. Тагын бер мәртәбә Акназарның ул хәтле бозык юлга басмаганлыгын, аны колониягә озату турында сүз дә була алмавын әйтте. Талия бер нәрсә дә ишетергә теләмәде. Аның үз туксаны туксан! Бары тик шуннан соң гына Гәүһәр:

— Минемчә, сез бүген артык дулкынлангансыз, Талия,— диде.— Кирәкмәгән сүзләр дә әйтеп ташладыгыз. Мин аңлыйм, анага баладан да газиз кеше юк. Сез әле уйларсыз, үзара киңәшерсез. Билгеле, үз өстебезгә төшкәнен без дә кайгыртырбыз, тик ана мәхәббәтенә, ана кайгыртуына җитми инде ул.

Талия бик җилләнергә дип килсә дә, вакыты-вакыты белән җилләнеп китәргә әзер торса да, Гәүһәр аны коралсызландыра барды. Талия хәтта мәктәптән чыгып киткәндә дә үз-үзеннән канәгать түгел иде. Шул чүпрәк баш алдында эреп төште бит. Ире ни өчен куганын битенә бәреп әйтсәң, аннан соң кеше белән ничек сөйләшергә кирәк икәнен белер иде. Исе китте ди Талиянең бер башкорт калдыгына. Уйларсыз, үзара киңәшерсез, имеш. Киңәштеләр ди, тот итәгеңне!

Талияне озаткач, Гәүһәр директор янына керде. Аның чырае караңгы, кәефе кырылганлыгы әллә кайдан күренеп тора иде. Бибинур моны ачык сизде. Аның бераз бавыры авыртып торса да, Гәүһәрне хәзер үк тыңларга риза булды. Шул чакта кабинетка өстенә соры каракүл якалы пальто кигән, бүреген кулына тоткан, озын буйлы, тар йөзле бер кеше килеп керде. Күзләре тере, кешегә игътибар белән карыйлар. Бик ягымлы иттереп Бибинур белән күреште, аннары директор аны Гәүһәр белән таныштырды. Гәүһәр районда эшләүче Әгъзәм Ибраһимов турында ишеткәне бар иде.

— Менә үзегезне күрергә дә насыйп булды,— диде Әгъзәм, Гәүһәрнең кулын кысып.— Бик шатмын. Тик сезнең кәефегез нигәдер кырылган кебек. Авырмый торгансыздыр бит?

«Кара, күзләре очлы икән»,— дип уйлады Гәүһәр. Акназар турында сөйләп бирде. Аннары чак кына кызарып:

— Сезнең начальник икәнегезне онытып та торам тагы, әллә нәрсәләр сөйлим шунда,— диде.

— Юк, нигә әллә нәрсәләр булсын, шулай бит, Бибинур апа? — диде Әгъзәм, директорга таба борылып.

— Әлбәттә,— диде Бибинур.

— Мин белмим,— диде Гәүһәр, яклау сүзләрен ишеткәч,— бу чибәр Талия... Баласы турында тәмам ят кеше төсле сөйләшә. Үзенең бәгырь алмасын хәтта колониягә озатырга хәзер. Әйтерсең, колония-

нең нәрсә икәнен белми. Минемчә, баланың язмышын мәктәп үз кулына алырга тиеш.

— Әтисе юкмыни аның? — дип сорады Әгъзәм.

— Аерылышканнар. Әйтүләренә караганда, ул шофер булган, йомшак холыклы. Семья тормышлары бозылгач, каядыр китеп барган. Бәлки белә торгансыздыр, башкорт Аралбай...

— Юк, белмим. Малае яхшымы соң?

— Мин үземнең балаларыма начар характеристика бирә алмыйм, иптәш Ибраһимов. Малай бераз үзенчәлекле булса да, кул селтәрлек түгел. Аннары ул өченче класста укучы бала бит. Бөтен киләчәге алда.

Бергәләп уйлашырга дигән фикергә килделәр.

## 11

Яшел Ярның урамнарында да, мәктәп бинасында да кояш нурлары мул иде. Гәүһәр генә ничектер кояшны күрмәде. Ләкин бер көнне иртән күзенә кояш нуры төшүдән уянып китсә, ни күрсен, бөтен өй эченә кояш нуры тулган! Гөл яфраклары, гөл чәчәкләре кояшка шулхәтле шатланганнар кебек, Гәүһәрнең исе китте. Ул күзен йомды, ләкин йомык күзләргә дә шул кояш яктырткан гөл чәчәкләре генә күренде. Мондый чакта урында аунарга мөмкинме соң! Кай арада Гәүһәр сикереп торды да, кай арада халатын киеп, гөлләр янына килде, чәчәкләрне иснәде, тышка карады. Җылытканлыгы тәрәзәдән дә күренеп тора. Кар әле күп булса да шактый утырган инде, яз ишек кага, тәрәзәдән карый. Аңлашылмый торган бер шатлык Гәүһәрне биләп алды. Болай шатланырга сәбәп юк иде шикелле. Шәхси тормышында да, мәктәптә дә ул-бу юк, Акназар язмышы да хәл ителмәгән. Бибинур апа да, Әгъзәм дә берни эшли алмыйлар, ахрысы.

Ишек ачылган тавыш ишетелде, күрәсең, Зәбирә түти тыштан керде. Кош-кортлары белән кәҗәсе янына ул таңнан чыга. Бүген ял көне булгач, Гәүһәр озаграк йоклар дип уйлаган иде, күр, тынгысыз җан, торган да инде.

— И-и, минем самоварым да куймаган әле,— диде Зәбирә түти, Гәүһәрнең үз бүлмәсеннән чыгуын күргәч. Шунда ук иске бишмәтен сала башлады.

— Зәбирә түти, тышта бик җылытып җибәргән, ахрысы.

— Бик. Чыксаң, керәсең килми. Мартта шарт диләр.

Бераздан Гәүһәр юынып керде, чәчен тарады. Толымлы чакта рәхәт иде, хәзер менә парикмахерга да барырга кирәк. Монда мастерлары да шулчаклы гына, ә хатын-кыз бу мәсьәләдә аеруча таләпчән. Казан Мәскәүгә, Ленинградка карап йөз тотса, Яшел Яр Казаннан күчерә.

— Әйдә, Гәүһәрем, утыр инде. Көзгегә бик күп карадың, харап матурайгансың инде.

— Зәбирә түтинең ике күзе, тел очында безе. Миңамы соң инде матураерга.

— Ярый, ярый, Алабуга җиңгәсе булма әле. Пәри шәһәрчегеннән төшмәгәнсеңдер.

Гәүһәр, чәй эчә-эчә, бүген Миләүшә белән Вилдан килергә булдылар, диде.

— Бик яхшы. Кунак килсә, өй ямьләнә.

— Өй ямьләнер дә, өстәлгә ни куярбыз. Миләүшә генә булса, ничек тә узар идек, Вилданы бар бит. Беренче тапкыр килә. Син Вилданны беләсеңме? Яшел Яр егете бит.

— Җаным-бәгырем Нурдидә малаен белмәскә тагы! Тәпи йөргән чагыннан бирле беләм. Укыган елларында гына бераз югалып торды.

— Күгәрчен суы алабызмы?

— Ансыз дөнья сансыз булса да, укытучы кешегә кирәкмәс. Алай-болай булса, бөтен гаепне үз өстемә алырмын. Бәлеш пешерәбез, чәй-коймагын кайнарлый гына өлгертербез. Кәнфитебез бар. Шул житеп торыр. Бик кирәк булса тагы, чәйгә салырга кәжә сөте куярбыз.

— Синең белән югалмабыз, Зәбирә түти. Хәзер башыма яулык ябам да янына булышырга чыгам.

Таралып торган чәчен арттан резинка белән кысып, биленә ак алъяпкыч бәйләп Гәүһәр бер минуттан кече якка чыкты, уен-көлке сүзләр белән Зәбирә түтисенә булыша башлады. Камыр бастылар, бәлеш ясадылар. Ул арада Зәбирә түтинең миче өлгерде. Бәлешне тирән таба белән кайнар күмер өстенә куйдылар. Мич алдында Зәбирә түтинең йөзе кызарып киткән иде. Яулык чите белән тирен сөртте дә инде савыт-саба юарга керешкән Гәүһәргә карап тора башлады. Зәбирә апа үзе гомер буе инде мич каршында, ә менә Гәүһәр каян өйрәнгән?

Савыт-сабаны юып бетергәч, бәлешнең ничек пешүен тагын бер тапкыр тикшерде дә, Гәүһәр өстен-башын рәтләргә китте. Сәгать инде бер тула, озакламыйча Миләүшә белән Вилдан килерләр. Аларга сәгать бергә-икегә килегез дип әйтелгән иде.

— Ярый, Гәүһәр, мин чыгып каз-тавыкларымны карыйм, кәжә бәтиләрем дә әнә мич астыннан туктаусыз тавыш биреп торалар. Аларны да әнкәләре янына чыгарасы бар.

Зәбирә түти, тагын иске бишмәтен киеп, өйдән чыгып китте. Гәүһәр үзалдына җырлый-җырлый киенә, бизәнә башлады.

Радио кысып кына куелганга, татарча концертны ишетми дә калдылар. Гәүһәр радионың тавышын көчәйтеп куйганда, ниндидер пьеса тапшырыла иде. Гәүһәр тыңлап-тыңлап карады да нинди пьеса икәнен белә алмады, күрәсең, яңа бер нәрсәдер. Тик артистлардан Габдулла Шамуков белән Нәҗип Гайнуллинның һәм Рәшидә Җиһаншинаны гына таныды. Соңгысы бәлки Рәшидә дә булмагандыр, чөнки яшьләр өлкәннәргә бик нык охшатырга тырышалар.

Шунда Гәүһәрнең исенә бәлеше төште. Тиз генә мич каршына барып, мич капкачын ачты да бәлешне карады, Зәбирә түти әйткәнчә, алгарак тартып куйды. Аннары өстәлгә яңа ак ашъяулык япты, кәнфитләрен, вареньесын чыгарды. Ул арада Зәбирә түти керде, коймак пешерергә тотынды. Әллә ни юанмаслар инде. Шулай гына уйлаганнар иде, капка ачылган тавыш ишетелде. Гәүһәр тәрәзә янына килде. Өстенә әйбәт язгы пальто, башына эшләпә кигән Вилдан, бераз алдарак, өстенә зәңгәр пальто, башына ак шапка кигән Миләүшә күренде.

— Зәбирә түти, кунаклар.

Ул арада ишек ачылды, алдан Миләүшә, аның артыннан Вилдан килеп керделәр.

— Ничек көттерәләр, бәяләре мең алтын торганны яхшы беләләр,— диде Зәбирә түти, кунакларны каршы алып.— Үзегез сау-исәннәрме, әниегез Нурдидә йөгереп йөриме?

Гәүһәр Миләүшә белән үбешеп күреште, Вилданга кул бирде, киемнәрен салырга кушты. Вилдан Миләүшәнең пальтосын, аннары бүреген чөйгә элде, соңыннан үз киемен салды, чәчен тарый-тарый түргә узды.

— Үзебез, Зәбирә түти, тимер кебек таза, әнкәй дә бирешми.

— Алай булса, бик яхшы. Әйдә, яхшылап утырыгыз, мин хәзер.

Гәүһәр белән Миләүшә Гәүһәр бүлмәсенә кереп китеп, нидер пышылдаша башладылар, Вилдан стеналардагы рәсемнәрне карап алды. Ул Гәүһәрнең рәсем ясавы турында ишеткәләгән булса да, әмма эшен бүгенгә хәтле күргәне юк иде. Рәсемнәрендә кояш нуры ялтырый кебек. Шул ук вакытта бер рәсемдә дә кояш үзе күренми. Монда инде ниндидер күләмдә осталык башлана. Дөрес, Вилдан бу өлкәдә үзен белгеч санамый, аның карашы бик субъектив булуы да мөмкин. Ләкин рәсемнән рәсемгә күчә-күчә аның шул уе ныгый барды.

— Менә шул инде Гәүһәр апаның рәсемнәре. Мин сиңа сөйләгән идем бит. Бу бүлмәдә дә бар әле. Карыйсыңмы?
— Ярыймы, Гәүһәр апа?
— Рәхим итегез, ләкин бу рәсемнәр бар да өйрәнчек эшләр генә.
Бу бүлмәдәге рәсемнәр Вилданны тагын да кызыктыра төште бугай. Менә монысы Кама буе. Миләүшә сөйләгән иде. Текә яр башындагы карт имән, яфракларында көз бизәкләре. Тын, кояшлы кич, ниндидер тантана һәм яшерен бөеклек. Кеше дә юк, елга өсте дә буп-буш, әмма бөтен рәсем яшәү җырын җырлый. Алай гына да түгел, менә шушы имән артында Миләүшә яшеренгән кебек, әнә ул... көлә, көмеш тавышы чыңлый, аңа кушылып, су өсте дә, меңләгән яфраклар да көләләр кебек. Гаҗәп икән, буяу белән ничек итеп кеше көлүен бирергә кирәк? Әллә Вилдан Миләүшәгә гашыйк булганга гына, Миләүшә ялтырап торган күзләре белән аңа карап торганга гына шулай тоеламы икән?
— Әйе,— диде Вилдан, башын селкеп,— бу рәсем күп уйландыра. Гаҗәп. Миләүшә сөйләгәч, ышанып бетмәгән идем...
— Миңамы ышанмадың? Менә, Гәүһәр апа, ирләр,— диде Миләүшә, ә үзенең күзләре шундый бәхетле, шундый нурлы, аның сөйгәне белән горурлануын әллә кайдан күреп була.
— Миләүшә тагын нәрсәләр булса сөйләгәндер инде...
— И, Гәүһәр апа, хәзер сүзне читкә борасыз.
Миләүшә каршы килеп маташса да, йөзе алсуланган иде. Бу Гәүһәргә җитә калды. Әмма хәзергә берни әйтмәде. Ә менә туй көнне бу рәсемне ул Вилданнарга бүләк итәр. Башкаларга ул яр башындагы бер имән генә булса, Миләүшә белән Вилданга күп нәрсәне искә төшерер. Бу бәхетле уйның башка килүенә Гәүһәр бик шатланды.
— Я, рәхим итегез, табын янына утырыгыз, калганын бередә сөйләшерсез,— диде Зәбирә түти теге яктан.
Башта Гәүһәр, аның артыннан Миләүшә белән Вилдан чыгып, өстәл тирәсенә утырыштылар. Миләүшә өстенә бик килешеп торган шоколад төсендәге күлмәктән, кулында алтын сәгать. Чәче дә нәкъ шул алтыннан коелган төсле. Аз гына алсуланган йөзендә яшьлек нуры, бигрәк тә зәңгәр күзләре бәхетле. Ул Вилданың өй шартларында да курсәтергә теләде. Мәктәптә, укытучылар арасында, кеше үзен саграк тота, бик акыллы сыман күренергә тырыша, ә өйдә болар барысы да югала бит. Өйдә кешенең яңа кара костюмы да, бизәкле галстугы да, хәтта аз гына сипкелле йөзе дә артык күзгә бәрелми, өйдә кеше кеше булып, һичбер бизәксез-нисез кала. Шул турыда Миләүшә бая Гәүһәргә дә пышылдаган иде. Ул Гәүһәргә ышана, аның тәҗрибәсенә, сәләтенә, күзләре үткенлегенә югары бәя бирә. Менә хәзер дә ул Гәүһәргә астан гына карап алды. Гәүһәр сизелер-сизелмәс кенә керфек какты, елмайды. Димәк, аңлый һәм Вилданны хуплый. Миләүшә моңа тәмам эреп китте.
— Зәбирә түтинең бәлеше тәмле икән, телеңне йотарсың,— диде ул кайнар бәлешне ашый-ашый.
— Телеңне йотсаң, Миләүшә җаным, миңа үпкәләмә, бәлешне Гәүһәр апаң пешерде,— дип көлде Зәбирә түти.
— Гәүһәр апа? Ул ашка да шундый остамы? Менә миннән бер нәрсә дә чыкмый. Бер көнне Вилдан булып Вилдан да бәлешемне яратмады.
— Ышанмагыз, Миләүшә әзрәк хәйләли.
— Зәбирә түти дә әзрәк хәйләли. Гаеп булса, икебез өстенә төшсен ди. Монда Зәбирә түтинең өлеше зуррак,— диде Гәүһәр, көлеп.
— И-и, китте тәяп... Зәбирәнең нинди булса да бирәү бер сүз әйтмәс, ә менә яшьләргә әле күп нәрсә кирәк. Кая, Вилдан, тәлинкәңне бирче бирегә. Миләүшәң сыйламас, үзем бәлешнең төбен кисеп

куйыйм. Сиңа да, Миләүшә. Нечкә билләргә дә ярый торган итеп кенә. Югыйсә, кыз сайлаучы егетләр бу нәзберек икән, бәлеш төбен дә ашамый, дип әйтерләр.

— И инде, Зәбирә түти, оялтып бетерәсең. Хәзерге егетләрнең кесәләре бик такыр. Азрак ашаганны яраталар.

— Вилдан, сизәсеңме, синең эшең бик хөрти бит. Гел синең бакчаңа таш ташлыйлар.

— Борчылма, Зәбирә түти, һәммәсен дә мыекка урыйм.

Барысы көлеп алдылар. Шулай уен-көлке белән бик тәмләп чәй эчтеләр. Сүз арасында Миләүшә кич белән кинога барасыларын әйтте. Гәүһәрне дә чакырды. Гәүһәр бераз уйлап торды да барырга риза булды. Әллә Вилданның бу яктан да күрсәтәсе киләме? Әллә Зәбирә түтидән яшерен сүзе бармы?

Нәрсә әйтсен? Вилдан, билгеле, Гәүһәр стилендәге кеше түгел, буе да кыскарак, гадирәк тә, ләкин сөйкемле, эчкерсез. Иң мөһиме, Миләүшәне ярата, әнә, күзен дә алмый бит. Гәүһәр аңардан бу мәктәптә күптән эшлисеңме? дип сорады. Егет бу сорауның ни өчен бирелгәнен дә аңламады бугай, әмма җавабы Гәүһәрне канәгатьләндерде. Вилдан бу мәктәптә Миләүшә килгәнчегә кадәр үк эшли башлаган. Миләүшә монда дүртенче кыш укыта. Бер-береңне белер өчен дүрт ел бик җиткән...

## 12

Бу якларда кар ява башласа, тоташтан бер атна буранлый да кинәттән туктый, ялтырап кояш чыга, дөнья нииндидер аклык, пакьлек белән балкый, һичбер авырлык сизелми, барысы да җиңел сыман, күбекләнеп тора шикелле, кырга ятып туйганчы бер ауныйсың килә. Кышның мамык җәймәсен, мамык юрган кебек төреп, култык астына тыгып алып китәрсең кебек. Бөтен тирә-якта тынлык һәм тынычлык хөкем сөрә, тик юллар чистарткан көрәк тавышлары гына ишетелә. Яктылык тантана итә. Кичә генә бу тәбәнәк күк, бу тоташ кар, бар дөньяга сарылган бу караңгылык бик озакка килгән күк тоела иде, бүген күр, эзе дә юк боларның, бер-ике көннән елгалар чылтырап агып китәрләр. Ихтыярсыз Кама буйларына карыйсың: анда әле кар, ап-ак диңгез, калын боз, ләкин күп тә үтмәс, бу калын бозлар шаулап ярылыр, язның бөек көче бар нәрсәдән куәтле сыман тоелган бозларны челпәрәмә китереп ватар, мәгърур елганы кышкы зынҗырлардан тулысынча азат итәр, елга, иркенләп бер сулыш алгач, уйнап, шаярып, үзенең озын юлына чыгып китәр. Дулкыннары әкрен генә үз алларына, моннан мең ел элек булган төсле, чайкалырлар, тибрәнерләр, мәһабәт теплоходлар, олылыкларын саклап, елга уртасыннан йөзәрләр.

Язны бигрәк тә балалар сагынып көтәләр. Аларның күзләре тәнәфес вакытларында гына түгел, дәрес барган чагында да тәрәзәдә, кошлар чыркылдашуында да, машиналар гөрелтесендә дә алар әллә нәрсәләр ишетәләр. Дәрес бетүгә аларны мәктәптә тотармын димә, тимер чылбырга бәйләсәң дә тышка омтылалар. Тышка чыгуга ялан кул, ялан баш кар атышырга керешәләр, бит урталары кызарып чыга, күзләре очкынлана...

Билгеле инде, укытучы балалар күңеле белән яши, аларның беркемгә дә әйтмәгән һәм әйтелмәячәк серләрен укый. Бу серләр аны кайчак шатландыра, сөендерә, кайчак бик куркыта. Кайчагында классындагы бөтен балалар түгел, бәлки берничәсе яки берсе генә аны җәлеп итә. Менә хәзер дә Гәүһәр күбрәк Акназарга карый. Терсәгенә таянып, тәрәзәдән күзәтә. Укытучының сүзләрен гүя тыңламый да. Сорасаң, җавап бирә. Әмма Гәүһәр ачык сизә: Акназар гүя табигатьтәге һәм

кешеләрдәге үзгәрешнең нәкъ киресе булырга тырыша, чырае көннән-көн караңгылана бара, иптәшләре белән сөйләшми, хәтта Зиләгә дә ачуланган бугай, аңа карамый, сорауларына җавап бирми, мәктәптән берүзе китә. Әйтүләренә караганда, Акназарның әнисе Зиләләргә кереп бик каты тавыш күтәргән, улын кулыннан җитәкләп, сөйрәп алып киткән. Берничә сәгатьтән Акназар, качып, тагын Зиләләргә килгән, ләкин Рәми бабай да, Зиләнең әнисе дә Акназарга өенә кайтырга, әнисен бимазаламаска кушканнар. Бала моны үзенчә аңлаган булса кирәк, Зиләгә бик каты үпкәләгән.

— Әни дә, бабай да Акназарны кумадылар, әниеңне генә ачуландырма, диделәр. Көндез дәресләрен хәзерләргә килергә куштылар. Хәзер Акназар безгә бөтенләй керми, гел урамда йөри. Мин аны әллә ничә тапкыр чакырып карадым, ул сөйләшми дә,— диде Зилә Гәүһәргә, үзе чак еламый. Башка укучылар да Акназардан гел зарландылар, әле анысын, әле монысын үкертеп кыйнаган. Элек Акназар мәктәптә артык сугышмый иде, әнисе килеп киткәч, бигрәк зәһәрләнде. Бала күзгә күренеп бозыла, бүген менә дәресен дә хәзерләмәгән. Интернатта бер урын юк, Бибинур апа күпме тырышып та таба алмады. Шул ук вакытта балалары кыйналган ата-аналар әледән-әле директор янына кереп Акназардан зарланып чыктылар. Гәүһәр, аптырагач, Әгъзәм Ибраһимов янына районга барып, Акназарга ничек тә ярдәм итүен үтенде.

— Бала күз алдында бозыла бит. Пароход юлы төшкәч, аның бөтенләй китеп баруы бар. Аннары безнең беребезгә дә аклану булмаячак, Әгъзәм иптәш. Бер көнне мәктәп коридорыннан киләм шулай. Акназар белән бер малай багана артында сөйләшеп торалар. Акназар нидер ясап бирүләрен үтенә. Синең әтиең мастер, ул ясап бирер, ди. Икенче малай әтисенең кәефе юклыгын, кичә телевизор да карамаганлыгын әйтә. Аларның заводында хезмәт хакын кассирсыз биреләләр икән. Өстәлгә куялар да һәркем үзенекен ала. Кемдер малайның әтисенә дигән эш хакын алган, әйтмәгән дә. Элек аларда шундый бер хәл булган, ялгышлык белән алган акчаны икенче көнне үк китереп биргәннәр. Ә бу юлы өч-дүрт көн узган, китереп бирүче юк. Күрәсең, яңа эшчеләрдән кем дә булса алгандыр.

— Алай, акчасыз калдыгыз? — ди Акназар.

— Юк,— ди икенче малай. Аның әтисенә иптәшләре акча җыеп биргәннәр.

— Ә сез шуны балаларга сөйләргә уйламыйсызмы? — диде Әгъзәм.

— Туктагыз, Әгъзәм иптәш. Сез мине аңламадыгыз бугай,— диде Гәүһәр.— Акназар әйтә: акчаны саклап торырга бер кеше куярга кирәк, ди. Икенче малай әйтә: безнең әтиләр сакчы куймыйлар. Бөтен цех каракны сүгә. Ул артык урламас, ди. Акназар көлеп җибәрде. Бала көлә. Мыскыллап көлә. Димәк, ышанмый, акчаны сакчысыз куючыларны ачык авызларга саный. Йомгаклап әйткәндә, баланың тәрбиясендә ике башлангыч бар, аның кайсы өстенлек алуы безгә, тәрбиячеләргә, бәйләнгән. Акназарның әнисе нинди икәне сезгә мәгълүм. Мин анардан, һәрхәлдә, яхшылык көтмим. Сез мине дөрес аңлагыз, Әгъзәм иптәш: укытучылар тәрбия эшеннән баш тартмый, әлеге очрак турында да сүз булыр. Ләкин баланы өй тәэсиреннән тартып алырга кирәк.

Әгъзәмнең тар йөзенә күләгә ятты. Ул вәгъдәләр бирмәде, юатмады, тынычландырмады, бары тик бу мәсьәлә белән тагын шөгыльләнәчәген әйтте. Гәүһәр үзе дә ел бетәргә торганда интернатка бала урнаштыру никадәр читен икәнен белә, ләкин шундый хәл килеп чыккан икән, нишлисең, юкны да табарга кирәк, читтән килеп табып бирмәсләр бит,

Әгъзәм аны игътибар белән тыңлады, тик бер тапкыр гына аңа тутырып карады. Гәүһәр моны сизде, уңайсызланды. Бәлки бу Гәүһәр аңлаган мәгънәдә дә булмагандыр, Әгъзәмнең гади бер күз карашы Гәүһәргә шулай тоелгандыр. Үзеңнең шикләреңне кешегә тагарга ярамый, әллә нинди җайсыз хәлләргә калуың бар.

Өйгә кайткач та Гәүһәр беркадәр вакыт Әгъзәм Ибраһимов турында уйланды. Бу аларның икенчеме, өченчеме очрашулары иде. Беренче очрашулар бер дә истә калмаган. Азмыни укытучылар район кешеләре белән очраша. Дөрес, хатын-кызларга хас кызыксыну белән Гәүһәр Әгъзәм турында аз-маз сораштыргалаган иде. Шул гына. Бүгенге очрашуда да әллә ни булмады. Бер тапкыр Әгъзәм аңа тутырып караган икән... Тик шунысы гаҗәбрәк: Гәүһәр аны үзе дә сизмәстән Җәгъфәр белән чагыштырды. Дөрес, бу тыштан гына чагыштыру иде, чөнки Әгъзәмнең эчке дөньясын ул бөтенләй белми. Аһ итеп торырлык бер нәрсә дә тапмады Гәүһәр. Кайбер хатын-кызларның аны мактап телгә алулары Гәүһәргә кимендә сәер булып тоелды: Җәгъфәр әнә нинди иде дә нишләп ташлады...

Икенче көнне Гәүһәр Акназарны тагын үзләренә чакырды. Бармас, дип уйласа да, Акназар бик тиз риза булды. Гәүһәр журналын укытучылар бүлмәсенә кертеп, киенгән арада Бибинур тагын бер күңелле хәбәр әйтте: иртәгә интернатта Акназарга урын табачаклар. И шатланды Гәүһәр, ә директор әйткәч, Әгъзәм турында уйлап алды: сүзләрен җилгә чәчми, эшен эшли икән.

Акназар киенеп аста көтеп тора иде.

— Мин хәзер,— диде Гәүһәр малайга,— менә ачкычны гына куям.

Бераздан алар урамга чыктылар. Көн тәмам җылыткан, шабырдап тамчылар тама. Юлларда чыпчыклар инде чыркылдашып су коеналар, түбә кыекларында күгәрченнәр гөрли, кайдадыр казлар гайрәтләнеп каңгылдый. Күк йөзе чиста, зәңгәр, кояш көлә, бик йомшак булып җылы җил исә. Урамнарга кәҗәләр чыккан, юл буенда чемченәләр, түшләрен киереп әтәчләр кычкыралар. Ашханә каршында әллә нихәтле машина күренә. Халык та бик күп, әле берсе, әле икенчесе Гәүһәр белән исәнләшәләр.

Менә алар таныш капкадан ишек алдына керделәр, бусага төбендә аякларын кактылар, аннары өйгә атладылар. Зәбирә түти мич каршында булаша иде.

Зәбирә түти, безгә чәй эчермәссеңме икән: минем кунагым бар.

— Ә-ә, Акназар икән. Хәзер, хәзер, Гәүһәр.

Бик тиз табын әзерләделәр.

— Син тартынмыйча аша, эч, Акназар. Менә таба бәлешен Зәбирә түти бик тәмле итеп пешергән.

— Кая, чәй дә ясап бирим үзеңә, Акназар.

Акназар сүзсез генә чынаягын сузды, бит алмалары кызарды. Ул бик аз сөйләште, бирелгән сорауларга беркатлы гына җаваплар кайтарды. Аның шәхси ягына кагылмадылар, әнисе турында да, үги әтисе турында да сораштырмадылар.

Ахырда чәй эчелеп бетте. Аннары Гәүһәр үз бүлмәсенә кереп китте. Бу юлы барысы да алдан хәзерләп куелган иде, ахрысы, Гәүһәр рәсемнәр күтәреп чыкты. Ул арада Зәбирә түти өстәлне дә җыйды. Гәүһәр урындыкларга рәсемнәрен тезде. Акназар ашыкмый гына рәсемнән рәсемгә күчеп карады, бер якынрак килде, бер ераграк китте. Гәүһәр аны тын да алмыйча күзәтте. Юк, бу баланың тумыштан рәсем кырарга, рәсем ясарга сәләте бар булса кирәк, әнә ничек карый бит, әнә ничек яктылыктан файдалана, йөзендә ашыгу да, кабалану да юк. Вакыт-вакыт алсу иреннәрендә чак кына елмаю сизелә, вакыт-вакыт ул тәмам уйчанлана. Бу баланы бер хулиганга санау һич тә дөрес түгел, хулиган бала могурлык дөньясы алдында болай тын калмый. Билгеле,

ул әле рәсемнәрнең эчке мәгънәләрен аңламый, гомумән, сәнгать әйберләренең табигате дә аңа караңгы әле, әмма шулай да, күр, ул нинди житди! Башка кеше моны ачык сизмәсә дә, Гәүһәр, аз гына художник кеше, яхшы аңлады. Аның эчке тойгысы бу балада алданмаганлыгын әйтә иде.

Стеналардагы рәсемнәр әүвәлгечә торалар. Тик берничәсен генә Гәүһәр алмаштырып куйган. Акназар аларга бер йөгерек караш ташлаган, хәзер кабат карый. Бигрәк тә Кама буенда ясалган рәсемгә ул озак карап торды. Аннары тәрәзәгә башын борды, урамда кар булуына һич тә ышанасы килмәде. Әллә кайчан яз булгандыр да, Камада дулкыннар тибрәлә торгандыр.

Ниһаять, Акназар «Юлдаш» дип исемләнгән рәсем алдына кабат кайтты. Гүя хәзер аңа калган рәсемнәр берсе дә юк, бары шул «Юлдаш» кына бар. Бу рәсем алдында ул шактый озак торды, бераз арткарак чигенеп тә, кырыйга китә төшеп тә карады, йөзе ничектер уйчанланды, күз карашы да ничектер үзгәрде, әйтерсең, баланы күз алдында алмаштырдылар.

Зәбирә түти дә күптән инде рәсемнәрне карый. Ахырда ул да әлеге «Юлдаш» алдында туктады, озак кына карап торгач:

— Акназар балам, бу син түгелме соң? — диде.

Акназар кычкырып көлеп җибәрде. Аның күзләре үткенрәк, малайның авыз-борын тирәләре, хәтта тырпаеп торган колаклары, чәче дә охшаган төсле, ләкин бу Акназар түгел, бу Юлдаш, бу башка малай. Мәктәпкә илтеп күрсәтсәң, менә кызык булыр иде. Мәктәптә Юлдаш исемле малайлар бармы? Бар бугай, әллә унынчыда, әллә тугызынчыда, тик чәче чем-кара түгел, нииндидер җирән, янып тора.

Рәсемнең балага охшавы Гәүһәрне канатландырып җибәрде.

— Әгәр ошаса, бу рәсемне сиңа бирәм, Акназар,— диде.

— Миңа? — Малай куркып артка чигенде.— Кирәкми. Урладың дип бәйләнерләр. Сез аны үзегез мәктәпкә алып барыгыз.

— Мәктәпкә? Эшләнеп бетмәгән көенчәме? Миннән көлсәләр, Акназар?

— Көлмәсләр. Эшләнеп бетмәгән дип уйламаслар да әле. Былтыр бер Казан художнигының Яшел Ярда күргәзмәсе булган иде, мин барып карадым. Анда да эшләнеп бетмәгән рәсемнәр бар иде. Беркем берни әйтмәде.

— Ярый, алайса, мин риза,— диде Гәүһәр, уйланып.— Ләкин минем рәсемне генә куймыйбыз. Бөтен башлангыч классларныкын җыябыз. Ул чагында тулырак га, кызыклырак та булыр. Мин иртәгә үк Бибинур апа белән сөйләшермен, рәсем дәресе укытучысын да ярдәмгә сорарбыз. Син, Акназар, беренче булышчы. Ярыймы?

— Ярый.

Үз рәсемнәреннән Гәүһәр бер-икене генә куяр. Алар күзгә бәрелеп тормасыннар, укучыларның рәсемнәрен басып китмәсеннәр. Төп игътибар балаларның рәсемнәрендә булырга тиеш. Эш күп булыр. Гәүһәр моны ачык сизде, ләкин Акназарны коткару өчен ул барысына да риза иде. Әлбәттә, шундый уе барлыгын Гәүһәр беркемгә дә әйтмәс, әмма үз алдына төп бурыч итеп шуны куяр.

Акназарны чакырган вакытта Гәүһәр күргәзмә турында уйлап та карамаган иде. Акназар да бары тик шул бер рәсемне генә алып бару турында әйтте, калганы шул әңгәмә вакытында туды, әмма бу нәрсә тора-бара Гәүһәрне дә, Акназарны да биләп алды. Ахырда, Акназар кайтырга җыена башлагач, Гәүһәр әйтә куйды:

— Акназар, интернатка күчерсәләр, риза булыр идеңме? Әниләрең каршы килмәсләрме?

— Мин алардан китсәм, әниләр шатланачак кына...

— Ә син үзең ничек уйлыйсың?

— Мин риза, алсыннар гына.
— Син бүген әнием белән яхшылап сөйләш. Ул мәктәпкә килсен, мине яки Бибинур апаны күрсен. Төшендеңме?
— Утка янсын мәктәбегез, дип әйтә ул.
— Юк, син яхшы гына сөйләш, килер.
Ниһаять, Акназар чыгып китте. Зәбирә түти ияген тотып озак кына утырды да әйтте:
— Әй, заманалар,— диде,— кешенең үзеннән алда уйлыйлар, атаанасы да кайгыртмый, укытучылары барысын да эшлиләр.
Гәүһәр көлеп җибәрде, чәчелеп яткан рәсемнәрен җыя башлады.
Берничә көннән балалар мәктәпкә үзләренең рәсемнәрен китерә башладылар. Рәсемнәр бик күп иде. Акназар аларны аерым шкафка җыя барды. Ул бик мавыгып китте. Аңа каравы күңелле иде. Кара инде, күңеленә ошаган эш баланы да нишләтә! Тик күргәзмә беткәч кенә суына күрмәсен, нәрсәдер уйларга кирәк булыр.

## 13

Җинел кулдан гына башланган күргәзмә мәктәптә зур уңыш казанды, аны балалар гына түгел, укытучылар да кызыксынып карадылар. Балаларның рәсем сәләте әллә кайдан күренеп тора. Әлбәттә, Гәүһәрнең үз рәсемнәрен дә күрми калмадылар. Алар бер читкә генә һәм каранлырак почмакка куелсалар да, алар алдында һәрвакыт кеше булды, күпләр Гәүһәрнең шундый сәләте барлыгын беренче тапкыр беләләр. Мәктәп директоры «Юлдаш» рәсеме турында:
— Мин рәсемнәрне тирән бәяли белә торган кеше түгел, шулай да синең бу рәсемең, Гәүһәр, балаларда нык тәэсир калдыра, мин үзем күзәтеп тордым,— диде һәм, күргәзмә беткәч, бу рәсемне мәктәп коридорына элеп куячагын әйтте. Бу хәл Гәүһәрне шатландырды, ләкин иң мөһиме Акназарның үзгәрүе иде. Ул шаярмый башлады, башкаларга кагылмады, дәресләрен яхшы укыды, ә дәрес беткәч, күргәзмә тирәсендә бөтерелде. Хәлбуки, хәзер язның шундый бер вакыты килгән иде, өйдә, мәктәптә бер минут артык утырасы килми, кайдыр урамга, бакчаларга, су буйларына чыгасы, дөньяны җимерел уйныйсы, шаярасы, я булмаса бөтен җанлы-җансыз әйберләргә акрен генә сеңеп барган кечкенә алсу тынлыкны күзәтәсе килә.
Ниһаять, күргәзмәне җыеп алдылар. «Юлдаш»ны, бик матур рам ясатып, коридорга элделәр. Хәзер инде дәресләр бетәргә дә күп калмаган иде, алда җәйге каникул. Чиксез шатлык белән бергә балаларда ниндидер яшерен гамь дә сизелә, бигрәк тә моны Акназарга караганда ачык күрергә була иде. Гәүһәр хәтта Зиләдән: «Акназарга ни булган?» дип берничә мәртәбә сорады. Зилә белмим дип кенә җавап бирде. Шуннан соң Гәүһәр интернат җитәкчеләренә дә мөрәҗәгать итте. (Акназар анда тора башлаган иде.) Тик анда да бер нәрсә дә әйтмәделәр. Акназар үзен бик тәртипле тота, диделәр. «Күргәзмәнең ябылуы аңа да тәэсир иткәндер, ахрысы. Без аның белән күбрәк мавыктык шул. Балаларның төп бурычы — уку елын яхшылап тәмамлау икәнен онытып җибәргәнмен», дип уйлады Гәүһәр. Кайчагында ул тагын да тирәнрәк уйларга бата иде. Күп вакытта баланы чын кеше итеп тәрбияләү өчен зәмин югалган яки бик аз гына калган була. Укытучы бер нәрсәне сөйли, бер нәрсәне алга сөрә, ә семьяда бала шуның нәкъ киресен ишетә, киресен күрә. Шул ук Акназар. Нәрсәгә өйрәтте аны семья? Гамьсезлеккә, икейөзлелеккә. Шул яшендә бала тормышта идеалсыз калса, кая бара инде ул? Ул бит нәкъ шушы елларда зур тормышның нигезен сала, нәкъ шул елларда оеткы барлыкка килә. Теге яки бу сәбәп белән нигез булмый калса, оеткы начар булса, баланың бик кыен хәл кичерүе мөмкин.

Тын, жылы, аяз кичләрдә су буенда утырганда да Гәүһәр еш кына шул турыда уйланды. Аның үз тормышында да телгә алырлык бер нәрсә дә булмады шикелле, тик кайдадыр күңел тирәнлегендә генә нәрсәләр хәзерләнә иде бугай.

Гәүһәр Галимҗан абыйдан берничә хат алды. Әлбәттә, тормышның ачысын, төчесен күргән олы кешенең хатлары гыйбрәтле. Тик алар күбрәк беркая да чакырмыйлар, бернәрсә дә вәгъдә итмиләр шикелле, бары тик дөрес юлны үзеңә табарга кирәклеккә өндиләр. Гәүһәр исә яшь кеше, ярдәмгә, күрсәтүгә мохтаҗ. Әйе, булсын иде менә шундый нәрсә, аның канын да, җанын да актарсын иде. Гәүһәр күзен дә йоммыйча менә шул юлдан атлар иде.

Менә хәзер дә ул шушы каршылыклы уйлар эчендә су буенда кичке Камага карап утыра. Су гаҗәп киң, олы, тыныч. Бер карасаң, хәтта җылы да кебек. Әмма су керергә иртәрәк әле, бу вакытта бик чыдам кешеләр дә коенмыйлар. Алай гына да түгел, бу вакытта җиңел булса да өскә пальто кирәк әле, бөтен яр буенда күлмәкчән йөргән бер кешене күрмәссең. Ләкин шулай да яз үзенекен итә. Гәүһәрләрдән аерылып киткән Миләүшәнең шат көлүе ишетелә, ул да булмый, шундый ук шат тавыш белән Вилдан җавап бирә. Әйе, аларга рәхәт, күңелләрен бер болыт кисәге дә басмаган, мәктәптә укулар беткәч тә гөрләп туй итәргә җыеналар. Бәхетле булсыннар инде, бер дә кояшлары батмасын. Гәүһәрнең дә кайчандыр шундый чаклары бар иде. Бар иде...

Гәүһәр янында Әгъзәм Ибраһимов утыра. Соңгы вакытларда ул ничектер очраклы сыман булып һаман аның янына килеп чыккалый башлады. Гәүһәр аңа болай килешми бит, дип әйтергә дә уйлаган иде, менә һаман әйтми килә, гүя нәрсәдер көтә. Әгъзәмнең өстендә күгелҗем плащ, башы ялан баш, кара тутлы тар йөзе бик ачык. Бүрек яки эшләпә кигәндә аның йөзе ничектер түгәрәгрәк, олырак сыман күренә. «Аңа ялан баш килешә төшә», дип уйлады Гәүһәр.

Бүген Гәүһәр бернәрсә ачты: әгәр Әгъзәмгә озаграк карап торсаң, ул бик күп кыенлыкларны башыннан кичергән, утка кергән солдатка охшый. Үзе шунда ук көлемсерәп тә алды, ул аның армиядә булуын-булмавын да белми. Сорар иде, уңайсыз, Әгъзәмнең әллә ни уйлавы бар. Бәхеткә каршы, яннарыннан гимнастеркалы бер кеше узып китте.

— Менә шундый кеше күрсәләр, балалар хәзер батырлык турында уйлыйлар,— диде Гәүһәр аның артыннан карап.— Батырлык турында сөйли башласаң, авызыңа керергә торалар. Менә чын геройны аларга күрсәтсәң иде.

— Нигә, безнең шәһәр план бүлегендә чын Советлар Союзы Герое эшли. Чакырсагыз, килер.

— Чынмы? Сез аны беләсезме?

— Мин дә беләм, директорыгыз да. Балалары сездә укый ич.

— Алайса чакырабыз. Сез дә килерсез бит?

— Мин герой түгел ич,— дип елмайды Әгъзәм.— Армиядә дә сугыш беткәч кенә булдым.— Кызыл Йолдыз ордены белән бүләкләнүен телгә дә алмады.

Әйтүләренә караганда, Әгъзәмнең тормыш иптәше геолог булган. Күршедә салынып ята торган Яшьлек шәһәренең урынын эзләшкән, бик күп корылмаларның урынын билгеләгән, аннары бер көнне, Кама ташыганда, өенә кайтмаган. Бер атнадан соң аның үле гәүдәсен Яшьлек шәһәреннән утыз чакрымнар түбәндәрәк тапканнар. Бу бер бәхетсезлек булганмы яки бер җинаятьме — вакытында ничектер ачылмаган. Шау-шуы күп булган, бигрәк тә Әгъзәм күп йөргән, соңыннан әкренәкрен тынган, тормыш яңа мәшәкатьләр, яңа шатлыклар, яңа кайгылар алып килгән. Хәзер бу эшкә өч ел инде. Шулай да иптәшләре Әгъзәм бар вакытта бу вакыйгага кагылмаска тырышалар, чөнки Әгъ-

зәм моны бик каты кичерә. Ихтимал, шул тирән кайгысын белгәнгә, Гәүһәр дә тыйнаклык күрсәтә торгандыр. Кайгыны уртаклашуда хатын-кыздан да сизгер күңел юк бит.

Хәзер караңгылык дөньяны капларга ашыкмый, мул сулы елгага сәгатьләр буе карап тор. Яңа туфрак исе, эчкелтем бәре исләре башны әйләндерерлек. Елгадан дым тарта, ә шәһәр ягыннан төрле тавышлар ишетелә, бер карыйсың, ап-ачык булып йөк машинасы гүли, аннары кемдер кычкыра, кемнәрдер көлә[лә]р, чыр-чу ишетелә, шуннан соң барысы да тына, бетә, аннары барысы да яңа бер көч белән яңгырый башлый. Елгада пароходлар күренгәли, берничә көннән пристаньнар тирәсе үзенә бертөрле тавыш белән гөрли башлар. Хәзер пристань ягыннан күбрәк буяу исләре генә килә.

— Гәүһәр, Билал Шәнгәраев бирелә бит,— диде Әгъзәм көтмәгәндә. Гәүһәр кинәт сискәнеп китте.

— Билал Шәнгәраев?

— Әйе. Яшьлек шәһәренә урын карарга килгән. Ул бөтенләйгә күчәргә уйлый бугай. Ленинградтан туйдым, дигән була.

Ленинград андый шәһәр түгел. Билал үзе аның турында никадәр ялкынланып сөйләде. Юк, монда сәбәп башка. Ләкин ни кирәк ул Билал Шәнгәраевкә? Гәүһәр аның яшерен уйларын белә, ләкин ул аны барыбер кабул итмәячәк бит. Билал шуны аңламыймы икән? Нәрсәгә исәп тота ул? Югыйсә Гәүһәр аңа ике аңларга урын калдырмыйча ачык итеп әйтте бит. Әллә Гәүһәрнең авыр хәленнән файдаланмакчы буламы? Бусы бит шулай ук нигезсез. Әнә Алчынга әйтте бит. Данына, шөһрәтенә бер дә карап тормады. Хәер, Шәнгәраевнең Алчын турында бер нәрсә дә ишетмәгән булуы мөмкин. Яшел Яр хәбәрләре Ленинградка барып җитми инде. Соң, нәрсәгә исәп тота ул? Ни булса да Билал Гәүһәрдән гафу үтенергә тиеш әле, аның аркасында күпме газап чикте. Хәзер инде Гәүһәр Дидаровның тыкшынуларын белә, ләкин утсыз төтен чыкмый бит. Ә ут ягучы шул Билал Шәнгәраев булды. Ут ягучы... Бәлки ул котылгысыз нәрсәне генә тизләткәндер? Юк, шулай да... шулай да Гәүһәр аны гафу итмәячәк, бу мөмкин түгел.

— Әгәр мин аны кайчан да булса бер күрсәм, аңа тагын бик каты итеп әйтәчәкмен. Мин күрәзәче булырга җыенмыйм, шулай да ул булмаса, мин бу хәлгә калмас идем шикелле. Мин аңа бертөрле дә вәгъдә бирмәдем, аны бертөрле дә өметләндермәдем, киресенчә, безнең арада бер нәрсә дә юк, булуы мөмкин дә түгел, дидем. Ә ул...

— Туктагыз әле, Гәүһәр. Бәлки ул бөтенләй гаепле дә түгелдер. Сөйгәч, кеше нишләсен...

Гәүһәр Әгъзәмгә бик сынап карады. Бу карашта нәрсә генә юк иде: кисәтү дә, шикләнү дә, ятсыну да бар иде.

— Мин бер генә яклы мәхәббәтне аңламыйм. Яшәргә туган, яшәүне раслаган мәхәббәт ике яклы, бер-беренә тулы ышаныч хәлендә булырга тиеш. Минемчә, Билал менә шуны аңламый яки уенда башка бер нәрсә бар...

— Бәлки, Гәүһәр ханым. Шулай да мәхәббәт мәсьәләсендә салкын акыллы булырга кирәк, дип әйтәләр бит. Минемчә, Билал ничек кенә уйламасын, аңа бик үк каты бәрелмәскә кирәк.

Гәүһәр көлеп җибәрде.

— Сез яучылыкка язылмагансыздыр бит?

Әгъзәм башын селекте.

— Юк, әлбәттә. Гомумән мондый эшкә минем сәләтем юк. Ләкин сөйгән кешене аңлыйм бугай. Ул сезне бер күреп, сандугач шикелле, дөньясын онытып сайрамый. Ялгышмасам, Билал сезне студент чактан ук белә, шул чактан бирле сезне ярата да. Шулчаклы гомер истә тоту, ярату — уен түгел, Гәүһәр ханым. Бик күпләр мона сәләтле дә була алмый, анысын да әйтик. Һәрхәлдә, төрле яклап уйларга кирәк.

— Бигрәк акыллы киңәшче икәнсез, Әгъзәм иптәш. Тикмәгә сезне начальник итмәгәннәр икән.

— Юкка көләсез, Гәүһәр ханым. Минем монда бер гаебем дә юк. Мин сезгә турысын әйттем, ә нәтиҗә ясау — ул сезнең эшегез.

Гәүһәрнең йөзенә тирән сагыш ятты. Якынлашып килгән караңгылык моны тагын да көчәйтте. Кешенең иңбашларына кинәт бинийая авырлык салсалар, шулай була: җиргә ташларга да йөрәк җитми, күтәреп тотсаң да тез буыннары калтырый. Шушы йөк белән бергә аусаң, бетәсең, югаласың. Гәүһәр куллары белән йөзен каплады, берничә минут шулай тын торды.

— Сез Билал Шәнгәрәевне каян беләсез? — дип кинәт сорады Гәүһәр, кулларын йөзеннән алып. Аның күзләрендә яшь юк, ләкин алар тирән бер кичереш белән карый. Ихтимал, ул Кама буендагы ял йортында үткәргән ваемсыз көннәрен яки Казанда җимерек йорттан чыгып килгәндә Билал белән очрашуларын исенә төшергәндер.

— Билал белән без Казанда бер гостиницада тордык, шунда таныштык. Ул миңа үзенең төпле егет булуы белән ошаган иде. Тормышка бик реаль карый. Ике атна эчендә без аның белән шактый дуслаштык. Ул миңа үзенең мәхәббәт мажаралары турында да сөйләде. Бер нәрсәне дә яшермәде, хәленең чамасыз авыр булуын әйтте. Мин аны ул вакытта ук бик кызгандым. Кыш көне ул миңа тагын бер хат язды. Гәүһәр иреннән аерылган, ләкин минем өметем тагын да ераклашты дигән. Мин аның бу сүзләрен төшенеп җитмәгән идем, инде менә сезнең белән сөйләшкәч, аңладым бугай. Минемчә, аның соңгы өмете аны сезнең янга китерә...

— Рәхмәт, мин дә аңладым.. Әнә Миләүшәләрнең тавышы да ишетелә. Безгә кайтырга вакыт.

— Сез монда икән... Бер нәрсә дә ишетмәдегезме, Гәүһәр апа? — диде Миләүшә, агачлар арасыннан килеп чыгып.

— Юк, Миләүшә. Нәрсә бар?

— Җиһан апаны да күрмәдегезме?

Җиһан апа интернатта өлкән тәрбияче иде. Гәүһәр берьюлы сискәнеп китеп, әмма котылгысыз хәбәрне ишетмәскә теләп:

— Нәрсә бар соң? — диде.

— Акназар... каядыр киткән.

— Акназар?

— Әйе, эзлиләр, эзлиләр, һаман таба алмыйлар. Без дә Вилдан белән эзләштек...

Бу вакытта Гәүһәр торып аякка баскан. Әгъзәм дә аяк өсте иде.

— Әрләмәгәннәрдер бит?

— Әллә тагы... Анысын мин сорамадым да.

Менә сиңа мә! Шулай ук... Юк, бу мөмкин түгел, монда нәрсәдер бар. Бер минуттан алар шәһәргә таба баралар иде инде.

## 14

Акназар югалганнан бирле, Гәүһәр аның турында гына уйлады. Хәзергә ул аны әрләми дә, ачуланмый да, бары тик пошына гына. Милициягә күптән хәбәр ителде, Яшел Ярның бөтен җирен актарып чыктылар, ә Акназар юк та юк. Камада пароходлар күренә башлаган, әллә шуларга утырып киттеме? Милиция, билгеле, анда да хәбәр иткән, ләкин аннан да куанычлы хәбәр юк әле. Гәүһәр еш кына дулкыннарга карый. Алар, ярга кагыла-кагыла, гүя нәрсәдер пышылдыйлар, әйтергә ниндидер серләре бар шикелле. Берничә мәртәбә мәктәпкә Талия килеп китте. Ул инде сүз дә сайлап тормый, такт та белми, хәтта баласы югалганга борчылмый да кебек, бары тик көнелендәге ачуны — мәктәпкә, укытучыларга, тәрбиячеләргә булган ачуын әйтергә җай туганга гына

килгән кебек. Гәүһәргә дә, Бибинур апага да, Җиһан апага да, хәтта каян белеп алгандыр, Әгъзәм Ибраһимовка да әллә нәрсәләр әйтеп ташлады. «Күз нурымны әнисе кочагыннан тартып алдылар да суга салдылар», дип бөтен Яшел Ярга кычкыра, яхшылап әйткәнне, сабыр булырга кирәк, эзлиләр бит әле, дигән сүзләрне колагына да элми, буш сүзләр белән, ичмасам, күнел ярама тоз салмагыз, сезгә ни, кеше кайгысы сезне борчыймыни, ди. Аңа бик каты әйтерләр иде дә, бала табылмагач, ни әйтәсең? Барыбер аныкы дөрес булып чыга бит. Тузга язмаганны сөйләсә дә дөрес булып чыга, синең бер сүзеңә каршы унны кайтара ул. Җитмәсә, чын дөресен белергә комачаулый. Мәктәптә, класста андый-мондый хәл булмаган шикелле. Интернатта балалар сугышканнар, Мөбинә исемле тәрбияче, дөрес булса, хәтта Акназарга суккан, хулиган, дип кычкырган, ди. Мөбинә ант итеп әйтә, Акназарга тырнак та тидергәнем юк, ди, кычкырмадым да, ди. Балалар эндәшмиләр, алар нәрсәдер беләләр, ләкин әйтмиләр. Җиһан апаның сүзләренә караганда, алар хәтта төннәрен дә үзара нәрсәдер бәхәсләшәләр, тәрбияче яки укытучы керсә, су капкан шикелле тын калалар. Үз классындагы балалар булса, Гәүһәр алар күңеленә ничек тә ачкыч табар иде, башка классныкыларны белми.

Шулай да тора-бара кайбер нәрсәләр ачыкланды. Дөрес булса, вакыйганың башы әлеге дә баягы шул күргәзмәгә барып тәртелә икән. Күргәзмәне япканда анда катнашучы бик күп балаларга, шул исәптән Акназарга да, яхшы рәсемнәре өчен, мактау бүләге бирделәр.

Бишенче класста укучы Фаил дигән малайның рәсемнәрен күргәзмәгә бөтенләй куймаганнар. Фаил класста әйбәт укучы саналганга, кайбер укытучылар да аңа яхшы мөнәсәбәттә булганлыктан, ул рәсемнәренең күбесе үтәр дип уйлаган. Әмма күргәзмә ачылганда Фаилнең бары тик бер генә рәсеме калган була. Анысы да күзгә бәрелерлек түгел. Йомгаклау вакытында жюри ул рәсем турында ләм-мим әйтмәде. Соңыннан балалар арасында бу турыда бәхәс чыккан, Фаил, минем рәсемнәремне юри куймадылар, югыйсә мин иң зур бүләкне аладыр идем, дигән. Акназар нидер каршы әйткән. Шуннан бәхәс киткән, балалар ике төркемгә бүленгән, ди.

— Беләбез,— дигән Фаил, Акназар яклы малайлар алдына басып.— Әллә белмиләр дисезме? Үзенең рәсемнәрен барысын да укытучыныкы янына куйдырган. Менә карагыз, ул нинди художник, имеш. Җитмәсә, үз рәсемен газетага да җибәргән. Белмиләр дисезме, беләбез!

Балаларның әйтүләренә караганда, Акназарның газетага рәсемнәр җибәргәне юк, анда җибәрергә ярый икәнен дә белмәгән. Кем җибәргәндер — анысы балаларга билгеле түгел.

— Ялганчы! Мин редакциянең адресын да белмим,— дип кычкырган Акназар.

— Аны беләсе дә юк, газетаның актыккы битендә басыла. Син үзең ялганчы, ялганлап интернатка да урнаштың. Югыйсә сине монда якын да җибәрмиләр иде. Синең әниең урамда кычкыра гына белә ич.

Шуннан инде балалар арасында түбәләшү башланган. Кем беренче булып кул күтәргәндер, билгесез. Һәрхәлдә, алар яхшы ук сугышканнар булса кирәк, Мөбинә йөгереп килгәндә, бүлмәнең асты өскә килгән була. Гәүһәр хәлнең менә шул өлешен җентекләп сораштырырга теләсә дә, никадәр тырышса да, берни ачыклый алмады, балалар да, Мөбинә дә белмибез, күрмәдек, дип кенә җавап бирделәр. Югарыда сөйләнгән кадәресен дә Гәүһәргә ачык кына әйтмәделәр, ул төрлесен төрле җирдән, өзек-өзек кенә белде. Соңыннан тагын бер нәрсә билгеле булды: балалар сугышканны күргән бердәнбер олы кеше Мөбинә — Талиянең якын кардәше икән. Моны белгәч, Гәүһәр уйга калды. Талиянең кардәше булгач, ул Акназарга яхшы мөнәсәбәттә булырга тиеш ләбаса! Димәк, аның Акназарга кул суузы, аңа әшәке сүзләр белән кычкыруы

турындагы хәбәр ялган булып чыга. Ул чагында инде хәл бөтенләй аңлашылмый. Шул ук вакытта Җиһан апа Мөбинәнең кырысрак табигатьле булуын, балалар аны яратып бетермәүләрен әйтте.

Берничә тапкыр мәктәпкә Әгъзәм Ибраһимов килеп китте. Ул куанычлы хәбәр китермәде, киресенчә, үзе килгән саен ул-бу юкмы дип сорашты.

— Юк шул,— диде Гәүһәр, гирән кайгы белән.

Әгъзәмнең аңарга керүе бик аңлаешлы иде. Ә менә шундый чакта Билал Шәнгәрәевнең килеп чыгуы Гәүһәрне бөтенләй ачуландырды. Әйтүләренә караганда, ул милициягә йөри, имеш. Аңа ни калган? Кайдадыр бер бала югалган икән, аның Билалга ни катнашы бар? Газетада исемен атасыннар өчен тырышамы? Ленинградтан килгән бер инженер да үз теләге белән эзләшүгә катнашты, дип язсалар бик шат булыр. Кайчагында кешеләр бәхетсезлектән дә үзләренә файда чыгаралар бит.

Икенче көнне бер тәнәфестә Бибинур апа Гәүһәрне читкә чакырып:

— Күптән түгел генә милиционер Акназарны китерде... Тәмам пычранып беткән,— диде.

Гәүһәрнең күзләре ялтырап китте, ул шатлыгыннан чак кына кычкырып җибәрмәде, бик зур көч белән үзен тыеп калды.

— Кая ул? — диде.

— Интернатта, Җиһан карый. Дәрестән соң минем янга кер, киңәшергә кирәк.

Гәүһәрнең әле Акназарны күргәне юк, әле бернәрсә дә белми, ләкин ниндидер коточкыч бәла үтеп китте шикелле. Ул исән. Югыйсә Гәүһәр эченнән әллә нәрсәләр уйлап беткән иде бит. Ни әйтсәң дә, Акназар — бала, ә баланың алда ни эшләве берәүгә дә мәгълүм түгел, дөресрәге, ул үзе дә белми. Кыерсытылган, кимсетелгән балаларның үз-үзләренә кул салулары да мөмкин. Әлбәттә, Гәүһәр качкынны кочагын җәеп каршы алырга уйламый. Үзенең борчылулары турында да ул беркемгә дә әйтмәс, болар аның үз эчендә калыр. Аннары бик күп ачыклыйсы нәрсәләр дә бар әле.

Дәрестән соң, Бибинур апа белән киңәшкәч, Гәүһәр туп-туры интернатка китте. Әле коридорда ук аңа Җиһан апа очрап, Гәүһәрне үз кабинетына чакырды.

— Табылды бит,— диде ул ачуын да, шатлыгын да яшерә алмыйча.— И борчылуымны белсә иден... Әллә кайдан пароходтан тотып алып кайтканнар. Тәмам пычракка баткан, ябыккан, ике күзе генә ялтырый. Әниләргә кайтарсагыз, тагын качып китәм, ди. Минемчә, Мөбинәнең гаебе бар шикелле, Акназар аның белән сөйләшергә дә теләми. Мөбинә шулай ук кара көеп йөри. Мин аны чакырткан идем, эштән чыгарыгыз, ди. Кич белән балаларны җыярга булдык. Сөйләсеннәр!

— Мин Акназарны күрим, Җиһан апа,— диде Гәүһәр.

— Әйдә, рәхим ит. Хәзер әле укучылар мәктәптән кайтып житмәгән. Акназар өстә, бүлмәсендә утыра.

Гәүһәр белән Җиһан апаны күргәч, Акназар аякка басты, башын түбән иде. Җиһан апа озакламыйча чыгып китте, Гәүһәр урындыкка утырды. Берничә секунд, акылын җыеп, эндәшми торды. Акназарны инде мунча керткәннәр, киемнәрен алмаштырганнар. Әйе, аңа җиңел булмаган, тәмам ябыккан, аннары суык та тидергән, ахрысы, әледән-әле йөткергәләп ала. «Врач белән сөйләшергә кирәк булыр», дип уйлады Гәүһәр.

— Нинди начар эш эшләп ташлавыңны беләсеңме, Акназар? Иптәшләрең барысын да гафу итәрләр дип уйлыйсыңмы?

Малай эндәшмәде. Башы тагын да түбәнрәк иелде.

— Берәү белән дә сөйләшмичә, берәүгә дә әйтмичә, шулай эшлиләрмени? Болай эшләгән нинди баланы күргәнең бар? Ә син качкын. Монда синең класстагы барлык иптәшләрең борчылып беттеләр. Көн

саен эзләп йөрделәр. Хәзер инде сине нишләтергә? Әниенә кайтарып җибәрсәк кенә. Җиһан апа интернатта тотмас бит. Иртәгә тагын качып китәрсең дип уйлар. Качмассыңмы?

— Әниләргә кайтармасагыз... качмам,— диде Акназар әкрен генә.

— Ни өчен әниләреңә кайтырга теләмисең?

Акназар эндәшмәде, аннары каядыр читкә карап тора башлады.

— Мөбинә апаңны да күрергә теләмисеңме? — дип сорады Гәүһәр, гүя сүз арасында гына. Акназар сискәнеп китте, авыр сулый башлады. Хәзер бертөрле дә шик юк, Мөбинә малайны бик нык рәнҗеткән булса кирәк. Ләкин Акназар аның турында барыбер бер нәрсә дә сөйләмәячәк, шуна күрә аны хәзергә бу мәсьәлә белән азапламау яхшы. Бәлки, соңыннан ничек булса да буа ерылыр. Гәүһәр урыныннан торды.

— Иртәгә, Акназар, кичекмичә дәрескә кил. Ямә?

— Килермен.

— Мин Бибинур апа белән дә, Җиһан апа белән дә сөйләшермен, интернатта калдырыгыз, дип сорармын. Ләкин моның өчен, Акназар, синең дә тәртипле булырга чын күңелдән сүз бирүең кирәк. Бәлки алар сиңа ышанырлар. Төшенәсеңме?

— Төшенәм.

Ашханә коридорында Гәүһәр Җиһан апаны күрде, аның белән шыпырт кына сөйләште дә ишек алдына чыкты. Шунда Зилә белән очрашты.

— Зилә, син кая? — дип сорады.

Кызчык ни әйтергә дә белмәде, кызарды.

— Акназар янына киләдер идеңме? — Бала җавап бирмәгәч, Гәүһәр елмайды.— Мин күреп торам лабаса. Ярый, бар, ул өстә, үз бүлмәсендә утыра.

Зилә йөгереп кереп китте, Гәүһәр уйга чумып әкрен генә урамга атлады. Әле бу Акназар белән күп эш булыр булуын, шулай да артык качмас шикелле. Моны аның бөтен торышы, бөтен күз карашы сөйли. Гәүһәргә дә ничектер җиңелрәк булып китте, күз аллары яктырды.

Тыкрык башында Билал Шәнгәрәев көтеп тора иде.

— Мин ишеттем,— диде ул, Гәүһәр белән исәнләшкәннән соң,— мин бик шатмын. Сез шулхәтле борчылган идегез.

— Укытучы борчылмый булмас. Миңа сез ни өчен көясез?

— Мин ни... Мин болай гына. Миңа сезнең өчен мин чыннан да бик шат.

— Рәхмәт. Мин, Билал, турысын әйткәндә, һаман аңламый йөрим: ни кирәк сезгә? Өченче көнге тупаслыгым өчен гафу итегез, әлбәттә. Үзегез күрәсез, минем хәлләрем нинди иде. Бүген кеше белән сөйләшә алам шикелле.

— Минем, Гәүһәр, сезгә житди сүзем бар. Мөмкин булса, әйдә су буена төшик яки бераз урам буйлап барыйк.

— Бик азга гына, Билал. Озакламыйча минем мәктәпкә барасым бар.

— Өченче көн әйтә башлаган идем дә, сез тыңламадыгыз. Шундый хәл килеп чыгуына мин сездән бик нык гафу үтенергә тиешмен, Гәүһәр. Мин сезгә һичбер начарлык теләмәдем. Җәгъфәр белән дә бер тапкыр да сөйләшмәдем, сез миңа рөхсәт итмәдегез.

— Исрафил Дидаров белән сөйләштегезме?

— Әйе, мин электән аны бераз белә идем. Тик ниятен сизмәгәнмен. Моны мин Җәгъфәрнең Фаяга өйләнүен ишеткәч кенә аңладым. Элек Дидаров балдызын миңа бик тәкъдим итә иде.

— Сезгә?! Миңа монысы минем өчен яңалык.

— Мин Исрафилның тәкъдимен нәфрәтләнеп кире кактым, яратмагач, Фая миңа нигә кирәк?..

— Ярый, Билал, бу кадәресенә рәхмәт.

Алар берсүзсез кире борылдылар. Билал эчке сабырсызлык белән сөйләде. Гәүһәрне чиксез яратуын, аның артыннан дөнья читенә барырга риза булуын әйтте.

— Мин сезнең сүзгә ышанам... Сезнең чын күңелдән сөйләвегезгә шикләнмим. Ләкин, Билал, без икебез ике сыңар. Аларны бергә кушсаң да, барыбер бәхет килеп чыкмаячак. Башта мин сезгә бик нык ачуланган идем, аннары шундый фикергә килдем: сез болай да өзелергә торган мөнәсәбәтләрнең уртасына килеп эләккәнсез... Туктагыз, бүлдермәгез, әйтәсе сүземне әйтим. Хәзер мин сезгә үпкәләмим, сезне гаепләмим. Ачык итеп тагын бер мәртәбә, соңгы тапкыр, әйтергә тиешмен: мин сезнең турыда яхшы истәлек саклармын, сез минем яннан китегез. Әйе, әйе! Бу сүзләр, ихтимал, әллә ничек ягрырый торгандыр, шулай да мин аларны әйтергә тиешмен. Менә шул, Билал. Зинһар, киресен сөйләмәгез. Чөнки файдасыз. Сезгә дә кайдадыр бәхет табарга кирәк. Мин сезгә чын күңелемнән бәхет телим.

— Әйтмәгез, әйтмәгез моны! Мин ишетергә дә теләмим!

— Шулай да дөреслекнең күзенә бер карарга кирәк, Билал.

— Гәүһәр, сез ничек... Юк, бу мөмкин түгел!

— Мин, Билал, кайгы шәрабен тустаганның зурысыннан эчтем, артык теләмим. Бу очракта карарым нык. Тагын әйтәм: сез мине калдырыгыз. Яшьлегемдә үз характерыгызны шулай тирән ачсагыз, мин каршы тора алмас идем, хәзер... бүләккә минем бер кыйммәтле нәрсәм дә юк, күләгә белән алдарга, юатырга теләмим. Бу, иң элек, минем үзем өчен газап булса, сезгә дә бер җиңеллек тә китермәс.

— Гәүһәр, сез мине үтерәсез!

— Юк, мин дөресен сөйлим, Билал.— Гәүһәр сәгатенә карап алды.— Миңа вакыт инде.

Гәүһәр тиз генә сумкасын ачты, кулъяулыгын алды. Аннары китеп барды. Билал тораташка әйләнеп, баскан урынында кузгала алмыйча калды.

## 15

Уку елы бетсен дә бер класста икенче елга утырып калучылар мәсьәләсе килеп чыкмасын, имеш! Хәер, бу хәзер генә түгел, уку елы тәүлегендә дә иң кискен, укытучының төн йокыларын качыра торган бер күренеш булып торды. Әйтүе генә ансат бит, әмма лозунглар язылган, без тулы өлгереш өчен көрәшәбез, диелгән. Аерым очракларда, аерым классларда бу бик мөмкин, ә тулаем алганда? Шәһәр яки район күләмендә? Монда инде бәхәс китә. Берәүләр отчет, докладлар өчен бик кирәк булган, аларны үзенә күрә бизәп, матурлап торган бу саннарны яклый, шәһәр мәгариф бүлеге кешеләре аларны күккә чөя, укыту-тәрбия эшенең бердәнбер күрсәткече итеп саный, башкалар ачыктан-ачык каршы килмәсәләр дә, мәсьәләнең укытучылар өчен чиксез катлаулы, четерекле булуын әйтеп, саграк булырга чакыралар. Ахыр килеп, бу мәсьәләне отчетлар, докладлар, киңәшмәләр хәл итми бит. Бөтенесе укытучының намусында. Шәһәр мәгариф бүлеге бер яктан, мәктәп дирекциясе икенче яктан бик бәйләнә башласалар, укытучы, намусына каршы килеп булса да, укучыга өчле билгесе куя. Барысы да аның дөрес эшләмәвен беләләр, ләкин отчетлар матур чыга: мәктәпләрдә тулы өлгереш! Ихтимал, намуслы укытучы мондый хәлдән соң төн йокламый торгандыр, ләкин моны кем күрә? Начар укытучыга икенче яктан шәп: бөтен күрсәткечләр бар—тулы өлгереш. Аңа үз эшенә җитәрлек әһәмият бирмисең дип әйтеп кара, илла җилләнер, син гайбәтчеләр сүзе белән эш итмә, эшнең нәтиҗәсенә бак! Макаренкога да сылтамагыз... Макаренко кайчан укыткан да, без кайчан укытабыз. Берәү дә бәхәсләшми, Макаренко заманында Балмесовлар булган, алар иске

заман калдыгы, ә хәзер без коммунизмга аяк баскан кешеләр, совет властеның уңышлары...

Элек, әле Казанда торган чагында, Гәүһәр бу турыда күп бәхәсләшә, хәтта җыелышларда сөйли торган иде. Бер укучысына да билгесен арттырып куймады. Бу мәсьәләдә укытучы бердәнбер хуҗа, ул укучысы өчен тулысынча җавап бирә. Мәктәп администрациясе дә, ата-аналар да аңа берни әйтә алмыйлар. Бер хатын бар иде, яшелле-күкле тавышлар белән кычкырырга ярата иде, әтисе янәсе профессор, ә улы икеле ала, имеш. Баласын хәзер үк икенче класска күчерүне таләп итте. Ә Гәүһәр риза булмады, бала мондә икеле алган икән, мондә төзәтергә дә тиеш, диде. Хәер, мондый хәлләр бераү генә булмады, байтак булды алар, ата-аналар белән шактый сугышты ул. Кайберләре аңа соңыннан рәхмәт әйтте, кайберләре беренче баскыч беткәнче аңа үпкәләп йөрде. Ләкин ни хәл итәсең, теләсә нинди очракта да укытучы намусы өстен.

Яшел Ярга килгәч, Гәүһәр җыелышларда, киңәшмәләрдә булсын бу турыда сөйләмәде. Аныңча, монда да мәсьәләнең куелышында бертөрле дә аерма юк.

Гәүһәр Яшел Ярда өченче классны алды. Балалар элекке укытучыны һаман исләрендә тоталар булса кирәк, гүя ул әллә кая ерак китмәгән, ишек ачылыр да кайтып та керер кебек. Ләмига кырыс булган, Гәүһәр кебек йомшаклык күрсәтмәгән. Әйтүләренә караганда, ул әле беренче классны алганчы ук тик ятмаган. Нәтиҗәдә өлгереш ягыннан аның классы һәрвакыт алда булган. Ләмига киткәч, Бибинур аның классын тулысы белән Гәүһәргә биргән. Баштарак Гәүһәр кайбер балаларның кисәктән генә уйга калуларын, каядыр читкә карап нәрсәдер көткән сыман утыруларын күрде. Укытучы үз классын сулышыннан белергә тиеш, диләр. Казанда чакта Гәүһәр шулай белә иде дә кебек. Монда исә өзеп кенә әйтә алмый. Акназарның бер дә уйламаганда качып китеп югалып торуы аны бик тирән уйландырды. Бу беренчесе һәм соңгысымы, әллә дәһшәтлеләрәген көтәргәме? Уку бетәргә күп калмаган булса да, Гәүһәр классын һаман күзәтте. Бер карыйсың, класс класс кебек, шикләнергә, пошынырга һичбер урын юк шикелле, бар да ачык, икенче карыйсың, класста нәрсәдер бар кебек. Менә шундый минутта айнык акыл ясаган нәтиҗәләр ышанычлы булып күренми. Әнә бер укучы башын иеп, күзләрен яшереп утыра. Димәк, сабагын белми. Гәүһәрнең элек тә аны шул хәлдә күргәне бар иде. Нигә күрмәмешкә салынды икән? Беренче чиратта сабагын сорамады, ә дәрестән соң калырга кушты. Ул аңа күңеленнән икелене куйган иде, ә сөйләшә башлагач, бу фикеренең дөрес түгеллеген аңлады. Нәрсә бу, һәрбер укучыга индивидуаль якын килүме, әллә укытучылык сәләтенең яраксызлыгымы?

Бер көнне мәктәптәге киңәшмәдән соң, Бибинур белән Гәүһәр урамга бергә чыктылар. Караңгы төшеп килә иде. Әллә кайдан гына чыр-чу ишетелә, балалар йөгерешә. Укытучы инде бу тавышларга колак салмыйча булдыра алмый. Бу аның ихтыярыннан тыш эшләнә торган профессиональ үзенчәлегедер. Куркыныч булмаса, ул башын да күтәрми. Балалар уйный икән, әйдә уйный бирсеннәр.

— Бибинур апа,— диде Гәүһәр, кичке саф һаваны рәхәтләнеп бер сулагач,— һаман сорыйсым килә дә ничектер кыймыйм да. Ләмига апа нинди кеше булган?

-- Ләмига? Нинди Ләмига?

— Минем классның элекке җитәкчесе.

— Аһ, Ләмига! Бик үзенчәлекле укытучы иде. Күп сөйләми, үз фикерен әйтергә ашыкмый, әйтсә, шул фикернең киресен аңа һич төшендерә алмыйсың.

— Ул сездә озак укыттымы?

— Ун елга якын.

— Сез аны хөрмәт итә идегезме?

— Мин мәктәп директоры лабаса, Гәүһәр. Ничек инде үз укытучымны хөрмәт итмим.

— Кеше буларак, күңелегездән?

— Кеше буларак та, күңелемнән дә хөрмәт итә идем, Гәүһәр. Сез нигә әле кинәттән генә Ләмига турында сүз башладыгыз?

— Кинәттән генә түгел, Бибинур апа. Мин аның турында күп уйлыйм. Бу чыгарылыш көннәрендә бигрәк тә.

— Алай булса, бер хәл. Нинди фикергә киләсез?

— Фикерем шул, Бибинур апа. Сез бүген минем классымны мактап телгә алдыгыз. Мин Ләмига апа турында уйладым. Ул үзе булмаса да, күзгә күренмичә һаман минем классымда утыра кебек. Балалар күп очракта, миңа түгел, аңа карыйлар кебек. Бу бер елдан соң шулай. Мин, билгеле, аңа үпкәләмим, рәнҗемим, тик аның авторитеты никадәр зур булуын гына уйлыйм.

— Сезнең үзегезне дә балалар яраталар бит.

— Ихтимал. Ләкин мин, Ләмига апаның киресе булмасам да, башка кеше, Бибинур апа. Ул монда булса, мин Ләмига апа белән бик киңәшер идем.

— Кызганычка каршы, ул юк шул. Хәтерем ялгыштырмаса, ул Башкортстанга ук күчеп китте шикелле.

— Кызганыч. Ләкин дөньяда шундый кешенең булуы мине шатландыра.

— Нәтиҗә ясарга ашыкмагыз, Гәүһәр. Сез бит аны якыннан күрмәдегез. Кайберәүләр аны яратып та бетермиләр иде.

— Мин Ләмига апаны йөз процент яхшы димим, кимчелекләре бардыр. Ул яхшы укытучы булган, моны мин бер ел күреп, сизеп килдем. Бер ел эчендә ул мине укытучы буларак бик нык үстерде. Моны минем бүтәннәргә әйткәнем дә юк, әйтмәм дә. Моны аңларга кирәк. Сезнең белән уйларымны бүлешәм икән, димәк, сезгә ышанам, сезне якын саныйм.

— Рәхмәт, Гәүһәр.

— Вакыт-вакыт укытучының үзендә генә яшереп калдырып булмый торган уйлары туа бит, Бибинур апа. Ул аларны кемгәдер сөйләргә, үзен сынарга тиеш. Бигрәк тә минем хәлдә. Яңа урын, дуслар юк, шәхси тормышым чыгырыннан чыккан... Мин бөтенләй укыта да алмам дип уйлаган идем. Ләмига апаның классына туры килүем өчен үземне бәхетле саныйм.

Алар тыкрык башында туктаганнар иде. Гәүһәрләргә моннан ике-өч кенә йорт, Бибинурларга бераз барасы бар әле. Инде бөтенләй караңгы төшкән. Барлык тәрәзәләр электр утлары белән балкый. Саф һава белән бергә кичке тәмле аш исләре йөзеп йөри. Кайбер өйләрнең ачык тәрәзәләреннән урамга җыр ишетелә, әллә радио уйный, әллә магнитофон куйганнар. Кайчак бик ачык булып Илһам Шакировның тавышы яңгырый. Кызык бу артистлар, үзләре күренми, үзләре әллә кайда торалар, ә тавышлары һәр өйдә диярлек. Аларны белмәгән кеше юк...

Ә Алчын? Аны да җырчы буларак беләләр, ә кеше буларак? Гәүһәр ирененең бер почмагы белән генә көлемсерәп куйды. Әгәр теге вакытта килеп, мәхәббәтен сайрамаган булса, Гәүһәр дә аны яхшы кешегә санап йөрер иде. Хәер, аңа тирәнтен уйланырга вакыт та булмаган. Һәрхәлдә, Гәүһәр янына тирәнтен уйлану нәтиҗәсендә килмәгән, кем беләндер әрләшкән дә алаймы-алай дигән булса кирәк... Хәзер кайда икән? Бер дә тавышы-тыны ишетелми, радиода гына әллә нигә бер җырлый. Дөресрәге, радионы көн саен тыңларга Гәүһәрнең вакыты да юк. Менә Билал төплерәк кеше иде. Гәүһәр аны актыккы мәртәбә борып кайтарды, инде аның кабат Яшел Ярга килмәвенә дә ышана, кайда булса очраклы очрашсалар гына.

Кама буенда пароход тавышлары яңгырый. Чыгып, суга карап уты-

расы иде. Су буе уйлата бит. Ләкин вакыт соң инде, аннары ялгызярым чыгып утырып та булмый.

— Ярый, Гәүһәр, мин кайтыйм, Гөлназ да күптән көтә торгандыр,— диде Бибинур апа.

— Булмаса мин сезне базар читенә кадәр генә озата барыйм. Тышта бигрәк рәхәт.

Алар әкрен генә сөйләшеп култыклашып атладылар. Сүз инде башка темаларга күчкән, Бибинурга да, Гәүһәргә дә турыдан-туры кагылмый иде. Яз килгән бит, аннары җәй, ял вакытлары. Хатын-кызның хәле нинди генә булмасын, ул тегүчеләрен оныта алмый, аннары Яшел Ярда алар әллә ни күп тә түгел. Бер-береңә адрес бирешмәсәң, нишләргә кирәк.

Гәүһәр кайтканда, Зәбирә түти капка төбендә утыра иде.

— Уф, арыдым,— диде Гәүһәр, Зәбирә түти янына утырып.— Башта киңәшмә булды, аннары Бибинур апаны әзрәк озата бардым... Киче нинди матур, Зәбирә түти. Әллә нигә өйгә кермәс идем.

— Тамагың ачкандыр инде. Чәем ничә кайнап сүнде.

— Мәшәкать ясыйм да инде сиңа, Зәбирә түти.

— Мәшәкате берни түгел, Гәүһәрем, минем ашыгасы җирем юк. Баярак Әгъзәм кагылган иде, сөйләшеп утырдык,— диде Зәбирә түти бик гади нәрсә турында әйткән кебек. Аннары Гәүһәрнең бу турыда сөйләтәсе килеп тә, сүзне дәвам иттермәвен сизеп өстәде: — Сүзнең тәмен белә, шул ягы белән безнең ише карчыкларга да ошый. Без бит такылдарга күнеккән кешеләр. Әзрәк такылдамасаң, безгә нәрсә кала аннары. Безнең бит киңәшмәләребез юк.

— Киңәшмәләрегез булса, үзегез качып китәр идегез әле,— диде Гәүһәр, көлеп.— Анда бик четердәвек кешеләр дә түзми, сызу ягын карыйлар.

— Мәгънәсез сүз сөйләсәләр, билгеле, шулай инде. Мәгънәсез сүз йокыны китерә... Ярый, Гәүһәрем, әйдә, тамагыңны туйдырыйм.

— Хәзер, Зәбирә түти. Син әйтмәсәң, аш искә дә килми иде. Күрәсең, сүздән тук булганбыз.

— Синең кебек берничә кеше сүздән тук булып ашны бөтенләй ашамый башлаганнар ди,— Зәбирә түти күңелле генә көлеп алды.— Хәзер утырган урыннарыннан тора алмыйлар ди.

Кайдадыр якында гына гармун сыздырып җибәрделәр. Әле генә агачлар артыннан күтәрелгән ай да, болытсыз йолдызлы күк тә, тынып барган Яшел Яр урамы да, капка төбендәге кешеләр дә, яшел яфраклы бакчалар да юк иде кебек. Инде барысы җанланып, үз телләрендә сөйли башладылар. Сихерле һәм моңлы гармун тавышы. Ник шундый ул? Күрәсең, гармун шул авыл яки әлегә шәһәр булып җитмәгән авыллар урамында туган, аларның моңын көйли. И-и-и, кара инде, Зәбирә түти булып Зәбирә түти дә күз төпләрен сөртә!

Гармун тавышы ераклашты, аннары бөтенләй тынды. Зәбирә түти урыныннан торды.

— Әйдә инде, Гәүһәрем, керик.

Нәкъ шул чакта өй алдындагы карт тирәк башында сандугач сайрап җибәрде. И сайрый да инде, өздереп кенә ала. Зәбирә түти дә, Гәүһәр дә баскан урыннарында тынып калдылар. Гүя гармун моңы дәвам итә, тик тагы да нечкә, тагы да ләззәтле булып яңгырый.

## 16

Мәктәптәге соңгы атна бик киеренке үтте. Монда укулар тәмамланырга тора, уку елы йомгакларын ясарга кирәк. Акназар вакыйгасыннан соң Гәүһәр беркадәр тынычланган булса да, күңеле әле утырып җитмәгән иде. Интернаттагы җыелыштан Гәүһәр бик курыкты, кызулык

белән балалар да, тәрбиячеләр дә төп мәсьәләдән читкә китәрләр, Акназар язмышы икенче мәсьәлә булып калыр дип уйлады. Бәхеткә каршы, җыелыш тыныч үтте, кирәкмәгән шау-шу булмады.

Мөбинә җыелышка килмәде. Акназарның качуында аның роле зур булган булса кирәк, тик моның сәбәпләре ачылып бетмәде, шуңа күрә бу хәл Гәүһәрне шактый борчыды. Акназарның әнисе, берничә чакыртсалар да, шулай ук мәктәпкә килмәде. Бала язмышы бер мәктәпкә генә тапшырылмаган бит. Ана кеше монда берничек тә читтә кала алмый. Ләкин Талия башкача уйлый иде бугай. Бик сәер иде бу. Акназар югалгач, көн саен диярлек мәктәпкә килеп йөргән, тавыш кубарган, истерикага бирелгән ана, баласы табылгач, мәктәпкә бөтенләй килми башлады, баласы турында һич тә кайгыртмады. Гәүһәр интернат кешеләре белән сөйләшкәндә дә, Бибинур апа һәм башка укытучылар белән киңәшкәндә дә, ниһаять, Зәбирә түтигә зарланганда да моны һичничек аңлый алмавын әйтте. Ана бит, ана! Ул Талиянең кызулык белән әйткән сүзләрен онытырга әзер иде. Тирән кайгы эчендә ана ни әйтмәс. Алай гына да түгел, элек баласына беркадәр гамьсез булган Талия, авыр кайгы янагач, бөтенләй үзгәргәндер, баласы өчен канга батып сугышырга әзердер, дип уйлады Гәүһәр. Һәм менә шул Талия... хәзер мәктәп ишеген дә ачып карамый. Бу нәрсә?

— Мин моны аңлый алмыйм,— диде Гәүһәр, ачынып,— бу минем башыма сыймый, Зәбирә түти. Ничек кенә булмасын, Талия Акназарның әнисе бит. Бөтенләй югалдыга исәпләнгән баланың табылуы, исән-сау булуы — моннан да зур шатлык бармы?

— Син, Гәүһәрем, Талияне белеп бетермисең әле. Ул бер күзеннән канлы яшь агызыр, бер күзе белән көләр. Син боларны йөрәгеңә якын алма, Гәүһәрем.

— Кеше язмышы хәл ителгәндә ничек алмыйсың, Зәбирә түти. Акназар бит тал-чыбык шикелле әле, ул алай да бөгелә, болай да. Без аның яхшы кеше булып тәрбияләнүен телибез.

Аптырагач, Гәүһәр үзе дә Талияләргә барып кайтты, Талияне тагы өендә очрата алмады. Үзенчә бик тәэсирле, шул ук вакытта куркыту да сиздертеп торган язу калдырды. Икеме, өчме көннән соң Талия мәктәпкә килде. Аны танырлык та түгел иде, әйтерсең, абзар чистартып йөргән җиреннән кергән. Иске телогрейкадан, иске шәлдән.

— Чакырттыгызмы? — диде ул укытучыларга.

— Утырыгыз, Талия. Чакырткан идем шул,— диде Гәүһәр.

— Минем күп утырырга вакытым юк. Әйтәсен әйтегез дә китим.

— Ашыкмагыз әле. Эш бик мөһим, иплэп сөйләшик.

— Сөйләшеп, вакыт әрәм итәсе юк. Минем Акназарны карарлыгым юк! Болай да башым катып беткән, кая карарга да белмим.

— Болай кырт өзмәгез. Сез ана кеше. Балага ана кирәк.

— Төкерә ул миңа.

— Минемчә, сез балагызга гадел түгел. Сез аның белән кайткач сөйләштегезме?

— Чәчен йолыктым, сөйләшүем шул булды. Икенче качса, буып ташлыйм.

— Юк, Талия, аны кыйнап җиңеп булмый. Иплэп сөйләшергә кирәк...

— Сөйләшегез, сөйләшкән өчен сезгә акча түлиләр.

— Сөйләшкән өчен безгә берәү дә акча түләми. Бала безгә кадерле булса, сезнең йөрәк җимешегез,— диде Гәүһәр, тыныч кына. Талия аның бу кадәрле тынычлыгына исе китеп, аклы-күкле булды. Сүз таба алмый торды.

— Мөбинә сезгә кем була? — дип сорады ахырда Гәүһәр.

— Бәрәч, кем булсын... Нигә миннән сорыйсыз, ирдәүкә Җиһаннан сорагыз.

Жиһан апа кебек олы хатынны «ирдәүкә» дип нәчен кыска итеп кистергәнгә, тавышы ирләрнеке кебек калын булганга әйтә торгандыр инде Талия. Гәүһәр бу кадәресе белән бәхәсләшмичә:

— Аны сезнең кардәшегез диләр,— диде.

— Хәзер ата-ананы да кардәш дип белмиләр. Мөбинә кебек чыбык очлары күп булыр.

Димәк, Талия Мөбинә турында сөйләргә теләми!

— Акназарны нишләтәбез соң? Хәзер җәй бит.

— Мин сезнең тел төбегезне әллә кайдан сизеп торам. Сез Акназарны тәгәрәтергә тырышасыз. Тәгәрәтми торыгыз! Мин сездән зуррак начальникларга да барып җитәрмен,— һәм Талия пыр тузып чыгып китте.

Гәүһәр бермәл сүзсез торды. Башын иде. Шул чакта карт укытучы Гөлсем апа кереп, ни булды дип сорады. Гәүһәр сөйләп бирде.

— Син артык борчылма, Гәүһәр,— диде Гөлсем апа.— Укытучыга төрле ата-аналар белән эш итәргә туры килә.

— Моның кебекләре булмый торгандыр инде, Гөлсем апа.

— Талияләр атлаган саен очрамый, шунысы яхшы да, Гәүһәр. Минемчә, Акназарның язмышын Бибинур белән сөйләшеп хәл итәргә кирәк. Бу Талияләр белән сөйләшүдән мәгънә чыкмас.

— Талия, Гөлсем апа, нинди генә булса да ана бит. Баласына бөтен мәхәббәте корыгандыр дип ышанасы килми.

Менә шул мәсьәлә әле хәл ителеп бетмәс борын Гәүһәр өчен икенче бәла килеп чыкты. Дөрес, монысы мәктәпкә бәйләнгән эш булмаса да, Гәүһәргә бик авыр минутлар китерде. Мәсьәлә шунда, Гәүһәр Билал Шәнгәрәев Яшел Ярдан киткән, дип исәпли иде. Дөрес, Билал ул чакта бик кызды, әлек, ирегез бар чакта мәсьәлә башка иде, мин сезне яшып сөйсәм дә, бу турыда сезгә әйтергә батырчылык итмәдем, инде язмыш сезне ирегездән аерган икән, дөресрәге, мине кызганган икән, нигә яңадан киреләнергә? Сезне минем кебек саф күңелдән сөюче бүтән кеше дөньяда да юк бит, диде. Шуннан соң да Гәүһәр аны кире какты, мин сезгә ачуланмыйм, ләкин үз туксаныгызны туксан дип сайрый башласагыз, мин бүтәнчә эшли алам бит, диде. Билал башын иде, озакламыйча Яшел Ярдан бөтенләй китеп барды. «Авыр булса да, аңлагандыр», дип уйлады Гәүһәр. Никадәр ялгышкан! Билал Шәнгәрәевнең яңадан кайтканлыгын әйттеләр. Моны ишеткәч, Гәүһәр аптырап калды, бик нык ачуланды, Билал Шәнгәрәев белән асла очрашмаска булды. Ләкин бер дә көтмәгәндә Билал Шәнгәрәев аның каршына килеп чыкты.

— Куркыттым бугай, гафу итегез,— диде Шәнгәрәев, ялан башын иеп.— Беләм, минем өметем юк...

— Билал, сез, ахрысы, мине чыннан да ачуландырырга уйлагансыз. Сез шуны телисезмени?

— Юк. Ләкин минем сезнең көләч төсегезне соңгы тапкыр күрәсем килә. Сез белмисез бит, белергә теләмисез дә: мин сезне бик сагыначакмын, озак сагыначакмын.

— Билал, ихтимал, сез дөресен әйтә торгансыздыр. Ләкин минем йөрәгем буш, салкын. Мин сезгә яхшы дус итеп карыйм. Артык бернәрсәм дә юк бит. Мәхәббәт өчен бу бик аз, чамасыз аз. Нигә сез шуны аңламыйсыз?

— Мин бәлки аңлый да торганмындыр, бәлки көн кебек ачык нәрсәләрне дә аңламый торганмындыр, бәхәсләшмим. Ләкин...

Гәүһәр аңа башын кыйшайта төшеп карады. Юк, Билал алдамый кебек, пароходтан төшеп юлдан кайтуы да дөрес. Ничек, нинди йөрәк белән шундый кешегә каршы тупас кыланасың да, онытылмас авыр сүз әйтәсең? Ләкин нишләсен соң Гәүһәр? Билал янында булса да ул бер рәхәт таймый, дөнья да аңа башкача күренми, тирә-як та киң түгел, күгендә кояшы да юк. Күп булса, аның күңелендә Билалны кызгану

бар, ә кызгану — мәхәббәт түгел бит. Бәлки, Гәүһәр бервакытта да чын мәхәббәт тапмас, гомер буе ялгыз калыр, үткән хисләр, тонык күләгәләр белән яшәр, нишләсен, өлешенә төшкән көмеше... Ә белә торып кешене ничек алдарга, үз уйларыңны яшереп кыланыргамы? Юк, ачы булса да, тагын бер тапкыр, бусы инде соңгы тапкыр, турысын әйтергә тиеш:

— Билал, сез мине гафу итегез, боларны бәлки кешегә сөйләргә ярамый торгандыр, мин кешенең иң нечкә хисләренә кагыла торганмындыр... Миңа сез киткән идегез, ә мин, турысын әйтәм, һич ялганламыйм, сезнең турыда... якын итеп уйлап та карамадым. Бәлки, кайчан булса, искә алыр идем, ихтимал, уйлар да, әзрәк сагышланыр да идем. Ләкин болар барлык кешеләргә дә хас нәрсә, болардан мәгънә эзләү яки шул булмас нәрсәләргә ышанып, гомереңне заяга үткәрү, минемчә, тилелек, ихтимал, артыграктыр да әле. Үзем хөрмәт иткән кешемне мин шундый хәлдә күрәсем килми, Билал, дөресен әйткәндә...— Гәүһәр ачы гына елмаеп куйды.— Күрәсең, мин нинди акыллы булдым, нинди тирән мәгънәле сүзләр сөйлим.— Һәм житди итеп өстәде:— Мин бик авыр чакта сүз кушарга бер кешем бар дип уйлый идем, инде аның белән дә мәңгегә саубуллашам. Мин беләм, хәзер сез бернәрсә дә әйтә алмыйсыз, соңыннан, күпмедер вакыт үткәч, теләсәгез, бәлки, хат язарсыз, теләмәсәгез, бу сөйләшү онытылганчы, бер истәлек булыр.

Билал бу кадәр мәрхәмәтсез булмауны, яныннан бу кадәр тиз кумауны үтенде.

— Минем әйтәсе бик күп сүзләрем бар иде, күрәм: хәзер аларны сөйләп тору,ниндидер өмет баглау — буш нәрсә. Мин, билгеле, күп нәрсәне аңламыйм. Бу яман төш кенә кебек. Миңа уянып китәрмен дә барысы да үзгәрер шикелле... Бу кечке кояш белән яктыртылган тын урамнарны, мәһабәт Каманы һаман уйлармын. Сезнең Нева елгасын күргәнегез юк. Бик күп нәрсәне искә төшерә ул, бигрәк тә миңа шундый кичке тын сәгатьләрдә. Мин Невага карап Каманы күз алдыма китерермен, сезне сагынырмын... Яшермим, пароходтан төшкәндә минем әле кечкенә генә өметем бар иде. Хәзер ул да юк. Мин бөтен дөньяда ялгыз...

— Зинһар, мондый сүзләрне әйтмәгез, Билал. Аларны кемнәрдер әйткән инде.

— Яхшы. Миңа яр буенда бераз утырыйк, Камага карыйк, аннары мин китәрмен...

Алар яр буендагы ялгыз урындыкка утырдылар. Кичке кояшта Кама җемелди. Ул шулай җемелди-җемелди айны каршы алыр, аннары су өстенә ай юлы сузылыр. Батмыйча, шул ай юлыннан туйганчы бер йөрсәң иде. Бәлки, кычкырып, бар дөньяга ишетерлек итеп бер җырларга кирәктер. Нәрсә турында? Бәлки, мәхәббәтне кабул итмәгән бер чибәр турында, бәлки, тагын берәр нәрсә турындадыр. Җыр бит үзеннән-үзе чыга, аның башы да, азагы да булмый. Ә бәлки, җырларга да кирәкми торгандыр, кайгыңны агым суга сөйләп яр буенда утырсаң да җитәдер...

Билал Шәңгәрәев тирән итеп көрсенеп алды, еракта күренгән пароход утларына күз төшерде. Пароход әллә килә, әллә китеп бара. Салкын да түгел кебек, ә Гәүһәр йөзен җиңелчә пальтосының якасына яшергән. Әдәп йөзеннән Билал янында утырса да, уйлары кайдадыр еракта, ахрысы. Нәрсә уйлый ул? Әйтүе кыен. Бәлки классы, бәлки Казандагы тормышы турындадыр. Алар бит җәй җитүгә Идел буена чыга торганнар иде, дача тәрәзәсеннән яки ярга чыгып утырып, менә шулай киң елгага карыйлар иде...

— Карагыз, Кама нинди киң, тирән, салмак... Ул кешеләрнең бөтен нәрсәне кабаланып эшләүләрен яратмый торгандыр,— диде кинәт Билал, карашын елга түренә төбәп.— Сезнең Кама турында уйлаганы-

гыз бармы, Гәүһәр? Мин Нева турында күп уйланам. Миңа шулай аның дулкыннарына карыйм да әллә нәрсәләр исемә төшә. Онегиннар, билгеле, әдәби геройлар гына. Ә мин аларны да Нева ярында күрәм, алар да тирән уйларга батканнар кебек. Бер карасаң, заманалар башка, күп сулар аккан, революция җилләре искән, ә кешеләр... Мине үз заманының дәһшәтле елларын йоклап үткәргән бер өтек җан дип уйламагыз тагы, мин үз заманымны, аның хисләрен яхшы беләм, әлбәттә. Мин монда мгновениеләр турында,— Билал елмаеп җибәрде,— гафу итегез, татарчасын тапмадым, миңа шул күз ачып йомганчы үтә торган вакыт турында уйлыйм. Миңа шундый чакта мәхәббәт бер дә үзгәрмәгән кебек. Сезгә шулай тоеламы?

— Белмим,— диде Гәүһәр, бераз хәйләләп.— Мин алай зурдан уйламыйм.

— Сез юри үзегезне каралтырга тырышасыз, Гәүһәр. Бер дә каралмыйсыз. Мин моңа ышандым инде.

— Юатуыгыз өчен рәхмәт.

— Юк, мин юатмыйм, сез аңа мохтаҗ да түгел... Әгәр кирәксенсәгез, үпкәләмәсәгез, мин сезгә әйтер идем дә...

— Кирәкми, Билал. Болар, минемчә, сүз уйнату гына. Әйдәгез кайтыйк инде.

Билал урыныннан торды, аннары икесе дә яр буйлап сүзсез генә кайттылар. Инде караңгы төшкән, урамнарда халык кайный, кино каршында яшь-җилкенчәк, кайдадыр бик матур музыка, чыр-чу, автомобиль тавышлары. Әллә каян гына Миләүшә белән Вилдан килеп чыктылар. Аларның сөйләшергә теләкләре бик зур булса да, Гәүһәр янында чит кеше күргәч, исәнләшеп кенә узып киттеләр. Бик киенгән, бизәнгән Талия очрады. Гәүһәр аның белән исәнләште, Талия башын да имичә үтеп китте. Аның бу кыланышы Гәүһәрне кимсетмәде, тик Билал аны күрдеме-юкмы дип уйлады. Ләкин Билалның үз уйлары чигеннән ашкан, ул беркемгә дә карамый иде.

Ниһаять, Гәүһәр туктады, алар тыкрык башына җиткәннәр иде. Билал сискәнеп китте, тирә-ягына карады.

— Я, сау булыгыз, Билал. Иртәгә самолет белән очасызмы?

— Әйе, самолет белән,— диде Билал әкрен генә.— Мин сезгә тагын ни әйтергә дә белмим. Әллә ничек кенә шунда... Шулай аерылабызмы икәнни?

— Кирәкми, Билал. Бераздан барысы да онытылыр.

— Мин бит сезне бүген генә күрмәдем...

Менә Гәүһәрнең күләгәсе дә югалды инде. Билал тын тыкрыкка тагын бераз карап торды да ай яктырткан урамга борылды.

## ӨЧЕНЧЕ БҮЛЕК

### 1

Пароход әкрен генә кузгалып, агым өстендә салмак кына борылды да Яшел Яр пристаненнан китте. Минутлар үткән саен, ул кечерәйгәннән-кечерәя бара, ә Әгъзәм Ибраһимов һаман яр буеннан кузгала алмыйча тора. Инде озатучылар да шау-гөр килеп, кайберләре тирән уйга батып, башларын түбән иеп, кайтып киттеләр. Юл юл инде ул, озынмы, кыскамы — аның бер башында билгесезлек. Кешеләр шул турыда уйламасалар да, ул кайдадыр күңелнең бер почмагында яшеренеп ята. Шуңа күрә күңелеңнән әллә нәрсәләр уйлыйсың, әллә нәрсәләр көтәсең.

Әгъзәм Ибраһимов башка озатучылардан бер ягы белән дә аерылмый иде. Ул дебаркадерның түбән катында кул болгап басып торды, пароход моннан начар күренә башлагач, ашыгып, өске катка менде.

Су өстендәге пароходны моннан ярыйсы шәйләргә була әле. Вакыт-вакыт аннан күңелле музыка ишетелә. Әгъзәм күз алдына китерә: хәзер анда, пароходта, берәү дә каюталарда калмагандыр, барысы да палубага чыгып, яр буйларын карап бара торганнардыр. Көн кояшлы, эссе, җил бөтенләй юк. Мондый чакта җир өстендә баш тыгарга урын таба алмыйсың, ә су өстендә рәхәт, җиләс. Миләүшә белән Вилданның гитара-мандолиналары бар, домино да алып чыкканнардыр, алар бит бу сәяхәткә озак хәзерләнделәр. Укулар беткәч тә шаулатып туй ясадылар, җитмәсә, шатлык өстенә шатлык дигәндәй, аларга шәһәрнең югары өлешеннән менә дигән ике бүлмәле аерым квартира да бирделәр. Квартиралары өске катта, тәрәзәләреннән Кама күренеп тора. Менә шул шатлыкларның барысын бергә җыеп, Миләүшә белән Вилдан туй сәяхәтенә чыктылар, хәзер берсе гитара, берсе мандолина чиертә торгандыр. Гәүһәр дә алар янындадыр...

Иделдә сәяхәт итәргә аның бер дә теләге юк иде. Бигрәк тә соңгы вакытта Акназар вакыйгасы аны нык борчыды. Башта бер дә бирешмәгән иде кебек, Акназар табылып, ачыкланасы хәлләр бар да ачыкланып беткәч кенә Гәүһәр кинәт туарылды да калды. Җитмәсә, нәкъ шул вакытларга Билал Шәнгәрәев тә туры килде. Барысы бергә булгангадыр, ахрысы, ул укулар тәмамлангач, авырып, урынга ук егылды. Бик озакка дип уйлаган иде, яшь организм үзенекен итте, күрәсең, берничә көннән соң ул аякка басты. Хәзер, күңеле һәм тәне тәмам ныгысын өчен, аңа яхшы ял кирәк. Әгъзәм аңа санаторийга путевка да тәкъдим итеп карады. Гәүһәр моңа бик гаҗәпләнде, сагая калды. Бер кыш укыткан кешегә ни сәбәптән мондый хөрмәт? Әйтми генә, мөгаен, үзенә дигән путевканы тәкъдим итә торгандыр әле. Гәүһәр аңа җылы карый башлаган иде, болай булгач, Әгъзәм дә, Алчыннар, Билаллар кебек, бер иштән була түгелме? Әй, бу ирләр!

Гәүһәр путевкадан баш тартты. Үгетли торгач, Иделдә сәяхәт итәргә генә күнде.

Казанда алар Идел пароходына утырырлар, аннары Горькийга юл алырлар. Соңыннан яңадан Казанга кайтып, Астраханьга таба төшеп китәрләр.

Ни өчен ул үзен шулкадәр яраткан, шулкадәр озак еллар аның артыннан йөргән Билал Шәнгәрәевне борып җибәргән, дип уйлады Әгъзәм. Билал начар егет түгел. Яшел Ярдан кайтып китәр алдыннан ул Әгъзәм янына да кереп чыкты. «Бар да бетте, минем барлык өметләрем челпәрәмә килде,— диде ул, башын ике кулы белән кысып.— Ләкин мин аны гомердә дә оныта алмам шикелле. Минемчә, дөньяда икенче шундый хатын-кыз юк».

Шунда Әгъзәмнең үз өмет йолдызы кайдандыр томан эченнән күренгәндәй булды, ләкин бу йолдыз шулкадәр кечкенә, аңа нинди булса бер ышаныч баглау тилелек булыр иде.

Әгъзәм Билал Шәнгәрәевнең бөтен мәхәббәт тарихын белә, бу мәхәббәт бар чакта ул үз хисләре турында авыз ачарга да курыкты, чөнки шундый олы тойгыга кул сузу чиксез зур мөртәтлек булыр иде, дип санады. Билалның мәхәббәте кире кагылгач, ул тагын шиккә төште: бу — нәрсә, Гәүһәрнең бик эредән сайлавымы, әллә тормышы бер җимерелгәч, икенче тапкыр үтә сак кылануымы?

Сәяхәткә китәр алдыннан Гәүһәр Әгъзәм белән бераз эчке дөньясы турында да сөйләште. Идел буйларында йөрү, андагы шәһәрләрне бер күрәсе килүе — күптәнге хыялы булуын әйтте.

— Чынлап уйласаң,— диде,— Идел-Камада торып, буйларында бер йөрмәү — әллә ничек, бигрәк тә укытучы кешегә. Укытучы бит үзенең зәвкы турында гына уйламый, аның классы бар, классында ничәмәничә бала бар. Балалар барысын да белергә телиләр, бу аларның табигате. Аларга бит теләсә ничек сөйләп булмый.

Әгъзәм Гәүһәрнең күңел яраларын яхшы белгәнгә, бик сак кыланды, бер артык сүз әйтмәде. Гәүһәр үзенең шәхси тормышын яңадан төзергә ашыкмас, шуңа күрә ул Алчынны да, Билалны да кире каккандыр, хәтта Ленинградка да кызыкмагандыр. Гәүһәрнең чын уйларын белү бик авыр, аның каравы, Әгъзәмнең үзенең дә хәле хәл. Сылу һәлак булганга өч елдан артык инде, ә Әгъзәм аны әүвәлгечә сагына, бигрәк тә ялгыз калганда түзүләре читен. Хәтта Гәүһәр турында уйлаганда да аның уйлары Сылу белән үрелделәр. Шуңа күрә Әгъзәм кайчагында саташа сыман хис итә үзен. Чын менә, сәламәт акыл болай булмаска тиеш шикелле. Авыр, бик авыр булса да, ахыр килеп ул бу хәлгә күнәргә тиеш, чөнки башны ташка бәреп булмый, үлгән артыннан үлеп булмый, ә ул... һаман эзли. Билгеле, юкны эзли, аңа карап Сылу табылмаячак. Акылы айныграк булганда, Әгъзәмне бер нәрсә куандыра: соңгы вакытларда Сылу нечектер бераз артка чигенә төште, гүя ихтыяри рәвештә ул үзенең урынын башкага бирде. Кемгә? Монысын ул әйтми, шулай ук Әгъзәм дә анык кына белми. Әнә пароход киткәнгә күпме булды инде, аның аксыл томанга кереп югалуына да байтак, ә Әгъзәм һаман да суга карап тора. Су өсте тибрәнә, дулкыннар гүя нәрсәдер әйтергә телиләр, тик әйтмиләр. Суның өсте генә бераз шадра, төбе — кара, серле, анда бернәрсә дә ачык күренми. Шул дулкыннар кебек, йөрәк тә серле, каядыр чакыра да кебек, нәрсәдер чабудан да тота шикелле.

Атна-ун көннән Әгъзәм үзе дә ял алырга тиеш. Дөрес, ул Идел буйлап сәяхәткә чыкмаячак, монсы хәзер көн кебек ачык, ул каядыр көньякка, диңгез буена китәчәк. Аңарчы ул телеграмма көтәчәк. Бу телеграмманы Горькийдан әйләнеп кайткач, Вилдан сугарга тиеш. Өмете дә юк Әгъзәмнең, шулай да... Нәрсә бу? Тилелекме?

Әгъзәм сабыр гына елмаеп куя. Телеграмма көтмичә, аның үзенә пароходта китәргә мөмкин идеме? Чарасын күргәндә, мөмкин иде. Ул бармады, хәтта бу турыда авыз да ачмады. Ник? Гәүһәрнең аның белән бармаячагын белгәнгәме? Әллә үз күңеленә үзе ышанып бетмәгәнгәме? Хәер, буласы булган инде хәзер, үкереп еласаң да пароход кире кайтмаячак, ул һаман үз юлы белән бара бирәчәк, ике ара торган саен ераклаша барачак.

Әгъзәм тагын бераз суга карап торды да түбәнгә төште, ашыкмый гына ярга чыкты. Аяк астында такталар әкрен генә сыгылып калды. Узышлый яр буена сыенып утырган пристань биналарына күз төшереп алды да — бу җирләр аңа күптән таныш иде — бераз барып, текә тауга күтәрелде. Аннары коры елга аркылы салынган озын басмага юнәлде. Ничектер артына борылып, бик киң булып җәелеп яткан Камага карады. Кояш төшкән, су чак кына тимгелләнеп тора, монда аз гына да җил булмаса да, елга өстендә, күрәсең, бераз бар. Кама ялтырый-җылбырдый кешеләрне үзенә дәшә кебек.

Бүген Яшел Яр Әгъзәмгә күңелсез булып тоелды. Урамнарында, тыкрыкларында шулай ук халык кайный, бар да күбәләктәй матур итеп киенешкәннәр, шау-гөр килеп сөйләшәләр, көлешәләр, кинолар, кибетләр, кафелар эшли, машиналар йөреп тора, әнә кемнәрдер больницага ашыга — өзек-өзек сүзләреннән шул аңлашыла, әнә кемнәрдер Яшьлек шәһәренә бара торган автомашиналар туктаган урынга юл тоталар, сәгатьләренә карый-карый, кызурак атлыйлар. Ә Әгъзәмгә боларның кызыгы юк. Ул кемнедер юксына, билгесез сәбәпләрдән борчылып та куя. Нәрсәдән икән? Шундый нык, таза ир кеше куркамы? Әгәр берәр таныш хатын-кыз очрап, нигә болай күңелсезләндең, дип турыдан-туры сораса, ул ни әйтә алыр иде аңарга?

Әгъзәм эш урынына — ронога кайтып керде. Ике катлы агач йорт, борылмалы текә баскыч, тар һәм ярым караңгы коридор. Башка вакытта Әгъзәм боларны сизми дә иде, мең кат моннан узган, һәрбер

борылышы, һәрбер ишеге таныш, коридорларда айкалып торучы халыкны исәпләмәсәң, монда эшләүчеләрнең һәрберсен ул исемнәре белән белә. Икенче каттагы кечерәк кенә эш бүлмәсе аның инде аерылмас бер кисәге булып киткән. Көтеп торучылар юк. Әгъзәм кесәсендәге ачкыч белән ишекне ачып керде. Монда бераз салкынчарак. Ул ачык тәрәзә кырыендагы өстәл янына килеп утырды, маңгаена бәреп чыккан тирләрен кулъяулыгы белән сөртте. Өстәле тулы кәгазь, газета, шунда ук телефон. Кәгазьләр бар да бүген хәл итүне, сөйләшүне сорый. Әгъзәм үзе дә кабинетка керү белән үк эшкә чумармын дип уйлаган иде. Ләкин бүген аңа әллә нәрсә булды, ашыгыч эшләренең берсенә дә кулы күтәрелмәде. Тәмәке кабызды да, төтенен ачык тәрәзәгә өрә-өрә, уйга чумды. Карасу яшел агач яфраклары арасыннан күк күренә. Бу якта кояш юк. Бакчада бер генә яфрак та селкенми, бер генә чыр-чу тавышы да ишетелми. Урамдагы машина гүләве дә монда килеп җитми диярлек, нинди дер оеганлык, талгынлык. Ботактан ботакка, яфрактан яфракка сузылган тожым җепләре күренә. Күптән җил, яңгыр булганы юк. Көннәр, ахрысы, шактый озакка утырган. Әйе, июль башы шулай була инде ул.

Әгъзәм Гәүһәр турында ихтыярсыз уйлана башлады. Башка вакытларда да шулай була торган иде, бүген бигрәк тә. Ул әллә ничә мәртәбә кесәсенә тыгылды. Нәрсәдер оныткан мы, төшереп калдырганмы. Әйе, шулай. Юк, исенә төште. Фотограф Гәүһәрнең бик матур рәсеме бар диган иде. Әгъзәм махсус бер-ике данә эшләргә кушты. Шунысын әйт, бу рәсем Әгъзәмгә кирәк икәнен каян белеп алган фотограф? Әгъзәмнең бит аңа Гәүһәрнең исемен дә, фамилиясен дә әйткәне юк (Гәүһәр ире белән аерылганнан соң яңадан кыз чактагы фамилиясен — Гарипова дип йөртә башлады). Җор була шул фотограф халкы, күрәсең, иснәнгән. Хәер, моның әһәмияте бармыни? Әгъзәм урыныннан торды да бүлмәсеннән чыкты. Фотограф шул ук бинаның беренче катында — район газетасы белән янәшә кечкенә генә бер бүлмәгә урнашкан. Ләкин фотограф бүлмәсе бикле иде. Әгъзәм шундагы кешеләрдән күрмәдегезме дип сораштырып та карады. Төшкә хәтле бүлмәсе гел ачык булган, хәзер кая киткәндер — күрүче юк икән.

Өчме-дүртме төшкәннән соң гына Әгъзәм фотографны очратты. Рәсемне эшләмәгән булып чыкты, тик пленкасын гына әзерләп куйган.

— Сез, Әгъзәм абый, бер дә борчылмагыз. Рәсем минә диган. Тик хәзер вакытым гына юк, номерга рәсемнәр өлгертәм. Бераз вакытым булу белән үк эшлим. Әйткән сүз — аткан ук, бетте.

— Онытырсың,— диде Әгъзәм фотографка бик үк ышанып бетмичә.

— Минме? Что сез. Кайбер кешеләр яулык почмагын бәйләп кесәләренә тыгалар. Ә минем хәтер сандыгы — менә чәнчә бармак очында,— ул йөзекле бармагын шундый мәзәк итеп кыймылдатып алды, Әгъзәм ихтыярсыздан елмаеп куйды.

— Хәтер сандыгың әйбәт кыймылдый, ләкин кайсы якка,— диде Әгъзәм.

— Фотограф белән сапожникка анысы да кирәк, ләкин сез тыныч булыгыз. Әйттем, бетте. Үлсәм, үләрмен, но эшлим.

— Үлә күрмә, болай өметкә ышанабыз, үлгәч, өмет тә калмый бит.

Фотограф кычкырып көлде. Әгъзәм, алайса иртәгә керермен, дип чыгып китте.

## 2

Сылу исән чакта аларның бүлмәләре шактый иркен иде. Әгъзәм мәктәптә укыту бүлеге мөдире булып эшли иде. Сылу һәлак булгач, Әгъзәм торган шәһәреннән дә, мәктәбеннән дә китте. Аңа монда, һәр

адымы Сылуны хәтерләткән шәһәрчектә, яшәве бик кыен иде. Иптәшләре моны аңладылар, аның икенче шәһәргә күчеп китүенә каршы килмәделәр. Әгәр теләсәң, безгә кабат килерсең, без һәрвакыт сине кабул итәрбез, диделәр. Бер киткәч, Әгъзәм кайта алмады инде. Ул әтиәниләренә кунакка гына кайткалады. Анда да бер-ике көн эчендә тәмам кешелектән чыга, Яшел Ярга кайткач та бер атна буе диярлек әйле-шәйле йөри иде. Тик Гәүһәр белән танышкач кына бераз үзгәрде. Элек ул Гәүһәрне читтән торып кына белә иде. Барысы да шул очраклы рәвештә Казан гостиницасында танышкан Билал Шәнгәраев аркасында башланды. Бер яктан, ул Гәүһәрне күкләргә күтәреп мактады, икенче яктан Гәүһәрнең ирдә булуы, үзенең берниндн дә өмете юклыгын сөйләде. Бу вакытта Әгъзәм Билалны бары тик кызганды гына, аңа бертөрле дә киңәш бирә алмады. Хәтта Билалның үгетләвенә дә карамастан, Гәүһәрне читтән генә күрү теләге дә тумады. Гәүһәр әллә нинди генә матур булса да, ул ирдә чакта Әгъзәм Билалга бернichек тә булыша алмаячак. Хәер, Билал да артык бәйләнмәде, аптыраганнан гына, диде һәм озакламыйча кайтып та китте. Соңыннан, Гәүһәр Яшел Ярга килеп чыккач, Әгъзәм аны читтән генә күзәтте. Гәүһәр матур булса да, Билал мактаганча ук түгел. «Гашыйкның күзенә сөйгәне фәрештә булып күренә», дип уйлады ул. Хәзер, әгәр Билалның карашы үзгәрмәгән булса, Әгъзәм аңа, ихтимал, булыша да алыр иде. Гәүһәр белән танышу бары тик вакытка гына бәйләнгән, иртәме, соңмы алар барыбер танышачаклар, алар бит бер өлкәдә эшлиләр. Һәм таныштылар да. Бер күрүдә генә Гәүһәр аңа тәэсир итмәде. Әгъзәмнең Билалга булышу теләге артканнан-артты. Ул хәтта Билал Шәнгәраевкә хат та язды. Ә Билал: «Пароход төшү белән үк Яшел Ярга барам», дип телеграмма гына сукты.

Бу вакытта әле кар-бураннар уйный иде. Әгъзәм экрен-экрен Гәүһәргә ияләште, аңа ничектер башка күз белән карый, аның вак-төяк йомышларын бик теләп үти башлады, аның белән очрашу юлларын үзе эзләде, аның белән урамга да чыккалады. Кама буена да төште. Ихтимал, сизгер хатын-кыз кешегә аның күз карашы күп нәрсә әйткәндер, әмма Әгъзәм, Гәүһәрне ачуландыра язып, Билал турында гына сөйләде. Гәүһәр бераз киреләнсә дә, бик тиз риза булыр, Ленинград турында күптән хыяллана torгандыр дип уйлады. Шундый тәкъдимне кире кагаргамы? Билал бит төпле егет, инженер, Ленинградта квартирасы да бар, тормышны алып бара белә. Тәскә-башка да ямьсез түгел, сөйләшергә дисәң дә булдыра, белгеч буларак та яхшы исәптә булса кирәк, урыны зур, үзе бер дә шапырынмый. Гәүһәрнең гел кире кагуы хатын-кыз назлануы гынадыр. Әллә, элекке ире аның бик яхшы булып, аны һаман оныта алмыймы? Кире кайтырга нияте бармы?

Гәүһәр пароходта сәяхәткә киткәч, Әгъзәмнең бу фикере тагын да көчәйде. Гәүһәр пароходтан төшеп калыр да элекке иренең каршына барыр күк тоелды аңа. Әгәр шундый уе булмаса, нишләп Билал Шәнгәраевне кире борып җибәрер иде икән?

Ишек шакыдылар. Күршеләре Әгъзәмгә телеграмма кертеп бирде. Әгъзәм аны көне буе көтә иде, алгач, ачарга куркып торды. Телеграмма әллә нәрсә хәбәр итәр күк тоелды. Ниһаять, укыгач, җиңел сулап куйды. «Казаннан исән-сау чыгып киттек. Һичбер үзгәреш юк. Вилдан»,— диелгән иде анда.

Әгъзәмнең иңнәреннән тау төшкәндәй булды. Ул телеграмманы кабат-кабат укыды. Бу инде Горькийдан кайткач җибәрелгән телеграмма. Хәзер Гәүһәрләр кайда икән? Ульяновскийны узганнардыр инде.

Әгъзәм фотографтан алып, матур рамкага куйган Гәүһәр рәсеменә карый. Фотографка сүз әйтерлек түгел, рәсем чыннан да матур чыккан. Гәүһәр чак кына көлемсери төшкән.

Байтак уйланып утырды Әгъзәм, аннары сәгатенә карап алды. Җиде тулган, сигезенче. Ашыйсы да килә. Әгъзәм, буфетны ачып, корысары белән тамагын туйдырды, аннары ишеген бикләп урамга чыкты. Эңгер-меңгер төшкән, җылы, җил бөтенләй юк. Бу вакытта өендә утыручы кеше бик аз булса кирәк, бөтен халык ишек алдында, капка төпләрендә, урамда. Һәммәсе әкрен генә нидер гәпләшәләр, яшь-җилкенчәк кулында кечкенә радиоалгычлар, бөтен тирә-якка талгын гына музыка тарала, шунда ук бала-чага да чыр-чу килә. Өйләрнең караңгы тәрәзәләре ачып куелган.

Әгъзәм зур урам буйлап бераз барды да тынрак тыкрыкка борылды. Биредә дә капка алларында олырак яшьтәге абый-апалар сөйләшеп утыралар. Әгъзәмгә берсе дә игътибар итмәде, монда аны танымыйлар күрәсең. Кайдандыр тәмле токмач исе килә иде.

Бераздан Әгъзәм Зәбирә түтиләр каршында иде инде. Әле ерактан ук ул капка төбендә кулына газетамы, журналмы тотып утырган Зәбирә түтине күрде. Якынрак килгәч, исәнләшеп янына утырды.

— Әле менә яңа «Азат хатын» журналын алдым. Элек ничә бәйрәмдә бер кулыма эләксә генә аз-маз йөртә торган идем. Яңа елдан Гәүһәрем өйгә яздырды. Хәзер көтеп алып, бар эшемне ташлап укыйм. Бик кызык язалар да инде, хикәяләре дә бар.

— Бик яхшы, Зәбирә түти, димәк, аң-белемгә тартыласың.

— Һәй, әйттең инде, Әгъзәметдин, аксак Зәбирә дә аңлы булган дисәләр, тигез җирдә егылып үләрсең. Эч пошканнан гына инде.

— Эч пошканнан көтеп алып укымыйлар, яратканга укыйсыңдыр.

— Билгеле, яратканга, яратмасам, вакыт әрәм итәмме. Я, ярый, Гәүһәрдән хат-хәбәр юкмы?

— Ә мин сезгә юкмы дип белешергә кагылдым әле.

— Юлдан язган бер ачык хаты килде. Сиңа зур хат язгандыр дигән идем.

— Миңа, Зәбирә түти, ул язмас. Мин кем ул хәтле?

— Син кем дә түгел түгелен, тик нигә ул сиңа язмасын? Пароходта эш юк лабаса. Менә миңа язган бит.

— Син, Зәбирә түти, башка. Сиңа берне дә, икене дә язар.

— Әйдә кереп укыйсыңмы?

— Хәзер керербез. Киче бик яхшы бит. Нинди тын, нинди җылы. Җәй айларында Яшел Ярдан һич китәсе килми.

— Ялга барам дигән идең түгелме соң?

— Шулай дигән идем дә, белмим, барыйммы икән? Берничә көн уйлыйм әле, Зәбирә түти.

— Кыш көне бит сиңа ял бирмәсләр. Яшь кешегә бераз дөнья күрергә дә кирәк. Үзояңнан чыкмасаң, җиһанның зурлыгын каян беләсең. Укып кына яки кинода гына әллә ни күренми.

— Анысы шулай да, ялкаулык зур.

— Юкны сөйләмә әле, Әгъзәм. Ялкаулар җитәрлек булса да, син алар исәбенә керми торгансыңдыр әле.

— Һай, Зәбирә түти, синең янында итәкләрне җыя төшеп утырырга кирәк икән.

— Миннән, Әгъзәм, җыйдың ни дә, җыймадың ни. Мин барыбер кешегә сөйләмим. Менә хәзер, Гәүһәрем өйдә булмагач, өйгә керәсем дә килми. Ярый әле, кичләр озын, капка төбендә утырып була.

— Эч пошу ул, Зәбирә түти, бездә дә җитәрлек. Шуңа күрә, бүген ял көне дип тормадым, иртүк торып лагерьга киттем. Рәхәт анда, Зәбирә түти. Гәүһәр укыткан балаларны да күрдем. Акназар исемле малайлары суга батучы бер баланы коткарган икән, бик зур итеп сөйлиләр.

— Гәүһәр әйткән иде шул. Акназарның әнисен дә күргән идем. Авызыннан төкерек урынына ут чәчә, имеш, Гәүһәр аның улын харап

итәргә алынган. Качырып башына житә алмагач, суга батырырга ыргый.

— Чеп-чи ялган бит бу, Зәбирә түти!

— Акны кара дип сөйләүчегә синең чынын ни дә, ялганың ни.

— Гәүһәр моны ишетсә, ана бик авыр булыр.

— Юк, ул Талиянең кемлеген белә инде хәзер. Балаң турында бергәләп кайгыртыйк дип күпме мәктәпкә чакыртты, өенә дә барды, Талиянең кашы да селкенмәде.

— Менә ана кеше!

— Аналар, Әгъзәм, балалары өчен утка да керә, бусы анын арадан чыккан... Әйдә Гәүһәрнең хатын укыйсыңмы? Берәр стакан чәй дә эчәрсең. Мина да күңелле булыр.

— Чәй эчәсем килми, Зәбирә түти. Менә хатны рәхәтләнеп укыйм.

— Укы да, Әгъзәм балам, үзең дә яз. Мин кая язарга икәнен дә белмим, аннары минем таракан эзләреннән әллә ни мәгънә дә чыкмас.

Алар өйгә керделәр, ут кабыздылар. Бүлмә эче балкып китте. Гөлләр, рәсемнәр — бар да элеккечә, Гәүһәр үзе дә такта белән генә бүлгән икенче бүлмәдән әкрен генә елмаеп килеп чыгар төсле.

Зәбирә түти, аксый-аксый өстәл янына килеп, Әгъзәмгә открытка суздзы. Өстенә Идел күренеше белән ап-ак пароход төшерелгән бу хатка Әгъзәм берничә секунд карап торды, аннары кире ягын әйләндерде. Бу хатны Казаннан салган икән, язуы әле Камада булган. Бик яхшы барабыз, Идел пароходына утыргач ничек булыр тагы, белмим, дигән. Хатта язмаса да, һәр сүзеннән, һәр юлыннан яшерен борчылу сизелә. Күрәсең, көтелмәгән очрашудан курка. Вилданның телеграммасы соңрак, Горькийдан әйләнеп кайтып, кабат Казаннан кузгалыр алдыннан сугылган. Димәк, очрашу булмаган. Гәүһәрнең үзенең күңеле нык булса, бу очрашудан әллә ни куркыр урын да юк шикелле. Гәүһәр үз күңеленә үзе ышанмый булса кирәк.

Хатны укыгач, Әгъзәм кайтырга җыена башлады.

— Чәй эчмим дисең инде.

— Рәхмәт, бик рәхмәт, Зәбирә түти.

— Алай булгач, ни әйтим. Хәлемне белгән өчен үзенә рәхмәт. Мөмкин булса, хат язып, Гәүһәремне дә шатландыр инде.

Әгъзәм Гәүһәргә хат язу турында уйламаган иде. Әллә чыннан да язаргамы?

Өенә ул бик ашыгыч эше бар кеше кебек кайтты, кәгазь алып өстәл артына утырды. Тәрәзә ачык, караңгы төшкән. Җил бөтенләй юк, бер яфрак селкенми, тик бакчадан бик нечкә агым булып ниндидер хуш ис керә һәм менә шушы саф ис нәрсәнедер Әгъзәмнең исенә төшерә кебек. Әгъзәмнең бик күп тапкырлар пароходта йөргәне бар. Кич белән бөркү каютадан чыксаң, палубада шундый рәхәт салкынча була, капкара күктән бихисап йолдызлар карый. Ниләр, ниләр генә искә төшми. Ә хәзер, ачык тәрәзә каршында утырганда, Әгъзәмнең уйлары Яшел Яр белән пароход арасында айкала. Һәм кинәт хат язу гаҗәп бер кыен эш булып тоела аңарга. Ничек итеп беренче сүзне язарга? Ул синең борчылуыңны да, хисләреңне дә күрсәтмәсен, шул ук вакытта, кипкән яфрак кебек коры да, кирәксез дә булмасын.

Әгъзәм бик озак бернәрсә дә яза алмый. Сәгать уникe була, аннары бер тула, икенче ярты китә. Ул Гәүһәрнең рәсеменә карап тора һәм, ниһаять, бер сүз яза: «Гәүһәр!» Ахрысы, шул тотып торган, Акназар турында да, Зәбирә түти янында булуы, аның хат язарга тәкъдим итүе турында да, ниһаять, соңгы яңалыклар турында да яза. Миләүшә белән Вилданга күп итеп сәлам куя, үзенең алар бәхетенә кызыгуын әйтә...

Хат язылып беткәндә сәгать өченче иде инде. Тышта инде яктыра башлаган. Таң алдыннан була торган ниндидер сихри тынлык. Тик

кайдадыр пароходмы, буксирмы кычкырта. Аннары нәрсәдер ухылдаган кебек ишетелә дә янадан тирән тынлык урнаша. Әгъзәм бер ачык тәрәзәгә, бер өстәлдә яткан конвертка, рәсемгә карый. Соңыннан урынына ята. Йокысы килми, ул чытырдатып күзләрен йома. Шулай күпмедер ята, аннары кинәт күзен ача: күр, бөтенләй яктырып киткән! Өстәлдән ап-ачык булып рәсем күренә. Әгъзәм елмая. Ул яткан җиреннән рәсемгә карый һәм шулай карап ята-ята йоклап та китә. Төш күрә. Имеш, рәсемнән карап торган Гәүһәр кинәт иңбашларын селкетеп ала, Әгъзәмнең бәләкәй булмәсен күздән кичерә, аннары берни әйтми, сүзсез генә чыгып китә. Яшел Яр урамы буйлап каядыр бара. Бераздан инде ул мәктәпкә керә, классына юнәлә. Ул да булмый, Гәүһәр бик матур бакчада утыра, имеш. Тыңлый. Сандугач сайрый. Әгъзәм дә шунда, имеш. Якын килми, әллә сандугачны куркытырмын дип борчыла, әллә Гәүһәрне. Зәбирә түти дә чыккан икән. Ул, кулын изәп, Әгъзәмне янына чакыра, имеш. Әгъзәм аңа таба бара, ләкин алда ниндидер зәңгәр урман. Шунда балалар уйнап йөриләр, имеш. Менә текә яр, ниндидер бер зәңгәр күзле кызчык кулы белән аска күрсәтә.

— Менә шуннан сикерде ул! — ди.

Әгъзәм балалар каршында, имеш, акыллы батырлык турында сөйли, имеш. Аныңча без балаларда нәкъ менә шундый батырлыкны тәрбияләргә тиешбез. Күз ачып йомган арада хәрәкәт итәргә кирәк булганда, берәү дә батырлык турында сафсата сатмый, ләкин шушы бик кыска вакыт эчендә аның тәрбиясендәге бөтен яхшы сыйфатлар хәрәкәткә килеп өлгерә. Ул бер секунд эчендә соңыннан таң калып сөйләрлек батырлык эшли...

Әгъзәм артына борылып карый. Агач төбендә Гәүһәр елмаеп басып тора. Әгъзәм аның кулын кыса.

Гәүһәр шунда:

— Юк, юк. Бу Ләмига апаның эше,— дип, әкрен генә күздән югала.

## 3

Гәүһәр Казан — Горький — Казан — Астрахань пароходына бик озак ияләшә алмады. Пароход Казаннан киткәнче аның җаны уч төбендә торды: пароходка әллә кемнәр утыргандай булды, әллә кемнәрне чемоданнары белән пароходка килгәндәй итеп күрде. Хатыны Фаягөл белән Җәгъфәр яки Исрафил Дидаров утырса, Гәүһәргә нишләргә кала? Ә курыккан күзгә әллә нәрсәләр күренә бит. Аның хәтта палубадан каютага яшеренгән чаклары булды, соңыннан, тынычлана алмыйча, бик озак калтыранды. Пароход Идел уртасыннан барганда да ул палубага чыга алмыйча йөдәде, анысының чәче охшаган, монысының күлмәге... Миләүшә килеп мен бәла белән ышандыргач кына Гәүһәр палубага чыкты, анда да әле аның күзләре тынычсыз иде. Миләүшә, Вилданнарның ваемсыз көлүләре, музыка чиертүләре, әледән-әле дөньяларын онытып домино уйнаулары, ким дигәндә, аңа сәер тоелды. Бары тик кичкә таба гына әзрәк тынычланды, әле Миләүшә, әле Вилдан белән, әле танышып өлгергән күршеләре белән әкрен генә палуба буйлап әйләнде. Ул чәчрәп көлми, чак кына елмая, тынычсыз зур күзләре белән тирә-ягына карап ала. Миләүшәләр беренче сәгатьләрдә үк актарып чыккан түбәнге катларга, буфетка, почтага, кино залларга төшми, һаман палубада йөри, я челтәрле урындыкка утырып, кичке тонык суга карый.

Икенче көнне, Горький шәһәренә якынлаша башлагач, Гәүһәр шактый ачылып китте. Аның Горькийда булганы юк иде. Әле пароходтан төшмәс борын ук ул, исе китеп, яр буендагы мәһабәт Чкалов һәйкәленә, ярминкә вакытларын хәтерләткән бик кызыклы борынгы архитектура корылмаларына, яңа стильдә салынган елга порты корылмаларына

карады. Бөтен дөньяга атаклы булган автомобиль заводлары кайдадыр ундарак, диделәр. Барыннан да бигрәк, укытучы буларак, Гәүһәрне бөек пролетар язучысы Алексей Максимович Горькийга бәйләнешле урыннар кызыксындырды. Оят, ләкин аның әле бүгенгә хәтле Каширин йортында булганы юк, бары тик китаплардан укып кына Горькийның бабасын, әбисен, кызыл күлмәкле Цыганокларны күз алдына китерә...

Соңыннан, Каширин йортын караганда, Гәүһәр үзен бу йортның һәрбер почмагын белә күк хис итте, аның гүя буяу мастерскоена да әллә ничә тапкыр кергәне бар кебек, сәндерәле тәбәнәк бүлмәләрдә дә әллә ничә тапкыр йөргән кебек, Алешаның әбисе бүлмәсендәге бизәкле обойлар да, стенадагы борынгы сәгатьнең авыр гере аңа таныш кебек. Билгеле, музей хезмәткәренең борынгы Нижегородчарак итеп сөйләвен ул игътибар белән тыңлады. Бу сөйләү, китаплардан укылганнар белән бергә кушылып, кабатланмас дөнья тудырдылар...

Горькийда алар күп җирләрдә булдылар, һәйкәлләрне, борынгы Кремльне карадылар. Соңыннан, пароходка утырып, яңадан Казанга кайтканда да Гәүһәр гел шул турыда гына уйланды. Ә икенче көнне аның күңелен тагын курку һәм шик биләде, күзенә әле хатыны белән Җәгъфәр, әле Исрафил Дидаров күренгәндәй булды. Билгеле, хәзер Гәүһәр шактый тыныч, чөнки пароходка утырасы кешеләр утырган иде инде, тик моны бит акыл әйтә, ә күңел һаман үзенекен итә. Вакыт соң булганга, Казанда Гәүһәр беркая да бара алмады, бары тик вокзал тирәләрендә генә йөрде. Эчке уйларын барысын да Миләүшә белән Вилданга да ачмады, Галимҗан абыйларына бик барасы килгән иде, соң булу сәбәпле, анда да бармады.

Каяндыр Миләүшә белән Вилдан килеп чыктылар.

— Кайчандыр монда кызлар күлләре, әнә тегендәрәк Бакалтай булган,— диде Вилдан.— Бу тирәләр бит утын оясы. Каравылчылар янына Тукай килә торган булган... Бер кыз белән ул шунда күз бәйләш уйнаган...

— Абау, син дә уйнамакчы иденме? Кара, нәрсә турында хыяллана бит, Гәүһәр апа?

— Хыялланыр чагы,— диде Гәүһәр, сәгатенә карап алып.— Һай, соң икән инде. Унике тула. Әллә кереп ятабызмы?

Алар пароходка керделәр. Якты утлары кабынып торган палубадан бер әйләнделәр дә Гәүһәр үз каютасының ишеген ачты. Ул бер кешелек каютада бара иде.

Икенче көнне, йокыдан уянганда, Гәүһәр инде шактый тынычланган иде. Әле бик иртә булса да, киенеп, палубага чыкты, буп-буш мәйданда арлы-бирле әйләнә башлады. Кешенең җаны гаҗәп икән: бер ачыла, бер йомыла. Кичә аның күзенә бернәрсә күренмәгән иде, бүген, күр, тирә-як нинди якты, һәр тарафта кабатланмас матурлык, мәһабәтлек. Әле карыйсың, томанлы киңлек, әле су эчендәге агачлар, куаклар күренә, күтәрелеп барган кояш турысына киек үрдәкләр очып килеп төшәләр. Әнә пароход тирәсендә акчарлаклар ялкау гына очалар. Пароход кузгаткан дулкыннар арасыннан балык эзлиләр булса кирәк. Менә берсе суга омтылды, һавага күтәрелде, томшыгында ак балык ялтырады.

Ял итәргә кушылган яр буйлары әкрен генә артка шуалар, текә ярларда кайчак мәһабәт имән яки нарат күренә. Ул пароходны каршы алып озатып кала. Су өсте тип-тигез, шоп-шома. Кайдадыр еректан якынлашып килгән «метеор»ныңмы, «ракета»ныңмы тавышы ишетелә, ул узып киткәч, бераздан үзйөрешле баржа тавышы су буйларын яңгырата. Җәй көне Идел бервакытта да озакка тынмый. Ул гаҗәп бер тормыш белән яши...

Гәүһәр Казаннан еракта уянгач, әлеге куркыныч юклыгын тоеп, гүя бөтенләй үзгәрде, хәрәкәтләрендәге авырлык гүя эрегәндәй булды. Дөрес, тирәннән күзәтә белүче кеше күп нәрсәне әле сизәр иде, эченә йоткан кайгы бетте, югалды дигән сүз түгел, әмма шушы мизгелдә ул бөтенләй юк кебек, телисең икән, хәтта дөньяны яңгыратып җырла! Кызык икән, матурлык эзләп без кая гына бармыйбыз, баксаң, ул матурлык дигәнебез күршедә генә икән, әллә ни озак эзлисе дә юк, каюта ишеген ачып чыктың исә, ул сиңа бөтен зиннәтләре белән ялтырый, җанынны бизи. Бу хәзер югала, хәзер бар була торган бер минутлык матурлык та түгел, бу озак вакытлы, дәвамлы матурлык. Күңелдә бик ягымлы музыка уйнап тора кебек, каяндыр татарча җыр ишетелә, талгын гына искән җил яр буйларыннан төрле чәчәкләрнең хуш исләрен алып килә кебек, бер-берсен алмаштырып торган төрле бизәкләр күзне иркәли. Күр инде ул ярларны, тонык су буйларын, пароход-баржаларны, авыл-шәһәрләрне, эреле-ваклы пристаньнарны, коштай җиңел көймәләрне, зәңгәр күктәге чынаяктай ак болытларны... Валлаһи, мольбертыңны алып, бертуктаусыз рәсем яса. Гәүһәр рәсемнәр дә ясады. Тик ул, кешеләрне борчымас өчен, иң өскә менеп утырды. Монда төшке ашка кадәр беркем дә булмый. Гәүһәр күп вакытта карта, домино да уйнамый, музыка да тыңламый, җырламый да, сөйләшми дә. Кайдадыр берүзе посып табигатьне күзәтә. Болай табигать белән икәүдән-икәү калганы, серләшкәне юк иде әле аның, үзен бик бәхетле итеп сизде. Идел буе шәһәрләренә якынлашканда ул гүя яңадан туа. Аның бит бу шәһәрләрдә гомердә булганы юк, бар да яңа, үзенчә. Дөрес, аларда иске Иделдән нәрсәдер сакланган, хәтта урамнарында, өйләрендә дә шул сизелә, шуның белән бергә анда яңа Идел дә бар. Гүя шәһәрдән шәһәргә күченгән саен Иделне тирәнрәк хис итәсең, ул сиңа нииндидер икенче бер ягы белән ачыла, гүя син әле минем менә бу ягымны күрмәдең, минем бу ягым да бар бит, дия иде. Идел буе шәһәрләренең урамнарында йөрү, аларның берсеннән-берсе матур һәйкәлләрен күрү, музейларында, бакчаларында булу, архитектура үрнәкләрен карау, кибетләренә кереп-чыгулар, сувенирлар, китаплар сатып алу, төрле тарихи урыннарда йөрү сине, кеше буларак, үстерә, баета, канатландыра. Ульяновскида яшь Володяның торган, укыган җирләрен карап йөрү, Куйбышевта Чапаев һәйкәлен, Саратовта Чернышевский йортын, Волгоградта ил батырлыгын күрү, Мамай курганында илне яклаучыларның һәйкәлләре белән янәшә тору, Идел гэсының зур залларында йөрү — Гәүһәргә гүя моңарчы билгеле булмаган яшәү мәгънәсен ачты. Карасана, без нинди изге җирдә яшибез икән! Шуларның барысы өстенә бу Идел буе шәһәрләрендә никадәр картина галереялары! Кайбер шәһәрләрдә, бик азга булса да, Гәүһәр анда керергә дә вакыт тапты, андагы бүтән җирдә һич кабатланмас җәүһәрләрне үз күзе белән күрде. Аның хәтере яхшы иде, аннары мөмкин булган хәтле яза да барды. Соңыннан, пароходка кайтып, шул язуларны кабат укыганда гүя андагы матурлыкны икенче тапкыр кичерде. Гәүһәрнең гади, телгә алып сөйләрлеге дә булмаган тормышы гүя бик мәгънәле, бик зур булып китте, үз кайгыңа бикләнү, башыңны иеп йөрү, дөньяны үзең яшәгән почмак белән генә чикләнә дип фараз итү — нинди мәгънәсезлек икән, бөек кеше исеменә табигать тарафыннан җибәрелә торган зур мохитны үз кулың белән җимерү, тарайту икән бу! Юк, кеше киң сахрага чыксын, дөньяның искиткеч матурлыгын үзе күрсен, үзе татысын, үзен азат итеп, хөр итеп сизсен. Шуның өчен туган бит ул!

Вакыт инде соң, Гәүһәрнең күзенә йокы керми. Ул урыныннан тора, киенеп, палубага чыга. Буш, салкынча, халык юк, барысы да йокларга ятканнар инде. Гәүһәр, аяк очларына гына басып, култыксага килеп таяна. Су өсте кап-кара, кайдадыр чулт-чулт иткән тавышлар ишетелә. Кинәт яп-якты булып китә, капитан каршы килүче теплоходны тәбрик-

ли. Теге дә сәлам бирә. Аннары тагын барысы да куе караңгылыкка чума.

Миләүшәләр аерым каютада баралар. Бу аларның туй сәяхәтләре. Гәүһәрнең артык тагылмавына алар күңелләреннән шат бугай. Ни әйтсәң дә, аларның икәү генә сөйләшәсе сүзләре күп бит.

Бүген пароход көне буе диярлек туктамаячак. Ял итүчеләр, иртәнге ашны ашагач ук, кайсылары кызынырга менеп киттеләр, кайсылары, күләгәле якка утырып, домино сугарга керештеләр, карчыклар күбрәк карта уйныйлар. Гәүһәрне Миләүшә кызынырга алып менде. Вилдан алдан урындыклар алып куйган иде.

Миләүшә Гәүһәргә таба борылып:

— Я, син канәгатьме? — дип сорады.— Син нигәдер күбрәк ялгыз булырга тырышасың.

— Идел уйландыра торган урын бит. Уйланганда ялгыз буласың килә,— диде Гәүһәр, елмаеп.— Гомумән, мин бик канәгать. Рухи үстем, баедым шикелле.

— Мин үпкәләдеңме әллә дип торам тагы.

— Монда кемгә үпкәлисең.

— Алайса, ярый. Югыйсә, без әллә нәрсәләр уйлап бетәбез.

— Зинһар, борчылмагыз.

— Их, нинди кыздыра... Яшел Ярга кайтып төшкәнче, ком гарәпләре булып бетәбез инде.

Миләүшәнең көлүе, җырлавы бик озак яңгырап торды.



## 4

Иделнең бөеклеген Иделгә чыксаң гына күрәсең. Барасың, барасың, көн китәсең, төн китәсең, тоташ бер атна барасың, һаман юлыңның очы-кыры юк. Әле генә анда бер күренеш иде, син аңа сокланып туймадың, инде икенче, элеккесеннән дә матуррак манзара ачыла. Син ниндидер мәңгелек тынлыкка чумган текә ярларга карыйсың, кемнеңдер ялгыз тәресе белән ялгыз кабере артта кала. Теләсәң, тыңла, пароход дикторы аның тарихын сөйли, тыңларга теләмәсәң яки кайчан да булса бер ишеткән булсаң, тагын яр буйларына карап бар. Пароход зур пристаньнарга гына туктый, болай ул һәрвакыт юлда. Ничектер суга сыенып утырган шәһәрләр, авыллар күренә, анда ниндидер төзелешләр, аннары кеше хезмәтенең аерўча бөеклеген һәм матурлыгын күрсәткән шлюзлар бер-берсен алмаштыралар. Каршыга уннарча пароход, теплоходлар, үзйөрешле баржалар, буксирлар очрый.

Астраханьга таба якынлашуга, көньяк сулышы бигрәк тә ачык сизелә башлады, иртә-кичләрен рәхәтрәк, чөнки көндез чамасыз кояш кыздыра. Кояшта кызынучылар туйдылар инде, каралып чыктылар, хәзер күбрәк күләгәле урыннар эзлиләр. Пристаньнарга якынлашу белән, баян күтәреп культурник чыга. Идел өстендә ял итүчеләрнең үз җырлары яңгырый.

Пароход Астраханьга төш вакытында якынлашты. Миләүшә татарча яңа җыр башлады. Үзе гел күзләрен уйнатып, каш сикертеп, Гәүһәргә карый:

Кунак кызы килгән Иделгә,
Мәхәббәтен сагынып күрергә,
Исме аның Карагөл.
Карагөл,
Ал гөлләрдән,
Гөл гөлләрдән
Һич кенә дә,
Һич кенә дә
Ким түгел.

Ашкындыра Идел алкыны,
Уйнап тора йөрәк ялкыны,
Күзен кыса Карагөл.
Карагөл,
Күрсәң иде,
Сизсәң иде,
Ир егеттән
Һич кенә дә
Ким түгел.
Бергә чаклар нигә тиз үтә,
Аерылышу нигә тиз җитә,
Башың имә, Карагөл.
Карагөл,
Моңсуланма,
Сагышланма,
Һич шикләнмә,
Һич боекма,
Яшь күңел!

Пароход ярга ике-өч метр каларак нигәдер туктады, җырчылар шуннан файдаланып җырны дәвам иттеләр. Дәртле моң, яшәү шатлыгы, саф мәхәббәт тантанасы аңа кабатланмас бер төс бирде. Җырлаучылар күп түгел, биш-алты гына кеше, күпләр әле аны белмиләр. Ләкин Миләүшәнең тавышы аеруча чыңлый. Җыр, күрәсең, аның күңеленә хуш килгән. Гәүһәргә карап-карап алулары үзенең рухи халәтен каплау өчен генә булган, күрәсең. Гәүһәр читкәрәк чигенгәч, ул аңа карамыйча да бик матур җырлый башлады...

Астраханьда пароход бер тәүлек торырга тиеш. Ял итүчеләрнең күбесе хәзер «татар-базарга», ә кич, күмәк төстә, Астраханьның пальмалар үсеп торган атаклы кинотеатрына барырга булдылар.

Яр буеннан ук башланган гүзәл бакчага кызыксынып карый-карый бардылар. Агачлар ничектер янтая төшеп үскән. Нәкъ исерекләр кебек. Монда су күп икән, бакчада күлдәвекләр, шунда ук аккошлар да йөзеп йөри. Мороженое павильоннарында халык тыгылган, өстәлләр барысы да тулы. Каршыда, иске шәһәрне каплап, менә дигән яңа таш пулатлар, сулдарак кремльнең бер почмагы күренә. Базарга уң якка барырга кирәк икән, ерак түгел, диделәр.

Базарны әйләнеп чыктылар, әмма каты-коты вобладан башка берни дә күрмәделәр.

— Шулмыни инде атаклы татар-базар? — диде чиксез аптырап Миләүшә.— Безнең Яшел Яр базары моннан бер дә ким түгел.

Өсте ябулы прилавкалар янында ике-өч кеше сөйләшеп тора иде. Берсе Миләүшәнең ачынып әйткән сүзен ишетте, ахрысы.

— Кызым, сез Казаннанмы? — дип сорады.

— Шулайрак, абый кеше. Макталган базарыгызны әйтер идем...

— Базары аның базар инде. Базарга яхшы әйбер чыкмый. Сезгә ни кирәк иде?

— Вобла белән икра алырбыз дигән идек. Астраханьнан кайткач, күрсәтергә кирәк ләбаса.

...Кирәкләрен алгач, алар, күпер аркылы чыгып, яңадан порт каршындагы бакчага керделәр. Гәүһәр каядыр бакча түренә карап атлады.

— Ни бар анда, ни карыйсың? — диде Миләүшә.

— Сөргенгә озатылган Чернышевский кайдадыр шул бакчалар тирәсендә йөргән. Соңрак Тукай белән Сәгыйть Рәмиев тә шунда булганнар, дип язалар. 1911 елның 6 июнендә шагыйрь «Василий Лапшин» пароходында кайтып китә. Аны якын дуслары, иҗатын ихтирам итүчеләр озата. Алар күп булмый. Пристаньда исә Астрахань татарлары мыж

килә, ләкин яннарында бөек шагыйрь басып торганын белмиләр. Белсәләр дә исләре китмәс иде. Миллионер түгел ич ул!

Миләүшә белән Вилдан Гәүһәрнең сүзләрен кызыксынып тыңладылар.

Пароходта Гәүһәр әйберләрен куеп, киемнәрен алмаштырырга ашыкты. Ул шабыр тиргә баткан иде. Каюта тәрәзәсен ачып, рәшәткәне төшерде дә, тиз генә юынып алды, аннары чәчен тарады, үтүкләнгән җинел маркезит күлмәген киде. Ул арада ишек кактылар. Миләүшә иде бу.

— Булдыгызмы? Әйдәгез, сыйланабыз.

— Кулыңда нәрсә, Миләүшә?

— Күрдегезмени?

— Хат? Кемнән?

— Кемнән түгел, кемгә диген, мә! — Миләүшә хатны сузды да, озак юанма дип, китеп тә барды. Кире адресы юк, кулы да таныш түгел. Почта штемпеле Яшел Ярныкы. «Әллә бер-бер бәхетсезлекме? Хатны Зәбирә түти яздырганмы?»

Гәүһәр тиз генә конвертны ачты һәм, хатны укудан элек, имзасына карады. Хат Әгъзәм Ибраһимовтан икән. Бер секундта кояшлы Астрахань югалды, Гәүһәр күңеле белән Яшел Ярга очты.

Тагын ишек кактылар.

— Әйдәгез инде, Гәүһәр апа. Хатыгызны соңыннан укырсыз.

— Хәзер, Миләүшә, хәзер.

Гәүһәр хатны сумкасына салды да каютадан чыкты, ишекне бикләде. Миләүшәләр шул ук класста, пароход борынындагы ял бүлмәсеннән өченче каютада иделәр.

— Әйдүк, әйдүк, Гәүһәр апа. Менә монда утырыгыз. Вилдан, газеталарыңны ташла. Рәхим итегез. Кайнаган салкын су белән ике тапкыр юдым. Җиләге бик шәп. Хат кемнән, Гәүһәр апа? — дип, белмәмешкә салынып сорады Миләүшә.

— Әгъзәм язган. Шаккаттым.

— Нәрсәсенә? — Миләүшә белән Вилдан күзгә-күз карашып алдылар, чак кына көлемсерәделәр.

— Мин аңа хат яз дигән булсам, адрес калдырган булсам...

— И, Гәүһәр апа, анысына исегез китмәсен. Кирәк булгач, табалар инде. Яшел Ярда барысы да исән-саулармы?

— Мә, укы.

Башта Миләүшә, аннары Вилдан хатны укып чыктылар. Аннары җиләк ашап, урамга чыктылар, яр буйлап киттеләр, кремль буена борылдылар. Стенаның буеннан-буена күз явын алырлык кызыл чәчәкләр утыртканнар. Уртадарак Ленин һәйкәле, кремль эчендә биек чиркәүләрнең исәпсез манаралары.

Миләүшә сәгатенә карап алды.

— Киногa кичегә язганбыз ич. Әнә безнекеләр баралар, әйдәгез тизрәк.

Бер төркем ял итүчеләр киногa баралар иде. Миләүшәләр аларга кушылдылар. Мәңгелек ут янып торган һәйкәлләре булган бакча яныннан уздылар, бераздан тагын бер бакча янына килеп чыктылар. Бакча түрендә биек постаментта Сергей Миронович Киров басып тора. Моннан инде кино да ерак түгел. Кино бинасының тыштан әллә ни үзенчәлеге юк шикелле, ә эченә керсәң, фойеда юан-юан пальмалар үсеп тора!

— Әнекәем! — диде Миләүшә, гаҗәпләнеп,— менә кайда ул могҗиза. Пальмалары кисмәкләрдә түгел, идәндә үсә.

Ял итүчеләр төркем-төркем булып пальмалар тирәсендә әйләнәләр. Язуларын укыйлар, башларын селкәләр. Элек пароход радиосыннан

сөйләгәндә, ничектер кечкенә генә пальмалар күз алдына килгән иде. Ә болар — һай-һай!

Пальмаларны карап бетерергә генә өлгергәннәр иде, звонок булды.

## 5

Яшел Ярга кайтканнан соң, Гәүһәрнең беренче эше лагерьга бару иде. Ул инде лагерьдагы хәлләр турында да, Зилә, Акназарлар турында да барысын да белә, аңа инде бәйнә-бәйнә сөйләгәннәр иде. Шулай да үзең барып күңелне тынычландырмасаң булмый икән. Балаларны үз күзе белән күрсә, аңа шул җитә. Бибинур апа да шулай дигән иде. Гәүһәр кайтканның икенчеме, өченчеме көнендә ул, кызы Гөлназ белән, ялга китеп барды. Ул арада мәктәпкә күз-колак булу өчен кеше билгеләнгән иде, Гәүһәргә дә Бибинур йомыш тапты. Мәктәп бит зур, ремонт эшләре дә, башка төр эшләр дә җитәрлек анда.

Кич белән, күңелен тынычландырып, лагерьдан кайтканда, Гәүһәр тагын бер нәрсәгә игътибар итте: ул Идел буе турында күпме сөйләмәсен, ул хикәя никадәр генә кызыклы булмасын, шулай да Идел моннан шактый ерак, шушы ераклык бөтенесенә үзенең төсен йоктырган. «Анда әллә нәрсәләр булыр, тик бездә генә булмас», дип әйтәләр иде кебек балаларның күз карашлары. Моннан Гәүһәр бер нәтиҗә ясады: «Бөтен нәрсә турында сөйлә, ләкин үз тирәңне онытма. Үз тирәңә бәйләсәң, чын ераклар да ерак булмый». Шуннан инде Яшьлек шәһәренә барып кайту теләге анын күңелендә ныгыганнан-ныгый барды. Республика газета-журналларында Яшьлек шәһәре турында көн саен диярлек язалар. Аннары моннан ул ерак та түгел, йомшак автобуска җәелеп утыруың була, барып та җитәсең.

Бөркөнне сөйләшеп утырганда Гәүһәр Әгъзәм Ибраһимовка да шуларны әйтте. Әгъзәмгә шул җитә калды, ул Гәүһәрне Яшьлек шәһәрен карап кайтырга чакыра башлады.

— Күрү ишетү түгел, — диде ул, беркадәр хыялланып.— Хәзер, Идел буйларында булып кайтканнан соң, Яшьлек шәһәренә бармау сезгә килешми дә.

— Шулайдыр,— диде көлемсерәп Гәүһәр,— нәкъ минем күңелемдәгене алып әйтәсез.

— Мин бик шат,— диде Әгъзәм.— Һәрхәлдә, үкенмәячәксез, Гәүһәр ханым.

Әгъзәмнең әти-әниләре Яшьлек шәһәрендә торалар икән. Әтисе, сугыштан кайткач, башта Лениногорск шәһәрен салышкан, аннары бу тирәләрдә эшләр башлангач, хатынын, әтисе Хәйбүш картны һәм төпчек кызы Сажидәне ияртеп Яшьлек шәһәренә килгән. Ул чакта алар күрше авылда бер җимерек мунчада торганнар, чөнки Яшьлек шәһәрендә бер таш бина да булмаган, әле халык кыш көннәрендә дә палаткаларда яшәгән. Әгъзәмнең абыйлары берсе Лениногорскида нефтьтә калган, икенчесе Бөгелмәдә шулай ук нефть эшендә икән. Әгъзәм, институтны тәмамлагач, үз районы авылларында балалар укыткан. Яшьлек шәһәрендә дә эшләгән...

Гәүһәр боларны өстән генә белә иде. Әгъзәмнең шәхси якларына кагылмады. Аннары аның күңеленә төрле шикле уйлар килә башлады. Җитмәсә, ул арада көннәр бозылып китте. Җомга һәм шимбә көн төш вакытына кадәр диярлек чиләкләп яңгыр яуды. Яңгыр туктагач, кояш чыкты, бөтен тирә-як үзгәреп киткәндәй булды. Шулай да Гәүһәр әле, барыргамы, бармаскамы дип икеләнеп торды. Әмма якшәмбе көн Әгъзәм килгәндә, ул инде барырга дигән ныклы бер карарга килгән иде.

Алар урамга чыкканда, күктә кояш көлә, көн җылы, бер тузан юк. Мондый чакта машинада яшел кыр уртасыннан бару, ара-тирә куе яшел урманнарга килеп керү, аланнарны тутырып үскән төрле-төрле чәчәкләргә күз ташлау гаҗәеп бер рәхәт. Ул да булмый, машина бер уйсулыкка килеп төшә, тәгәрмәчләр астыннан тамчылар чәчрәп кала. Үр буйлап бераз баргач, сихерле урман бетә, янадан иксез-чиксез кыр башлана. Тирбәлеп торган җиңел рәшә эчендә Яшьлек шәһәренең биек таш биналары күренә. Машина якынлашкан саен, бу таш биналар күбәя, биегәя. Әйтүе генә ансат бит: мең, миллион еллар буе бушлап торган Кама ярында тугызар катлы таш пулатлар күтәрелә.

Гәүһәр тәрәзә янына елышты, машина туктаганчы тәрәзәдән күзен алмады. Комбинат моннан күренми, ул алдагы урман эчендә. Халык белән тулы трамвайлар гына шул якка таба китеп югалалар. Машиналар бик күп. Кая карама, биек краннар. Кафелар, кибетләр Яшел Ярда да шактый, монда тагын да күбрәк шикелле. Халык кына ул хәтле күренми. Мондый эссе көндә су буена киткәннәрдер, нишләп шәһәрдә тыгылып торсыннар. Гомумән, монда, шәһәр булса да, ничектер җил уйный кебек, бер яктан иксез-чиксез кыр, урман, икенче яктан киң елга шул сафлык тойгысын тагын да арттыралар.

Гәүһәрләр машинадан төштеләр дә шәһәргә таба юл тоттылар. Әгъзәм туп-туры этиләренә алып кермәкче иде дә, Гәүһәр риза булмады.

— Без кунакка килмәдек, без шәһәр карарга килдек,— диде.

Алар аяклары талганчы Яшьлек шәһәрендә йөрделәр. Кермәгән кибетләре, карамаган биналары калмады. Яңа мәктәпләрендә дә булдылар, балалар бакчаларында да йөрделәр, аннары трамвайга утырып, үзе янә бер шәһәрчек төсен алган комбинатка киттеләр. Урман эченнән ул әллә ни күренмәсә дә, сәгатьләр буе карап йөргәч, аның мәһабәтлеген ачык сизәсең. Ниһаять, су буйларын урап, янадан шәһәргә кайткач, Әгъзәм Гәүһәргә мөрәҗәгать итеп, ярыйсы кыюланып:

— Кунак алып киләсең икән, аның күңелен дә күр, тамагын да онытма, диләр. Инде чама белән сезнең тамагыгыз бик нык ачкан булырга тиеш. Әйдәгез, безнең картларга керик, бик тә шатланырлар,— диде.

— Бәлки, кафега гына кереп...

— Юк, зинһар, картларның хәтерен калдырмагыз. Алар болай да көтә-көтә көтек булганнардыр инде.

— Син хәбәр иттеңмени? Без нинди кунаклар ул хәтле?!

Гәүһәр баягыча кискен сөйләшми, аның каршы торуы бары тик әдәп йөзеннән генә. Күңел тирәнлегендә хәтта кызыксыну да бар.

Әгъзәмнең этиләре мәктәп артында гына, биш катлы таш йортның өченче катында торалар. Әле ерактан ук ишек алдындагы бакчада таякка таянган Хәйбүш бабайны күрделәр. Ул үзе ел саен миңа йөз дә биш яшь дигән була, чынында күпмедер — бер алла белә, әйтүләренә караганда, Хәйбүш яшь чакта авыллары янган, метрика кәгазьләре сакланмаган.

Картның күзләре яхшы күрә әле, ул Әгъзәмне янына килеп җиткәнче үк танып:

— Әгъзәметдин, тамаша, бу син түгелме? Яныңда кемдер — танымыйм,— диде.

— Гәүһәр бу, укытучы була,— диде Әгъзәм, бабасы белән бик җылы күрешкәннән соң.

— Укытучы дисеңме? Ярый, бик ярый. Күрешик, кызым, Гәүһәрме әле исемең?

— Әйе, бабай.

— Борынгыча әйтсәк, мөгаллимә. Мөгаллимәнең, әйтәләр иде: ике ягында ике фәрештә басып тора, кая керсә, шунда бәхет өләшә, дип.

Әйдәгез, өйгә рәхим итегез. Әниегез, күренмиләрме дип, ничә чыгып карады инде.

Карт утырган урыныннан җәһәт кенә торды. Кара, шул ященә хәтле һаман ярдәмчесез йөри. Бу кадәр җиңел сөякле булыр икән! Өченче катка хәтле һичбер тынмыйча күтәрелде.

Өйдәгеләр бабайның кычкырып сөйләшүен ишеткәннәр булса кирәк, ишекне киң ачып каршы алдылар. Исәнлек-саулык сорашулар, күрешүләр барысы бергә буталып китте. Башына кара түбәтәй кигән, кара мыеклы, Әгъзәмнең бераз базыграк буйлы этисе гөр килеп йөри, кунакларны кая утыртырга белми, әнисе — ак яулыклы, озын буйлы, ябык хатын — бигрәк тә ачык күңелле икән. Ул, мәзәк сүзләр әйтеп, табын хәзерләде. Гәүһәр белән сөйләште, улының озак килмәве өчен чәнчеп алды. Әгъзәмгә бик ошаган, буй җиткән сеңелесе Җәмилә кухня белән табын арасында очып кына йөрде. Ул быел гына ун классны тәмамлаган. Озакламыйча химия-технология институтына имтиханнар бирергә җыена икән.

Ниһаять, табын янына утырыштылар.

— Ягез, кунаклар, аштан житешегез, суытмагыз. Иртән унда киләсе кешеләр көндез дүрттә килеп җиттеләр. Ул-бу булса, гаеп итмәссез.

— Ашыйсылары килмәгән булса гына аштан гаеп табарлар, килен. Миңа калса, пәрәмәчләрең, сумсаларың, бәлешләрең тамаша килешкән.

— Аш мактарга Хәйбүш бабайны куш инде!

— Юк, кызым Җәмилә, ризык мактаганны ярата. Үзең күпме тырыштың, сөйлимме? Мена тамаша булырсың.

— Кирәкми, бабай, мактамый тор әле. Гәүһәр апа барыбер минем яклы, шулай бит, Гәүһәр апа?

— Җәмилә кемнең кемлеген сизеп алган инде.

— Әйе, кемнең канаты астына сыенырга кирәген белә. Һай, кызым, гомерле булырсың икән.

— Хәйбүш бабайдан уздырам әле,— диде Җәмилә, көлеп.

— Һа, миннән уздыра! Башта син йөз дә биш яшькә җит әле, аннары сөйләшербез, һе-е.

— Син шулай ел саен йөз дә биш дип торсаң, нигә җитмим ди, җитәм!

— Я инде, Гәүһәр, безнең сүзгә колак салып, ашамый утырма әле. Без көн саен шулай. Аш житмәгән чакта да шулай туена идек, хәзер, биргәненә шөкер, аш жаның күпме теләсә, шулчаклы.

— Анысын, килен, дөрес әйтәсең. Без төрле чагын күреп гомер сөрдек. Түлке, җәмәгать, начарны сөйлисе килми. Аның нәрсәсен искә аласың. Гомернең яхшысы да житәрлек бит. Бер заман, минем егет чак, дала ягында яшим. Трактирга керсәм, карыйм, өстәлдә калач, мена шуның шае, күпереп тора, ике чәйнек чәй. Ул чактагы чәйнекләрдән корсагың ярылганчы эчсәң дә суы бетми иде. Карыйм, өстәл кырыенда минем таныш Сабили да утыра. «Хәйбүш, давай, безнең белән», ди. Карыйм, боларның чәйнекләреннән бу чыкмый, аракы значетса. Мать якасы, тамаша! Мин — мөселман, аракы белән дуслык юк. Сизәм, не ладно. Туда-сюда сүз китте. Сабили дус миңа бәйләнә башлады. Иптәшләре кыздырып тора. Но минем яшь чак, гайрәтле чак. Кулга, бияләй эчендә, чылбырлы пәке ураган. Киерелеп торып тегеңә кундырган идем, Сабили дус урындыкка лып утырды. Карыйм, эш начар. Сабили дусның тәмам йөзе үзгәрде. Монда Сабилинең эшнәләре кычкырыша башлады: «Убил, басурман!» диләр. Өстемә стена булып киләләр. Ничек өйдән чыкканмын да ничек чөйдән толыпны алганмын — белмим. Атым ут иде. Чанага сикереп менеп, «Әй-й-й!» дип бер кычкырган идем, тамаша, чананың табаннары жиргә әллә

тиде, әллә юк. Урамда инде син күр дә мин күр. Күпмедер баргач кына аңыма килдем. Карыйм, кыр уртасы. Каршыда эрәмәлек. Ат колакларын торгызган, пошкыра. Әттә генәсе! Бер көтү бүре килә! Уйлап торырга вакыт юк. Атка бер кычкырган идем,— пошел! Бүреләр дә калмый. Исемә килде: салам астында минем кистән бар бит. Тартып алдым да чананы куып житә язган бүрегә кайрылып торып берне бирдем. Карыйм, баштүбән атылып китте бу. Икенче селтәнгән идем, икенче бүре дә йөзтүбән китте... Башкалары арткарак калганнар иде, егылып җан биргән бүреләрне өзгәли башладылар. Икенче тапкыр тагын шул трактирга керәм. Карыйм, тагын шул Сабили дус утыра. Түлке бу юлы исерек түгел, чәйнегеннән бу чыга. «Давай, князь, минем белән чәй эчәргә утыр, ди. Мин, ди, синең белән килешергә булдым, ди. Синдә көч бар, бер сугуда ике кабырганы сындыргансың. Билгеле, парин, кызган чакта эләккән булсаң, сиңа да тигән булыр иде. Русның бер яхшы мәкале бар: кто старое помянет, тому глаз вон, ди. Күптән сатулашып йөргән кара айгырны сиңа сатарга булдым, ди...

— Булды инде, эткәй, кунакны ялыктырып бетерерсең. Синең Сабили дусларың, тамашаларың бетәсе түгел.

— Бетмәс тә, килен. Мин бит йөз яшәгән кеше. Менә Гәүһәр кызым бик олылап тыңлап тора әле. Мөгаллимәнең ике ягында ике фәрештә дип тикмәгә генә әйтмәгәннәр шул.

Аштан соң Җәмилә Гәүһәрне үз бүлмәсенә алып керде. Кызлар бүлмәсе һәркайда да бер икән: якты, чиста, бөтен җирдә тәртип. Бүлмәнең ике тәрәзәсе бар, берсеннән ишек алдындагы бакча, икенчесеннән балалар бакчасы күренә. Монда урамнар, машиналар юк, барысы да шәһәрдән тышта. Шәһәрчек үзе тоташ бакча эчендә. Хәзер әле агачлар бик кue түгел, ә берничә елдан танымассың да.

— Мин укып бетергәнче, Гәүһәр апа, бу шәһәр гаҗәп булачак. Хәзер үк аны шәһәр-бакча диләр. Кайберәүләр аны киләчәк шәһәре дә, диләр. Монда хыял уйный. Әгәр имтиханнарны тапшыра алмасам, бер дә кайгырмыйм, Яшьлек шәһәренә кайтам да эшкә керәм.

Җәмилә үзенең китапларын, аннары киемнәрен күрсәтте. Билгеле, яңа гына унны тәмамлаган кызның байлыгы искитәрлек түгел. Унынчы классны бетерүгә Әгъзәм абыйсы бик матур күлмәк белән биек үкчәле туфли алып биргән. Әгәр институтка керә алса, абыйсы кышкы пальто да алып бирергә вәгъдә иткән икән.

Гәүһәр сәгатенә карап алды. Кайтырга вакыт иде.

## 6

Кешенең тормышы һәр җирдә мул ага ала, моның өчен бары тик эчке һәм тышкы дөньяның бер булып сулавы гына кирәк. Әгәр шул берлек булса, син үзеңне гаҗәеп көчле итеп сизәсең. Эшнең зурысы да, кечкенәсе дә — барысы да сиңа канәгатьлек бирә. Яшәү дә ничектер матур, күңелле булып китә.

Яшьлек шәһәреннән кайткач, Гәүһәр үзен шулай хис итте. Тормышның Яшел Ярда да матур, мәгънәле булуына исе китте. Бар дөньядан качып, Кама буена сыенгач, ул яшәү инде ана бервакытта да әлеккечә елмаймас дип уйлаган иде. Күр, ничек алданган!

Бибинур апага биргән вәгъдәсе буенча, Гәүһәр көн саен диярлек мәктәпкә йөрде, ремонт эшләрен күзәтте. Житмәсә, мәктәпнең завхозы кинәт авырып китеп, бөтен эш туктала язган иде. Гәүһәр завхоз терелгәнче ремонт эшләренә чумды. Аның булышуы бик ярап куйды, завхоз, карт кына бер абзый, хәтта дулкынланып китеп:

— Гәүһәр сеңел, мондый чакта арага керүегез өчен бик рәхмәт,— диде һәм көн саен нәрсәләр эшләргә кирәген сөйләде. Гәүһәр бер дә

иренмәде, кушканны гына түгел, үзеннән дә күп нәрсә башкарды. Шулай да уйларына чумарга да вакыт таба иде. Хәзергә хәтле аның Әгъзәмгә булган мөнәсәбәте ачык түгел: Әгъзәм үзе ошый, әти-әниләре дә начар кешеләр түгел, тик Гәүһәрнең Сылу урынына утырасы килми, курка да иде. Әнә нинди булган бит ул, әнә ничек аны ятраткан-нар! Хәйбүш бабай булып Хәйбүш бабай да теленнән төшерми. Баксаң, йөз яшәр картның теленнән төшмәс өчен күп нәрсә кирәк бит. Тормышта бер ялтырап киткән кешене генә, ай-һай, карт шулай мактап телгә алырмы икән?

Соңгы вакытларда Гәүһәр Әгъзәмне югалтудан да курка башлады. Дөрес, бар кешегә күрсәтеп, якын итәсе дә килми, шул ук вакытта каядыр читкә этәрүдән дә саклана, томан эчендәге бер якты йолдыз кебек җемелдәп торсын иде! Әнә бит сәяхәттән кайткач, көтмәгәндә, уйламаганда Гәүһәрнең өендә каршы алуы нинди күңелле булды. Ярый, үзе әйтмешли, очраклы гына, узып барышлый гына кергән булсын, ди. Ләкин хатын-кызны болай алдый алмассың, аннары Зәбирә түти дә бик ачык әйтеп салды бит, көн саен керә, барлык открыткаларны укый иде, диде. Тикмәгә генә көн саен кермиләр инде, сагынып көтелгән путевкалардан ихтыяри баш тартуы шулай ук очраклы хәл түгел инде. Гәүһәр боларны күрмәмешкә салынса да, күрмәде түгел, аның әле андый юләр булганы юк. Яшьлек шәһәрендә Әгъзәмнең әти-әниләрен барып күрүләре шулай ук бушка түгел, әлбәттә...

Хәер, болар нинди дер ныклы аңга нигезләнгән, сулышы саен үзеңә хисап бирерлек уйлар түгел, болар кайдадыр аңнан тыш бара кебек, бер дә көтмәгәндә кузгалалар да сискәндереп җибәрәләр. Кайчак Гәүһәр тынычланып та куя. Җәгъфәргә хәтле аның өчен дөньяда егетләр әллә бар, әллә юк иде. Җәгъфәрне ул ничектер берьюлы сөйде, аның янында Гәүһәргә дә бик рәхәт иде. Шушы рәхәтлек дөньясында аның биш-алты елы үтте дә китте. Хәер, авыр, газаплы көннәре дә булгандыр, исәпләсәң, ике меңнән артык көн бит! Ләкин үткән дә киткән инде, Җәгъфәр үзенең тәхетеннән төшкән, гади бер җан иясе булып калган. Хәзер Гәүһәр моңа бөртек тә борчылмый. Тик шул хәлнең яңадан кабатлануын гына Гәүһәр җаны-тәне белән теләми. Бер тапкыр кеше әле иң зур гаделсезлеккә дә түзә, ә инде ул хәл кабатлана башласа, син яңадан якты хыялларыңның челпәрәмә килеп ватылуын күрсәң, җитмәсә, шуның хаксызлыгына ышансаң, түзүе бик чамалы. Һәрхәлдә, аңлы рәвештә моны кабат кичерергә омтылмыйсың. Юк, вакыт үз эшен башта эшләсен, аннан соң да Гәүһәр үз адымын атларга өлгерер.

Гәүһәр, үзен борчыган уйларны никадәр генә яшерергә тырышмасын, ахыр килеп үз алдында танырга мәҗбүр булды, аның тормышында да күп язылган «өч почмак» бар: Җәгъфәр, Гәүһәр, Әгъзәм. Сәерме? Беркадәр шулайрак. Алчыннарны, Билалларны ул «почмакларга» исәпләми, чөнки үзе аларга битараф иде, аларны Җәгъфәр белән берничек тә чагыштырып карамады, артыклыкларын да, кимлекләрен дә уйламады, Әгъзәм турыдан-туры үзен Җәгъфәр белән чагыштыруны сорый: кай ягы артык та, кай ягы ким? Билгеле, сүз тышкы сыйфатлар турында бармый, шуңа күрә мәсьәлә шактый читен. Иң мөһиме шунда, боларның барысын да Гәүһәр берүзе хәл итәргә тиеш, чөнки башкалар моңа катнаша алмый.

Августның уннарында институттан Гәүһәргә хат килеп төште, уку мәсьәләсен хәл итәр өчен институтка кереп чыгуын үтенгәннәр иде. Шул ук көнне Галимҗан абыйдан да хат алды. Аның хаты, билгеле, рәсми хат түгел, бик җылы язылган, кешелекле. Июльдә күрә алмавы өчен бик үкенгән. Күчтәнәчләр өчен күп итеп рәхмәт әйткән. Бу юлы килсәң, туйганчы бер сөйләшер идек. Кызлар да озакламый кайтачаклар, тик алар дачага китәрләр инде. Аларга бит дөнья түгәрәк, дигән.

Ремонт эшләре бетмәгән булса да, завхоз терелеп аякка баскан иде. Гәүһәр аңа кинәшкә килгәч, ул тәмам эреп төште:

— Бар, Гәүһәр сеңел, бар. Монда мин үзем карармын, хәзер арулана бугай. Кайткач, тагын бераз булышырсың,— диде.

Әгъзәмгә әйтергә теләмәгән иде. Шулай да иртәгә китәсе көнне аңа да әйтте. Әгъзәм, хәерле юл, диде. Бер ел калгач, укуны бүләләр димени?! Китапларның кайберләрен аннан да караштыр, монда да табарга мөмкин булыр, диде. Үткән ел Гәүһәр Яшел Яр китапханәләренә әллә ни йөрмәгән иде. Анда шактый нәрсә бар икән. Аннары Әгъзәмнең үзендә дә, шулай ук Бибинур апа белән башка укытучыларда да әдәбият җитәрлек. Хәзер бит кешеләр шәһәрдән күбрәк китап ташыйлар.

Билгеле, Әгъзәм башкарак сүзләр белән әйтсә дә, Гәүһәр Казанга бармый калмас иде, әмма теләкләрнең туры килүе нинди яхшы икән!

Гәүһәр, кулына кечкенә чемодан алып, Зәбирә түти белән саубуллашты да юлга чыкты. Әгъзәм озата барыйм дисә дә, Гәүһәр каршы килде. Нигә мәшәкатьләнергә?

Автобус асфальт юлдан выжылдап кына бара. Басуларда игеннәр инде өлгергән, комбайннар эшли, каршыга ашлык төялгән автомашиналар очрый. Халыкның күнеле күр, быел уңыш яхшы. Казанда чакта Гәүһәр моңа игътибар итми торган иде, хәзер ачык күрә: иген мул булса, салкын, озын кыш та куркытмый, аңа ничек әзерләнергә кирәкен беләләр.

Һава юлларының рәхәтлеге шунда, син яхшылап утырырга өлгермисең, барып та житәсең. Чын, әле кайчан гына самолет җирдән күтәрелә иде, инде күр, Казанга да якынлаша.

...Галимҗан абыйлар Гәүһәрне бөтен семьялары белән каршы алдылар. Кызлар чирәм җирләрдән кайтканнар. Аларның кайтуына бигрәк тә Гөлназ шатланган, Бибинур апа кичә генә пароход белән Яшел Ярга кайтып киткән. Кызлар бүген иртәдән бирле Идел буенда, хәзер тагы чыгып китәргә торалар. Гәүһәрнең кызларны шактый вакыт күргәне юк иде,— буйга үскәннәр, матурланганнар, тик бераз ябыга гына төшкәннәр кебек. Гөлназны да ул җәй буе диярлек күрмәде. Буйга җиткән кыз булган. Житмәсә, яңа күлмәк алганнар үзенә, шундый килешә, толымнары озын, маңгай тирәсендәге чәчен кискән. Ул Гәүһәр апасыннан Яшел Яр турында да сорашып өлгерде. Гәүһәр аның кечкенә генә хәйләсен сизде: ни әйтсәң дә, Гөлназ үзенең Яшел Яры, мәһабәт Камасы белән әз генә мактана һәм горурлана. Гәүһәр, чак кына елмаеп, аңа шул ук рухта җавап бирде. Башкалар аларның әзрәк арттыруларын сизделәрме, юкмы, Галимҗан абыйның кызлары хәтта әйтеп куйдылар: быел булмаса да, киләсе елга Яшел Ярга бер барып карыйбыз әле, диделәр.

— Җәй көне килегез. Җәй көне Яшел Яр бик матур, әйе бит, Гәүһәр апа?

Бик күңелле итеп бергәләп чәй эчтеләр, аннары кызлар, без озакламыйча кайтырбыз, дип, чыгып киттеләр. Гәүһәр дә институтка җыена башлады, кайтышлый китап кибетләренә дә кагылырга булды.

Гәүһәрнең институтка килүе бик уңышлы булды. Ике сәгать эчендә күрәсе кешеләрнең барысын да күреп, сөйләшәсе сүзләрен сөйләшеп, программалар белән танышып чыкты. Бер кочак язу, программа, исемлекләр тоттырдылар. Таныш укытучыларыннан да ике-өч кешене очратты. Сөйләштеләр. Укытучылар мәктәп турында, укыту эшләренең торышы турында сораштылар, балалар белән бик кызыксындылар. Берсе Бибинурны бик яхшы белә икән, бергә укыганнар. Әгъзәм Ибраһимовны да беләләр булып чыкты. Ул шул ук институтны тәмамлаган. Әле дә киңәшмәләргә килгән саен институтка кагылмыйча китми икән. Аның шәхси тормышын беләләр идеме, юкмы, ул турыда нигәдер

берни әйтмәделәр, Гәүһәр дә сөйләмәде. Гомумән, ул Әгъзәм хакында күп сөйләшмәде, ялгыш кына үзенең мөнәсәбәтен сиздерүдән курыкты.

Институттан чыккач, китап кибетенә керде. Программада күрсәтелгән берничә китап бар иде, Гәүһәр аларны шатланып алды. Калганнары бар да элек чыккан китаплар, аларны китапханәләрдән генә табарга мөмкин, диделәр. Русча китаплар шактый. Гәүһәр аларны да сайлап алды. Бу кибеттә язучылар да шактый еш күренә дигәннәр иде, бу юлы берәү дә юк, җәй көне, ялда булсалар кирәк, диде китап сатучы. Шуннан соң Гәүһәр ашыкмый гына Бауман урамы буйлап үтте, милли ашлар бинасын карады, аннары кире борылып, кибетләргә керә-керә Партия мәгариф йорты, Муса һәйкәле яныннан узды. Троллейбуска утырды. Кулы шактый талган иде, китаплар ярыйсы авыр. Хәзер, китапларны урындык читенә куйгач, бу авырлыкны ул аермачык сизде. Шунда көтмәгәндә Исрафил Дидаровны күреп алды. Дидаров аңа бик җитди итеп карап тора иде. Пиджагын беләгенә салган. Башына җиңел ак эшләпә кигән.

Гәүһәр аңа бер карап алды да башын иеп кенә исәнләште. Дидаров та башын иде. Бу минутта алар икесе дә Җәгъфәр турында уйладылар бугай, икесе дә берничә секунд кузгалмыйча, эндәшмичә тордылар. Аннары Исрафил Дидаров үзен кулга алды, Гәүһәр янына килде, аңа кул биреп, чак кына елмаеп:

— Каян килеп чыктыгыз? Сезне районда дигәннәр иде бит,— диде.

Гәүһәр, кешегә усаллык саклый белмәсә дә, Исрафил Дидаров белән бик коры сөйләште. Шулай да Дидаров үзенә кирәк кадәресен белеп алды. Гәүһәр Галимҗаннарда туктаган. Иртәгә тагын районга оча. Дидаров тагын нәрсәдер сорамакчы иде дә, Гәүһәр, урыныннан торып, саубуллашып чыгып китте.

Бу көтелмәгән очрашу Гәүһәрнең уй агышын үзгәртте. Казанда Җәгъфәрне, Исрафил Дидаровны искә дә алмам, дип уйлаган иде ул. Менә көтмәгәндә ничек була икән.

Кайткач, Галимҗан абый белән Рәхимә апага да әйтте. Галимҗан абый бу мәсьәләгә тыныч карады. Дидаров ялда булган, күрәсең, яңа кайткан. Моннан биш-алты ай элек эшеннән алалар дип сөйләнгәннәр икән. Ул үзе дә Галимҗанга: «Мин баш инженер вазифасын ташлап, җиңелрәк эшкә күчәргә булдым», дигән иде. Соныннан мәсьәлә ничектер җайланган, ахрысы, һәрхәлдә, соңгы ике-өч айда заводта баш инженерның китүе-китмәве турында сөйләмиләр. Галимҗан үзе һаман цехта эшли икән, начальство эшләренә артык катнашмый. Соңгы вакытларда завод үзенең эшен шактый яхшырткан, яңача планлаштырырга күчкәннәр, атнага ике көн ял итә башлаганнар.

— Шулай да мин сезнең коллективны аңлап житкермим, Галимҗан абый,— диде Гәүһәр.— Ничек Дидаровка шулхәтле түзеп торасыз икән?! Үземә начарлык эшләгәне өчен генә әйтмим, анысы, ихтимал, частный мәсьәләдер. Ул гомумән әшәке кеше бит. Шундый кеше завод башында торгач, белмим тагы...

Шунда алар сүзләрен бүләргә мәҗбүр булдылар, кемдер Галимҗан абый янына килде. Гәүһәр сәгатенә карап алды да имтихан тапшырырга килгән Җәмилә янына китте, аның адресын Әгъзәмнән алган иде.

Җәмиләне эзләп табуы бер дә кыен булмады. Ул бер имтиханын бишкә, берсен дүрткә тапшырган. Тагын ике имтиханы бар. Ни булыр? Яшьлек шәһәрендә Җәмилә оптимистрак иде, монда бераз басынкылана төшкән.

— Абыйга сәлам әйтегез. Имтиханнарымны тапшырсам, телеграмма бирермен,— диде кыз.

— Беркая да бармыйсыз, йөрмисез инде?

— Юк, Гәүһәр апа. Имтиханнардан башка берни дә башка керми. Ябыкканмынмы әзрәк?

— Сизелми.

— Монда өйдәге гамьсезлек юк. Ярый әле берүзем, бөтенесен үзем кичерәм, бер тилелегемне дә күрүче юк.

Алар байтак сөйләштеләр, аннары Гәүһәр китеп барды. Җәмиләнең озатасы килсә дә, Гәүһәр рөхсәт итмәде. Яхшылап хәзерлән, кышкы каникулга килгәндә озаграк йөрербез, диде.

Бер карасаң, Җәмиләне барып күрү — бик гади эш. Моны кем эшләми. Ләкин Гәүһәр аның янына шулай уйсыз гына бардымы икән? Алай булгач, ни өчен Җәмилә яныннан чыккач, күңелендә яшерен бер ныклык сизде? Җәмилә ана әллә ни әйтмәде дә, вәгъдәләр дә бирмәде бит...

Гәүһәр яңадан Галимҗан абыйларга кайтты. Озак та үтмәде, ишектә тагын звонок шалтырады. Кем булыр икән? Кызлар кайттылар да кинога киттеләр. Бик һәйбәт картина бара, диделәр, карамый калырга һич ярамый икән. Бәлки күршеләредер, алар кайчагында шулай кергәләп утыргалыйлар. Әмма килүче бөтенләй көтелмәгән кунак булып чыкты.

— Исәнме, саумы, Галимҗан, Рәхимә ханым, исәнмесез. Сез дә, Гәүһәр ханым... Бая, троллейбуста күргәч, бөтенләй танымаган идем. Кешегә, мин әйтәм, нпи кайда да килешсә килешә икән. Безгә менә курортта да бугазга аркылы килә. Докторлар эчтә әллә нәрсә генә табалар...

Бу — Дидаров иде. Аны монда берәү дә көтми иде, берәү дә аның килүенә шатланмады. Бары тик әдәп йөзеннән генә аны бүлмәгә чакырдылар, урындык тәкъдим иттеләр. Рәхимә апа Фәнүзә турында бер-ике сүз сорашты, аннары чәй куярга чыгып китте.

— Син, Галимҗан дус, керми кергән кешегә гаҗәпләнә торгансындыр инде,— диде Дидаров, бераз тын алгач.— Синең өйдә икәненне белгәч, сугылдым әле. Эшкә бер-ике көнсез чыкмыйм. Аннары, анда ул-бу юк бугай. Планны арттырып үтәгәнсез, эшчеләрнең кәефе дә шәп күренә.— Дидаров тирләгән башын кульъяулыгы белән сөртеп алды. Хәзер ул костюмнан, корсагы баягы кебек чыгып тормый.— Тукта, мин әйтәм, үзе чакырып-чакырып кермәсә дә, мин иске дуслык хакына керим әле, биткә бәреп кайтармаслар. Эштә бит эш турында гына сөйләшергә кирәк. Тормыш булгач, аның башкасы да килеп чыга. Куляса әйләнә... Курорттан кайтып төшсәм, хатын балавыз сыга, балдызның чырае җир кебек кара. Ни булды дим? Хатын әйтә: менә, ди, Фаягөл ирен һаман әрли, ди. Өйләрендә гел талаш икән. Ничек әле: көлдергән дә хатын, бөлдергән дә хатын, диләрме? Мин үзем ир кешене гаепләүдән ерак торам. Башта ук балдызга әйткән идем: белеп чыгасыңмы? Гәүһәр ханым әнә нинди акыллы, сабыр иде дә, Җәгъфәрне кулында тота алмады, сиңа, чуар холыклы кешегә, подавно. Аннары кеше арасында төрле сүз булуы мөмкин. Кая мине тыңлау...

«Ник бу боларны сөйли?» дип уйлады Гәүһәр.

## 7

Күптән көтелгән беренче сентябрь көне дә үтеп китте. Быел инде класс, үткән елдагыча, жилсез көнне дә гөжли торган урман кебек түгел. Балалар бар да таныш, якын, үз. Аларның көчле һәм көчсез яклары да билгеле, бу шаян күзләр дә, бу шаян елмаюлар да сер яшермәгән, алар балалыкның үзе кебек, бары тик сафлык, беркатлылык, бетмәс-төкәнмәс көч кенә алып киләләр. Җәй буена балалар шактый үскәннәр, күп нәрсә күргәннәр, күп нәрсәгә өйрәнгәннәр. Укытучы менә шушы аерманы класска аяк баскан сәгатьтә үк сизәргә

тиеш, югыйсә һәркайсына ачкыч табуы кыенлаша аңа. Балалар бит бер генә минут та тик тормый, аларда күзгә күренмәгән туктаусыз үзгәреш, туктаусыз үсү-үзгәрү, күчеш, үзгәреш, туктаусыз күчеш, туктаусыз күчену булып тора. Аларның җаннары барысын сизә, барысын күрә, бигрәк тә алар ялганны, икейөзлелекне, пычраклыкны тиз сизәләр. Шуңа күрә аларның күңелен яулап алу да, аларның ышанычын югалту да бердәй җиңел. Дөрес, балаларның холкындагы кискен үзгәреш гадәттә икенче баскычның беренче елларында башлана, әмма алар инде хәзер үк «зурлар» — дүртенче класста укучылар.

Гәүһәр балаларның җәйге эшләренә тукталганда Акназарны мактап алды. Соңыннан балаларның Акназар тирәсенә җыелуларын, нинди күңелле сөйләшү башланып китүен күрде. Ул тагын бер мәртәбә үзенең төп юнәлешенең дөреслегенә ышанды: балаларның кечкенә генә яхшы эшен дә игътибарсыз калдырырга ярамый, һәммәсен күрергә, исәпкә алырга кирәк. Нәкъ менә шул яшьтә балалар игътибарга аеруча мохтаҗ. Аның яхшысын күрмәсәләр, таптап үтсәләр, аңа өстән карасалар, ул үз эшеннән үзе ояла башлый, юри тупас кылана, шул тупаслыкта ниндидер өстенлек күрә. Гәүһәр көче житкән кадәр балаларны шул юлга төшүдән саклады.

Укулар башланганның беренче көннәрендә үк Гәүһәр балаларга Иделдә сәяхәт итүе һәм Яшьлек шәһәре турында сөйләде. Моңа ул җентекләп әзерләнде. Дәресен кат-кат уеннан кичерде, аерым вакыйгаларны гына түгел, аерым детальләрне, эпизодларны, хәтта сүзләрне дә сайлады. Яшьлек шәһәренә, аның комбинатының зурлыгына, куәтенә, торган урынына аеруча тукталды. Балаларның күбесе анда булганнар. Гәүһәр сөйләгәндә, аларның күзләре очкынланып, йөзләре яктырып китте. Соңыннан, үскәч, комбинатта эшләргә теләүләрен балалар кайта-кайта сөйләделәр. Билгеле, алар моны үтә беркатлы аңлыйлар, Гәүһәр исә эшнең житдилегенә артык басым ясамады, аларны алдан куркытырга теләмәде. Вакытыннан элек аларны үтә акыллы итәргә тырышудан ни мәгънә?

Хәзер, балаларның дәфтәрләрен карап утырганда, Гәүһәр бары тик елмая иде. Укытучы өчен моннан да шатлыклырак минутлар бармы икән? Боларны синнән башка хәзергә берәү дә күрми, абайламый. Бик яхшы, иҗат сәгатьләренең яшерен ләззәтен нинди чит кешенең татыганы бар? Ул бит фәкать иҗатчының үзенә генә бирелә, аны гына белән ала. Кеше бит теге-бу уйның кайчан тууын анык кына белеп житкерми, аңа барысы да менә хәзер генә туды кебек тоела, хәлбуки бу уй, бу фикер, өскә калыкмыйча, байтак еллар аның хыял чоңгылында йөргән, кайчандыр бу уйның тәүге орлыгын аның күңеленә укытучысы салган була. Әгәр бүген бу уй җимеш бирерлек булып үскән икән, кайчандыр укытучы сөйләгәннәр бушка китмәгән дигән сүз.

Гәүһәр үзен көннән-көн яхшырак хис итә барды. Көн саен күзгә күренми эшләгән эшенең әһәмияте бермә-бер артты кебек. Әлбәттә, бу аның эчке дөньясы бөтен яктан тәртипкә килде дигән сүз түгел. Кеше үзенең күңел дөньясын алай тиз үзгәртми. Исрафил Дидаровның Җәгъфәр турында әйткәннәре Гәүһәрне хәзер куркытмый, гаҗәпләндерми. Элек кешеләр генә әйткән булса, хәзер үзе дә аңлады: Җәгъфәр үзе нәкъ шундый җәнҗалны эзләде бит. Гәүһәр кебек икенче бер юләр аның юлында очрамас инде хәзер.

Уе шул төшкә житкәч, Гәүһәр сискәнеп китте: яшерен-батырын түгел бит, Җәгъфәр аны «кара елан» дип атаганнан соң да Гәүһәр аны күңеленнән сыза алмады, ул хәтта бернигә карамастан, берни белән исәпләшмәстән аның янына кайтырга да риза иде. Тик Җәгъфәре генә үзенең хатасын аңлаган булсын.

Ләкин Рәхимә апа дөрес әйтә бугай: Исрафил Дидаров төнгә каршы Галимҗаннарга тикмәгә генә килмәс. Дөресрәге, эш монда Галим-

жаннарда түгел, Галимжаннарга, кирәк икән, ул теләсә кайсы көнне кылә ала. Монда хикмәт Гәүһәрдә. Аның иртәгә китәсен белгәнгә Исрафил Дидаров шулай төнгә каршы килеп җиткән. Хәзерге акылы булган булса, Гәүһәр, һич югында, Казанда әле тагын берничә көн торам дигән булыр иде. Ул чагында Дидаров та, әйтәсе сүзләрен төплерәк уйлар өчен, вакыттан файдаланырга тырышыр, шул ук көнне чабып килмәс иде. Сүз юк, аны Җәгъфәрне кызгану хисе дә чыбыркылamas, балдызы өчен дә ут йотмас,— Исрафил Дидаров андый беркатлы кеше түгел. Күзләре нинди тынычсыз иде ул чакта! Бу күзләрдән рәхим көтмә! Галимҗан абый да соңгы хатында: «Заводта тагын да Дидаров турында сүз купты, эшеннән алалар дип тә сөйлиләр, бу юлы аның урынына кем буласын да әйтәләр, инженер Вера Данилова турында сина сөйләгәнем бар идеме? Менә шул булыр диләр»,— дип язган.

Ниндидер бер яшь инженер Вера турында Галимжан абый сөйләгән иде бугай, тик Гәүһәр яхшылап тыңламаган, ахрысы, хәтерләми. Менә Дидаровны баш инженерлыктан, ниһаять, алалар икән, дөрес эшлиләр. Ләкин боларның кайдадыр укытучы булып эшләгән Гәүһәргә ни мөнәсәбәте бар соң?

Яңа уку елында туган бихисап мәшәкатьләр, көндәлек ыгы-зыгылар һәм мәктәп җыелышлары, район күләмендә барган төрле киңәшмәләр Гәүһәргә үз уйларына бирелергә күп вакыт калдырмады. Исрафил Дидаров бөтенләй исеннән чыкты.

Сентябрь башларында яңгырлар явып торганга, быел көз яңгырлы булыр, ахрысы, аяз, матур көннәр булмас дип сөйләнделәр Яшел Ярда. Ләкин табигать үзенеке итә икән. Ай урталарында һавалар утырып, көннәр җылынып китте, хәтта тожым җепләре оча башлады. Урамга чыксаң, әллә кайдан борынга хуш ис килеп бәрелә, бала-чага да, зурлар да көлмәкчән генә йөриләр. Пароходларда кеше бик азайган иде, инде тагын тулып үтәләр. Дөрес, Яшел Ярга күп төшмиләр, барысы да диярлек Яшьлек шәһәренә һәм арырак узалар. Кич белән Кама буенда халык җәйдәге кебек, бала-чага тавышы тәмам караңгы төшкәнче тынмый. Аларның кайгы-хәсрәт белми торган шау-шулы авазларына нәкъ менә шундый тын, җылы кичләр кирәктер.

Ниһаять, карасу күктә зәңгәр йолдызлар кабына. Алар күкне бизи, Кама киңлегенә аларның зәгыйфь нурлары агыла, әйтерсең, маяклар белән күз кысыш уйныйлар.

Гәүһәрнең быел эше бик күп иде, шуңа күрә кичләрен дә су буена сирәк чыкты. Былтыр ул күбрәк үз эченә бикләнеп яшәгән иде, җәмәгать эшләренә дә әллә ни катнашмады. Инде җитте, укытучыга болай килешми дигәндәй, быел аңа җәмәгать эшләрен өя генә тордылар. Ул баш тартырга батырчылык итмәде, алды да алды. Ярый әле, Бибинур апа аек акыллы директор икән, тау булып өелә башлаган җәмәгать эшләрен күреп:

— Чама дигән нәрсәне кайчак онытып җибәрәбез, иптәшләр,— диде.— Гәүһәр каршы килми дип, җәмәгать эшләрен өяргә тотындык. Соныннан без үк аныcын эшләмәгән дә, монысына житешмәгән дип нәфрәтләнеп тавыш күтәрергә әзер. Юк, соңыннан әрләгәнче, хәзер уйлап эшлик: Гәүһәрнең моңа вакыты житәме? — Ул бөрәм-бөрәм, бармагын бөгә-бөгә, Гәүһәрнең җәмәгать эшләрен саный башлады. Ул әле сүзен бетермәгән иде, Миләүшә утырган җиреннән генә:

— Дөрес, Бибинур апа,— диде.

Шуннан Гәүһәргә җәмәгать эшләрен өйми башладылар, буш сәгатьләре булган саен институт дәресләрен әзерләп утырды. Кирәкле китапларның кайберләрен үзе тапты, кайберләрен Әгъзәм табарга булды. Ул инде үзендә булганнарын өеме белән үк китергән иде.

Гәүһәр күңеле белән көннән-көн Әгъзәмгә якыная барганын тоя, үзе бу якынаюдан шүрли иде. Ул хәтта Әгъзәмгә: «Безгә килеп йөрмә», дип әйтергә дә җыенды. Ул бала түгел бит, унтугыз-егермедә генә диңгез тубыктан, утызга якынлашканда, бигрәк тә тормышта шундый фаҗига кичергәннән соң, җиңел караш бетәргә тиеш. Әйе, бу бүгенгә шулай, ә иртәгә? Иртәгә кичә уйлаганнарыңнан бернәрсә дә калмаса? Шуннан соң нишләргә? Барысын да яңабаштан башларгамы?

Әгъзәмнәр гаиләсе болай җилбәзәк түгел. Күбәләк кебек чәчәктән чәчәккә очып кунмыйлар. Дөрес, Хәйбүш бабай кебек картларга мактану хас нәрсә дә, йөз яшәгән карт бит ул. Әгъзәмнең әтисе белән әнисе бергә гомер сөргәннәр, ачысын-төчесен бергә күргәннәр, ләкин берберсенә элеккечә тирән хөрмәт белән карыйлар. Шушындый семьяда гына тормышка гашыйк булган кешенең үсүе мөмкин. Җәмилә шундый түгелме? Ул Яшьлек шәһәренә кайтып бераз торган да җаны-тәне белән ашкынып укырга киткән. Беренче хатларына караганда химия-технология институты аңа бик ошый. Гәүһәр мәгънәле генә итеп елмаеп та куя: биш-алты елдан ни буласын алдан әйтүе кыен, бигрәк тә кыз кешенең тормышында. Әмма шулай да якты йолдызга карап барган шикелле өметенә туры карап барса, бигрәк тә аңа ирешергә тырышса, бу инде буш нәрсә түгел. Җәмилә шикелле кызлар моңа ирешми калмаслар...

Әгъзәмне аерым алып карамый Гәүһәр. Ул аңа кагылудан курка да, тартына да. Шулай да... ул җылыта. Аңа бик озак карап торырга, җылысында җылынырга мөмкин. Хәзергә шуннан артыгы Гәүһәргә кирәкме? Кирәк түгелдер, ахрысы, чөнки сизелер-сизелмәс җылыга ул бик канәгать. Әлбәттә, Миләүшә була алсаң, бик яхшы булыр иде дә. Һәркемгә дә андый бәхет бирелмәгән шул. Миләүшә Гәүһәр уйлаганнарның чиреген дә уйламый торгандыр. Шул ук вакытта аның башында Гәүһәрнең төшенә дә керми торган уйлар бардыр. Кеше уйсыз тора алмый, алар аның теләгеннән тыш күңеленә киләләр, җитмәсә, бик үзенчәлекле булып киләләр.

Гәүһәр күңеле белән һаман шул «өчпочмак» тирәсендә әйләнә, гүя кемнеңдер белеп алуыннан куркып, исемнәрен атамыйча гына Җәгъфәр белән Әгъзәмне чагыштыра. Күрәсең, вакыт-вакыт элекке ирен, үзе дә сизмәстән, кай ягы беләндер, өстенрәк куя, ни әйтсәң дә, ул аны күбрәк белә, аннары элекке сөюен сагына булса кирәк, айнык акыл, ачы чынбарлык кисәтүләрен барысын да оныта...

Шулай төннәр көннәр белән алмашына. Гәүһәр мәктәбенә китә, нәкъ звонок булгач классына керә, көндәгечә балаларны барлый, аннары дәрес бирә. Былтыр ул кайчагында үзенең элекке тәҗрибәсенә дә таяна торган иде, я дәрес хәзерләргә вакыты булмый, я үз уйларына чума иде. Быел дәрескә әзерләнмичә килмәде. Шуңа күрә дәресләреннән бервакытта да канәгатьсезлек тойгысы кичермәде.

Гәүһәр өенә караңгы төшкәч кенә кайтты. Ул арыган булса да, саф һава аның арыганнарын бик тиз бетерде. Ата-аналар аны тыкрык башына кадәр озата килделәр. Зиләнең әнисе бигрәк тә ягымлы. Ул шатлыгын яшерә алмыйча, Рәми бабай быел хәтта бераз йөри башлады дип сөйләде. Акназарның әнисе яңа иреннән аерыла бугай. Өйләрендә көн дә талаш, ишек алдына чыгып та кычкырышалар, ди.

— Шундый кешеләр инде алар, әйткән белән генә акылга утыра торган түгелләр. Ярый, Гәүһәр, сау бул. Балаларыбызны яхшы укытканың өчен рәхмәт,— диде Зиләнең әнисе саубуллашкан чакта.

Гәүһәрнең тамагы кипкән иде. Ишектән керү белән үк Зәбирә түтисенә:

— Үләм, Зәбирә түти, шулхәтле сусадым,— диде.

— Әйдә чишен, самоварым күптән кайнаган.

Гәүһәр киемнәрен алыштырырга кереп китте. Зәбирә түти өстәлгә гөжләгән самовар китереп куйды, чынаякларын тездe, аннары үзе, яулыгын колак артына бәйләп, самовар янына килеп утырды. Ул арада, кулларын юып, Гәүһәр дә килде. Берәр чынаяк чәй эчәргә өлгермәделәр, ишек шакыдылар.

— Ярыймы? И-и, әллә инде тагын чәйгә? — диде Әгъзәм, оялып.— Кайчан килмә, чәй!

— Димәк, яхшылык теләп йөрисең. Шулаймы, Зәбирә түти?

— Безгә дә начарлык теләсә, җир күтәрмәс үзен.

Гәүһәр инде Әгъзәм сузган китапларны алырга, баш битләрен актаргаларга өлгерде. Барысы да нәкъ кирәкле китаплар икән.

— Каян таптың? — дип сорады Гәүһәр, шатланып.

— Таптым инде,— диде Әгъзәм, елмаеп.

— Ярый, Гәүһәр, син кунакны аяк өсте тотма. Табынга рәхим итсен.

— Рәхмәт, Зәбирә түти. Минем өчен борчылмагыз. Әлерәк кенә эчтем.

— Мин эчмәгәнсең димим бит. Менә утыр шунда. Гәүһәр дә тамагым кипте дип тора иде әле.

Гәүһәр китапларны язу өстәленә куйды да Әгъзәмне чакырды.

— Әйдә, рәхим итегез. Минем җыелышта сөйли-сөйли тамагым кипте. Сезнең дә кипкәндер әле. Киче бераз бөркү бит.

Әгъзәм елмайды.

— Йөзгә карап беләсез дисәм, алдау булыр инде,— диде ул, өстәл янына утырып.— Безнең дә яңарак кына җыелыш бетте. Тәнәфес вакытында буфетка кереп бер стакан чәй генә эчкән идем.

— И, буфет чәе — чәймени, үтәсеннән Казан күренә.

— Зәбирә түти әйтер инде... Җыелышта нинди мәсьәлә карадыгыз?

— Укытучыларның өлгереш өчен көрәшләре.

— Кайсы мәктәпне алдыгыз?

— Бишенче һәм җиденче мәктәпләрне. Бибинур апа бар иде. Бер күрдем дә, тик сөйләшергә генә вакыт булмады.

— Алайса, тиздән безгә дә сәлам бирерсез.

— Бик сагындыгызмыни?

— Начальство игътибар итсә, күңеллерәк була.

— Итне дә капкала, Әгъзәм. Шулпа булса, яхшы буласы иде дә...

— Рәхмәт, Зәбирә апа. Минем тамак кына әзрәк кипте, ашыйсы һич килми. Обедны бик ныгытып ашаган идем. Ә чәегез чыннан да тәмле, буфет чәе белән чагыштырырлык түгел.

— Без, Әгъзәм балам, салкын су бирсәк тә телеңне йотарлык диярсең.

Зәбирә түтинең кем бакчасына таш ташлавы ачык булса да, Гәүһәрнең ничегрәк уй йөртүен белеп бетермәгәнгә, Әгъзәм ачыктан-ачык хупларга батырчылык итмәде.

## 8

Кышын чатлама аяз көннәр сирәк һәм кыска була. Иртән үк кояш теләр-теләмәс кенә, колакланып туа. Мәктәп эчендә рәхәт, тыштагы суык борыннан, яңак очларыннан чеметә, тизрәк җылыга куа. Тәрәзә яннарына да бик якын бармыйсың, салкын монда да үзен сиздерә. Әмма көн урталарына таба көн шактый җылыткан сыман тоела, ялан өс тышка йөгереп чыгасы, туйганчы кар атышасы килә. Тик берәү дә моны эшләми, яхшылап киенмичә берәү дә тышкы ишекне ачмый. Шулай да мондый көннәрдә Гәүһәрнең күңеле шактый күтәренке була, балаларга шаян сүзләр дә әйткәли, берәрсенең йокымсырый башлавын күрсә, хәзер бөтен классны аякка бастырып, дәртле, күңелле

тавыш белән физкультура командалары бирә, әлбәттә, үзе дә хәрәкәтләнә, карыйсың — дүрт-биш минуттан бөтен класс үзгәрә. Яңа дәрт белән Гәүһәр бүленеп калган дәресен башлый.

Укытучылар практикасында еш кына шулай була: бер якта ул үзе — укытучы басып тора, икенче якта утызлап-кырыклап бала. Укытучы сөйли дә сөйли, карап торсаң, бик акыллы да, бик матур да кебек, программада күрсәтелгән дәресне бик төгәл башкарып чыга, кабатларга да өлгерә, өйгә эш тә бирә, укучылардан бераз сорарга да вакыт таба. Әмма класс барыбер икегә бүленеп кала, звонок булу белән укучылар төрлесе төрле якка чабып китә, укытучы үзе дә, дәресе дә онытыла, ул яңадан класста күренгәнче ул әйткәннәр балаларның башына кереп тә чыкмый. Инде сорый башласа, берсе дә рәтләп җавап бирми. Гәүһәр менә шундый хәлдән качарга бик нык тырыша торган иде. Хәтта кәефе бик начар булганда да моны онытмый, классны икегә бүлүгә юл куймый. Әлбәттә, күп вакытта аңсыз рәвештә, тәҗрибәгә буйсынып кына эшләгән чаклары да була торгандыр. Укытучы җансыз курчак түгел, ул минут саен үзгәреп торган җанлы коллектив эчендә эшли, аннары ул үзе дә кеше, теге-бу йомшаклыкларның берсе дә аңа ят түгел. Тик йомшаклыгыңны класска күрсәтмә — менә шунда осталык. Гәүһәр шуннан бик оста файдалана, классның аз гына тыпырчынуын сизсә, хәтта тәнәфес вакытларында да классыннан китми, төрле уеннар уйната, күңелле җырлар җырлата. Дәрес вакытында карыйсың, бөтен классның игътибарын үзенә тарткан, бөтен балалар аны йотлыгып тыңлый яки дирижер таягына буйсынган шикелле әле анда, әле монда кул күтәрәләр, җавап бирәләр. Берәү дә читтә калмый, онытылмый, кагылмый, бөтен класс әңгәмәгә дәррәү катнаша. Күзләр ялтырый, сулыш ешая, вакыт үткәне сизелми.

Балалар үзләренең көчләре житкән кадәрле төрле уйлап табуларны бик яраталар. Төрле кәгазь, картон кисәкләреннән ясалган кубик, пирамидалар, сәгатьләр, фанер кисәкләреннән лобзиклар белән бик матур итеп кисеп ясалган төрле бизәкләр, тартмалар, җыйнак савытлар, пластилин һәм балчык кисәкләреннән ясалган төрле сурәтләр Гәүһәр классында бик күп иде. Бик еш уку барышында аларның әле берсен, әле икенчесен алып күрсәтә. Табигатьне танып белүгә Гәүһәр бик игътибар итә. Аның классы кечкенә бер музей почмагы шикелле. Төрле үсемлекләр, яфраклар, гөлләр — барысы да бар. Ул рәсемнәр! Аларның иң яхшыларын сайлап, үзләре үк ясаган матур рамкалар эченә куеп, стенага элгәннәр. Иң мөһиме тагын шунда, балалар класстагы бернәрсәне дә ватмаска, сындырмаска, җимермәскә өйрәтелгәннәр. Бер тапкыр шундый хәл булды: кемдер гөл сабагын терәтеп куяр өчен ясалган баскычны ватып киткән иде. Балалар ике көн буена шауладылар, дежурныйлар рәтләп карамый, дип нәфрәтләнделәр. Дәрестән соң калып, баскычны төзәттеләр, класс старостасы Зиләдән тәртипне ныграк күзәтүне таләп итте. Гәүһәр балалар эшенә турыдантуры «тыгылмаса да», балалардан барысын төгәл эшләтү аның эш планында бар иде. Балаларның шулай дәррәү кубуы, класс эшен шулай йөрәкләренә якын алулары аны бик шатландырды.

Хәзер Гәүһәрнең күз аллары яктырганнан-яктыра бара. Класска килеп керүе, класста үткәргән сәгатьләре аңа үзенә күрә бер кечкенә генә бәйрәм сыман тоела. Класска, балаларга ул ияләште. Ул килгәндә үк стеналар шәп-шәрә булмаса да, Гәүһәр үзе монда ят кеше иде әле. Тора-бара ул класска күнекте, аның аерылмас бер кисәге булды, балалары белән бүлмәне бизәүне дә дәвам иттерде. Шунысы кызык, монда дәрес өчен кирәк булмаган бер генә үсемлек тә, бер генә чәчәк тә, таш та юк иде. Шуңа күрә алар барысы да җанлы сыман, кирәк чакта телгә киләләр.

Биология укытучысының кабинеты тагын да шәбрәк, дип сөйлиләр. Гәүһәр моңа гаҗәпләнмәде дә, көнләшмәде дә. Биологияне өлкән классларда үтәләр, димәк, вакыты белән Гәүһәрнең классы да укыр. Дөрес, биология укытучысы турында әллә нәрсәләр сөйлиләр, имеш, аның нервлары тимердән, диләр. Гәүһәр моңа елмая гына. Укытучыга гомумән нервларын тота белү кирәк, таш яуса да алар «кузгалмаска» тиеш. Бу — тәҗрибә белән бергә килә, күктән йолдыз чүпләүче укытучылар, белмим, бармы икән. Шулай да Гәүһәр биология кабинетына әледән-әле кергәләп торды. Төрле кошлар, җәнлекләр утыртылган читлекләргә, балыклы аквариумнарга, чәчәк, муляж, гербарийларга кызыксынып карап йөрде. Барысыннан да бигрәк шунда эшләүче укучы балаларны — малайларны һәм кызларны күзәтте. Барысы уңлап бала булыр. Кайсылары читлекләрдәге комнарны, кайсылары тагаракларны чистарталар, аквариумнардагы суларны алмаштыралар. Берәү дә аларны син аны эшлә, син моны эшлә дип өйрәтми. Үзләре белә. Бер керүендә Гәүһәр өстенә кара халат кигән кызчыкны күрде һәм бары тик исәнләшкәч кенә танып алды: Гөлназ иде ул!

Гәүһәр, өстенә киенеп, мәктәптән чыкты. Күр, шундый суыкта да балалар аны көтәләр, таралмаганнар.

— Салкын тидерәсез ич, нигә кайтмыйсыз? — диде Гәүһәр, мөлаем гына.

— Безгә суык тими, без үзебез суыкка тиябез,— диделәр балалар, бертавыштан.

— Гәүһәр апа, кыш көне кар астында җир йоклыймы?

— Йокламыйча. Язга чаклы тын да алмый.

— Ә көн уртасында, кояш караганда?

— Кояш караганда да йоклый. Мин бер китапта укыган идем, аю бармагын имеп кыш буе йоклый. Шулай бит, Гәүһәр апа?

— Ә шатун аюлар. Алар кыш көне дә йөри.

— Ә син, Нияз, китап укымыйсыңмыни?

— Укыйм да...

— Ул күбрәк космонавтлар турында гына укый. Үскәч космонавт булам, ди.

— Шулаймы, Нияз?

— Менә мин суыктан бөртек тә курыкмыйм,— дип, Нияз ялан кулын чыгарып күрсәтте.— Анда, космоста, бөтен яктан нык булырга кирәк, ди.

— Ә мин химик булам, Яшьлек шәһәрендә эшлим.

— Ә мин Камада «Ракета» йөртәм!

— Мин автомашина. Үгезләне!

— Үгез түгел ул, зубр.

Балалар өйләренә тараддылар. Гәүһәр таныш тыкрыкка борылды. Нигәдер аңа бик күңелле иде. Балалар хыялланалар! Кем аларның хыяллары тормышка ашмас дип әйтә ала?

Быел кар шактый, тыкрыкка машина керерлек түгел. Җәяүле юлы гына. Кар ап-ак, кояшта җемелдәп ята. Туктап карасаң, чаткыланып та тора кебек. Биек агач башында бер ала карга утыра, шунда ук зур башлы чәүкәләр дә кунган. Күрәсең, алар нәрсәдер көтеп торалар. Пыр тузып Гәүһәр яныннан гына чыпчык көтүе очып үтте.

Гәүһәр өйгә керде.

— Һәй, Гәүһәрем! Мин әле сәгать унике генә дип торам. Бәрәч, ул гөнаһ шомлыгы туктаган икән! — диде Зәбирә түти, ачынып тиз генә самоварын куя башлады.

— Ашыкма,— диде Гәүһәр, өс киемен чишенә-чишенә.— Бишенче яртыга хәтле мин өйдә. Биштә мәктәп укытучыларының гомуми җыелышы.

Гәүһәр портфелен олы бүлмәдә язу өстәленә куеп, үз бүлмәсенә узды, гардероб ишегендәге көзгегә карады, чәчен, күлмәген төзәтте. Яңаклары кызарган, күзләре ялтырыйлар.

— Мә әле, аягыңа җылы каталар ки,— диде Зәбирә түти, мич башыннан каталар алып.— Фасоны яшьләргә бераз туры килми дә, өйдә ят кеше юк. Син бит өстәл артында утырасың, идән салкын.

Бу вакытта Гәүһәр, җилкәсенә мамык шәл салып, язу өстәле янына утырган иде. Зәбирә түти биргән җылы каталарны рәхәтләнеп аягына киде, аннары көлеп җибәрде:

— Моның белән Казанның Бауман урамында гына йөрергә! Иртә белән бөтен матур кызлар кибеттә ката эзләп мәш килерләр иде.

— Минем иске катам да хутка китәр идеме? — Зәбирә түти, кулын селкеп, кече якка кереп китте.

Гәүһәр дәфтәрләр тикшерә башлады. Кулына Нияз дәфтәре эләккәч, ул аны әйләндереп-әйләндереп карады. Булачак «космонавт» яхшы ук тырышып эшләгән, язуы да ару гына, хаталары да юк. Дәфтәрләрне тапшырганда бераз мактарга кирәк булыр үзен...

Зәбирә түти ишек алдыннан кергәндә дә, Гәүһәр һаман өстәле янында утыра иде. Ишек ачылган тавышка башын күтәрде. Вакыт инде бишенче булган. Кай арада минутлар да, сәгатьләр дә үтә.

— Миңа җыенырга да вакыт җиткән, ә мин әле дәфтәрләремне дә карап бетермәдем.

— Кайткач карарсың.

— Юк, бетерим инде. Ике генә дәфтәр калды.

Укытучы өчен укып чыктың да билге куйдың түгел шул. Эш анда гына булса, әллә ни кыен да булмас иде. Гәүһәргә һәр дәфтәр иясе турында уйланырга кирәк. Шунда аның иртәгәге дәресенең өстәмә планы да туа, үзенең көчле якларын да, көчсез якларын да күрә, балалар белән сөйләшәсе сүзләре дә бер-бер артлы исенә килә.

Ниһаять, ул дәфтәрләрен төреп, иртәгә сөйлисе сүзләрен төгәлләп куйды да тиз генә үз бүлмәсенә кереп, өстен алмаштырды. Берничә минуттан ул тәмам киенеп, ишек тоткасына тотынды:

— Ярый, Зәбирә түти, мин киттем. Кайчан кайтырмын, анык кына әйтә алмыйм.

Гәүһәр артыннан ишек ябылгач, өй эче тирән тынлыкка чумды. Зәбирә түти бәйли башлаган оекбашын киштәдән үрелеп алды да мич буена утырып инәләрен кыймылдатырга тотынды.

## 9

Караңгы һәм җилле кышкы кичләрдә ялгызы гына калган минутларда Гәүһәр үзенең тормышын Миләүшәләр тормышы белән чагыштырып карый иде. Күптән түгел генә ул аларда булды. Яңа мебельләр алганнар, шуларны урнаштырышты. Вилданның әнисе Нурҗидә апа белән сөйләште. Күңелле иде аларда. Ләкин Гәүһәр шундый тормышта яши алыр идеме? Бер профессия кешеләренең, аерым алганда, укытучыларның тормышларында уртак яклар байтак. Ни әйтсәң дә, профессия үзенең билгеләрен сала, алардан качып булмый торгандыр, күрәсең. Шулай да Гәүһәр Миләүшәләр тормышы белән яши алмас иде шикелле. Нинди дә булса кимчелекләре булганга түгел, кимчелекләрне белсәң, аларны бик тиз бетерергә мөмкин. Әнә бүлмәләрен бизәүдә кимчелекләре барлыгын белгәч, Миләүшә минуты-сәгате белән аларны бетерде. Аннары нәрсә ул бүлмә бизәү? Тормышны бизәү авыррак шул. Аның бормалы юлларының очы күренми. Гәүһәр бары тик шуны гына күңеле белән тоя: Миләүшәләр тормышында да ул әкренләп күп нәрсәне үзгәртер иде. Тик ул моны эшләмәячәк, эшли алмаячак,

чөнки бирәү дә аның ярдәмен сорап килмәгән. Миләүшә белән Вилданга үз тормышлары бик яхшы. Нурҗидә апа шул тормышка хәтта гашыйк, ул бит аны төшендә дә күрмәгән. Һәр кеше үзенең шәхси тормышын үзенчә төзи. Кешенең тормышы — аның холкы, диләр. Ә һәр кешенең холкы үзенчә була.

Кайчагында Гәүһәргә болай да тоела: аның көннәре гаҗәп дәрәҗәдә бер-берсенә охшаганнар, бер аермасы юк кебек. Атналар, айлар бер-берсен алмаштырып торсалар да, көннәр үзләренең ыгы-зыгылары белән бик киеренке үтсәләр дә, тормышны ничектер алга итмиләр, аны ниндидер яңа бер баскычка сизелерлек күтәрмиләр шикелле. Гәүһәрнең гомерләре заяга үткән кешеләр турында укыганы бар. Элек ул моны аңламый иде. Ничек инде акыллы кеше гомерен трай тибеп үткәрсен. Хәзер аңлый шикелле. Кеше бер дә трай типми, ул яши, башкалар кебек эшли, тирә-ягында кайнап торган тормышка да көче җиткәнчә катнаша кебек, алай гына түгел, тормыштагы бик күп мөһим вакыйгалар аңа турыдан-туры килеп кагылалар шикелле. Шулай еллар гына түгел, гомер дә үтә. Соңыннан икенче берәү тикшерсә, күрә: әлеге кеше тирәсендә чынында зур тормышның шау-шуы гына булган, ә тормыш үзе бер читтән үтеп киткән! Кайчагында кеше, тормыштан китмәс борын ук, исенә килә, аның әле үз тормышын әзме-күпме үзгәртергә кулында көче була, ләкин башта әле шаккатып карап тора: күрсәнә, ул бит һаман бер эздә таптанган! Иптәшләрең сине ачуланмыйлар да, син зур тормыш белән яшисең дип уйлыйлар. Хәлбуки, кая ул зур тормыш!

Гәүһәр калтыранып китте. Үз тормышында да нәрсәдер күргәндәй, сизгәндәй булды. Әгъзәм, Җәгъфәр... Җәгъфәр соңгы вакытларда онытыла, хәтта бөтенләй күңел күзеннән югала башлаган иде. Әллә Гәүһәр үз-үзен генә алдап килдеме? Әгъзәм янында булгач, аны күбрәк үз иттеме? Алар бит Әгъзәм белән бергә «Зәңгәр шәл»гә дә бардылар, соңыннан халык театры турында бик озак сөйләшеп утырдылар. Спектакль аларга ошады, артистларның уеннары да, кием-салымнар да, декарацияләр дә ярыйсы. Гәүһәр хәтта Яшел Ярда шундый театр барын күз алдына да китермәгән иде. Бүген... Гәүһәргә соң тагы ни кирәк? Нәрсә көтә ул?

Бу сорау аның башына еш килә башлады. Тормышы аңа әле бик әкрен бара күк тоела, әле кар-буран шикелле, бер урында бөтерелә, кайчагында каядыр чакырып ишек тә кага кебек. Икенче көнне эшкә тотынам дип торса, бер нәрсә дә юк, бар да элеккечә бара, Гәүһәр тагын аптырап кала. Ул башын авырттырганчы уйлый, нәрсәнедер хәтеренә төшерергә тырыша, тик бер нәрсә дә исенә төшми.

Шулай да Гәүһәр нәрсәдер көтә. Кинәт ишек ачылса да, ишек алдына бер тавыш ишетелсә дә, ул сискәнеп китә. Хәтта соңгы вакытларда бу артыграк була башлады бугай. Элек ул тынычрак, болай юк-бар нәрсәгә пошынмый иде. Нәрсә борчый соң аны? Ни тели Гәүһәр? Аның нәрсәгәдер каршы барганы, көрәшкәне сизелми. Бер карасаң, ул бик булдыксыз кеше, аның бер максаты, бер омтылышы да юк. Барысын вакыт иркенә генә куйган. Ә вакыт бит алай да, болай да борыла, кая юл тотасы да билгеле түгел. Тормышта кешенең акылы, ихтыяр көче кирәк, мәрткә киткән кебек кылану бернәрсә дә бирмәячәк. Хәер, Гәүһәр боларны белмимени? Белә, бик яхшы белә дә, ни хәл итсен.

Менә шундый көннәрнең берсендә Бибинур апа Гәүһәрне мәктәп коридорында күреп, дәрестән соң үз янына кереп чыгарга кушты. Вакыт бик тар, сорашып торырга мөмкинлек юк иде. Гәүһәр ярый диде дә үз классына кереп китте, чөнки звонок булган иде инде. Актыккы ике дәрес — арифметика. Гәүһәр хисап мәсьәләләрен яхшылап аңлатты да тактага Зиләне чакырды. Соңгы вакытта алар Акназар белән

шаяргаладылар, кайчагында укытучының сүзен дә яхшылап тыңламыйлар кебек. Гәүһәр, бу бер нәрсә дә белми торгандыр, дип Зиләне тактага чакырды, үзе моны юри эшләгәнлеген күрсәтмәс өчен аңа текәлеп карамады. Гади бернәрсә кебек китаптан мәсьәләне укыды. Аннары тагын бер мәртәбә укыды да Зиләдән:

— Аңладыңмы? — дип сорады.

— Аңладым,— диде кыз, бик тиз мәсьәләне чишә башлап. Аның иреннәре үзалдына кыймылдый, кыска толымнары әкрен генә чайкалалар. Гәүһәр сагаеп караштыргалап торды, бу кызчык никадәр генә үз-үзенә ышанган булып тотынмасын, дәресне игътибар белән тыңламавы өчен җәзасын алырга тиеш. Шулай булды да, Зилә бармагын авызына кабып, тертелеп калды. Гәүһәр юри дәфтәрләргә күз салган булып, кайчагында теге-бу укучының ялгышын төзәтеп, Зиләгә игътибар итмәде. Аның исәбе Зиләне такта алдында күбрәк тотып, аңа үзенә күрә җәза бирү иде. Әмма кызчык үзенең ялгышын бик тиз сизеп, язганын бозды да мәсьәләне яңабаштан чишә башлады. Бу юлы ул төртелмичә, бик ару эшләде. Гәүһәр аңа карады да сизелер-сизелмәс кенә елмайды. Зиһенле балаларны ярата иде ул. Мәсьәләнең дә юри кыенрагын сайлаган иде. Болай булгач, Зилә молодец.

— Бик яхшы,— диде ул кызчыкка,— инде аңлатып бир.

Зилә — чая кыз. Җавап биргәндә аның тавышы өлгер, ачык, кыю. Моның өчен Гәүһәр әллә ничә тапкыр аны класс алдында мактаган иде, бу юлы да Зиләгә бернichә җылы сүз әйтүдән тыела алмады.

Шуннан соң Гәүһәр тактага бер-бер артлы дүрт-биш укучыны чакырды. Балаларның берсе әзрәк тотлыккаласа да, ахыр килеп ул да мәсьәләне дөрес чиште. Калганнарына яхшы, бик яхшы билгесе генә куярга мөмкин иде. Гәүһәр канәгать булды. Күңеле күтәрелеп китте. Юк, ни әйтсәң дә, балалар белән эшләве күңелле. Вакыты-вакыты белән алардан туйганчы көләргә мөмкин, вакыты-вакыты белән бик тирән уйга каласың, чөнки алар бала эшләмәстәй эшләрне дә эшләп ташлыйлар. Кемдер, балалар арасында бик оста көймәче булырга кирәк, дигән. Әйе, Гәүһәр үзе дә аларның су астындагы ташларга таба баш әйләндергеч тизлек белән барганнарын күрде. Бик оста кул гына аларны актык минутта куркынычтан коткарып кала, ә балалар, гүя моңа аз гына да игътибар итмичә, юлларын дәвам иттерәләр, куркыныч булганын гүя сизмиләр дә.

Икенче дәреснең азагында Гәүһәр өйгә биреләсе мәсьәләләрне аңлатты. Ул арада звонок та булды. Балалар дәрес беткәнгә кинәнешеп, шау-гөр килеп, коридорга чыктылар. Тавыш, көлү, йөгерү, баш өстендә портфельләр уйнату, аннары чиратта бер-берсен төртешүләр китте. Монда инде укытучының: «Балалар, сабыр, әкрен», дигән тавышлары беркемгә дә ишетелми иде. Гәүһәр директор бүлмәсенә юнәлде. Ник чакырды икән бу Бибинур апа? Ул-бу юкмы икән?

Дүрт-биш укытучы берьюлы директор кабинетына керде. Гәүһәр белән аларның кайсы күрешкән иде, кайсы шунда аяк өстән генә башын иеп исәнләште.

Башка укытучылар Бибинур апаны сырып алдылар. Гәүһәр, аның бушаганын көтеп, диванга утырды. Ул арада Миләүшә дә килеп керде. Үзенә хас омтылышлы итеп Гәүһәр белән күреште, аның хәлләрен, кәефләрен сорашты. Аннары тәрәзәгә карап:

— И, ябалак-ябалак кар ява башлады,— диде.

Берьюлы бөтен дөньяны кар басты шикелле. Бернәрсә күренмәс булды, бары тик кар бөртекләре генә бөтерелә иде.

Миләүшә тәрәзәдән бераз карап торды да яңадан Гәүһәр янына диванга килеп утырды. Ул арада Бибинур апа, башкалар белән сүзен бетереп, Гәүһәргә борылды. Гәүһәр тиз генә урыныннан торып, аның өстәле янына килде.

— Гафу ит, Гәүһәр, көттердем. Исәнлек-саулыкмы?
— Бик яхшы, Бибинур апа.
Бибинур апа гөлләр өстеннән каядыр зур тәрәзәгә таба карады. Тышта инде кояш, тик кояш үзе моннан күренми, һавада болытлар гына йөзә, алар гүя беркая да ашыкмыйлар, беркая да чакырмыйлар.
— Ә безнең өйдә хәлләр шәп түгел әле,— диде Бибинур апа, тирән көрсенеп.
Шунда Гәүһәр беренче тапкыр Бибинур апаның йөзенә тутырып карады. Нәкъ шул вакытта кояшны да болыт каплады, ахрысы, бүлмә эче берьюлы караңгыланып китте. Бибинур апаның тулы ак йөзе сулган сыман күренде. Гәүһәр эчтән сискәнеп китте. Ничек соң ул элегрәк моңа игътибар итмәде? Ул бит кешегә карата сизгер була белә иде. Гәүһәрнең авыр көннәрендә Бибинур апа күпме булышты, ә ул...
— Ни булды, Бибинур апа? — дип сорады ул, борчылып.
— Гөлназ авырый. Менә бер атна була инде.— Ак чәчле өлкән укытучының йөзендә хәзер ана хәсрәте генә ярылып ята иде. Гүя мәктәп тә, уку-укыту эшендәге көндәлек мәшәкатьләр дә — берсе дә юк, бары тик ана борчылуы гына калган. Шул ук вакытта ул моннан минуты белән чыгып та китә алмый. Ихтимал, ул Гөлназның әкрен генә ыңгырашуын ишетә торгандыр. Күрше карчыгына Гөлназны кергәләп караштыр, дигән дә, карт кеше, онытуы бар. Ә Бибинур апаның бөтен шатлыгы — шул бердәнбер баласы.
— Тәмам башым каткан, төннәр буе йокламыйм.
— Мин бернәрсә дә белмәдем бит. Белгән булсам...
— Рәхмәт, мин аның өчен чакырмадым.— Бибинур апа, авыр хәсрәтеннән аерылырга теләгәндәй, башын селкеп алды. Әллә чыннан, әллә Гәүһәрне тынычландырыр өчен генә өстәде:— Бүген бераз хәле җиңелрәк шикелле. Врач та шулай дигән иде.
— Салкын тидергәнме?
— Грипп. Без гриппка еш кына җиңел карыйбыз, ә ул бик әшәке нәрсә икән... Я, ярый, Гәүһәр. Син керсәң берничә көннән керерсең. Классны куркыныч астына куеп булмый. Үзем дә шуның аркасында сиңа керә алмадым. Гафу итәсең.
— Бибинур апа, мин гафу үтенәсе урында...
— Ярый, Гәүһәр, анысы үткән эш инде. Синең эшең никадәр күп икәнен күреп торам ич. Хәл-әхвәлләрең турында да сорашырмын дигән идем.
— Минем хәлләр болай ярыйсы кебек.
— Галимҗаннардан хат аласыңмы?
— Бу араларда юк,— диде Гәүһәр, кызарып.— Дөресен әйткәндә, үземнең дә язганым юк. Сәлам генә язасым килми, үз хәлем белән кешеләрне борчырга яхшысынмыйм. Мин бит аларга болай да баш тиңентен бурычлы. Хәзер алар саулармы икән?
— Бар да исән-саулар. Сине һаман сорашалар.
— Рәхмәт. Мин аларга хат язарга тиешмен. Язмый торып...
— Язсаң, шатланырлар...— Бибинур апа портфеленнән бер конверт алды.— Менә шул хатны өеңә кайткач, яхшылап укырсың әле, Гәүһәр. Галимҗаннан бу.
Гәүһәр конвертны алды да портфеленә салды.

## 10

Әйе, бу хат Галимҗан абыйдан иде...
Нәрсәдер сизенгән сыман, Гәүһәрнең бу хатны мәктәптә укырга көче җитмәде. Гади хат булса, Бибинур апа да болай кереш ясап тормас иде. Аннары читтә буласы, уйлары белән берүзе каласы килде Гәүһәрнең. Кешеләр бит аларны күп вакытта аңлап та бетермиләр,

шуңа күрә әллә ниләр сөйлиләр. Гәүһәр исә эчке уйларын кешегә чыгарырга бик теләми дә иде.

Гәүһәр чишенде, киемен алмаштырды, чәчен тарады, аннары чыгып кулларын юды. Зәбирә түти өйдә юк, күрәсең, каядыр киткән. Өстәлгә кашык, тәлинкә куйган. Димәк, кайнар ашы мичтә. Гәүһәр мич авызын ачып, чуенны алгарак чыгарды да аш состы, аннары итен, компотын алды. Ашыкмый гына, вакыт-вакыт гөлләргә, стеналардагы рәсемнәргә күз төшергәләп, тамагын туйдырды. Хат аның йөрәген тырный, күңелен кытыклый иде. Шулай да өстәлдән савыт-сабаларны жыйганчы ул үзен-үзе тыеп торды. Шуннан соң гына үз бүлмәсенә кереп, портфеленнән зәңгәр конвертны алды.

Хатның беренче ике бите Гәүһәргә бөтенләй кагылмый иде. Монда Бибинур белән Гөлназга сәлам, семья хәлләре, озак хат булмаганга борчылулары язылган иде. Хатның бу өлешен Гәүһәр күз йөгертеп кенә укып чыкты. Өченче биттән ахырга кадәр диярлек хат Гәүһәргә багышланган. «Мин, әлбәттә, дигән Галимҗан абый, турыдан-туры Гәүһәрнең үзенә дә яза алган булыр идем. Ләкин сездән озак хат алмагач, мин андагы хәлләрне белмим. Шуңа күрә сиңа язу хәерлерәк шикелле тоелды. Кирәк тапсаң, хатны Гәүһәргә укытырсың, кирәк тапмасаң, үзеңдә калдырырсың. Ихтыяр тулысынча синеке». Шуннан инде төп нәрсә башлана. Күрәсең, Бибинур апа хатын Гәүһәргә укытырга, хәтта аның кулына бирергә ярый дип тапкан. Хатның бу өлешен Гәүһәр утлы күмер тоткан шикелле укыды.

«...Август башларында Гәүһәр Казанга килгәч, без аның белән тормыш хәл-әхвәлләре турында байтак сөйләштек. Миндә Гәүһәр элекке тормышы белән араны бөтенләй өзмәгән дигән тәэсир калды. Ул элекке ирен сагына булса кирәк. Ул миннән дә бу турыда фикерләремне сораган иде. Мин, кеше тормышына керәгеннән артык кагыласым килмәгәнгә, бик сак булдым. Моның өчен аның хәтере дә калды бугай. Теге вакытта Җәгъфәрнең өйләнергә әзерләнүен әйтмәгән өчен дә миңа әзрәк үпкә белдерде. Дөрес, үзе һич үпкәләмим, дигән булды. Ләкин монысы инде гади хатын-кыз хәйләсе булгандыр дип уйлыйм.

Хәзер эш тагын да җитдирәк. Бу арада Гәүһәрнең башында нинди уйлар булгандыр — белмим. Теге вакытта алган тәэсирләремне дәвам иттерсәм, шактый күңелсез нәрсә килеп чыгар төсле. Шулай да мин Гәүһәргә тирәнтен ышанам, ахыр килеп, ул дөрес адымны атлар дип уйлыйм. Исрафил Дидаров Гәүһәр алдында бер әйткән иде инде: Җәгъфәр яңа хатыны Фаягөл белән начар тора дип. Ихтимал, ул вакытта ук аларның аерылулары хәл ителгән, Дидаровның безгә килеп чыгуы да шуңа бәйләнгән булгандыр. Хәзер инде алар рәсми рәвештә аерылышканнар. Рәхимә дә ишеткән. Кичә ул тагын бер яңа хәбәр сөйләде: Җәгъфәр, ди, Гәүһәрне бик сагына, юләр булганмын, шундый турылыклы хатынымны кеше сүзенә карап аерганмын, ди. Хәзер ди, Гәүһәрнең аягына егылырга әзер. Чын булса, Гәүһәр янына да барырга уйлый икән. Боларны мин, Бибинур, син дә белеп тор, Гәүһәр дә белеп торсын дип кенә язам. Кинәттән генә кеше шундый хәлләр алдында калса, аңа акылын җыю бик кыен була, дөрес юлны тапмавы да мөмкин. Аңа бит мәсьәләне дөрес хәл итәргә, халык әйтмешли, җиде үлчәп бер кат кисәргә кирәк. Гәүһәрнең хәзер беркадәр тәҗрибәсе бар, кешеләрне дә яхшырак таный, тормышны да тирәнрәк төшенә. Ихтимал, киңәшергә дуслары да бардыр.

Хаттан, юл араларыннан, минем үз карашым сизелә торгандыр. Тәфсилләп язмыйм, Гәүһәрнең уйларына тимер тагасым килми. Син дә, Бибинур, аңа үз карашыңны такма. Моны Гәүһәр үзе хәл итсен. Ул яшь кеше, аңа дөньяда яшәргә кирәк. Ә яшәү, үзең беләсең, уен түгел. Безгә, тормышның ачысын-төчесен күргән кешеләргә, күп нәрсә ачык. Ләкин бөтен хикмәт тә шунда, һәркем үз юлын үзе үтә, анысын

алай эшлә, монысын болай ит, дип кеше әйтүгә карап мәсьәләнең асылы үзгәрми. Кыскасы, Гәүһәргә үзенә уйларга мөмкинлек бирергә кирәк.

Исрафил Дидаров турында бары тиң алдагы мәсьәләләргә бернигадәр бәйләнеше булганга гына язам. Син минем бу кешегә чын мөнәсәбәтемне ачык беләсең. Ниһаять, гаделлек тантана итте, Дидаровны эшеннән алдылар, бүлектә гади бер инженер итеп кенә калдырдылар. Минемчә, монда ул озак утырмас. Аңа кыерсытылган инженер, кыерсытылган җитәкче ролен уйнарга кирәк. Дидаровны яхшы белгән коллективта моны эшләве кыен, хәтта мөмкин түгел. «Ул җитәкчеләрне шулай бертуктаусыз иләп торалар инде», дип сөйләнгәли икән, ләкин заманнарны гомумиләштерү, үзең беләсең, бик хәтәр. Аннары вак җаннар зур фаҗигаләрдән дә файдаланырга тырышалар. Алар, хәчтерүш җаннарын яшереп, фаҗигагә эләккән кешеләр арасында, үзләрен дә хаксызга кимсетелгән дип йөриләр. Тыңлаучылар табыла бит...»

Гәүһәр хатны бер укыгач, әле тагын нәрсәдер калган кебек, икенче кат та, өченче кат та укыды. Аннары аны читкә куеп, уйга чумды. Ул артык дулкынланган иде, шуңа күрә хаттагы күп фикерләр хәзергә читкә очтылар, ул хатның, мондагы хәлләрне белмәүдән тыш, тагын нинди төп максат белән Бибинурга җибәрелүе турында уйлап та карамады.

«Җәгъфәр Фаягөл белән аерылган, Җәгъфәр янадан ялгыз», дип уйлады Гәүһәр. Хатын-кызның иң көчле хисе — кызгану хисе Гәүһәрне биләп алды. Ул Җәгъфәрне кызганды. Ялгыз бит, тамагына да рәтле азык булмас. Ачлы-туклы йөреп, ашказанын тәмам бозуы бар. Болай да ашказаным авырта, дип зарлангалый иде бит. Гәүһәр гүя аерылмаган да, куылмаган да, мең газаплар да кичермәгән. Ул үзен гомумән оныткан. Җәгъфәр генә бар. Ул элеккечә саф, эчкерсез. Ихтимал, аның өсте-башы бераз каралгандыр, ләкин Гәүһәр аны бик тиз чистартыр. Ул бит Гәүһәрне сагына, ул аңардан кеше сүзенә карап кына, юләр булганга гына аерылган. Ул хәзер Гәүһәрнең турылыклы булганын, һичбер вакытта да аңа хыянәт итмәвен аңлаган, ул Гәүһәрнең аягына егылырга әзер...

Бу уйлар татлы да, газаплы да, очы да, кырые да юк аларның. Гәүһәр бик озак уйланды. Аңа берәү дә комачауламады, өйдә бер кеше юк. Зәбирә түти һаман кайтмый иде. Тышта караңгыланса да, Гәүһәр ут кабызмады. Дәресләргә әзерләнәсе дә, дәфтәрләр карыйсы да бар. Ләкин уйларыннан аерыласы килмәде, алар җиңел канатларында аны тирбәтәләр кебек. Җәгъфәр килсә, ул аны ничек каршы алыр? Кая утыртыр, ни әйтер? Әйтәсе сүзләр, орышу, үпкәләр дә бик күп. Алары калып торсынмы? Билгеле, ансы ашыгыч түгел, соңыннан, җае туры килгәндә әйтелер. Зәбирә түти Җәгъфәрне, билгеле, яратмас инде. Соңыннан, Гәүһәргә яхшы булганын күргәч, ул да йомшар. Зәбирә түти — яхшы күңелле карчык, ул куенында Гәүһәргә таш асрамый. Тукта, кайчанрак килер икән ул Җәгъфәр? Хатның килгәненә байтак инде. Димәк, аның иртәгә үк килүе мөмкин, хәтта бүген үк. Әнә капка ачылды түгелме? Әйе, ачылды. Гәүһәр сагаеп көтә, бер, ике, өч... Гәүһәр урыныннан кузгалмый. Вакыт үтә, ишек ачылган яки ишек каккан тавыш ишетелми. Әллә нервлары бик киеренке булганга, Гәүһәр үзе алдандымы? Ахрысы, шулайдыр.

Гәүһәр тәрәзәдән карый. Тышта кар очкалый. Торып ут кабызгач өй эче берьюлы яктырып китте. Олы якка чыгып монда да ут кабызды. Тышта әүвәлгечә тынлык. Гәүһәр бервакытта да курку белми иде, бүген аңа нигәдер куркыныч булып китте. Әллә кайда гына, өй почмакларында нәрсәләрдер кыштырдый, шыгырдый, тәрәзә төбендә кемнәрдер йөри кебек. Яшел Ярда күпме торды, күзгә төртсәң күренмәслек кара төннәрдә дә кайтканы бар, әмма аның күңеленә бервакытта да шик

килмәде. Әлбәттә, бу тирән борчылудан, рухында Гәүһәр әле үзе дә аңлап житкермәгән кузгалышлар башлану алдыннан була торган хәл. Моннан котылу да юк, биш кат юрган астына кереп ятсаң да, күзләреңне чытырдатып йомсаң да, тонык күренешләр барыбер синең күз алдыңа киләчәкләр. Ичмасам, тизрәк Зәбирә түти кайтсын иде.

Зәбирә түти сәгать жиделәрдә генә кайтты. Вакыт күп түгел әле, иртә караңгыланганга гына соң булып күренә. Зәбирә түтине бер кардәшенә чакырган булганнар икән, шул кардәше кинәт авырып китеп, дөнья белән саубуллаша башлаган. Аны тынычландырып, врач чакырып китергәнче байтак вакыт үткән. Врач әллә ни куркыныч нәрсә тапмаган, бик каты салкын тидергән, ди, дарулар биргән.

— Мичтә аш калдырган идем, ашадыңмы?

— Ашадым, Зәбирә түти.

— Алайса ярый, хәзер чәй куям. Үземнең дә тамагым кипкән, авыру янында ашың аш буламыни.

Зәбирә түти, мич алдына үтеп, киемен алмаштырды да чәй куйды. Аннары олы якка чыгып өстәл хәзерли башлады, үзе гөлләр арасына утырып уйга чумган Гәүһәргә карап-карап алды.

— Бая, көндез, Талияне күргән идем. Бер галәмәт тузына. Сиңа да ачуы килгән, ахрысы. Ни кирәктер ул хатынга, һич аңламыйм.

— Миңа ни дип бәйләнә? Минем аның белән алыш-бирешем юк бит.

— Һай, алла! Аңа нигә синең алыш-бирешең?!. Теләнә килә — сөйли.

— Нәрсәмне яратмый соң минем?

— Һаман шул малае өчен... Минем багалмамны тартып алды, ди. Бик кирәксә, үз баласын интернатка урнаштырсын иде, ди. Мин, ди, барыбер Акназарымны аннан алам, ди.

— Акназарны ала? Әгәр ул әнисенә кайтырга теләмәсә?

— Менә шуны ишеткәндер дә инде...

Зәбирә апа кече якка чыкты, бераздан кайнар буларын бөркеп торган самоварын өстәлгә кертеп куеп, чынаякларга чәй коя башлады. Өстәлдә варенье белән ак күмәч бар иде, шуларны Гәүһәр алдынарак этәрде. Гәүһәр уйчан иде. Зәбирә түти, моңа бая ук игътибар итсә дә, берьюлы шул турыда сүз ачарга курыкты. Ул Гәүһәрнең холкы тигез булмавын белеп алган иде инде. Моңсу чагында Гәүһәр аз сөйләшә. Нәрсәдән бу — Зәбирә түти анык кына белми. Элекке тормышын сагына булса кирәк. Хәзер инде Зәбирә түти белә, Гәүһәрләрнең Казан уртасында менә дигән квартиралары булган, үз машиналары, дачалары... Ире зур галим, акчаны күп алган, ди. Билгеле, хатын-кыз боларны сагынмый булмас. Хәзер Гәүһәрнең нәрсәсе бар? Бернәрсәсе дә юк, ә хатын-кыз кешегә яңадан тормыш кору жиңел эш түгел. Зәбирә түти Әгъзәмнең дә ник йөрүен белә. Ул бераз кыюсызрак, ахрысы. Ә хатын-кыз андыйларны яратып бетерми бит. Бәлки, шуңа күрәдер, Гәүһәр аңа әле бик ягымлы була, әле салкынаеп китә. Менә хәзер дә Әгъзәмне телгә алмый, димәк, караңгы көннәр башлана. Зәбирә түти кайгы йотып яшәргә күнекмәгәнгә генә түгел, гомумән кешенең сагышка чумуын өнәмәгәнгә, Гәүһәрнең бу гадәтен яратып бетерми. Аңа күбрәк табын янында да, болай да шат көлү яңгырасын. Тормыш ике килми бит, ах-вах итеп кемне шаккатырасың. Ялгыз торган чагында да, рәтләп жырлый белмәсә дә, жырлый иде. Тик Гәүһәр килгәч кенә, юләргә санамасын дип, аның алдында жырламас булды.

— Гәүһәр, хәлең бармы, башың авыртмыймы? — диде ул ахырда, хәйлә белән.— Нигәдер бераз төсең киткән кебек.

— Хәлем дә бар, башым да авыртмый, Зәбирә түти, ә канатларым салынган.

— Кирәкми, Гәүһәрем, сагышка бирелмә. Менә минем ахирәт дус бер көн авырган да дөнья белән бәхилләшә. Без чакырып тормасак та,

актыккы көн килер, саулык бар чагында яшәп калырга кирәк. Бигрәк тә сезнең ише яшьләргә.

— Анысы шулай да, Зәбирә түти, уй баса шул...

— Уйны урамга чыгарып ат.

Гәүһәр сабыр гына елмайды.

— Моны бик акыллы кешеләр әйткән дә...

— Мин, Гәүһәрем, акыллылар рәтенә кермим. Рәтләп китап та укыганым юк, радиодан да җыр гына тыңлыйм. Мин ата-бабадан ишеткәнне сөйлим.

— Синең сүзләрең, Зәбирә түти, бик төпле, мин акылым белән аларны аңлыйм да. Тик йөрәкне генә берни эшләтә алмыйм...

Табынны икәү җыештырдылар. Аннары Зәбирә түти кече якка кереп китте, савыт-сабасын юа башлады. Хатын-кыз эше беркайчан да бетми бит. Нәкъ сихерле бер йомгак.

## 11

Бер көнне Гәүһәр мәктәптән кайтуга өстәлендә хат күрде. Ялгышмады, бу хат аңардан иде. Гәүһәр өс киемен дә салмыйча, аны бер дә, ике дә, өч тә укыды. Башта аны кызык бер тойгы белән алды, гүя бу хатны Җәгъфәр язмаган, ә нindидер бер ят кеше язган. Ялгышмыйммы дип, Гәүһәр хәтта кире адресына карады. Юк, шикләнергә урын юк, адресы да шул ук, кулы да шул ук — Җәгъфәр кулы. Тагын бер тапкыр укыгач, Гәүһәрнең шиге калмады, әйе, Җәгъфәр нәкъ шулай язарга тиеш. Башкача язса, ул Җәгъфәр дә булмас иде. Гәүһәрнең күзләренә яшь килде. Ләкин яшьләрен эченә йотты һәм янадан хатны кулына алды. Җәгъфәр, ниләр уйлавын, ниләр кичерүен бик тәфсилләп язганнан соң, Гәүһәргә мөрәҗәгать итеп, син теләсәң нишлә, теләсәң ничек уйла, мин синнән башка тора алмыйм, дигән. Шуннан соң, хат гүя бөтенләй үзгәрә. Бөтен эш гүя Гәүһәрдән генә тора. Әгәр ул үзенең иске хаталарын таныса, әгәр ул Җәгъфәрдән гафу үтенсә, әгәр ул Җәгъфәр алдына килсә... Тукта, бу нәрсә бу? Мин моны аңламыйм, Җәгъфәр. Бу синең шартларыңмы? — дип сорады Гәүһәр, хат урынында Җәгъфәр үзе утырып торган кебек.— Әйтерсең, минем нindидер хаталарым булган да мин аларны синнән яшергәнмен, алай гына да түгел, мин синнән бөтенләйгә китеп барганмын, имеш. Бу коточкыч бит, Җәгъфәр, син ничек шуны яза алдың? Шул ук вакытта син үзең турында чынлап торып бернәрсә дә әйтмисең. Гүя син сабый бала, синдә бер гаеп тә юк. Алай түгел бит инде, дип Гәүһәр әле һаман йомшак кына бәхәсләште. Кем инде синең җавап рәвешендә генә өйләнергә мәҗбүр булуыңа ышансын. Син бит югары белемле кеше, кандидатскийны яклаган. Хаталарыңның тамырын ачмасаң, яңадан бергә торырга мөмкинме соң? Ахыр килеп, бу базардагы алдымбирдем түгел бит. Син шуны һич тә аңламадыңмы? Мин генә гаепле булсам, эш бик җиңел булыр иде бит.

Дөресен әйткәндә, Гәүһәр Җәгъфәрдән теләсә нәрсә көтсә дә, мондый хатны көтми иде. Ул чиксез аптырап калды. Әлеге йомшак кына сөйләшүе дә шул аптыравының бер күренеше. Ул сүз таба алмады, шуңа күрә үзе дә белмичә башына ни килсә, шуны әйтте. Күрәсең, Җәгъфәр булып узган хәлләр турында җитди уйланмаган. Хәтта үзенең хаклы икәненә ышана. Монысы инде артыгы белән. Гәүһәр авырлыклар алдында тәмам курыккандыр, хәзер ул Җәгъфәрнең каршысына килеп, аягына егылыр дип уйлап, бөтен гаепне — булганын да, булмаганын да үз өстенә алыр, гафу үтенер, дип уйлыймы? Бу бит Гәүһәрне бөтенләй белмәү дигән сүз.

Гәүһәр бик гарьләнде. Җәгъфәргә моңарчы булмаганча үпкәләде. Хәзер инде аңа Җәгъфәрдән шулкадәр зур өмет белән хат көтүе дә гаҗәп. Юк, Җәгъфәр генә түгел, Гәүһәр дә Җәгъфәрне белми икән. Соң аңласа, башка төрле адым көтәр идеме аңардан? Җәгъфәр үзенә бертөрле дә хилаф эшләмәгән, ул йөзен тирәнрәк кенә ачкан, ә Гәүһәр шуны аңламаган. Без еш кына, кеше көмеш акча кебек ялтырап ята, дибез. Дөрес, ялтырап ята торгандыр, әмма аның эчендә нәрсә бар? Кешенең буе-сыны, өсте-башы гына кыйммәт түгел бит, аның йөрәгене белән сулый — менә шуны белергә кирәк.

Кеше аерым мохит эчендә яши. Аңа аерым нәрсәләр туктаусыз тәэсир итеп торалар. Тик кайбер тәэсирләр шулкадәр кечкенә була, кеше хәтта аларның барлыгын да сизми. Кайсыберләре, киресенчә, үзеннән көчле күренәләр, кеше алар тәэсиренә бирелеп, байтак вакыт үзен кая куярга белми йөри. Ләкин бу тәэсирләр ике котыптан гына тормый, кеше дигәнең үзе чиксез катлаулы булган шикелле, аның тәэсир чыганаклары да санап бетергесез. Гәүһәрнең уй агышы үзгәргән икән, моның сәбәпләрен кем әйтә алыр? Бәлки, теге-бу укытучының узып барышлый гына ташлаган сүзе аңа тәэсир иткәндер, бәлки балаларының шаяруларында ул нәрсәдер ишеткән күк булгандыр, бәлки Зәбирә апа эш арасында гына аңа берәр хикмәтле сүз әйткәндер, бәлки ул үзе озак уйлау аркасында шул нәтиҗәгә килгәндер,— ничек кенә булмасын, аның фикер агышы үзгәргән. Ләкин, дип уйлады ул хәзер, хат хат инде ул, нинди моментта языла да, кем йогынтысында языла. Җәгъфәрнең үз башы белән генә эшләмәве хәзер Гәүһәргә ачык. Фая киткән, димәк, монда аның тәэсире юк. Дидаровның? Белмим, бу очракта ул да читкә китәргә тиеш кебек. Гәүһәрнең белгәннәре шулар. Ә белмәгәннәре? Дөнья кадәр! Шуңа күрә, Гәүһәр хатка бик үк ышанмаска булды. Әйе, аны тулысынча чыгарып ташларга да ярамый, шулай да бөтен ышанычны да аңа салырга ярамый. Иң мөһиме Җәгъфәрнең үзе белән сөйләшү. Кайчагында синең чак кына каршылыгың да кешенең бөтен уйларын үзгәртеп җибәрә бит. Аннары Җәгъфәрнең үзенең дә сөйләшергә нияте бар бугай, элеккечә тоткан җиреннән сындырмый. Кышкы каникулларны көтәргә кирәк. Менә шунда Җәгъфәр белән дә иркенләп сөйләшер...

— ...Нәрсә әйтим сиңа, Гәүһәр бәгырем,— диде Бибинур, Гәүһәрнең сүзләрен тыңлагач.— Бер тапкыр сиңа әйткән идем дә бугай. Кеше акылы белән эшләнә торган эш түгел бу. Бигрәк тә мин үзем Җәгъфәрне бөтенләй белмим. Аны мактый да, хурлый да алмыйм. Аерылу да, кушылулар да тормышта була торган хәл. Сәбәпләре дә төрле. Син миңа бик аз сөйләдең, бик бер яклы сөйләдең. Хәзер мин моны аңлыйм. Син башкача булдыра да алмас идең. Әгәр теләсәң, мин сиңа йөрәгем кушканны гына әйтә алам. Кара, үзең хәл ит, минем әйтүем кирәкме, әллә әйтмәвем хәерлерәкме? Минем сүзләремнән сиңа җинел булмас бит.

— Зинһар, кызгану хисе белән эш итмәгез. Мин үземне кызгандыру теләге белән сезгә килмәдем.

— Җәгъфәрне сез киселгән кисәк итеп карамагансыз икән. Димәк, сезнең әле тагын нииндидер яшерен өметләрегез бар. Миңа килгәндә... Билгеле, тормышта ялгыз башыңа бик авыр, чамасыз авыр. Шулай да мин кушылырга ашыкмас идем. Син гел үзеңнең кире кайтканыңны уйларсың, ә ул үзен һичбер гаепсез санар. Калганын үзең кара инде, Гәүһәр. Монда, әйтәм бит, киңәш тә биреп булмый.

— Рәхмәт, Бибинур апа. Мин уйлыйм әле. Каникулга ике атналап вакыт бар. Аңарчы әле, бәлки, кайбер нәрсәләр ачыкланыр да. Ачыкланмаса да, үзем шактый тынычланырмын.

## ДҮРТЕНЧЕ БҮЛЕК

### 1

Кышның салкыннарын күрсәтә торган чагы булса да, һавалар өенче көн инде җылытып тора. Билгеле, яңгыр яумый, тамчы таммый, шулай да җил әллә кайдан гына яз исен алып килә, көн урталарында кояшка каршы хәтта бияләйләрне салырга мөмкин. Кар ап-ак булса да, салкын түгелдер шикелле, гүя ап-ак мамык төшәп киткәннәр. Бигрәк тә самолетта очканда бу тойгы көчәя. Бу якларда тоташ кар далалары аз, агачлар күптән каралган инде. Кырда шундый аклык һәм пакьлык — самолеттан сикереп төшәсе килә. Гәүһәрнең мондый йомшак аклыкны гомерендә күргәне юк әле. Элек әйтсәләр дә, бик үк ышанмас иде. «Алданса, күңел алдана икән!» дип уйлады ул.

Гәүһәрне каршы алучы юк. Кем каршы алсын, кем көтсен. Тиз генә автобуска кереп утырды. Озакламыйча машина, авыр үкереп, киң юлга чыкты.

Еракта Яшел Яр шәһәрчеге күренә башлады. Аңа якынлашкан саен юллар карала бара. Бер мәл Кама күренеп китте, ләкин ул тирән кар астында әле. Әнә беленер-беленмәс кенә сукмак сузыла, кешеләр йөри. Кама өстендә кешеләр йөри!

Автобус шәһәрчек урамнарыннан бара башлады. Бүген урамнарда кешеләр күбрәк кебек. Йөзләре дә көләч сыман. Нинди шатлыклары бар? Гәүһәрнең аларны болай күргәне дә юк иде шикелле. Кызык икән, тора-тора үз шәһәреңне яңадан ачасың! Якындагын яхшырак күрер өчен каядыр еракка барырга кирәк дип сөйлиләр, чын икән. Машинадан төшкәч, бу тойгы тагын да көчәйде. Әллә нинди күрмәгән, белмәгән ят кешеләр, туктатып, исәнлек-саулык сорашалар, кышкы имтиханнарны уңышлы бирүе белән котлыйлар. Каян белгәннәр икән, гаҗәп. Гәүһәр беркемгә дә әйтмәде кебек. Ярый әле, кешеләр барысын да шул укуга гына кайтарып калдыралар. Чынлап карасаң, Гәүһәрнең башында бер уку кайгысы гына идеме? Үз-үзен өзгәләрдәй булып елаган чаклары да, акны-караны күрмичә институттан кайткан чаклары да бу уңунбиш көн эчендә аз булмады аның. Инде болар һәммәсе дә, һәммәсе дә артта калды, ул җиңел сулап үзенең бәләкәй шәһәрчегенә кайта. Озакламыйча Зәбирә апаның капкасын ачып керер.

Гәүһәр үзендә сүз белән аңлатып булмый торган бер җиңеллекме, тагын башка бер нәрсәме ачык тоя. Анда, Казанда, бу хис бөтенләй юк иде, ул өстенә бинибәя авыр йөк салган кеше кебек иелә-сыгыла йөрде. Ярабби, бу хатын исерек дип тә уйлаганнардыр очраган кешеләр, бәрелмәсен, кагылмасын дип читкә тә тайпылганнардыр. Һава нинди сөремле, караңгы иде. Тик имтиханнарны биргән бүлмәдә генә бераз яктырак булып, сулыш алулары иркенәя төшә иде. Ә хәзер ул тәмам җиңеләйгән кебек, кайгы-хәсрәте — барысы да самолет ишеге төбендә торып калды кебек. Хәзер мөмкин булса, йөгереп тә китәр, җырлап та җибәрер иде. Ләкин ул боларны берсен дә эшләми. Күзгә күренмәгән җепләр бәйләп тота кебек.

Казанда чакта Гәүһәр Әгъзәмне бер тапкыр күрде. Ләкин сөйләштеме икән? Хәтерләми. «Мин сиңа ышанам, син акылын кушканча эшләрсең». Бу сүзләрне Әгъзәм әйттеме, әллә Гәүһәр соңыннан уйлап чыгардымы? Юк, әйтте шикелле. Тагын нәрсәләрдер әйтте, Гәүһәр боларның барысын да үз башыннан чыгара алмас иде. Әгъзәмнең институтка килүе хак. Гәүһәр чираттагы имтиханын тапшырып чыгып килә иде. Андый чакта бит кешенең туктаусыз сөйлисе килә, гүя ул барысын да бик яхшы белә, кай төшеннән кушсалар, шул җиреннән шартлатып әйтеп бирер кебек...

Менә шул уйларны күңеленнән кичереп чыкканда аңа институт коридорында Әгъзәм очрады.

— Әгъзәм... Син кайдан? Син ничек монда? — дип сорады Гәүһәр.

Әгъзәм берничә көнгә генә Казанга киңәшмәгә килгәнен әйтте. Коридорда бер буш урындыкка утырып сөйләштеләр дә шикелле. Нәрсә турында? Гәүһәрнең хәтерендә ачык калмаган. Шунда Әгъзәм: «Мин сиңа ышанам, син күңелең кушканча эшләрсең», диде. Ул чакта Гәүһәр аны тизрәк кайтарып җибәрергә ашыкты, чөнки менә-менә Җәгъфәр килергә тиеш иде. Сүзләрнең мәгънәләре турында уйлау аның башына да килмәде. Аерылышкан чагында гына, аңлаудан битәр сүз өчен генә кабатлап әйтә куйды: «Миңа үземә уйларга вакыт бир әле, моны мин үзем хәл итәргә тиешмен», диде. Әгъзәм үз сүзләрен көчләп тагарга тырышмады. Гафу үтенде дә китеп барды. Гәүһәр тиз генә бер буш аудиториягә керде һәм Әгъзәмнең чыгып киткәнен көтте. Әгъзәмгә минем тагын имтиханнарым бар, дип әйтте бугай. Хәлбуки, ул көнне аның бүтән имтиханы юк иде. Соңыннан Әгъзәм тагын ике тапкыр институтка килгән булган да Гәүһәрне очрата алмаган. Кайтыр алдыннан ул Галимҗан абыйларга да кергән, язу язып калдырган. Гәүһәр аңа адрес бирмәгән иде, күрәсең, Бибинур ападан алган булгандыр. Ул көнне Гәүһәр гадәтенчә соң кайтты, кәефе начар иде.

— Имтиханнарыңны тапшырдыңмы? — дип сорады Рәхимә апа, Гәүһәргә аш җылыта-җылыта.

— Тапшырдым, Рәхимә апа.

— Алайса ярый. Мин тагы әллә нәрсәләр уйлап беттем... Сиңа записка бар. Көтте-көтте дә, син кайтмагач, самолетка ашыгам, дип китеп барды.

Гәүһәр, апасының сүзләрен ишетсә дә, мәгънәсен аңламады, язуны укыды, аның да мәгънәсен аңламады булса кирәк. Кухняга чыгып тамагына капкалады. Шуннан соң гына аңына килгәндәй, тиз генә урыныннан торды. Әгъзәмнең язуын кабат укып чыкты. Тиз генә сәгатенә карап алды. Тагын егерме минуттан самолет очарга тиеш.

— Рәхимә апа, мин аэропортка барам, самолет әле китмәгәндер,— диде һәм, пальтосының төймәләрен дә төймәләмичә, баскычка йөгерде, урамга атылып чыкты.

— Зинһар, аэропортка... тизрәк,— диде.

Такси шоферы сүзсез генә башын иде. Син ашыкканда ул кабалана дигәннәр, чат саен кызыл светофорга туры килделәр. Ниһаять, туры урамга чыктылар, машина кош кебек очты. Бер-ике минуттан инде алар аэропорт каршына килеп туктадылар.

Гәүһәр аэропортта справочныйдан Яшел Ярга оча торган самолетны сорады.

— Хәзер китә,— диде белешмә бирүче кыз.

Гәүһәр перронга йөгереп чыкканда, самолет инде кузгалган иде. Ул әле җирдән бара. Менә самолет еракка китеп борылды, аннары үкереп җибәрде, бер минуттан инде болай таба кызулап килә башлады, тәгәрмәчләре җирдән аерылды. Ул да булмады, өскә күтәрелеп, вокзал турысыннан узып китте. Озатучылар дәррәү кул болгадылар, аннары, самолет күздән югалгач, таралыша башладылар.

Гәүһәр иң актыктан чыкты. Күңелендә бер уй: ул аны Әгъзәмгә әйтергә теләгән иде, әйтә алмады. Бәлки хәерлегәдер, бәлки... Гәүһәрнең күзенә яшь килде. Озатучылар арасында күз яшьләрен сөртүчеләр байтак булганга, Гәүһәргә берәү дә игътибар итмәде. Вокзал почмагында ул күзләрен сөртте дә җәяүләп кенә кайтып китте.

Бераздан Әгъзәм бөтенләй онытылды, әйтерсең, самолет аның турындагы уйларны да алып китте. Хәзер бер Җәгъфәр генә калды. Ул көн дә бер сәгатьтә Гәүһәр янына килә, бик җитди, бик эшлекле кыяфәттә Гәүһәр белән күрешә, аннары урамга чыгып китәләр. Күп вакытта

гомердә йөрмәгән буп-буш урамнар буйлап йөриләр, кайчан, бик салкын булса, киногада керәләр. Җәгъфәр ничә тапкыр Гәүһәрне өенә чакырды, Гәүһәр баш тартты. Ул сизә иде, әгәр барса, Җәгъфәр үзенең иркәләүләре белән аның бөтен ихтыяр көчен алачак, аннары инде Гәүһәр бар нәрсәгә дә риза булачак. Кайчагында Гәүһәр Җәгъфәрнең аһ-зарлары алдында бөтенләй коралсызланып кала яза, тагын аз гына омтылса, Гәүһәр бөтенләй бетәчәк кебек. Хәлиткеч минутта Гәүһәр үзендә нинди дер яшерен көч таба, горурлыгын, намусын саклап кала.

Тагын аның бер генә имтиханы калды. Моңарчы булганнары ничектер чагыштырмача җиңел тапшырылды, соңгысы Гәүһәрне нигәдер бик куркыта. Бу имтиханны Гәүһәр җиңә алмас, ул үзе Гәүһәрне «егар» кебек. Имтихан сәламәт кешедән дә күп көч сорый, Гәүһәр кебек көчен башкага сарыф иткән кешене әйтмисең дә инде. Бүген ул көне буе укыса да, башында берни дә калмады. Аэропорттан җәяү кайтуының сәбәбе дә шунда: саф һавада зиһене ачылмасмы дип уйлады ул. Кайтып, дәресләргә утырырга кирәк бит. Бу тубал баш белән ничек утырасың инде.

Җәгъфәр белән өзеп бер нәрсә дә сөйләшенмәгән булса да, Гәүһәр аны артык көтми иде инде. Әллә Җәгъфәрнең барыбер киләсен белгәнгәме, әллә башка бер сәбәптәнме, бүген ул тыныч. Иртәгә дә Җәгъфәр үткәндәгеләрне кабатлар, яңа бернәрсә дә әйтмәс. Нигә ул шундый? Гәүһәргә ни кирәген белмиме соң ул? Гәүһәр ничә әйтте бит. Җәгъфәр һәрвакыт сүзне сиздермәстән генә икенчегә бора. Әллә сүзгә мавыгып моны сизмиләр дип уйлыймы? Ихтимал, аның бүтән әйтер сүзе юктыр? Ул чагында шулай туп-туры әйтергә дә кирәк, сәгатьләр буе урам таптаудан ни мәгънә? Гәүһәр аны акыллырак дип, тирәнрәк дип уйлый торган иде. Шулай ук ул... Юк, моңа ышанасы килми. Иң хәтәр минутларда да уеннан чыгармый йөртте бит ул аны. Шулай ук ул өметсез алданган идеме?

Иртәгә Гәүһәрнең көне бик авыр булачак, имтиханы ничек булыр да, Җәгъфәр белән сөйләшүләре ничек үтәр. Гәүһәр белә: өметеңне бөтен дөньядан яшереп йөртсәң дә, бер тапкыр аны ахыргача ачарга кирәк. Я син аңа ышанасын да бөтен киләчәгеңне аның белән бәйлисең, я аңардан өметеңне өзәсең дә бөтенләй яңа юлдан китәсең. Тегесе дә, монысы да Гәүһәрне куркыта. Тегесе дә, монысы да караңгы.

Ул инде чатка җиткән иде. Монда троллейбуслар да йөри, трамвайлар да. Гәүһәр бераз уйлап торды да тагын бер остановка җәяү барырга булды. Көтелгән сафлану килмәгән иде әле.

Гәүһәр Җәмиләне исенә төшерде. Аның, инде Казанда күптән булса да, бу кыз янына бара алганы юк иде әле. Вакыт та тар, ләкин эш анда гына түгел. Җәмилә, һичшиксез, сүзне ахыр килеп абыйсына кайтарыр. Гәүһәр ни әйтер?

## 2

Гәүһәр, соңгы имтиханнан бик курыкса да, нәкъ шуның киресе булárак, бик ансат тапшырды, хәтта башын да ватмады. Ихтимал, сораулары бик җиңел туры килгәндер, ихтимал, сораган кадәресен үзе белгәндер, ничек булса да булгандыр, кулына имтихан кенәгәсен тотып укытучы яныннан чыгып киткәнен үзе дә сизмәде. Аудитория ишеген япкач, беркадәр вакыт, ах җыеп, шунда басып торды. Кемнәрдер килеп нинди сораулар эләкте? дип сорадылар, аннары китеп, тиз генә дәфтәрләренә төртелделәр.

Ишек янында өстенә соры каракүл якалы кара пальто, пыжик бүрек кигән, озын буйлы карап торырга бик интеллигент кыяфәтле күренгән Җәгъфәр Мәүлиханов басып тора иде. Алтын күзлектән, кулында күн папка.

Башка көннәрдә Гәүһәр аны күрүгә эчтән генә булса да шатлана иде, бүген ул аз гына да куанмады, гүя Җәгъфәр институт коридорында йөренгән йөзләрчә кешеләрнең берсе.
Җәгъфәр коридор буйлап килгән Гәүһәрне күреп алды, тиз генә аның алдына килде.
— Әйтмә, кирәкми,— диде ул, елмаеп,— мин барысын да беләм. Йөзең әйтә, барысы да яхшы. Шулай бит?
— Әллә тагы... Тапшырдым.
— Бик яхшы булган. Димәк, бүген актыккысы инде?
— Әйе, иртәгә кайтып китәм. Хәзер яшел булмаса да, Яшел Ярымны сагындым.
Бу сүзләргә каршы Җәгъфәр берни әйтмәде, киемнәр бүлмәсе янында Гәүһәрнең киенгәнен көтте дә, алар урамга чыктылар. Урамда халык мыж килә, күбесе кулларына сумка тотып, базарга ашыгалар. Кайчандыр Гәүһәр дә базарга йөри иде.
Алар сүз куешып түгел, кеше аз булганга гына Болак буйлап киттеләр. Җәгъфәр шунда ук сүз башлады. Гәүһәр белеп алган иде: Җәгъфәрнең сүзе ничек кенә һәм кайдан гына башланмасын, һаман бер тирәдәрәк әйләнә. Тыштан күрсәтмәсә дә, бүген ул да аз гына дулкынланган, актыккы сөйләшү икәнен сизә. Ни булса да бүген була. Тик Гәүһәрнең артык тыныч булуы гына аңа ошап бетми. Кичә сөйләшәсе калган, кичә Гәүһәрнең җаны болай тыныч ук түгел иде. Җан тыныч булмаганда, ни сөйләгәнен кеше үзе дә белми.
— Ярый инде,— диде ул, тирән сулап,— хаталар бик күп булды, ахмаклыклар җитәрлек эшләнде. Әгәр шунда нокта куймасак, алар эшләнүдә дәвам итәчәк. Безгә озын юлны бергә үтәсе бар. Хаталарны кабатларга без ул хәтле яшь тә түгел. Кыскасы, алсу томаннардан арынырга вакыт. Тормышның үз буяулары бар. Әгәр чынлап карый башласаң, алар бик үк ямьле дә түгел.
Җәгъфәрнең сүзе күп була, кирәк икән, тоташ берничәшәр сәгать сөйли ала. Әмма Гәүһәр никадәр калтыранып көтсә дә, ул бер тапкыр да гади сүзләрне әйтмәде. Бүген, әгәр бер-бер борылыш ясалмаса... Ләкин Җәгъфәр үзенә хыянәт итми, тел төбе һаман бер, аныңча, килеп чыккан күңелсезлекләрдә бары тик Гәүһәр генә гаепле, әгәр ул акыллы булса, мондый хәлләр һич буласы түгел икән, чөнки Җәгъфәр тузан кадәр дә хата ясамаган, ул бары тик... мәҗбүр булган.
Әлбәттә, Гәүһәр үз гаебен дә инкарь итми, кызу чакта башны иясе, сүз катмыйсы, түзәсе, салкынрак акыл белән эш итәсе урында ул тотты да китте, семьядан гына түгел, Казаннан ук китте.
— Җәгъфәр, күрәсең, без бер сүзгә килә алмабыздыр. Син гел үз туксаныңны туксан дисең. Әйтерсең, мин каршы киләм, теләмимм, бөтен эш миндә генә. Мин сиңа ничә аңлаттым инде...
— Юк, Гәүһәр, юк, син... Без аерым-аерым тора алмыйбыз. Син миңа һава кебек кирәк! — диде Җәгъфәр, Гәүһәрнең тел төбе кай якка таба баруын сизеп алып.
Гәүһәр ачы көлемсерәде.
— Өй караучы булыпмы, аш пешерүче булыпмы? Синең бар капризыңа да баш иеп торыр өченме?
— Гәүһәр, зинһар, юк нәрсәләрне тезмә. Алайга китсә, мин дә әллә нәрсәләр тезә алам. Моның кирәге бармы? Бер-беребезне без болай да җитәрлек кимсеттек.
— Мин сине кимсетмәдем, сиңа кара елан дип әйтмәдем.
— Зинһар, кирәкми. Кызулык белән әйткәнмен икән... Нигә аларны телгә алырга?!
— Мин бик алмас идем дә, синең каныңда шул бит. Хәзер син барысына күз йомасың, ә соңыннан йөземә бәреп әйтәчәксең. Юк, Җәгъфәр,

без бер кискәнне ялгый алмыйбыз. Мин төрле яклап уйладым. Синең белән сөйләшкәнгә кадәр минем әле ниндидер ышанычым бар иде. Бәлки үзгәргәнсеңдер дип уйлаган идем. Хәзер барысы да...

— Алай димә. Әгәр теләсәң...

Алар стадион янына җиттеләр, яңа каток бинасы кырыеннан уздылар. Бик шәп бина икән. Әйләнә-тирәдә бишәр катлы торак йортлар, шунда ук гостиница, искиткеч яхшы стадион. Карыйсы иде шуларга, шатланасы, сөенәсе иде, ләкин бу ике кешенең сүзләре бу тирәдән бик ерак. Җәгъфәр бу тирәләргә рәтләп карамады да, Гәүһәр шулай ук йөгерек бер караш кына ташлады.

— Аннары син үзең...— диде ул, тирән хәвеф белән,— син үзең... әз генә уйлыйсыңмы? Синең бит башкаң бар. Әгәр ул... яңадан... кайтып керсә, синнән гафу үтенсә...

«Бу тагын нәрсә?» дигән шикелле Җәгъфәр Гәүһәргә тиз генә карап алды, аннары, башын артка ташлап, кычкырып көлеп җибәрде.

— Кайтса... Кем кертә аны. Үзе киткән икән...

— Алай җиңел карама әле... Бик җитди бит... Ул да, ахыр килеп, кеше бит,— диде Гәүһәр.

— Бик яхшы, ләкин бу турыда ул элек уйларга тиеш иде. Берәү дә аның башын кисеп алмаган бит.

Җәгъфәр сәгатенә карап алды, Гәүһәрне өенә чакыра башлады. Инде институттан чыкканга да ике сәгать чамасы булды. Гәүһәр арыгандыр, тамагы ачыккандыр. Җәгъфәр буфеттан пешкән тавык алып кайткан булган, торты да бар, чәй хәзер кайный. Печеньелары да, тагын нәрсәләредер бар бугай. Калганын шушы чәй янында ашыкмыйча сөйләшергә мөмкин. Анда берәү дә комачауламаячак. Иң мөһиме,— ул усаллыксыз гына көлеп алды,— икесе юлның ике ягыннан бармаячак. Уйлары да бер юнәлештә агачак. Соң, аларны әллә нинди коточкыч нәрсә аерамыни, Араларында кеше үтә алмаслык идея каршылыклары бармыни? Юк бит. Килешү өчен Гәүһәрнең бер сүзе җитә. Аннары инде ул сүзне телгә дә алмаслар, аның кирәге дә булмаячак.

Гәүһәрнең иртәдән бирле бер валчык капканы юк, нибары бер стакан чәй генә эчкән иде. Ләкин бу юлы да ул Җәгъфәрнең тәкъдимен кире какты.

— Җәгъфәр, мин инде сиңа ничә әйттем... Синең өеңә... бара алмыйм. Анда...

— Әллә ниләр уйлап чыгарасың, Гәүһәр.

— Юк, әллә ниләр түгел.

— Акылга җиңеләя башлагансың дисәм, артык каты булыр, шуңа барасың түгелме, Гәүһәр? — диде ул, борчылып.

— Белмим, син теләсәң ничек уйла. Мин үзем уйлаганны әйттем.

Җәгъфәр туктады, Гәүһәргә баштанаяк карап алды. Йөзе үзгәреп китте, күзләре кечерәйде. Бу аның салкын канлылыгын югалта башлавы иде.

— Гәүһәр,— диде ул әллә нинди тавыш белән,— мин кулымнан килмәстәйне дә эшләдем. Артык булдыра алмыйм. Болай урам таптап берни чыкмас. Син бик нык үкенерсең, тик эш узган булыр. Әйе, әйе. Мин үз хаталарыңны үзең аңларсың дип уйлаган идем. Син һаман киресен сукалыйсың, бөтен гаепне миңа өймәкче буласың. Әйе, әйе, күрәм мин моны. Син үзең акыллы булгач та, башкалар шәрран-яра тиле дип уйлыйсыңмы? Берни дә әйтмәгәч, бу бернәрсә дә белми дип фараз итәсеңме? Синең анда Билал Шәңгәрәевләрең, а-лә Алчыннарың булганы безгә билгеле түгел дип беләсеңме? Я, нигә шулхәтле агарындың? Белмәсләр дип уйлаган идеңме? Без әле синең Әгъзәм-Мәгъзәм дигән асыл кошыңны да беләбез. Син минем белән сөйләшкән чагында да аны монда чакыргансың бит. Ничә мәртәбә ул институтка килгән. Аннары син аны аэропортка да озата төшкәнсең...

— Күрәм, син чыннан да барысын белгәнсең икән, Җәгъфәр,— диде, ниһаять, Гәүһәр. Ул чамасыз агарган, чак аягында тора иде.— Ниһаять, син үзеннең чын уйларыңны да беркадәр ачтың. Син аларның меңнән берен генә әйттең. Әгәр мин синең тәкъдимеңә күнсәм, син аларны әкренләп барысын әйтәчәк идең. Синең уең, мине әкрен-әкрен агулап, үзеңнең колың итү иде. Минем актык минуткача моңа ышанасым килмәде. Мин сине үзгәргәнсең, яңаргансың дип уйлаган идем. Юк, син бүлдермә. Мин сине тыңладым, инде син мине тыңла. Мин сине үлеп ярата идем, сине башка кеше дип йөри идем. Аерылганнан соң да күңелемнән чыгарып ташлый алмадым. Хәтта син кабат өйләнгәч тә сиңа булган мәхәббәтем җилгә тузып бетмәде. Элекке кебек булмаса да, әле нәрсәдер калган иде. Бүген барысы да бетте. Мин сиңа һич үпкәләмим, син бервакытта да үзеңә хыянәт итмәдең. Мин үземнең шулкадәр сукыр булуыма гына гаҗәпләнәм. Теге вакытта без синең белән чынлап торып аерылмаганбыз икән, инде хәзер мәңгегә аерылабыз. Мин күңелемдә һичбер авырлык тоймыйм. Син дә шулайдырсың дип уйлыйм. Һәрхәлдә, шулай булырсың. Әнә синең троллейбусың килә. Хуш.

Җәгъфәр саубуллашмыйча кырт борылып китеп барды. Гәүһәрдән коточкыч авыр сүзләр ишетсә дә, бөртек тә шикләнмәде, аның әллә кая барыр җире юк, ул барыбер Җәгъфәр артыннан килер. Хатын-кыз шулай үзенең бәясен күтәрергә ярата. Троллейбуска кадәр ул артына борылмады. Вагонга утыргач кына тәрәзәдән карады. Гәүһәр аңа таба бер адым атлады кебек. «Шулай, атларсың әле!» дип уйлады ул.

Әмма Гәүһәр урыныннан кузгалмады, троллейбус ераклаша барса да, ике арадагы яшерен җеп сузылмады. Күрәсең, ул күптән өзелгән иде инде, тик Гәүһәр генә аны өзелгәнгә санамаган, юк нәрсәгә ышанган. Ярый, ахыр килеп, Гәүһәрнең күз аллары ачылды. Җиңел сулап куйды. Аннары ул урам буйлап Галимҗан абыйларга таба китте. Әлбәттә, аңа троллейбуска утырырга да кирәк булыр. Әзрәк суынгач утырыр да. Хәзер суынырга кирәк.

## 3

Зәбирә тутиләргә житәрәк, Гәүһәрне бер төркем мәктәп балалары каршы алды. Алар арасында Зилә белән Акназар да бар иде. Балалар шундый шатландылар, әйтеп тә бетерерлек түгел. Күрәсең, алар да нидер сизенгән булганнар. Гәүһәрне күргәч, бер мәл текәлеп карап тордылар. Шул аз гына вакыт та аларга барысын аңларга җитте булса кирәк, икенче секундта алар барысы, кычкырышып, Гәүһәр апаларына ташландылар. Әй сикерешәләр, әй бер-берсен бүлдерешеп кычкырып сөйлиләр, Гәүһәр берьюлы балалар дөньясына чумганлыгын сизде. Ул балаларның үзен бигрәк сагынганлыгын аңлады, үзе дә аларны ким сагынмады. Кемнәрдер аның чемоданын җилтерәтеп алып киттеләр. Гәүһәр, чебиләр арасындагы тавык кебек, балалар белән сөйләшеп кайтты. Әйтерсең, балалар янында ул ике атна түгел, ким дигәндә бер ел булмаган!

Капка төбендә алар дәррәү туктадылар. Гәүһәр балаларны өйгә чакырды, балалар бертавыштан, икенче вакытта керербез, диделәр. Ул арада чемоданны алдан алып киткән балалар да чыкты.

— Чемоданыгызны, Гәүһәр апа, өйгә кертеп куйдык,— диделәр алар. Шуннан соң алар шау-гөр килеп кайтып киттеләр. Гәүһәр яктырып киткән күзләре белән балалар артыннан бераз карап торды да капкага таба борылды. Менә кары чиста итеп себерелгән бәләкәй ишек алды. Менә өй алдының бәләкәй генә ишеге.

Зур йортка иелеп кергәнче, бәләкәй йортка бөгелмичә кергәнең мең артык. Гәүһәр бу сүзләрне кайдадыр ишеткән идеме, укыган идеме,

әмма хәзер шушы бәләкәй ишек каршында кинәт туган булып тоелды ул сүзләр. Ул эчке шатлык белән Зәбирә түтинең бәләкәй ишеген ачты.

— Әем генә,— диде Зәбирә түти, ике кулын чабып,— кемне күрәм. Гәүһәрем кайтты түгелме?

Гәүһәр сораша-сораша, сөйләшә-сөйләшә чишенде, үз бүлмәсенә кереп күз йөгертте. Һичнн үзгәрмәгән, бар да шул көенчә, тик тузаннары гына сөртеп алынган, аннары өйгә яздырган газета-журналлар тәртип белән өстәл читенә өеп куелган. Шунда ук ике хат. Берсе Ленинградтан, Билал Шәнгәрәевтән, кире адресы бик ачык язылган, икенчесенең кире адресы юк. Кемнән булыр икән? Хәзер Гәүһәр бер кемнән дә хат көтми иде, шуңа күрә хатлар аны беркадәр гаҗәпләндерде. Иң элек Шәнгәрәевнең хатын ачты. Хат артык озын түгел. Төп яңалык — Билал Шәнгәрәев өйләнгән. Кемгә, ничек — анысын язмый.

«...Сине һич оныта алмасам да, син теләмәгәч, бүтән чарам калмады. Белмим, башка белән мин бәхетле булырмынмы, аны да сине яраткан кебек ярата алырмынмы — киләчәк күрсәтер. Бу хатны язуымның сәбәбе башкада. Әлбәттә, түем турында сиңа мактанып хәбәр итәргә дә уйламадым. Мин Җәгъфәр белән бервакытта да сөйләшмәдем, син рөхсәт итмәдең, ә моннан бер ай элек аның үзеннән хат алдым. Билгеле инде, ирле хатыннарга күз атуым өчен ул мине эт итеп сүккән, киләчәктә дә моны онытмавын искәрткән. Анысына минем исем китмәде. Мин сине яратып йөрүемне хатынымнан да яшермәдем, барысын ачыктан-ачык аңа сөйләп бирдем. Сөйләмәсәм дә ышанмас иде, чөнки минем яшемдәге егетләр хатын-кызга бер карамый булдыра алмый, зур мәхәббәт кенә аларны бозыклыктан саклап кала ала. Ни булса да, шундый мәхәббәткә сәбәпче булуыгыз өчен мин сезгә рәхмәт әйтергә тиешмен. Син миңе бер адым да якын җибәрмәдең, әмма үз чиратымда мин мәхәббәтемә турылыклы булдым. Менә Җәгъфәргә гаҗәпләнәм. Шундый укымышлы кешедә шундый түбән әхлакый җан. Мин бит синең кыз чагыңны беләм, беренче мәхәббәтем дә шунда уянган иде. Син Җәгъфәргә чыккач та, онытырга теләп тә, сине оныта алмаганмын икән, монда мин гаеплемени? Һәрхәлдә, син миңа юләрләнергә бертөрле дә сылтау бирмәдең. Ихтимал, син иреңә бик турылыклы булырга тәләгәнсеңдер. Ни әйтим? Җәгъфәрнең шундый түбән җан икәнен белгәч, мин бик кайгырдым, синең өчен кайгырдым. Әлбәттә, син миннән бертөрле ярдәмемне дә кабул итмәс идең. Бер-бер нәрсә әйтсәм, киресенчә, мине түбән җанлылыкта гаепләр идең. Хәзер инде мин башка кулында, аңа хыянәт итәсем юк, шуңа күрә бу соңгы хатны сиңа язарга булдым. Җавап көтмим, аннары син язмассың да. Ни генә булса да мин сиңа тормышта үз бәхетеңне табуыңны телим.

*Хөрмәт белән Билал Шәнгәрәев».*

Бу хатны укыгач, Гәүһәр тирән уйга калды. Җәгъфәр турында ул уйламады, Гәүһәр өчен бу хат Җәгъфәрне артык ачмый да иде. Әмма Билал... Гәүһәрнең аны әрләгән чаклары булса да, аңа бервакытта да чынлап торып ачуланмады. Ләкин Билалның шундый намуслы булуын күз алдына китермәгән иде. Чын күңеленнән шатланып, бу хаты өчен аңа рәхмәт укыды. Шундый кешенең үзен еллар буе яратуы өчен горурланып та куйды. Ахыр килеп, аның өйләнүенә дә кинәнде. Бәхетле булсын!

Икенче хат... Алчыннан булып чыкты. Хәтта бер җирдә дә аның имзасы булмаса да, Гәүһәр аны беренче сүзеннән үк таныды. Хатны укып чыккач, ихтыярсыздан көлеп җибәрде. Алчын үзен әзәрлекләмәвен үтенгән, болай да мең газаплар кичерүен язган.

Күрәсең, бу Җәгъфәрнең эше, Гәүһәр аны әзәрлекләү түгел, исемен дә телгә алмады.

Хатларны укып бетергәч, Гәүһәр Зәбирә түти янына чыкты.

— Әйдүк, Гәүһәрем, утыр. Син киткәннән бирле чәем чәй булмады. Бер тәме дә юк.

Гәүһәр чемоданын ачып конфетлар алды, Рәхимә апа әллә нинди чәкчәкләр куйган. Аларны чыгарды.

— Бигрәк миһырбанлы кешеләр икән Рәхимә апаларың. Кара инде, нихәтле кучтәнәч... Мең рәхмәт үзләренә.

— Менә боларын Бибинур апаларга җибәрделәр. Монысын аерым Гөлназга куйдылар. Аларның игезәк кызлары бар, бер-берсенә шундый охшаганнар, һич аерып алырлык түгел.

— Бибинурлар да бик шатланыр. Ул, бичара, көннән көн буе мәктәптә. Беркенне үзен урамда күрдем. Зарлануын зарланмый да, аңа никадәр кыен икәнен сизмимме мин. Бичараның чәче ап-ак булган, күз төпләре каралган. Мәктәп хәтле мәктәпне алып барырга көч кирәк бит.

Зәбирә түти Гәүһәр алдына чынаягы белән чәй куйды, күчтәнәчләрне этәрде. Ул сораштырудан тартына, үзенең Гәүһәр кайтканга шатлыгы эченә сыймаганлыгы күренеп тора. Йөзендәге вак җыерчыкларына кадәр — барысы да әкрен генә елмая кебек.

Иртәгә каникулның соңгы көне. Гәүһәр, чәйләр эчеп, өйдә бераз тегесен-монысын тәртипкә китергәләгәч, мәктәпкә кереп чыгарга булды, бәлки Бибинур апаны да күрермен, диде.

— Бар, бар,— диде Зәбирә түти, өстәлдәге чынаякларын кече якка ташый-ташый.— Мәктәптә укытучыларны да күрерсең.

Гәүһәр киенде дә урамга чыкты, күзләрен кыса төшеп, тирә-ягына каранды. Каршы очраган кешеләр аның белән исәнләштеләр, кайсылары, туктап, бер-ике авыз сүз дә алыштылар, Казанны сораштылар. Кызык икән ул, кемгә Казан бер сәгатьлек юл, кемгә гомергә бер генә барырга туры килә торган бик ерак кала. Дөньяны үз аршынына гына үлчәргә һич ярамый шул. Сораганы юк, Зәбирә түтинең Казанда булганы бармы икән? Тимер юл булмагач, элек бу урыннар, бигрәк тә кыш көннәрендә, Казанга чыннан да ерак булган, хәзер һава юллары ачылгач, Яшьлек шәһәре кебек кенә якын булып китте.

Мәктәп коридорына кергәч, Гәүһәрнең күңеле бөтенләй ташыды, мондагы һәр гәл ямь-яшел, кояшка каршы аларның һәр яфрагы көлә кебек. Бүген монда тып-тын, ә укулар башлангач, иртәдән кичкә кадәр шау-шу гөрләп торыр.

Директор бүлмәсендә Бибинур апа белән тагын биш-алты укытучы киләчәк дәресләр турында сөйләшеп утыралар иде. Гәүһәрне күргәч, сүзләреннән туктап, ачык йөз белән аңа таба борылдылар. Бигрәк тә Бибинур апаның йөзе яктырды. Аңа Гәүһәр турында төрле уйлар уйларга туры килгәндер, ул бит теләсә нинди очракта да классны укытучысыз калдыра алмый. Кыш уртасында яңа укытучы табуы да җиңел эш түгел, әмма ул шундый хәлнең булуын да исендә тоткандыр. Моннан дүрт-биш көн элек Әгъзәм белән сөйләшкәч, ул шактый тирән борчуга төшкән иде, күрәсең, бушка булган. Ләкин ул үзенең тирән хисләрен тышка чыгарырга өйрәнмәгәнгә, бик сабыр елмаеп:

— Я, ничек, кайттың? — диде.

— Менә, күрәсез,— дип елмайды Гәүһәр.

— Бик яхшы булган. Менә без расписаниеләрне карап утыра идек. Туры килеп бетмәгән урыннар килеп чыккалый.

— Директорның шул булыр инде. Ә мин, Бибинур апа, мәктәбемне сагынып беттем.

Гәүһәрнең бу сүзләрен ишеткәч, Бибинур көлеп куйды.

— Ә монда һаман шул. Менә үз расписаниеләреңне кара.

Укытучылар, саубуллашып, чыгып китә тордылар. Ниһаять, Гәүһәр белән директор икәү генә калды.

— Бик тирән борчу салган идең, инде шәят тынычландым шикел-

ле,— диде Бибинур апа.— Әгъзәм хәлләренне сөйләгәч, йөрәгем жу иткән иде.

— Булды инде, Бибинур апа.

Гәүһәр Казан хәлләрен сөйләп бирде.

— Ничек дип әйтим, Гәүһәр... бик зур адым ясагансың, уйлагансың да. Хатын-кыз шулай инде. Әзрәк тынычлан, уйларың урынына утырсын. Инде күңеленне балаларга тулысы белән бир. Алар сине сагынып беткәннәр. Минем яныма да кергәннәр иде. Алар бит, Гәүһәр, укытучы күңелен бик яхшы сизәләр. Бигрәк тә бу аларның беренче баскычта соңгы еллары. Синең дә соңгы елың, киләсе елда син инде өлкән классларны алырсың. Бу турыда вакыты белән сөйләшербез әле.

Ишек ачылып китте, шау килеп Миләүшә керде.

— Исәнме, Гәүһәр апа? Ябыккансың диимме? Бибинур апа, ябыккан бит?

— Имтиханнар бит, бераз бардыр,— диде Бибинур.— Миләүшә, синең бер-бер йомышың бармы?

— Юк, Бибинур апа, мин Гәүһәр апа артыннан гына кердем.

— Алайса, сөйләшегез. Минем райкомга кереп чыгасым бар иде.

— Без дә китәбез. Рәхимә апайлар Гөлназ белән икегезгә күчтәнәчләр җибәргәннәр иде. Кич белән кертермен.

— Ярый, көтәрмен. Бигрәк тә Гөлназ шатланыр. Сорамадым да, абыйлар исән-саулармы?

— Бар да исән-саулар. Сезгә күп итеп сәлам әйттеләр.

Алар кабинеттан чыктылар. Бибинур, коридорда кемнедер туктатып, сөйләшә калды, Гәүһәр белән Миләүшә урамга атладылар. Гәүһәр шактый йончыган иде, урамда вакыт-вакыт иснәп тә алгалады. Башта моны сиздермәскә тырышты, Миләүшә дә сизмәмешкә салынды. Култыклашып, бер-берсенә сыена төшеп, сөйләшә-сөйләшә кайттылар.



## 4

Бу көннәрдә Гәүһәр ничек тә булса Зиләләргә ярдәм итү уе белән янып йөрде. Ул Бибинур апа белән сөйләште. Рәми бабайның үлүе турында ишеткән булса да, Талиянең җәнҗалы аның өчен дә яңалык иде. Моңа бик каты нәфрәтләнде.

— Шундый кешеләр карт-корыларны, бала-чагаларны кимсетүдән тәм табалар, ахрысы,— диде Бибинур апа, ачуын чак тыеп. Аннары ул Гәүһәргә, дәрестән соң Зилә берничә көн сезгә кереп торсын, ул арада мин аның турында ни дә булса уйлармын, диде. Квартир белән утын мәсьәләсе бик авыр икән, Бибинур апа нишләргә дә белми.— Зиләләрнең йортлары да бик иске, утыннары да беткән иде.

— Ул турыда мин үзем больница житәкчеләренә, аннары шәһәр башкарма комитетына барырмын. Сез, зинһар, мәшәкатьләнмәгез,— диде Гәүһәр.

— Шулай итә күрегез,— диде Бибинур апа.— Укытучының сүзен искә алмаслармы. Югыйсә Яшел Ярда торак мәсьәләсе бик читен.

Гәүһәр больница житәкчеләре белән телефоннан сөйләште дә, икенче көнне, дәрестән соң, туп-туры больницага китте. Зиләне Зәбирә түти янына кертеп калдырды. Баш врачның хуҗалык эшләре буенча урынбасары Гәүһәрне ачык йөз белән каршы алды. Аның чәче яртылаш коелып беткән, йөзе ябык, муены нечкә. Гәүһәрнең нинди ният белән килгәнен иснәп белергә тели кебек иде.

— Укытучылар безгә сирәк килә,— диде ул, бер күзен йома төшеп.— Хуш, нәрсә белән ярдәм итә алам?

Гәүһәр аңа Зиләнең әнисе турында бәйнә-бәйнә сөйләп бирде. Аның утыны беткән, квартира сораган булган, аңа да игътибар юк. Хәлләре

бик авыр. Куптән түгел бабалары үлгән. Дүртенче класста укучы кызы Зилә өйгә керергә дә курка. Әнисе эштән кайтканчы урамда тора икән.

— Кызганычка каршы, балага без берничек тә ярдәм итә алмыйбыз шул,— диде абзый, борынын тарта-тарта.— Моның өчен мәктәп бар. Инде әнисе турында... Бабалары үлгәч, без аларга ярдәм иткән идек. Билгеле, күп түгел, үзегез беләсез, андый эшләргә акчаны күп бирмиләр. Менә утын. Быел безнең хәл бик авыр. Больницаны да ничек жылытырга белмибез. Шулай да бер-ике кубометр ничек тә табарбыз дип уйлыйм.

— Хәзер бит февраль ае гына, бер-ике кубометр белән генә нишләр икән ул.

— Белмим. Без мөмкинлегебездән чыгабыз.

— Өч-дүрт кубометр табыгыз инде. Минем белүемчә, ул хатын больницага бөтен вакытын бирә.

— Эшеннән зарланмыйлар. Шуңа күрә юк нәрсәне бар итеп бирәбез дә.

— Бу инде сезнең актык сүзме?

— Күрәм, сез бик каты сөйләшергә уйлыйсыз, ахрысы,— дип елмайды башлык.— Мөмкинлегем булса, мин ун кубометр да бирер идем. Ярар, бәлки ничек тә рәтләрбез.

— Рәхмәт, бик озакка гына сузмагыз. Ягарларына бөтенләй юк. Салкын чак.

— Ярый, иртәгә, берсекөнгә китерербез.

— Квартира ягын ничек уйлыйсыз?

— Монысы инде, Гәүһәр ханым, безнең эш түгел. Кәгазьләр горсоветта. Кайчан бирерләр — анысы алар кулында.

Икенче көнне Гәүһәр шәһәр Советына барды. Председатель үзе кабул итте. Ул Гәүһәрне бик игътибар белән тыңлады. Рәмиеваның хәлен бик өстән генә белә икән ул, ныклап кызыксынырга булды.

— Без хәзер су баса торган урыннардагыларны күчерәбез. Халыкның күбесе үзенә йорт салырга ашкынып тормый, дәүләттән сорый. Рәмиеваның хәлен аңлыйм мин, хезмәт хакы аз ала торган хатынга йорт тоту авыр. Иптәше төзелештә бәхетсезлек аркасында үлгән дисезме?.. Хәзер үзеп кенә вәгъдә итә алмыйм, истә тотармын... Семьясы ике кеше дисезме?

Председатель бик йомшак сөйләште, аз гына вәгъдә дә итте, тел төбеннән шул аңлашылды. Ләкин күз-колак булмасаң, вәгъдә вәгъдә көенчә калуы мөмкин. Ул ихтыярсыздан Әгъзәм турында уйлады. Бу тирәләргә ул якынрак тора, кешеләре дә аңа таныш.

Гәүһәр туры өйгә кайтты. Сәгать дүрттә Зилә белән аларга китте. Зәбирә түти ишек алды себерә иде. Гәүһәр Зиләләргә барасын, бик озак тормыйча кайтасын әйтте.

— Ярый, хәере белән. Мескеннәремә ярдәм итә күр инде,— диде.

Аяк астындагы кар шыгырдый, әле тиз генә эретер көне күренми шикелле. Өйләр икенче тапкыр ягылган, һавага әчкелтем төтен исе таралган. Мондый чакта эссе мич каршында утыру үзе бер рәхәт. Әмма бер ягарлык кына утының булса нишләргә? Утын китергән булсалар ярый, китермәгән булсалар...

Әле ерактан ук өй каршына утын аударганлыкларын күргәч, Гәүһәрнең эченә жылы йөгерде: китергәннәр! Өстенә иске сырма гына кигән Зиләнең әнисе дә шунда. Зилә аңа каршы йөгереп китте.

— Мәрхүм Рәми бабай әйтә торган иде, укытучы фәрештәләр белән сөйләшә дип,— диде Зиләнең әнисе, Гәүһәрне каршы алып,— валлаһи чын икән.

— Булган икән,— диде Гәүһәр, мактауга игътибар итмичә,— Утыны бик үк яхшы түгел шикелле.

— И-и, Гәүһәр, биргәннең битенә карамыйлар. Больницабызда да шуның ише генә утын.— Хатын әкрен генә көлеп куйды: — Бу укытучы кемең була дип сорыйлар. Кызымның укытучысы дим дә, ышанмыйлар. Син, Гәүһәрем, ул завхозны әллә нишләткәнсең.

— Үзенекен бирми лә ул,— диде Гәүһәр.

— Сорарга калган кеше кемнеке икәнен уйламый инде. Бирсә, рәхмәт, бирмәсә...

Гәүһәр утынны ташыша башлагач, Зиләнең әнисе каршы килде.

— Кит инде, кит, Гәүһәр, шундый яхшы пальтоңны пычратырсың. Үзем дә ташып бетерәм. Әнә Зилә дә ярдәмгә чыга.

Гәүһәр, хатынның ай-ваена карамыйча, юкарак утыннарны Зиләнең чанасына төяште, аннары бергәләп чананы тартып киттеләр.

Сөйләшә-сөйләшә утынны ташып та бетерделәр. Шуннан киемнәрен каккалап, Гәүһәрне өйгә алып керделәр. Мич яккан, чытырдап яна иде.

— Хәзер кайнар күмер белән самовар да куеп җибәрәм, күз ачып йомганчы кайнап чыга,— диде апа, сырмасын сала-сала.

— Миңа дип борчылмагыз, апа. Без Зилә белән хәзер генә эчкән идек.

— Әллә ни сыем юк, Гәүһәр. Бер стакан чәемне эчсәң, рәхмәт әйтер идем. Зиләм дә борчый инде үзегезне.

— Бер дә борчымый. Безнең Зәбирә түти ул яктан ачык күңелле, килгән кешене үз кунагы итеп каршы ала.

Апаның кулы кулга йокмый иде. Озын ак яулыгы, чуар күлмәге җилфердәп кенә тора, соры оекбашлары идәндә тавыш-тынсыз гына шуалар. Өй салкынча иде, тора-бара бераз җылынды.

— Шәһәр Советына да бардым,— диде Гәүһәр, кайнар чәен эчә-эчә.— Председатель ачык кына, өзеп кенә әйтмәде әйтүен, болай вәгъдә иткән кебек күренә. Менә майга яңа йортта бер бүлмә бирсәләр, тормышыгыз бөтенләй үзгәреп китәр иде.

— Рәхмәт инде сиңа, Гәүһәр, мең рәхмәт. Әле утыны өчен дә бая елап алдым.

— Әле әйтмәгән идем, әгәр теләсәгез, иртәгәдән Зилә сәгать дүрткә кадәр интернатта тора башлар. Зилә, ничек, акыллым, телисеңме?

— Телим, апа...

— Менә инде, бала да бала, ул да бала. Гәүһәр апаларыңа авыр көнеңдә керткән өчен мең рәхмәт әйтергә кирәк.

— Рәхмәт,— диде Зилә, әкрен генә.

Гәүһәр Зиләләрдән чыкканда инде караңгы төшкән иде. Ул әллә ни эшләмәде дә кебек. Әмма үзалдына булса да елмаясы килә иде.

Икенче көнне мәктәптә укытучылар бүлмәсенә кереп барганда Гәүһәр коридорда Зилә белән Акназарны күрде. Алар икесе дә бик шат, ниндидер бик күңелле нәрсә турында сөйләшәләр иде. Гәүһәрне күргәч, чак кына кызарып, аның белән исәнләштеләр. Гәүһәр бу балаларның дуслыгын күптән белә иде. Бу дуслыкка салкын кул белән кагылырга гына кирәкми. Ихтимал, ул берничә елдан үзеннән-үзе сүнәр, ихтимал, зур дуслыкка әверелеп китәр. Укытучы, билгеле, сукыр була алмый, ул һәрвакыт күзәтә, чөнки балалар алдында җаваплы.

Зилә гүя чәчәк аткан, яңадан аңа җанлылыгы, өлгерлеге кайткан. Интернатка барып берничә сәгать анда торуына шулай шатланганмы?

Гәүһәр өенә бүген шактый соң кайтты, педагогик утырыш булды. Утлар инде кабынган. Бөтен тәрәзәләр ял-якты. Гөлләр арасында кемдер йөренә кебек. Кем булыр икән? Гәүһәр тәрәзәгә якынрак килде. Пыялалар туңган, берни күренми. «Әгъзәм түгелме?» Гәүһәр ишеккә таба ашыга башлавын үзе дә сизмәде.

Кинәт ишек ачылды, эчтән хатын-кыз тавышы:

— Гәүһәр, бу синме? — дип сорады.
— Мин, мин, Зәбирә түти. Бездә кем бар?
— Ят кеше түгел инде. Әгъзәметдин хәл белә кергән. Хәзер кайта дия-дия...
Әгъзәм, өс киемен салып, гөлләр арасында арлы-бирле йөренә иде. Бер кулы чалбар кесәсендә. Менә ул ишек тавышына борылды. Ишек төбендә бит очлары кызарган Гәүһәрне күрде.
— Кунак бар икән,— диде Гәүһәр, кулын сузып.— Исән-сау кайттыңмы?
Кешенең сүзләренә карама, ул сүзләрнең ничек әйтелүе кыйммәт. Гәүһәрнең көләч тавышы ишетелгәч, Әгъзәмнең авыр уйлары гүя юкка чыкты. Ул әкрен генә елмайды, Гәүһәрнең сузган кулын кысты.
— Зәбирә түти, Әгъзәм ябыкканмы? Яңаклары тәмам суырылган.
— Авырган шул.
— Авырдыңмы? Салкын тидерденме?
— Үтте инде. Үзең исән-сау кайтып җиттеңме?
— Мин кайтканга биш былтыр инде. Менә син генә авырып йөрисең.
Гәүһәр чишенде. Әгъзәмнең аны бу матур җылы күлмәктән күргәне юк иде, сокланып карады.
— Гәүһәр, ашыйбызмы, чәй эчәбезме?
— Тукта, Зәбирә түти, кунактан сорыйк. Әгъзәм, ашыйсың киләме, эчәсең киләме?
— Миңа карама. Син эштән кайткан кеше.
— Алай булса, Зәбирә түти, башта ашат, аннары чәй эчәрбез. Кунагыбыз бик тәртипле, хуҗалар җырын гына җырлап тора.
Гәүһәр кулларын юды, Әгъзәмне дә чакырды. Бик тәмләп, уен-көлке сүзләр кыстыра-кыстыра, шулпа һәм ит ашадылар. Гәүһәр больницага, шәһәр Советына барулары турында сөйләде, Зиләләрнең кәгазьләрен таптырып өскә чыгарткан, ләкин алар шунда тагын еллар буе ятмагае.
— Мин кызыксынырмын,— диде Әгъзәм, Гәүһәрне ярты сүздән аңлап.
— Кызыксына күр инде,— диде Зәбирә түти дә.— Ятимнәр сөенече мең рәхмәт булып әйләнер.
Гәүһәр белән Әгъзәм күзгә-күз карашып алдылар да пырхылдап көлеп җибәрделәр.
Бер-берең белән аңлашканга кадәр күңел яшерен җылылыкны тоя. Шул яшерен җылылык булмаса, синең купшы сүзләрең кирәк түгел, чөнки алар җанга рәхәт бирми.
— Син миңа бераз үпкәләгәнсеңдер дә инде, мин бит теге вакытта аэродромга озатырга килгән идем, тик мин килеп җиткәндә самолет кузгалган иде инде. Күңелең синең бик төшенке булгандыр, әйеме?
— Булгандыр инде,— диде Әгъзәм, елмаеп.
Бу кичне алар озак сөйләштеләр, гүя аларның җаннары ачылганнан-ачыла барды.

## 5

— Әгъзәм, синең балаларны кыйнаганың бармы? — дип сорады Гәүһәр.
— Балаларны?!
— Әйе, нигә болай карыйсың? Соравым гаҗәпме? Көн дә була торган хәлләр турында сорап та тормыйм.
— Шулай да соравың бик кискен. Әйтерсең, мин балаларны кыйнарга тиеш. Нәкъ элекке хәлфә кебек.
— Күрәм, күрәм, кыйнаганың бар икән,— дип көлде Гәүһәр.

— Каян күрәсең?

— Соң, гомердә балаларга кул күтәрмәгән кеше болай апты-рыймы?

— Эләктем,— диде бераздан Әгъзәм, әкрен генә елмаеп.— Дөрес, кыйнавын кыйнамадым, бер баланы якасыннан алып селектем.

— Я, я, ничек булды, ни өчен?

— Монда әллә ни кызык нәрсә юк. Авыл укытучысының көндәлек практикасыннан бер күренеш.

— Шулай да сөйлә әле. Югыйсә, укытучының тормышы гел бер төрле, ул борчылмый да, гарьләнми дә, еламый да диярләр. Балалар бар да коеп куйган кебек, дәресен сорасаң, шартлатып җавап бирә-ләр, имеш.

Әгъзәм башын селекте дә Гәүһәргә мәгънәле генә итеп карады.

— Бик тәти булып йөрмәгез, үзегезнең дә гөнаһларыгыз бар, дип әйтмәкче буласыз инде. Мин курыкмыйм. Анвары заманында мине житәрлек кыйнадылар да.

— Шулай да, Әгъзәм, укытучы логикасына буйсын әле. Тәртип бе-лән генә сөйлә. Укытучы булган кеше ләбаса син.

— Кечкенә бер төзәтмә белән. Укытучы булганым бар, анысы дө-рес, ләкин...

— Алдан акланасыңмы? Кирәкми, чалмалы ишан түгеллегеңне күрәм.

Әгъзәм рәхәтләнеп бер көлде, аннары сөйли башлады.

— Мин авыл мәктәбендә эшли идем. Беркөнне минем класс алтын-чы «б» классына каршы сугыша. Бөтен класс, хәтта кызлар да кал-мый. Мондый хәлдә үзең беләсең, бөтен мәктәп аякка баса, умарта оясы кебек гөжли: групповой сугыш! Җитмәсә, кем сугыша? Үрнәк класс! Ни өчен сугыш чыккан,— анысын яхшылап тикшерү юк, бары-сына шелтә чәпиләр. Билгеле инде, класс җыелышы да, мәктәп җые-лышы да, ата-аналар җыелышы да — берсе дә калмый. Ул чакта роно-да бер бик белдекле хатын эшли иде, шул бик тырышты. Мин аңа башта мәсьәләнең төбенә карыйк, нәрсәдән сугыш чыккан, аннары нәтиҗә ясарбыз, дим. Әле дә онытасым юк, вәкил апа миңа шундый итеп карады: син, ди, ничә ел укытасың? Мин әйтәм, икенче ел. Күре-неп тора, ди, классыңда групповой сугыш, ә син демагогия сатасың, ди. Синең үзең турында мәсьәләне куярга кирәк, ди. Син мондый чак-та яшь укытучының хәлен беләсең, сөйләп торуның кирәге юк. Шулай да мин класс җыелышын җыйдым. Ни өчен сугыш чыкты, сөйләгез, дим балаларга. Моңарчы безнең арада сер булмый торган иде, дим. Берәү дә эндәшми. Бик озак газаплангач кына белдем. Ул көнне мәктәптә пионер сборы булырга тиеш була. Алтынчы «б»дан Әһли исемле бер малайны пионерга алу мәсьәләсе каралырга тиеш. Ул Әһли дигәннәре бер сугыш чукмары, бөтен дәресләрдән артта бара иде. Алтынчы «б»дан берәү дә аңа каршы сөйләми, Әһли барысының ко-тын алган. Алтынчы «а»дан аңа каршы чыгалар. Нәтиҗәдә Әһлине пионерга алмыйлар. Сбордан чыкканда, урамда элеге сугыш башла-на. Алтынчы «а» җыелышта чыгыш ясаган иптәшләрен яклый, Әһли-ләргә каршы бер кешедәй булып сугыша. Менә шул. Җыелыштан соң минем күңелем күтәрелеп китте. Үзегез уйлагыз: балалар коллектив-ны яклап сугышалар. Минемчә, алтынчы «а»га шелтә түгел, рәхмәт белдерергә кирәк иде. Ләкин эш шунда бетмәде. Беркадәр вакыттан соң, элеге шул Әһлине безнең класска күчерәләр. Күрәсең, алтынчы «б»да аңардан туеп беткәннәр. Безнең мәктәптә алтынчы класслар икәү генә, «а» һәм «б». Карыйм, Әһли иң арттагы партада ялгыз гына утыра. Пычрак йодрыкларын парта өстенә үк чыгарып салган. Башта тәнәфес вакытларында гел үз классы малайлары янына китә торган иде. Бервакытны мин Әһлинең бәдрәфкә йөргән өчен класстан акча

җыйганын ишетәм. Башта шаккаттым, бу эшкә кем батырчылык итәр? Мин Әһлине чакыртып, бу әшәкелек оят түгелме? дип сорадым. Малай минем йөземә карап мәсхәрә белән көлде. Ул үзенә бернәрсә дә булмасын белә, ничә еллар буе аны үгетләгәннәр, мораль укыганнар. Ул бер укытучыдан да курыкмый, аларның сүзен санга сукмый, чөнки болай гына каты сөйләшкән булалар, ә үзләре бернәрсә дә эшләмиләр. Мин малайны үгетләп тормадым, якасыннан алдым да селкә башладым. Күрәсең, каты селеккәнмен, малай куркуыннан елап җибәрде, миннән гафу үтенә башлады, бүтән бервакытта да начарлык эшләмәм, ди. Әлбәттә, соңыннан миңа шактый тиде, ронодагы апа миңа тешен бик кайрап йөрде. Министрлыкка да хәбәр иткәннәр. Анда мәсьәләгә ачыклык керткәннәр, ахрысы, миңа артык бәйләнми башладылар. Шуның белән минем сугышуларым да бетте.

— Соңыннан син ул Әһлине күрдеңме?

— Кыш көне генә күрдем. Казанда Авыл хуҗалыгы институтында укый.

— Ул сиңа якасыннан тотып селкүең турында әйтмәдеме соң?

— Бәлки әйткәндер дә. Моны мин нинди булса гыйбрәтле вакыйга булганга сөйләмәдем бит, син сораганга гына.

— Ә син минем балаларны кыйнавымны күз алдыңа китерәсеңме?

— Юк, син андый түгел.

— Менә белмәдең шул. Укытучыга тыштан гына карарга ярамый. Тыштан без барыбыз да ал да гөл. Әмма безнең профессия кайчак җилекләреңне суырып бетерә. Әгәр синең үзеңдә шундый четерекле хәл булмаса, мин сиңа сөйләп тә тормас идем. Тыңла. Әле Казанда чакта шундый бер хәл булган иде,— дип, Гәүһәр классындагы мәгълүм вакыйганы сөйли башлады. Үзенең «батырлыгын» артык күпертмәсә дә, моның бер гаебе дә юк икән, дигән шикелле күмеп тә калдырмады.— Үзең күрәсең, укытучы тормышында еш булмаса да була торган хәл,— диде аннары.— Мин сиңа ул вакыйганы тулысы белән сөйләмәдем, вак детальләре онытылган да инде. Мин, билгеле, үземә нәтиҗәләр дә ясадым. Тик бер яклы гына. Хәер, бу уй минем башыма соңыннан килде, ә ул чакта барысын да дөрес эшләдем шикелле тоелган иде. Тупаслыгым өчен гафу да үтендем. Безнең мәктәпнең директоры Шәриф Гыйльманович миңа бер сүз дә әйтмәде. Ихтимал, ул чакта минем тормышымда авыр хәлләр булганга бу мәсьәләне йомып калдыргандыр. Уку елы азагында мин ул мәктәптән киттем. Ләкин соңыннан гел үкенеп йөрдем. Мин — укытучы, теләсә нинди очракта да гасабиланмаска, кулыма ирек бирмәскә тиеш идем...

— Хәзер дә шул турыда уйланасыңмы?

— Соң, уйланмыйча! Минем тәҗрибәм әллә ни зур түгел бит. Бөртекләп җыйнамасам, ярга чыгарып ташланган балык кебек булачакмын. Мин үткәнне кире кайтарырга да, бигрәк тә кайчандыр эшләгән хатам өчен җәза алып тынычланырга да уйламыйм. Сүз киләчәктә тулы канлы укытучы булу турында бара. Мин шул турыда гына борчылам.

— Башта миннән ни өчен сөйләтүең хәзер аңлашыла,— дип көлемсерәде Әгъзәм.— Кимендә, син үзеңә союзник эзләгәнсең. Ә мин шуны да сизмәгәнмен.

— Әгәр син барысын ярты сүздән сизсәң, даһи кеше булыр идең. Без үз кайгыбызны сөйләп тә тормас идек, шундый чүп-чар белән даһи кешенең вакытын алалар димени?!

Әгъзәм башын артка ташлап көлде:

— Син, Гәүһәр, бик шаян да, акыллы да. Әгәр мин ялгышмасам, син үз хатаңнан — әгәр шулай дип әйтергә яраса — күптән нәтиҗә ясап киләсең. Элек мин синең, укытучы буларак, тегe-бу адымыңны бик үк төшенеп җиткерми идем.

Кояш язга таба борыла инде, көннәр озая, жылыта башлады. Март башларында суык әле бер биетеп алды, гүя кыш янадан кайтырга, янадан гайрәт чәчәргә уйлый иде. Мартның урталарында инде көннәр тәмам сындырды, апрельнең беренче атнасында яшь-жилкенчәк пальтоларын сала башлады. Дөрес, иртә-кичләрен суыграк, кыш тартыша иде әле, аннары ул, хәлсез карт шикелле, тәмам биреште, һавада көндезләрен генә түгел, кичләрен дә жылы жилләр искәләде. Мондый чакта инде кешеләрне, бикләсән дә, өйдә тота алмыйсың.

Былтыр Гәүһәр әллә күрмәдеме, әллә елы шулай идеме, яз монда гадәттәгечәрәк килде. Баксаң, Кама елгасы буенда яз үзенчәрәк икән, аның әллә никадәр кабатланмый торган яклары бар. Яктылык бермә-бер көчлерәк, эри башлаган кар гаҗәеп бер нур белән жемелди, исәпсез-хисапсыз елгачыклар, ерганаклар, Кама якынлыгын сизгәндәй, тыелгысыз гөрлиләр. Кая карама, яз ашкынуы. Бу ашкыну шундый көчле, үлгәнне терелтер кебек.

Башта аяк асты бик пычрак иде, су чамасыз күп булыр төсле иде, соңыннан ул ничектер юкка чыкты, сукмаклар әкренләп кибә башлады. Гәүһәрнең дәресләрне тизрәк кырга, болыннарга, елга буйларына чыгарасы килде. Табигать матурлыгын, табигатьнең янаруын класста сөйләмәссең бит. Илһамланыр өчен киңлек кирәк. Балалар да моны сизәләр, «Гәүһәр апа, кайчан Кама карарга барабыз?» дип шаулашалар. «Тиздән, тиздән», дигәч, баскан урыннарында сикерешәләр.

Ниһаять, бер көнне алар Кама буена төштеләр... Йа алла, монда нинди матурлык, нинди киңлек! Җәен тар гына булып кала торган коры елга хәзер ничек киңәйгән! Берничә көннән ярларыннан бөтенләй ташып чыгар. Ә Кама! Ул диңгез булган бит, аргы як күренми дә. Зур-зур бозлар әнә ничек актарыла! Нинди яшерен көч аларда! Үз-үзеңне онытып, сәгатьләр буе карап утырырсың! Табигатьнең бу стихиясен үлчәрлек куәт бармы икән? Нинди тыныч бит ул кыш көннәрендә, теләсә кемгә өстеннән йөрергә, курыкмыйча, хәвефләнмичә йөрергә рөхсәт итә. Ә хәзер янына барып кара! Иң батыр йөрәкле ир дә артка чигенер. Ә җәй көне балалар да аның ярларында колач салып йөзәрләр, уйнарлар, көймәләр, пароходлар, теплоходлар салмак кына йөзәрләр. Вакыт! Хәтта елгаларны да котырта, шаштыра. Әнә кара, су һаман арта бара. Иртәгә инде бүген кешеләр басып торган җирләрне дә су басып китәр. Күзеңне йомсаң, хәтта туфан булыр сыман!

Гәүһәрнең табигать белән күзгә-күз карап торуы күпмегә сузылгандыр, әйтүе кыен. Бәлки берничә минут, бәлки бераз артыграк булгандыр. Мөмкинлеге булса, табигать белән озаграк та серләшер иде. Ул табигатьнең башкаларга мәгълүм булмаган бик күп якларын күрә, әгәр кирәк булса, алар турында сөйли дә ала. Укучылары өчен Гәүһәр күп белә, күп белергә тиеш тә, чөнки ул укытучы. Сөйләгәндә ул балалар аңлардаен гына сөйли. Аннары кызык итеп сөйли. Табигать серләре балаларны мавыктыра. Әнә кояш жылытканга үләннәр ничек баш калкыткан, әнә чылтырап аккан су туфракка яшәү азыгы бирә, әнә кошлар ничек рәхәтләнеп һавада очалар, әнә беренче бөҗәкләр туфракта мәш киләләр. Гаҗәеп серле дә, гаҗәеп гади дә хәл бу.

— Гәүһәр апа, Каманы бугач, бездә ташу булырмы?

— Гәүһәр апа, җәй көне дә Камада шулай боз аксын иде. Без гел карарга килер идек.

— Әй, тиле! Җәй көне Камада боз акса, без кайда коеныр идек.

Мондый сәер сораулары өчен балаларга ачуланырга ярамый. Бик житди итеп, бик төгәл итеп аларга җавап бир. Гәүһәр моны белә, сабырлыгын җуймыйча, шул ук вакытта үзе дә ничектер бала сымаг-

рак булып, аларга аңлата. Ихтимал, өлкәннәргә бу сәер тоела торгандыр, бу турыда әдәбиятта да әллә ни юк шикелле. Балаларның һәрберсе үзенә күрә кабатланмас бер дөнья ача бара бит. Тик, кызганычка каршы, алар моны гомумиләштермиләр, соңыннан болар эзсез югала. Тагын шунысы кызык, монын югалуын берәү дә белми, ачканда исә яңа бер дөнья ача кебек.

Алар Кама ярыннан кайтып кергәндә, кояш тагы да җылыта төшкән иде. Балалар беркадәр арыганнар, ләкин бераз ял иткәч, тагын көчләре кайтачак. Өйләре якын булганнарны Гәүһәр кайтара торды, өйләре югары якта булганнарны мәктәпкә кадәр алып барды. Ул үзендә эчке бер канәгатьлек тойды. Ниндидер бер бик яхшы эш эшләде шикелле. Күңеле күтәрелеп китте. Шул күтәренке күңел белән ул мәктәпкә керде, шул күтәренке күңел белән өенә кайтты.

Өй эче бик ямьле, гөлләр барысы да кояшка борылганнар. Күбесе шау чәчәктә. Ниндиләре генә юк ул чәчәкләрнең: ак, зәңгәр, кызыл, алсулары, энҗе бөртекләре кебек ваклары, төймә-төймәләре, бала йодрыгы хәтле зуп-зурлары да бар. Күбесенә Зәбирә түти терәкләр ясап куйган. Гөл сабагы нечкә бит, авыр чалмаларын күтәрә алмыйча бөгелеп төшәләр.

Чәй эчеп, Гәүһәр китапларын гына карый башлаган иде, Зилә белән аның әнисе килделәр. Шатлыклары эчләренә сыймый. Монысы сүз катмас борын ук күренә.

— Эштән кайттым да, шатлыгыбызны сиңа әйтергә йөгердек, Гәүһәр. Ялган булмастыр инде. Эштән чакырып алып әйттеләр. Әнә теге югары яктагы яңа йорттан бер бүлмә бирәбез, диделәр. Кухнясы да бар, имеш.— Зиләнең әнисе күз яшьләрен сөртә башлады. Аңа карап Гәүһәрнең дә күзләре томанланды. Тик Зилә генә зурларның шатланасы, бисе урында елап утыруларына исе китеп торды. Аның каравы, Зәбирә түти кереп, эшнең нәрсәдә икәнен белгәч:

— Бәрәч, шуңа елашып утырасызмы? — диде.— Валлаһи, урамга чыгып кычкырасы урында ела, имеш! Соң, кай җирдән бирәбез диләр?

— Шул инде, югары якта, Зәбирә апа. Теге тиле хатынныкы төсле, шатлыктан яшь ага инде.

— Менә бик яхшы булган. Үзебезнең советски влач. Картың, мәрхүм, төзелеш кешесе иде. Сезгә дә бирмәгәч, кемгә бирсеннәр.

— Безнең шикелле кеше күп бит ул, Зәбирә апа. Менә Гәүһәргә рәхмәт. Ул булмаса, безнең кәгазьләр бәлки озак ятар иде әле...

— Юк, апа, алай ук димәгез. Зәбирә түти, чәй куеп җибәр булмаса.

— Юк, юк, зинһар, мәшәкатьләнмәгез. Без шатлыгыбызны гына әйтергә дип килдек. Рәхмәт инде, Гәүһәр. Теләгәнеңне ходай бирсен. Син дә, Зәбирә апа, сау булып тор.

Зиләләр киткәч, Зәбирә түти тәрәзәдән карап торды да:

— Кешенең шатлыгын күрсәң, үзең сөенгән төсле буласың,— диде.

Икенче көнне иртүк мәктәп тәрәзәләрен каерып ачып җибәргәннәр иде. Коридордагы гөлләрнең чәчәкләре тәмам ачылган. Балаларның шат тавышлары бөтен мәктәп буенда яңгырый, гүя язны сәламлиләр иде.

Укытучылар бүлмәсенә узып барган Гәүһәр кинәт туктады. Мәктәптә түгел, кайдадыр урамда шундый ачык, шундый саф булып бала көлүе ишетелә. Чү, Зилә түгелме соң бу? Балалар арасында ул гына шулай тирә-якны яңгыратып эчкерсез көлә шикелле?

Соңгы вакытларда Гәүһәр Зиләне туктаусыз күзәтте. Кызык икән ул бала күңеле. Зәбирә апа белән Гәүһәр Зиләгә бөтен шартларны булдырырга тырышканнар иде кебек. Мәктәптән кайтуга ашарына дисеңме, җылы бүлмә дисеңме, ачык чырай дисеңме — бар да бар, ә ба-

ла моңаеп утыра, сәгатькә карый-карый әнисенен эштән кайту вакытын көтә, ул кайткач, җан-фәрманга өйгә чаба. Ә соңыннан нинди зур теләк белән интернатка китте. Аңа гүя тамагына да кирәкми. Ниһаять, көннәр җылыткач, интернатка да бармый башлады. Портфелен куеп, икмәк кисәге ала да ишек алдына, урамга чыга. «Әле һаман куркасыңмы?» дип сорасалар, «куркам» дип бер сүз белән генә җавап бирә. Дөрес, интернатка торып торырга күчкәннән бирле ул шат күңелле балага әверелде. Әмма бүгенге кебек бу кадәр чыркылдап көлми иде. Укытучыга моннан да зуррак сөенечнен булуы мөмкинме?!

Кешенең шатлыгына да, кайгысына да кинәттән бәреп керергә ярамавын Гәүһәр белә. Балаларны күргәч, нидер исенә төшкән кебек, кырт борылып китеп барды. Коридорның икенче башында, аулакта, ике кулы белән ике яңагын кысып тотты. Кинәт аңа әллә нәрсә генә булды кебек. Ниндидер зур, бик зур бәхет биләп алды аны. Тик аны башкаларга сөйләп кенә булмый, кешеләргә белдерсән, челпәрәмә килер төсле.

— Гәүһәр, ни булды?

Күзләрен ачса, каршысында Әгъзәм басып тора иде. Ул Гәүһәрне ерактан ук күргән, ахрысы, борчылуы йөзенә чыккан иде.

Гәүһәр, кулларын яңакларыннан алмыйча, бер секунд басып торды, аннары әкрен генә елмайды.

— Юк, бернәрсә дә булмады. Әнә ишетәсеңме?

Ерактан, бар тавышларны күмеп, бала көлүе генә ишетелә иде. Әгъзәм аңламады. Ул сәерсенеп бер тавышка колак салды, бер Гәүһәргә карады.

— Бала көлә, бала. Бу — ул, Әгъзәм, ул!.,



## 7

Яз уйный диләр. Апрель башларында көннәр бик җылы булса да, ай азагына таба шундый салкынайтып алды, кешеләр яңадан кышкы киемнәрен чыгардылар. Кар да яуды, инде яшелләнә, бөреләнә башлаган үләннәр, агачлар яңадан йомылдылар, гөрләвекләр бөтенләй ишетелми башлады. Урамнардагы кешеләр йөгереп-атлап кына узалар, йөзләре көлсыман, каралган, боеккан. Аяк асты яңадан чамасыз пычранды, озын кунычлы резин ботылар булмаса, эшең тәмам харап. Машиналар таш җәйгән үзәк урамнарда гына йөри, башка җирләргә борылсалар, чыга алмаслык баталар. Белмәссең, әллә кар, әллә яңгыр сибәли. Яз түгел, кара көз килгән сыман.

Ниһаять, тагын яхшы ук җылытып җибәрде. Кешеләр әле язга бик үк ышанып бетмәде, кыш яңадан калдык-постык суыкларын, кырыпсебереп, җиһанга куып чыгарыр төсле тоелды. Тик яшь-җилбәзәк кенә, калтыранса да, язгы юка киемнәрен кигән. Ахыр килеп, кояш аларны кызганды кебек, көн урталарында яхшы ук кыздыра башлады, кышкы киемнәрнең бөтенләй кирәге бетте.

Гәүһәр белән Миләүшә мәктәптән бергә чыктылар. Башта бер көтү мәктәп балалары, алардан аерылырга теләмичә, шаулаша-шаулаша бергә кайттылар. Гәүһәрләр тыкрыгы башында алар инде таралып беттеләр.

— Нәкъ чебиләр кебек. Тәмам янына иярләштереп беткәнсең үзләрен,— диде Миләүшә, елмаеп. Элек ул мондый чакларда тавышланып көлә торган иде. Хәзер күр, елмая гына, елмаюында да ниндидер моңсулык бар шикелле. Гәүһәр Миләүшәдәге бу кадәр үзгәрешкә башта гаҗәпләнде, аннары аның ана булырга җыенуын уйлап, аңа хөрмәт белән карады. Ул үзе тормышта ничә ел булып та бу бәхетне татымады. Башта, беренче елда, кибетләрдә бала киемнәренә күз салгалап йөрде, йөрәгендә аңлашылып та бетми торган кузгалышлар булды,

соңыннан барысы да онытылды, күрәсең, бу бәхетнең аңа түгеллеген аңлады. Менә хәзер дә, Миләүшәнең сагышлы шатлыгын күргәндә дә аның яшерен йөрәк тибешен сизмәде.

— Бөтен куанычың шул булгач, нишлисең,— диде, үзенең бераз хәйләләвеннән чак кына кызарып.— Менә сиңа карап, Миләүшә, шатланам, чын менә! Син тиздән бәгырь алманны күтәреп йөртәчәксең.

— Белмим,— диде Миләүшә, әкрен генә.— Нигәдер бик куркам. Вилдан белән сөйләшәбез. Ул мине юата да... Өйдә, кайчан, тиле хатын кебек, гел бер җырны җырлап йөрим. Элек нинди җыр икәнен дә белми торган идем, соңыннан бер көнне Вилдан җырлап күрсәткәч кенә белдем. «Әлли-бәлли» икән ул.— Миләүшә оялып кына көлеп җибәрде.— Мондый чакта кеше бераз юләрләнә дисәм, арттырып җибәрү булыр, һәрхәлдә, шактый сәерләнә икән.

Аларның авыз тутырып бер сөйләшәселәре дә килә иде. Хатынкызның азмыни сүзе. Бигрәк тә ана булырга җыенучының. Дөрес, Гәүһәрнең бу өлкәдә тәҗрибәсе юк, ләкин тормышта ул күбрәк күргән, холкы да утыра төшкән. Ә Миләүшә нәкъ шуңа мохтаҗ да.

Гәүһәр Миләүшәне өенә чакырды, бераз серләшеп утырырбыз, диде. Миләүшә мөмкин булса, автобуска кадәр генә озат, диде. Озак кайтмасам, Вилдан да бик борчыла, бер-бер хәл булмадымы дип, хәзер артымнан килеп җитә, диде.

Миләүшәнең әкрен генә көлүе иреннән бик канәгать булуын күрсәтә иде. Гомумән, Вилдан бик яхшы икән. Акыллы да. Кечә Бибинур апа аңа бер эш кушкан. Ана теле һәм әдәбияты укытучысы Гөлсем апа укулар беткәч тә пенсиягә китә икән. Укулар бетәсе көннәрдә мәктәптә аңа багышланган бик зур кичә буласы. Шул кичәдә Вилдан Гөлсем апа турында доклад ясарга тиеш икән. Вилдан үзе дә кайчандыр Гөлсем апаның яраткан шәкерте булганга, бу эшкә аңардан да кулай кеше табылмаган. Вилдан хәзер бөтен буш вакытын шул докладка әзерләнүгә бирә икән. Шуннан соң Миләүшә, сер әйткән шикелле, Гөлсем апаның классларын Гәүһәргә әзерләүләрен сөйләде. Бибинур апаның шулай еракка карап эш итүе Гәүһәрне бик сөендерде. Әмма җавабы тыйнак иде:

— Минем бит әле, Миләүшә, имтиханнарым бар,— диде, тирән көрсенеп.— Болай, үземчә хәзерләнгән булам да, күңел тынычсызлана.

— Имтиханнар бирү җиңел эш түгел. Моны безнең һәрберебез белә,— диде Миләүшә, юлда корырак урыннарны сайлый-сайлый,— тик син башыңны имә. Син имтиханнарны яхшы бирәсең ич. Бу юлы да сынатмассың. Инде мондагы эшеңә килсәк, Гөлсем апа — минем бик яхшы танышым. Мин аның белән сөйләшермен. Ул сиңа ярдәмен кызганмас.

— Рәхмәт,— диде Гәүһәр.— Мин үзем Гөлсем апа белән әллә ни таныш түгел.

— Минем таныш булуым җитәр,— дип елмайды Миләүшә.— Менә Әгъзәм абый белән араларыгыз ничек? Бер көнне икегезне урамда күргәч, Вилдан белән сөенеп киттек әле. Сез чын менә, берегез өчен берегез тугансыз кебек.

— Юк, Миләүшә, сез хискә биреләсез...

— И инде, Гәүһәр апа, бик акыллы булып, актык миллиметрына кадәр үлчәп кыланмагыз. Мәхәббәттә бераз тилерәк булганың яхшы. Без менә Вилдан белән шулай идек.

Гәүһәрнең көләсе килсә дә, ул бик житди иде.

— Сез башка ул, Миләүшә. Миннән инде әүвәлге юләрлекләр очкан. Мин теләсәм дә алай була алмыйм. Әгъзәмне начар димим, ләкин без... гомумән, сөйләшүдән узган кешеләр түгел. Сөйләшәбез дә аерылабыз.

— И-и-и. Сезнең турыда инде...
— Юк, Миләүшә. Кеше кешенең күңел эченә керми.
— Минемчә, монда эчкә керәсе калмаган. Бер көнне минем Вилдан Әгъзәм абыйларның өенә кагылган булган. Әгъзәм абыйларда укытучылар булгалый икән. Шул Вилдан әйтә: Әгъзәм абыйның язу өстәлендә Гәүһәр апаның менә дигән рәсеме тора, ди. Үзе, ди, һаман, һаман шул рәсемгә карап-карап ала, ди. Ул әйтми генә, ди, Вилдан әйтә, Әгъзәм абый Гәүһәр апаны бик ярата, ди.

Автобус әле күренми. Миләүшә белән Гәүһәр тукталышка күптән килеп җиткән булсалар да, яннарыннан бер машина да узганы юк. Хәер, яшь хатыннар моны сизмиләр дә. Тик кайчагында Гәүһәр генә Миләүшәгә авыр була күрмәгәе дип борчыла. Ичмасам, урындык-фәлән дә юк.

— Белмим,— диде аннары Гәүһәр, өзелгән сүзне ялгап,— без бит тустаганның ачысын тутырып эчкән кешеләр. Яшьлекнең беренче мәхәббәте, бер-беренә бетмәс-төкәнмәс ышанулары да, бергә булгач, бөтенесе ал да гөл булыр дип киләчәкне хуш итеп күз алдына китерүләр дә очкан инде. Яшьлегемә бик теләп кайтыр идем дә, вакыты үткәч, булмый икән, Миләүшә.

— Ярый, әллә нәрсәләр уйлап башыңны әйләндермә. Әнә безнең автобус та килә. Укуыңны тәмамлагач, кая булса барырга булдыгызмы? Путевкаларга заказ биргәнсездер инде? Без менә беркая да бара алмабыз инде. Кечкенә әле тумаган, ә дөньяга үз таләпләрен куя.

Миләүшә, бер сагышланып, бер шатланып сөйләде. Гәүһәр моны бик ачык сизде.

Миләүшә белән бик җылы саубуллашып, аны автобуска утыртып җибәргәч, Гәүһәр кул болгап, озатып калды. Аннары тирә-ягына каранды: кая барырга? Кайтыргамы? Юк, үзәк ун-унбиш минутлык кына юл булса да, монда гел килеп булмый бит. Форсаттан файдаланып калырга кирәк. Китап кибете якында гына. Гәүһәрнең күптән кергәне юк.

Кибетне шушы арада гына ремонтлаганнар, бөтенләй иркенәеп киткән, нәкъ зур шәһәрдәгечә булган. Барысы да күренеп тора. Гәүһәр күргәзмәгә куелган китапларны карап чыкты да күңеленә ошаган бер шигырь китабы, бер роман сатып алды. Элек аңа «китап җене» кагылган иде. Казанда кайда яңа китап күрсә, шунда сатып ала иде. Яшел Ярга килгәч, ул китап алмаска тырышты, күңеле утырып җитмәгән, тагын барысын ташлап калдырырга туры килмәгәе, дип уйлады. Быел, бигрәк тә кышкы каникулдан соң, ул ничектер төпләнде кебек. Һәрхәлдә, моннан тиз генә китәргә уйламый шикелле. Үз-үзенә ачык кына әйтмәсә дә, экренләп тормышны яңабаштан корырга кереште, кибетләргә чыккалады, күңеленә ошаган теге-бу әйберне сатып алды.

## 8

Әле моннан бер атна элек балаларга: шимбә көн тимер-томыр җыярга чыгабыз, дип әйтелгән иде. Шуннан соң классны бишәр-бишәр итеп төркемнәргә бүлделәр, һәр төркемнең үзләреннән башлыклары билгеләнде. Тимер-томыр хәзер һәр җирдә аунап ятмый, балалар алдан күз сала торырга тиеш, кем кайда күрә, онытмасын, утын сарайларында бәлки искедән калган ватык тимер караватлар, тимер әйберләр бардыр. Өлкәннәр белән сөйләшергә, алар ярдәм итәр. Өлкәннәр белән сөйләшүгә Гәүһәр аеруча басым ясады, чөнки балаларның күбесе әле кайда нәрсә ятканын белми дә бит. Гәүһәр балаларга урамнардагы яңа машиналарны, Камадагы яңа пароходларны күрсәтте. Менә шундый машиналар күбрәк булсын өчен, безгә тимер-томыр кирәк, диде.

Шимбә якынлашканда барысы да кат-кат сөйләнгән иде кебек. Гәүһәр балаларга сиздерми генә борчылды да. «Укытучы әйтте...», «Укытучы кушты...» дигән сүзләр генә хәзер балаларга аз бит. Хәзер бала гаҗәп күп белә, бөтен планета тормышы аның күз алдында: һәр өйдә радио, телевизор бар. Тик өлкәннәр һәр җирдә... бер төсле сөйләмиләр. Кайсыберләренең шул ук тимер-томыр җыюдан да көлүләре мөмкин, хәтта: «Ярар, синнән башка да җыярлар әле, аларның бүтән эшләре юк!» дип кычкырулары бар.

Балаларны, бер сәгатьтән җыелырга кушып, кайтарып җибәрделәр. Гәүһәр тагын бер мәртәбә класс эчен күзәтеп чыкты. Стенада яңа рәсемнәр. Уртада «Ленин Кремльдә өмәдә» рәсеменең репродукциясе. Балалар аның алдында бик озак туктап торганнар иде. Мәктәп ишек алдында, биек мачта башында, дружина байрагы җилферди. Мәктәп радиосы «Һәрвакыт булсын кояш»ны җырлый.

Бераздан балалар җыела да башлады. Гәүһәрне беренче шатландырганы шул булды: аның классындагы балалар барысы да килгәннәр.

— Бригадирлар,— диде Гәүһәр.— Хәзер эшкә керешегез. Кая барырга кирәген беләсезме?

— Беләбез!

— Мин монда булачакмын. Тагын бер мәртәбә әйтәм: төзелешләргә кереп, эшкә яраклы бернәрсә дә алмаска.

Соңгы елларда аяк астында аунаган тимер-томырларны балалар җыярга өлгергәннәр иде инде. Ләкин алар һич уйламаган җирдән яңадан-яңаларын табалар. Тутыгып, күгәреп беткән төрле тимер кисәкләрен каян гына казып чыгармыйлар. Гәүһәр күбрәк алып кайткан бригадаларны мактады. Барысын балалар белән бергә үлчәде, язды. Ә яңадан-яңа балалар тимер-томыр кисәкләрен кайсы сөйрәп, кайсы кечкенә арбаларга салып мәктәпкә китерә тордылар. Акназарлар каяндыр ике тәгәрмәчле арба алганнар да шуңа шактый зур машина кисәге салганнар. Гәүһәр исе китеп:

— Каян алдыгыз моны, ничек арбага күтәреп салдыгыз? — диде.

— Ул чокырда әллә кайчаннан ята инде. Туфрак белән күмелеп беткән иде. Тимер көрәкләр белән казыдык. Аннары бер шофер абый чылбыр белән бәйләп, югла чыгарышты, бергәләшеп арбага куйдык.

Балалар кызарышканнар, яңаклары ут булып яна, үзләре чиксез канәгать иде. Үлчәүгә куйгач, барысыныкыннан күбрәк тартты.

— Әттә генәсе! — диде завхоз.— Младец, егетләр һәм кызлар!

Гәүһәр бүген эштән бик канәгать булып кайтты. Бөек бәйрәм алдыннан өмәнең яхшы үтүе, андый-мондый начар хәлләр булмавы шатландырды. Алтынчы класс балалары гына күршедәге төзелеш мәйданына кереп труба «чәлдергәннәр». Аннан бер абый килеп бик яман тавыш куптарды. Шундый хәл була калса, оятыңнан керер тишек тапмассың.

Өмә тиздән булачак бөек бәйрәмнең бер пункты иде. Дүшәмбедән башлап чынлап торып бәйрәмгә әзерләнүгә тотынырга мөмкин. Гәүһәрне бәйрәм комиссиясенә керткәннәр.

Гәүһәр юынган арада да, өстәл янына утырып, тамагын туйдырганда да Зәбирә түти дәшмәде, ашарга утырмады, нигәдер ашыйсым килми, дигән булды. Гәүһәр рәхмәт әйтеп урыныннан торды да Зәбирә түтине муеныннан кочып:

— Урамда шундый күңелле, һавадан бәйрәм исе аңкый, ә син шундый чакта ут йоткан кебек йөрисең. Ни булды, Зәбирә түти? Әйт тә бир, мине дә хафалама, үзең дә кара көймә. Кешеләр шатлыкларын да, кайгыларын да бергә-бергә күтәрә дисең бит.

— Һай, Гәүһәрем, шундый шатлыклы көннәрендә әйтәсем дә кил-

мәгән иде, күрәсең, бөтен кешегә дә шатлык бирьюлы килми. Талия авырый бит.

— Талия!?

— Нигә шулхәтле гаҗәпләнәсең? Без бер урам кешеләре ләбаса. Яхшысы, яманы — барысы бергә.

— Ул каядыр киткән дип сөйләгәннәр иде бит.

— Өч аймы, өч ай ярыммы кайдадыр Урта Азия ягында йөргән. Шунда ниндидер яман бер зәхмәткә туры килгән. Дүшәнбедә дә, Казанда да докторларга күрендем, ди, бер файдасы булмады, ди. Сары яфрак кебек кипкән, мескен, таный да алмый тордым.

— Син аларга кергән идеңмени?

— Өйдәше килеп чакырды. Ул чакырмаса, белмәгән дә булыр идем. Акназарын бик күрәсе килә. Теленнән дә төшерми.

— Интернат ерак түгел бит. Чакыртырга иде.

— Чакырткан, килми, ди.

— Ул чагында үзенә үпкәләсен, Зәбирә түти. Яхшы анадан бала китми. Колониягә озатырга кирәк ул разбойникны, дип үземә әйткәне бар.

— Ачуы килгәндә әйткәндер инде. Әйткән сүзенең ахырын уйламады. Бер үк, Гәүһәрем, актык көннәрендә кешеләр бәгырьсезләр дип рәнҗи күрмәсен. Берәү дә бу дөньяга мәңгегә килми.

— Зәбирә түти, мин сине аңлап бетермим. Шулай бик каты авырыймыни?

— Каты дип кенә әйтү аз, Гәүһәрем. Әҗәл тушәгендә.

— Алайса врачларга әйтергә кирәк, больницага салсыннар.

— Әйткәннәр инде. Ничә килеп караганнар. Больницага барырга үзе теләми. Үз өемдә үләм, ди.

Гәүһәрнең Талиягә бөтенләй хөрмәте юк, бу аның һәр сүзеннән сизелеп тора иде. Зәбирә түти беркадәр вакыт эндәшмәде. Аннары әрнеп әйтте:

— Укытучыларны да әйтер идем инде... Сез мәңге дөрес, мәңге хата сүзләр белән генә эш итәсез, ахры. Җитмәсә, үзегез югары мәктәп өтергәнсез. Талия, яхшымы, яманмы, шәкертегезнең анисе. Үлеп китә, нишләрсез? Бала бит үскәч сездән сорар, нигә үләр сәгатендә иемне күрсәтмәдегез, дияр. Ул анисенә гел ачулы булмас.

Гәүһәр урыныннан торды. Мәктәпкә барырга вакыт иде. Ул сүзсез генә киенә башлады. Аннары әллә Зәбирә түтине, әллә Талияне кызганып:

— Узышлый кереп чыгармын. Син, Зәбирә түти, зинһар, борчылма,— диде.

— Шулай итә күр, Гәүһәр. Ярамаган эшләре күп булса да кеше бит...

Әле урамда чакта да, Талияләрнең капкасын ачканда да Гәүһәрнең күңелендә кызгану хисе юк иде. Ул Талиядән әрләү сүзләре ишетергә әзерләнде. Чама белән җавапларын да уйлады. Әлбәттә, Гәүһәр тупас сүз әйтмәс, шул ук вакытта укытучы дәрәҗәсен дә саклар.

Гәүһәр өйгә керде. Сөлгеләр белән бизәлгән олы бүлмә. Янда бер тәрәзәле тагын бер кечерәк кенә бүлмә. Бу бүлмәгә Гәүһәрнең әлек кергәне юк иде. Караватта Талия ята. Аны күргәч, Гәүһәр бер адым артка чикте, үзе белән бүлмәгә кергән карчыкка карады. Карчык хәсрәтле кыяфәт белән башын селкеп алды. Сүз әйтү кирәкми иде.

— Әби, Акназарым килдеме? — диде Талия, йомган күзләрен ачмыйча. Тавышы бик зәгыйфь, бик хәлсез ишетелде.

— Юк, бу Акназарның укытучысы килгән. Таныйсыңмы аны?

— Укытучы...— Талия берничә мәртәбә авыр сулыш алды, күзләрен ачмады.

— Талия, хәлең ничек? — дип сорады Гәүһәр.

— Сез... хәлем... Акназарым да килдеме?

— Хәзер чакыртырмын.

— Күрәсем килә... Әнисенә... Уф, янам! Су бирегез, су!

Гәүһәр аптырап карчыкка карады. Карчык тастымалны тәрәзә төбендәге суга чылатып Талиянең маңгаена куйды. Бераздан Талия тирән сулыш ала-ала тынды. Ул тагы да кечерәебрәк калды шикелле.

— Доктор чакыртканыгыз бармы соң? — диде Гәүһәр әбигә.

— Чакырттык, килеп тә карадылар. Дару да бирделәр. Файдасы гына юк. Син, кызым, Акназарын чакыртсаң иде. Дөнья хәлен белеп булмый бит.

Гәүһәр урамга чыкты. Хәзер ул Зәбирә түтинең хәлен аңлый иде. Үзе дә тирән итеп көрсенеп куйды. Әле кайчан гына Талия сау-сәламәт иде, менә, Зәбирә түти әйтмешли, әҗәл түшәгендә ята инде. Соңыннан Талиягә әйтәсе сүзләр дә булыр әле, аның барлык адымнарын, барлык эшләрен акламаслар, әмма хәзер... бары тик кызгану хисе һәм, мөмкин булса, аңа ярдәм итү теләге генә өскә чыккан. Гәүһәр йөгерә-йөгерә мәктәпкә ашыкты, туп-туры Бибинур янына керде, Талиянең хәлен сөйләп бирде. Бибинур шунда ук урыныннан торды, аннары алар интернатка киттеләр. Башта Акназар әнисе турында ишетергә дә теләмәде, күрәсең, аны яңадан әнисе янына кайтаралар дип уйлап, мин аның янында барыбер тормыйм, диде.

— Без сине аның янына кайтармыйбыз, Акназар. Ул авырый, аның хәлен барып белергә кирәк. Гәүһәр апаң әниең янында булган, ул сине күрергә тели.

— Мин аңа кирәк түгел. Дүшәнбегә киткәндә мине чакырмады ич.

Бибинур белән Гәүһәр ике яклап үгетләделәр. Җиһан да килеп кушылды. Ахырда малай җиңелде. Бераздан алар өчәүләп урамга чыктылар. Гаҗәп, урамда музыка уйный, бөтен җирдә яшәү тантана итә. Шул ук вакытта Талия үлем түшәгендә ята. Гәүһәр дә, Бибинур да шулай уйладылар, тик Акназар гына үлемне күз алдына китерә алмый иде. Ул укытучылары әйткәнгә генә әнисе янына бара. Анда бераз торыр да күңелле интернатка кайтыр. Алар бәйрәмгә бүлмәләрне бизиләр.

Гәүһәр Акназарны кулыннан тотты һәм алар өчәүләп өйгә керделәр. Кечкенә бүлмәгә уздылар. Талия һаман күзләрен йомып ята. Аяк тавышлары ишетелгәч, керфекләре калтырап китте.

— Улым...

Гәүһәр баланы әнисенә таба этәреп.

— Талия, менә бирердә ул,— диде.

Бала инстинкт белән артка чигенде, әнисенең күкрәгенә капланмады. Ул аңа сәерсенеп карап торды, бу аның әнисеме?

— Кая? — Талия әкрен генә кулын кыймылдатты, күзләреннән ике бөртек яшь чыгып, ябык яңаклары буйлап тәгәрәде.

Укытучылар сүзсез үгетли торгач, бала әнисенең кулын тотты, аннары үзе дә сизмәстән аның күкрәгенә капланды. Талия күзләрен ачмады, тик сулышы гына ешайды. Бераздан аның сулышы тәмам тукталды. Бибинур апа белән Гәүһәр урыннарыннан тордылар. Карчык калтыранган кулларын сүзсез генә кыймылдатып торган иреннәре янына китерде...

## 9

Бәйрәм араларында көннәр дә бик җылы торганга, Яшел Ярга Хәйбүш бабай килде. Өстенә җылы бишмәт, башына киез ак эшләпә, аягына резин галош белән киез итек кигән Хәйбүш бабай, кулындагы тамыр таякка таянып, Гәүһәрләр өенә озак кына карап торды да:

— Борынгы авыл өендә яшиләр икән,— диде. Моны ул әллә би-

тәрләп, әллә яхшыга юрап әйтте инде, карт кешенең бик үк белеп бетермәссен.
— Хәйбүш бабай, исәнлек-саулыкмы?
Гәүһәр карт белән ике куллап күреште.
— Ә, килен, саумы, сәламәтме? — диде карт, Гәүһәр белән Әгъзәмнең, елмаешып, күзгә-күз карауларын сизмичә.— Менә сине дә күрер көн бар икән. Тамаша.
— Хәл белә килгән өчен бик зур рәхмәт, Хәйбүш бабай. Әйдүк, өйгә керегез. Тирләгәнсездер дә.
Гәүһәр белән Әгъзәм, бабайны икесе ике яктан култыклап, өйгә алып керделәр. Аларны бик ачык чырай белән Зәбирә түти каршы алды. Исәнлек-саулык сорашты.
Хәйбүш бабай нечкә мыегын, кечкенә ак сакалын сыпырып, дога кылды да әкрен генә елмаеп куйды:
— Кем, Зәбирә, мактанырга урын калмаган инде. Егерме-утыз ел элек булса, бабаңның дәрманы бар иде әле. Мине Стахеев абзаң өрмәгән җиргә утыртмады. Сез инде, яшьләр, Стахеевны белми дә торгансыздыр. Камада шундый бер миллионер бар иде. Алабугада тора иде. Яр буенда менә дигән таш пулатлары. Бөтен Кама буеның ашлыгы аңа агылып торды. Вяткадан да, Агыйделдән дә, Кама белән Иделдән дә. Мин бер гади крушник кына, ә бай минем белән исәнләшер өчен кул бирә. Сизә иде ул, шельма, миндә нинди көч барын.
— Стахеев, бабай, егерме-утыз ел гына элек булмаган, ул революциягә кадәр яшәгән.
— Мин яшәмәгән димме? Яшәгән шул. Син менә, Әгъзәметдин, Алабуга янында Пәри шәһәрен күргәнең бармы? Шайтаннар аны бер төн эчендә салганнар, ди. Әтәчләр кычкырмаса, алар аны салып бетерә торган булганнар, әтәчләр кычкырган...
Зәбирә түти белән Гәүһәр табын әзерләделәр, кайнар пәрәмәчләр китереп куйдылар.
— Хәйбүш бабай, якынрак утыр әле. Менә шулай. Зәбирә түти, катык та бар түгелме?
— Бар, бар, Гәүһәр. Кар базына, бераз суынсын дип, төшереп куйган идем. Хәзер китерәм.
Бу вакытта Хәйбүш бабай бишмәтен, киез эшләпәсен салган иде. Эшләпәсе астында ялпак түбәтәе бар икән. Бишмәте астыннан мех эчле җиңсез тән җылыткыч кигән иде. Өй шактый эссе булса да, карт күнеккән киемен салырга теләмәде.
— Тыштан өегез минем шикелле генә булса да,— диде ул, бераз дәшми торгач,— эчтән бик иркен икән. Нәкъ бакча төсле.
— Я инде, бабай, сүз белән генә мавыкмагыз. Пәрәмәчтән житешегез. Менә катык та бар.
— Рәхмәт, рәхмәт, кем, Зәбирә. Менә Гәүһәр киленне күрдем, күңелем тынычланды. Карт кеше, үзең беләсең инде, юк нәрсәдән борчылучан була.
— Борчылырга кирәкми, Хәйбүш бабай. Безгә берни булмас.
— Анысы шулай да, Гәүһәр килен, күңел бар бит. Яшь чакта искә-акылга килми торган нәрсәләр, картайгач, сыгып салалар... Пәрәмәчегез бик тәмле икән, тагын берне ашамый булмас. Тамаша.
— Туйганчы ашагыз, бабай. Менә чәйдән дә житешегез. Әгъзәм, син нәрсә карап торасың? Сөйләшмисең дә, ашамыйсың да, эчмисең дә.
Әгъзәм көлемсерәде.
— Мин шундый сәгатьләр күбрәк булсын иде дип телим, Гәүһәр. Сөйләшү, ашау-эчү качмый ул.
Гәүһәрнең йөзенә җиңелчә кызыллык йөгерде, ихтыярсыз дулкынлануын сиздермәс өчен, юри шаярган булып кыланды.

— Менә шундый кешеләрне кунакка чакыруы да әйбәт, Зәбирә түти. ашамый-эчми, үзе бик канәгать. Харап инде.

Хәйбүш карт чәй эчкәч өстәл артында ук йокымсырый да башлады, Зәбирә түти мендәр китереп салды.

— Бала инде,— диде ул, шыпырт кына,— күр, йокыга да китте.

— Син дә әзрәк сузыласыңмы? — диде Гәүһәр Әгъзәмгә.— Нигә көлемсерисең?

Ул көнне алар озак сөйләштеләр. Хәйбүш картның «Гәүһәр килен» дип әйтүләре, әлбәттә, эзсез үтмәде. Алар икесе дә моңар игътибар иттеләр. Билгеле, картның сүзен берәү дә чынга алмый, әмма шул ук вакытта берәү дә аңа каршы да килми иде.

Ниһаять, бабай уянды, Зәбирә түтинең яңадан чәе кайнаган иде. Тагын бер самоварны бушаткач, кунаклар, мең рәхмәтләр укып, кайтып киттеләр. Гәүһәр аларны капка төбенә кадәр озатып калды. Икенче көнне иртә белән Әгъзәм Хәйбүш картны Яшьлек шәһәренә илтеп куярга тиеш.

Кич белән Гәүһәр, бүлмәсенең ачык тәрәзәсеннән карап, бик озак ялгыз утырды. Аңа рәхәт тә, әзрәк ямансу да, Зәбирә түти ишек алдында кош-кортларын урнаштырып йөри. Ата каз берүзе га-га дип гайрәт чәчә. Ана казлар бар да ояда, бәбкә чыгаралар.

Иртәнге якта, гадәттәгечә, мәктәптә дәресләр булды, аннары Гәүһәр классын яр буена алып төште. Быел су буенда бер булсалар да, урманга кадәр барып җитмәгәннәр иде. Хәзер җир коры. Дөрес, агачлар әле тәмам яшел бөдрәгә төренеп җитмәгән, әмма берничә көннән бу җирләрне танымассың да. Хәзер үк урман бер караганда яшел, бер караганда алсу төскә керә. Яр буйларына, су өсләренә үзенә бер төрле бизәк салганнар кебек. Су быел мул булды, боз күптән аккан булса да, Кама җәйге ярларына кайтырга уйламый, кайбер агачлар һаман су эчендә әле. Алар тирә-якка үзенә бертөрле төс бирә. Художник өчен монда «азык» күп. Мольбертын Гәүһәр теләр-теләмәс кенә алды. Аның Алабугада булганы, бөек художник туган йортны — музейны күргәне юк, әмма бу урманнар Шишкин урманнарына бик якын бит, кем белә, ихтимал, Шишкин үзе дә бу тирәләрдә булгандыр, яр буйларына карап торгандыр. Юкка гына бу яклар табигать җырчысын тудырмагандыр. Бу яклар гомумән мәшһүр шул. Киң Россиянең шул җирендә кавалерист-кыз туган! Унбер ел армиядә хезмәт иткән, исеме данга күмелгән Кутузовның адъютанты булган...

Балаларның һәркайсы үзенә матур урынны сайлап алган. Әнә бер читтәрәк Акназар нинди шәп урын сайлаган. Гәүһәр аның үзе ясаган мольберты янына килеп, бу баланың зәукы нечкәлегенә исе китеп, бер табигать күренешенә, бер рәсемгә карап торды. Ул монда киңәш биреп бары тик бозарга гына мөмкин икәнен аңлады.

Гәүһәр мольберттан мольбертка күчеп йөрде, берсен мактады, берсенә киңәшләр бирде. Аннары үзе дә эшкә утырды. Ул үзенең дә тик тормавын күрсәтергә теләде. Әмма онытылып китте, табигать белән икәүдән-икәү генә калды. Һәм табигать, шуңа рәхмәт әйткән шикелле, үзенең яшерен серләрен аңа тирәнрәк ачарга тотынды, төсләрен мулрак күрсәтте. Гәүһәрнең күзе үткенәеп, кулы ныгып киткәндәй булды. Су эчендә калган агачларны бөтенләй яңача күрде, аларның кеше телендә әйтелмәгән сүзләрен аңлап, шуларны буяуларына күчереп утырды. Күңеле иҗат нуры белән балкыды. Ул хәтта үзенең укытучы икәнен онытты, янында балалар да, берни дә юк иде кебек. Кайчагында ул чак кына елмая, кайчагында, пумаласын тоткан көе, табигатькә карап тынып кала, күзләре генә, нәрсәдер эзләп, ялтырыйлар. Киң, шома маңгаендагы текә сызык әкрен генә калтырый. Тотып аласы уй кайдадыр бик якында гына кебек. Шулай да бер минут, ике

минут тын тора, аннары ашыгып-ашыгып пумаласын йөртергә тотына...

Ниһаять, ул эшеннән аерыла, үзенең укытучы икәнен исенә төшерә, яңадан балаларның мольбертлары тирәсендә йөри.

## 10

Бик озакка сузылса да, ахыр килеп, Гәүһәр Әгъзәм белән дә аңлашты. Ул көнне Гәүһәр бик дулкынланды, төне дә әллә ничек булды, бәхет тә, борчу да бергә өелде, карасаң, хәзер ул көннәр дә үткән. Алай гына түгел, ул көннәрне Гәүһәр хәтерләми дә кебек. Билгеле, бу артык борчылганга гына шулай, күпмедер вакыт үтәр, барысы да бөтен ваклыкларына кадәр хәтергә төшәр, ихтимал, ятларга булмаса да, бер-берсенә сөйләрләр дә әле. Сәгатьләр буе, юк, гомер буе сөйләргә житәр!

Классындагы актыккы көн турында Гәүһәр ике ел буенча күп уйлады, ул көн, зәңгәр йолдыз сыман, бик ерак, бик томанлы иде. Инде ул көн дә үтеп бара. Балалар чыгып киткәч, класс тып-тын калды. Дөрес, алар әле бөтенләй китмәгән, аларның күңелле шау-гөре түбәндә ишетелә әле, алар анда Гәүһәрне рәсемгә төшәргә көтәләр. Балаларга ни, аларга шул рәсемгә төшү шатлыгы да житкән, ә Гәүһәрнең күңеле ташына, күзеннән яшь тә бәреп чыга. Менә буш класста, өстәл янында ул берүзе утыра, инде бер бала да аңа берәр йомыш белән мөрәҗәгать итмәс. Хәтта Гәүһәрнең укучылары арасында иң яраткан шәкертләре — Акназар белән Зилә дә аның яныннан киттеләр инде. Класста укыткан чагында моны балаларга сиздермәде, ул үзен барлык балаларга да бертигез сыман тотты. Хәзер, үзенә булса да, кемне күбрәк ятратканыңны әйтергә ярый торгандыр. Ул аларны моннан соң укытса да, укытмаса да, көче житкән кадәр күзәтер әле. Билгеле, башкалар өчен дә сөенер, әмма бу ике бала аның йөрәгенә ничектер артык якынрак булдылар.

Әйтүе ансат, ике ел буе аның кулында утыз өч бала иде. Бу утыз өч баланың утыз өч төрле холкы бар. Юк, утыз өч төрле генә түгел, аларның әле утырып житмәгән холыклары көненә утыз өч төрлегә үзгәргәндер. Алар, үзләре дә сизмәстән, Гәүһәрнең күпме йөрәк җылысын алганнардыр, күпме төннәр буе йокламаска мәҗбүр иткәннәрдер. Дөньяда моны үлчи торган үлчәү бармы?

Гәүһәр көрсенеп куя: балалар... Ихтимал, тәҗрибә туплана, яшь олыгая барган саен, аларны тирәнрәк аңларга мөмкин булыр, һичбер дәреслекләрдән табылмый торган белем менә шунда ятадыр. Аларның хәтерен калдыру — ансатның ансаты, рухларын төзәтү — авырның авыры. Балаларның бертөрлесе бик яхшы, бертөрлесе яхшы, калганнары уртача гына укыдылар,— ансы беркемгә дә сер түгел. Дүртенче класс белән аларның тормышында беренче баскыч төгәлләнә. Балалар үзләре белмиләр, бу класстан класска күчү генә түгел, зуррак нәрсә. Укытучы бу турыда күпме уйлады! Асылда ул бит утыз өч баланы гына укытмады, бәлки утыз өч билгесез белән хисап мәсьәләсен чиште. Хәзер инде кулны күкрәккә куеп әйтергә була: куркыныч чик үтелгән, бер генә бала да класста утырып калмаган! Моңа ничек шатланмыйсың? Гәүһәр шатлана. Ул бит үзе дә, әгәр имтиханнарын тапшыра алса, яңа баскычка күчәргә тиеш. Үзең күчеп, балаларың класста утырып калса, нинди күңелсез булыр иде. Билгеле, киләчәкне тулаем күз алдына китерү кыен, мөгаен, шатлыклары да, кыен чаклары да булырдыр, әмма быелгы утыз өч бала, ахыр килеп, Гәүһәрне хәл ителмәс борчуга салмады, алар беренче сынауны егетләрчә үттеләр. Хәзер буш класста бераүгә дә курсәтмичә туйганчы елыйсы иде. Әмма Гәүһәр еламый, ул бары тик күзләрен генә сыпырып ала, анна-

ры урыныннан тора. Актыккы мәртәбә буш һәм тын класска карый да... әкрен генә елмая. Бу елмаю сагыш катыш булгандыр инде, укытучы моны еракк арак яшерде. Җиңел адымнар белән балалары янына төшкәндә аның йөзендә шатлык кына иде. Балалар, аңа каршы йөгереп килеп, чәчәкләр бирделәр.

— Гәүһәр апа, үзебез җыйдык, болары сезгә,— диде Зилә, яңгыравыклы тавыш белән.

— Рәхмәт,— диде Гәүһәр, нәфис чәчәкләрне күкрәгенә кысып, аннары ак якалы, ак алъяпкычлы балаларның башларыннан сыйпады.

Урындыклар тезеп куелган иде. Балаларның һәрберсе, этешә-төртешә, укытучыга якынрак утырырга тырышты. Гәүһәр моны бик яхшы күрде, балаларга шушы әчкерсез мәхәббәтләре өчен күңеленнән рәхмәт әйтсә дә, тыштан берни дә сиздермәде, ыгы-зыгы килүләре өчен балаларга ачуланмады, аларны әрләмәде. Аңа шушы шау-шулы балалар арасында утыру бик күңелле иде.

Фотографны район газетасыннан чакырганнар икән. Елгыр егет, мыеклы үзе. Гәүһәрнең Әгъзәмдәге рәсемен дә шул егет төшереп алган иде инде.

— Күзләрегезне чекерәйтмәгез, тыныч кына утырыгыз. Әй, менә син, нигә телеңне чыгарасың!.. Я, тынычланыгыз, шау-шу бетте. Тссс! Менә чәнчә бармагым башына карагыз. Һоп! Көлмәскә! Тагын бер мәртәбә. Түшәмнән конфет эзләмәгез, ул менә минем чәнчә бармагым башында. Тынлык. Карагыз. Һоп! Булды, рәхмәт.

Балаларның кайберләре йөгереп чыгып китте, кайберләре Гәүһәрне сарып алдылар. Шау-гөр килеп, алар Гәүһәргә сораулар бирделәр, нәрсәләрдер сорадылар. Гәүһәр, чәчәкләрен күкрәгенә кысып, барысы белән берьюлы сөйләште, йөзеннән елмаю китмәде. Ул әле берсенең, әле икенчесенең аркасыннан какты. Зилә, мөмкин булса, аның кочагына керер иде, Акназар да шунда, арттарак басып тора. Ни әйтсәң дә малай кеше, кызлар кебек, тойгыга бирелми.

Ниһаять, Гәүһәр балаларның барысын да озатып җибәрде. Үзе бер минут алар артыннан карап торды. Күзләренә яшь килде, үзен ялгыз итеп, ятим итеп сизде. Ул арада звонок булды, коридорда өлкән класс балалары шаулаша башладылар. Гәүһәр чәчәкләренә иелде, күз яшьләрен йотты. Аннары яңадан өскә күтәрелде, аның әле Бибинур апаны күрәсе бар. Баскычта һәм коридорда укучы балалар, укытучылар аның белән исәнләштеләр. Миләүшә хәтта аны култыклап алды, укулар тәмамлану белән котлады.

— Вилдан исән-саумы? — дип сорады Гәүһәр, коридор буйлап укытучылар бүлмәсенә таба бара-бара.— Бишенче көн инде күргәнем юк.

— Монда ул. Кабинетында булса кирәк. Хәзер мине берүземне беркая җибәрми. Белмим инде, бала тугач та шундый булырмы? — Миләүшә сагышлы гына елмаеп алды.— Көннәре якынлаша барган саен, борчуым арта бара.

— Бер дә борчылма, Миләүшә. Бәби туена әзерлән.

Бераздан Миләүшә укытучылар бүлмәсенә, Гәүһәр директор янына кереп китте. Директор бүлмәсе бервакытта да буш булмый, әле бу, әле теге укытучының йомышы төшә. Башлангыч класслар укуларын тәмамлаган булса да, икенче баскычта әле кызу көннәр. Шуңа күрә һәрберсенең директорда ашыгыч эше бар, һәркем эш турында директор белән бер-ике авыз сүз алышырга тырыша. Гәүһәр, эше артык ашыгыч булмаганга, исәнләште дә диванга — Гөлсем апа янына утырды.

— Я, Гәүһәр, укуларыңны тәмамладыңмы? — диде ул, яшь укытучының бәхетле йөзенә карап. Һәм барысы да исенә төште. Кайчандыр аның да менә шундый чагы бар иде, ул да шатлыктан исерә, кайчагында җиңелчә сагышлана да иде. Кай арада еллар үткән! Аңа

инде алтмыш яшь тулды, шуның кырык елга якыны мәктәптә, балалар белән бергә узган.

— Тәмамладым, Гөлсем апа. Иңемнән тау төшкәндәй булды. Тик хәзер, балаларымны кайтарып җибәргәч, ямансулыйм да. Әллә нәрсә генә онытылган, әйтелмәгән кебек.

— Боларны инде, Гәүһәр, барыбыз да кичергән. Шулай да киләсе елда син тагын класска керерсең, әйтелмәгәнеңне шунда әйтерсең. Менә мин актыккы дәресләремне укытам инде. Киләсе елга мәктәптә дә булмам, булсам да, читтән караучы булып кына. Менә шунысы бик авыр, Гәүһәр.

— Сез үз бурычыгызны намус белән үтәдегез, Гөлсем апа. Авыр булса да, күңелегез тыныч сезнең.

Коридорда звонок шалтырады. Гөлсем апа, тиз генә урыныннан торып, директор янына килде, аның белән бер-ике авыз сүз алышты да, Гәүһәр белән саубуллашып чыгып китте. Башка укытучылар да берәм-берәм ишеккә юнәлделәр. Гәүһәр Бибинур янына барып утырды.

— Рәсемгә төштегезме, Гәүһәр?

— Төштек, Бибинур апа.

— Яхшы булган. Бүген вакытым юк, иртәгә сәгать уникеләрдә минем яныма кер. Минем сәгатьләрем иртәнге якта гына. Барысы турында да иркенләп сөйләшербез. Без элекке уебызда торабыз, Гөлсем сәгатьләрен сиңа бирербездер. Син кайчан Казанга китәсең?

— Шушы берничә көн эчендә китәрмен. Бераз алданрак барып, әзерләнергә уйлыйм.

— Дөрес итәсең. Анда тынычрак, көн үткәне сизелмәс тә, уку гына исеңдә булыр. Әлбәттә, Галимҗаннарга туктарсың?

— Белмим әле, Бибинур апа. Алар сүз әйтмәсләр дә, аларга бик кыенга килер. Институтның тулай торагы булса, анда торыр идем.

— Галимҗаннарның хәтерен калдырырсың, Гәүһәр. Алар бит сине бик яраталар. Минемчә, әле вакыт бар, уйларсың. Ничек барырга уйлыйсың, самолет беләнме, пароход беләнме?

— Пароход белән дип торам, Бибинур апа. Имтиханнарны караштырырга да, уйланырга да әйбәтрәк су өстендә.

— Бик дөрес. Әзрәк ял да булыр, фикерләреңне дә туплый төшәрсең. Ял турында онытырга ярамый. Сиңа быел шактый кыенга туры килде, Гәүһәр.

Гәүһәр көлемсерәде. Булгандыр инде. Эчке көрәш эзсез үтмәгәндер. Яшь чакта, кеше беренче тапкыр тормыш корганда, уйланса да, ничектер башкачарак була, ватылган тормышны төзәткәндә, ай-һай, йөрәккә төшә. Күрмәгәнгә күрсәтмәсен, шул гына. Ихтимал, Гәүһәрнең кара чәче дә кайдадыр тамырларында агара башлагандыр, бер көнне көзгегә караганда аларны күреп тә алыр.

Гәүһәр, саубуллашып, чыгып китте. Урамда көн кояшлы, җылы. Бөтен дөнья инде куе яшеллеккә чумган. Җил дә юк. Әнә мәктәп бакчасы, уртасында Ватан сугышында һәлак булган Яшел Яр батырлары истәлегенә һәйкәл куелган. Балалар аны һәрвакыт карыйлар, тирәсенә чәчәкләр утырталар. Пионерларның тантаналы линейкалары һәрвакыт шунда үтә. Һәйкәл әле агачтан гына, бер заман таштан эшләнер.

Кичен Гәүһәрләргә Әгъзәм килде. Өстендә чигүле ак күлмәк, ялан баш. Ул ишек төбендә Зәбирә апа белән бик җылы итеп исәнләште, олы якта Гәүһәр күренмәгәч, әллә өйдә юкмы? дип сорады.

— Өйдә, өйдә,— диде Зәбирә түти.— Әнә чыга инде.

Үз бүлмәсеннән, кулына чәчәк тотып, елмая-елмая, Гәүһәр күренде. Ул бүген тәмам актан киенгән, туфлиләре дә ак. Әгъзәм белән кул биреп күреште.

— Бүген, мәктәптән кайткач,— диде ул, урындыкка утырып һәм икенчесен Әгъзәмгә күрсәтте,— тәрәзә төбемдә шушы чәчәкләрне күрдем. Бу — тагын балаларымның эше. Бик сөендем, Әгъзәм. Бу аларның эчкерсез ихтирамы.

— Әгәр ул чәчәкләрне мәктәптә бирсәләр, ул кадәр тәэсирле булмас иде, әйеме?

— Әйе шул. Әнә теге вазадагыларын мәктәптә биргәннәр иде.

Әгъзәм нурлы күзләре белән Гәүһәргә карады. Хәзер Гәүһәр янында аңа аеруча рәхәт. Иң мөһиме тагын шунда, ул Гәүһәр көнелендәгеләрне аермачык күрә. Хәтта аның күңелендәге иң яшерен серләрне дә белә. Элек бу кадәр түгел иде.

## 11

Зур хисләрне вак күңелләр тудыра алмый. Бу — мул сулы бөек Каманың агышы кебек бик табигый бер нәрсә. Тик ул зур хисләр бер тугач, бер әйтелгәч, аларны яңадан телдән кабатларга ярамый, кабатлау аларның матурлыгын бетерә. Бер әйтелгәч, алар арткарак чигенгәндәй булалар, әмма югалмый, алар һәрвакыт бар, күзгә күренмичә яши, синең һәр сүзеңдә, һәр хәрәкәтеңдә, һәр сулышыңда, һәр күз карашыңда ярылып ята, сине канатландыра да, дәртләндерә дә.

Гәүһәр Әгъзәмгә карап елмаеп куйды. Сүз әйтмәде. Нигә? Алар болай да бит бер-берсен аңлыйлар, әйтелмәгән теләкләрнең үтәлүе рәхәтрәк тә. Алар яр буена төшәбез, дип башта ук сүз куешмасалар да, Гәүһәр урамга чыгу белән шунда таба атлады, Әгъзәм берсүзсез аңа буйсынды. Аларның бу вакыттагы сүзләрен кәгазьгә күчерүе дә кыен булыр иде, алар ярым сүзләр генә әйттеләр, елмайдылар, көлделәр.

Хәзер яр буйлап, беленер-беленмәс сукмактан баруы аларга бик күңелле. Бер якта мәһабәт Кама ялтырап ята, икенче якта, тау битенә таба күтәрелеп, яшел урман сузыла. Һава тын, көндез искән җил басылган, хәтта яфрак та селкенми. Карт наратлар, мәһабәт имәннәр уйга чумганнар сыман. Гүя җемелдәп яткан Камага карап, нәрсәдер исләренә төшерәләр. Сукмак куаклар янынннанрак үтсә, йөзләргә тоҗым җепләре сырыша, чак кына кытыклап алалар. Кайчак Кама уртасыннан килгән ап-ак пароход күренә, вакыт-вакыт музыка да ишетелә, җыр да яңгырап куя.

Гәүһәр аз гына уйчан, Әгъзәм исә шундый шат, гүя ул урманны да, Каманы да күрми, аның өчен бары Гәүһәр генә бар, аның бөтен игътибары Гәүһәрдә генә. Янында Гәүһәрнең җиңелчә сулышын тою, ара-тирә ярым тавыш белән генә «Карагөл»не җырлап алуы, култыклаган кулыннан күчкән җылыга чак кына баш әйләнү — болар Әгъзәмгә әйтеп бетергесез бер рәхәтлек бирә.

Алар яр кырыена басып, кояшта ялтыраган киң Камага карап тордылар. Пароходлар, буксирлар, баржалар үтәләр. Әнә палубада бер яшь кенә хатын-кыз күренә, бәлки ул, Гәүһәр кебек, бәхетен татып исергәндер. Сөйләшәсе иде аның белән. Ни әйтер иде икән? Кешеләр бәхетне ничек кичерәләр икән?

Баржа күздән югала, сал сөйрәп баручы буксир да күренми. Ә Кама һаман җемелди. Шул миллион җемелдәүдән тагын әллә нәрсә туар шикелле. Гәүһәр күзләрен йома. Бәлки бер секунд, бәлки кимрәк уйланып тора торгандыр, аннары күзләрен ача, чак кына елмая.

Кич якынлаша, күләгәләр озая, кояш шактый түбәнәя. Гәүһәр белән Әгъзәм туктаган урыннарыннан кузгалалар. Алар уйсулыкка

төшәләр, тагын югары күтәреләләр. Монда бер күренеш тә икенчесен кабатламый, менә инде тоташ нарат урманы.

Кайта торгач, куе урманнан яңадан яшь урманга чыктылар, яңадан куаклар арасыннан Кама ялтырап күренде.

— Уф, арыдым,— диде Гәүһәр.

— Әнә анда эскәмия бар.

Борылышта, Каманың бик матур бер төше күренгән җирдә, буш урындык бар иде. Алар шунда килеп утырдылар. Гәүһәр, Әгъзәмнең иңбашына башын салып, күзләрен йомды.

— Әгъзәм, син ни уйлыйсың? — дип сорады бераздан Гәүһәр.

— Мин, юньсез, сине арыттым дип уйлыйм.

Гәүһәр көлеп җибәрде.

— Син һәрвакыт шундыймы, Әгъзәм?

— Син миннән үземне мактатма, моның өчен күп акыл кирәкми,— диде Әгъзәм.

Гәүһәр аңа карады да бармак янады. Яңагын Әгъзәмнең кул башына ныграк кысты.

— Син туфлиләреңне бөтенләй сал, аягыңны кыса, ахрысы.

— Каян беләсең?

— Аягыңа карап, күреп торам.

— Бигрәк үткен күзле икәнсең.

Кояш суга берничә карыш кына тимичә тора. Аңа карап та булмый, шундый көчле балкый. Әнә ул суга тиде инде, менә яртылаш батты. Тагын берничә секундтан аның кызыл шәүләсе генә калды. Башта бу шәүлә саф алсу иде, теге як яр бик ачык күренә иде, аннары шәфәкъ тоныклана башлады, ахырда тәмам каралды. Сүзсез калган Гәүһәр белән Әгъзәм әле тагын берничә минут алсу шәүлә урыныннан күзләрен алмадылар. Анда нәрсәдер балкыр күк тоелды аларга.

— Мин батып барган кояшка карап классымны уйладым,— диде Гәүһәр. Балалар да шулай балкыдылар да баттылар. Мәңгегә түгел, әлбәттә, иртәгә кояш чыккан кебек, алар да киләсе елга яңа класста күренерләр. Тик бүгенгедәй булмаслар. Алар белән аерылышу нигәдер ямансу.

— Бу бик табигый, Гәүһәр. Ләкин син балаларның зур булуларын уйла. Аларны гаҗәп эшләр көтә. Ахыр килеп, укытучының бурычы да аларны кеше итү бит, аларны зур эшләргә хәзерләү.

— Анысын аңлыйм... Шулай да... Әгәр син аларның нинди яхшы икәнлекләрен белсәң иде. Моның өчен алар белән еллар буе бергә булырга кирәктер.

— Мин балалар укыттым, мин моны беләм, Гәүһәр.

— Укытучы балаларга бөтен йөрәген бирә. Ярты-йорты белән ул канәгатьләнә алмый, дөресрәге, аны ярты-йорты килеш кабул да итмиләр. Балалар кечкенә булсалар да, исәпләре зурларча. Әгъзәм, син кайчан да булса көмеш ачкыч турында хыялланганың бармы?

— Көмеш ачкыч турында? Син һәр укытучының балалар күңелен ача торган серле көмеш ачкычы турында әйтәсеңме?

— Әйе, әйе.

— Аның турында кайсы укытучы хыялланмый икән.

— Кызык бит, Әгъзәм. Мин әлек бу турыда ачыктан-ачык хыялланырга курка торган идем. Кайчагында ул серле ачкычны ап-ачык күрәм, кайчагында ул югала, мин балалар күңеленә керә алмам, караңгыда адашып йөрермен кебек.

— Яшь укытучы өчен болай шикләнүләр бик табигый.

— Моны инде синең кебек начальниклар әйтсә әйтә торгандыр,— диде Гәүһәр, шаян көлеп.— Безнең кебек гади укытучыларга андый бөек акыл бирелмәгән.

— Чәнчәсеңме? Мин моны рәхәтләнеп тыңлыйм.

— Шулаймы? Мин шул көмеш ачкычны гомер буе югалтмасаң иде дип уйлыйм. Укытучы өчен иң кадерлесе шул булса кирәк. Югыйсә ул меңләгән, миллионлаган кешеләргә тиң булып кала, алардан бернәрсәсе белән дә аерылмый. Күрдеңме — нинди мәгънәле сүзләр әйтеп ташлыйм.

— Мин бу фикерләрдән көлмәс идем.

Күктәге алсу буяулар инде сүнгән, анда ай урагы күтәрелгән, көньяктагыча бихисап эре йолдызлар калыккан. Елга кояш яктысындагы матурлыгын, мәһабәтлеген югалткан, ул ничектер кечерәеп, ярлары арасына сыенып калган. Бер пароход, бер буксир юк, тик көндез күренми торган маяк кына кызыл күзен кыскалый. Гәүһәр, ярты сүздә туктап, каядыр елга түренә карый башлады. Һава җылы, чак кына җил исеп тора, йөздән, муеннардан, чәчтән сыйпый, гүя тынычландыра. Кайдадыр пристань ягында бик тонык булып тавышлар ишетелә. Черкиләр булмаса да, ялангач беләкләргә әледән-әле нинди-дер бөҗәкләр килеп куналар да җиңелчә кытыклап алалар.

Әгъзәм төшенде. Гәүһәр тагын үзен борчыган темага кагылды. Моңа ул төрле яклап бик еш туктала. Күрәсең, икәүдән-икәү булган рәхәт минутларда да бу аның исеннән чыкмый. Дөресрәге, ул киләчәк тормышы өчен борчыла. Инде зур адым да атланган, чигенергә урын да юк, чигенергә уйламый да, бирелгән вәгъдә — иман, әмма борчу калган, әгәр ул шундый минутта да үзен сиздерә икән, димәк, ул тере, аны бернәрсә дә баса алмаган.

Гәүһәр беләкләрен кушырып утыра иде. Минутлар үткән саен елгадан көчлерәк салкынча дым тарта. Ә Гәүһәр белән Әгъзәм бик җиңел киенгәннәр.

— Кузгалсак та ярый,— диде Гәүһәр, урыныннан торып, шул ук вакытта борылышта бөтен утлары белән балкып пароход күренде.— Менә бәхетлеләр. Бер кайгылары юк, баралар да баралар.

— Пароходта да кайгы күтәреп йөрмәсләр инде.

— Син бигрәк реалист икән, Әгъзәм...

Бу вакытта алар, култыклашып, тар сукмактан кайталар иде. Тонык ай яктысында сукмак бер күренә, бер югала, бигрәк тә куе куаклар арасында. Ләкин яшьләр моңа артык хафаланмадылар, аларның күзләре яхшы күрә иде.

Алар кырыйдагы берән-сәрән вак йортлар яныннан үтеп озын һәм киң урамга борылдылар. Өйләрдә утлар балкый, капка төпләрендә кешеләр утырышкан. Арада балалар да күренә. Гәүһәр, экрен генә кулын тартып алып, Әгъзәм белән янәшә бара башлады. Әгъзәм аның сүзсез хәрәкәтенә күнеккән иде. Ул үзе ныграк карап, ныграк тыңлап барды, кешеләр булган җирдә тавышын экренәйтте яки бөтенләй туктатты. Ара-тирә аларны яктыртып машиналар узып киттеләр.

Үзәк урамда халык шактый күп. Күрәсең, яңарак кына кинодан чыкканнар, барысы бер үк картина турында сөйләшәләр, берәүләре мактый, икенче берәүләре пыр туздырып сүгә, нигә шундый фильмнарны халык акчасын әрәм итеп чыгаралар, диләр. Гәүһәр белән Әгъзәм бу картинаны карамаганнар иде, бер якка да кушылмадылар, дөресрәге, бу турыда уйламадылар, чөнки аларның икесе өчен генә кадерле үз сүзләре бар иде.

## 12

Гәүһәр кулларын йөзеннән алды. Ул еламый, еларга уйламый да. Хисләре артык ташыганга гына йөзен каплады. Соң шулай булмыйча! Бу көн турында ул хыялланырга да курка иде. Югары белемле укытучы. Шундый авыр көннәрдән соң! Дөресен әйткәндә, ул укуын тәмамлар өчен укымады. Бу бик яхшы теләк, мавыктыргыч, шулай да бу көн бервакытта да килмәс, ул ерактагы таулар кебек, кайдадыр зәң-

гәр томан артында торыр. Хәтта кышкы имтиханнарны тапшыргач та, ул һаман шикләнде. Менә нәрсәдер булыр да, ул утырып калыр кебек иде. Ә иртәгә яки берсекөнгә диплом алып үзенең Яшел Ярына кайтачак.

Институтка берничә тапкыр Җәгъфәр килеп чыкты. Гәүһәр аны күрергә дә, аның белән сөйләшергә дә теләмәде. Шулай да бер тапкыр Җәгъфәр, искәрмәстән аның алдына чыгып, нәрсәдер сөйли башлагач, Гәүһәр ачы көлемсерәп:

— Карагыз әле, иптәш Мәүлиханов, боларны нәрсәгә миңа сөйлисез? — диде.— Алтын сүзләрегезне үзегезгә калдырыгыз, бәлки лекциягездә кулланырга ярар, ә мин тыңламыйм.

Һәм Гәүһәр, Җәгъфәрнең арттан килүенә карамыйча, китапханәгә кереп китте. Шулай аларның соңгы очрашулары булды. Билгеле, күңел төбендә Гәүһәрнең Җәгъфәргә ачынып, мәсхәрәле көлеп әйтәсе сүзләре дә булгандыр. Җәгъфәр, башын иеп, барысын тыңларга да хәзер. Гәүһәр элекке ирен горуррак кеше дип уйлый иде. Ә ул... Юк, күңел түрендәге, утта янып, күмерләнеп беткән сүзләрне аңа әйтеп түбәнәйтер хәл юк.

Кайткан чагында Гәүһәргә Исрафил Дидаровның хатыны Фәнүзә очрады. Ул Гәүһәр белән бик дәртләнеп күреште дә, гүя вакыты бик тар булганга, күңелендәген барысын да тизрәк әйтеп калырга ашыкты. Ул ире белән аерылышкан икән! Дүрт ай инде, ди.

— Гаҗәпләнмә, Гәүһәр бәгырем,— диде Фәнүзә, бик күңелле хәбәр әйткән кебек,— берьюлы кистем дә ташладым. Дусларым әйтә, бөтенләй үзгәрдең дип, хәтта күзләреңдәге курку да беткән дип. Соң шулай булмыйча! Исрафил янында егерме ел күләгә булып йөрдем. киемем яхшы булса да, үземнеке дип әйтерлек берсе дә юк иде. Оекларыма кадәр көн саен барлап тора иде бит. Кешегә сөйләргә оят, сөйләсәң дә ышанмаслар. Сине дә тинтерәтеп бетергән. Фаягөлгә дә күз яше белән әйттем, кешене җәһәннәм утына салмагыз, үзегез янарсыз дип. Көлде генә. Гел жизнәсен генә тыңлый, аның гына авызына карап тора иде. Хәзер гаҗиз булып йөри. Шул кирәк тә, сеңелем булса да кызганмыйм. Җәгъфәре дә артына тибеп чыгарган.

Гәүһәр бу хатынга карата үзен ничек тотарга да белмәде. Бер карасаң, аның тирән фаҗигасе дә, шуннан котылу шатлыгы да аңлашыла кебек, икенче карасаң, бар да буталып китә: гомеренең иң яхшы елларын шул Исрафил Дидаров белән торган бит ул, аның җырын җырлаган, көен көйләгән. Аерылуы да Дидаровның рәте беткәнгә генәдер бәлки. Фәнүзә әйтми әйтүен, алтын күзлек кебек берәр бәндәне тапмаганмы икән?

Шуларны Галимҗан абыйсына сөйләп биргәч, ул елмаеп куйды.

— Шулай, Гәүһәр, бездә туры юлдан барган кеше генә хөрмәткә ирешә. Туры юлдан читкә тайпылса, кеше бетә, югала,— диде.

— Галимҗан үзе турында сөйләми бит,— дип көлде Рәхимә апа.— Күк капусы ачылгандай булды.

— Әллә баш инженер итеп билгеләделәрме? — дип сорады Гәүһәр.

— Юк, мин инде карт ул эшкә. Тагын бер елдан пенсиягә чыгам. Баш инженер итеп Светлана Калужнаяны билгеләделәр.

— Светлана турында ишеткәнем бар иде дә, аның фамилиясе башка түгел идеме?

— Әйе, кызларның фамилияләре үзгәрә бит. Аның белән эшләве җиңел.

— Яшәреп киттем диген, Галимҗан.

— Яшәрүен яшәрмәгәнмендер, кадерем артты, ә кадерең арткач, пар канат чыккан күк була инде.

Гәүһәр, бераз исе китеп, Галимҗан абыйны беренче күргәндәй итеп карап торды. Галимҗан абый аңа бик-бик таныш, әтисе кебек якын.

Гәүһәр аңа килгән көнендә үк тулай торакка күчәргә нияте барлыгын әйтте. Галимҗан абый бу турыда ишетергә дә теләмәде.

— Кызлар бит сине әллә кайчан көттеләр. Син килергә ике атна калгач ук алар раскладушка кертеп куйдылар. Кайсы раскладушкага ятар дип, ике көн буенча бәхәсләштеләр. Тегесенең дә, монысының да сиңа яхшылык эшлисе килә. Шуннан соң, син тулай торакка күчеп китмәкче буласыңмы? — дип, Галимҗан абый көлемсерәп куйды.

...Ә бүген Гәүһәр шатлыгын яшерә алмыйча:

— Галимҗан абый, тәбрик ит. Дәүләт имтиханнарын тапшырып бетердем. Берсекөнгә диплом бирәчәкләр,— диде.

— О-о, бик шатмын. Чын күңелемнән тәбрик итәм,— дип, Галимҗан абый Гәүһәрнең кулын кысты. Алайса, бүген өйдә билгеләп үтәбез. Рәхимә, кайда син? Әзрәк рәтең бармы?

— Менә пәрәмәчләрем пешә инде. Син тизрәк юын. Гәүһәр өстәл әзерләсен.

Галимҗанга эштән соң юынырга, Гәүһәр белән Рәхимә апага табын әзерләргә әллә ни күп вакыт кирәкми. Галимҗан абый серванттан башланмаган мускат чыгарды.

— Әйдә, Рәхимә, утыр. Гәүһәрнең дипломын китергәч юарбыз. Монысы Гәүһәр өчен чын күңелдән шатлануыбызның билгесе булсын.

Өчесе дә рюмкаларын күтәрделәр, Гәүһәр рәхмәт әйтте, сез булмасагыз, миңа бу бәхеткә ирешү бик кыен булыр иде, диде.

— Безне мактама, без монда, рус әйтмешли, сбоку припеку,— дип, Галимҗан абый кайнар пәрәмәчне урталай сындырды.

## 13

Гәүһәр бик иртә уянды. Шау-шулы Казаннан чыгып киткәч, барлык борчулар артта, мәңгегә торып калган кебек тоелганга, аңа бу салкынча тып-тын саф һавада баруы рәхәт иде. Ашыгасы, кабаланасы юк. Су өстендә сыек кына ак томан йөзә, җил бөтенләй исми. Бары тик пароход кына бераз калтырана. Томан эченнән кояш күренә, еракта, еракта, тау башында Чистай йоклап ята. Алга чыгып торган биек борын артка шуыша. Минутлар үткән саен, су өстендәге томан да сыеклана, су эчендәге куаклар, агачлар калка, елга үзенең бөтен матурлыгы белән балкырга керешә. Гәүһәр, сузыла төшеп, елга үренә карый. Бу сәгатьтә Кама бик матур. Никадәр тынлык һәм тынычлык. Ник бер генә дулкын тибрәнсен. Ахрысы бүген бик каты кыздырыр, инде хәзер үк җылы. Гәүһәр иңенә салырга дип алган яшел фуфайкасын янына куйды. Хәзер ул бизәкле сарафаннан гына иде.

Бу вакытта инде палубага кешеләр күбрәк чыга башлаган иде. Тора-бара каюталарда кеше дә калмагандыр. Бик күпләр, Гәүһәр белән исәнләшеп, хәерле иртә теләделәр. Пароходта якын танышлар булмаса да, Яшел Яр халкы байтак иде.

Иртәнге ашны ашарга вакыт житкәч, Гәүһәр күршесе олы гына бер апа белән чәй эчте. Рәхимә апа куйган күчтәнәчләр белән күршесен сыйлады. Бу апа Минзәләгә кайта икән. Тормыштагы кызында кунакта булган. Кызы белән кияве икесе дә врачлар. Инде ун елдан артык больницада эшлиләр. Бик яхшылар, бик кече күңелләр. Апа бәби карарга барган икән.

— Балалары булмый, ахрысы, дип бик борчылып тора идем, инде тынычландым. Валлаһи, оныгым бар, дип урамга чыгып кычкырасым килде.

Гәүһәр берни әйтмәде. Кешеләрнең менә нинди бәхетләре дә була икән.

Апа Әҗекүлдә төшсә дә, әйберләрен төреп куйган инде. Гәүһәр киенеп чыкканда пароход Яшел Ярга якынлаша иде инде. Гәүһәр ике

күзен дүрт итеп карады. Әнә шул төшләрнең ул рәсемен ясады түгелме? Су өстеннән яр буе бераз башкачарак күренсә дә, яз көне су эчендә калган теге агач әнә шушы бугай. И-и-и! Яр буйлары хәзер ничек үзгәргән.

Ерактан шәһәр җәелебрәк күренә, якынрак килгәч, ул җыйнаклана. Гәүһәр түзмәде, алгарак узды. Әнә Әгъзәм. Юк, ул түгел. Юк, ул! Култыксага таянган, кулында чәчәк. Гәүһәрне күрде булса кирәк, чәчәген баш өстенә күтәреп, як-якка болгады.

Гәүһәрнең Казаннан алып кайта торган чәчәкләре булса да, Әгъзәм яңаларын тоттырды, Гәүһәр белән бик җылы исәнләште. Кулыннан чемоданын алды. Ярга чыккач, Гәүһәр иң элек Бибинур апа, аннары Вилдан һәм башка укытучылар белән исәнләште.

— Миләүшә нихәл?

— Кызы белән, шуңа килә алмады,— диде бәхетле ата.

— И, Хәйбүш бабай, исәнме? Тәмам яшәргәнсең кебек? Җәмилә, исәнме? — Гәүһәр аны яңагыннан үбеп алды.— Нурҗидә апа, исәнмесаумы?

— Без, җаным-бәгырем, бик исән, үзең сәламәт кенә кайттыңмы?

— Теленнән, кем, Нурҗидә, әйттермә. Тел хәйләли ул, ә күз алдамый. Карар күзгә килен бик шәп күренә.

— Килен дә килен, дисең, Хәйбүш бабай, иртәрәк түгелме соң әле?

— Кемгә, Нурҗидә, иртә, кемгә юк.— Бабай кеткелдәп көлеп җибәрде.

Ул арада Гәүһәр балалар белән исәнләште. Менә кайда ул шатлык, менә кайда ул шау-шу. Гәүһәр, Зилә белән Акназарга аерым сүз әйтергә вакыт тапмаса да, башларыннан сыйпады. Бу балаларга аеруча ошады. Алар әле сүз кадерен белеп бетермиләр, ә турыдан-туры булган хәрәкәт аларга бик аңлашыла.

— Сез лагерьда түгелмени, балалар?

— Лагерьда! — дип хор белән җавап бирделәр алар.— Без Гөлназ апа белән машинада килдек. Гөлназ апа — безнең вожатый.

Гәүһәр Гөлназны әнисе белән килгән дип тора иде. Кара инде нинди зур булган, үзе балалар алып килгән. Гәүһәр аны кочагына кысты.

— Кызлар сиңа сәлам әйтте, августта киләбез, диделәр.

Бераздан балалар, машинага утырып, кайтып киттеләр. Укытучылар сөйләшә-сөйләшә үзәк урамга кадәр бергә бардылар да кибеткә кереп калдылар. Гәүһәр аларны чәй эчәргә чакырып караса да, башка вакытка дип, риза булмадылар. Бибинур да, кич килергә вәгъдә итеп, китеп барды. Аннары тукталышта Вилдан белән Нурҗидә апа да калдылар.

— Килен тизрәк кайтыгыз дигән иде,— диде Нурҗидә апа.— Хәзер, җаным-бәгырем, бездә яңа кеше инде, вакытында хәстәрен күрмәсәң, полный разбой сала.

Актыктан Хәйбүш бабай белән Җәмилә дә китеп бардылар.

— Без әле килербез, менә бабай әзрәк ял итеп кенә алсын. Югыйсә менә аяк өстендә йоклый башлады,— диде Җәмилә, көлеп.

— Син, Җәмилә, бабаңны йоклатыр идең дә үзең тыр-тыр, ә? Вәт тамаша! — дип көлде бабай, үзе һичбер каршылыксыз Җәмиләнең ихтыярына буйсынды.

Икәү генә калгач, Гәүһәрләр беркадәр вакыт сүзсез бардылар. Гәүһәр сиздермәскә тырышып кына Әгъзәмгә карап алды. Күрәсең, Гәүһәр Казанда чакта ул борчылган. Күз төпләре каралган, йөзе шактый суырылган. Гәүһәр, авырмыйсыңмы? дип сорагач, Әгъзәм көлеп куйды. Аның бу көлүендә үтеп киткән күкрәүләрнең соңгы гөрелтесе генә, анда да бик зәгыйфь кенә яңгырый иде.

— Бабайны Җәмилә йоклатырга алып китте дип беләсеңме?

— Кая алып китте соң? — дип, гаҗәпләнеп сорады Гәүһәр.
— Миңа күптән вәгъдә иткән ике бүлмәле квартира бирделәр. Менә шуны рәткә китерәләр. Кичә генә күчтек әле.
— Менә монысы шәп булган. Кайда, шәһәрнең югары ягындамы?
— Әйе, яңа йортларны анда гына салалар бит. Өченче катта, Кама ялтырап күренә. Миләүшәләрдән ерак түгел.
Ул арада Зәбирә апаларга килеп җиттеләр. Ишек алдының күп җирен каз үләне баскан. Юллар чиста итеп себерелгән, казык башларына, әүвәлгечә, чүлмәкләр киертеп куелган. Каз бәбкәләре күренми, алар өй артындагы чокырда, күрәсең, тик этәч кенә кукраеп йөри.
— Ай-һай, сагындырганым кайтып җитте,— диде Зәбирә түти, кулларын алъяпкычына сөртә-сөртә.— Исәнме-саумы, Гәүһәрем. Яңа дипломың котлы булсын.
Гәүһәр аны яңагыннан үпте, күкрәгенә кысты.
— Рәхмәт, Зәбирә түти. Тәмам сагынып беттем үзегезне.
— Кара, Әгъзәм, безне дә сагынучылар бар икән.
Гөлләр белән тулы бу кечкенә өй тагын да матураеп киткән, барысы да чәчәк аткан. Өстәлдә бәйрәмнәрдә генә ябыла торган эре бизәкле ашъяулык. Гәүһәрнең такта белән генә бүленгән, бер тәрәзәле бүлмәсендә дә тәртип.
— Әгъзәм, утыр. Мин хәзер өс-башымны гына алмаштырам.
— Менә дипломым,— диде Гәүһәр, киенеп чыгып, һәм Әгъзәмгә алтын язулы катыргы сузды.
Әгъзәм алып карады да урыныннан торып:
— Тагын бер тапкыр тәбрик итәм,— дип, Гәүһәрнең кулын кысты.
— Зәбирә түти, менә кара, яңа дипломым.
— И-и,— диде Зәбирә түти, кулын яңадан алъяпкычына сөртеп.— Бәхете белән булсын. Игелеген күр.
Бик күңелле итеп чәй эчтеләр, Яшел Яр яңалыкларын сөйләп алдылар.
— Сәгать җиләкләрдә Бибинур апа, кереп чыгармын, диде. Җәмилә белән Хәйбүш бабай да. Сиңа инде, Зәбирә түти, бүген тия. Мин нәкъ кунак шикелле,— диде Гәүһәр, көлеп.— Кама буйларын бер карыйсым килә. Нигәдер бик сагынып кайттым.
— Барыгыз, бар. Мин үз эшемне эшләрмен, бер дә борчылмагыз.
Гәүһәр белән Әгъзәм чыгып киттеләр. Кояш инде кичкә авышкан, күләгәләр озынайган, көндезге эсселек сүрелә төшкән. Су буена чыккач, сулыш алулары тагын да рәхәт булып китте. Кеше дә аз монда. Яшел Яр халкы махсус сайранга чыгарга өйрәнмәгән. Гәүһәр белән Әгъзәм, көлеп сөйләшә-сөйләшә, тар сукмактан бардылар, вакыт-вакыт су буендагы урындыкларга утырып тордылар. Кама ага да ага. Якынлашып килгән кичтә аның агышы әллә нәрсәләр турында сөйли кебек. Болай ул дулкыннар бөтенләй юк та шикелле, ә бик игътибар белән тыңласаң, кайдадыр тирәндә алар нәрсәдер пышылдыйлар сыман.
— Әнә ишетәсеңме? — ди Гәүһәр, әкрен генә.
— Әйе, ишетәм, кайчак йөрәк шулай тибә кебек тоела миңа.
— Әллә чынмы икән? — Гәүһәр Әгъзәмгә мөлаем гына карап алды. Бу караш күп нәрсә әйтә иде. Әгъзәм, хисләре ташуга чыдый алмыйча, аның кулыннан тотты. Гәүһәрнең кулы эссе иде.— Һич тә уйламаган идем... бәхет шулай якындыр дип.
Әгъзәм аны үзенә таба тартты, Гәүһәр аз гына артка тайпылды, тынып калды. Аларның күзләре күздән китмәде.
Кама өстендә миллион-миллиард җемелдәвек, ул бик күп, бик күп нәрсәләр вәгъдә итә иде. Аңа ничек буйсынмыйсың!

*1968*

*Роман кыскартып басылды.*

## Харрас Әюпов

### Сау бул, ялгызлык!

Синең белән үтте күп көннәрем,
Бер-беребезгә шундый өйрәндек.
Сагышларны бергә җиңeләйттек,
Уйларыма бирдең тирәнлек.

Төннәр буе кочагыңа ятып,
Серләремне сөйләп арыттым.
Син үзеңне тыйнак, эчкерсез дус,
Хыянәтсез итеп таныттың.

Тынычлыгың белән иркәләдең,
Кешеләрдән мине аерып.
Мин шатлансам, бергә син дә көлдең,
Мин еласам — елап, кайгырып...

Тик шау-шусыз яши алмам, китәм
Тынлыгыңны үзеңә калдырып.
Истәлеккә калсын хыянәтем —
Кичер мине, сау бул, ялгызлык!

### Минем хисләр

Давыл булса, диңгез ярын кыйный,
Ә давылсыз диңгез буламы?! —
Минем күкрәк, ахры, диңгезләрнең,
Океаннарның тынмый торганы.

Сабый чакта минем диңгеземә
Ятимлегем салкын җил өргән,
Егет булгач, яңа давыл итеп
Тормыш миңа сөю җибәргән.

Сөйгән ярым, сылу акчарлагым,
Диңгезләрдән тынлык эзләмә.
Давылларын син үз итәр булсаң,
Диңгез үзе сиңа тезләнә...

Дулкыннарым, тормыш, сиңа булсын,
Тын ярларга мин һич табынмам,
Юк, үкенмим мондый язмышыма:
Зарланмый бит диңгез давылдан...

●

Уйламаска тырышасың,
Онытылмас микән дисең —
Колакта аның тавышы,
Күңелдә шул ук исем...

Язларны усал булыр, дип
Көтмәгән идем ич мин:
Ел саен юри тарата
Ул сөйгән сирень исен.

...Хәтердән куып карыйсың,
Сүрелмәс микән дисең —
Йөрәктә шул ук сөюем,
Телемдә шул ук исем...

## Уеннар

Хәтеремдә таныш болыным бар,
Сүнми торган якты уем бар.
Оныталмасам, гаҗәпләнмәс төсле
Балачакта белгән уеннар...

Без качышлы уйный идек элек.
Малай чакта бик еш эзләдем:
Хәтеремдә,
Сине табалмасам,
— Мин монда! — дип әйткән
сүзләрең.

Еллар аша әле дә эзләп киләм,
Таныш исем төшми иренемнән.
Балачагың булып, «мин монда» дип
Тавыш бирче качкан җиреңнән.

...Хыялымда иркен яланнар бар,
Синең хакта татлы уем бар...
Сиздермичә егет чакка күчкән
Балачакта белгән уеннар.

## Таш әти

Гранит солдат мәйдан уртасында:
Таш иреннәр, таш күз, таш йөрәк,
Еламыйлар ләкин бу иреннәр,
Таш йөрәктә — үч һәм нәфрәт.

Үткән еллар мәйданнарга бүген
Гранитлар белән тоташа.
Тыйнак алар,
Ярсып кычкырмыйлар,
Сүзсез генә сөйли бу ташлар.

Яшь бер егет тыңлый гранитны,
Бер секундка күздән төшерми.
Таш солдатның горур карашында
Үз этисен, ахры, төсмерли.

Тынып калган җилләр каршысында,
— Улым! — диеп ник соң бер
әйтми? —
Сакка баскан кайтып мәйданнарга
Таш мәхәббәт, таш сын, таш әти...

Карт бер ана һәйкәл каршысында,
Ник килүен монда оныткан,
Әллә инде аның кайгысыннан
Елый-елый үтә болытлар...

Үткән еллар мәйданнарга бүген
Гранитлар аша тоташа,
Ярый әле, ярсып кычкырмыйлар,
Сүзсез генә сөйли бу ташлар...

## Мәхәббәт

Җир жылысын йөрәгендә йөртте,
Абынганда җиргә иелде,
Җире өчен керде сугышка ул,
Әсир итте җирне сөюе.

Ялан аяк йөгереп үсте кырда,
Ялан аяк йөрде сабанга,
Хөкемгә дә ялан аяк килде,
Җирнең чыгын тоеп табанда.

Ишетмәде ату тавышын да,
Арыш ура иде хыялы,
Соңгы тапкыр җирен кочаклады,
Алсу каны җирне буяды.

Сискәнделәр зәңгәр кыңгыраулар,
Ату тавышы кырны уятты.
Ашыктырып шулчак җил-хәбәрне
Ромашкалар йөгереп озатты...

Басуларга аның сөюе килә,
Яңгырына кушылып, җиленә.
Уҗым булып ел да баш калкыта
Аның гомере туган җирендә.

## Иске яулык

Еракларадан килгән хәбәр сыман,
Ак кирләргә салкын җил бәрә,
Ак пәрдәләр белән янәшәдә
Иске яулык җилдә тирбәлә.

Озатканда сугыш кырларына:
Кайтырлар бит! диеп бу яулык
Өметләнеп карап калган иде,
Киткәннәргә теләп уяулык.

Хәбәр көтте көн дә карый-карый
Алар киткән киң юл ягына,
Гаепле күк дәшми үтте җилләр,
Түзмәс диген кебек кайгыга.

8*

Килде хәбәр,
Давыл булып килде,
Яңгыр булып килде,
Бу яулык
Өнсез калды кинәт, ә аннан соң
Еллар кичте ялгыз юаныл...

...Кайларгадыр чакырып искән
сыман,
Ак керләргә житез жил бәрә,
— Каберләрен күрсәт! — дигән
кебек
Иске яулык жилдә тирбәлә.

## Алдану

Кош тоткандай сөенеп йөрдем ул
чак
Бүрек белән каеш калганга.
Әткәй үлгән көнне язмыш мине
Иске каеш биреп алдаган.

— Итеген дә мин киярмен инде,
Шинеле дә ярар көзләрен,—
Ничек, әнкәй, шул сүзләрем өчен
Телемне син тартып өзмәдең?!.

— Улым, улым,
Әткәң исән булса,
Каеш кына тапмас идеме? —
Каһәрләдең шунда сугышны син,
Ләгънәтләдең әрсез үлемне.

Бүрек белән нужа кидем башка,
Каеш белән будым кайгысын —
Алары да миңа калган икән,
Минем гомер, минем жан өчен.

Авырлыклар сөендереп килгән,
Сабый күңеле соңрак аңлаган:
Әткәй үлгән көнне язмыш мине
Иске бүрек биреп алдаган...

## Сәет Кальметов

# КӨНБАГЫШТАН БАШЛАНДЫ

*Комедия өч күренештә*

КАТНАШАЛАР:

Салих
Камилә
Лотфи
Мәдинә
Сержант Фатихов.

### БЕРЕНЧЕ КҮРЕНЕШ

Өй артында җимеш бакчасы.
Читтәрәк аякларын җиргә кагып ясалган өстәл белән эскәмия. Кулына портфель тоткан Салих бакча капкасы янына килеп туктый.

Салих *(кычкырып)*. Әхнәф! Әхнәф дим!

Агач арасыннан Камилә килеп чыга.

Камилә. Атасы, Әхнәф нигә кирәк булды?
Салих. Менә кара! *(Күрсәтә.)* Егеткә портфель алдым.
Камилә. Егет дияргә Әхнәфнең борын асты кипмәгән әле.
Салих. Авыз тутырып егет дисәк тә була. Быел алтынчы класска керә ич. Камилә, чакыр әле үзен, портфельне күреп авызы ерылсын...
Камилә. Әхнәф өйдә юк шул.
Салих. Кая китте?
Камилә. Балык тотарга.
Салих. Кара син ташбашны! Мин анаңа булыш дигән идем. Ә ул, малай актыгы, тизрәк чыгып сызган.
Камилә. Берүк баланы каргама, атасы, мин аны үзем җибәрдем.
Салих *(кабынып)*. Үзең җибәрдең! *(Капканы капылт ачып, бакчага уза.)* Әй, Камилә, Камилә, мин малайны үңга тартам, ә син булсаң сулга сөйрисең. *(Эскәмиягә утырып папирос кабыза.)*
Камилә. Ярар инде, атасы, шуның өчен дә каныңны бозма.
Салих. Бозма, имеш! Сиңа булышса, кулы корымас иде.

Камилә. Таш кисмим ич, атасы. Бер сәгатьтән ранетканы үзем дә җыеп бетерәм, күрерсең менә.

Салих. Хикмәт син эшләүдә түгел, Камилә, малай эшкә күнегеп үссен дим.

Камилә. Күнегер әле, күнегер. Ике бала үстереп, аякка бастырдык инде. Эшкә килгәндә икесе дә сынатмадылар.

Салих. Анысын син әйтмәсәң дә беләм. Менә Әхнәф тә ата-ана сүзеннән чыкмасын диюем.

Камилә. Чыкмас, чыкмас, атасы, күз генә тимәсен. Ул йөз кызарта торган бала түгел.

Салих *(урыныннан торып, койма янына бара)*. Камилә, көнбагышларны Әхнәф чукыймы?

Камилә. Ни сөйлисең, атасы, ул бала көнбагышка кагылмый. Чыпчыклар ябырыла.

Салих. Китче, карачкыдан курыкмыйлармы?

Камилә. Ул мәлгуньнәр карачкыны бар дип тә белмиләр. Шуңа аптырыйм, атасы.

Салих. Хикмәт бу! Күрәсең, кошларга заман тәэсир итә. Димәк, аларга да аң кергән. Томана чыпчыклар калмаган булып чыкты.

Мәдинә *(керә)*. Исән-сау гына торасызмы?

Салих. Шәп дисәк, мактану булыр, ярыйсы дип бел.

Мәдинә. Салих абый, кибеткә рәхим ит, син ярата торган лимонлы конфетлар кайтты.

Салих. Камилә, ишеттеңме? Әхнәфне бүген үк конфетка җибәр.

Камилә. Ярый, ярый, атасы, анысын үзем дә чамалап алдым.

Салих. Кара әле, Мәдинә, шушы көннәрдә сельмагка караватлар кайтачак диләр, безгә хәбәр итәргә онытма.

Мәдинә. Яз көне генә никельле караватн алдыгыз ич. Өстәлеп торсын дисезме?

Салих. Әхнәфкә кирәк. Алтынчы класста укучы егетне сандык өстендә йоклатып хур итмик.

Камилә. Ай, атасы, бу хәтле дә бала җанлы булырсың икән!

Салих. Ул якка синнән уздырып булмас инде.

Камилә. Сүз белән мавыкма, сиңа эшкә барырга вакыт җитте.

Салих. Җитте, җитте, хәзер кузгалам. Кара, Мәдинә, безне караватсыз калдыра күрмә.

Мәдинә. Борчылма, Салих абый, кибеткә кайту белән очып килермен.

Салих чыга.

Камилә *(өстәлгә кастрюль куя)*. Мәдинә, кил, утыр, менә ранеткадан авыз ит.

Мәдинә *(утыра. Кастрюльдән ранетка алып каба)*. Тәмам пешеп житкән бу, Камиләттәй, авызда эреп кенә тора.

Камилә. Шуңа күрә үзем дә, көндезге савымга барганчы, җыеп алырга булдым.

Мәдинә *(койма ягына күз төшереп)*. Бәй, сез дә көнбагыш үстерәсез икән ләбаса...

Камилә *(утыра)*. Быел утырткан булган идем. Әхнәф тынгылык бирми, өлгермәсә дә чүпләп кенә тора.

Мәдинә. Әхнәф дигәннән, улыгызның кеше әйберенә кагылганы юкмы?

Камилә. Язмаганны сөйләмә, Мәдинә. Ул хәлнең гомердә буласы юк.

Мәдинә. Камиләттәй, алай кырт кисеп куйма әле.

Камилә. Унөч ел буе канат астында яшәгән баламның күңелен, фигылен белеп торам. Бик ипле, юаш малай ул.

М ә д и н ә. Юаштан юан чыга. Узган төнне Әхнәфегез безнең бакчага төшкән бит! Сигез төп көнбагышның башларын кыркып алган.

К а м и л ә *(тора)*. Булмас, булмас, язмаганны сөйләмә. Әхнәфтән андый явызлык көтмим. Башка берәүнең баласыдыр.

М ә д и н ә. Камиләттәй, мин кем баласы икәнен анык белеп килдем.

К а м и л ә *(кызып)*. Мәдинә, балага нахак бәла тагарга йөрмә.

М ә д и н ә. Бер дә нахак бәла түгел, Камиләттәй.

К а м и л ә. Я әйт, әйт, күрүчеләр бармыни?

М ә д и н ә. Күрүчеләр юк. Менә җансыз шаһит! *(Кесәсеннән пәке чыгара.)* Бу пәкесен бакчага төшереп калдырган. Сабында «Әхнәф Салихов» дигән язуы да бар.

К а м и л ә *(тиз генә пәкене ала)*. Әйе, әйе, бу зәңгәр саплы пәке Әхнәфнеке. Җизнәсе бүләк иткән иде. Ай, йөзе кара! Мәсхәрә итте бит. Урамга чыгарлыкны калдырмады... Хәзер бөтен авыл шау-гөр килер.

М ә д и н ә. Ул яктан хафаланма, Камиләттәй. Бу турыда берәүгә дә шаулаганым юк. Хәтта иремә дә әйтмәдем.

К а м и л ә. Ай, рәхмәт, Мәдинәкәй, яманатыбызны сатмагансың.

М ә д и н ә. Дөнья булгач, төрлесен уйлыйсың. Кем белә бит, көннәрнең берендә минем малай сезнең кар базына төшәр.

К а м и л ә. Анысы бик ихтимал. Малай-салайга ышаныч юк. Андый хәл була калса, мин дә сезнең малаегызны сатып йөрмәм. *(Кесәсеннән акча ала.)* Менә сиңа көнбагышларың өчен ике сум!

М ә д и н ә. Кирәкми, кирәкми, вакланмыйк.

К а м и л ә. Бала-чага зыянын ата-ана күтәрергә тиеш.

М ә д и н ә. Уйлама да, алмыйм дигәч алмыйм.

К а м и л ә. Алмасаң, бик яман хәтерем калыр.

М ә д и н ә *(акча ала)*. Зыянны түләтермен дигән уй башыма да кергәне юк. Бары тик Әхнәфкә күз-колак булсыннар, дип әйтергә килдем.

К а м и л ә. Килүең бик әйбәт булды, Мәдинәкәй. Инде бу хакта Салих абыеңа тишә күрмә. Өч тиенлек көнбагыш өчен каны бозылмасын.

М ә д и н ә. Дөрес, дөрес, чүп-чар өчен дә ата кешенең кәефен җибәрмик. Әхнәф сарык урламаган бит. Үзең шунда мыштым гына малаеңның колагын борып куярсың.

Китә.

К а м и л ә. Ул йөзе кара малай кайтып күземә генә күренсен. Чалбарын салдырып, арт ягын кычыткан белән туныйм. Алай эшне зурга җибәрсәм, атасы сизәр. Малайны син бозасың дип, ин әлек үземне дөмбәсләп ташлар. Баланы җәзасыз калдыру да ярап бетмәс. Нишләргә соң? Билләһи дип әйтәм, ике ут арасында калдырды бит бу малай.

Ут сүнә.

## ИКЕНЧЕ КҮРЕНЕШ

Шул ук җимеш бакчасы. С а л и х бүкән өстендә балта белән җәпле таяклар очлый. Пауза. Л о т ф и керә.

Л о т ф и. Әйбәт кенә яшисезме, Салих абзый?

С а л и х. Шәп дисәң, мактану булыр, ярыйсы дип бел.

Л о т ф и. Салих абзый, бер мәлгә эшеннән бүлсәм, ни диярсең?

С а л и х. Ашыгыч эш юк югын да... Менә алма агачларына терәүләр әзерли идем...

Лотфи *(бакчага күз төшерә)*. Ай-һай, сездә алма котырып үнгән.

Салих. Күрәсен ич, ботакларны сыгып төшерде. *(Балтасын җиргә куеп, бүкән өстенә утыра.)* Утыр, Лотфи энем, ниләр җимертеп йөрисен?

Лотфи *(эскәмиягә утыра)*. Озакламый укулар башлана. Кызыма портфель кирәк. Сельмагта булган да беткән. Район үзәгендә дә юк. Өмет сездә, Салих абзый. Улыгызга ике портфель алгансыз икән.

Салих. Лотфи энем, безгә адашып кергәнсен. Ни шайтаныма бер малайга ике портфель.

Лотфи. Сатучылар әйтте, алар белмичә сөйләмәс.

Салих *(торып капка янына бара)*. Камилә! Камилә! Чыгып кер әле! *(Килеп бүкәнгә утыра.)* Лотфи энем, синең кыз ничәнчедә укый әле?

Лотфи. Алтынчыга күчте. Әхнәфнең классташы ул.

Салих. Ә, әйе, әйе, онытып торам икән. Кырык биштән узгач, хәтер дигәнең абына да сөртенә.

Камилә *(керә)*. Ни бар, атасы?

Салих. Без Әхнәфкә ике портфель алдыкмыни?

Камилә. Әйе, әйе, атасы, берсен син алдың, икенчесен — мин.

Салих. Без шулай баеп беттекмени соң?

Камилә. Ничарадан бичара! Әхнәф әйберне саклап, кадерләп йөртә белми. Бишенчене җырып чыкканчы, өч портфельнең башына житте.

Салих *(тора)*. Кара син ташбашны! Әй, Камилә, Камилә, нишләп син миңа бу турыда әйтмәдең?

Камилә. Юк-бар белән каныңны бозасым килмәде.

Салих. Хәзер Әхнәфкә акыл керде. Алай җүләр сатмасын. Ике елга бер портфель — менә нормасы!

Камилә. Ярый, ярый, атасы, мин риза.

Салих. Бер портфельне менә Лотфига бирик.

Лотфи. Мөмкин булса, бер яхшылык итегез, Камилә түти. Кызның да күңеле булыр.

Камилә. Ярый, авылдаш, мин риза.

Чыга.

Салих. Лотфи энем, кызның өлгереше ничегрәк булды?

Лотфи. Әйбәт, укуга бик тырыш ул.

Салих. Менә безнең Әхнәф дүртенчедә майлаган кебек шома гына барды. Бишенчедә абына да сөртенә укыды. Бөкресе чыккан өчлеләре дә ешаеп китте.

Камилә *(портфель кертеп Лотфига бирә)*. Мә, авылдаш, кызыңны куандыр!

Лотфи. Рәхмәт, Камилә түти. *(Камилә чыга.)* Салих абзый, менә портфель өчен төп-төгәл дүрт сум. *(Өстәлгә акча сала. Салих балтасын алып эшенә тотына.)* Салих абзый, эшеңне калдырып тор, мин сезгә портфель өчен генә сугылмадым.

Салих. Шулаймыни әле, бездән тагы нәрсә таптырасың? *(Көлә.)*

Лотфи. Көләсең, Салих абзый, мин күңелсез хәбәр китердем.

Салих *(балтасын куя)*. Китче, әллә бәла-казага дучар булдыкмы?

Лотфи. Бәлагә син, казага мин дучар булдым. Узган төнне сезнең Әхнәф безнең бакчаны ботарлап чыккан.

Салих. Чү әле, чү!.. Ничек итеп ботарлаган?

Лотфи. Алмага һөҗүм иткән.

Салих. Әкият сөйләмә, энем...
Лотфи. Әкият түгел, чын.
Салих. Бу йортка адашып кергәнсең. Безнең нәселдә кеше бимазалап йөрүче хәшәрәтнең булганы юк.
Лотфи. Шуңа күрә ачынып килдем дә...
Салих. Үзең уйлап кара, Әхнәфнең ашасы килсә, әнә агачта — үзә дә каба! Ул нишләп кеше бакчасына керсен, ди.
Лотфи. Күрше тавыгы күркә булып күренә. Бала кешегә безнең алмалар тәмлерәк булып күренгәндер.
Салих. Авылда малай-салай азмыни. Кара, энем, бу усаллыкны Әхнәфтән күрмә.
Лотфи. Бәхәсләшмик, Салих абзый, Әхнәф үз-үзен тоттырды. *(Кесәсеннән берет ала.)* Менә аның яшел береткасы! Бакчада агач ботагына эленеп калган.
Салих *(беретканың эчен карый)*. Әйе, бу Әхнәфнеке, тамгасы да бар. Тотылдык без, тотылдык!.. *(Күрсенә.)* Малай чыгырдан чыккан... Укытучылар алама икән бездә, биш ел укытып та балага тәрбия бирмәгәннәр...
Лотфи. Укытучыларга тел-теш тидермә, Салих абзый.
Салих. Укалары коелыр дисеңме?
Лотфи. Безнең мәктәптә укалылары юк.
Салих. Ул хәтлесен каян беләсең?
Лотфи. Мәктәп белән элемтәм бар. Менә ничә ел инде синең бер генә мәртәбә дә ата-аналар җыелышына барганың юк.
Салих. Моңарчы малай тәртип бозмады ич.
Лотфи. Ә-ә, син тәртип бозганын көтеп яттыңмы?
Салих. Ачу чыкканда үчекләп торма әле. *(Кепкасын салып башындагы тирен сөртә.)* Хур итте бит, ташбаш! Хәзер ничек итеп кеше күзенә күренмәк кирәк.
Лотфи. Ул яктан тыныч бул, Салих абзый. Мин бу хакта шауламадым.
Салих *(куанып)*. Бер кешегә дә әйтмәдеңме?
Лотфи. Юк, әйтмәдем.
Салих. Шаяртмыйсыңмы, Лотфи энем?
Лотфи. Чын инде, чын, хәләл хатыныма да әйтмәдем.
Салих. Молодчина! Атаңнан да яхшырак булып чыктың син. Лотфи энем, әллә бу хәлне икебезнең арада гына томалап калдырабызмы?
Лотфи. Бу турыда уйлап карарга була.
Салих. Лотфи энем, бугазга килеп терәлде, уйлап торма.
Лотфи. Әхнәфнең кеше әйберсенә орынуы беренче мәртәбәме?
Салих. Авыз тутырып әйтәм, икмәктер, беренче мәртәбә.
Лотфи. Алай булса, мин риза.
Салих. Бир бишне! *(Лотфиның кулын кыса.)* Лотфи энем, исәпхисапны өзик. Малаеның китергән зыяны зурмы?
Лотфи. Зыян дип сөйләшмик. Нибары ике-өч кило алма суккандыр...
Салих. Ул да зыян. Өстә бурыч булып тормасын. *(Өстәлдән акча ала.)* Мә, үз акчаң үзеңә!
Лотфи. Акча сузып, мине кыерсытма, Салих абзый.
Салих. Бала китергән зыянны ата-ана күтәрә. Бабайлардан калган йола.
Лотфи. Шулаймы? Йолага мин дә буйсынам. *(Акчаны алып кесәсенә сала.)*
Салих. Менә рәхмәт! Карале, Лотфи энем, бу хакта Кәмиләгә ычкындырма.

Л о т ф и. Анасыннан яшерү дөрес булмас. Бала өчен ул да җавап бирә.

С а л и х. Әй, ул Камиләнең холкын белмисең шул. Чамадан тыш бала җанлы. Малайга кер кундырасы килми, арага керә, яклаша...

Л о т ф и. Ярар, аңлашылды. Үзенә ничек җайлы, шулай ит. Миннән сүз чыкмас. Теләк бер генә, Әхнәф туры юлдан тайпылмасын. *(Портфельне кулына ала.)*

С а л и х. Менә авыз тутырып әйтәм, малайга бүген үк тимер кыршау кидерәм!

Л о т ф и. Кемгә, кемгә, сиңа ышанам, Салих абзый.

Китә.

С а л и х *(кызып)*. Ул ташбаш кайтып күземә күренсен, сырт сөяген каеш белән каезлыйм. *(Чалбар каешын суырып ала.)* Тимерле башы белән! Тотып ярсаң да куркыныч. Анасы сизәр дә авыруга сабышыр. Түшәктән тормас, ярты чиләк алма өчен Камиләнең бәгырен теткәләсәм, томаналык, кыргыйлык була ич. Малайны җәзасыз калдырырга да ярамый. Нишләргә соң? *(Җилкәсен кашып, уйга кала.)* Ух, шайтан алгыры... Утыз килограммлы малай атасының өстенә утыз центнер таш бастырды!

Ут сүнә.

## ӨЧЕНЧЕ КҮРЕНЕШ

Шул ук җимеш бакчасы. С а л и х әрҗә төбенә соңгы тактаны кага. Пауза. Яулыгын артка чөеп бәйләгән К а м и л ә керә дә өстәлгә ашъяулык җәя.

К а м и л ә. Атасы, табынны бакчага әзерләргә булдым, өйдә бөркү.

С а л и х. Анысына зиһенең җиткәч, бик әйбәт.

К а м и л ә. Хәзер бәлеш ашыйбыз, эшеңне калдырып тор.

С а л и х. Эш бетте дисәң дә була. Менә сиңа алма салырга әрҗәдә өлгерде. *(Күрсәтә.)*

К а м и л ә. Барып чыккан бу, җыйнак та, пөхтә дә.

Ф а т и х о в тавышы: Хуҗалар өйдәме?

С а л и х. Өйдә, өйдә, бакчага узыгыз!

Кулына катыргы тартма тоткан участок милиционеры Фатихов керә.

Ф а т и х о в. Хәерле көн!

С а л и х. Сезгә дә шул теләк! *(Көлеп.)* Камилә, иптәш сержант тикмәгә килмәгәндер, кайсыбыз тәртип бозды, синме, минме?

К а м и л ә. Анысын белгән юк, атасы. Әйтсә, менә иптәш Фатихов үзе әйтер инде.

Ф а т и х о в. Мин дә әйтә алмыйм, чөнки берегезнең дә колагы кызармый. *(Көләләр.)*

С а л и х. Утырыгыз, иптәш Фатихов! *(Фатихов эскәмиягә, Салих букәнгә утыра.)*

С а л и х. Колхозда эшләп әллә ни кырмасам да, җәен-кышын кулдан балтаны төшергән юк.

К а м и л ә. Мин булсам, ферма тирәсендә маташам. Үзебезгә калса, тырышкан булабыз.

Ф а т и х о в. Икегездән дә колхоз җитәкчеләре бик риза. Хезмәтләре белән мактауга лаек, диләр.

К а м и л ә. Алай зурлый белгәч, рәхмәт инде.

Ф а т и х о в. Апа, утырып торыгыз. *(Камилә әрҗә өстенә утыра.)* Сезнең янда хәзер бала да берәү генә калган икән.

С а л и х. Әхсәнне армиягә озаттык...

Камилә. Әкълимәне кияүгә бирдек. Бөтен юанычыбыз шул өйдәге төпчек, Әхнәф кенә.

Фатихов. Ул егет кисәге кайда соң әле, уендамы?

Салих белән Камилә икесе дә сүз куешкандай берьюлы торып басалар.

Салих. Ни... Әхнәфне бүген иртүк күрше авылга озаттык.

Фатихов. Кайсы авылга?

Салих. Тәмле Тамакка.

Камилә. Укулары башланганчы, бабаларында берәр атна кунак булып кайтсын, дидек.

Фатихов. Басып тормагыз, утырып сөйләшик.

Салих белән Камилә утыралар.

Ул баланың тәртибе белән, укуы белән кызыксынасызмы соң?

Салих. Дүртенче класска хәтле дәресләрен хәзерләшергә булыша идем. Бишенчегә күчкәч, кул селтәдем. Тыгылмыйм.

Фатихов. Апа, сез мәсьәләгә ничек карыйсыз?

Камилә. Мин дә тыгылмыйм, атасы рөхсәт итми.

Салих. Минем өстән иптәш сержантка жалоба биреп утырма. Башта үзеңнен кем икәнлегеңне бел.

Камилә. Күз өстендәге каш шикелле балама начарлык эшләдеммени?

Салих. Эшләден шул. Үткән ел Әхнәф арифметикадан муены кәкрәйгән икеле алып кайтты. Гаеп миндә түгел, хисапны әни чыгарып биргән иде, ди. Хәзер аларга физика, химия, формула, дробь кирә. Бездәге такы-токы белем белән малайга ярдәм итеп булмый. Дөресме, иптәш сержант?

Фатихов. Монысы дөрес. Баланың башын әйләндермәвегез яхшы. Бу соңгы көннәрдә Әхнәф кичләрен чыгып йөрмиме?

Салих белән Камилә торып басалар.

Камилә. Йөрми дип әйтеп булмый. Кичләрен күршеләргә телевизор карарга кирә. Дөрес ич, атасы?

Салих. Дөрес булгач, дөрес инде.

Фатихов. Бик сәер кешеләр булып чыктыгыз, сикерәсез дә торасыз. Зинһар, утырыгыз!

Салих белән Камилә утыралар.

Әхнәф кунакка киткәндә, аягына нәрсә киде?

Салих. Әйт, әйт, Камилә!

Камилә. Яңа туфлиен киде.

Фатихов. Улыгыз берәр әйберсен югалтмадымы?

Салих белән Камилә сикереп торалар.

Корт чагамыни соң сезне? Тыныч кына утырыгыз.

Салих белән Камилә утыралар.

Абайламадыгызмы, улыгыз нәрсә югалткан?

Салих. Камилә, яшел береткасы башында иде ич!

Камилә. Әйе, әйе, атасы. Аны беркайчан да башыннан төшерми ул.

Фатихов. Хәтерләмисезме, кичә ул нинди туфлидән йөрде?

Салих. Камилә, син белергә тиеш.

Камилә. Ни... аягында сап-сары туфли иде.

Фатихов. Ниндирәк билгеләре бар?

Камилә. Туфли башлары бик хәтәр тырмалган булыр.

Салих. Үкчәләре шактый гына янтая төшкән...

Фатихов *(тартмадан туфли алып күрсәтә)*. Танынсызмы?

Камилә. Танымыйча. Мин Әхнәфнеке дип кычкырып тора ич.

Салих. Иптәш сержант, бу хикмәтле туфли сезнең кулга ничегрәк килеп эләкте?

Фатихов. Узган төнне Әхнәф ларектан лимонлы конфет чәлдергән. Форточкадан чыкканда, туфлие ларек эченә төшеп калган. Кире кереп алырга кыюлыгы җитмәгәндер.

Салих *(кызып)*. Әй, Камилә, Камилә, син нәрсә карадың?

Камилә. Кызма, атасы, кызма. Ир баланы иң элек ата булган кеше күзәтә.

Салих. Күзәтә, күзәтә... Бар, хәзер өйдән акча алып чык!

Камилә. Ашыкма, атасы, башта белик, кибеткә зыяны күпме соң?

Фатихов. Сельпога китергән зыяны җиде сум җиде тиен.

Камилә *(куанып)*. Нибары шулмы?

Фатихов. Ул гына түгел. Бала тәрбияләүгә гамьсез караганыгыз өчен, авыл Советы сезгә унар сум штраф салды!

Салих. Иптәш сержант, штраф суммасы күбрәк түгелме?

Фатихов. Минемчә, азрак, чөнки ул хәл өченче мәртәбә кабатлана.

Салих. Чү әле, чү, иптәш сержант, кем әйтте аны сезгә?

Мәдинә *(керә)*. Салих абый! Сельмагка бик матур кроватьлар кайтты.

Салих. Ни... Ни дигәннән... Без быелга караватн алмаска булдык...

Мәдинә. Менә тагы, нишләп кире уйладыгыз?

Салих. Бүгеннән башлап малайны уртабызга салып йоклатабыз.

*Пәрдә.*



## Муса Сираҗи

●

*Беренче тапкыр кояшны, йолдызларны күргән, Тукайча «әткәм-әнкәм» дип телем ачылган җир — Башкортстанның Туймазы районы Төпкилде авылы.*

*Күңел күзем дөньяга, ә йөрәгем шигърияткә ачылган урын — урта мәктәп, университет, «Кызыл таң» редакциясе.*

*Шигъри сүзем көрәшкә чыккан мәйдан — Уфаның газета-журналлары, әдәби альманахлар һәм «Очрашу» исемле беренче шигырьләр җыентыгы...*

*Менә шулай җәмгысе өч дистәгә якын гомерне сүткәнмен. Язганнарымны туачак әсәрләремнең увертюрасы гына дип исәплим. Тормышка ашырасы хыялларым да, чын иҗат шатлыкларым, газапларым да — барысы да әле алда — үтеләчәк, язылачак юлларда...*

●

Җәйге янгырлы юлдан
Атлар юыртып бара.
Тәгәрмәчләр пычракны
Артка ыргытып бара.

Әнә шулай тазарынып
Әйләнә Җир шары да:
Әйләнгән саен коллыктан,
Вәхшилектән арына.

●

Бу йөрәгем кайчагында
Дусларга бик кырыс кебек,
Ә дошманга — тыныч кебек.
Кырыс кебек — юлдан язса,

Дуслар кулын каты кысып
Йомарланган бер уч кебек.
Тыныч кебек — ләкин бит ул
Кында яткан кылыч кебек.

### Көнгә ачык тәрәзәләре

Туган калам.
Кат-кат йортлар
Кәрәзләрдәй тезелгән.
Тәрәзәләрнең һәрберсе
Кояш чәчә үзеннән.

Кешеләре ай-кояшлы,
Йолдызлы бу
йортларның,
Гүя тормыш чәчкәсенә
Сарылган бал кортлары.

Тәрәзәләр тарта көн дә
Илһамлы җыры белән.
Ә кәрәзләр арта көн дә
Бал белән, нуры белән.

Көнгә ачык тәрәзләре,
Дөньяга — күңелләре,
Күңелләре — кәрәзләрнен
Тулышып түгелгәне...

## Соңлаган мәхәббәт

*Дустым истәлегенә*

Алдыбызда кара кабер,
Үлем төсле кара икән.
Дустыбызны бүген бездән
Аерып торыр ара икән...

Көлә идек: «Бигрәк гади,
Әллә бераз тиле микән?..»
Без аңардан көлдек микән,
Үзе бездән көлде микән?

Туфрак өйдек үзе зурлык —
Юрган итеп ябынырлык.
Яхшылыгын өйсәң әгәр —
Тау булырлык, тау булырлык!..

Кабер өсте чәчкә, чәчкә...
Әллә күктән яуган микән?
...Их, аларны исән чакта
Бирәселәр калган икән...



## Рафаэль Хуҗин

●

*Миңа 22 яшь. Туган җирем: Киров өлкәсе Вятские Поляны районының Түбән Шөн авылы. Шул авылда урта мәктәп тәмамладым. Хәзер университетта IV курста укыйм. Шигырьләр язам, дөнья әдәбияты белән танышам. Шигырьне шигырь итеп аңларга һәм язарга өйрәтүче остазларым: Тукай, Такташ, Блок, Лорка.*

## Ташлар

Таш урам, таш йортлар, таш сыннар,
Таш койма, таш мәйдан, таш юллар...
Күпме җир таш белән түшәлгән,
Таштай нык, каты бу — таш куллар.

Ташны да бу тормыш кайвакыт
Таптаган, я кискән, я ваткан.
Йортларның нигезен җимереп,
Кемнәрдер чардуган ясаткан.

Зиратта кабердә ташлар бар:
Агарып ерактан, калкудан,
Дөньяга тарихын сөйләргә
Үлгәннәр таш булып калкыган.

●

Тумыштан ук
Кешe шулай, ашыга ул...
Алга өндәп,
Хыял дигән көч атлый.

Абына икән,
Кочаклый ул газиз җирен,
Кайвакыт җир
Аның үзен кочаклый...

## Кайчак

Кайвакытта бер елыйсы килә...
Җитәкли дә мине сагышлар,
Алып китә аулак урыннарга,
Кайда кеше азрак, тавышлар.

Кайвакытта бер көләсе килә...
Җитәкли дә мине шатлыклар,
Алып китә шаулы урыннарга,
Кайда кеше күбрәк, тавышлар.

## Төн

*Этюд*

Төн...
Җирнең кояшка аркасын
Җылытып яткан чагы.
Күкрәгендә кешеләрнең
Йокыга баткан чагы.

Төн...
Ана йоклата нәниен:
«Йокла, бәбкәем»,— диеп.
Күктән йолдызлар карыйлар
Кара күзлекләр киеп.

Төн...
Җир-ана тып-тын, хыялда...
Нәрсә уйлый — сагына?
Мондый чакта ул һәрвакыт
Кара шәлен ябына.

## Юлларга карлар яуган

Юлларга карлар яуган,
Елларга карлар яуган.
Тамырларын җәеп үскән
Карт имән инде ауган...

Имән канаты астына
Елышып үскән усаклар
Хәзер инде башкаларны —
Чыршыларны кочаклар.

Бер киткәчтен дөньясына
Ачу да юк, юк үпкә.
Имән зәңгәр төтен булып
Ага болытлы күктә...



## Әхмәт Гадел

●

*Мин 1942 елда Кырымда туганмын. Бу дөньяга килгән барча кешеләр кебек үк, тормыш юлымны кычкырып елап башлаганмын. Язмыш гел миһербанлы булып торды дисәм, ялганчы булырмын дим. Чөнки чишмә сулары да эчтем, ачы күз яшьләре белән дә канәгатьләнгән чаклар булды. Илләр, җирләр күрдем, үстем, укыдым. Хәзер Куйбышев шәһәрендә РСУ-1 дә хезмәт итәм.*

### Кошлар кайта

Кошлар язгы җилләр белән
Кайта туган илләренә.
Озын юллар кичә алар,
Салкын, ачлык кичерә алар...
Курыкмыйлар бернидән дә,
Канатларын җилпегәндә
Төшеп кала каурыйлары...
Сагышлы да сагынулары...
Почмакланып тезелешеп,

Күктә кошлар бара очып,
Биек таулар кала аста,
Күпләр егыла бәрелеп ташка...
Моңлы көйләр суза алар,
Дингезләрдән уза алар...
Ләкин барча авырлыкны
Бу көрәштә җиңә кошлар,
Язгы айда, якты көндә
Кайта туган җиргә кошлар.

### Чам[1]

Тамырларын тирән туфракка
жибәреп,
Яр кырыйларына тотынып,
Ташлар кочып үсә,
җилләр сөя аны,
Башка үсемлекләр үсалмаган җирдә,
Үсә кәкре нарат — Кырым чамы!
Ботаклары күк гөмбәзен тотып тора,
Бакчачының бармакларыдай...
Һәркем туган җирен сөйсен иде шулай,
Ташлы тауның батыр чамыдай...

### Янгын сүндерүчеләр

Янгын сүндерүчеләр,
Сез кая ашыгасыз?
Янгын юк,
Бу — кичке офык яна.
Янгын сүндерүчеләр,
Сез кая ашыгасыз?..
Янгын юк,
Бу — көзге яфраклар оча,
Очкыннардай алар уйнап оча...
Янгын сүндерүчеләр,
Сез кая ашыгасыз?

Янгын юк,
Бу — мин киләм,
Чәчләремне туздырып
Мин янам,
янам,
янам.
Һәм сез мине
сүндералмассыз
Җиз башлы брандспойтлардан!
Янгын сүндерүчеләр,
Сез гел юкка ашыгасыз!..

---

[1] Кара диңгез буйларында үсә торган нарат.

Әхмәт Рәшитов

# ЛЕНИН ЯШЬЛЕГЕНӘ ШАҺИТ ҖИРЛӘР

Зур язмышка шаһит бу урыннар
Онытылмаслык, мәңге сөйкемле —
Күнелләрне үзенә дәшеп тора
Кояш Җирне тарткан шикелле.

Тормыш өзлексез дәвам итә. Бабаларга алмашка аталар килә. Буыннар эстафетасы куллардан кулларга күчә бара. Беркем дә үзенә мәңгелек дәгъваламый. Ләкин безнең эшебезне мәңгелек итәрдәй тарих бар, безнең көрәшебезне гасырлар буе яңгыратырдай тәүге таңыбыз — 1917 елның октябрендә планетабызның алтыдан бер өлешенә бәхет кояшы балкыткан революциябез бар, әле тагын меңнәрчә буыннарны җиңүгә рухландырачак үлемсез Ленинобыз бар. Менә шушы хакыйкать хакына яшәгән саен яшисе, эшләгән саен эшлисе килә.

Узган юлыбызда җиңүләр аз булмады, ә киләчәктә алар тагын да күбәер, ишәер, билгеле. Һәм тарихны алга әйдәп баручы һәр буын, бүген без даһи Ильич истәлеге алдында хисап биргән кебек, җиңүләре хакында иң башлап аңа сөйләр, аның белән киңәшер. Безнең кебек, ерактагы елларның серле йомгагын сүтәргә теләп, кайчандыр Ленин гомеренә шаһит булган җирләргә барып чыгар... Апрельнең кояшлы иртәсендә Ульяновскиның үзәгендә уйланып торыр, Казан университетында күп еллар элек булган давыллы вакыйгаларны хыялыннан кичерер. Алакаевка урманнарын буйлар. Шушенскоега, Мәскәүгә, Ленинградка юл тотар...

Владимир Ильич Ленинның якты истәлеген саклаган, аның соклангыч тормышында күренекле роль уйнаган урыннар Җир шарында ул кадәр күп түгел. Иң кадерле кешебезнең тууына 100 тулу бәйрәмен каршылаган бу көннәрдә аларның һәркайсына меңләгән кешеләр килә.

Кояш Җирне үзенә тарткан кебек еракларда күңелләрне чакырып торучы шундый истәлекле җирләргә — Куйбышев шәһәренә һәм өлкәнең Кинель районындагы Алакаевка авылына мин узган елның декабрендә барып чыккан идем. Биредә үткәргән үн көнемнең һәр минутын нәтиҗәле файдаланырга, В. И. Ленин тормышының Самара чорын мөмкин кадәр җентекләбрәк өйрәнергә тырыштым, көннәр буе музейларда актарындым, кешеләр белән очраштым. Куйбышев шәһәренең кайчандыр сөекле юлбашчыбыз йөргән урамнарын буйладым. Аның истәлегенә бәйләнешле һәр урынны, һәр мемориаль тактаны хәтергә сеңдереп калырга тырыштым.

# I Алакаевканиләр хәтерли?

Чал еллардан даулап,
Аның эзен
Саклый урман, кырлар, аланнар.
Хөр күңеле белән яшь Ульянов
Монда кебек әле һаман да.

Бирегә ерак араларны якын итеп киләләр. Чөнки бөек Ильич исеме белән бәйле һәр урын совет кешеләренең күңеленә якын һәм кадерле. Олы шәһәрләрдән читтә, урманнар һәм кырлар кочагында урнашкан Алакаевка авылы да әнә шулай еракларДан үзенә тартып тора.

Күз алдыннан кабатланмас бөек тормышның истәлекле сәхифәләре узгандай була.

Ленинның Самара якларында үткән еллары. Узган гасырның ахыры. Бөлгенлектә газап чигүче иксез-чиксез Россия киңлекләре. Мин менә шул заманнарны күз алдыма китерәм, ә колагымда Самара губернаторының полиция департаментына җибәргән донесениесе чыңлагандай була:

**«1899 елның 21 феврале. Самара өязе исправнигы үзенең 29 январьдагы рапорты белән, Департаментка минем узган елның 25 августында җибәрелгән 911 нче номерлы белешмәмнән билгеле булган, Санкт-Петербургның казенный палатасында канцелярия хезмәткәре булып эшләүче действительный студент Марк Тимофеевич Елизаровның, асып үтерелгән дәүләт җинаятьчесе Ульяновның туганнары булган апалы-энеле Ульяновлар ышанычнамәсе буенча, җир биләүче Константин Михайлов Сибиряковтан 7500 сумга Алакаевка янында 83 дисәтинә җир участогы һәм тегермән сатып алуын хәбәр итте. Тегермән Казан губернасы крестьяны Алексей Евдокимовка арендага бирелгән. Сатып алынган участок хуҗаларыннан әле беркем дә Алакаевкага яшәргә килмәде. Узган елның 6 ноябрендә җибәрелгән 1364 нче номерлы белешмәгә өстәмә буларак, Полиция департаментына шул турыда белдерергә җөрьәт итәм.**

**Губернатор Свербеев».**

Бу донесение юллары язылган көннәрдә Ульяновлар гаиләсе Казанда әле. Ләкин, күрәнебезчә, Владимир Ильич һәм аның туганнары күчеп киләчәк Алакаевка өстендә болытлар куера башлый инде. Ашыгыч чаралар күрелә, шымчылар үзләренең кара эшләрен эшләргә әзерләнәләр, әледән-әле Алакаевка авылы читендәге ялгыз усадьбаны күзәтеп үтәләр. Юк, Ульяновлардан беркем дә күренми әле...

Һәм менә, ниһаять, 1899 елның 8 мае...

Самараның өяз исправнигына шомландыргыч донесение килеп төшә.

**«Полициянең яшерен күзәтүе астында торучы, Казан университетының элекке студенты Владимир Ильич Ульянов майның өчесе көнне Казаннан Самара өязе Богдан волостеның Алакаевка авылы янындагы хуторга китте.**

**Шул турыда сез галиҗәнапләргә зур түбәнчелек белән белдерәм.**

**Казан полицмейстеры».**

Ульяновлар гаиләсе Алакаевкада биш җәйләрен үткәргәннәр. Владимир Ильич биредә революцион карашлы кешеләр белән очрашкан, алдагы көрәшләргә әзерләнгән. Алакаевка юлбашчыбызга Казандагы беренче бастилиядән соң яңа плацдарм, яңа көрәш мәйданы булган. Салкын декабрь көннәренең берсендә мин әнә шул авылга юл тоттым.



*Алакаевкада Ульяновлар гаиләсе торган йорт.*

Алакаевка Куйбышев шәһәреннән 60 километр ераклыкта. Иртәнге автобус җирле вакыт белән сәгать алтыда кузгала. Ике ягына «Ленинский» дип язылган, тәрәзәләренә революцион вакыйгалар темасына рәсемнәр ясалган мәһабәт «Икарус»ны әнә тирә-яклап сырып та алганнар. Пассажирлар күп бүген. Аларның байтагы В. И. Ленинның Алакаевкадагы музей-йортын күрергә баралар.

Автобус озын урамнар буйлап боргаланып йөри дә, ниһаять, шәһәр читенә чыгып, төньяк-көнчыгышка таба юл тота. Төнлә явып үткән карны ера-ера баручы «Икарус» фаралары караңгылык эченнән такыррак урыннарны капшый. Тирә-якта — куаклар, ә бераздан алар урман белән алышына. Пассажирлар, бу җирләрне хәтерләренә сеңдереп калырга тырышкандай, тәрәзәләргә текәлгәннәр.

Без Алакаевкага барып җиткәндә яктырып беткән, кар да явуыннан туктаган иде.

«Икарус» зур гына бер бина янына — Владимир Ильич Ленинның Алакаевкадагы музей-йорты янына килеп туктады. Яшел рәшәткәләр белән әйләндереп алынган бу утар шәһәр тибындагы шундый агач йортлардан бернәрсәсе белән дә аерылып тормый шикелле. Капкачлары эләктереп куелган зур, якты тәрәзәләр, өйдән турыдан-туры ишек алдына алып чыгучы болдыр, агач түбә өстендә калкып торган берничә кирпеч морҗа, йорт тирәли — кура җиләк, сәрби агачлары...

Музей директоры Владимир Иванович Мартынов безне ишек төбенә үк чыгып каршылады. Владимир Ильичның бирегә тормышы белән танышу шуннан башланды.

Нинди язмыш җилләре Ульяновлар гаиләсен бу ерак җирләргә алып килгән соң? Нигә алар бу тыныч, олы юллардан читтә урнашкан урынны сайлап алганнар? Алакаевка юлбашчының яшьлек елларыннан ниләр хәтерли?

Владимир Иванович Мария Александровнаны бирегә күчеп килергә мәҗбүр иткән сәбәпләр турында сөйли. Соңгы елларда зур фаҗигаләр кичергән ана үзенең балаларын Саша кебек үк язмышка эләгүдән саклаган. Владимир Ильич игенчелек эше белән мавыгып, политикадан читләшер дип өметләнгән. Соңыннан Ленин Надежда Константиновна Крупскаяга: **«Әни минем авылда хуҗалык белән шөгыльләнүемне теләгән иде. Мин тотынып та карадым, ләкин күрәм — ярамый, крестьяннар белән мөнәсәбәтләр бозыла башлый»,**— дип сөйли.

Ульяновлар гаиләсе Алакаевкада сатып алынган җир участогыннан файдаланмый, аны арзан хак белән крестьяннарга арендага бирә.

Ульяновлар гаиләсенең тормышы һәрвакыт полициянең игътибар үзәгендә тора. Өяз исправнигының Самара губернаторы исеменә язылган рапортларында полициянең ачык күзәтүе астында торучы Анна Ильиничнаның һәм яшерен күзәтү астында торучы Владимир Ильичның һәр адымы турында әйтелә.

Ульяновлар ул вакыттагы Россиянең эре алпавыты Сибиряковтан җир участогы белән бергә сатып алынган агач йортта яшиләр. Шунда ук ярым ташландык хәлгә килгән бакча да була. Өй һәм бакча ул чакта бер яктан да тотылмаган, бакча тирәли чокыр гына казылган. Аның эзләрен бу участокның кайбер урыннарында хәзер дә күрергә мөмкин әле.

Бакчада җиләк-җимеш агачлары үсә, өрәнге, каен, усак агачлары ябалдашлары белән бер-берсенә кушылып ышык һәм тыныч аллея хасил итәләр. Анна Ильинична үзенең буш вакытларын каен аллеясында үткәрергә яраткан. Ольга еш кына нинди дә булса өрәнге төбенә утырып сәгатьләр буе китаплар укыган. Ә Владимир Ильичның көнелен юкәләр аллеясындагы аулак һәм тын урын җәлеп итә. Ул үзенең яшел кабинетына өстәл һәм урындык ясап куя. Иртән сәгать тугызларда китаплар, дәреслекләр, белешмәләр, дәфтәрләр күтәреп үзе яраткан шул урынга юнәлә һәм төшке ашка кадәр үз эшләре белән мәшгуль була. Тәнәфес ясаган араларда үзе әмәлләп куйган турникта атынып ала. Нидер уйланып сукмак буйлап әрле-бирле йөренә. Аннан янадан үзенең китапларына чума. Бу вакытта Владимир Ильич юридик фәннәр буенча экстерн имтиханга әзерләнә. Марксизм тәгълиматын үзләштерүгә, Россиядә эшчеләр һәм крестьяннарның көнкүрешен өйрәнүгә дә зур игътибар бирә. Аның өстәлендә еш кына Карл Маркcның «Капитал», Фридрих Энгельсның «Англиядә эшчеләр сыйныфының хәле» китапларын, народниклар язган хезмәтләрне очратырга мөмкин була. Владимир Ильич барысын да җентекләп укый, алган тәэсирләрен, уянган фикерләрен үз дәфтәренә терки бара. Бу чорда яшь Ульяновны Россиядә социал-демократик хәрәкәтнең мөмкинлекләре, капитализмның үсеше һәм аның авыл хуҗалыгына торган саен ныграк үтеп керүе турындагы статистик мәгълүматлар кызыксындыра. Владимир Ильич Алакаевка һәм тирә-як авыллардагы крестьяннар белән тыгыз элемтәдә яши, аларның яшәү шартларын сораша, төрле мәсьәләләр буенча киңәшә. Еш кына Ульяновларга кунакка Алакаевкадан өч-дүрт километр ераклыктагы Шарнеля хуторыннан Преображенский килеп йөри. Бу кеше ул вакытта народниклык настроениеләреннән арынып житмәгән була әле. Ул еш кына Владимир Ильич белән кызу бәхәсләр кузгатып җибәрә. Янадан очрашкач, ул бәхәсләр яна көч, яна дәлилләр белән кабынып китә. **«Әгәр мин берәр хата җибәрсәм,**— дип яза Преображенский үзенең истәлекләрендә,—**Владимир Ильичның күзләрендә яшел ут ялтырый һәм ул хәйләкәр елмаеп: «Я, я, туган, төзәтеп кара үзеңне», дип әйтә иде».**

Шундый бәхәсләрдә Ленинның революцион карашлары ныгый. Ул чын революционерларның барлык гүзәл сыйфатларын туплый бара.

Владимир Иванович безне музей заллары буйлап озак йөртә, андагы йөзләрчә экспонатлар, фотографияләр, бүләкләр белән таныштыра. Узган ел гына да биредә унбер меңнән артык кеше булып киткән икән. Кемнәр генә юк алар арасында?! Самара якларында революция давыллары уйнаткан чал чәчле ветераннар да, бөек Ленин эшенә турылыклы булырга ант итүче ал галстуклы пионерлар да... Һәр тарафтан адреслар, адреслар, адреслар... Төркмәнстаннан, Шушенскоедан, Ульяновскидан, Мәскәүдән, Казаннан, Үзбәкстаннан... Бирегә килгән һәркем Ильич көнеленең җылысын тоярга, аның искиткеч гүзәл тормышына тагын бер кат сокланырга тели.

Музейдагы дулкынландыргыч хикәядән соң, күзләр ирексездән, ул истәлекле елларның шаһите булырга ниятләнеп, еракларга, Алакаевканы тирә-яклап урап алган күксел урманнарга текәлә. Әнә каршы якта Муравельный урманы, тегесе Банный дип атала... Каменный... Гремячий...

Ульяновлар гаиләсенең иң яраткан ял урыны Муравельный урманы була. Биредә җир җиләге дисеңме, кура җиләге дисеңме — ел саен мул уңа. Бөтенесе, шау-гөр килеп, бергәләп чыгалар. Уен-көлке, шаян сүз. Һәркемнең күңеле күтәренке. Владимир Ильич бу сәяхәтләрне аеруча ярата.

Еш кына Ульяновлар бакча башына терәлеп торган буага су коенырга төшәләр.

Урман читенә терәлеп үк диярлек икешәр катлы зур таш йортлар тезелеп киткән. Бу шәһәрчек Алакаевкада әле соңгы елларда гына пәйда булган. Без «Ленинский» совхозы директоры Алексей Васильевич Чеховских һәм партоешма секретаре Евгений Васильевич Солдатов белән әнә шул биналар яныннан узабыз. Алакаевкага урнашкан «Ленинский» җиләк-җимеш совхозы эшчеләренең күбесе хәзер бөтен уңайлыклары булган иркен һәм якты квартираларда яшиләр. Мондый йортлар саны әлегә күп түгел — алар сигез генә. Ләкин тиздән барлык кешеләрнең ихтыяҗы тулысынча канәгатьләндереләчәк. Моннан тыш тирә-ягында бакчасы булган унсигез коттедж төзелә. Кечерәк гаиләләр өчен ике катлы коттеджлардан квартиралар биреләчәк. Кыскасы, 1970 елга Алакаевка бөтенләй шәһәр төсен алачак. 360 урынга исәпләнгән культура сарае, мәктәп, административ бина, сәүдә үзәге, мунча, техниканың соңгы казанышларын исәпкә алып төзелгән механикалаштырылган терлекчелек каралтылары инде быел үк сафка басачаклар.

Совхоз директоры Алексей Васильевич бу турыда хыялланып һәм дулкынланып сөйли.

Минем Алакаевканың үткәне белән бүгенгесен чагыштырып карыйсым килә. Авылга нигез салучылар 18 нче гасырның башында Россиянең үзәк губерналарыннан куып китерелгән крепостной крестьяннар булганнар. Алар эре алпавыт Данненберг милке саналган җирләрне эшкәрткәннәр, иртә таңнан кичке караңгыга кадәр аның байлыгын ишәйтү өчен бил бөккәннәр, якты кояшны, бу якларның гүзәл табигатен күрми яшәгәннәр. Крепостное право бетерелгәч тә, аларның хәле җиңеләймәгән. Кырык хуҗалыкка нибары алтмыш дисәтинә җир бирелгән. Аның да иң уңдырышлыларын кулаклар һәм дин әһелләре бүлеп бетергән.

Ә хәзер алакаевкалыларның тормышына сөенеп туя алмыйсың. Бүгенге Алакаевка бер сынык икмәк турында түгел, тагын да куәтлерәк машиналар, зур әзерлекле белгечләр, җирне тагын да уңышлырак итү турында хыяллана. Ил-күләм җиңүләр белән канатланып яши. Аның мул сыйлы табынында шундый ук шат, шундый ук бәхетле кунаклар. Бу — бөек Ленин идеяләренең тормышка ашуы, бу — бөек Ленин омтылышларының тантанасы!

Әйе, патша самодержавиесе шартларында мондагы җирләр крестьян агайга үги булган, кысыр җирләр тамакны тук итмәгән, өсне бөтәйтмәгән. Ә хәзер уңыш биредә каерылып уңа. 1967 елда, мәсәлән, Алакаевка игенчеләре җирләрнең һәр гектарыннан моңарчы күрелмәгән уңыш — 24,5 центнер ашлык алганнар, дәүләткә икмәк тапшыру планын 600 процентка үтәгәннәр. Бу — Куйбышев өлкәсе өчен иң югары күрсәткеч. Терлекчелек продуктлары җитештерү буенча да «Ленинский» совхозы Кинель районында гына түгел, ә бөтен Куйбы-

шев өлкәсендә алдынгылардан санала икән. Саннардан да көчлерәк дәлил бармы соң? Аларны көздән кичереп, ирексездән, менә ул бүгенгенең искиткеч үзгәрешләре, менә ул гасырлар буе хыялланган муллык һәм байлык, дип куясың.

Ләкин Алакаевканың төп байлыгы — кешеләр. Биредә төрле милләт вәкилләре — руслар, казакълар, мордвалар тату гаилә булып яшиләр, шатлыкларны да, көндәлек мәшәкатьләрне дә бергәләп кичерәләр, матур киләчәк, якты идеаллар хакына җиң сызганып эшлиләр.

Менә аларның берничәсе белән генә танышыйк. Рус Алексей Федорович Давыдов тракторчы булып эшли. Ул «Почет билгесе» ордены белән бүләкләнгән, Мәскәүдә авыл хуҗалыгы күргәзмәсендә катнашкан.

Казакъ Харис Якоримов терлекләр карый. Совхоздагы һәр яңа башлангычта аның өлеше бар, социалистик ярыш алдынгысы.

Коммунист Яким Екереевич Колесников милләте буенча мордва. Ул симертү группасында эшли. Ул тәрбияләгән терлекләрнең тәүлеклек артымы бик күп алдынгыларны көнләштерерлек.

Күргәнебезчә, өч кеше — өч язмыш, аларның өчесен дә бер уй, бер максат берләштерә, алар өчесе дә халык интереслары белән янып яшиләр. Бу — кеше кешегә дус, туган һәм иптәш, дигән ленинчыл принципның ачык чагылышы түгелмени?!

1965 елдан бирле совхоз җиләк-җимеш хуҗалыгы булып санала. Бу яктан әле беренче адымнар гына ясалган. Хәзер биредә 600 гектар мәйданлы бакча бар. Якын елларда ул 900 гектарга җитәчәк. Җиләк-җимешне эшкәртү комбинаты булдырыла.

Планнар зурдан. Ләкин аның тормышка ашачагына шикләнмәскә мөмкин.

Ул елларда Алакаевкада яшәгән Владимир Ильич, бу якларда шундый казанышларга ирешеп булачагын, мөгаен, күз алдына да китермәгәндер, аның яшьлегенә шаһит җирләрдә күп милләтле гаилә булып яшәп, революция тудырган буын яңа, якты тормыш төзи. Биредә хәзер тормыш чишмәләре кайнап тора.

Алексей Васильевич Чеховских белән бергә без кешеләр белән сөйләшәбез, механика мастерскоена кереп, андагы эшләр белән танышабыз. Һәр җирдә хезмәт шавы, һәр җирдә тормыш авазы.

Кайчандыр тынып һәм йокымсырап яткан бу якларда туктаусыз хәрәкәт. Әнә, авыл кырыеннан гына узучы асфальт юлдан борылып, машиналар монда таба үтә. Кузовларда тамыры-туфрагы белән җыйнак итеп казып алынган усаклар, каеннар, юкәләр... Хәзер Алакаевкада Ульяновлар торган йорт тирәсендәге бакча шул замандагыча итеп торгызыла. Юкә аллеялары, каен, өрәнге аллеялары булдырыла. Владимир Ильичның ул чактагы «яшел кабинеты» өчен дә тиешле материаллар кайтарылган. Ульяновлар утары һәм Алакаевкада соңгы елларда пәйда булган шәһәрчек бөек юлбашчыбызның тууына йөз ел тулу көненә мемориаль зона тәшкил итәчәк.

Мондагы гаҗәеп мөлаем һәм хезмәт сөючән кешеләр белән һәм аларның гүзәл эшләре белән танышкач, Алакаевканиләр хәтерли, дигән соравыма да җавап тапкандай булдым. Ул Ленин васыятьләренә турылыклы, ул Ленинның якты истәлекләрен үзендә саклый, авылның үткәнен, бүгенгесен хәтерли һәм киләчәккә карап яши — даһи остазыбыз идеяләрен тормышка ашыра барып, яңадан-яңа җиңүләр яулый, диясем килә минем.

## 2 Давыл алдыннан

Ильич дусларының истәлеген
Сөйли безгә ярдан тирәкләр.
Идел уртасына ашкынганнар
Давыл көтеп типкән йөрәкләр.



Куйбышев якларында даһи Ленин образын хәтерләткән истәлекле урыннар, аның исеменә лаек булырдай гүзәл эшләрне һәр адымда очратасың. Юлбашчыбыз исемен йөрткән гигант гидроэлектростанция дисеңме, Тольяттида корыла торган автомобиль заводы дисеңме, синтетик каучук заводы яки башка куәтле промышленность предприятиеләре дисеңме... Хәер, Ильич якташларының горурланырлык эшләрен санап бетереп буламыни?!

Мин шәһәрнең мәһабәт биналары, культура сарайлары, куплэгән завод-фабрикалары янынннан, шау-шулы үзәктән үтеп иске Самара урамнарына таба юнәләм. Тын, йокымсырап яткан хәвефсез урамнар. Декабрь җилендә карт өрәнгеләрнең очлары салмак кына тирбәлә. Кайчандыр бу юллар, бу сукмаклар буйлап Владимир Ильич йөргән. Иске йортлар, тын урамнар, Идел ярлары еракта елларның хәтердә калган сәхифәләрен, юлбашчыбызның гүзәл яшьлеген сөйлиләр сыман.

Юлбашчыбызның Самара якларында яшәү еллары бөтен Россия киңлекләрендә социаль тетрәнүләр чорына туры килә. Ул чакта Идел буйларына коточкыч корылык, ачлык зәхмәтләре җәелә. Шыксыз үлем карачкысы үзенең кара эшенә керешә.

«Ач үлемнең куркусыннан ил елаган» дәһшәтле 1891 ел. Шәһәр урамнарында бер кабым икмәк сорап кулын сузган хәлсез крестьяннар төркеме.

Афәт вакытында үзләренең «киң күңеллелекләре» белән шапырынып алырга форсат тапкан һәртөрле радикаллар, либераллар, купецлар, чиновниклар һәм хәтта реакцион обывательләр ыгы-зыгы киләләр, шау-шу куптаралар — үзләренең «кече туганнары — мужикны» һәлакәттән коткаралар, янәсе. Аһ-ваһ килеп төзелгән «Ачларга ярдәм комитеты»нда туктаусыз уфтанулар яңгырый, һәртөрле чаралар билгеләнә, ә халык... кырылганнан-кырыла бара.

Петербург университетында экстерн тәртибендә дәүләт имтиханнарын тапшырып бетергән Владимир Ильич Самарага әнә шул лыгырдауларның иң кызган вакытында кайтып төшә.

Бердәнбер мактанычы бай китапханә булган, ил файдасы өчен аркылы яткан таякны буйга алып салмаган либерал народник В. В. Водовозов (шунысы кызык, Александр Ильичның патшаны үтерергә маташуда гаепләнеп кулга алынуын ишеткәч, ул: «Ах, нинди кызганыч, минем бик кыйммәтле китабымны алып торган иде, харап булыр инде»,— дип кенә пошыну белдерә) һәр почмак чатында диярлек Владимир Ильич һәм аның тирәсенә тупланган яшь марксистларны ачларга ярдәм кулы сузмауда гаепләп акырына.

Ленинның якын көрәштәшләреннән берсе — А. А. Беляков үзенең истәлекләрендә бу уйдырмаларның нигезсезлеген фаш итә. Владимир Ильичның ачларга соңгы сыныгын авызыннан бүлеп бирергә әзер торуы турында сөйли. Шул ук вакытта яшь Ульянов бу афәтне китереп чыгарган социаль сәбәпләр хакында да дәшми кала алмый. Ул ил кичергән бәланең рәхимсез эксплуатация нәтиҗәсе икәнлеген бар йөрәге белән аңлый, аның сыйнфый асылын ачып күрсәтә.

Владимир Ильич Ленинның Куйбышевтагы музей-йортында куелган күп санлы экспонатлар даһи юлбашчыбызның кече яшьтән гади



Куйбышев шәһәрендә В. И. Ленин музей-йорты.



Самара округ суды бинасы. Бирегә Владимир Ильич присяжный поверенный ярдәмчесе булып эшләгән.


халык массалары белән тыгыз элемтәдә яшәвен, аларның уй-хыяллары үзенә тормыш идеалы итеп алуы хакында сөйлиләр. Менә ул Сызрань көймәчеләренең хокукын яклап башбаштак купец Арефьев белән судлашып йөри, менә ул ярлы крестьяннарга теге яки бу мәсьәлә буенча эшлекле киңәшләр бирә...

1892 елның январенда Владимир Ильич Самара округ судында присяжный поверенный ярдәмчесе булып билгеләнә. Бер елга якын вакыт эчендә ул уналты эшне карауда катнаша. Яшь адвокатның беренче чыгышы ук җәмәгатьчелекнең игътибарын үзенә җәлеп итә. «Ходай тәгаләгә һәм патша хәзрәтләренә тел тидерүдә» гаепләнүче В. Ф. Муленковны яклау кебек «өметсез эшкә» алына ул.

Авыр тормыштан иза чиккән, дөньяның ачысын-төчесен байтак татыган, очын очка көчкә ялгап баручы карт тегүче Василий Федорович көннәрнең берендә усал гына итеп сүгенеп ташлый. Хәбәрне шунда ук властьларга җиткерәләр. Аңа җәзалар турындагы Уложениенең 180 нче статьясы нигезендә күпьеллык төрмә яный. Адвокатларның барысы да бу четерекле процесстан баш тарталар. Владимир Ильич кына «күңелсезлек чыгудан» курыкмый, эшне ахыргача җиткерергә карар итә. Прокурорның кинаяле сүзләрен дә, судьяларның кырын карашын да салкын кан белән каршыларга туры килә аңа. Адвокат Ульянов барыбер үз максатына ирешә — Муленковны бары бер елга гына хөкем итәләр. Шуның өстәвенә аның судка кадәр тоткында үткәргән алты ае да исәпкә алына.

Бу уңыш хөкем көтүче башка крестьяннарда да өмет чаткысы уята. Кайберләре хәтта элек үзләре сайлап алган адвокатлардан да баш тарталар. М. В. Опарин, Т. И. Сахаров, И. И. Уждин, К. Ф. Зайцев, И. В. Красильников, Е. Я. Ишкин, И. Ф. Зорин кебек еллар буе ачтан газап чиккән һәм ахыр чиктә байлар милкенә кул сузарга мәҗбүр булган ярлы крестьяннарга да Владимир Ильич яклавының зур файдасы тия.

Үзен тиз арада көчле адвокат итеп таныткан бу яшь юристка еш кына югары катлау вәкилләре дә мөрәҗәгать итә, ләкин Ульянов аларны яклауга алынмый. Акча эшләү, байлык туплау мөмкинлеге кызыктырмый аны. Үзе катнашкан процессларда Владимир Ильич игътибарны гаепләнүчеләрнең җинаятьләренә сәбәп булган социаль шартларга юнәлтә



*Яшь адвокат В. И. Ульянов судта ярлы крестьян В. Ф. Муленковны яклый.*



*«Давыл булса, тартышырбыз» (А. Лебедев картинасыннан)*

һәм барысына да патша самодержавиесе строе гаепле икәнлеккә мәгънәле ишарәләр ясый.

Юристлык практикасы аны ул кадәр мавыктырмый. Егерме ике яшьлек Ульянов күп вакытларын легаль булмаган марксистик түгәрәкләрдә — кызу бәхәсләрдә һәм эчкерсез фикер алышуларда уткәрә.

А. П. Скляренко түгәрәге тирәсенә туплаган яшьләр башта әле народниклык настроениеләреннән арынып бетмәгән булалар, житди фәнни әсәрләрне анализлауга һәм тирәнтен өйрәнүгә ныклап керешә алмыйлар.

А. А. Беляков үзенең истәлекләрендә: **«Революцион марксизм микробын Самарага Владимир Ильич Ульянов алып килде»**,— дип яза. «Капитал»ны «кимерү» дә бирдә шул вакытларда башлана. Владимир Ильичның һәрнәрсәне гади итеп аңлата белүе күп кенә катлаулы һәм шактый буталчык булып тоелган хезмәтләрнең дә серенә төшенергә ярдәм итә, яшьләрдә үз көчләренә ышаныч тудыра. Унбишләп кешене берләштергән бу группа тора-бара «акыллар хакиме» саналган Михайловский һәм аның һәртөрле тарафдарларына житди «идея сабагы» бирерлек куәтле сугышчан отрядка әверелә.

Музейга килүчеләрнең игътибарын «Давыл булса, тартышырбыз» дип исемләнгән бер картина аеруча җәлеп итә. Мин дә аңа карап озак уйланып тордым. Хәтердә Ленин замандашлары калдырган истәлекләр җанлангандай булды. В. И. Ульянов һәм А. П. Скляренко житәкчелек иткән түгәрәк членнарының Идел һәм Уса елгалары буйлап сәяхәте турында ул картина.

1890 елның апрель азакларында шундый «Җир тирәли сәяхәт» вакытында алар Царевщина авылы крестьяны Василий Князев, Амос һәм Ерфилыч дигән ике сектант белән очрашырга уйлыйлар.

Кояш чыгар-чыкмас борын В. И. Ульянов, А. П. Скляренко, И. А. Кузнецов, В. В. Савицкий, Н. Я. Полежаев, А. А. Беляков утырган көймә юлга кузгала. «Нимфа» агым уңаена бара да бара. Бәхәсләрне уен-көлке, җыр-музыканы тагын бәхәсләр алмаштыра. Менә горизонтта Екатериновка авылы. Биредә аларга фикердәшләре А. П. Нечаев кушылырга тиеш.

Екатериновкада Владимир Ильич озак кына Нечаевның әтисе белән сөйләшеп утыра.

— Нигә авылда ярлылык көчәйгәннән-көчәя бара? — дип сорый ул аннан.

— Менә бу «аракы» дигән нәрсә дә бар бит,— ди Нечаев,— ә ана безнең йомшаклыкны кая куясың. Шуның өстәвенә, янгыннар, игеннең уңмавы, авырулар — барысы да өсте-өстенә чүмәлә. Бүген йөгәнеңне сатып эчәсең, ә иртәгә атыңны, ә аннан, әйтик, ашлыгың булмады, ди — эшең бетте, кодагый. Ярлы хәерчегә әйләнә, урта хәллесе аның урынын алыштыра, ә акчасы һәм башы булганы — ул җирләрне үзенә эләктереп ала һәм теге каһәр сукканнарны ипи һәм су хакына эшләргә мәҗбүр итә. Димәк, авызың ачып калырга ярамый. Менә шулай үз җаена тәгәри инде ул. Авылның бер өлеше бөлә бара, ә икенчеләр баеганнан-байый; берәүләр фабрикага яки батраклыкка китеп бара, икенчеләр исә алпавыт булырга чамалый...

Бу сөйләшү Владимир Ильичны нык тәэсирләндерә.

— Югыйсә бу карт Нечаев экономист-галим дә түгел, ә әйберләрнең мәгънәсенә әнә ничек төшенә белә,— ди ул дусларына.— Николай Даниельсоннарга, Михайловскийларга авылның котылгысыз дифференциацияләнү процессын да, артельләр һәм общинаның авыл тормышындагы чын ролен дә аңларга менә кемнән өйрәнергә иде, ул чагында, мөгаен, Россия үсешенең үзенчәлекле юллары һәм мужик социализмы турында лыгырдаудан туктарлар иде. Үзенең кыска гына сүзендә дә Нечаев авылның катламлануын һәм хуҗалыкның капиталистик формалары калкып чыгуын ачып салды бит...

«Җир тирәли сәяхәт» әнә шундый кызыклы очрашулар, эчкерсез сөйләшүләр белән аралашып дәвам итә. Дуслар табигать гүзәллегенә сокланып Идел уртасыннан йөзәләр. Кайчагында ярга туктап яшеллек эчендә күңел ачып алалар. Йөгерешү, көрәшүләр... Владимир Ильич мондый чакта читтә каламы соң?! Менә ул шактый нык күренгән Кузнецов белән бил алыша башлый, барысын да гаҗәпкә калдырып, аны җиңел генә күтәреп тә бәрә. Аннан Владимир Ильичка Скляренко килеп тотына һәм, гомуми көлү астында, ком өстенә сала. Һәркемнең күңеле шат. Табигать тә бу күңеллелеккә ямь өсти сыман.

Ә бер көнне, аларның «Нимфа»лары Идел уртасына чыккач кына, давыл куба. Коеп яңгыр ява, зур-зур дулкыннар көймә өстенә үреләләр... Яшен яшьни, күк күкри... Скляренко, Полежаев, Савицкий ярга таба йөзү ягын каералар, ә Беляков, Кузнецов һәм Нечаев, киресенчә, яр буенда куркынычрак, көймәнең әйләнеп каплануы да бар, дип баралар. Владимир Ильич иптәшләрен тынычландыра, көр күңеллелеген югалтмый, «яр тарафдарлары» өстеннән шаяртып көлеп тә ала.

«Давыл булса, тартышырбыз» — җырдан алынган бу сүзләр яшь Володяның да, аның көрәштәш дусларының да тормыш девизына әверелә. Алар мондый давыллар турында гына түгел, тиздән бөтен Россияне чолгап алачак революцион көрәш өермәләре турында хыялланалар ул вакытта.

Владимир Ильич Самарада чәчкән марксизм орлыклары уңдырышлы туфракка төшәләр, матур шытымнар бирәләр. Биредә узган биш ел әрәмгә китми. Ә яшь көрәшче үзе киңрәк мәйданнар эзләп, 1893 елның август ахырында Петербургка китеп бара.

Кайчандыр юлбашчыбыз яшьлегенә шаһит булган бу җирләрдә Ильичның варислары яши. Алар Ильич хыялланган якты тормыш — коммунистик җәмгыять төзиләр. Аларның җиңүләр белән данга күмелгән байракларына «Ленин» исеме язылган.

**Газиз Мөхәммәтшин**

# РАЙКОМ СЕКРЕТАРЕ

Еракта-еракта — Кама таулары өстендә — сызылып кына язгы таң ата. Төн кунарга туктаган болытларның алсу итәкләрен балкытып, һавага беренче якты нурлар сузыла. Җир күзләрен ачып яңа көнне сәламли. Табигать уяна. Кошлар гадәттәге җырларын җырлый башлыйлар, елга-күл өсләреннән җиңелчә пар күтәрелә, яшел болыннарда җем-җем итеп чык бөртекләре ялтырый.

Минзәлә дә уяна башлый. Капкалар ачыла. Урамнарга җылы күмәчнең тәмле исен таратып, пекарня ягыннан фургоннар кайта, әле анда, әле монда машина моторлары гөрелди башлый, чит урамнарның билгеләнгән урыннарына мөгри-мөгри сыер көтүләре җыела, тимер күперле дамба буйлап шәһәргә беренче колхоз машиналары керә.

Үзәк урамнарның берсеннән тиз-тиз атлап, каратут йөзле, нык һәм җиңел гәүдәле кеше килә. Очраганнар хөрмәт белән аңа сәлам биреп узалар:

— Исәнмесез, Мәгъсүм Шәйгазәмович!

— Хәерле иртә, иптәш Хөсәенов!

— Исәнме-саумы, әйбәт йокладыгызмы, Хөсәенов абый! — диләр.

Менә ул КПССның район комитеты урнашкан ике катлы ак бинаның ишек алдына килеп керә. Ишек алды — кечкенә генә аллы-гөлле бакча. Сукмакның ике ягында да, иртәнге җилдә яфракларын лепердәтеп, алмагачлар үсеп утыра. Алмагачлар арасында — гөлләр-чәчәкләр. Ниндиләре генә юк аларның! Кашкарыйлар да, эре чәчәкле ирисләр дә, җете кызыл гладиолуслар һәм тюльпаннар да, дәлия чәчкәләре дә, пионнар һәм розалар да һәм тагын исемен бакчачылар гына белә торган уннарча төрле ят чәчкәләр дә, хәтта Кырым һәм Кавказның назлы «кунаклары» да үсә монда.

Райкомның беренче секретаре аларга сокланып карап тора. Бакча буйлап әйләнеп чыга. Кайберләренең төпләрен йомшарта, чүп үләннәрне алып ташлый, сыгылып төшкән эре чәчәкләрне күтәртеп бәйләп куя. Аннан соң әлегә буш һәм тыныч коридор буйлап икенче катка күтәрелә һәм кабинетына керә. Эшкә утырганчы тәрәзәләрне ачып җибәрә. Тәрәзәләрдән яшел алма һәм чәчәкләр исе бөркелеп керә. Мәгъсүм Шәйгазәмович, күзләрен кыса төшеп, тагын бакчага карап тора. Нинди матур бит! Ә элек монда бер нәрсә дә юк иде. Алмагачларны ул үзе утырттырды, чәчәкләрне ул үзе тәрбияли, үстерә. Райком кассиры Нина Михайловна Кукаркина белән алар икесе эшлиләр. Февраль ахырларында ук ящиклар ясап тәрәзә төпләрендә рассадалар үстерә башлыйлар. Мәскәүгәме, Казангамы, санаторийгамы — кая гына бармасын, ул пакет-пакет чәчәк орлыклары алып кайта. Төрле оешмаларга өләшә, утырту, үстерү юлларын өйрәтә. Хәзер, соңгы берничә ел эчендә, Минзәләдә чәчәкләр күбәйде. Паркларда да, ишек алларында да, өй каршындагы бакчаларда да. Чәчәкләр колхозларга да күчәләр. Узган ел Минзәлә районы хезмәт ияләре Октябрь бәйрәменә бер миллион төп чәчәк үстерәбез, дигәннәр иде. Сүзләрендә тордылар. Көз көне районның чәчәк күргәзмәсендә моны шатланып билгеләп үттеләр.

Җир өстендә чәчәкләр күбәя. Ул җирне матурлый. Кешеләрне матурлыкны аңларга, яратырга өйрәтә, көнне һәм тормышны бизи, зәвыкны үстерә, күңелләргә дәрт һәм шатлык өсти, кәефне күтәрә.

Секретарь, чәчәкләрнең хуш исен күкрәгеннән тутырып тагын бер сулады да, өстәл янына килеп, тартмадан бер хат алды. Ул Красноярск краеның бер райкомыннан килгән. «Чәчәк үстерүчеләр» журналыннан укыганнар да: «Без дә сезнең кебек эшләргә телибез, орлыклар җибәрмәссез микән?» — дип язганнар. Орлыкларны, билгеле, шунда ук җибәрделәр. Хәзер Себер җирендә дә Минзәләдә үскән чәчәк орлыкларыннан шыткан матур гөлләр үсә...



Ишек ачылган тавыш ишетелде. Райком хезмәткәрләре килә башладылар. Хөсәенов хатны өстәл тартмасына салды һәм телефон трубкасын алды.

— Сеңелем, миңа Куйбышев колхозын бирегез әле. Газизовны,— диде.

Тынгысыз һәм авыр хезмәт көне башланды. Ул, гадәттәгечә, кояш баеп караңгы төшкәнче дәвам итәчәк. Әле өйгә кайткач та әллә ничә телефон звоногына җавап бирергә, әллә кемнәр белән әллә ничә төрле мәсьәләләрне хәл итәргә туры киләчәк.

Айлар, еллар буена, гомер буена шулай...

Мәгъсүм ага — безнең якташ. Ул 1911 елда Сарман районы Балтамак авылында крестьян семьясында туа.

Белмим, әти-әниләре ул чакта уллары Мәгъсүм үскәч кем булыр дип уйладылар икән?! Һәрхәлдә, син, улым, 277 686 гектар җире-суы булган зур районда партия райкомы секретаре булып эшләрсең, халык сине дәүләтнең югары органнарына депутат итеп сайлар, Ватаның сине Социалистик Хезмәт Герое итеп күкрәгеңә Алтын Йолдыз медале һәм Ленин ордены тагар, дип уйларына да китермәгәннәрдер.

Гади халыкның уена да килмәгәнне, төшенә дә кермәгәнне Бөек Октябрь социалистик революциясе, Совет власте күрсәтте. 1931 елны, Алабуга техникумын тәмамлаганнан соң, Мәгъсүм ага укытучы булып авылга кайта. Авыл балаларына белем бирә башлый. Шул ук вакытта комсомол эшенә бирелеп китә. Ә комсомолда эшләрлек эшләр күп була ул чакта. Гомер буена башлары казан тирәсеннән, мич арасыннан чыкмаган хатын-кызлар яңача яшәргә, яңача уйларга телиләр. Аларны комсомол сафларына тартырга, клуб сәхнәләренә алып менәргә кирәк. Яшь комсомол секретареның инициативасы белән, тегү машиналары алып, кызларны тегүгә өйрәтү түгәрәкләре оештыралар. Аларны җитәкче эшләргә дә тарта башлыйлар: бригадирлар, звено җитәкчеләре итеп куялар. Гомумән, ул чорларда массаларның аңын күтәрү, яшьләр һәм кызлар арасында яңа тормыш өчен пропаганда алып бару һәм кичә генә әле байларда ялчы булып йөргән кешеләрдән җитәкче кадрлар әзерләү комсомолның бик мөһим бурычларыннан берсе була.

Аның үзен дә бик тиз күреп алалар. «Рәт чыга бу егеттән», диләр һәм ВЛКСМ район комитетына бүлек мөдире итеп куялар. Бу инде «Үрнәк яшьләр» колхозы гына түгел. Горизонт киң. Эшләр дә, мәшәкатьләр дә күп. Ләкин, теләге булган таш аудара, дигән шикелле, егетнең теләге дә була, «ташлар да авып тора». Шуннан соң аңа тагын әйтәләр: «Иптәш Хөсәенов, сезне ВЛКСМның райком секретаре итеп куйсак, ничек булыр икән?» — диләр. Егет, бүрегә һәм түгәрәк ак йөзле яшь һәм чибәр кәләше Сәрвәр белән киңәшә дә, үзенең ихтыярын һәм көчен чама бизмәненә салып карый да, мин риза, ди. Хәзер инде районның бөтен комсомол эшләре аның җилкәсенә төшә. Тик, бәхеткә каршы, егетнең җилкәсе киң һәм нык булып чыга. Ул олыларның ышанычларын аклый. Ә олылар — хәйләкәр. Районның гөрләп торган комсомол эшенә, комсомол секретареның үзенә текәп-сынап карыйлар да өченче мәртәбә сүз кушалар: «Иптәш Хөсәенов, сезне партиянең район комитеты пропагандисты итеп алырга ният бар иде, бу хакта ничек уйлыйсыз?» — диләр. «Партия кайда кушса, минем урыным шунда»,— ди егет.

Яңа пропагандист монда да сынатмый. Авыллардан кайтып керми. Йокы юк, ял юк. Муеннан эш. Коммунистларның политик белемнәрен күтәрү күп көч һәм зур теләк сорый. Тик ул курыкмый. Йөрәгең яңадан-яңага омтылып, яшьлек энергияң ташып торганда, авырлыклардан куркырмы егет башы!..

Менә 1941 елның июнь ае җитә. Авырлык бер ир-егет башына гына түгел, ил-егет башына төшә. Тыныч төзелеш чоры вакытлыча өзелеп тора. Халык коралга тотына.

Хөсәенов та августның 15 ендә фронтка чыгып китә. Смоленск өлкәсенең Ельня юнәлешендә төнлә белән алгы сызыкка барып төшә.

Хөсәенов — беренче ротаның политругы.

Икенче көнне таң белән немецлар, җиңел генә җиңү өмет итеп, һөҗүмгә ташлаңалар. Ләкин батальон егетләре — фин сугышында катнашып «чиркәнчек» ал...ы батырлар. Алар дошманны ут ташкыны яудырып каршы алалар һәм яралыларын, үлекләрен ташлап, алларына-артларына карамыйча качарга мәҗбүр итәләр. Ләкин әле дошманның, гомумән, көчле чагы, кара яу шикелле бере арты бере корыч дивизияләрен җибәреп торган вакыты. Батальонның хәле начарлана, ул чолганышта кала. 18 көн сугыша-сугыша дошман тылында йөргәннән соң гына исән калган 410 кеше Звенигород янында Можайск шоссесына килеп чыга. 400 дән артык арсландай егет, Ватаны һәм халкы өчен гомерен биреп, берәм-берәм егылып кала.

Исән калганнар иптәшләре өчен үч алырга ант итәләр һәм ул антларын намус белән үтиләр. Мәгъсүм Хөсәенов хезмәт иткән батальон Мәскәүне саклау өчен барган сугышларда катнаша, бөтен ачуын йөрәгенә җыеп, каһарманнарча сугыша, һәлак булган иптәшләреннән бик күп мәртәбә артык немецны теге дөньяга озата.

Батальон партбюросының җаваплы секретаре М. Хөсәенов 1942 елның 31 мартында аягы яраланганнан соң гына якын дусларыннан, фронтташ иптәшләреннән аерылып китәргә мәҗбүр була...

Беркөнне без аның белән шул еллар турында сөйләшеп утырдык.

— Беләсеңме, минем бер тапкыр разведкага да барганым булды бит,— диде ул.

— Политрук була торыпмы? Сез бит разведвзводта түгел!

— Теләге бар кешеләрне җибәрделәр. Мин дә теләк белдердем. 41 елның сентябрь, октябрь айларында иде шикелле. Ельня тирәләрендә. Ундүрт кеше киттек шулай. Ундүртебезгә бер автомат, башкаларыбызда винтовкалар. Ә ул автомат бөтен батальонга берәү генә иде. Шуны кызганмыйча безгә биреп җибәрделәр... Вак кына әрәмәлектә засадада ятабыз. Менә бер мәлне таң беленде. Томан тарала башлады. Карасак, бер төркем фриц, каз кебек тезелешеп, безнең яктан кайтып килә бит, агай. Алар да разведкадан. Бәлки, берәр этлек тә эшләргә өлгергәннәрдер, кем белгән. Яктырып беткәнче, үз якларына ычкынып калырга тырышалар болар. Кызу атлыйлар. Тик ычкындырмадык. Якынлашкач кына ут ачып җибәрдек. Дүртесе шунда ук егылып үлде, бер-икесе яраланды. Калганнарын сарык көтүен кугандай үзебезнең якка куып алып кайттык.

— Безнең солдатларны эләктерергә барган немец разведчикларының үзләрен эләктерүегез шәп булган, билгеле.

— Дөрес. Мәсьәләнең тагын икенче ягы да бар: дошманның бер чакта да җиңелми торган әллә нинди мифик сугыш чукмары булмыйча, бик шәпләп тукмарга да, үкчәсенә басып кыйный-кыйный куарга да, сарык көтүе шикелле әйдәп алып кайтырга да мөмкин булган гап-гади фашист икәнен халыкка күрсәтү, аңлату да әһәмиятле иде. Кешеләрдә җиңүгә ышаныч тудырырга кирәк. Аңын яктыртырга кирәк аның. Кушкан эшләми, аңлы кеше эшли...

Кешеләрнең аңын яктырту! Матур һәм эчтәлекле сүзләр. Укытучы, педагог кебек. Партия эшендә эшләүчеләргә дә, бигрәк тә секретарьларга бик кирәк мондый сәләт.

Ата — бер балага ата, укытучы йөз балага ата, ә район җитәкчеләре анда яшәүче барлык кешеләргә дә ата булырга тиеш. Аларның шатлыкларын да, кайгы-хәсрәтләрен дә вакытында күрә белергә һәм дөрес аңлап, нәтиҗә чыгарырга тиеш.

Партия җитәкчесе иң әүвәл Кеше булырга тиеш! Кешелекле кеше булырга тиеш! Без аларны нәкъ шулай булыр дип, шуны теләп һәм ышанып сайлап куябыз да бит.

Мәгъсүм Хөсәеновның Советлар Союзы Коммунистлар партиясе сафларына кабул ителүенә быел тәгәл утыз ел тулды. Ир гомере — ике утыз, диләр. Димәк, гомернең

яртысы партия идеяләре өчен, киләчәк өчен көрәшеп, алай гына да түгел, шул көрәшчеләрнең алгы сафларында үткән. Әйтергә кирәк, җитәкче урыннарда, кайда авыр — шунда.

Ул Чаллыга Кемерово госпиталеннән дәваланып чыкканнан соң, 1943 елның көз аенда кайта. Өч ел буе район комитетының кадрлар буенча секретаре булып эшли. 1946—1948 елларда КПССның Татарстан өлкә комитеты каршындагы республика партия мәктәбендә белемен күтәрә. Партия мәктәбен тәмамлаганнан соң, Чаллыны калдырырга туры килә. Чөнки аны Мөслим район Советы Башкарма Комитеты председателе итеп сайлыйлар. Аннан соң ул җиде ел буе КПССның Минзәлә райкомының беренче секретаре, ә 1957 елдан 1962 елга кадәр тагын үзенең таныш Мөслимендә партия район комитетының беренче секретаре булып эшли.

Менә 1962 ел җитә. Бу чорда Хөсәенов ике ел КПСС өлкә комитеты парторгы булып эшләп ала. Аннан Минзәлә колхоз-совхоз производство идарәсенең партком секретаре була. 1965 елның январенда, Минзәлә белән Актаныш аерылгач, янадан Минзәлә райкомының беренче секретаре булып сайлана һәм шушы урында бүгенге көнгә кадәр эшләп килә.

Минзәлә! Аның исемен әйтүгә, борылмалы Ык суы, чите яшел камышлы тәңкә-тәңкә күлләр, көр мал көтүләре утлап йөргән киң болыннар, таң җиле белән серләшеп, шаулап утыручы сандугачлы урманнар, ат дугасы кумелерлек булып каерылып иген уңа торган иркен басулар һәм шушы җирләрдә җырлап яшәүче эшчән кешеләр — шушы җирләрнең чын хуҗалары искә төшә.

Алар — иген үстерүчеләр. Илне туйдыручылар. Минзәлә районының колхозлары һәм совхозлары 1959 елда дәүләтебезгә 335,8 мең центнер ашлык сатканнар иде. Шуннан бирле бу санның төшкәне дә һәм бер урында торганы да юк. Ул 1963 елда 448,1 мең центнерга, 1967 елда 692,1 мең центнерга җитте. Ә инде узган елда Минзәлә районы дәүләткә 702,5 мең центнер икмәк сатып, моңа кадәр район тарафыннан күрелмәгән рекорд бирде.

Азмы бу, күпме?

Моны ачыклау өчен тарихка күз салыйк.

В. И. Ленин 1901 елның октябрь аенда «Эчке күзәтү» исемле хезмәтен яза. Ул шул ук елның декабрь аенда «Заря» журналының 2—3 саннарында Т. Х. имзасы белән басылып та чыга. Ленин «Эчке күзәтү» дә: «...Уфа губернасында Минзәлә һәм Бәләбәй өязләре уңыш начар булган өязләр дип игълан ителгәннәр, һәм Эчке эшләр министрлыгының земство бүлеге, «губернатор белдерүенә караганда» «тик азык-төлек өчен генә» хөкүмәттән 800 000 пот ссуда кирәк булачак, дип хәбәр итә. Хәлбуки, Уфа губернасының иген уңмаудан зарар күргән кешеләргә ярдәм күрсәтү мәсьәләсен тикшерү өчен 27 августта чакырылган гадәттән тыш земство җыелышы бу өязләрнең азык-төлеккә булган ихтыяҗын каплау өчен 2,2 миллион пот икмәк, плюс калган өязләргә 1 миллион пот ашлык кирәк дип белдерде, ә чәчү орлыгы өчен (губернага 3,2 миллион пот) һәм терлекләрне туйдыру өчен (600 000 пот) ссуда бу исәпкә керми. Димәк, министрлык азык ссудасын земство билгеләгәннең дүрттән бер өлеше кадәр генә билгеләгән»,— дип ачынып язган иде.

Әйе, элекке крестьянның тормышы ачынырлык булды. Үзе икмәк игеп, тамагы икмәккә туймады. Өсте ялангач иде. Кулаклар гына, авыл байлары гына бай торды. Аларның икмәге, бәрәңгесе булган, атлары, сыерлары, әйбәт бишмәтләре һәм бәйрәмнәрдә, сабан туйларында гына авылны шаккатырып, күзләрен яндырып киеп чыккан ялтыр галошлары булган. Боларның барысы да хәзерге колхозчының нарат сагызы исе аңкып торган биек якты бүлмәләре, шкаф-шкаф кием-салымнары, паласлары, челтәр пәрдәләре, җырлап торган радиоалгычлары, уйнап торган телевизорлары, өйләрен җылытып торган батареялары, краннардан чаптырып агып килгән салкын сулары, шырпы тертүгә гөлт итеп кабынып киткән зәңгәр газлары, бөтен җирне балкыткан электр лампочкалары, мал-туар тулган ишек алды, ак мунчалары, шифер түбәле келәтләре, велосипедлары, мотоцикл, машиналары, тальян, баяннары һәм башка байлык-муллыклары белән чагыштырырга мөмкинме соң? Болар барысы да башка кешеләрнең маңгай тиренә, ачы күз яше бәрабәренә килгән харам байлык түгел, моны совет кешесе үз кул көче белән, үзенең сирәк акылы белән эшләп бар иткән.

1901 елда Минзәлә һәм Бәләбәй өязләренә азык-төлек өчен хөкүмәттән 800 000 пот ашлык кирәк булган. Ә узган ел бер Минзәлә игенчеләре генә, үзләренә һәм мал-туарларына калдырганнан соң, җитәрлек чәчү орлыгы салганнан соң, артып калган 4 миллион 215 мең пот икмәкләрен дәүләткә саттылар.

Менә хәзер уйлап карагыз инде: азмы, күпме бу?

Күп! Бик күп!..

Моңа тагын узган ел дәүләткә сатылган 188,4 мең центнер сөтне, 49,2 мең центнер итне, 951 центнер йонны да китереп кушсак, күңелле генә саннар килеп чыга. Бу — ил һәм Ватан алдында Минзәлә эшчәннәренең йөзләре пакь дигән сүз...

Ләкин болар чик түгел.

Быелгы планнар бар бит әле. Алары ничек?

Бу сорау Хөсәеновны бик уйландыра, борчый.

— Алдагы планнар безнең зур,— диде ул, бер сөйләшеп утырган чакта.— Без быел гектардан уртача 20—21 центнер икмәк алырга тиешбез. Быел дәүләткә икмәк сатуның бишьеллык планын арттырып үтәргә һәм 5 еллык ахырына кадәр планнан тыш бер миллион центнер икмәк артык сатарга дигән ният бар.— Аннан көрсенеп өстәде:

— Бу, билгеле, безнең хыял.

— Елларның көйсез килүен дә хәтердән чыгарырга ярамый, Мәгъсүм абый.

— Менә шул шул. Кыш карга бик саран, ә салкыннарга юмарт булды. Ничәмә йөз гектар арыш уҗымы туңды, яз көне сөреп кире чәчәргә туры килде. Күпме орлык кирәк булды, күпме кеше һәм машина көче сарыф ителде. Табигать без дигәнчә генә килсә, бу артык чыгымнарның берсе дә кирәк булмый иде. Нишлисең, йөрәкне күчереп утырта торган заманнар килеп җитсә дә, табигать көчләрен йөгәнли, баш идертә алмыйбыз әле.

— Әйе, хәзергә әле үз көчеңә ышанырга туры килә.

— Әйе. Үзеңә, кешеләргә ышанырга. Җиңнәреңне сызганган килеш эшләргә, эшләргә һәм тагын бер кат эшләргә. Вакытны да, йокыны да кызганмаска.

Бу сүзләрнең чыннан да дөреслеген исбат итү өчен райком секретареның бер көнен генә күз алдыннан кичердек.

Иртә. Әле яктырып кына килә. Мәгъсүм Хөсәенов инде аяк өстендә. Кичә КПСС райкомының утырышлар залында колхоз председательләренең, совхоз директорларының, зоотехникларның, товарлыклы-сөтчелек һәм дуңгызчылык фермалары мөдирләренең район киңәшмәсе булды. Киңәшмәгә махсус Татарстан авыл хуҗалыгы министры урынбасары С. С. Нилов та килгән иде. Ул терлекчеләр алдында чыгыш ясады. Житешсез якларга да күз йоммады, тәнкыйть сүзләре дә әйтте. Шуңа күрә секретарьның кәефен бүген бик шәптән үк дип булмый. Ләкин нишлисең? Кәеф юк дип урында ятып булмый. Эш көтә. Эшләмәгән кешеләргә генә «эләкми» бу дөньяда...

Райкомда әле берәү дә юк. Хөсәенов менә шундый иртәләрне ярата да. Тыныч кына уйланырга, планнар корырга була. Берәү дә комачауламый. Ә инде эш сәгате башлангач — бетте, баш та калкытып булмый. Әле иртә, тыныч. Беренче секретарь телефоннан шалтыратып колхозларның, совхозларның хәлләрен белеп чыга. Председательләр һәм директорлар да «хуҗаның» гадәтен, тавык белән бергә уянуын беләләр. Иртә таңда идарә тирәсендәрәк булырга тырышалар. Кайбер чакларда райком секретареның күзләре ялтырап китә: «Рәхмәт, сөендердең, молодец, шулай кирәк»,— дип, мактап та ала. Сирәк-мирәк аның кашлары җыерыла, тавышы катылана. Эшен җиренә җиткереп эшләмәгәннәргә эләгә...

Шулай ярты сәгать үтә, бер сәгать. Менә ишекләр ачыла-ябыла башлый, коридорларда аяк тавышлары ишетелә. Райком эшкә керешә.

Беренче булып район Советы башкарма комитеты председателе Сөләйман Вильданов керә. Терлекчелек мәсьәләләрен тикшереп, хәл итеп кайту өчен ул авылларга китәргә җыена. Китәр алдыннан тагын бер киңәш-табыш итеп алырга дип кагылган.

Икенче кеше булып шәһәр Советы председателе Александр Дмитриевич Соловьев керә. Ул секретарьга балалар бакчасына куелачак карусель проектын күрсәтергә алып килгән. Мондый карусельләр башка район җирләрендә юк икән әле.

— Ни өчен шәһәрләрдә булырга тиеш тә, район балалары бу рәхәттән мәхрүм

калырга тиеш? — ди Хәсәенов һәм үз-үзенә җавап бирә:— Безнекеләр дә самолетларга утырып очсын, күңел ачсын.

Секретарь карусельнең эшләү техникасы белән кызыксына.

— Күпмегә төшәчәк инде бу? — дип сорый.

— Өч меңгә якын,— ди Соловьев.

— Балалар өчен, аларның шатлыктан елмайган йөзләрен күрер өчен артыгы да кызганыч түгел,— ди секретарь...

Билгеләнгән сәгатькә райком бюросы членнары һәм чакырылган кешеләр дә җыела. Көн тәртибендә өч мәсьәлә. Беренче — районның лаеклы хезмәт ияләрен КПСС членлыгына кандидатлыкка һәм КПСС членлыгына кабул итү, икенче — район төзелеш оешмаларының бүгенге эшләре һәм киләчәккә планнары, өченче — төрлеләр.

Һәр аңлы совет кешесе, Коммунистлар партиясе сафларына басып, коммунизмның бөек төзелешләренә коммунист булып катнашырга тели. Бу теләк соңгы вакытларда — юлбашчыбыз В. И. Ленинның тууына 100 ел, Татарстан АССРның төзелүенә 50 ел тулу юбилейларына якынлашкан көннәрдә — бигрәк тә көчәеп китте. Шуңа күрә бу бюрога да Коммунистлар партиясе сафларына кабул итүне сорап егерме бишләп кешенең килүе бик табигый. Узган елны, мәсәлән, Минзәлә районында КПСС членлыгына кандидатлар итеп 113 кеше кабул ителгән. Аларның утыз сигезе предприятие һәм промышленность эшчеләре, егерме җидесе хезмәткәрләр, калганнары колхозчылар: терлекчеләр, механизаторлар, кырчылар.

Менә шуларның берсе — сыер савучы Галина Мыльникова. Озын буйлы, ак йөзле, чибәр һәм мөлаем кыз. Бюро членнары алдында каушамыйча тыныч кына басып тора. Гаризасына ул: «Ленинның тууына йөз ел тулган көннәрне партиябез сафларында каршыларга телим»,— дип язган.

Галина, эшләве өстенә, зоотехникумның икенче курсында читтән торып укый икән. Хәзер имтиханнар вакыты. Дүрт имтихан тапшырган да инде. Ике «5»ле, ике «4»ле алган.

— Үзең яшь, чибәр, тавышың да бар шикелле. Үзешчән сәнгать смотрында катнаштыңмы соң? — дип сорый секретарь.

— Юк.

— Нишләп?

— Авылда без ике генә кыз. Түбән Кама ГЭСы салынгач, авыл су астында кала. Күчәләр.

— Егетләр дә юкмы?

— Ю-ук,— ди Галина, көрсенеп.— Армиягә китә торалар.

— Күңелсездер?

Галина яшерми:

— Күңелсез...

Тагын бераздан аны тәбриклиләр. Эшендә, укуында уңышлар телиләр. Кыз, рәхмәт әйтеп саубуллаша да, ишеккә барган җиреннән борылып:

— Мин хәзер бишенче имтиханымны тапшырырга киттем,— ди.

Галинаның күз карашында горурлык һәм куаныч чагыла.

Аңа бөтен бюро «5» ле тели. «Ни пуха, ни пера, үскәнем!» дип елмаеп озата.

Мыльникова артыннан ишек ябылгач, җитәкчеләрнең йөзләре уйчанланып китә. Ялкынланып яшәр чагында чибәр кыз авызыннан чыккан «күңелсез» дигән сүзне ишетү бераү өчен дә күңелле түгел. Авылларында клуб салыр идең — озакламый күчә. Авылны һәм Галина эшли торган фермаларны икенче авылга күчерер идең — хәзер генә, бүген генә барысын да булдырып булмый, кулда Әбугалисина тылсымы юк, вакыт кирәк...

Ә Минзәлә җирендә ГЭС белән бәйләнгән мәшәкатьләр шактый. Ничәмә-ничә авыл яңа урыннарга күчеп утырачак. Нихәтле хуҗалык корылмаларын сүтеп яңа урыннарда торгызырга туры киләчәк. Бу эшләр башланган да инде. Партия һәм хөкүмәт күчүчеләргә зур ярдәм күрсәтә. Акча бирә, бүрәнә һәм бүтән төзелеш материаллары белән тәэмин итә. Кадагына, сүсенә, мүгенә кадәр китерә. Тик башланган гына шул әле, очына чыгасы бар. Аннан башка да кырык җирдә кырык төрле эш. Һәрберсе игътибарны, вакытны сорый.

Райком бюросы членнары, менә шуларны уйлап, икенче кеше кергәнче бераз

тын тордылар. Нишлисең, билгеләнгәнсең икән, син башкарырга тиешсең икән — кыен дип торырга ярамый, тырышырга кирәк.

Менә өстәл башында терлек симертү совхозының тракторчысы Мәрданов Галимәрдән басып тора. Аңа партия, устав, хәзерге халыкара хәлләр турында сораулар бирелә. Механизатор тәпле, белемле күренә. Менә тагын бер сорау:

— Иптәшегез кем булып эшли?

— Хатыным Галия дә тракторчы. Бер тракторда эшлибез.

Галимәрдән белән Галияне трактор кавыштырган икән, «яучы» шул булган. Алар — яшь егет һәм яшь кыз — 1952 елны бер үк тракторда эшли башлаганнар. Шунда яратышканнар, өйләнешкәннәр, хәзер дә бер тракторда эшлиләр. Җәй көне кырлардан кайтып кермиләр, кыш җитсә, фермага кайтып, икесе дә дуңгызлар карый.

Бюро членнарының сүзләре бер: механизатор Галимәрдән Мәрдановны КПСС членлыгына кандидатлыкка кабул итәргә!

Ул чыгып киткәч, Хөсәенов, сыңар колаклы күзлеген кулында әйләндергәләп утырды да, районның «Коммунизм таңы» газетасы редакторы урынбасары Фәрит Хәбибуллинга дәште:

— Менә шундый кешеләр турында күбрәк языгыз әле газетага, ә?

Әйе, мактап газетага язарлык кешеләр күп Минзәлә районында. Ирле-хатынлы Госманов һәм Госманова турында ник язмаска? Аларның бүген һич онытылмаслык, гомер буйларына сагынып һәм горурланып сөйләрлек шатлыклы көннәре: икесе дә бергә, бер сәгатьтә Коммунистлар партиясенә член булып кабул ителделәр.

Бүген тагын күпләр өчен дә бәйрәм көн булды. Төзүчеләр бригадиры Никитин, шофер В. Кириллов, укытучы Шарыгина, механизатор Сайманов, кассир Сафина, зоотехник Идрисов, башка иптәшләре белән бергә, партия сафларына кабул ителделәр.

Беренче секретарь аларның һәрберсен бу уңай белән чын күңеленнән котлады, уңышлар теләде, һәркемгә җылы, ягымлы сүзләр тапты.

Икенче көн тәртибенә күчкәндә бүлмә тутырып төзүчеләр килде. Күп идә алар. Хәзер безнең илдә иң мактаулы һәм хөрмәтле профессияләрнең берсе — әлбәттә, төзүче һөнәре. Төзүче эше бездә елдан-ел арта, киңәя. Илебез — тоташ төзелеш мәйданы. Минзәлә дә ашыга-ашыга төзелә. Элек ярминкә вакытларында гына бер киерелеп, шаулап-гөрләп ала торган, сәүдәгәрләрнең берничә таш өе һәм таш «лафка»лары гына булган, вак сатучылар, йокымсырап гомер сөргән мещаннар шәһәре хәзер көн-төн гөрләп тора. Төзелеш гөрелтесе, яңа тормыш, яңача яшәү гөрелтесе белән Минзәләнең Ыкка һәм Камага китә торган ягында икешәр катлы таш өйләрдән яңа нефтьчеләр шәһәре калкып чыкты. Ул болын ягына таба үсә, колачын җәя бара. Шәһәр уртасында — элек чаптар атлар юырттыра торган мәйданда — рәт-рәт булып сулы, газлы йортлар салына. Культура йортлары, магазиннар, ашханәләр, мәктәпләр, тораклар салына, бакчалар, парклар бизәлә, урамнарга асфальт җәелә, яңа фонарьлар куела.

Кыскасы, төзелеш һәм төзүчеләр Минзәләдә почетта. Шуңа күрә, киләчәк планнар турында сөйләшү өчен, бүген райкомга чакырылганнар да инде алар.

Сөйләшү озак барды. Конкрет һәм кискен төстә барды. Кызганычка каршы, һәркайда, һәркемнең авырткан җире ике генә — төзелешкә эшче көчләрнең һәм төзелеш материалларының (Минзәләдә конкрет — кирпеч) җитенкерәмәве. Бюрода бу мәсьәлә нәтиҗәле хәл ителде, конкрет карар чыкты...

Иртәгесен Хөсәенов Чаллы юлы буйлап авылларга китеп барды.

Ул беренче булып туктаган Коноваловка председателе Кадыйров, үзенең пәһлеван гәүдәсенә дә карамастан, гаять җитез кеше. Үз-үзен тотышында, хәрәкәтендә генә түгел, башлыча, эшендә җитез ул. Коноваловкада, Белопахатныйда һәм бүтән бригадаларда дуңгыз, сыер фермалары, бөтенләе белән машинага көйләнгән сыерлар фермасы да, дуңгызлар фермасы да чиста һәм җылы. Абзарлар әле шушы елларда гына салынганнар. Фермалар янында тагын яңалары төзелеп ята.

Җае чыкканда әйтергә кирәк: райком секретаре үзе дә җитезлек сорап күршеләргә керә торган түгел. Юлны, сукмакны карамый, яшь егетләрчә элдерә генә...

Мәгъсүм Хөсәеновны райондашлары, ул үз районының чын патриоты, ул үз җирен чын күңеле белән ярата, диләр. Хак сүзләр. Һәм тагын шунысын әйтергә кирәк: райком секретаре бу изге хисләрне бүтәннәр күңелендә дә көчәйтергә тырыша.

Бу турыда, минзәләлеләрнең патриотик хисләре турында сүз чыккач, ул болай диде:

— Мин туган ягыбызны, аның табигатен яратам. Табигатьне яратмаган кеше минем дошман. Туган җиреңне, туган җир табигатен ярату — туган илеңне ярату бит ул. Үз җиреңне белән горурлану кирәк. Үз хезмәтең, һөнәрең белән горурлану кирәк. Шунсыз хезмәтеңнең нәтиҗәсе өчен кайгырту булмаячак. Ә минзәләлеләр, әйтергә кирәк, хезмәтләренең нәтиҗәсе белән кызыксынмыйлар түгел...

Әйе, үз җирен яратып, аның көннән-көн матураюы, баюы өчен, муллыкка күмелүе һәм чәчәк атуы өчен җаннарын аямыйча эшләүчеләр Минзәлә районында бик күпләр. Минзәлә халкы алар белән хаклы рәвештә горурлана.

Бораулау мастеры Фәсхетдин Шәрәфетдинов, Хөсәенов шикелле үк, күкрәгенә Алтын Йолдыз медале тагып йөри. «Марс» колхозы председателе Нәҗип Галимәрдәновны, Куйбышев исемендәге колхоз председателе Галимҗан Газизовны, «Дружба» колхозы бакчачысы Василий Петровны, пенсионер Әхмәтмөдәррис Вәлиәхметовны, «Победа» колхозы тракторчысы Мирзахмәт Нуриәхмәтовны, «Урожайный» совхозының сыер савучысы Мария Холкинаны һәм башка иптәшләрне Ватаныбыз Ленин орденнары белән бүләкләде. Болардан кала, минзәләлеләрнең тагын җитмешләп кешесе Хезмәт Кызыл Байрагы, «Почет билгесе» һ. б. орден, медальләргә лаек булдылар.

Тормыш юлы чәчәкле бохар паласы җәелгән йомшак юл түгел. Тормышның ачысын да, төчесен дә татырга туры килгән чаклар булгалый. Авыз гел шатлыктан ерылып тормый, борчылып кысыла да белә. Минзәләлеләрнең дә борчылган чаклары булды быел. Бигрәк тә терлекчеләр борчылды, алар белән бергә район җитәкчеләре борчылды, райкомның беренче секретаре Мәгъсүм Хөсәенов борчылды. Район хезмәт ияләре җилкәсенә төшкән кырык эшнең кырыгы әйбәт барса да, кырык беренчесе узган елда аксый башлады. Терлекчелеккә игътибарның җитенкерәмәве сизелде. Узган елны 100 сыердан 88 генә бозау, «Урожайный» совхозында, «Кама» һәм «Гигант» колхозларында һәр төп ана дуңгыздан сигезәр-тугызар гына бала алынды. «Искра» һәм Тукай исемендәге колхозларда бик бәләкәй — 230—240 килограммлы гына сыерлар сава башладылар. Төрле сәбәпләр аркасында районда сөт кимеде. Узган елны район буенча һәр сыердан уртача 2.458 килограмм гына сөт савып алынды. Бу — республиканың уртача саныннан 146 килограммга кимрәк булды.

Мәсьәлә Татарстан АССР Министрлар Советында каралды. КПССның Минзәлә райкомында колхоз председательләренең, совхоз директорларының, зоотехникларның, товарлыклы-сөтчелек һәм дуңгыз фермасы мөдирләренең район киңәшмәсе җыелды. Зур сөйләшү, киңәш-табыш булды. Татарстан авыл хуҗалыгы министры урынбасары иптәш Нилов, чыгыш ясап, Минзәлә терлекчеләренең эшенә анализ ясады. Райком секретаре Хөсәенов терлекчелекне фәнни нигезләрдә оештыру өчен алдынгылар тәҗрибәсен өйрәнүне киң җәелдерергә, җитәкчеләрнең һәм белгечләрнең ролен күтәрергә, ферма хезмәткәрләренең хезмәт дисциплинасын ныгытырга чакырды, район коммунистларының терлекчелектәге хәлне тиз көндә төзәтәчәкләренә һәм данлы юбилейларны зур хезмәт җиңүләре белән каршы алачакларына тирән ышаныч белдерде.

Хәзер инде җәйнең соңгы ае керде. Шуннан соң үткән көннәр һәм айлар Минзәлә терлекчеләренең сүзе коры сүз генә булып калмаганлыгын исбат итте. Алар вәгъдәләрен үтиләр. Терлекчелектәге эшләр дә күңелле нәтиҗәләр бирә.

Чөгендернең һәр гектарыннан — 180 центнер, бәрәңгедән — 130, кукуруздан — 250 центнер уңыш алырга. 60.000 центнер ит, 200.000 центнер сөт тапшырырга. Менә Минзәлә хезмәт ияләренең быелгы планнары.

Минзәләдә йөргән көннәрнең берендә без Мәгъсүм абый Хөсәенов белән сөйләшеп утырдык. Аның эш урынында түгел, өендә, табын янында. Мин аны кырда, эш өстәле янында, киңәшмәләрдә күргәнем бар иде. Ә өйдә бик шаян, әңгәмәне сүрелдермичә оста алып бара торган йорт җанлы кунакчыл хуҗага әйләнде дә куйды Мәгъсүм абый. Дөрес, аңа вакыт-вакыт өстәл яныннан торырга, телефон чакыруларына җавап бирергә, кайчакларда җитди генә сөйләшүләр алып барырга, төрле мәсьәләләрне хәл итәргә дә туры килде.

— Райком секретареның шул инде аның,— диде ул,— көне юк, төне юк.

Сүз Минзәлә шәһәренә, районнардагы төзелешләргә күчте. Хәзер «Ярыш», «Алга»

колхозларында, Ямашев исемендәге совхозда, совхоз-техникумда Культура сарайлары төзелә. Куйбышев исемендәге колхозда 500 урынлы, Минзәләдә 650 урынлы мәктәпләр салына. Болар өстенә, шәһәрдә тагын 600 урынлы Культура сарае салынып ята. Ул В. И. Ленин исемен йөртәчәк. Болар — культура төзелешләре генә. Ә фермалар, торак йортлар һәм башкалар санап бетергесез. Алар һәркайда, һәр авылда.

— Төзелеш материаллары гына җитсен,— дидем мин, райком бюросында барган сүзләрне искә төшереп.

— Әйе,— диде секретарь.— Безнең тез астына шул суга — кирпеч! Тагын бер мәртәбә кирпеч!..

Дөрес, 1970 елда Чаллыдамы, Түбән Кама районындамы елына йөз миллион кирпеч чыгара торган завод салына икән. Ул чагында кирпеч проблемасы бераз җиңеләячәк. Тик аңа кадәр шактый вакыт бар шул әле. Аннан соң ярый ла ул вакытында төзелеп бетсә...

Секретарь кайчандыр үзе белән бергә эшләгән иптәшләрен сагынып утырды.

— Кешеләр үсә,— диде ул, дуслары өчен шатланып. Чыннан да М. М. Рәпеев 50—54 елларда аның белән бергә эшләгән, Минзәлә райкомының икенче секретаре булган. Хәзер республиканың партконтролендә эшли. Һидият Хәмидуллин 53—57 елларда Минзәлә райисполкомының председатель урынбасары булган, ә хәзер ул республика прокуроры. Тимер Шәймиев — Минзәләнең элекке авыл хуҗалыгы техникасы берләшмәсе председателе — хәзер КПСС өлкә комитетында авыл хуҗалыгы бүлеге мөдиренең урынбасары...

Күп алар, күп — дуслар, иптәшләр! Әйе, дуслар, гади танышлар гына түгел, чын дуслар. Бергә эшләгән, бергә көрәшкән, җиңү шатлыгын да, хезмәт борчуларын да бергә кичергән дуслар.

Мәгъсүм Хөсәенов моның шулай булуына бигрәк тә Социалистик Хезмәт Герое исеме бирелгән көннәрдә нык ышанды. Ул кадерле Указ 1966 елның 22 мартында игълан ителде. Шул ук көнне Хөсәеновлар өенә хатлар, котлаулар, телеграммалар ява башлады. Ишек бер дә ябылып тормады. Кайлардан гына, кемнәрдән генә юк иде ул кайнар котлаулар! Өйгә дә агылдылар алар, райкомга да.

Мәгъсүм абыйның тормыш иптәше Сәрвәр ханым аларны миңа алып күрсәтте. 150 телеграмма, хат. Яшьлек иптәшләреннән, дусларыннан, колхозлардан, совхозлардан, белгән һәм белмәгән кешеләрдән. Менә художник Кондрат Максимов телеграммасы, республика мәгариф министры Мәхмүтовныкы, профессор Дорофееваныкы, Татсоюз председателе Артемьевтан һәм башкалардан, һәм башкалардан. Казаннан, Әлмәттән, Чаллыдан, Мәскәүдән, Актаныштан, Арчадан һәм башка җирләрдән...

Шундагы хисләрен Мәгъсүм абый, бер генә сүз белән әйтеп бирде:

— Еладым,— диде. Аннан соң өстәде.— Телеграммаларны, хатларны кочакладым да еладым...

Карагыз әле: безнең, «тимер ихтыярлы, корыч йөрәкле, утта янмас, суда батмас, беркайда да аптырап калмас, беркайчан да еламас»,— дип язарга һәм уйларга гадәтләнелгән райком секретаре кадәр райком секретаребыз елап утыра лабаса, җитмәсә, моны үзе дә яшерми кычкырып әйтеп тора!

Гап-гади кеше шикелле, безнең шикелле!

Хәзер инде укучыларга әйтим: мин, беренчедән, райком секретарен, икенчедән, Кешене эзләп барган идем Минзәләгә. Мин аларның икесен дә таптым. Мәгъсүм абый Хөсәенов — Кеше. Аның Алтын Йолдызы астында гади кешеләрне аңлаучы гап-гади йөрәге тибә...

Еракта-еракта, Кама таулары өстендә сызылып кына җәйге таң ата. Төн кунарга туктаган болытларның алсу итәкләрен балкытып һавага беренче якты нурлар сузыла. Җир күзләрен ачып яңа көнне сәламли. Табигать уяна. Кошлар гадәттәге җырын җырлый башлыйлар, елга-күл өсләреннән җиңелчә пар күтәрелә, яшел болыннарда җем-җем итеп чык бөртекләре уйный.

Райкомның беренче секретаре Мәгъсүм Хөсәенов кабинетына килеп керә дә тәрәзәләрне ачып җибәрә. Тәрәзәдән яңа өлгергән алмаларның хуш исе, чәчәкләр исе бөркелеп керә. Секретарь чәчәкләр һәм алма исен күкрәгенә тутырып бер сулый да өстәл янына килеп кулына телефон трубкасын ала:

— Гаражмы бу? Машина китерегез, авылларга чыгарга кирәк.

# ДАНЛЫ ЮЛ

Китап — белем һәм яктылык чыганагы, халыкның кадерле байлыгы һәм горурлыгы, ул халыкка коммунизм өчен көрәштә куәтле корал булып хезмәт итә. Совет кешеләре китапны яраталар, аңа акыллы киңәшче һәм дус итеп карыйлар. Менә шуңа күрә дә безнең илдә әдәбият күп чыгарыла һәм зур тиражлар белән таратыла, һәр әһәмиятле китапның дөньяга тууы хуплап каршылана.

Кибетләрдә, китапханәләрдә, уку йортларында һәм гыйльми учреждениеләрдә тупланган әдәбият дөньясында Татарстан китап нәшрияты чыгарган әсәрләрне дә күп очратырга мөмкин. Бу нәшрият озак еллар буена күп төрле әдәбият чыгарып килә, татар мәктәпләрен дәреслекләр белән тәэмин итеп зур эш башкара.

Безнең нәшрият моннан илле ел элек, Идел һәм Кама буйларында гражданнар сугышы барган авыр көннәрдә дөньяга туа. 1919 елның 22 июлендә партиянең Казан губерна комитеты Президиумы карары белән РСФСР Дәүләт нәшриятының Казан бүлеге оештырыла. ТАССР төзелгәч, 1921 елның декабреннан бу бүлек Татарстан Дәүләт нәшрияты дип атап йөртелә башлый. Шул рәвешчә, 1919 елның 22 июле Татарстан китап нәшрияты оештырылган көн булып исәпләнә.

Яңа нәшрият партия Өлкә комитеты җитәкчелегендә актив идеологик эшчәнлек җәеп җибәрә, марксизм-ленинизм идеяләрен таратуга, хезмәт ияләрен хуҗалыкны аякка бастыруга, социалистик төзелешкә туплауга, халыклар арасында туганнарча дуслык, совет патриотизмы һәм интернационализм хисләре тәрбияләүгә юнәлдерелгән китаплар чыгара башлый. Үткән 50 ел эчендә фәнни коммунизмга нигез салучы К. Маркс, Ф. Энгельс һәм В. И. Ленин әсәрләре генә дә 250 исемдә 3 миллион экземплярдан күбрәк тираж белән чыгарылды. Хәзерге вакытта В. И. Ленин әсәрләренең 45 томлыгы татар теленә тәрҗемә ителеп чыгару тәмамланып килә.

Татарстан китап нәшрияты баштан ук киң профильле нәшрият итеп оештырыла, ул политик һәм авыл хуҗалыгы әдәбияты да, фәнни-техник, укыту-педагогик һәм матур әдәбият һәм яшьләр-балалар әдәбияты да чыгара. Хәзерге вакытта ул РСФСР да зур нәшриятның берсеннән санала һәм ел саен 400 исемдә барлыгы 6,3 миллион экземплярдан күбрәк китап чыгара һәм аның продукциясе бөтен Советлар Союзына диярлек таратыла. Илле ел дәвамында нәшрият 25 мең исемдә барлыгы 260 миллион данә китап басып таратты.

Үзенең беренче көннәреннән үк нәшрият матур әдәбият чыгаруга зур игътибар итә, татар классик язучылары Г. Тукай, Г. Камал, Ф. Әмирхан, Ш. Камал әсәрләрен чыгара. Г. Ибраһимовның «Кызыл чәчәкләр» һәм «Алмачуар», «Тирән тамырлар» исемле әсәрләре, М. Гафуриның «Эшче» поэмасы һәм татар совет әдәбиятының алтын фондына кергән күп кенә башка әсәрләр беренче мәртәбә шунда басыла. Нәшрият шул елларда әдәбият мәйданында актив эшләүче Һ. Такташ, Ф. Бурнаш, К. Нәҗми, Ш. Усманов, М. Җәлил, А. Шамов, Н. Исәнбәт һәм башка талантларның гражданнар сугышы героикасын гәүдәләндергән, азат хезмәт һәм яңа тормыш төзү пафосы белән сугарылган повесть һәм хикәяләрен, пьеса һәм шигырь китапларын басып тарата.

Утызынчы елларда, илдә культура революциясе киң колач җәйгән вакытта, нәшриятның эше (ул чакта директоры Самат Шәрәфетдинов) аеруча киң колач ала: Казан шәһәре үзәгендә мәһабәт биналардан берсе — Матбугат йорты төзелә, хәзерге заман машиналары белән җиһазландырылган куәтле полиграфия базасы булдырыла һәм халыкның рухи ихтыяҗын тулырак канәгатьләндерергә, китапларны тагын да күбрәк һәм матуррак итеп чыгарырга мөмкинлекләр ачыла. Нәшрият эшенә яңа иҗат көчләре тартыла, А. Шамов, Г. Гали, Ф. Кәрим, И. Гази, С. Хәким, Н. Баян, А. Алиш, К. Басыйров, Х. Хәйри кебек язучы һәм тәнкыйтьчеләрнең редактор булып эшләве чыгарган әдәбиятның идея-художество дәрәҗәсен югары күтәрергә мөмкинлек бирә. Нәшрият бу елларда республиканың культура тормышында зур вакыйга булган һәм җәмәгатьчелек тарафыннан җылы кабул ителгән күп кенә китаплар чыгара. Алар арасында Г. Ибраһимовның сайланма әсәрләренең 5 томлыгын, Һ. Такташның «Киләчәккә хатлар» поэмасын, М. Җәлилнең «Шигырьләр һәм поэмалар» җыентыгын, Г. Кутуйның «Тапшырылмаган хатлар», Г. Бәшировның «Сиваш» повестьларын, К. Тинчурин, А. Алиш, М. Әмир, Х. Туфан, И. Гази, Ф. Хөсни, Г. Гобәй, Г. Минский һәм башка бик күп авторларның әсәрләрен күрсәтергә мөмкин. Болар бар да элек патша самодержавиесе чорында гасырлар буена рәхимсез җәберләнгән татар халкының совет чорында Коммунистлар партиясенең ленинчыл милли политикасын тормышка ашыру нәтиҗәсендә күп алга китүен, эчтәлеге белән социалистик, формасы белән милли әдәбияты һәм сәнгатенең чын мәгънәсендә чәчәк атуын исбат итә торган гүзәл күренеш булып торалар.

Бөек Ватан сугышы башлангач, бөтен совет халкы туган илнең бәйсезлеге һәм азатлыгы өчен изге көрәшкә күтәрелгән көннәрдә, нәшриятның күп работниклары — директоры Ш. Арсланов, сектор мөдирләре К. Шәйхетдинов, Т. Әхмәдиев, редакторлардан Ф. Кәрим, К. Басыйров, Н. Баян, И. Гази, А. Шамов һәм башкалар фронтка киттеләр, каләмнәрен автоматка алмаштырып, алгы сызыкта сугыштылар, фронт газеталарында актив катнашып, үзләренең әсәрләре белән совет сугышчыларын җиңүгә канатландырдылар. Ул иптәшләрнең байтагы кире әйләнеп кайтмады, сөекле Ватаныбызның азатлыгы өчен барган авыр сугыш кырларында һәлак булып калды.

Сугыш елларында, шартлар кыенлашуга карамастан, барлык совет халкы кебек, нәшрият коллективы да җиңү өчен бөтен тырышлыгын биреп эшләде, халкыбызның фронтта һәм тылда күрсәткән тиңдәшсез батырлыгын чагылдырган, аларны изге көрәшкә рухландырган яңа әсәрләр басып таратты. Татарстан улларыннан Советлар Союзы Герое исеме алган сугышчылар турында очерклар җыентыгы — «Батырлар китабы» (төзүчесе К. Нәҗми), Икенче Украина фронты сугышчыларына багышланган җыентык, «Татар халкының фронтовик татарларга сәлам хаты» кебек махсус китаплар чыгарылды. К. Нәҗминең «Фәридә» исемле драматик поэмасы, Н. Арслановның «Рус кызы», Ә. Исхакның «Танкист Петр Новиков турында җыр» поэмалары, Р. Ишморатның «Кайту», М. Әмирнең «Миңлекамал» драмалары киң катлау укучыларның һәм тамашачыларның яраткан әсәрләре булып танылдылар; Ф. Кәрим, Г. Кутуй, Ш. Маннур, Г. Хуҗи, Г. Әпсәләмов, Ш. Мөдәррис, М. Садри, Г. Иделлә, А. Әхмәт һәм башкаларның сугыш кырларында язган хикәя һәм очерклары, шигырьләре һәм публицистик мәкаләләреннән батыр көрәш елларының кайнар сулышы бөркеп тора.

Совет халкының немец фашистларына каршы героик сугышы бөек җиңү белән тәмамланганнан соң, сугышта зарарланган өлкәләрне тергезү, экономиканы үстерү өчен гаять зур эшләр башланды. Язучылар, Ватан сугышы темасын дәвам иттерү белән бергә, үзләренең әсәрләрендә энә шул гигант эшләрне, сугышта җиңеп кайткан совет солдатларының хуҗалык төзелешендәге батырлыгын гәүдәләндерә башладылар. Партия Үзәк Комитетының әдәбият-сәнгать турындагы тарихи карарлары белән коралланган язучылар яңа иҗади уңышларга ирештеләр, әдәбият мәйданына яшь иҗат көчләре килде.

Әнә шундый гомуми үсеш фондында Татарстан китап нәшриятының эшчәнлеге тагын да киң колач алды. 1946 елның мартында Татарстан Халык Комиссарлары Советы кабул иткән карар нигезендә нәшриятның яшьләр-балалар әдәбияты, авыл хуҗалыгы, сукырлар әдәбияты редакцияләре һәм сүзлекләр группасы яңадан оештырылып эшли башлады. (Хәзерге вакытта ул Политик-тарихи әдәбият, Фәнни-техник, Авыл хуҗалыгы, Матур әдәбият, Яшьләр-балалар әдәбияты, Укыту-педагогик һәм сукырлар әдәбияты редакцияләреннән һәм график оформление бюросыннан тора.) Нәшрият чыгарган китапларның идея-художество дәрәҗәсе күтәрелде, саны һәм тиражы артты. Бу чорда нәшрият басып чыгарган китаплардан «Язгы җилләр» (К. Нәҗми), «Намус» (Г. Бәширов), «Тукай» (Ә. Фәйзи), «Онытылмас еллар» (И. Гази), «Алтын йолдыз» (Г. Әпсәләмов), «Җәяүле кеше сукмагы» (Ф. Хөсни), «Ялантау кешеләре» (М. Әмир), «Саз чәчәге» (Ә. Еники), «Тукай турында поэмалар» (С. Хәким), «Гайҗан бабай» (Ш. Маннур), «Олы юл буйлап» (С. Баттал) поэмалары, романнары һәм повестьлары татар совет әдәбиятының яңа үсешен чагылдырган әсәрләр булып танылдылар. Герой шагыйрь М. Җәлилнең фашист төрмәсе стеналары аша үтеп еракלардан туган илгә кайткан ялкынлы шигырьләр җыентыгы «Моабит дәфтәрләре»нең басылып чыгуын бөтен совет халкы тирән канәгатьләнү белән каршылады.

Шәхес культы чорында озак вакытлар хаксызга онытылган әдипләрнең әсәрләре бу елларда халыкка җиткерелүен аеруча күрсәтеп үтәргә кирәк. Бу чорда татар совет әдәбиятын үстерү юлында зур тырышлык күрсәткән атаклы язучылардан Г. Ибраһимов, К. Тинчурин, Ф. Бурнаш, Х. Туфан, Г. Гали, Г. Нигъмәти, М. Галәү, Г. Толымбай, Ф. Сәйфи-Казанлы, Ш. Усманов, Л. Гыйльми һәм башкаларның әсәрләрен басып тарату татар совет әдәбиятына гаять зур хәзинә булып өстәлде.

1957 елның маенда Ватаныбызның башкаласы Мәскәүдә татар әдәбияты һәм сәнгате декадасы үткәрелде. Декадага әзерлек көннәрендә нәшрият халкыбызның бай культура тарихын һәм Совет чорындагы үсешен чагылдырган бик күп китаплар чыгарды. Иҗат союзлары һәм гыйльми учреждениеләр белән берлектә поэзиябезнең мең ел эчендә тудырган гәүһәрләрен җыеп «Татар поэзиясе антологиясе» татар һәм рус телләрендә, республикабызның язучылары, композиторлары, художниклары турында биографик һәм библиографик белешмәләр, монографияләр, бик күп язучыларның һәм композиторларның сайланмалары һәм яңа әсәрләре басылды. Декада зур уңыш белән үтте һәм тугандаш халыклар семьясында татар совет әдәбияты һәм сәнгатенең уңышлы үсүен һәм чәчәк атуын күрсәтүче вакыйга булды.

Бу чорда татар әдәбиятында Ватан сугышы фронтларыннан кайткан иҗат көчләреннән А. Расих, З. Нури, Х. Вахит, Ә. Давыдов, Ә. Маликов, М. Ногман, Х. Камалов, Р. Тәхфәтуллин, колхоз кырларыннан һәм заводлардан, уку йортларыннан килгән яшь талантлар Л. Ихсанова, Г. Ахунов, Н. Фәттах, Ш. Галиев, Г. Афзал, И. Юзиев, З. Мәҗитов һәм башкаларның әсәрләре нәшрият чыгарган китаплар арасында зур урын били.

Шул ук вакытта нәшрият балалар һәм яшьләрне коммунизм рухында тәрбияләүгә юнәлдерелгән, туган илебезнең героик тарихын, Коммунистлар партиясенең көрәш юлын, халкыбызның хезмәт батырлыгын ча-

гылдырган әсәрләрне дә елдан-ел күбрәк басып чыгара. Шундый әсәрләрдән А. Расихның «Ямашев», Г. Ахуновның «Канатлар кая илтә», В. Исхаковның «Кунгур малае» һәм башкаларны күрсәтергә мөмкин.

Республикада культура төзелеше киң фронт белән барган, язучыларның иҗат осталыгы һәм активлыгы өзлексез үскән чорда нәшрият җитәкчелеге (директоры Г. Камалиев, баш редакторы Х. Гобәйдуллин) әдәбият чыгаруны тагын да активлаштыруга юнәлдерелгән мөһим чаралар күрде. Нәшриятның иҗади җитлеккән редактор кадрлары тәрбияләп үстерелде, иҗади оешмалар, фәнни учреждениеләр, типографияләр белән эшлекле контакт булдырылды, авторлар белән эшләү яхшыртылды һәм шуның нәтиҗәсендә китап чыгаруның еллык планнарын тулысынча үтәүгә ирешелде, нәшриятның материаль базасы ныгытылды.

Барыннан элек, китап чыгаруны планлаштыру яхшыртылды, иҗат союзлары һәм гыйльми учреждениеләр белән берлектә перспектив планнар төзү практикага кертелде. Аларны тормышка ашыру йөзеннән соңгы елларда күренекле каләм осталары Н. Исәнбәт, Г. Бәширов, М. Әмир, Ф. Хөсни, Г. Әпсәләмов, И. Гази, Р. Ишморат, Ә. Еники, Г. Гобәй, Н. Дәүли һәм башкаларның күп томлык сайланма әсәрләре чыкты яки типографиядә басылып ята.

Бу эш киләчәктә дә дәвам иттереләчәк. Хәзерге вакытта, мәсәлән, Г. Ибраһимов әсәрләренең ун томлыгын һәм борынгы татар әдәбияты әсәрләрен чыгарырга әзерлек эшләре бара.

Китап нәшрияты СССР халыклары һәм дөнья әдәбиятының иң яхшы әсәрләрен даими рәвештә татар телендә чыгарып килә. Татар хезмәт ияләре дөнья әдәбияты классикларыннан А. С. Пушкин, Л. Толстой, И. Тургенев, А. Некрасов, М. Горький, В. Маяковский, В. Гюго, Р. Роллан, А. Фадеев һәм башка атаклы әдипләрнең гүзәл әсәрләрен туган телләрендә укыйлар. Быелгы тематик план буенча бөек француз классигы О. Бальзакның бер томлыгы, рус әдәбияты классигы А. Купринның повесть һәм хикәяләр китабы чыгачак.

Шул ук вакытта нәшрият татар язучыларының күренекле әсәрләрен рус теленә тәрҗемә итеп чыгарып килә. Соңгы берничә ел эчендә генә Г. Ибраһимовның «Безнең көннәр», И. Газиның «Онытылмас еллар», Г. Әпсәләмовның «Сүнмәс утлар», Н. Дәүлинең «Җимерелгән бастион» исемле повесть һәм романнары, Ә. Исхак, С. Хәким, З. Нури, Ә. Давыдов, М. Садриның шигырь китаплары рус телендә басылып, Союз күләмендә таратылдылар һәм әдәбият укучылар тарафыннан җылы кабул ителделәр.

Соңгы елларда нәшрият үзенең эшендә китапларны сериялап чыгару практикасын киң куллана башлады. «Шагыйрь китапханәсе» сериясеннән Г. Тукай, С. Хәким җыентыклары дөньяга чыкты инде. Ф. Кәрим, М. Җәлил китаплары типографиядә басылып ята, киләсе елда чыгарырга Х. Туфан китабы әзерләнә. Быелдан башлап бу серияне рус телендә дә басарга керешелде, аның беренче карлыгачы булып бөек Тукай китабы чыгарылачак.

Болардан тыш, тугандаш халыклар поэзиясе үрнәкләреннән торган «Дуслык букеты», балалар өчен «Кайда син, романтика», «Иркен минем туган илем», «Мәктәп китапханәсе» сериялэре басыла. Ел саен чыгып килә торган хикәяләр (рус телендә) һәм «Шигырь бәйрәме» җыентыклары әдәбият укучыларны бу жанрларда иҗат итүче авторларның яңа әсәрләре белән даими таныштырып барырга мөмкинлек бирәләр.

Матур әдәбиятның гомуми үсеше белән бергә, соңгы елларда халык иҗатын җыюга игътибар көчәйде, фольклор әсәрләрен өйрәнү буенча шактый эш башкарылды. Нәшрият күренекле художникларыбызның рәсемнәре белән бизәлгән «Татар халык әкиятләре», «Халык җырлый», «Татар халкының сюжетлы җырлары», «Хуҗа Насретдин мәзәкләре», «Бәетләр» китапларын, Х. Ярминең «Татар халкының поэтик иҗаты», И. Надировның «Халык һәм җыр» исемле фәнни хезмәтләрен чыгарды. Алар арасында Н. Исәнбәт тарафыннан әзерләнгән «Татар халык мәкальләре» исемле өч томлык гаять зур хезмәтне аерып күрсәтеп үтәсе килә. Быел бу әдип әзерләгән яңа зур китап — «Татар халык табышмаклары» басылып чыгачак. Композитор Җ. Фәйзи ике йөз иллегә якын татар халык җырларының көйләрен нотага салган, аларның туу һәм башкарылу тарихын ачыклаган «Халык гәүһәрләре» исемле бик кызыклы һәм тирән эчтәлекле хезмәтен тәмамлап нәшриятка тапшырды.

Бу вакыт эчендә әдәбият белеме һәм тарихы, әдәби тәнкыйть әсәрләреннән «Татар әдәбияты тарихы очерклары», «Борынгы татар әдәбияты», Г. Халитның рус телендә «Тукай һәм аның замандашлары», «Революция тудырган геройлар», С. Хәкимнең «Дуслар авазы», Мансур Хәсәновның «Галимҗан Ибраһимов», И. Юзиевнең «Сәнгатьчә матурлык һәм осталык», Х. Хәйринең «Татар совет әдәбиятында социалистик реализм мәсьәләләре», Г. Иделленең «Язучы һәм аның китабы», Ф. Мусинның «Тормыш сынавы аша» исемле китаплары басылды. Киләсе елда чыгарырга И. Нуруллинның татар әдәбиятында критик реализм үсешен өйрәнүгә багышланган «Үсү һәм чыныгу юлында» исемле зур теоретик хезмәте әзерләнә.

Татарстан китап нәшриятының 50 еллыгы бөтен совет халкы бөек Ленинның тууына 100 ел тулу һәм республикабызның ярты гасырлык юбилейларына зур күтәренкелек белән әзерләнгән көннәргә туры килә. Бу тарихи даталарга әзерлек йөзеннән нәшрият коллективы сөекле юлбашчыбызга багышланган, республикабызның үсү юлын чагылдырган китаплар чыгара, олы бәйрәмнәрне үзенең эшчәнлеген тагын да яхшырту һәм югары баскычка күтәрү өчен бөтен тырышлыгын биреп эшли.

**Сафа САБИРОВ,**
нәшриятның матур әдәбият редакциясе мөдире.

**Азат Әхмәдуллин**

# ДРАМАТУРГИЯ УЙЛАНА, ЭЗЛӘНӘ[1]

Әдәбиятта эзләнүләр — кешенең рухи дөньясына тагын да тирәнрәк үтеп керү, заманга хас әдәби форма, стиль табу, әсәрләрнең архитектоникасын камилләштерү өлкәсендә өзлексез эзләнүләр бара. Шул ук хәлне драматургиядә күрәбез. Дөрес, сәхнә әсәрләре канунннарының тотрыклырак булуы нәтиҗәсендәме икән бу эзләнүләр, проза һәм поэзиядәге кебек, әлегә аяк терәп сөйләрлек, «инде менә шундый зур уңышларыбыз бар» дип кистереп әйтерлек нәтиҗәләр биргәне юк. Шулай да эзләнү, үсү процессы бара, соңгы елларда иҗат ителгән сәхнә әсәрләре шуны күрсәтә. Драматургия әһәмиятле темаларга ешрак мөрәҗәгать итәргә тырыша, тормышның катлаулы вакыйгалары белән тәлбрәк очраша башлады. Заман героен эзләү дә акрынлап киң иҗат юлына күчә бара. Бүгенге көн каһарманын сурәтләгәндә драматургларыбыз аның тышкы кыяфәтенә генә игътибар итү кебек берьяклылыктан котылу юнәлешендә дә кайбер уңышларга ирештеләр.

Тормыш сәхнә әсәрләрендә характерның тирән эчке мәгънәсен, рухи үзенчәлеген тулы ачып бирүне таләп итә. Бу — җәмгыятебез үсешендәге әйдәүче тенденцияләр чагылу дигән сүз. Чөнки хәзер аерым кеше тормышында рухи башлангыч һәм идеялелекнең роле торган саен арта. Шәхес буларак кеше һәр җәһәттән бай һәм күпкырлы төстә, урыны белән хәтта гадәттән тыш конфликт аша, көтелмәгәнчә ачыла. Герой характерын алдан билгеләнеп куелган юнәлештә генә үстереп, аңар алдан хәзерләнгән уңай һәм кимчелек сыйфатләрын ябыштырып түгел, ә аның үзенең эчке диалектикасы таләп иткәнчә тасвирлау, тормышчан нигезләрдә, тулы итеп һәм бөтен катлаулылыгында сурәтләү драматургиядәге үзәк юнәлешләрнең берсенә әверелде.

Узган елда иҗат ителгән сәхнә әсәрләре арасында Туфан Миңнуллинның «Миләүшәнең туган көне» исемле пьесасы аерылып тора. Ул драманың үзенчәлекле тирәнә мөрәҗәгать иткән: әсәрне «пьеса-бәхәс» дип атарга мөмкин. Анда яшәүнең һәм иҗатның мәгънәсен аңлаудагы төрле фикерләр үзара бәрелештерелә. Бәрелештә персонажларның берсе дә читтә калмаган, берсе дә үз карашын әйтмичә, үз мөнәсәбәтен белдермичә сәхнәдән чыкмый. Драма вакыт ягыннан да (вакыйга 2—3 сәгать эчендә бара), катнашучылар саны ягыннан да (барлыгы 9 персонаж), аларның үзәк конфликтка мөнәсәбәте җәһәтеннән дә җыйнак, хәрәкәт бер юнәлешкә төбәлгән, сюжет бер дә як-якка чәчелмичә үстерелә.

Әсәрнең кыскача гына эчтәлеген искә төшереп үтик. Җырчы Миләүшәнең туган көне. Шул уңай белән, гәрчә ире художник Шәһит өнәп бетермәсә дә, ул электә бергә укыган иптәшләрен үзләренә бәйрәм кичәсенә чакыра. Шул арада авылдан юбилярның әтисе дә килеп төшә. Харис агай ялгызы гына түгел, пристаньда фронтовик дусты Әһлиулланы очраткан һәм аны да үзе белән алып килгән. Аларның вакытсыз йөрүенә Шәһитнең шактый кәефе кырыла, ул

[1] Әдәби ел йомгакларына багышланган җыелышта сөйләнгән доклад.

мәҗлеснең «аракы чөмерүгә кайтып калуын» теләми.

Мәҗлес дәвамында әүвәлге дуслары Рәфис һәм Фәһим үзләреннән аерылуы, карьеризмы, талантлы художник Нурисламга юл бирмәве өчен, җае чыкса да, чыкмаса да Шәһитне «чукый» торалар. Арыган, йончыган Әһлиулланың исереп китүен сәбәп итеп, Шәһит өстәл артын ташлап чыга. Бәхәс ачык төс ала, һәр ике як тупаслыкларга күчә, вакыйга Шәһитнең элекке дусларын куып җибәрүе белән тәмамлана. Әһлиулла да китә, Харис та кияве йортын ташлап чыга. Миләүшә дә иптәшләре ягыч сайлый, Шәһитнең үзен генә калдырып, дуслары белән ресторанга юнәлә...

Эчтәлектән күренүенчә, әсәр психологик пландагы гаилә драмасына, көнкүреш драмасына тартым. Капма-каршы караштагы кешеләрнең үзара бәрелешләре, фикер көрәше пьесадагы хәрәкәтне барлыкка китерә. Мәгълүм булганча, мондый тип драмаларның (икенче төрле аларны «бүлмә драмасы» дип тә атыйлар) нигезендә әхлак проблемалары ята. Ләкин андый пьесалар әхлакка бәйләнешле мәсьәләләр белән генә чикләнмиләр. Бездәге иң яхшы гаилә драмалары һәм комедияләре һәрвакытта дип әйтерлек иҗтимагый эчтәлек алалар. Бу җәһәттән «Миләүшәнең туган көне» әсәре яхшы традицияләргә тугрылык саклый. Шәһит белән Миләүшә, Харис һәм Фәһимнәр арасындагы мөнәсәбәтләр җәмгыятьтә үз урыныңны табу, сәнгатькә һәм иҗатка карата дөрес караш булдыру юнәлешендә үсеп-үстерелеп баралар. Ике арадагы киеренкелекне тудырган, күңелле мәҗлеснең таркалуын һәм ахыр чиктә тату гаиләнең бозылуын китереп чыгарган төп сәбәпләр әнә шул соңгылары. Сәнгатьнең тормышта, социалистик чынбарлыкта тоткан урынын бәяләүдә, иҗатка һәм иҗат кешеләренә мөнәсәбәттә Шәһит бер юлдан, Нурислам һәм Фәһимнәр икенче юлдан киткәннәр. Һәм пьеса дәвамында, баштарак сак һәм нәзакәтле төстә барган, соңыннан тупас төс алган бәхәстә Шәһитнең карашлары хата булуы ачыла. Дөрес, кайвакыт Шәһитнең сүзләре һәм аргументлары да урынлы яңгырый. Ул үзенең хаклылыгына нык ышана һәм, чыннан да, аерым моментларда бер дә икеләнмичә аның ягына басып, Рәфисләрнең фикерләренә каршы чыгарга да мөмкин. Ләкин асылда ул ялгыша, вакыйгалар шуны күрсәтә.

Соңгы елларда иҗат ителгән башка күп кенә әсәрләрдәге кебек үк, бу пьесада да автор персонажларны катып калган «уңай — тискәре» схемасы буенча сурәтләми. Шәһит, мәсәлән, һич тә бөтенләй төзәлмәслек, юньсез кеше түгел. Аны тәнкыйтьләгән Фәһим һәм Рәфисләрне дә һәр яктан үрнәк кешеләр дип әйтүе кыен.

Т. Миңнуллин шәхескә, аның рухындагы, күңел түрендәге кечкенә генә үзгәрешкә дә игътибарлы, үз геройларының психологик кичерешләрендәге нечкә борылмаларга сизгер булырга омтыла. Бу яктан бигрәк тә Шәһит, Харис, Миләүшә, Рәфис образлары оста индивидуальләштерелгән булулары белән игътибарны җәлеп итәләр.

Драмада үзенчәлекле образларның берсе — Әһлиулла. Автор аны яратып иҗат иткән. Бу образда үткән сугышка нәфрәт, чын батырлык үрнәкләре күрсәткән гади кешеләргә олы мәхәббәт бөркелеп тора. Әһлиулладагы соклангыч сыйфатларның берсе — тыйнаклык. Һәм драматургның андагы бу сыйфатны алга куеп сурәтләве бик табигый. Батырлыкны гадидән, тыйнак кешеләрдән эзләргә кирәк, сәнгатьтә дә алар үз урыннарын алырга тиешләр — менә шул фикерләргә таянып сәләтле яшь рәссам Нурислам аны күп санлы кешеләр арасыннан эзләп тапкан һәм портретын язган. Ләкин, пьесада күренүенчә, кичәге геройфронтовик сугыштан соңгы тормышта үзенә урын таба алмаган. Әһлиулланың бу хәлгә калуына аның фронтовик дусты Харис та әрни, үз итеп, яратып ул аны тәнкыйтьли. Һәм әсәрнең ахырында абзыйда бу җәһәттән уяна башлау галәмәтләре күренә: аның кунак сөймәс бу йортны ташлап чыгып китүе шул турыда сөйли.

Бусы шулай, бусы аңлашыла. Инде мәсьәләнең четерекле ягына килик. Шәһит үз иҗатында гел яктыга, уңайга гына омтыла. Һәм башкаларның иҗатын бәяләүдә дә ул шул принципка таянып эш итә. Ләкин, күрәсең, ул уңайны, алдынгыны иҗат кыйбласы итеп алу белән тормышны бизәкләп, ялтыратып сурәтләү арасында артык аерма күрми, ягъни иҗатка формаль килә. Ә икенче тарафтагылар — Нурислам, Рәфис, Фәһим (һәм беркадәр Харис та) — гел авызын ерып торучы нефтьчеләрне, сыер савучы кызларны гына шомартып сурәтләү ялгыш, тормыш дөреслеген Әһлиулла кебек утны-суны кичкән кырыс солдатлардан, бүгенге гаять тыйнак, гади кешеләрдән эзләргә кирәк, иҗат кыйбласы шул тарафта булырга тиеш, дип баралар. Чөнки безнең көн каһарманнарында гүзәл сыйфатлар өстә генә ятмый, еш кына аларны күп көч

куеп таба һәм тиешенчә тасвирлый белергә кирәк. Теоретик планда соңгысы дөрес һәм шуны тамашачыга җиткерү — авторның изге теләге. Социалистик реализм методына нигезләнгән алдынгы һәм олы сәнгать барлык художниклардан нәкъ менә шуны таләп итә. Ә әсәрдә эш башкачарак килеп чыга. Автор тарафыннан «дөрес фикер йөртүче» дип тәкъдим ителгән рәссамнарыбыз йөз тоткан геройдан — Әһлиулла карттан бүген нинди дә булса үрнәк алуы кыен. Бу яктан Шәһит белән килешмичә мөмкин түгел. Уйлабрак карасаң, аның сугыш кырында үзе күрсәткән батырлыклар турында шапырынып йөрмәве хәзер үрнәк алырлык бердәнбер ягы булып калган. Ә чынында ул мескен бер кешегә әверелгән.

Сәнгать тормышка тирән үтеп керергә тиеш, дигән нигез кагыйдә бар. Сәнгатьнең бурычларыннан берсе — хаксызга онытылган, рәнҗетелгән кешене яклау, дигән әйбер бар. Болар икесе ике яссылыктагы нәрсә. Безгә калса, Т. Миңнуллин аларны бер тактага куярга тырышкан һәм, нәтиҗәдә, әсәргә дөрес булмаган чишелеш бирелгән. Чыннан да, карагыз, логик фикерләү буенча барсаң, Нурислам да, аны яклаучылар да хаксыз булып чыга бит. Димәк, Шәһитнең, иҗатта формализмны яклаучы, карьерага омтылучы бу кешенең ялгыш иҗат практикасы ахырынача фаш ителми... алда сөйләнгән фикерләргә таянуы аңар тормышта уңыш һәм дәрәҗә китерә, чөнки аны яклыйлар, шуның белән сәнгатьтә хата юнәлеш чәчәк ата була. Кемнәрнеңдер ихтирамын казану, кемнәргәдер ошау бик җиңел, имеш, бары тик иҗатыңда уңайны сурәтлим дип, бүгенгене гел якты тоннарда, өстән-өстән эләктереп тик йөр! Шулай итеп, безнең сәнгатьтә һәм әдәбиятта халтурага юл ачык дигән нәтиҗәгә дә ерак калмый. Һәм, икенче яктан, социалистик реализм методының асыл таләпләреннән берсе — иҗатта беренче планга уңайны кую, заманның әйдәүче тенденцияләрен якты мисалларда чагылдыру дигән таләпкә күләгә төшерелә. «Миләүшәнең туган көне» әсәрендә менә шундый, йомшак кына итеп әйткәндә, фикер каршылыклары уятырдай уйлануларга мөмкинлек калдырылган. Шуңа күрә дә Т. Миңнуллинның бу драмасындагы яңалыклар, уңышлар тиешенчә яңгырый алмый. Чөнки бары тик идеясе ягыннан югары булган әсәрнең генә сәнгатьчә тәэсир итү көче тиешле дәрәҗәдә була.

Узган ел Т. Миңнуллинның «Нигез ташлары» исемле тагын бер пьесасы сәхнәгә куелды. «Нигез ташлары» гомумән алганда әйбәт һәм кызыклы гына пьеса, аның нигезендә тудырылган спектакль җәмәгатьчелек тарафыннан бик хаклы төстә уңай бәяләнде. Бу әсәрендә дә авторның язу стиленә хас булган үзенчәлекләр күренә. Иң әүвәл, бер үк мотивлар дәвам иттерелә, ягъни монда да, алдагы әсәрдәге кебек, тормышка, хезмәткә төрле караш үзара бәрелештерелеп, фикерләр көрәше бәхәс төсен ала. Иҗат алымнары ягыннан да Т. Миңнуллин кулын танырга була: вакыйгалар тыгыз итеп «төенләнгән», хәрәкәт күп, катнашучылар саны чагыштырмача аз һәм алар, ягъни катнашучылар, берсенә-берсе якын бәйләнештә, тыгыз мөнәсәбәттә алынганнар. Шуның белән характеристиканы тирәнгә «җәелдереп», персонажларны эре планда бирү мөмкинлеге туа. Бу — хәзерге драматургия өчен, гәрчә бердәнбер булмаса да, сәнгатьчәлек ноктасыннан уңышка ирешүдә өметле һәм киләчәге зур булган мөмкинлек. Андый типтагы драма әсәрләре соңгы елларда күзгә күренеп ешая. Шул ук вакытта мондый характердагы драма әсәрләренең мөмкинлекләре тулысынча ачылып беткән һәм инде бу җәһәттән зур уңышларга ирешелде дип әйтергә дә иртәрәк.

Пьесага килик. Гарифулла карт читтә төрлесе төрле урында яшәүче улларын «каты авырыйм, тиз кайтыгыз» дип ашыгыч телеграмма белән чакыртып ала. Дүрт малай бер-бер артлы кайтып төшәләр. Баксаң, карт сау-сәламәт икән, йөгереп йөри. Характеры белән бик тә үзенчәлекле, вакыты белән хәтта дуамалрак та, ләкин акыллы һәм туры кеше ул Гарифулла абзый. Авылда абруе зур, һәр җиргә житеш, әле менә колхоз җитәкчеләре үзенә яңа йорт җиткереп бирәбез дип торалар. Балалары да инсафлылар кебек, һәрберсе үз урынында әйбәт кенә хезмәт итә, Хәмите хәтта министр урынбасары булып эшли. Ни җитмәгән карт кешегә?! Шулай да Гарифулла абзыйның ни өчендер күңеле тыныч түгел, бүтәннәргә дә тынгылык бирми. Карт алардан ерак яшәсә дә, улларындагы кайбер кимчелекләрнең акрынлап көчәя баруын белеп, сизеп ята икән. Һәм ул шуның өчен аларның барысын бергә җыеп, кайбер мәсьәләләрне ачыкларга тиеш тапкан, аерым күңелсезлекләр турында алар белән ачыктан-ачык сөйләшергә, аңлашырга уйлаган.

Гарифулланың улларын бергә җыеп, һәрберсеннән үзенең ничек яшәве турында

сөйләтүе, кимчелекләрен һәрберсенә ачыктан-ачык күрсәтүе, тәнкыйтьләве, аларны бер-берсе турында уйланырга, кәяргә-янарга мәҗбүр итүе пьесада җентекләп, психологик яктан нигезле һәм уйлап эшләнгән күренешләрдә ачыла. Монда безнең алга үзенчәлекле характерлар галереясы килеп баса, ышандыра һәм уйландыра торган хәлләр туа. Гарифулланың намуслы булуы, килешмәүчән һәм принципиаль булуы тулы ачыла. Хәниф, Хәмит һәм Хәлилнең кеше буларак, хезмәткәр һәм эшче буларак көчле һәм көчсез яклары, уңай һәм кимчелекле сыйфатлары беленә, һәрберсенең тормышка карашлары ачыклана. Хәмит баштарак үзенә карата һич тә сүз әйттермәскә тырыша. Ләкин ата һәм бигрәк тә энесе Хәлил, туганлык хокукларына нык таянып, аның эш стилендә, үз-үзен тотышында тамыр җәя баручы кимчелек сыйфатларны каты тәнкыйть итәләр; министр урынбасары үзендәге җитешсезлекләрне аңларга һәм җитәкчелек итүендәге кайбер ялгыш алымнарына башка күзлектән карарга тиеш була. Туганлык җепләре Хәлилне ялгыш юлдан — караклык юлыннан йолып алуда иң үтемле чараларны кулланырга һәм аның үзенең упкын өстендә торуын аңлый башларга ярдәм итә һ. б.

Комедиянең ахырында автор барлык сорауларга да җавап биреп бетерми, ягъни, хәл ителәсе мәсьәләләрнең барысын да хәл итеп куймый. Һәм бу очракта ул мәҗбүри дә түгел. Авторның бар нәрсәне дә чәйнәп бирмичә, тамашачыга, аның белем дәрәҗәсенә һәм рухи байлыгына нык ышанып, аның үзенә дә уйланырга урын калдыруын, йомгакны үзенә ясатырга тырышуын хупларга кирәк. Әлбәттә, бу драматургтан билгеле бер осталык һәм такт сорый. Пьесада күренә ки, Т. Миңнуллинда андый сәләт бар.

«Нигез ташлары»н автор комедия дип атаган. Чыннан да, төп ситуациясе һәм күп кенә алымнары ягыннан, кайбер образларны сурәтләүдә әсәрдә комизм өстенлек итә. Ләкин пьесаның соңгы өлешләрендә драмага тартымлык көчле. Гөлҗиһан карчыкны йөрәк авыруы белән түшәк өстенә ятарга этәргән вакыйгаларда, аерата соңгы пәрдәдә юмор югала, әсәрнең стиле үзгәрә. Шуның белән жанр бөтенлегенә зыян килә. Нәтиҗәдә алынган проблеманың әһәмияте кими, чөнки драма өчен Гарифулла картның малайлары, бигрәк тә Хәлил алдына куйган таләпләре (ә бит төп ситуация шуңар корылган!) вагая башлый, драматик материал үзенең тормышчанлыгын җуя.

Жанр сафлыгына игътибарны киметү аркасында, яшьләр генә түгел, өлкән һәм тәҗрибәле драматурглар да уңайсыз хәлдә калырга бик мөмкин. Талантлы язучы, Тукай премиясе лауреаты Нәкый ага Исәнбәтнең татар драматургиясендә тоткан урыны турында иркенәеп сөйләп торуның монда хаҗәте юктыр. Аның «Һиҗрәт», «Хуҗа Насретдин», «Зифа», «Мулланур Вахитов», «Гөлҗамал», «Муса Җәлил» кебек драмалары һәм комедияләре әдәбиятыбызның алтын хәзинәсенә керде. Моңарчы драматург жанр үзенчәлекләрен һәр әсәрендә нык саклавы, икенче төрле итеп әйткәндә, әсәрләренең жанр ягыннан сафлыгы белән күпләргә үрнәк булды. Шуңа күрә дә узган елда сәхнәгә чыгарылган «Кырлай егете» беркадәр аптырап калу тудыра. Әсәрдә, иң беренче, стиль чуарлыгы эчне пошыра. Беренче пәрдәдәге халыкчан юморга, сатирага, тапкырлыкка бай вакыйгалар һәм күренешләр, реалистик әкият стиле ахырга кадәр сакланмаган. Авторның шүрәлеләрне сурәтләү белән нәрсә әйтергә теләве ачык түгел, гомумән, шүрәлеләрне тасвирлауда ниндидер бер логик үсеш табу кыен. Кешеләр арасындагы кайбер иң начар гадәтләргә һәм мөнәсәбәтләргә (алдауга, байлыкка табынуга, бер-берсенә ышанмауга) каршы куеп тасвирланган, шул начарлыкларны фаш итешүдә мәгълүм бер роль уйнарга тиеш булган Җирәнкәй-шүрәле тора-бара бөтенләй дә икенче кыяфәткә керә. Кешеләрдәге начар гадәтләрне күз ачып йомганчы үзләштереп, ул бу яктан рухи гарип Шәпи белән Татлыбикәне дә уздырып җибәрә. Соңгы пәрдәдә Җирәнкәй дә, башка шүрәлеләр дә беренче күренгәндәге гөнаһсыз табигать балалары түгел инде. Безнең алда мәкерле һәм явыз җан ияләре, алар кешеләргә карата гына түгел, бер-берләренә карата да хәйлә һәм усаллык белән эш итәләр. Аларның кыланышлары да, кешеләр арасындагы кайбер кыргый гадәтләргә каршы юнәлтелгән булырга тиеш дип исәп тотылган сүзләре дә ялгыш аңлауга урын калдыра. Соңгы күренешләрдә урыны белән хәтта шүрәлеләр кешеләр өстеннән хакимлек итәләр. Мәсәлән, Сарбай шүрәле Бибкәйне эзләп йөрүче авыл кешеләрен туйганчы мыскыллаган. Егетләр дә шүрәленең хәйләсен сизмиләр; алай гына да түгел, «син нигә шүрәле булып сызгырасың?» дип бер-берсенә гаеп ыргыталар, үзара җәнҗал куптаралар һәм, кызны эзләүне ташлап, кире авылга кайтып китәләр. Шулай итеп, мәхлук бер хәй-

ван бу урында кешеләрдән өстен булып чыга.

Соңгы елларда бездә комедия жанры сизелерлек алга китте. Узган сезонда да бу өлкәдә уңышларыбыз булды. Зәйни Шаһиморатның Республика дәүләт күчмә театрында куелган «Әй, әшнәләр, әшнәләр» водевиле, мәсәлән, шундыйлар җөмләсеннән. Татар драматургиясенә җыйнак кына, матур гына эшләнгән, күңелле сәхнә әсәре өстәлде.

«Әй, әшнәләр, әшнәләр» турында «Социалистик Татарстан» газетасының 1968 елгы 14 декабрь санында язучы Газиз Мөхәммәтшинның рецензиясе басылды. Рецензент әсәрне дә, спектакльне дә асылда дөрес бәяләде, водевильдәге уңай якларны урынлы күрсәтте, уңышсыз җирләрен дусларча тәнкыйтьләде. Әйе, әсәрдә искелек һәм яңалык көрәше чагылдырыла, бүгенге кешеләр арасындагы матур мөнәсәбәтләр шат һәм күңелле көлү аша ачыла, сәламәт гадәтләрнең торган саен ныграк урын ала баруы кызыклы ситуацияләрдә сурәтләнә. Водевильдәге «бүселгән» урыннар хакында да рецензия авторы, безнеңчә, хаклы искәртте. Чыннан да, хатыннарның ирләре алдына ультиматум куеп, «югары галиҗәнап яклар» дип сөйләшүләре дә, Диләфрүзне курчак тирбәттереп йөртүләр дә беркадәр фарс характерын ала, әсәрнең гомуми стиленә ят авазлар өсти.

Әсәрнең теле хакындагы мактау сүзләренә ике куллап кушылган хәлдә, берничә искәрмә дә ясап үтәсе килә. Әйе, драматург телгә игътибарлы, аның теле шома, халыкчан. Автор персонажлар теленә бик күп һәм яңача яңгыраган мәкальләр, үткен әйтемнәр, тапкыр тәгъбирләр керткән. Фикерләү үзенчәлекләре, тел алымнары аша да теге я бу профессия кешеләрен төсмерләргә мөмкин. Мәсәлән, кичәге укытучы (күрәсең, ул биология укыткан) Сәвия ирен болай дип битәрли: «Яңгыр суы да ул кадәр чиста булмый. Аның да һәр литрында утыз дүртәр грамм тозлы матдәләр була. Ә син яңгыр суыннан да чиста булмакчы буласың. Балаңның бәхетен җимерә торган мондый чирле чисталыкның кемгә кирәге бар?»

Яки менә электә медсестра булып эшләгән Диләфрүз болай сөйләшә: «Мин скальпель дим, ул һаман эскәнҗә! Аңла, алар яшьләр. Куянга мөгез, ташбакага йон чыкканны көтә алмыйлар. (...) Мәхәббәтне кисә ала торган скальпель әлегә яратылмаган, атасы!» Аңар ире — бухгалтер Хуҗахан: «Сүзнең дефициты юк ансы. Аңа пушлина салмыйлар. Ләкин юкка!» — дип җавап бирә.

Образларны индивидуальләштерүдә мондый чаралар, билгеле, авторның беренче ярдәмчеләре һәм Ш. Зәйни алардан урынлы файдалана. Ләкин ул вакыты белән коймакны артыграк майлый: мәкаль һәм әйтемнәрне һәрбер персонаж теленә куплап кертә. Һәм шунысы аяныч, геройларның яшь үзенчәлеге дә, характерлары да исәпкә алынмый башлый, персонажларны сөйләм теле ягыннан индивидуальләштерү түгел, ә төссезләтү килеп чыга. Мәкальләрнең үз мәгънәләре белән персонаж теленә ятышмаган, репликалардагы тулаем сүз сөрешенә туры килеп бетмәгәннәре дә очраштыргалый. Ремаркаларга игътибар кимегән җирләр дә бар. Мәсәлән, III пәрдәдә шундый ремарка бирелә: «Пәрдә ачылганда өстәл тирәсендә аталар». Нәрсә, ни дигән сүз бу? Мылтыктан аталармы? Юк икән, сүз ике әти кеше турында бара икән. Водевильдәге җыр текстларының һәммәсе дә уңышлымы икән?

Ни өчен боларга шулкадәр киң тукталдык? Чөнки драмада боларның һәрберсенең әһәмияте зур. Икенчедән, Зәйни ага Шаһиморат — чыннан да тел өлкәсендә зур уңышларга ирешеп, бигрәк тә яшь драматурглар өчен саф, бай тел үрнәкләре бирә ала торган драматург. Шуңа күрә аның әсәрендәге аз санлы бу чатаклыкларга да тәнкыйть күзе белән карау тиеш. Аннан соң, «кызым, сиңа әйтәм, киленем, син тыңла» дигән матур мәкаль дә бар бит әле...

Узган елны мәктәп тормышыннан алып язылган ике драма әсәре сәхнәгә менде. Болар — Рәйсә Ишморатованың «Шамил» исемле һәм Һава Сафинаның «Җыр дәвам итә» дип аталган драмалары. Тәрбия темасына мөрәҗәгать итү гомумән күңелле факт, чөнки бу мөһим мәсьәләгә әле игътибар җитеп бетми. Р. Ишморатова пьесасында турыдан-туры тәрбия темасы үзәккә куелган. Ә Һ. Сафина әсәрендә исә, гәрчә материал мәктәп һәм укытучылар тормышыннан алынган булса да, нигездә гаилә мәсьәләләре, әхлак проблемалары ята. Әмма бу әсәрдә дә тәрбия темасы читләтеп үтелмәгән, ни өчен дисәң, бу мөһим мәсьәлә укытучының профессиясен генә түгел, ә аның мораль-этик йөзен дә ачыклый.

Вакытлы матбугатта (мин монда Ләбибә Ихсанованың «Социалистик Татарстан» газетасының узган елгы 24 ноябрь, Зәйни Ша-

һиморатның «Татарстан яшьләре» газетасының 3 декабрь саннарында басылган рецензияләрен күз алдында тотам) «Шамил» драмасы Р. Ишморатова иҗаты өчен уңыш дип билгеләп үтелде. Алдарак сүз булган, драматургиябездә соңгы елларда көчәя бара, дип әйтелгән тенденциягә автор игътибарсыз калмаган. Моны рецензиясендә Ш. Зәйни дә искәртә: «Драматург бу мәсьәләдә (ягъни, яшь буынны тәрбия итүдә — А. Ә.) ата-аналар, мәктәпләр, укытучылар гына җаваплы, балалар үзләре гаепсез, дигән шаблон юл белән бармый. Аның геройлары — төрле семья балалары. Алар үзләрендәге гаепнең башын үзләреннән эзләрлек һәм туры юлга кире кайтырлык көч табалар. Икенче төрле әйткәндә, алар үз хәрәкәтләре өчен үзләре җавап бирәләр»,— ди ул. Дөрес, геройларның төрле семьядан булулары бу очракта бернинди дә роль уйнамый. Шулай да төп фикер ачык. Ягъни, монда бүгенге драма героендагы шәхси инициативаның роле зур булуы хакында сүз бара, шуңар игътибар итү әсәрнең уңай ягы дип күрсәтелә.

Соңгы еллар драматургиясендә бер ситуация бик тә эчпошыргыч төстә кабатлана башлады. Нинди дә булса ялгышлык эшләгән, яисә үзе яшәгән тормыштан туйган герой әсәрнең ахырында кая да булса китеп бара. Сөйгәне икенче берәүне яратса, аларга комачауламас өчен дә китә ул, мәхәббәттә алданса да китә, күңеле зур эшләргә, батырлыкларга омтылса да китә ул, кемнәрнеңдер әшәкелегенә түзә алмыйча да китә... Р. Ишморатова әсәрендә мондый геройлар тәнкыйть ителә. Шамил белән Ирекнең бөтенесен ташлап китеп барырга дигән уйларыннан кире кайтуларын белгәч, мәктәп директоры Исмәгыйль болай ди: «Кешеләр күңелсез хәлләргә очраган саен туган җирләреннән, ата-аналарыннан качып китә башласалар, качып китәргә урын да калмас иде. (...) Үзеңнән, вөҗданыңнан качарга урын юк. Аннан: башыңа килгән бәлане, төрле аңлашылмауларны, әнә шул аңлашылмау туган урында ерып чыгу җиңелрәк тә, яхшырак та». Дөрес сүзләр. Аларга шундый ситуацияләр белән артыграк мавыгучы драматурглар да колак салсыннар иде!

Һава Сафина исеме безнең өчен яңа әле. Күрәсең, бу пьеса аның сәхнәгә беренче адымыдыр. Яшь драматург җанлы һәм мавыктыргыч итеп сюжет төзергә, персонажларын үзенчәлекле юлдан хәрәкәт иттерергә, аларны үзләренә генә хас рәвештә сөйләтергә һәм уйлатырга тырыша. Үзәра бәрелешкә керүче көчләрне урнаштыруда, үзәк образларны характерлауда аның драматургия кануннарын сиземләве күренә. Пьесасында ул җырдан, аерым детальләрдән уңышлы гына файдалана. Бер генә мисал алыйк. Камил исемле укучы малай, ялгышып, яңа гына мәктәп директоры итеп билгеләнгән Шәүкәтнең башына туп белән бәрә. Шәүкәт бу хәлгә ачуланмый, алай гына да түгел, инде 5 елдан бирле төзелеп ятып та, һаман тәмамланмаган стадионны төзеп бетерергә сүз бирә һәм эшкә керешә. Бу мәктәпне һәм сөйгән кызын ташлап башка мәктәпкә күчеп киткән Салават белән беренче танышканда да без шундый ук хәлнең кабатлануын күрәбез. Бер укучы стадионда ялгышлык белән аңар туп бәргән һәм Салаватның күз төбе кара янып чыккан. Хатыны Наилә күтәрелеп бәрелүгә дә карамастан, бу директор да балага аны-моны әйтми. Шуның белән автор Салаватның балалар тәрбиясе мәсьәләсендә дә, кешеләр белән мөгамәләдә дә дөрес юлда торуын, аның асылда әйбәт, ләкин артык йомшак кеше икәнен искәртеп куя, аның хатыны Наиләнең каты күңелле, кешелексез булуын күрсәтә.

Кызганычка каршы, аерым уңышлары булуга карамастан, һәр ике әсәр сәнгатьчә эшләнеш җәһәтеннән әле шактый аксыйлар. «Шамил»да да, «Җыр дәвам итә»дә дә вакыйгаларның башлануы табигый, әмма табигыйлек ахырга кадәр сакланмый, кайсыдыр бер урында өзелә һәм югала. Вакыйгалар барышында бервакыт автор кулы күренә башлый, бу кулның геройларны ирексезләп диярлек йөртүе, хәрәкәт иттерүе сизелә. Шунда чынлык иллюзиясе җимерелә, әсәрдә ясалмалык өстенлек ала. Мәсәлән, «Шамил» пьесасында Барый күбрәк автор теләге буенча сәхнәгә кертелә һәм чыгарыла. Әйтик, Разиягә — Шамилнең әнисенә тиз генә бер җиргә барырга кирәк, шул вакытта үз машинасы белән Барый килеп керә. Соңгы пәрдәдә шундый күренеш бар: Шамил һәм Ирек, Якутиягә качу өчен, вокзалга киткәннәр, аларның поезды ярты сәгатьтән кузгалачак. Малайларны ялгыш адымнан туктатып калырга кирәк, ә вакыт аз. Нишләргә? Шул вакытта, ходайның бирмеш көне дигәндәй, әлеге дә баягы Барый килеп чыга (машинасы белән, әлбәттә). Барысы да җайлана. Яисә, Шамилне күп борчуларга салган, хаталар эшләргә мәҗбүр иткән Хәмзә картны алыгыз. Автор аны урынсыз шикләнүләре өчен гаепләргә тели.

Ләкин аның Разиядан шикләнүләре бөтенләй үк урынсыз түгел бит. Барый әле ике генә ай элек бу шәһәргә эшкә килгән. Шул арада: «Эштән соң мине машинасына утыртып берничә мәртәбә өйгә китереп куйды, берничә мәртәбә театрга бардык»,— ди Разия. Шул ук арада алар Шамилнең туган көнен бергә уздырганнар (Егеткә Барый яхшы фотоаппарат бүләк иткән), ниндидер атаклы профессорны каршы алып, аның лекцияләрен тыңлап «мәш» килеп йөрделәр. Әйтерсең, Барыйның бүтән эше юк. Кыскасы, Хәмзә картка да, тамашачыга да бик үк аңлашылмый торган якын дуслык килеп чыга. (Җәя эчендә генә булса да әйтеп үтик. Моны автор үзе дә сизә. һәм андый-мондый шик калмасын диптер инде, Барыйның өйдә хатыны барлыгын искәртеп уза: Разия авызыннан Барый аша аңар сәлам тапшырттыра.)

Бусы шулай да булсын ди. Хәмзә карт Шамилне һәм аның Якутиядәге әтисен кызганып, урынсыз шикләнүләргә бирелде, ди. Бу — табигый, ди. Шулай булган суррәттә дә Хәмзәнең Разия өстеннән «әләкләшеп» мәктәп директорына килүе — гайре табигый хәл. Ә бит автор картны соңыннан изге ният белән йөрүче, асылда яхшы күңелле, бары тик ялгышып киткән кеше итеп бирергә тырыша.

Шундый ук хәлләр «Җыр дәвам итә» пьесасында да очрый. Мәсәлән, укучы малай Камил үз укытучысына мәхәббәткә тугрылык саклау мәсьәләсендә «акыл сата». Авторның Салаватны канат астына алырга, шуның белән мондый принципсыз, тотнаксыз кешеләрне якларга омтылуы, йомшак кына итеп әйткәндә, инде әдәбиятта югалып бара торган кирәксез тенденцияләрнең берсе. Яисә Наиләне алырга мөмкин. Бу образ артык турысызыклы итеп бирелгән. һәм гомумән ул ирсез һәм әрсез хатын образлары, баласызлык гамен төчеләнеп сурәтләүләр соңгы елларда артык күбәйде түгелме?!

Сәет Шәкүревнең «Мәхәббәт газабы» драмасында да (әсәр Минзәлә театрында куелды), мәсәлән, вакыйгалар баласыз гаиләләр язмышын тасвирлауга корылган. Драматург сыналган мәхәббәткә нигезләнмәгән парлы тормышның тотрыксыз булуын раслый. Моның өчен артык яшьли өйләнешкән Фазыл белән Сурияне һәм олы яшьтәге Рәкыйп белән Кәүсәрияне, аларның кысыр гаилә тормышын янәшә куеп сурәтли. Пьесада Гадилә түти, Рәкыйп кебек кызыклы гына образлар бар, тозүчеләргә нәтиҗәле ярдәм күрсәтүче лаборатория хезмәткәрләре эшен мавыктыргыч итеп тасвирлау бар. Әмма әсәрнең төп фикерен яңа дип әйтеп булмый һәм ул, тулаем алганда, бик үк уңышлы да яңгырамый. Әсәр ясалмалылык тәэсирен калдыра, аңар мелодрама элементлары кертелгән. Пьесаның исеме җисеменә туры килеп бетмәве турындагы Бәян Гыйззәт фикеренең дә урынлы булуын әйтеп узарга кирәк («Советская Татария» газетасы. 1968 ел. 19 сентябрь).

Ә менә С. Шәкүревнең узган елда аерым китап булып басылып чыккан икенче бер әсәрен без чын күңелдән хуплар идек. Бу — «Зөһрә йолдыз» трагедиясе. Шушы уңай белән бер нәрсәгә басым ясап үтәсе килә. Драматургиядә соңгы вакытларда олы идеяләргә мөрәҗәгать ителгән, идеяләр көрәшен сурәтләүгә нигезләнгән әсәрләр аз языла. Без моның белән һич тә характерлар драмасының ролен кечерәйтергә теләмибез. Ләкин «идея драмасына» да игътибар кимемәскә тиеш, характерлар театры да, идеяләр театры да бердәй игътибар таләп итәләр, һәр икесе дә тамашачыны тәрбияләүдә көчле корал була алалар. Шушы яктылыкта алып караганда, «Зөһрә йолдыз» трагедиясе аерым игътибарга лаеклы. Драматург монда мәшһүр Таһир-Зөһрә сюжетыннан файдаланып төзелгән вакыйгаларны Бөек Ватан сугышы елларына күчерә. Таныш образларны һәм вакыйгаларны романтик стильдә һәм ачык буяулар ярдәмендә тасвирлап, автор хәзер бездә сирәк очрый торган романтик әсәр иҗат иткән. Монда коммунизм идеологиясе белән фашизм идеологиясе арасында килешмәүчән тартыш бара, бу көрәштә азатлык һәм гуманизм идеяләре җиңеп чыга, үзәк геройларның һәлакәтен сурәтләү аша оптимистик төстә раслана. Мондый характердагы әсәрләргә хас булган югары стильгә ирешү өчен автор шигъри сөйләмгә мөрәҗәгать иткән һәм үзе өчен җиңел булмаган бу вазифаны нигездә уңышлы башкарып чыккан. Әсәргә рецензия язган яшь тәнкыйтьче Һәнүс Мәхмүтевнең хуплау сүзләренә һәм кайбер тәнкыйть фикерләренә кушылган хәлдә (рецензия «Социалистик Татарстан» газетасының узган елгы 8 сентябрь санында басылды), шуны әйтергә кирәк: гомумән, С. Шәкүревнең романтик әсәрләр тудырудагы тәҗрибәләрен махсус өйрәнгәндә начар булмас иде. Аның «Уракчы кыз» исемле пьесасы да, мәсәлән, тәнкыйть тарафыннан шул рухтагы уңышлары өчен макталды бит. Чынбарлыкны эре

планда һәм чор каһарманнарын героик характер итеп сурәтләүнең җитешмәвен исәпкә алсак, татар әдәбиятының күп гасырлык тарихында күренекле урын тоткан романтик традицияләрне тергезүнең һәм яңартуның, аларны революцион романтизм дәрәҗәсенә күтәрүнең никадәр зарури булуы тагын да ачыграк аңлашылыр.

Шәриф Хөсәеневнең соңгы ике-өч ел Татар дәүләт академия театры репертуарында ныклы урын тоткан «Зөбәйдә — адәм баласы» трагикомедиясе узган елда аерым китап булып басылып чыкты. Ул сәхнәне, драматургия канунннарын яхшы белеп иҗат ителгән. Автор чыннан да көләрлек тә, еларлык та ситуация һәм образлар тудырган, ул күп тармаклы сатира угы белән тормышта очрый торган кимчелекләрне көйдереп кенә калмый, әһәмиятле мәсьәләләр турында уйланырга да мәҗбүр итә.

Бер генә мисал. Пьесада Җәүһәрия образы үзенчәлекле төстә бирелә. 48 яшьлек бу кыз 70 яшьлек картка кияүгә чыгарга җыенып йөри. Җәүһәриянең бу адымы тамашачыларда көлү уяга, асылда аның бу нияте, загска бару вакыйгалары (Сәмигулла карт кул кую вакытында егылып үлә) комик планда тасвирлана. Шулай да автор барын тик авыз еруны гына максат итеп куймаган. II пәрдәдә артык озын булмаган, әмма күңелләрне тетрәтерлек шундый бер күренеш бар. Габдрахман сеңелесен, кияүгә чыкмый картаюына ишарә итеп, «җимешсез агач, кипкән ботак» дип атый. Абыйсы чыгып киткәч, Җәүһәрия сүзсез генә тауша-лып беткән өчпочмаклы хат ала, аны укый һәм көзгегә карап уйга кала. Шул вакытта без кызларның сафлыгын үзенчә аңлап, сөйгән егетенә — ут эченә юнәлгән егетенә бер генә мәртәбә дә үбәргә рөхсәт итмәгән, сөеклесен мәңгегә югалткан, олы мәхәббәтеннән сугыш аркасында мәхрүм калган беркатлы һәм яхшы күңелле хатын-кызның тирән фаҗигасен күрәбез һәм тетрәнәбез. Бу шәхси фаҗигадә миллионнар өчен бәхетсезлек, кан һәм күз яшьләре китергән сугыш — гасырыбызның иң олы трагедиясе чагыла. Менә шундый, фаҗига белән көлкене, сатираны уңышлы аралаштыру «Зөбәйдә — адәм баласы» трагикомедиясен тормышчан һәм карау өчен кызыклы итә. Шуның белән бергә үк әсәргә инде тәнкыйть тарафыннан күрсәтелгән кимчелек — балалар белән аталарны урыны белән чамадан тыш һәм нигезсез каршы кую, һәр очракта да балаларны гына яклау, алар хаклы дип күрсәтү хас («Заман сулышын тоеп». Татарстан китап нәшрияты. 1967. 175—176 битләр).

Үзенең бер чыгышында өлкән язучыбыз Риза ага Ишморат кайбер сәхнә осталары иҗатында бер урында таптану, хәтта кайберләрендә элекtә яуланган иҗат үрләреннән чигенү күренешләре барлыгын тәнкыйть иткән иде. Шундыйларга мисал итеп ул Н. Исәнбәтнең «Кырлай егете», Х. Вахитның «Илһамия» кебек әсәрләрен санады, үзенең «Шаулыйлар дулкыннар» пьесасын да атады. Узган елда бу пьеса «Казан утлары»ның 7 санында басылып чыкты. Әйе, әсәрне «Давылга табан» драмасының авторы өчен алга китеш дип әйтеп булмый. Аның лирик драма дип аталуы да бәхәсле, чөнки монда лирика чамалырак. Айсылу, Акбүләк кебек образлар да инде сәхнәдә күренгән, кай яклары беләндер таныш персонажлар. Ләкин пьесада бер әһәмиятле момент бар. Бу — Бөркет образының бирелешендәге автор концепциясе. Дөрес, ул ахырына кадәр эшләп җиткерелмәгән, концепция хәлендә калган, шулай да аңар игътибар итү кирәк. Монда әзләнүләр ноктасыннан, иҗат принциплары ягыннан карэганда, кызыклы гына бер табыш күренә.

Кай ягы белән аерылып тора соң әлә ул Бөркет дигән егет? Ул моңарчы язылган әсәрләрдә шактый кабатланган, мәшһүр җырда әйтелгән кызлар күңелен аулап йөрүче «сызылып киткән кара мыеклы» чибәр явызларның тагын берсе генә түгелме?! Әйе дә, юк та! Әйе, чөнки Бөркет әсәргә ничек килеп керсә, шулай ук чыгып та китә, үзгәреш кичерми. Юк, чөнки бу тискәре герой без моңарчы күреп өйрәнгән явызлардан үзенең тулы бер фәлсәфәсе белән — яшәүнең мәгънәсе турында, хатын-кызларга һәм гаиләгә мөнәсәбәт мәсьәләсендә шактый җентекле уйланган фикерләре белән аерылып тора. Үз-үзен тотышы, нәзакәтлеге, тышкы культурасы белән аның рухи дөньясы, эчке мәгънәсе арасында җир белән күк аермасы бар һәм пьесада бу ачык күренә. Ләкин тулаем алганда Бөркетнең черек фәлсәфәсе тиешенчә фаш ителеп, кире кагылмый. Дөрес, финалда без егетне җиңелгән хәлдә күрәбез, ләкин бу — физик җиңелү генә, ә фикер ягыннан тар-мар ителү түгел. Язучы мондый карашларның зарарлы, болай тормыш көтү, яшәү җирәнгеч кенә түгел, ә куркыныч та булуын тулысынча фаш итәрлек ситуацияләр табыруны тиеш тапмаган. Ә кирәк иде! Югыйсә Бөркет кебекләр фәлсәфәсенә каршы куелган коммунистик әхлак нормалары болай

бик декларатив төстә генә раслана. Моңар икенче бер персонажның — Яшәрнең ялгышуларын ахыргача ышандырырлык төстә ачып бетермәү дә ярдәм итә булса кирәк.

Узган елда драматургиягә Татарстан китап нәшрияты җитди игътибар күрсәтте. Без алда аерым китап төсендә басылган драма әсәрләренең кайберләрен искә алдык. Басылып чыккан китаплар исемлеген тагын да Н. Исәнбәт «Сайланма әсәрләр»енең III томына, Х. Вахитның «Беренче мәхәббәт» исемле пьесалар һәм скетчлар җыентыгына һәм «Күңелле сәхнә»нең 18 китабына кергән әсәрләр исәбенә, шулай ук Ю. Әминевнең кызыклы эшләнгән «Кошның үз канаты була» дип аталган музыкаль комедиясе һәм башкалар исәбенә тагын да арттырырга мөмкин. Бу китаплар турында җентекләп сөйләүне вакыт сыйдырмавын һәм күбесенең тәнкыйтьтә һәм әдәбият белемендә тегеләйме-болаймы бәяләнгән булуларын истә тотып, шуны гына әйтеп узыйк. Китаплар арасында төрле характердагылары бар, жанр ягыннан да, тематик яктан да алар төрлеләр. Бу сәхнә әсәрләрен укып халкыбызның революцион көрәшен дә, Совет дәүләте елларында узган данлы хезмәт юлын да, бүген ирешкән политик, социаль һәм мораль-этик казанышларны да күзаллаурга мөмкин. И. Абдуллинның «Г. Камал драмаларының теле» исемле монографиясе дә дөнья күрү нур өстенә нур булды,— драматургиябез тарихының конкрет проблемаларын өйрәнүгә өлеш кертелде.

Узган елдагы драматургия үсеше йомгаклары, театр һәм сәхнә әдәбияты тәнкыйте турында сөйләгәндә бер фактка аерым тукталып, аның әһәмиятен ассызымлап үтәсе килә. Бу — 1968 елның октябрь аенда партиянең Татарстан өлкә комитеты уздырган, татар драматургиясенең бүгенге үсеш мәсьәләләренә багышланган җыелыш. Мәгълүм булганча, бу җыелыш-киңәшмәдә доклад белән Өлкә комитеты секретаре М. Вәлиев чыкты, аның бу доклады «Милли драматургия үсешенең кайбер мәсьәләләре» исеме белән «Татарстан коммунисты» журналының 12 санында басылды. Докладта һәм чыгышларда соңгы 50 ел эчендә ирешкән уңышлар яктылыгында бүгенге татар драматургиясенең торышы шактый җентекле анализланды. Милли сәхнә әдәбиятында хәзерге көндә дә яшәп килгән аерым кимчелекләр урынлы тәнкыйть ителде. Социалистик чынбарлыкның зур иҗтимагый проблемаларын яктыртуга игътибарның җитешмәве бүгенге драматургиянең төп кимчелекләреннән берсе төсендә күрсәтелде. Ике олы датаны, В. И. Ленинның 100 еллыгын, Татарстан республикасы төзелүгә 50 ел тулуны лаеклы билгеләп үтүгә нык хәзерлек барган көннәрдә социаль проблемаларга тиешле әһәмият бирү, данлы чорыбызның зур мәсьәләләрен олы образлар аша, тирән мәгънәле конфликтларда чагылдыру — драматургларыбыз алдында торган мөһим бурыч әнә шул. 1968 елгы татар драматургиясе ирешкән кайбер уңышлар киләчәктә бу юнәлештә җитди казанышлар яулауда билгеле бер роль уйнарлар, дип ышанырга кирәк.

## Роберт Батуллин

# ВИТАМИННАР ХАКЫНДА[1]

Балалар әдәбияты турында сүз чыкканда, «тәрбия» сүзе һәрвакыт янәшә йөри. Тәнкыйтьчеләр һәм педагоглар, балаларга багышланган әдәби әсәр турында сөйләгәндә, бик хаклы рәвештә, иң беренче планга тәрбия мәсьәләсен куялар. Әмма тәрбия чаралары аңарга сиздерми, күренми генә тәэсир итәргә тиеш. Һәм әдәби әсәр дә балага эмоция һәм конкрет сүзләр аша, вакыйга, образлар, характерлар һәм, ниһаять, әсәргә салынган идея-орлык аша, витамин аша, тәэсир итәргә тиеш.

**«А» дигән витамин бар,**
**«В» дигән витамин бар,**
**«С» дигән витамин бар,**
**Күп төрле витамин бар.**
**Түм-түгәрәк, вак-ваклар**
**Әйтерсең лә, борчаклар,**
**Кайсылары ал гына,**
**Ә үзләре бал гына!**

[1] Әдәби йомгакларына багышланган җыелышта сөйләнгән доклад.

**Иң уртасы әчкелтем,**
**Монысын белә ич һәркем —**
**Матур булса да тышы,**
**Эчендә файдалысы...**

Бу өзек «Витаминлы хәрефләр» исемле шигырьдән алынды. Шагыйрь Шәүкәт Галиевнең «Гаҗәп хәлләр, мәзәк хәлләр» китабы шушы шигырь белән ачыла.

Бал — сәнгатьчә эшләнеш, витамин — әсәрнең идеясе!

Энә очы хәтле витамин яки дару йотыру өчен, бармак башы чаклы конфет ясарга кирәк. Димәк, өлкәннәргә адресланган әсәрләргә куела торган таләпләрдән тыш, балалар әдәбиятының үзенә генә хас үзенчәлекләре дә бар икән әле. Бу хәл балалар әдәбияты өлкәсендә эшли торган әдипләргә тагын да катлаулырак һәм тагын да зуррак өстәмә җаваплылык йөкли. Балаларга атап язылган әсәр, беренче чиратта, гади һәм аңлаешлы булырга тиеш, автор баланың белем һәм тормышны аңлау дәрәҗәсе белән хисаплашырга мәҗбүр. Аннан соң мәктәпкәчә һәм мәктәп яшендәге балаларга язылган әсәрләр озын булмаска, баланы ялыктырмаска тиеш. Сөйләнгәннәрне конкретрак рәвештә аңлату өчен, яңадан Шәүкәт Галиев шигырьләренә мөрәҗәгать итик:

**Чана бара, чана бара,**
**Чана бара, алга бара.**
**Шул чанада чалкан ятып,**
**Туңа-туңа арба бара.**
(«Бу кайчак».)

Карагыз: нинди матур язылган, никадәр җиңел укыла һәм ятлана торган шигырь. Шәүкәт бер куплет шигырьдә җиде генә сүз кулланган. Аз сүзле, әмма тирән мәгънәле бу шигырьне бала бик тиз отып алачак.

Авторның «Ай, кызым», «Сарыкмахерская», «Уяулык», «Сызгырып йөрим» кебек шигырьләре дә бер укуда истә калырлык. Менә «Ике төрле Тәүфыйкъ» исемле тагын бер шигырь. Анда икейөзле, төче һәм ялагай малай турында сөйләнә:

**Тәртипле дип әйтсеннәр дип,**
**Шулай итенгән була —**
**Юри аякка баса да**
**Гафу үтенгән була...**

Инде бу шигырендә Шәүкәт характеры формалаша башлаган астыртын кеше турында укучылары белән җитди итеп сөйләшә. Бу инде — гади көлке әсәр генә түгел, бу инде икейөзле кешеләрнең асылын аңларга өйрәтә торган әсәр. Авторның яңа китабында сатирик, көлке шигырьләр белән бергә, уйландыра торган, уфтанырга мәҗбүр итә торган әсәрләр дә байтак, алардан соң табышмаклар һәм тизәйткечләр бирелгән. Шәүкәт Галиевнең «Гаҗәп хәлләр, мәзәк хәлләр» китабын мин узган әдәби елның иң уңышлы әсәрләреннән саныйм...

Мәгълүм булганча, балалар әдәбияты — гаять катлаулы тешенчә, һәм ул үз эченә күп жанрларны туплый. Шуның өстенә әле әсәрләрнең кече яшьтәге балаларга адресланганнары, урта һәм өлкән яшьтәге мәктәп балаларына атап язылганнары була.

Сүзне бәләкәйләр өчен чыккан китаплардан башлыйк. Гомәр ага Бәшировның «Ана каз белән ата каз һәм аларның уникә бәбкәсе» исемле хикәясе нәкъ әнә шундый: мәктәпкәчә һәм мәктәп яшендәге балалар өчен язылган әсәрләрнең берсе. Беренче карашка ул бик гади сыман, бу хикәяне теләсә кем яза алыр шикелле. Әсәр озын түгел, автор кем өчен язуын, баланың тормыш тәҗрибәсен игътибардан ычкындырмый. Хикәя кыска җөмләләр, матур һәм аңлаешлы әдәби детальләр кулланып язылган. Ярылып яткан морале дә юк. Ләкин хикәя зур эмоциональ тәэсир көченә ия, ул кош-кортларны, җәнлекләрне, тереклекне яратырга, табигатьне, тирә-ягыңны күзәтә белергә өйрәтә.

Кагыйдә буларак, җәнлекләр, табигать турындагы хикәяләр зур тәэсир көченә ия булалар. Кызганычка каршы, безнең язучылар табигать һәм җәнлекләр турында аз язалар.

Җәнлекләр, кош-кортлар турындагы хикәяләр гадәттә ике төрле максатны күздә тотып языла. Бер ишләре табигатьне күзәтә белүне, җәнлекләрнең тормышын, холыкларын аңларга өйрәтүне максат итеп ала. Икенчеләре, мәсәлән, әкият формасында язылып, җанварлар тормышын сурәтләү аша кешеләр хакында сөйләүне максат итеп куя. Соңгысына Алиш әкиятләрен мисал итеп китерергә була. Алдагысына Г. Хәсәновның «Ялкын» журналында һәм шул ук елда аерым китап булып басылган «Унике матур» әсәрен алырга мөмкин. «Унике матур» — елның унике аенда табигатьнең үзгәрүе, кош-корт, җәнлекләрнең тормыш итүе турындагы кызыклы һәм мавыктыргыч повесть. Бу китапны мин ел фасыллары, җәнлекләр, кошлар, үләннәр, табигать турында кечкенә энциклопедия дип атар идем. Әсәрнең дөньяга чыгуында журналның да, нәшриятның да хезмәте күп. Ләкин нәшрият зур бер ялгышлык эшләгән: китап

рәсемсез чыккан. Табигатьне, терлекләрне яратырга өйрәтү максатыннан чыгып язылган китаплар, натуралист язмалары, һичшиксез, буяулы рәсемнәр белән чыгарылырга тиешләр. Рәсемнәр бу кызыклы китапны тагын да баетыр иде.

Шәүкәт Галиевтән кала балалар өчен иң актив эшләүчеләрнең тагын берсе — шагыйрь Галимҗан Латыйп. Узган ел аның «Дусларым минем» дигән китабы дөньяга чыкты. Әлеге китапта бик матур бер шигъри әкият бар. «Итекче» дип атала ул. Шигырьнең эченә салынган витамины да төртеп тормый. Язылышы да мавыктыргыч, гыйбрәте дә саллы — хезмәттә, һөнәрдә көч-куәт ди автор! Бу әкиятне тулысы белән яхшы әсәрләр рәтенә куеп була. Ләкин, кызганычка каршы, китаптагы башка шигырьләр зәгыйфьләр. Сүзем буш булмасын өчен, «Хәмәй белән Җәмәй» шигырен алып карыйк. Ике малай, уен белән мавыгып, мәктәпкә соңга калалар. Мәктәпкә барганда алар:

**Әтәчләр сугышканны да**
**Карап озак торалар.**
**Үзләре дә әтәч кебек**
**Берсен-берсе е г а л а р.**

Белмим, «торалар» белән «егалар» сүзе никадәр уңышлы рифмалашадыр. Әмма мәгънә төгәллеге әллә ни искитәрлек түгел. Әтәчләрнең бер-берләрен егышуларын күз алдына китерүе шактый кыен. Әтәчләр «егышканны» караганнан соң, дуслар алга таба китәләр.

**Җиң очларына ш а л т ы р а п**
**Ката бозлы энәләр.**

«Шалтырап» түгел, шакыраеп ката түгелме соң ул! Шуннан соң малайларга салкын тия, автор аны болай сурәтли:

**Хәмәйнең дә, Җәмәйнең дә**
**Тамак төбе с ы з г ы р а.**

Бәләкәй генә шушы шигырьдә күпме төгәлсезлек, күпме буталчыклык!

Галимҗан Латыйпның бөтен шигырьләренә хас бер кимчелек шунда, аларның адресаты төгәл булмый. Алар өлкән класс укучылары өчен артык гади, бәләкәй бала өчен катлаулы итеп язылганнар. Сүзләр кайчакны матур яңгырашлы булганнары, рифмага уңай булганнары өчен генә сайланалар һәм шигырь тукымасына ямау итеп салыналар...

Кече һәм урта яшьтәге мәктәп балалары өчен язылган тагын бер шигырьне алып багыйк. Ул «Яшь ленинчы» газетасының 62 санында басылган. «Уйларга кирәк» дип атала. Авторы — Р. Мингалимов.

**Белер өчен дөресен,**
**Үсәр өчен тизрәк —**
**Бик күп уйларга кирәк.**
**Бик күп уйларга кирәк,—**

дип башланып китә шигырь. Шуннан соң шагыйрь баланы гаять кызыклы сәяхәткә алып чыга. Юк, үзе куйган сорауларга үзе үк җавап биреп бармый автор: дөньядагы бик күп «ни өчен»нәргә җавапны баланың үзеннән эзләтә. Рөстәм Мингалимов баланың хисләрен, тойгыларын, аңын, фикерен уятырга тырыша. Чөнки язучы укучыны йоклатырга түгел, уятырга тиеш, ачынырга, борчылырга, эзләнергә, көрәшергә өндәргә тиеш.

«Син шигырь укыйсыңмы?» — дип дәвам итә Мингалимов:

**«Ай көлә»,— дип язалар,**
**«Йолдызлар көлә»,— диләр;**
**Укыйсыңмы шигырьләр!**

. . . . . . . . . .

**Елаган кошны күреп —**
**«Җырлый!» дисеңдер әле.**
**Җырлаган кошны күреп —**
**«Елый!» дисеңдер әле...**
**Белер өчен дөресен,**
**Үсәр өчен тизрәк —**
**Бик күп уйларга кирәк.**
**Бик күп уйларга кирәк,—**

дип тәмамлый автор шигырен. Дөресен әйтергә кирәк: көчле шигырь! Автор да, «Яшь ленинчы» да балалар белән тормышның җитди яклары турында фикер алышалар.

«Ялкын» журналында Нәби Дәүлинең «Сине көтәләр, лейтенант» дигән хикәясе басылды. Бер караганда, хикәя бөтен шартын китереп язылган сыман. Адресаты да дөрес, күләме дә таман, авторның максаты да изге. Тик бер нәрсә эшне бозып ташлаган: батырлыкка мәдхия җырлыйм дип, автор чама тойгысын онытып җибәргән, нәтиҗәдә әйтергә теләгәненең киресе килеп чыккан.

Эш болай тора. Бөтен гаскәрләр чигенгәндә, совет офицеры постын ташлап чигенергә теләми. Чөнки аңа: пушканы ташлап китмә, дигән боерык бирелгән. Күпмедер вакыттан соң гаскәрләр кире әйләнеп килә. Ләкин алар килгәндә лейтенант белән пушка торган урында чокыр гына калган була. Лейтенант тубы белән үзен дә шартлаткан! Бер караганда, гаять зур батырлык бит инде. Ләкин уйлап карасак, Ватан өчен

шундый турылыклы, батыр офицерның тормышы кыйммәтме, әллә бер тупмы?.. Күпме танклар, күпме туплар һәлакәткә очраган заманда, бер тупны кызганып түгел, кешеләрне коткару бәрабәренә шәһәрләр калдырылган заманда, лейтенантның мәгънәсезгә һәлак булуы ачуны китерә. Ләкин лейтенант үзе һәлак булмыйча да тупны шартлата ала һәм башка солдатлар белән чигенә дә ала иде бит. Алда күпме батырлыклар эшләп, ватанга күпме файда китерә ала иде!..

Урта һәм олы яшьтәге балалар өчен язылган әсәрләргә килеп җиттек шикелле. Алдыбызда «Пионер сәхнәсе» китабының икенче саны. Болай китапның чыгу факты үзе матур күренеш, кирәк күренеш. Нәшрият та, китапны төзүчеләр дә зур эш башкарганнар.

«Пионер сәхнәсе»ндә җәмгысы унөч сәхнә әсәре бар. Кызганычка каршы, шуларның күбесе схематизм чире белән авырый, күбесенең характерлары зәгыйфь. Балаларны юк-бар белән кәлдерергә азаплану нык сизелә. Әзер штамплар буенча өстән-өстән генә язылган әсәрләр байтак анда. Гадәттә, балалар өчен язылган сәхнә әсәрләрендә һәм скетчларда ялкау, тәртипсез укучылар, ягъни тискәре типлар үзәктә була. Әсәр башында тискәре укучы үзен гел начар яктан гына күрсәтә: иптәшләре, өлкәннәр белән дорфа сөйләшә, гел әшәкелек кенә эшләп йөри. Әсәр азагына таба яхшы укучы (укучылар коллективы яки укытучы) килеп керә дә тискәре укучының начар икәнен исбат итә, үгетли, яный, оялта. Шуннан соң тискәре укучы гаебен аңлап елый башлый, гафу үтенә. Елау һәм гафу үтенү һәр әсәр өчен мәҗбүри.

Г. Нәбиуллинның «Харис бабайлар өендә» скетчында Әминә исемле кыз, Харис бабайның өй эшләрен эшләшкән өчен, аннан акча теләнә. Хәйләли торгач, тәки бераз акча төшерә бит кызый. Күп тә үтми, Әминәнең әнисе, ватык сәгатен төзәттерергә дип, Харис бабайга килә. Харис бабай сәгатьне бушлай төзәтеп бирә. Финалда үзенең ялгышын аңлаган Әминә түбәндәге тәүбә речен сөйли:

**«ӘМИНӘ. И, оятка калуларым шушы икән! Нигә дип кенә алдым соң мин бу акчаларны! Моннан соң Харис бабай күзенә ничек күренермен инде! (Акчаларны өстәлгә куя да чыгып йөгерә)».**

Г. Зәйнашеваның «Шомбай чыбыркысы» экият-комедия дип аталган. Әмма әсәрнең эчтәлеге дә, формасы да экият-комедия жанрына туры килми, дәресргә, ул жанрга җавап бирми. Биредә бер әдәби әсәрдә сыеша алмый торган төрле жанрлар буталган. Стена газетасыннан төшкән әкият батыры Шомбайның реаль вакыйгаларда катнашуы бөтенләй акланмый. Борынгы замандагы надан көтүче, ярлы көтүче Шомбайның бүгенге пионерлар белән булган мөнәсәбәте ачыкланмаган. Финалы белән ул алдагы скетчка бик тә охшаган.

Ш. Рәкыйповның «Кирәмәт» скетчындагы Кирәмәт бик саран малай. Үз тырмасын кешегә бирми. Кеше бассын дип аны тешләре белән өскә каратып куя. Ләкин тырмага басып үз маңгаена суга. Керпесе була аның, ялгыш керпесе өстенә утыра. Башка укучылар карап торганда, билгеле. Шуннан соң ул төзәлә, тәртипкә керә, тәрбияләнә һәм, кагыйдә буларак, елап җибәрә.

И. Абдуловның «Алма вакыйгасы» пьесасы да шундый ук әсәр. Сәлим исемле пионер, алма чәлдергәндә, көймәсе капланып, суга чума. Көймәгә балчык, су тула, көймә бата. Көймә башка кешенеке була. Алма урлаганны белерләр дип, Сәлим көймәнең кая батканын әйтми. Ә көймә суның аргы ягына чыгар өчен бик тә кирәк. Менә эзлиләр... Тик сизгер укучылар, пионерлар ярдәмендә укытучы җинаятьчене фаш итә. Сәлим үз гаебен таный һәм елап җибәрә...

Н. Гайсинның «Ялгышу»ы — тулы күләмле, өч пәрдәлек зур пьеса. Әмма бик өстәнөстән генә язылган һәм алдагы ишләреннән бик аз аерыла торган пьеса. Җиденче класс укучысы Дамир, хезмәт дәресеннән «бишле» алу максаты белән, кеше эшләгән яхшы детальне үзләштерә. Нәтиҗәдә деталь хуҗасы түбән билге алырга тиешле була. Тик монда да пионерлар бик сизгер булып чыгалар. Тоталар бит малайның ялганын. Дамир да артык киреләнеп тормый, гаебен аңлый:

**«ДАМИР. Үз ялгышымны таныйм, иптәшләр, мин гаепле, гафу итегез. Сезне оятка калдырдым. Хәмит абый каршына барып хәзер үк гафу үтенергә риза».**

Дамирдан шушы ике җөмлә сүзне әйттерер өчен, Нур Гайсин өч пәрдәлек пьеса язган.

Гомумән, балаларга адресланган сәхнә әсәрләре артык схематик булалар һәм өстән-өстән генә язылалар. Һәм алары да, гадәттә, кече һәм урта яшьтәге укучылар өчен генә була. Ә югары сыйныф укучылары, яшүсмерләр өчен язылган сәхнә әсәрләре соңгы ун елда бөтенләй күрен-

мәде дисәм дә әллә ни арттыру булмас кебек.

Дөрес, академия театры сәхнәсендә Аяз Гыйлаҗевнең «Җиргә тапшырылган серләр» дигән әсәре куелды. Игътибарга бик лаеклы сәхнә әсәре ул. Автор җитди проблема күтәрә. «Җиргә тапшырылган серләр» пьесасы уйландыра торган әсәр, зур киечрешләр әсәре. Һәм ул пьеса «Мәктәп сәхнәсе»ндә рәхәтләнеп басылырлык иде.

Балалар драматургиясенең зәгыйфь булуында яшь тамашачылар театры юклыгы гына төп сәбәп түгел, минемчә. Курчак театры бар бит. Ә драматургия юк. Бер Н. Дәүли нык бәйләнештә ул театр белән. Аның да ике пьесадан арттыра алганы юк. Ун елга ике пьеса — бик аз.

«Пионер сәхнәсе»ндә шактый матур, оста язылган берничә пьеса бар. М. Хәсәновның «Хикмәтулла»сы татар халык әкиятләре нигезендә язылган. Ул җор тел, кызыклы сюжет, маҗаралары белән укучыны үзенә җәлеп итәр. Ә Баяновның «Васыять» драматик поэмасы — игътибарга аеруча лаеклы әсәр. Формасы белән дә, сәхнә кануннарын белеп язылганлыгы белән дә һәм укучылар белән җитди телдә сөйләшүе белән дә бу әсәр кыйммәтле.

Роберт Рәкыйповның «Математик пьеса»сы форма ягыннан бик кызыклы уйланган. Бала уйнаганда һөнәргә өйрәнә, диләр. Бу әсәрдә геометрик фигуралар җанлы образлар булып хәрәкәт итәләр. Менә шушы уен аркылы элементар геометрия кагыйдәләрен балаларга аңлату авторның максаты, һәм ул үз максатына ирешкән. Ләкин автор, ни өчендер, шушы шаяру әсәренә кызыл, купшы сүзләр китереп өстәгән.

Мин башта бал — әсәрнең сәнгатьчә эшләнеше, витамин, дару — әсәрнең идеясе, дигән идем. Әле генә санаган әсәрләрдә идея тулып ята. Әмма менә шушы идеяне — витаминны бал белән төрү күренми.

Характерлар зәгыйфьлеге, схемачылык Х. Гардановның урта һәм олы яшьтәге мәктәп балалары өчен атап язылган «Су астында сукмаклар» повестенда да, Г. Нәбиуллинның «Яшел эстафета»сында да нык сизелә. Кызганычка каршы, олы әдипләребездән Г. Әпсәләмовның «Миңа унтугыз яшь иде», Г. Кашшафның «Чүл буенда» повестьларын да әдәби елның казанышы, дип әйтеп булмый. Габдрахман абыйның бу повесте:

«Мине 1941 елның декабрь азакларында Мәскәү янындагы сугышларда үтерделәр»,— дип, гаять мавыктыргыч, куәтле динамика белән башланып китә. Ләкин әсәрнең үсешендә ул динамика сүрелә, кими. Әсәр унтугыз яшьлек егет гомеренең гади иллюстрациясе булып кына калган. Сугышның фаҗигасе, коточкыч фәлсәфәсе, безгә таныш булмаган яклары күренми.

Г. Кашшафның «Чүл буенда» әсәре дә хәрби темага корылган. Ул бер яктан дөрес язылган, матур эпизодлар белән сугарылган. Әмма ләкин ярты гасыр моннан элек булган вакыйгаларның бүгенге яңгырашын табалмадым мин бу повестьта.

Аннан соң, бу ике әсәрнең теле читтән кергән сүзләр белән бик нык чуарланган. Г. Әпсәләмов повестенда «истопник», «тапочка», «костюм», «роддом» кебек сүзләр байтак очрый. Г. Кашшафта исә алар тагын да күбрәк: «конюшня», «субботник», «член», «бархат»...

Хәрби-патриотик темага язылган әсәрләр күп чыкты быел. Ш. Рәкыйповның «Кайда син, Җан?»ы, Ә. Галиевнең «Йолдызлар шаһит»ы һәм башкалар. Ләкин авторлар батырларның ничек батыр булу фактларын, әсирлектә булган вакыйгаларны констатацияләүдән ары китә алмаганнар.

«Сугыш язмалары» дигән китап та сугыш турында. Авторы — Хәертдин Мөҗәй, төзүчесе — Самат Шакир. Бу китапта без сугышның чынбарлыгын, коточкыч фәлсәфәсен, әче хакыйкатьне, сугыш мохитендәге зур язмышларның фаҗигасен пәрәнҗәсез күрәбез. Автор сугышның кайнаган урыныннан репортаж формасында көндәлек язган һәм, үзе дә сизмәстән, югары сыйфатлы сәнгать әсәре тудырган. Бу әсәрдә заман прозасының кыскалыгы, оешканлыгы ярылып ята. Совет солдатларының батырлыгы белән авторның геройлыгы, кайбер кешеләрнең куркаклыгы, кайбер командирларның совет офицерына хас булмаган яклары, сугышның әчесен, хәтта сугышның көлке якларын да фальшьсыз, ачыктан-ачык сурәтли бу әсәр. Х. Мөҗәй үзенең документаль повестенда контрастлар аша, батырлыкны куркаклык белән янәшә куеп, Совет солдатларының геройлыклары, Ватан язмышы, олы язмышлар турында сөйли. Һәм аларның батырлыклары, Ватанга булган мәхәббәтләре, тугрылыкларын күреп автор куана. Ләкин сугышның катлаулы мохитендәге кайбер каршылыкларга да күз йоммый.

Кызганычка каршы, китап нәшрияты Х. Мөҗәй елъязмасының күп кенә кызыклы эпизодларын төшереп калдырган. Бәлки,

ул кимчелек русчага тәрҗемә ителгәндә төзәтелер.

Өлкән сыйныф укучылары өчен атап чыгарылган китаплардан «Беренче карлыгачлар», «Чәчәкләр һәм кешеләр», Г. Фәрхетдиновның «Солдатлар» исемле беренче китабы, Р. Гатауллинның «Диңгез ээлим», Э. Мөэминованың «Синең өчен язам», Р. Вәлиеваның «Якты йолдызым», Р. Хафизованың «Таң билгесе», Г. Таблинның «Сары яфраклар коела» китаплары турында мактау сүзе дә, тәнкыйть сүзе дә әйтә алмыйм.

Ф. Шәфигуллинның «Авылым сандугачы» һәм М. Юнысның «Тимер фил»е укучылар тарафыннан теләп кабул ителерләр дип уйлыйм. Соңгысы бигрәк тә. Миргазыян Юныс чит илләрдәге тормыш турында күп яза. Һәм, әйтергә кирәк, оста яза. Бу китапка кергән очерклар аеруча кыйммәткә ия, алар мавыктыргыч, талантлы язылганнар. Мон-пеле, Стромболи, Этна, Везувий вулканнарына сәяхәт бик мавыктыргыч, су асты авы турындагы очеркта диңгез төбе дөньясының без белмәгән бик күп кызыклы яклары белән танышабыз. Тик автор чит илдәге хезмәт ияләренең авыр тормышын күрсәтү белән бергә ул җирләрнең гореф-гадәтләре, мәдәният һәйкәлләре һ. б. турында да язса, әсәр тагы да тулырак булыр иде.

Йомгаклап түбәндәгеләрне әйтәм.

Балаларга атап язылган фәлсәфи, гыйбрәтле әсәрләр, элегик кичерешләр белән сугарылган, уйландыра торган, моңсу әсәрләр бөтенләй юк, дисәм дә хакыйкатьтән ерак китмәм! Андый әсәрләр язмаска, дигән канун бармы әллә соң?!

Балаларның, яшьләрнең бер-берләренә булган хисләре турында югары сыйфатлы әсәрләр аз. Язучылар «Яшь ленинчы», «Ялкын» укучылары өчен мәхәббәт турында язарга шүрлиләр. Моннан бер ун-унбиш еллар элек, педагоглар, тәнкыйтьчеләр балаларга мәхәббәт турында сөйләргә, гашыйклар турында әсәр язарга ярамый, диләр иде. Хәтта «Муха цокотуха», «Бака патша турында әкият»не, «Ромео һәм Джульетта»ны да шик астына алып, чебеннең черкигә, Бака патшаның Иванга, Ромеоның Джульеттага булган мәхәббәтләрен балага күрсәтүнең зарарлы икәнен исбат итәргә маташып карадылар. Ләкин бу әсәрләр дөнья әдәбиятының шедеврлары булып калдылар һәм калачаклар. Һәм киләчәктә мең буын балалары аларны укыячак, караячак!

Ел йомгакларында театрларда яшь тамашачылар өчен куелган, радио-телевидениедә барган пьеса-сценарийлар да игътибардан төшеп калмасыннар иде. Һәр тапшыруның нигезе әдәби әсәр бит.

Безнең «Знание — сила», «Техника молодежи», «Наука и техника» кебек журналларыбыз юк. Балалар газетасы белән журналы гына бу эш белән даими шөгыльләнә алмый. Димәк, фән-техника яңалыклары, мавыктыргыч башваткычлар, һөнәргә өйрәтү китаплары, галимнәребезнең фәнни хезмәтләре, ачышлары популяр телдә язылып, китап булып чыгуына мохтаҗ икәнбез.

Халкыбызның тарихы, үткәне, мәдәнияте турында әдәбиятыбыз күптәннән дәшми («Казан утлары»ннан башка). Әдәби әсәрләр булмаса, тарихи материаллар, тарихчыларыбызның хезмәтләре популяр тел белән язылып, китап булып чыксалар, балалар өчен генә түгел, зурларга да бик кызыклы бүләк булыр иде.

Чыгышымның башында: балалар әдәбиятының хәлләре ничегрәк? дигән сорау куйган идем. Балаларга, яшьләргә сәнгатьнең бар төрләрен дә пропагандалау, сәнгать аша аларга рухи тәрбия бирү тиешле югарылыкта түгел, дигән идем.

Әмма әдәбият өлкәсендә дә хәлләр мактанырлык түгел!

Бу өлкәдә эшләүче өметле, сәләтле яшь язучылар бик аз: Р. Харисов, М. Харисов, Р. Мингалимов, Г. Рәхим, Ф. Гыйльметдинов.

Өлкән әдипләребез Г. Әпсәләмов, М. Әмир, Ә. Еники, Г. Гобәй, И. Туктар һәм башка агайлардан замана балалары, яшьләре арасындагы рухи бәрелешләр сурәтләнгән, язмышлар турындагы, фәлсәфәләр бәрелешен чагылдырган яңа хикәяләр, повестьлар, пьесалар, романнар көтәбез.

Фарваз Миңнуллин

# ТУГАН ҖИР ҖЫЛЫСЫ

*Эскизлар*

...Игътибар иткәнегез бармы икән: теге яки бу язучы хакындагы, бигрәк тә күренекле әдипләребезгә багышланган мәкалә һәм монографияләрнең күбесе, кагыйдә буларак, язучы иҗатын даими һәм өзлексез рәвештә үсә, камилләшә бара торган бер процесс итеп күрсәтү, укучыларны шуңа ышандыру максатыннан чыгып язылган була. Хәлбуки, андый бәхетле әдипләр күп түгел. Шәриф Камал, Мирхәйдәр Фәйзи, Кәрим Тинчуриннарны искә төшерегез, бүгенге язучыларыбыз иҗатына күз салыгыз. Әдәби иҗат эше без уйлаганнан һәм аңлатып килгәннән катлаулы һәм каршылыклырак, бай һәм тирәнрәк. Язучы мәңә дигән әйбәт әсәр иҗат итәргә, шуның артыннан ук уңышсызлыкка очрарга мөмкин. Иҗат эше бит ул...

Урта буын прозаикларның сәләтле бер вәкиле Рафаил Төхфәтуллин да үз иҗатында нәкъ әнә шулай борылмалы һәм сикәлтәле юллар буйлап бара. Язучының «Таныш гөрелте» исемле беренче җыентыгы 1954 елда дөнья күргән иде. Аннан бирле шактый гомер узды һәм шул вакыт эчендә ул тагын уннарча җыентык чыгарды, пьеса һәм повестьлар, бик күп лирик парчалар һәм хикәяләр иҗат итте. Шуларны рәттән тезеп, берәм-берәм күздән кичерсәң, арада төрлесе бар: кайчандыр актуаль яңгырап та, заман һәм вакыт сынавын үтә алмаганнары һәм урта куллары, бик яхшылары, бары Рафаил генә яза алырдайлары очрый.

Әмма, әнә шул рәвешчә күпләргә хас юлдан барып, моңа кадәр язган әсәрләре белән укучыларны әле сөендереп, әле көендереп килгән язучыбыз кинәт әллә нишләбрәк китте. Сөендерерлек әсәрләре кимегәннән-кими барды, көендерерлекләре исә торган саен арта төште. Шуңа күрә соңгы елларда без барыбыз да «Җәйге челләдә», «Елга аръягындагы йорт» һәм «Авылдашым Нәби»ләрне, «Йолдызым»нарны язган Төхфәтуллинны сагына башладык.

## ИР ЯЗМЫШЫ — ИЛ ЯЗМЫШЫ

Ихтимал, кайбер кешеләр әле дә хәтерлидер: Рафаил Төхфәтуллин әдәбият дөньясына үзенә зур өметләр баглатып һәм гомум игътибарны тартып, әгәр шулай әйтергә яраса, шаулап килеп керде. Ул — беренче хикәяләре белән үк өлкән әдипләрнең хәерфатихасын алган, аларның игътибарын җәлеп иткән кешеләрнең берсе [1]. Мондый бәхет теләсә кемгә эләкми. Әгәр Р. Төхфәтуллин шуңа лаек булган икән, димәк, бу тикмәгә түгел инде...

Дөньяга чыгуларына күпме еллар узганнан соң, мин язучының беренче хикәяповестьларын кабат кулга алам, бүгенге көн таләпләреннән карап, алар белән яңадан бер танышып чыгам. Ул әсәрләрнең күбесе сугыш еллары һәм сугыштан соңгы авыл

[1] Г. Бәширов. Яңа танышларыбыз. «Совет әдәбияты» журналы. 1955 ел. 4 сан; Ф. Хөсни. Тормыштагыча булсын. «Совет Татарстаны» газетасы. 1954 ел. 31 октябрь һ. б.

тормышына багышланган. Аларда шул авыр һәм кырыс еллар өчен генә хас күренешләр теркәлеп калган: кыйшаеп җимерелергә җиткән терлек абзарлары; утлыкларына «өлешләп кенә салынган» арыш саламын күшәүче ябык сыерлар; рәтләп, җиренә җиткереп эшкәртелмәгән һәм шуңа күрә чүп үлән басып киткән иген кырлары... Бүгенге яшьләрнең күбесе ышанмыйдыр да, ә бит булды, бар иде андый заманнар. Ул чорларны хәзерге авыл тормышы белән чагыштырып караганда, бүгенгебез куанып туймаслык мул, хәйран калырлык шәп!

Авыл тормышында булып узган шул үзгәреш-яңарышлар Рафаил Төхфәтуллинның хикәяләренә дә билгеле бер эз салган. Бүгенге көн, бүгенге авыл тормышы югарылыгыннан торып якын килгәндә, аның ул әсәрләре, гел кояш астында булган чәчәкле яулык кебек, нечкәләр, тоныкланыбрак һәм төскә уңыбрак калганнар, күпмедер күләмдә үткенлекләрен югалтканнар кебек. Ләкин зарар юк. Беренчедән, алар, бүгенге мул тормышны тизрәк якынайту өчен, кешеләрне көрәшергә чакырып, ягъни үз бурычларын һәм вазифаларын үтәп, искерә төшкәннәр. Аннан соң, сәнгать әсәрләренең вакыт яңгырлары да җуеп бетерә алмый торган үзенчәлекле бизәкләре, мәңгелек сыйфат һәм хасиятләре була. Алар, билгеле, Р. Төхфәтуллин әсәрләрендә дә бар.

Гадәттә, әдәби әсәр никадәр камил, никадәр шәп чыкса, аңа уңыш китергән, аны сәнгать әсәре иткән сыйфатлар да шулкадәр күп һәм төрле була. Чыннан да, Рафаил Төхфәтуллинның уңышлы хикәя һәм повестьларын сайлап алыгыз да, шуларның уңышын тәэмин иткән төп сәбәпләрне, характерлы үзенчәлекләрне күрсәтеп карагыз: аларның кайсысы иң әһәмиятле һәм кайсысы иң хәлиткеч! Һәм нинди сыйфатлары, кайсы яклары аның беренче чор әсәрләрен шулай кызыклы иткән! Күплəгән фараз кылулар, төрле-төрле җаваплар арасыннан беренче булып тел очына килгәне: материалны яхшы белү, тормышчанлык. Әйе, бу яктан аңа тел-теш тидереп булмый. Сугыш еллары һәм сугыштан соңгы колхоз тормышын, авыл кешеләрен, аларның ихтыяҗларын һәм теләк-омтылышларын Рафаил Төхфәтуллин кадәр якыннан һәм тирәнтен белгән язучыларыбыз күп түгел шикелле. Никадәр генә сәләтле һәм талантлы әдип саналмасын, әгәр материалын әйбәт белмәсә, аның беренче әсәрләре бу кадәр мәгънәле, фикерле һәм игътибарны җәлеп итәрлек булмаслар иде. Бериш язучылар безне күккә карарга, матурлыкны югарыдан, биектән эзләргә чакырган заманда Р. Төхфәтуллин, тота да, үз юлы белән китә. Ул гүзәллекне тормыш төбеннән күтәреп чыгара, укучыларны җиргә карарга, әйбәт кешеләрне ат караучылар, балта осталары арасыннан эзләргә өйрәтә. Әйтергә кирәк, Р. Төхфәтуллин яклаган алым да нәтиҗәле булып чыга. Ул Фазылҗан һәм Хөсәен абзыйлар, Нәби кебек гади кешеләрнең замандашыбыз дәрәҗәсенә күтәрелгән мөлаем образларын тудыра. Аңа гына хас үзенчәлекле сыйфатларның тагын берсе, бәлки, шушыдыр!..

Рафаил Төхфәтуллин әдәбият мәйданына килгән елларда образларны ике генә төркемгә бүлеп: я гел уңай, я гел тискәре итеп тасвирлау тенденциясе әле шактый көчле була. Бер читтән икенче читкә ташлану очраклары яшәп килә: берәүләр «кимчелексез уңай герой»ны куәтлиләр, икенчеләре, киресенчә, «кимчелекле уңай герой»ны яклап чыгалар. Башка талант ияләре белән бергә, Рафаил катлаулы характерлар, тормышчан типлар иҗат итү юлыннанрак барды кебек. Биредә шулай ук аның хикәяповестьларына хас җылылык, шигърият һәм лиризм хисе, аның әсәрләренең башка үзенчәлекләре турында да сөйләргә булыр иде... Әмма күп санлы һәм күп төрле сыйфатлар арасыннан аеруча әһәмиятле дип уйланган тагын берсенә тукталасы килә. Сүз әдәби герой һәм аны тудырган тормыш шартлары, аларның үзара мөнәсәбәте, бер-берсенә йогынтысы турында бара. Хәтерлисездер: ул еллар әдәбиятында тормыштагы теләсә нинди авырлык һәм кыенлыкларны «эһ тә итми» җиңеп чыгарга, күз ачып йомганчы тормышны яңадан үзгәртеп корырга сәләтле нык ихтыярлы каһарманнар күп иде. Сугышчан рухы, активлыгы белән аерылып торган андый геройларны үзебезнең татар әдәбиятыннан да байтак китерергә була. Ләкин әлеге тәвәккәл геройларның тормыш белән бәйләнеше, ягъни типик хәлләрнең типик характерларга булган йогынтысы, аларның диалектик бердәмлеге сыеграк күрсәтелә иде. Рафаил Төхфәтуллин әнә шул кимчелектән котылу юнәлешендә уңышлы, дөресен әйткәндә, тәүге адымнарны ясашкан язучыларның берсе булды. «Җәйге челләдә», «Елга аръягындагы йорт» кебек әсәрләрнең яңалыгын мин, барыннан да бигрәк, әнә шунда, ягъни геройларның характерын, үз-үзләрен тотышын һәм язмышын тормыш шартла-

рына бәйләп, шулардан аерылгысыз итеп сурәтли белүдә күрәм. Җир һәм кеше, колхоз һәм колхозчы, алар арасындагы мөнәсәбәт, аларның үзара бәйләнеше һәм берберсенә йогынтысы — Рафаил Төхфәтуллин әсәрләренең буеннан-буена кызыл җеп булып сузылган төп сыйфат әнә шул. «Авылдашым Нәби» — шундый әсәрләрнең аеруча характерлысы, аеруча үзенчәлеклесе.

«Кинәт туктаган вагонның дөберт итеп селкенеп куюыннан уянып киттем... Вагонда барысы да йоклыйлар. Тик күрше купеда гына берәү йокысы күптән качкан тавыш белән сөйли:

— ...Менә шулай, дустым... Мин аны сөяргә һич хакым юклыгын да, аны сөяргә һич ярамаганлыгын да яхшы беләм. Ләкин нишлим соң!.. Алда күпме гомерем бардыр, ә йөрәгемне мин инде егерме җиде яшемдә үк кабергә күмдем...

— Да-а...— дип суза калын гына икенче бер тавыш һәм шаулатып иснәп куя.— Күңелле хәл түгел, малай...

— Әйтмә!.. Белмим инде, нәрсә булып бетәр бу... Белмим.

— Син, туган, теге вакытларда, мәктәптә укыганда ук әле, шулайрак идең шул... Ничек кенә дип әйтим!.. Артык нечкә күңелле дип әйтимме... Барысын да күңелеңә артык якын аласың син, барысын да йөрәгеңнән кичерәсең...

Таң алдыннан ишетелгән бу очраклы сөйләшү миңа нигәдер авылдашым Нәбине, аның беренче карауга бик гади дә, әмма катлаулы да булган язмышын хәтеремә төшерде» [1].

Нәби турындагы, бик ягымлы һәм моңлы, бик гади һәм бик катлаулы гүзәл кеше турындагы бу повесть шулай башлана.

Беренче карашка, менә бу бәләкәй генә кереш-увертюраның әллә ни әһәмияте дә юк, баштагы берничә бүлеккә генә җитәрлек кебек аның «пары». Ә чынында алай гына түгел икән. Менә шушы бәләкәй генә керешне язганчы, автор бөтен әйберсен билгеле бер тәртипкә китерергә, сурәтләячәк вакыйгаларын, алган материалын билгеле бер формага, «Авылдашым Нәби»дәгечә формага салырга тиеш булган. Гадәттә, повесть һәм романнарның баштагы 50—60 бите, ягъни әсәрдә катнашачак геройлар һәм сурәтләнәчәк тормыш белән укучыны таныштыруга багышланган бүлекләре, авыр укылучан була. Мондый кереш исә әсәргә беренче юллардан ук алып кереп китә. Шул яктан да аның зур әһәмияте бар.

Аннары шушы керештә үк алда сөйләнәчәк вакыйгаларны искәртерлек, төп образның язмышына ишарә ясарлык урыннар да бар. Барысын да йөрәге аркылы үткәрә торган әлеге нечкә күңелле кеше белән повестьтагы Нәбине чагыштырыгыз! Яки менә егерме җиде яшендә үк йөрәген кабергә күмәргә мәҗбүр булган кеше белән Нәби язмышы арасында күпме уртаклык, күпме якынлык бар. Әлеге кеше кебек үк, Нәби дә соңга калып, бик соңга калып үзенең чын мәхәббәтен таба. Ләкин аның инде мәхәббәткә хакы юк: ул балалар атасы, аның хатыны бар. Бер уйлаганда, никадәр мавыктыргыч һәм кызыктырырлык интрига. Шул ситуацияне ал да, егерме җиде яшендә үк йөрәген кабергә күмәргә мәҗбүр булган, инде олы яшькә җиткән кешенең, гаилә башлыгының трагик язмышын, фаҗигале мәхәббәт тарихын сөйләп чык. Ябырылып укыла торган әсәр чыгарга мөмкин. Әмма шактый эффектлы һәм отышлы тоелган бу интриганы язучы файдаланмый, киресенчә, аны беренче планга куймый. Ул чагында «Авылдашым Нәби» безнең әдәбиятта күп кабатланган, ягъни беркайчан да кеше акылына буйсынмый һәм һәрвакыт соңга калып килә торган мәхәббәт хисләре турындагы гадәти бер әсәр булып калыр иде. Рафаил Төхфәтуллинның максаты зуррак, әһәмиятлерәк. Язучыны кеше гомеренең мәгънәсе кызыксындыра, ул кеше һәм ил язмышы турында уйлана.

Беренче карашка повесть Нәби тормышындагы игътибарга лаеклы аерым вакыйгалар җыелмасын, характерлы эпизодлар тезмәсен хәтерләтә: әнә Сәрвәр белән Нәбинең сугыш елларындагы тормышы, дөнья җимереп дигәндәй эшләп йөргән еллары, әнә өй салу белән бәйләнгән мәшәкатьләр, әнә Нәбинең Сәрвәр үлгәннән соңгы язмышы... Болай ул вакыйгалар арасында әллә ни ныклы эзлеклелек һәм бәйләнеш

[1] Р. Төхфәтуллин. Еллар авазы. Казан. 1966 ел. 5—6 битләр.

тә юк кебек. Әмма игътибар белэнрәк карарга тотындыкмы, әлеге эпизод һәм вакыйгалар арасында эчке бөтенлек, эчке бәйләнеш булуын күрәсең. Сугыш еллары һәм сугыштан соңгы колхоз авылы, ниһаять, партиянең егерменче съездыннан соңгы колхоз авылы фонында әсәрнең үзәгеннән Нәби язмышы, озак уйланулар һәм эзләнүләр нәтиҗәсендә туган замандаш образының язмышы уза. Язучыны Нәби язмышы һәм колхоз тормышы арасындагы тыгыз бәйләнеш кызыксындыра. Әсәрнең буеннан-буена ир язмышы — ил язмышы дигән матур философик идея уздырыла. Буйданбуйга сузылып барып, ул әсәрне бөтен итә, матур итә торган хискә әйләнә. «Авылдашым Нәби» — бер сулыш белән иҗат ителгән, бер тын алуда язылган әсәр.

Сәнгатьнең олы һәм асыл максаты — бер образ аша дөньяны ачу, бер тамчы суда бөтен дөньяны чагылдыру. Үзәк образ никадәр колачлы һәм масштаблы булса, аңа шулкадәр күбрәк «йөк» салып була. «Авылдашым Нәби» — тагын шул хакта сөйли торган әсәрләрнең берсе. Повесть баштанаяк Нәби турында, әсәр беренче юлыннан азакгы юлына кадәр аңа багышланган. Барлык персонажлар, әсәрнең һәр компоненты үзәк образны тулырак, киңрәк итеп ачуга буйсындырылган. Ахырдан әнә шул гади бер конюх сугыш еллары һәм сугыштан соңгы авыл тормышын бөтен катлаулыгы, бөтен каршылыклары белән ача да бирә инде.

Гаҗәеп күп нурларны үзенә җыйган асылташ кебек бу образ. Әйләндергән саен бер яңа, көтелмәгән һәм матур ягы белән күренеп кала. Сүзне Нәбинең хезмәткә мөнәсәбәтеннән башлап китәсе килә.

— Нәбигә эш — кәләш тә, калач та аңар.

Нәби тормышында хезмәтнең роле турында сөйләгәндә, шуннан да төгәл һәм матуррак итеп әйтеп булмас кебек. Бер генә вакытта да аның тик торганын күрмәссез. Аның өчен эшнең ниндидер савыктыру һәм тынычландыру галәмәте бар кебек. Артык шатланса да, нәрсәгә дә булса ачуы чыгып, күңеле бозылса да, Нәби кулына сәнәген ала, себеркесенә тотына. Эш, хезмәт аңа аек акыл, тынычлык алып килә.

Әнә бит, шома телле лекторлар киләләр дә авыл халкын матур сүзләр белән сыйлап китәләр, киләләр дә әллә нинди йөкләмәләргә кул күтәртеп китәләр. Билгеле, аңа карап кына тормышлар рәтләнми. Колхоз авылы һаман бер урында таптана, колхозчылар һаман икмәкпэ туймый. Конюшняның кечкенә өенә җыелып, авыл агайлары әнә шул хакта гәп алып баралар.

> «Моңарчы сүзгә катнашмый... утыручы Шакир ашыкмый гына торып баса да трубкасын саргайган тырнагына кага-кага бәрәүгә дә төбәп карамыйча эре генә әйтә:
>
> — Башыгызны катырып утырмагыз, җәмәгать. Мондый контр сүзләр өчен, беләсезме нәрсә!..— Ул, бармакларын аркылы-торкылы куеп, рәшәткә ясап күрсәтә.— Менә! Кереп утырганыгызны сизми дә калырсыз...
>
> Беразга уңайсыз тынлык урнаша. Нәби, кашларын җыерып, ишеккә карап куя.
>
> — Кайсыгыз ишекне ачык калдырды соң! — ди ул.— Эт кергән ич монда, эт! Фу, сасысы! Борынны яра...
>
> ...Нәби, фонарен алып, атлары янына чыгып китә. Шакир авыз эченнән нәрсәдер мыгырданып кала» [14 бит].

Аңлыйм мин Нәбинең мондый вакытлардагы халәтен. Менә ул уфылдап, ачуына буылырдай булып, атлар аранына килеп керә: маңгайдан җан тирләре агызып, кулларга ике илле сөял үстергән кешенең сүзе контр була димени!!. Каты итеп ябылган ишек тавышына сискәнеп, атлар башларын күтәрәләр, тавыш килгән якка карыйлар. Ә-ә-ә, үзләрен күп еллар буе карап, ашатып килгән хуҗалары Нәби икән... Алар, тынычланып, башларын яңадан тагаракка төртәләр, җайлап кына, салмак кына ашарга тотыналар. Шул салмак күшәү тавышлары тәэсирендә Нәби дә әкренләп суына. Әнә ул инде, атларның муеннарын шапылдата-шапылдата, алар белән җайлап кына сөйләшә-сөйләшә, аларның башакларын рәтләп, ясларын җыештырып йөри. Тынычланып калган, ачуы да басылган кебек. Әйе, эш — кәләш тә, калач та һәм җан тынычлыгы да аңар!

Хезмәт, эш — совет әдәбиятының үзәгендә торган мөһим темаларның берсе. Бездә бу теманың зур традициясе, бу темага язылган бик әйбәт повесть һәм романнар бар. Әмма аны хәп итүдә «Авылдашым Нәби» белән аннан элгәрәк язылган әсәрләр

арасында кайбер аерымлыклар, яңалыклар һәм үзгәлекләр дә күзгә ташлана. Рафаил Төхфәтуллин бу мәсьәләгә я ң а ч а р а к, д ә р е с р ә к һәм т и р ә н р ә к карый кебек.

Элеккерәк чорларда язылган әсәрләрдә хезмәт күбрәк дан һәм батырлык эше итеп карала һәм шулай сурәтләнә иде. Әгәр чыннан да шулай икән, Нәбидән дә данлырак, Нәбидән дә шөһрәтлерәк кеше булмас иде. Сугыш елларында Нәби бригаданың бөтен атларын бирүзе карый. Чәчү җиттеме, Нәби орлыкны басуга үзе ташый, чәчкечкә утырып үзе чәчә. Печән өсте җиттеме, Нәби болынның бер башында, Сәрвәр икенче очында көнгә ярты гар печән чабалар. Ә инде уракка төшкәч, алар бөтенләй дә өйләренә кайтмыйлар... Сугыш бетә, фронтовиклар кайта башлый. Ләкин тормышлар тиз генә, җиңел генә рәтләнмәгәч, кибет алдында күкрәк сугарга яраткан агайларның кайберләре шыпырт кына шәһәрләргә шылу, тегендә-монда акчалырак эшкә урнашу ягын карыйлар. Нәби авылда, үз постында кала. Чөнки ул дан өчен дә, шөһрәт өчен дә эшләми. Тырышмый гына, көч куймый гына тормышның «ал да гөлгә» әйләнмәячәгенә тирәнтен ышанганга, ир язмышы — ил язмышы булуын аңлаганга күрә эшли ул. Нәби һәм Сәрвәр кебекләр көне-төне тырышканга күрә, без авыр сугышта җиңеп чыктык, алар үз-үзләрен аямыйча эшләгәнгә күрә, кыска гына бер вакыт эчендә сугыш китергән авыр яраларны төзәтә алдык. Нәбинең хезмәткә мөнәсәбәтендәге яңалык әнә шунда.

Рафаил Төхфәтуллин әсәрләрендә хезмәткә, хезмәт кешеләренә мөнәсәбәт, гомумән, принципиаль бер төс ала. Кешенең кадере, зурлыгы, бәясе аның хезмәткә мөнәсәбәте, ничек эшләве белән билгеләнә. Шул ук Фазылҗан абзыйларны, Хөсәен абзыйларны без, барыннан да бигрәк, эш кешеләре булганнары өчен хөрмәт итәбез. Гөлзифа кече яшьтән үк эш яратып, эшләп үсә. Шул нәрсә аңарда сабырлык, ныклык тәрбияли, иң кыен вакытларда да Давыт кебек сыгылып төшмәслек көч бирә. Нәби кешене иң әүвәл хезмәт белән сыный, эшләтеп карый. Атка камыт киертә алмый алҗыган лекторны яки Нәбигә печән өяргә булышкан Рәмзияне хәтергә төшерегез. [Үз вакытында «Правда» газетасы «Авылдашым Нәби» повестеның нәкъ әнә шул өзекләрен сайлап баскан иде.] Гайнетдин абзыйның шәһәрдә укый торган төпчек кызы Фәүзияне алып багыгыз («Туган якларым»): болай чибәрнең дә чибәре инде, югыйсә. Аңарга булган мөнәсәбәтне карагыз: ак сөяк булганга, кара эшкә чирканып караганга өнәмиләр бит кызны. Кыскасы, Рафаил Төхфәтуллин әсәрләрендә хезмәткә мөнәсәбәт этик һәм эстетик категория дәрәҗәсенә кадәр күтәрелә. Һәм моның тамырлары ерактан килә бугай...

Без язучы иҗатына туган ил, туган як тормышы, халкының йолалары, гореф-гадәтләре, әхлак нормалары йогынты ясавы, тәэсир итүе турында сөйләргә яратабыз. Үз чиратында аларның һәммәсе тагын да конкретрак нәрсәләргә — язучы чыккан, аның үй-фикерләре формалашкан төбәккә, хәтта язучы туган авылга барып тоташа кебек.

...Арчадан, дүртесе дөньяның дүрт ягына карабрак, дүрт олы юл чыгып китә. Шуларның төньякка карап сузылганы буйлап егерме чакрымлап җир үткәч, Яңа Иябаш исемле бер авылга килеп керерсез. Рафаил Төхфәтуллин туган авыл әнә шул булыр. Иябаштан ерак та түгел, заманында район үзәге саналган Кенәр авылы урнашкан. Шунда унөч ел буе район газетасының секретаре булып эшләгән. Яңа Иябашның күршесендә генә Тукай-Кырлай. Анысында Габдулла Тукай яшәгән. Мәшһүр Казан арты бу!.. Үзе чыккан төбәк белән тирән бәйләнеш. Казан артына хас үзенчәлекләр Рафаил Төхфәтуллин әсәрләрендә тулып ята.

Әй, Казан арты... Синең кешеләреңә булган мәхәббәтен дә Тукай урман-кырларыңа салган: бөек шагыйрь сине чиксез матур итеп күргән. Сагынулары артык көчле булгандыр инде... Тукай шигырьләре буенча күпләр сине дөньяның иң гүзәл почмагы дип күз алдына китерәләр булыр. Кайберәүләр, бәлки, кара урманнар, көмеш сулы чишмәләр илендә кешеләр рәхәттә яшәгәннәр, «җил дә үз вакытында исеп, яңгыр да үз вакытында яуган» бу якларда җирләр бик игелекле һәм мәрхәмәтле булган, дип уйлыйлардыр. Шулай гына булсачы...

Казан артының уңдырышсыз җирләре икмәкне ялындырып һәм бик чамалап биргән. Шуңа да бит бабаларыбыз гомер-гомергә ачлы-туклы яшәгән. Ташлап, чит-ят җирләргә китеп баккан, яңадан әйләнеп кайткан. Хәерчелектән, мохтаҗлыктан котылу

өчен, чабата үргән, чыпта сугып караган. Алай да булмагач, тагын да ярсып һәм үҗәтләнебрәк, әлеге шул көлсу туфраклы, уңдырышсыз җирләргә ябышкан: тәрбияләгән, аңа маңгай тирен түккән.

Җир һәм кеше! Алар икәү һаман бергә булган. Шулай гасырлар узган. Кеше җирне, җир исә, аз-азлап һәм акрынлап, кешеләрне үзгәртә килгән. Кешеләр җирне тыңлаучанрак, мәрхәмәтлерәк һәм уңдырышлырак иткәннәр. Җир аларны хезмәт сөючән, сабыр һәм җитди булырга өйрәткән, аларның карашларын, холык-фигыльләрен формалаштырган. Җир кушуы, җир кодрәте белән туган характер ералгылары буыннан-буынга шулай ныгый, үсә, калыплана барган һәм безнең көннәргә килеп җиткән. Шулай Казан артында үзенә бертөрлерәк табигатьле: шактый басынкы һәм тыйнак, бик тырыш һәм уңган, хезмәт сөючән һәм эшчәннәрне яратучы, җиргә гашыйк кешеләр формалашкан. Эчке бер сиземләү белән мин әнә шулайрак уйлыйм, дөресрәге, әнә шулайрак уйлыйсым килә...

Шул халык үз арасыннан язучылар, мәдәният кешеләре үстереп чыгара торган. Талант белән бергә, аларга үз характерындагы әлеге әйбәт сыйфатларын да ияртеп җибәргән, җирне яратырга, хезмәт кешеләрен олыларга кушкан. Казан артыннан чыккан күренекле әдипләр иҗаты шул турыда сөйли төсле. Рафаил Төхфәтуллин әсәрләрендә дә мин, бөтен татар язучылары өчен хас сыйфатлар белән бергә, шул якларның гүзәл кешеләрен күрәм, аларның дөньяга карашлары, үзара мөнәсәбәтләре белән очрашкандай, барыннан да бигрәк, данлы Казан артының үзгә бер сулышын, рухын тойгандай булам. Ни өчендер, Р. Төхфәтуллин әсәрләрендәге җылылык, гади кешеләргә мәхәббәт, эшчәннәрне сөю әнә шуннан да киләдер кебек...

Бу гүзәл повесть, аның төп герое Нәби турында бик күп һәм бик озак сөйләп булыр иде. Соңгы еллар татар прозасында әдәби образ һәм характерларны юри ваклау, чынбарлыкның кимчелекле һәм кара якларын юри күпертеп сурәтләү, кешенең вак кимчелекләрен һәм йомшак якларын акларга һәм якларга тырышу төсендәге бик үк әйбәт һәм таза булмаган бер тенденция көчәеп алды[1]. Нәби безне хисләренең сафлыгы, тирәнлеге белән дә сокландыра. Сез аның гаилә тормышына, хатыны Сәрвәргә һәм улы Галигә булган мөнәсәбәтенә игътибар итегез: ихтирам итү, үз итү әллә каян сизелеп-аңкып тора. Ә үзенең эче тулы ут... Шушы кеше өйләнгәч, баласы булгач кына, чын мәхәббәтен — Зөһрәне очраткан, сыңар күз белән калган.

Безнең прозада, гомумән, мәхәббәткә багышланган әсәрләр бик күп булса да, арада гаилә мәхәббәтен, ир белән хатын арасындагы мәхәббәтне матур итеп тасвирлап биргәннәре бармак белән генә санарлык. Р. Төхфәтуллин — бу мәсьәләдә аерылып торган язучыларыбызның берсе. Ул, киресенчә, күбрәк гаилә мәхәббәте турында яза һәм, әйтергә кирәк, матур итеп, җылы хисләр уятырлык итеп яза. Аның «Йолдызым» повесте, «Таныш гөрелте», «Эш өстендә», «Өйдә» кебек хикәяләре әнә шул хакта сөйли. Нәбинең хатыны Сәрвәргә булган мөнәсәбәте дә шул фикерне куәтли. Мәхәббәт, турылык кебек мәсьәләләрдә дә гаять саф һәм эчкерсез бер кеше Нәби. Аның әнә өе тузган. Хатыны Сәрвәр көн саен диярлек шул хакта сүз кузгата. Бик тырышса, бер өй салып кермәслек кешемени ул. Сез, бәлки, аның җаны юктыр, кеше төсле аның да юньле өйләрдә яшисе килми дип уйлыйсыздыр! Шүрлек Шакир кебекләрнең, хәрам мал җыеп, кара-каршы икешәр йорт салып керүләрен Нәби күрми, аның шуңа җаны әрнемидер дип уйлыйсыздыр!.. Ничек кенә әле! Шулай булгач, хикмәт нәрсәдә соң! Бәхетнең ул тулы булуын тели, шатлыкта китерә торган байлык кирәк Нәбигә. Ил белән, бөтен колхоз белән байыйсы килә аның. Бу — инде тормышка халык мәнфәгатьләре күзлегеннән карый белү дигән сүз. Бу — инде мәсьәләләргә ил, дәүләт масштабыннан торып карый белү дигән сүз. Менә шуңа күрә дә, автор тормышның бик авыр һәм катлаулы мәсьәләләрен, уңга-сулга сугылмый, ерып чыга, дөрес хәл итә алган. Менә шуңа күрә дә тептән юан, базык гәүдәле, уң күзе мәңгегә йомылып, сул күзе дә кызарыбрак торган, каш турыларын тирән яра җөйләре чуарлаган бу кеше бик тә үз, бик тә сөйкемле күренә безгә. Менә шуңа күрә Нәбигә дә, һәм аның язмышына багышланган бу гүзәл повестьның үзенә дә, мич каршына куеп җылыткан кебек, кулыңны куеп җылытып булыр төсле тоела.

---

[1] Бу мәсьәлә Р. Мостафинның «Бәхәс дәвам итә» исемле мәкаләсендә тулырак яктыртыла («Казан утлары» журналы. 1969 ел. 2 сан. 96—109 битләр).

Нәби — татар совет әдәбиятының тагын да үсүе, тагын да камилләшүе турында сөйли торган, илленче елларда безнең әдәбиятта ясалган сыйфат үзгәреше турында сөйли торган образ. Ул татар совет прозасының үткәндәге бай тәҗрибәсенә нигезләнеп һәм таянып иҗат ителде: аны бары тик шулай гына аңларга һәм аңлатырга мөмкин.

## КАБАТЛАУЛАР ҺӘМ КАБАТЛАНУЛАР...

Рафаил Төхфәтуллин иҗатына хас үзенчәлекләрнең тагын берсе кабатлаулар белән бәйләнгән.

Соңгы елларда тәнкыйть язучыны бер урында таптануда, үз-үзен кабатлауда да гаепли башлады. Әйе, аның иҗатында кабатлаулар чыннан да бар. Ләкин бу аның соңгы әсәрләренә генә хас бер үзенчәлек түгел. Кабатлаулар күптәннән килә. Ихтимал, элекке әсәрләрендә күбрәктер дә әле.

Рафаил Төхфәтуллин әсәрләрендә кабатланган нәрсәләрнең барысын да санап күрсәтеп чыгу өчен озак вакыт, күп урын кирәк булыр иде. Аның хикәя-повестьларында бер-берсенә охшаган аерым күренешләр һәм эпизодлар очрый, охшаш ситуацияләр бар, кабатланган тема-проблемалар әллә никадәр. Аның әсәрләрендә кабатланган образлар, берсе икенчесенә охшаган, берсе икенчесен хәтерләткән персонажлар бик күп [1]. Моны ничек аңлатырга соң!

Авторның «Еллар авазы» исемле хикәяләр җыентыгына язган кереш сүзендә Гариф Ахунов бу мәсьәләгә бераз ачыклык кертә шикелле. Ул болай яза.

«Кинәт безнең егетебез (үзенең яңа — Ф. М.) повестен бастырудан баш тартты. Бик сәер иде бу. Аңлашылмый иде... Бер ел уздымы икән, икеме — аның бер-бер артлы «Таныш гөрелте», «Яңа магазинда, «Җәйге чилләдә» хикәяләре басылып чыкты. Һәм без кинәт аңлап алдык: үз-үзенә таләпчән яшь автор повесть материалын туган авылы турындагы хикәяләр циклы итеп бирергә уйлаган икән».

Дөрес, «Яңа магазинда» һәм «Җәйге чилләдә» кебек икесе ике тональностьтагы, икесе ике характердагы әсәрләрнең кайчандыр бер повесть эчендә булуларына ышану кыенрак. Ләкин ул кадәресе әллә ни принципиаль мәсьәлә түгел. «Яңа магазинда» белән «Җәйге чилләдә» бер әсәр эчендә була алмаса, «Елга аръягындагы йорт», «Күләгәгә койма», «Җәйге чилләдә» кебекләре бер әсәрдән аерылып чыккан булырга мөмкиннәр бит әле. Әгәр шулай икән, бу инде, чыннан да, мәсьәләгә күпмедер ачыклык кертү дигән сүз. Димәк, Рафаил Төхфәтуллин хикәяләрендәге кабатлануларның бер өлеше аларның кайчандыр бер повесть тукымасында булулары белән аңлатыла икән.

Эзли китсәң, шундый характердагы башка сәбәпләр дә табылыр иде, бәлки. Шулай да төп сәбәп бүтәндә, язучы иҗатының башка бер үзенчәлегендә булса кирәк. Рафаил Төхфәтуллинны мин гомер буе бер генә әсәргә гашыйк, бер генә китап укый торган кеше белән чагыштырыр идем. Аның да даими рәвештә, бертуктаусыз өйрәнә торган үз темасы, мәңгелек китабы бар. Ул — колхоз авылы һәм колхоз-

---

[1] Куллану ешлыкларына, башкарган вазифаларына карап, андый образларның үзләрен берничә төркемгә бүләргә мөмкин.

Рафаил Төхфәтуллин әсәрләрендә фон өчен генә алынган эпизодик персонажлар еш кабатлана. Метер Мәхмүзә, Фазылҗан абзыйның «төкереккә тайган» кияве, Әгъләм, Кашшаф әнә шундыйлар. Болар арасыннан аеруча еш кабатланганы һәм зуррак, үзгәрәк йөк тартканы — колхоз председателе Кашшаф.

Бер әсәрдә күренеп кенә киткән эпизодик персонажлар икенче бер урында, икенче бер әсәрдә ярыйсы ук тәфсилле һәм тулы тасвирланалар. Мисал рәвешендә Хөббениса карчык, аның күрше егете Сәгыйть, Хөсәен абзый, Рәмзия кебек образларны алырга мөмкин. «Кунак егет»тә Хөббениса әбинең, «Авылдашым Нәби»дә Хөсәен абзыйның һәм Сәгыйтнең, «Йолдызым» повестенда Рәмзиянең исемнәре генә күренеп китә. Инде килеп «Җәйге чилләдә» Хөббениса, «Авылдашым Нәби»дә Рәмзия бик матур һәм тулы ачылалар. Ә Хөсәен абзый белән Сәгыйтнең һәркайсына автор аерым-аерым хикәяләр багышлый («Елга аръягындагы йорт», «Кунак егет»).

Әсәрдән әсәргә үсә, үзгәрә килә торган образлар да бар. Мондыйларының аеруча кызыклысы, мөгаен, Фазылҗан абзыйдыр.

Моннан тыш болай, һәрберсе мөстәкыйль, үзенә аерым образ булып та, характер сыйфатлары, үзләренең асыллары белән бер-берсенә охшаганнары байтак. Мисал өчен «Йолдызым»дагы Шәрәфи белән «Тамчылар ни сөйли» повестендагы Нуруллалны, яки шул ук әсәрләрдәге Җиһангир һәм Мирсәетне үзара янәшә куеп, чагыштырып карарга мөмкин...

чылар тормышы, җир язмышы. Язучы һаман-һаман шулар турында, аларның язмышы өчен борчылып һәм уйланып яшәде. Шуңа күрә бер үк мәсьәләләргә кабат-кабат кайтырга мәҗбүр булды. Бу исә үз чиратында әлеге кабатлаулар диган нәрсәне китереп чыгарды. Әмма шуны истә тотарга кирәк: аның әсәрләрендә үзгәрешсез, нәкъ шул көенчә үк кабатланган ситуацияләр һәм эпизодлар да, темалар һәм проблемалар да, образлар һәм персонажлар да юк диярлек. Аларны авторның һаман тирәнәя, хакыйкатькә якыная баруын раслый торган мисаллар итеп карарга мөмкин. «Йолдызым» — бу яктан аеруча характерлы әсәрләрнең берсе.

«Авылдашым Нәби» кебек үк, «Йолдызым» повесте да үткәннәрне искә төшерү алымы белән язылган.

«— Әни, әни дим! Нигә минем исемемне Йолдыз дип куштыгыз! Әни дим...

— Нигәме!..

...Уйлар, уйлар, кайларга йөгердегез сез!..»

Кызының әлеге соравы Гөлзифаны үткән бөтен тормышын хәтерләргә мәҗбүр итә. Шулай әсәр башланып китә.

«Авылдашым Нәби»дәге кебек үк, монда да ил һәм кеше язмышы мәсьәләсе үзәккә куела, аларның аерылгысыз булуына басым ясала. Гөлзифаның язмышы да Нәбинекенә охшаш. Аның да яшьлеге авыр сугыш елларына һәм сугыштан соңгы кырыс чорларга туры килә. Әнә шул авырлыкларны җиңеп, аның характеры формалаша, торган саен чыныга, ныгый төшә. Бүлектән-бүлеккә, вакыйгадан-вакыйгага Гөлзифа образы эреләнә, әгәр шулай әйтергә ярага, монументальләшә бара.

Әмма, «Авылдашым Нәби»дәк аермалы буларак, «Йолдызым» повесте — күп сызыклы, күп планлы әсәр. Биредә Гөлзифадан калган образларга да тирән эчтәлек, зур мәгънә салынган. Аннан соң, күтәргән мәсьәләсе, аның зурлыгы, тирәнлеге һәм чишелеше ягыннан караганда да, бу — Рафаил Төхфәтуллинның иң әһәмиятле, иң җитди әсәре.

«Йолдызым» Рафаил Төхфәтуллинның сугыш еллары һәм аннан соңгы авыл тормышына караган әсәрләренең соңгы сүз булып исәпләнерлеге, йомгак рәвешендә йөртелерлеге. Элекке әсәрләрендә кагылып кына узылган тормыш материалы биредә тагын да киңрәк, тулырак һәм тирәнрәк итеп яктыртыла. Моңарчы язган әсәрләрендә кузгатылып та дөрес җавап таба, дөрес хәл итеп җиткерә алмый калган аерым мәсьәләләргә автор биредә кабат әйләнеп кайта.

Шундый мәсьәләләрнең иң кыены һәм иң четреклесе — колхоз авылын аякка бастыру, аны үргә алып менү. Колхоз тормышындагы кыенлык һәм авырлыклар хакында Р. Төхфәтуллин «Йолдызым» повестена кадәр дә күп язды. Ләкин аларның сәбәпләрен, авырлыклардан чыгу юлларын һәрвакытта да дөрес кенә күрсәтте, дип әйтеп булмый. Күп кенә әсәрләрендә гаепне, нигезтөр, начар председательләр өстенә өяргә тырышу да сизелмәде түгел. Юньле председатель булса, колхозлар бик тиз аякка басар, колхозчылар рәхәт яшәр иде, янәсе. Аның хикәяләрендә әйбәт председатель Кашшаф бер дә юкка шулай еш кабатланмый, билгеле...

«Йолдызым» повестенда язучы шул ук мәсьәләне яңадан күтәрә һәм шактый уңышлы хәл итә шикелле. Гөлзифалар колхозының язмышы бер заман бик тә әйбәт кешеләр кулына күчә: председатель итеп Шәрәфи абзый сайлана, Гөлзифаның үзен бригадир итеп куялар. ВЛКСМның район комитеты секретаре Мөнир Гарәпшин дә искиткеч шәп кеше, югыйсә. Әмма аңа карап кына колхоз әллә кая китми. Алга китү өчен Үзәк Комитетның мәгълүм пленумнары, партиянең XX съезды булып узу кирәк була. Хикмәт яхшы председательдә генә түгел икән шул әле...

Әсәрдән-әсәргә кабатланып килгән мәсьәләләрнең тагын берсе Давыт линиясе, повестьтагы Давыт образы белән бәйләнгән. Колхоз эшен ташлап шәһәргә качкан, тегендә-монда китеп, акчалырак эшкә урнашу ягын караган кешеләр хакында Рафаил Төхфәтуллин шулай ук аз язмады: «Авылдашым Нәби», «Нишләргә!», «Өйдә», «Туган якларым» кебек әсәрләрдә дә бар андыйлар. «Кунак егет» исемле хикәя исә баштанаяк гел шул турыда гына. Чорына, вакытына карап, авторның мондый кешеләргә булган мөнәсәбәте үзгәрә тора. Авыл үзе эшче кулларга тилмергән бер вакытта шәһәргә качучыларны язучы, хәтта чама тойгысын үк онытып ташлап, кискен һәм рәхимсез төстә фаш итә («Кунак егет»). Инде эшләр бераз рәтләнгәннән соң, әйтик,

чирәм җирләрне үзләштерү заманнары башлангач, андыйларны ул, киресенчә, мактап һәм хуплап бетерә алмый («Туган якларым»). Кыскасы, бу мәсьәләгә дә әдип колхоз һәм халык мәнфәгатьләрен яклау ноктасыннан чыгып якын килә барды. Инде килеп, «Йолдызым»да Давыт образы белән бәйләнештә, шул ук мәсьәлә яңадан күтәрелә.

Безнең матбугатта бу образ ничектер берьяклырак, гел тискәре кеше итеп кенә каралды кебек. Безнеңчә, ул алай ук беткән җан түгел. Кайчандыр Давыт авылдагы иң алдынгы укучылардан саналып йөртелгән. Халык арасында абруе да зур гына үзенең, намуслы һәм әдәпле дә кебек. Җае, кәефе килгәндә, умырттырып, җир җимертеп эшләүдән дә курыкмый, кулыннан эш тә килә Давытның. Хәер, Гөлзифа кебек чибәр һәм уңган бер кызны үзенә карата, аның мәхәббәтен яулый алган егет ничек начар булсын да, нишләп беткән баш булсын, ди. Әгәр тормышлары җай гына барса, кыенлыклар белән очрашырга туры килмәсә, кем белә, алар әйбәт кенә яшәгән дә булырлар иде. Кызганычка каршы, барыр юлларында авырлыклар очрый. Иң кыен вакытта Давыт сыната, Гөлзифа белән чагыштырганда, аның умыртка сөяге сыеграк булып чыга. Тормыш авырлыклары алдында куркып, каушап калган Давыт шәһәргә качып котылмакчы була. Нәтиҗәдә Гөлзифасын да, баласын да һәм үз-үзен дә югалта.

Билгеле, монда бер Давытны гына гаепләү дөрес булмас иде. Язучы да андый юлдан бармый, шул ук вакытта Давытны акларга да җыенмый. Әйе, Давыт кебек, авылдан шәһәргә качып, анда кыенга туры килә башласа, тәртәне яңадан авылга борырга яратучыларны аклап та, аларга ышанып-таянып та булмый. Ышаныч Нәби, Гөлзифа кебекләрдә...

Рафаил Төхфәтуллинның «Йолдызым»га кадәр язылган әсәрләрендә, «Күләгә» исемле хикәядәге Касыймны исәпләмәгәндә, тәмам эшләнеп, ачыкланып җиткән тискәре образлар юк диярлек. «Йолдызым» бу яктан да аерылып тора. Колхоз председателе Мортазаны, район вәкиле Хәмдиевне, я булмаса Идрисовны алыгыз: автор һәр образның үзенә генә хас характерлы якларын тапкан. Иң мөһиме һәм иң әһәмиятлесе шунда: ул әлеге образларның фәлсәфәсен, аларны чынбарлык белән бәйли торган җепләрне күрсәтә алган.

«Йолдызым» повестеның идея-проблемасы һәм образлар системасы безнең тәнкыйтьтә шактый тулы һәм дөрес яктыртылды. Әсәрнең ул якларына тукталып тормастан, мин тагын бары бер генә мәсьәлә турында берничә сүз әйтмәкче булам. Анысы — әсәрнең икенче кисәге, дөресрәге, Гөлзифа язмышын сузу, бүгенге бәхетле көнкәргә кадәр китереп җиткерү, әсәрне бәхетле итеп тәмамлау турында.

Хронологик тәртиптә вакыйга сөйләүгә корылган, күпме сузсаң да, сузыла торган әсәрләр була. Бәхетле тәмамланыш андый әсәрләр өчен, бәлки ярыйдыр да. «Йолдызым» — махсус бер проблемасы булган әсәр. Шул мәсьәлә хәл ителгәч, әсәрне сузу эшне боза гына, Гөлзифа тормышның авыр сынауларын уңышлы узды, авырлыклар белән көрәштә, кеше буларак, тагын да камилләшә һәм мөлаемләнә төште. Автор язып тормаса да, без инде аның моннан соңгы гомер юлын да намус белән узачагына аз гына да шикләнмибез. Шулкадәр көчле әсәр язып, шулкадәр әйбәт образ тудырып та, авторның тиешле урында нокта куя белмәве — бик кызганыч!..

## ТАМЧЫЛАР НИ СӨЙЛИ

Рафаил Төхфәтуллин турында, аның әсәрләренең үзенчәлекләре, көчле һәм көчсез яклары турында күңелдә йөрткән, әйтәсе килгән сүзләр шулкадәр күп кебек иде. Һич югы, шуларның яртысын гына булса да кәгазьгә төшерә, башкаларга да барып җитәрлек итеп аңлата алдыммы икән!..

Рафаил Төхфәтуллин әсәрләрен яңадан күңел иләге аша уздырам: нәрсәләр онытылып калган, нәрсәләргә игътибар ителмәгән. Бер уйласаң, әдип иҗатының баштагы дәвере дә гел уңышлардан гына тормаган инде. Шулай да сугыш еллары һәм сугыштан соңгы авыл тормышы турында язганда, Рафаил Төхфәтуллинның каләме тиңдәшсез, беркемгә дә бирешмәслек. Шул чор тормышы, аның кешеләре хакында никадәр әсәр иҗат итте, арада әйбәтләре, искиткеч әйбәтләре күпме иде. Һәрберсе дөнья бәясенә торырлык әдәби детальләр, тотып-капшап карыйсы килерлек дәрәҗәдә җанлы

һәм тормышчан булып чыккан образлар дисеңме, күңелнең әллә кай төшләренә барып җитәрлек җылылык кирәкме, гаять актуаль, барлык кешеләрне борчып-уйландырып килгән мәсьәләләр дисеңме — һәммәсе дә бар иде аның хикәя-повестьларында. Акрынлык белән булса да, әсәрдән-әсәргә, елдан-елга язучының колачы, тәвәккәллеге һәм кыюлыгы да арта барды, тормыш күренешләренең, кеше «җанының» асылына үтеп керү сәләте дә үсте. «Йолдызым» повестен шул тормышка, шул чорга караган әсәрләренең иң югары ноктасы дип санарга була. Сугыш һәм сугыштан соңгы колхоз авылына караган күзәтүләренең иң мөһим, иң әһәмиятлеләрен автор нигездә шушы әсәргә кертеп бетерде, аның авыл тормышы турындагы борчылу-уйлануларының да иң зур һәм иң төп өлеше шушы повестька сыеп бетте дияргә мөмкин.

Менә шуннан соң язучы алдына бөтен җитдилеге белән яңа бер мәсьәлә — партиянең XX съездыннан соңгы колхоз авылын, бүгенге тормышны сурәтләү бурычы килеп басты. Авылның элекке хәлен биш бармагыдай яхшы белгән автор, артык азапланмый һәм җәфаланмый гына, аның бүгенгесенә дә күчеп китә алыр, дип көтәргә бөтен нигезләр бар иде. Хәлбуки, алай булып чыкмады. Мәсьәлә яңаны сурәтләүгә килеп җиткәч, эш колхоз авылының элекке чорыннан бүгенгесенә күчүгә килеп терәлгәч, әллә нәрсә булды: Рафаил Төхфәтуллин, иске белән яңаны аерган межа уртасында туктап, аптырап һәм каушап, сискәнеп һәм югалып калгандай күренде. Әллә яңа авыл искиткеч кызу адымнар белән алга китеп, язучы тормыштагы яңалыклар артыннан өлгерә алмый башладымы икән!.. Әнә бит бүгенге авыл тормышында элек-электән ул күреп, гадәтләнеп килгән мәсьәләләрнең, гомер-гомердән аны борчып, кайгыга салып торган кимчелекләрнең берсе дә калмаган шикелле. Әллә яңа тормышның үз каршылыкларын, үзенә генә хас якларын вакытында күреп җиткерә һәм шуларны аңлатырлык ачкыч табып бетерә алмадымы!.. Алай булуы да бик мөмкин.

Әмма ни генә булмасын, көннән-көн бер нәрсә ачыклана барды: иске запас бетеп килә, ә яңасы әле тупланмаган иде, юк иде. Һәм әдип, аптырап, иске белән яңаны аерган, бер үк вакытта аларны берләштергән дә ызанда туктап калды. «Тамчылар ни сөйли» әнә шулай язылган, дөресрәге, бер аяк белән иске авылда торып, икенчесе белән бу якка басып иҗат ителгән әсәр дияр идем мин. Автор монда, берьяктан, баштагы әсәрләренә сыеп бетмәгән, анда-монда посып калган элекке материалдан файдалана, шул ук вакытта ике аяклап, ныгытып торып бу якка чыгарга да омтылыш ясап карый.

Минем үземә электән калганы күбрәк ошады. Байтагы билгеле, кабатланган нәрсәләр булса да, алары ныграк тәэсир итә, аларда Төхфәтуллин кулы нык сизелә. Чыннан да, бер караганда, гаҗәеп оста язылган эпизод һәм күренешләр, укучыны дулкынландыра торган гыйбрәтле язмышлар әллә никадәр анда. Болай үзе «Йолдызым»дагы Шәрәфи абыйны нык хәтерләтсә дә, шактый оста һәм тулы эшләнгән, укучы күңелендә җылы тәэсир калдырырлык Нурулла образы бар. Шакай Шәми, аның үткән тормыш юлын ачыклауга бәйле чигенешләр дә ярыйсы ук әйбәт эшләнгән. Автор бераз соңарган кебек, туйдан соң дөмбергә кебегрәк яңгырый-яңгыравын. Шулай да укырлык итеп, мавыктыргыч итеп язылган.

Мирсәетнең яшьлеген, Мөршидә белән алар арасындагы беренче саф мәхәббәт хисләрен, озак еллардан соң аларның кабат очрашуларын, Мөршиданең ире шофер Гарәфинең, көнләшүдән, кая барырга, нишләргә белми аптырап йөрүен тасвирлаган битләрне шулай ук салкын кан белән укып булмый.

Әмма шулай да минем үземә аеруча нык ошаганы, аеруча нык тәэсир иткәне Тәслимә образы, Тәслимә тормышы булды. Рафаил Төхфәтуллин каләменең гаҗәеп көче һәм мөмкинлекләре хакында сөйли кебек бу образ.

Менә шушы җитди әсәрдә, бик күп матур урыннары, драматик язмышлы, алай гына да түгел, олы язмышлы кешеләре булган повестьта үзәккә Ильяс кебек образ куелган, барлык җепләр аңа тапшырылган, аның кулына тоттырылган. Һич икеләнми әйтергә мөмкин: Ильяс — болай шактый кызыклы уйланган образ. Бу образның тамырлары соңгы еллар әдәбиятында барган киеренке эзләнүләргә барып тоташа.

Бүгенге Татарстанның географик картасы үзгәрде, татар халкының тормыш-көнкүреш, аң-белем дәрәҗәсе бик нык үсте. Бүгенге чынбарлыкны нинди герой белән тулырак сурәтләп булыр иде икән! Кем ул, нинди кеше ул бүгенге әдәбиятның типик уңай герое! Кемнәр, нинди профессия кешеләре арасыннан эзләргә аны! Зур эрудицияле, югары белемле яшь интеллигентмы ул!.. Космик корабльләр чорында әдә-

биятның уңай герое, бәлки, акыл хезмәте кешеләре, галимнәр булырга тиештер!.. Соңгы еллар әдәбиятында шундый характердагырак эзләнүләр барды. Һәр язучы, үзенең әдәби-эстетик карашларына, талант, сәләт дәрәҗәсенә карап, әлеге образны тудыруда катнашты, зур бинаның бер кирпечен салышты. Рафаил Төхфәтуллин аны әнә Ильяс кебегрәк яшь кеше итеп күз алдына китергән. Ахырга кадәр уңышлы эшләнгән очракта, бу образ бүгенге колхоз авылын, хәзерге яшьләрнең характерларын, теләк-омтылышларын, уй-фикерләрен шактый тулы һәм дөрес чагылдыра алыр иде.

Яшермим, укучы буларак, минем үземә әле авыл мәктәбендә укыган чагында ук, апасына ачу итепме, әллә бригадир Нурулла абыйсын кызганыпмы, колхоз эшенә йөри башлаган Ильяс, мышкылдый-мышкылдый, авыр капчыклар тәгәрәтәп, маңгай һәм арка тирләрен агызган, тургайлар җырын тыңларга яраткан бәләкәй малай бик ошый. Үсә төшеп, урта мәктәпкә йөри башлаган Ильясның да әйбәт сыйфатлары аз түгел: намуслы булуы, принципиальлеге, кайбер башка яклары...

Әмма еллар үткән, яше арткан саен, образ буларак, Ильяс гел кечерәя бара. Гәүдәгә үсә тора, күзгә күренеп көч-куәт керә тора егеткә. Әмма акылы белән, дөньяга карашы, тормыш мәсьәләләрен аңлау дәрәҗәсе белән Ильяс һаман сабый бала, башлангыч класс укучысы булып кала. Акыл ягыннан бигрәк үсми инде, шулкадәр гади мәсьәләләр алдында аптырап кала инде Ильяс! Бигрәк беркатлы, бигрәк «йпрактичный» инде: яшьли тормышның ачысын-төчесен күреп, колхоз эшен эшләп үскән авыл малае дип тә уйламассың. Буйга үскән, гәүдәгә калынайган саен, аның теләк-омтылышлары, идеаллары вагая, кечерәя, примитивлаша бара кебек.

Менә шул кешегә бөтен бер әсәрнең, күпме кешенең язмышы тапшырылган. Кызганычка каршы, Ильяс андый авыр йөкне күтәрә-сөйри алырлык образ түгел шул.

Рафаил Төхфәтуллинның моңа кадәр язган әсәрләре арасында да форма, архитектоника бөтенлеге, сюжет-композиция төзеклеге белән аерылып торганнары күп түгел иде. Бу яктан ул әллә ни мактана алмый. Аның каравы, ул әсәрләрне уңышлы эшләнгән үзәк герой бөтен итә, авторның тормыш турындагы төпле һәм кыю уйланулары кызыклы итә иде. Аның геройларына йөкләнгән вазифа бермә-бер зур: алар — сюжет-композиция төзү чарасы да, чынбарлыкны танып-белү чарасы да. Шуңа күрә үзәк геройның уңышлы сайлануы, масштаблы һәм күп сыйдырышлы булуы Рафаил Төхфәтуллин әсәрләрендә хәлиткеч әһәмияткә ия. «Тамчылар ни сөйли» повестен таркау иткән төп сәбәп, минемчә, нәкъ әнә шунда — Ильяс образының эшләнеп җитмәгән булуында, кызыклы омтылыш кына булып калуында. Үзәк герой шундый булгач, әсәрне бернәрсә дә, хәтта бик җылы итеп тасвирланган тургайлар җыры һәм язгы тамчылар да коткарып кала алмаган. Тамчылар әнә шул хакта да сөйли.

Үкенечкә каршы дип әйтергә кирәктер инде, Рафаил Төхфәтуллинның «Агымсу» исемле яңа повесте да укучыларны куандырып җиткерә алмады.

«Тамчылар ни сөйли» кебек ук, «Агымсу» повестен да мин межа уртасында торыбрак, ләкин беренче әсәр уңае белән телгә алынган межада түгел, бәлки игенче белән нефтьчене аерган һәм шул ук вакытта аларны үзара якынайткан да межада торып язылган әсәр дияр идем.

1959 елда язучы Яңа Кенәрдән нефтьчеләр шәһәре Әлмәткә күчеп киткән иде. Монда килгәч, аны авыл кешеләре белән нефтьчеләрнең үзара мөнәсәбәтләре аеруча нык кызыксындыра башлый. «Агымсу» — әнә шул юнәлештәге беренче кызыклы омтылыш, беренче адымны ясап карау, Рафаил Төхфәтуллинның колхоз темасыннан нефтьчеләр ягына күчеп баруын раслый торган әсәр.

Повестьның үзендә бу мәсьәлә күбрәк Хәйдәрнең әтисе һәм нефтьче-мастер Борһан ага образлары беләнрәк бәйләнеп бирелә. Ләкин ул шактый декларатив чыккан, әсәрнең буеннан-буена сузылып барырлык, бөтен әсәргә мәгълүм бер фәлсәфи яңгыраш бирерлек дәрәҗәдә түгел. Шулай булмый хәле дә юк. Игенче мәнфәгатен якларга, колхоз ягын каерырга тиешле кешебез — Хәйдәрнең әтисе үзе дә хәзергә җирдән ерактарак, сәүдә тирәсендәрәк йөргән бер кеше. Нефть темасына исә автор яңа керел, иләшеп кенә бара. 1962 елда Р. Төхфәтуллин, атаклы нефть мастеры Корбан Вәлиевкә багышлап, «Карт оста куллары» исемле бер очерк язган иде. Нефтьчеләр тормышы «Агымсу» повестенда да әнә шул очеркта сурәтләнгәннән әллә ни ерак китмәгән.

Шул нәрсә, ягъни яза торган әйберне тирәнтен белмәү «Агымсу»ның стилендә ук

сизелә. Гадәттә, Р. Төхфәтуллин әсәрләрендә вакыйга үзе түгел, бәлки теге яки бу вакыйганы сөйләү дәвамында аның укучыларга әйтә торган фикерләре, күзәтү һәм уйланулары кызыклы була торган иде. Кызганычка каршы, авторның соңгы әсәрләрендә вакыйга сөйләү, вакыйганың тышкы ягы өстенлек ала бара. Димәк, язучының тормыш, халык язмышы турында борчылып, туктаусыз кайгыртып яшәве сүрелә төшкән. Шуңа күрә әйтер сүзе дә азая бара.

Дөрес, беренче коймак төерле була, диләр. «Агымсу» — авторның авыл һәм нефть темасын яктырту юлындагы беренче коймагы. Бу темага караган икенче, өченче повестьлары, һичшиксез, тирәнрәк, уңышлырак чыгар дип ышанасы килә.

* * *

Нишлисең, «Авылдашым Нәби», «Йолдызым»нар белән чагыштырганда, «Тамчылар ни сөйли» дә, «Агымсу» повесте да таркаурак һәм зәгыйфьрәк чыктылар шул. Сәбәпләрен төрле кеше төрлечә аңлата. Берәүләр: гөлне үз туфрагыннан аерып, чит-ят җирләргә күчереп утыртырга ярамаган кебек, Рафаил Төхфәтуллинны да авылдан шәһәргә, колхоз темасыннан нефтькә җибәрергә кирәкмәс иде, диләр. Анысы дөрес, гөл ияләнгән туфракта җиңелрәк үсә үсуен. Үз туфрагы, язардай темасы һәм материалы булган язучыларны, һәртөрле шаукымнарга ияреп, бер туфрактан икенче туфракка күчереп йөртүләр белән, бәлки, артык мавыкмаска кирәктер. Әмма, Р. Төхфәтуллинга килгәндә, хикмәт әгәр шунда гына икән, аңа авыл юлын берәү дә бикләп куймаган бит. Ишетүемчә, автор үзе дә авылдан киткәненә әллә ни үкенми һәм аны иҗатына тискәре йогынты ясарлык җитди сәбәп итеп санамый кебек.

Хикмәт, бәлки, бүгенге чынбарлык каршында каушап калуда, бүгенге тормыш тудырган яңалыкларны һәм каршылыкларны аңлый һәм аңлата алмый иза чигүдә, аларга яраклы ачкыч таба алмаудадыр!.. Чыннан да, әле нефть якларына күчеп киткәнче үк Р. Төхфәтуллин егерменче съезддан соңгы авыл, бүгенге колхоз тормышы турында «Авылдашым Нәби»ләр дәрәҗәсендә торырлык әсәр иҗат итә алмады бит. Тормыш гаять катлаулы һәм каршылыклы нәрсә, шуларның һәммәсенә ярардай ачкыч табу, индидер гомуми бер караш булдыру, күрәсең, бик кыендыр. Төхфәтуллин иҗатындагы уңышсызлыклар, бәлки, шуның белән аңлатыладыр!..

Бәлки, бу — зур һөҗүмгә күчәр алдыннан бер тынып алу чоры, иҗади үсеш юлында яңа сикереш ясар, сыйфат үзгәрешләренә китерердәй җитди адым ясар алдыннан бер хәл җыеп алу гынадыр! Шулай гына була күрсен иде!

# АЛЫПКУЛНЫҢ СИГЕЗЕНЧЕ УЛЫ

Шигырьләренең берсендә Муса болай дип язган иде:

Әкияттәге серле йомгак булып
Җырым калды сүтелеп юлымда,
Сез табарсыз килеп шушы эздән
Минем соңгы йөрәк җырымда...

Нәкъ шулай булды да. Башта, җырлары калдырган эздән барып, каләмдәш дуслары шагыйрьнең үзен таптылар: Моабитның салкын базларында җәфа чиккән, әмма бирешмәгән һәм буйсынмаган халык улының фаҗигале язмышын ачыкладылар, курку белмәс кайнар йөрәкле шагыйрьнең тиңдәшсез батырлыгына сокландылар. Аннан, герой-шагыйрь истәлегенә багышлап, бик күп мәкалә-очерклар, шигырь-поэмалар, җырлар язылды, музыка һәм сынлы сәнгать әсәрләре иҗат ителде...

Муса Җәлилгә багышланган сәнгать әсәрләренең саны һаман саен ишәя, тулылана тора. Узган ел матбугатта чыккан китаплар исәбенә әлеге исемлек тагын берничә санга арта төште. Шулар арасыннан Шәйхи Маннурның «Муса» исемле романын[1] аерым рәвештә билгеләп үтәсе килә.

Шәйхи Маннур, мөгаен, шагыйрь Муса Җәлилне иң якыннан белгән, иң яхшы аңлаган кешеләрнең берседер. Автор үзе әйтмешли, аларның яшьлек еллары бер мәйданда узган: бергә эшләгән, бергәләшеп язган, әдәби бәхәсләрне дә бергә үткәргән, вакыты белән авыр сынауларны да бергә кичергән алар. Бу хәл исә шагыйрь Ш. Маннурга роман язу кебек җаваплы һәм авыр эшкә алынырга кыюлык һәм 47 табак күләмендәге бу калын романны укышлы итеп язып чыгарлык көч биргән.

Роман Мусаның Казан рабфагын бетереп, Орск шәһәренә комсомол эшенә китеп бару мәшәкатьләрен сурәтләүдән башланып китә.

Казанда нишләп ятсын ди ул! Аңа күп җирләрне күрергә кирәк, шигърият илһамын ул нәкъ әнә шулар арасыннан табарга тиеш. Китәр алдыннан, йомышларын бетерер, кордашлары белән саубуллашыр өчен, ул нәшриятка кереп чыгарга уйлый. Керсә, ни күзе белән күрсен, аңа:

— Рәхим ит, яшь шагыйрь, беренче китабың,— дип, зур гына төргәк сузалар.

Бу — Мусаның «Барабыз» исемле шигырьләр җыентыгы була. Беренче карлыгач, беренче китап! Бу зур шатлыкны яшь автор нәрсә белән дә чагыштыра алмыйча, төрле уйларга бирелеп, гомуми торакка кайтып җиткәнен сизми дә кала. Караса, кулындагы китапларын юлда очраган дусларына бирә-бирә бетерә дә язган икән!..

Әсәр әнә шулай 19 яшьлек Муса турында хикәяләүдән башланып китә. Әмма бу әле аның бала чаклары, Мостафа авылында үткән еллары, яшьлек ташкыны белән тулы Мәскәү чоры төшеп калган икән дигән сүз түгел. Автор Мусаның бала чагын һәм яшьлек романтикасын тасвирлауга да бик уңайлы урыннар тапкан.

Мусаны без Мәскәү консерваториясе каршындагы татар опера студиясендә әдәби җитәкче буларак та, либреттолар авторы һәм, ниһаять, Татар дәүләт опера һәм балет театрын оештырып йөрүчеләрнең берсе буларак та күрәбез. Кызганычка каршы, ил алдындагы нәтиҗәле эшчәнлеген тагын да киңәйтергә шагыйрьнең мөмкинлеге булмый. Татар әдәбиятының һәм сәнгатенең Мәскәүдә булачак декадасына хәзерлек эшләре белән ялкынланып, бөтен барлыгы белән эшкә бирелеп йөргән көннәрнең бе-

---

[1] Ш. Маннур. Муса. Роман. Татарстан китап нәшрияты. 1968 ел.

рендә радио куркыныч хәбәр китерә: гитлерчы бандитлар газиз илебезгә басып кергәннәр. Мусаны бу хәбәр тетрәтеп җибәрә. Аның якты планнары, рухландыргыч уй-фикерләре җимерелеп төшкәндәй була. Каһәр генә суксын!.. дип пышылдый ул. «Үз язмышын ерак үткәндәге конфликтлар аша рус халкы белән бәйләгән һәм шуннан бирле Россия өстенә нинди генә авырлыклар төшсә дә, һәммәсен бергәләп күтәрешә килгән татар халкы да бу фаҗигане уртак бәхетсезлек итеп» каршылый. Афәтне Муса да нәкъ шулай каршы ала. Шагыйрь булган кешенең, ди ул, барыбер солдат булып, сафка басмый хәле юк. Һәм, чыннан да, аңа озак көтәргә туры килми: башта беркадәр Казан артындагы хәрби лагерьда була, аннары Марьино дигән шәһәрдәге (Курск янында) хәрби-политик курсларга укырга җибәрелә. Биредә дә аны озак тотмыйлар, фронт линиясе кысрыклый башлагач, курсларны Минзәлә шәһәренә күчерәләр һәм Муса да, курслар белән бергә, яңадан Татарстанга кайтып төшә.

Озакламый укулар тәмамлана, аңа өлкән политрук дигән хәрби исем бирелә. Курслар беткән арада Муса да тик ятарга теләми: аның халык сулышын тоясы, авыл тормышын үз күзләре белән күрәсе килә. Партия райкомы белән сөйләшеп, Сайкинчү авылына барып кайтырга була.

Муса Җәлилнең Сайкинчү авылында булу вакыйгасын автор аеруча оста итеп тасвирлаган. Бу — үзе бер зур тема, үзе бер сюжет линиясе булып тора. Һәм әсәрнең ул битләрен дулкынланмыйча уку мөмкин түгел.

Мусаны Алыпкул бабай белән Гөлшикәр әби өенә урнаштырапар. Гаҗәеп киң күңелле, олы йөрәкле, тормышның әчесен-төчесен күргән кешеләр булып чыгалар алар. Бу картлар коллектив тормышның, күмәк хуҗалыкның кадерен белеп яшиләр. Җитмешне тутырган булса да, Алыпкул бабай әле һаман колхозның җитәкче эшләрендә икән, хәтта әби дә эшкә йөри. Әгәр дә сугыш булмаса, алар түр башында гына утырган булырлар иде. Юк бит, заманы андый түгел. Авылның яшьләре һәм кулына корал тотарлык ирләре бар да фронтта. Алыпкул бабай берүзе генә дә җиде малаен фронтка озаткан кеше икән.

Шуларны тыңлап утыра торгач, Муса, үзе дә сизмәстән, уйлар, хыяллар дәрьясына кереп чума:

*«Без: халык, дибез... Соң менә шушы түгел микәнни инде ул татар халкы? Шушы бабай түгел микән, аның җиде малае түгел микән, һәм аларны тудырган Гөлшикәр әби түгел микән?.. Ә мондый асыл зат кешеләр һәр авыл саен, һәр завод, шахта, фабрика саен әллә ничәшәр ич! Әгәр татар халкы дигәнебез шушы Алыпкул бабайлар һәм аңа тиң бик күп исемсез агайлар булса, безнең ул халык белән горурланырга хакыбыз юкмыни? Милли горурлык дигәнебез шушы түгел микәнни?.. Эх, менә хәзер утырасы иде дә язасы иде, поэма язасы иде! Нинди фигура, нинди маһабәт, кул тимәгән кисәк, русча әйтсәк: глыба бит бу!.. Колорит дибез, менә ул колорит!.. Исән генә булыйм, вакыт кына табыйм — язам мин моны, язам!..* (77 бит).

Ватан хакына, дошманны тар-мар итү хакына бер нәрсәләрен дә кызганмаган авыл кешеләре Мусада әнә шундый матур хисләр, шундый илһам көче тудыра.

Муса авылның байтак вакытлардан бирле эшләмәгән клубын эшләтеп җибәрә, яшьләрнең сәләтләләрен җыеп, концертлар оештыра, беседалар уздыра. Яшьләр звызыннан «Иршат белән Гөлшат» исемле җыр да язып ала ул. Сүзләре дә, көе дә гаҗәеп матур. Мусаның башына тагын бер яңа уй килә:

«Ә моннан бит менә дигән опера да чыгачак! Ватан сугышы темасына дип әйтик ди... Лейтмотив — әлеге яңа көй бар, геройлар бар, вакыйга бар...»

(Чыннан да, нинди матур идея, нинди матур тема бит, әй! Тик бу эшне башкарып чыгу безнең кадерле шагыйребез Мусага насыйп булмады инде. Тема исә бүген дә әһәмиятен һич югалтмаган. Иҗат работниклары әйтәсе килә: тотыныгызчы шушы эшкә, Муса үзе чакыра бит!)

Муса фронтка киткәч тә Сайкинчү авылын һәм аның гүзәл кешеләрен бик озак вакытлар буена оныта алмый йөри. 1942 елның май аенда Волхов фронтыннан ул сайкинчүлеләргә зур бер хат та язып сала. «Эх, сагынам мин сезнең авылны һәм сезнең үзегезне сагынам, барыгызны да сагынам! Матур яшәгез, батыр эшләгез!» — дип яза ул хатында.

Волхов фронты дигән идек. Әсәрдә язылганча, соңыннан Мусаны Волхов фронтының политик идарәсе карамагына җибәрәләр. «Анда сезне берәр газетага бирketерләр...» диләр аңа. Һәм шулай булып чыга да. Аны биредә «Отвага» газетасына

әдәби сотрудник итеп билгеләнәр. Волхов фронты камалышта калган Ленинград халкын һәм армияне ачка кырылудан коткарып калырга тиеш була.

...Фронттагы хәлләрнең никадәр авыр икәнлеген Муса яхшы аңлый. Чыннан да, алай-болай була калса, ни эшләргә! Язылып та, матбугатта чыгарга өлгермәгән әсәрләр белән ни эшләргә! Аларның бит югалып әрәм булулары да бар. Әллә васыять язып җибәрергәме!.. Шактый икеләнеп йөргәннән соң, Муса «васыять» дигән нәрсәне язарга була.

*«Мин, татар язучысы Муса Җәлил..., хәзерге вакытта Ватан сугышы фронтында, хәрәкәттәге удар Армиядә булганлыктан, әгәр алай-болай сугышта үлә калсам, үземнең иҗат мирасым турында түбәндәгеләрне әйтеп калдырам...»*

Әнә шундый сүзләр белән башланып киткән васыять язмасын конвертка салып, Островляна дигән почталы авылны эзләп китә.

Почтага кергәндә, ул кинәт татарча җыр ишетә. Күптәннән бирле ана телендә җыр ишетмәгән солдатка ничектер бик күңелле һәм рәхәт булып китә. Муса, әлеге моңлы тавыш эзеннән барып, җырчы кызның үзен таба. Казаннан икән, әлек телеграфта эшләгән. Билалетдинова Әлбидә. Ә хәзер хәрәкәттәге армиядә. Муса озатасы конвертын кызга бирә...

Һич көтелмәгән хәл! Әлеге эчкерсез, саф күңелле Казан кызы Әлбидә электән үк күрәсе килеп йөргән шагыйрен әнә кайда очратты. Хәер, аңлашыла торган нәрсә бу. Җырлары радио аркылы да гел яңгырый торган, шигырьләре исә матбугатта басыла килгән зур әдипне кемнең генә күрәсе килми ди!! Тик эш моның белән генә бетми: тормышның әчесен-төчесен татып та өлгермәгән беркатлы Әлбидә үзенең шагыйрь абыена гашыйк та була. Бу кыз Мусага да бик ошый. Чибәр булуы өстенә бик гади, тыйнак, тырыш, туган илнең кадерен белә торган, фронтта туган авырлыкларны батыр кичерә торган бу сабыр кызны ничек яратмыйсың ди! Ләкин бит ярату белән ярату арасында да аерма бар. Муса аңа сеңелесе итеп карый, фронтта кызның ничек тә булса исән калуы турында кайгырта. Муса күңелендә, автор әйткәнчә, Әлбидәдәге кебек, утлар янмый, Әлбидәне борчыган проблемалар Мусада бөтенләй юк иделәр. Шулай да язмыш аларны бик тиз аера. Муса, яраланып, фашист бәдбәхетләр кулына эләгә. Әлбидәне исә Гитлер Германиясенә эшкә куып алып китәләр.

Әсәрнең сюжет линиясенә органик рәвештә бәйле Әлбидә образы турындагы сүзне түгәрәкли төшеп, шуны гына әйтәсе килә: Муса абыйсы үрнәгенә ияреп, бу кыз фашистлар Германиясен эчтән җимерү кебек гадел, шул ук вакытта бик куркыныч һәм кыен эшкә тартыла. Ләкин аның хәрәкәте фаҗигале тәмамлана. Немецларның җир астындагы лабораториясендә үзенең дус кызлары Фая, Сания белән бергәләп янгын-шартлату оештырган чагында ул һәлак була. Сания дә шундый язмышка дучар була. Аларның күптәнге дуслары рус кызы Фая исә, аңын югалткан хәлдә, тоткыннар больницасына эләгә.

Гомумән, романда хатын-кыз образлары шактый гына һәм аларның күбесе игезгә уңай тәэсир калдыра. Аларның һәммәсенең диярлек үз йөзләре, үз гадәтләре, үз төсләре бар. Ш. Маннур үзе иҗат иткән образлардан берсеннән дә идол — сын ясамаган, алар барысы да тормыштагыча итеп биреләләр, үзенчәлекле чын характерлар. Әлбидә, Әминә һәм Рокыя образларын аеруча матур, талантлы эшләнгәннәр дип әйтергә мөмкин.

...Рус совет әдәбиятында һәм татар совет әдәбиятында да немец-фашист илбасарларның кабахәтлекләре хакында аз язылмады. Шулай да автор үзенә кадәр язган әдипләрдән беркемне дә кабатламый. Ул фашистлар тудырган фаҗигале хәлләрне сурәтләрлек үзенчәлекле яңа алымнар таптан. Безнең илебезгә оккупант булып килгән немец әрвахы үзенең, янәсе, русча белгәнлеге белән кәпрәеп, автоматын төзәгән килеш, ишәк тавышы белән тоткыннарга кычкыра:

— Шиягай, шнель!

Беренче карашка, бу бик кечкенә генә деталь кебек. Ләкин ул укучыда дошманга карата нәфрәт тудырмый калмый. Русча сүз кыстырып сөйләргә тырышкан булалар, сволочьлар! Яраланганнан соң әле тернәкләнеп тә җитмәгән Мусаны, безнең совет кешеләрен күпме газапладылар ул аждаһалар. Моны онытырга мөмкинмени! Әлбәттә, юк!..

...Кырык үлемнән котылган, яралы Муса тоткыннар яшәгән ат абзарына килеп эләккәнен берничек тә белми иде. Аны бер озын санитар табып ала һәм немецларның атып үтерүләреннән коткарып кала. Кем соң ул! Муса аңына килгәч, санитарның кем

икәнен белү теләге белән, аның кылларын тартып карый:

*«— Ник, Арыслан Алыпкулов инде мин,— ди әлеге санитар солдат.*

*— Ә минем фамилиям Гумеров, онытма,— ди Муса».*

Соңыннан Муса Арыслан белән бик дус булып китә. Арыслан үзенең яңа дустын үлән дарулары пешереп дәвалый, һәртөрле юллар белән азык-төлек табып, аның тамагын туйдыра. Аларның тирәнрәк танышулары да бик кызык. Көннәрнең берендә Муса сорый моннан:

*«— Ык буе да Ык буе дисең, кай тирәдән соң син, абзый кеше?*

*— Ник, Миндәлә инде, Сайкичу дигән авылдан, агай-эне!*

*— Шулаймыни?!.. Ә кем малае буласың?*

*— Ник, Алыпкул картныкы инде, аны белмәгән кем бар? Малайның беренчесе...»*

Муса Арысланга Сайкичүдә булганлыгын, аның атасы белән анасы янында кунак булганын бәйнә-бәйнә сөйләп биргәч, ике солдат арасындагы дуслык тагын да көчәеп китә. Әйе, Алыпкул бабайны кемнәр генә белми соң! Ул бит Ватан сугышына җиде малаен озаткан кеше... Арыслан Мусаны Алыпкулның сигезенче малае дип, Муса исә Арысланны бишенче туганым, дип йөртә башлый. Әйтеп кенә аңлатуы кыен: мондый олы дуслыкны иҗат итү таланттан башка, кеше йөрәгенә үтеп керә белүдән башка мөмкин түгелдер. Арыслан образы әсәрнең башыннан алып ахырынача хәрәкәт итә. Арыслан — халык образы, безнең халкыбыз символы. Искиткеч батыр да, тапкыр да, ягымлы да бу кеше. Кирәксә ул көлдерә дә, елата да белә.

Ватан сугышы тәгәлләнер алдыннан Арыслан немецлар тылында ат караучы булып урнашып алган иде. Язмыш аннары аны французлар секторына алып ташлый. Үзе карый торган 20 атны да ул үзе белән бергә алып китә. Шунысы да кызык бит: төрле кыенлыклар аша, төрле илләр аркылы әлеге атларның барысын да ул туган колхозына алып кайта. Бу җыелма образ, ничектер, бөек нидерланд язучысы Де Шарль Костерның «Уленшпигель маҗаралары» исемле романындагы Тиль Уленшпигель образын күз алдына бастыра сыман. Уннарча еллар үтәр, ләкин Арыслан образы һәрвакыт укучы белән бергә яшәр.

...Зур политик һәм оештыручы буларак, Муса Берлинда, гомумән немецлар тылында, гаять нәтиҗәле эш алып бара. Немецлар, тоткыннардан төрле легионнар оештырып, аларны үз илләренә каршы корал күтәртергә уйлыйлар. Аларга элекке эмигрантлар, ә хәзер немецларга сатылган Каюм Вәлиханов, Әхмәт Тимер кебек бәдбәхетләр «Төркстан легионы» һәм Алмаз Шәфи, Рәшит мулла кебекләр исә «Идел-Урал» легионы оештыруда булышлык итәләр. Мусага да эш тәкъдим итеmenu: «Идел-Урал» газетасының редакторы бул! Моның әллә нинди зәхмәте юк, янәсе. Булышырлар. Ә аларга, фашистларга, М. Җәлилнең обруе, исеме кирәк. Аннары «Идел-Урал» мәмләкәтә төзелер. Немецларның көнчыгыш министры боларны раслап куйган. Эшкә тотынасы гына бар. Муса немецларның тәкъдименә күнә. Ләкин фашистлар файдасына эшләү өчен түгел, бәлки әлеге «легионнарны», Кызыл Армия сафларына бер ук та атмыйча, Совет ягына чыгарып җибәрүне оештыру өчен...

Муса бу эшләрне үзе генә башкармый, билгеле. Дуслары бик күп аның: Арыслан һәм Алиш, Мәскәү журналисты Әхмәт Симай, Казаннан Габдулла Баттал, Гайнан Кормаш, Үзбәкстаннан Сәйфелмөлеков, Хисаметдинов, Гариф Шабаев, Фоат Булатов һ. б. Аларның һәммәсе дә бердәм фикердәге, совет идеологиясе нигезендә тәрбияләнгән киң күңелле һәм бик кыю кешеләр. Муса Җәлил җитәкчелегендә алар күрсәткән батырлыклар алдында һәркем, һәр укучы баш ия.

Әсәрдән ачык күренгәнчә, дошман оясында ике идеология көрәше бара. Бер якта — пропаганданың һәртөрле чарасыннан дәүләткүләм файдаланучы фашистик идеология. Икенче якта — Җәлил һәм аның дуслары үткәрә торган совет идеологиясе — миллионнарны үз йогынтысына тарта торган көчле социалистик идеология. Бу урында Муса фикерен китерү урынлы булыр:

*«Сатылмый ул татар халкы! Сез, әлбәттә, аны мәҗбүр итәргә теләрсез: чөнки сезнең кулда корал, ләкин мин дә карап тормам! Мин, менә шушы бәләкәй генә Муса, сезгә караганда мең тапкыр зәгыйфьрәк, әмма рухы белән мең тапкыр көчлерәк бер гади шагыйрь, үз тирәмә тугры дуслар җыеп, сезгә каршы яуга чыгам!.. Татар солдаты үз туган иленә атмас!..»*

Мусаны фашистлар партиясенең «теоретигы» саналган көнчыгыш министры Ро-

зенберг белән очраштыралар. Күренеп тора: тоткыннар арасыннан министрга көчле кеше кирәк икән. Ике арада шактый кискен әңгәмә булып ала, ләкин, бәхәссез, өстенлек Муса ягында: аргументлар, дәлилләр, үткен репликалар министрны чыгырыннан чыгарсалар да, ул түзәргә мәҗбүр, чөнки аңа әлеге «көчле шәхес» бик кирәк бит. Шагыйрьгә зур постлар, әйтик, «Идел-Урал» мәмләкәтендә вице-президент урынын вәгъдә итәләр.

*«— Гафу итегез, министр әфәнде,— дип, Розенбергның сүзен бүлдерде Муса,—...ит күргәнгә упкә тансык булырмы икән?.. Татар халкының республикасы бар, аңа уенчык кирәк булыр микән?..»*

Капма-каршы көчләрнең идеологик һәм политик көрәшләрендә совет идеологиясенең һәм политикасының тиңдәшсез өстенлеген роман авторы зур сәнгать осталыгы белән күрсәтә алган.

Мин кайбер уңай образларга гына туктадым. Бу — әсәрдә кире, тискәре образлар юк, дигән сүз түгел. Әсәрдә укучы ярата торган, аның идеалына ятышып торган образларга каршы хәрәкәт итүче тискәре образлар, дошман вәкилләре дә аз түгел. Шулай да ике образ турында кыскача гына булса да әйтми булмас. Чөнки романның төгәлләнүе дә алар эшләгән кабахәтлекләр белән бәйләнгән. Сүз Карип Ишбулдин белән Мәмүт Ямалтаев турында бара. Ишбулдин — коеп куйган ялагай, мещан, вак җан, провокатор. Иммигрант һәм жулик Алмаз Шәфи турында әйтелгән иде инде. Бу кешене хатыны иркәләп Шафист дип, ә җәлилчеләр исә аны фашист дип йөртәләр. Нәкъ менә шул фашистның аяк табанын ялаучы, аның хәер-сәдакасына куанып яшәүче Ишбулдин, үзенең хуҗасына ярарга тырышып, гел Алишны күзәтеп, эзәрлекләп йөри. Бервакыт Алиш саксызлык эшләп куя: листовкалар матрицасын җиргә күмгән чагында Ишбулдинның күзәтеп торганын сизми кала ул. Бу аянычлы хәл бик яшерен эш алып баручыларга зур бәхетсезлек китерә. Шунда ул, әлеге Ишбулдин, кош тоткан малай кебек, Шафист-фашист янына йөгерә. Бу образ укучыда урынлы җирәнеч тудыра һәм нәфрәт уята.

Мәмүт Ямалтаев исә, тискәре образ буларак, эшләнеп җитмәгән кебек тоела. Ә бит ул — төп провокатор һәм хаин, Ватанын һәм Мусаларны саткан өчен фашистлардан медаль алган кеше. Шунлыктан, бу кешенең чын йөзен фаш итә торган факторлар һәм дәлилләр көчле һәм ышандыргыч булырга тиеш иде. Хәлбуки, сатлык җанның эчке һәм тышкы дөньясын фаш итә торган буяулар җитәрлек түгел кебек.

Романны укып чыкканнан соң ясалган кайбер нәтиҗәләр һәм фикерләр әнә шундый. Муса Җәлилнең эшенә һәм иҗатына карата урынлы горурлык уята торган, дошман оясында совет кешеләре башкарган героик эшләр турында тасвирлаучы бу эпик әсәрне авторның иҗат уңышы дип санарга мөмкин.

Әсәрнең күләме турында әйтелгән иде инде. Аз гына булса да җыйнаграк итеп булмадымы икән! Бу җиңел эш булмас, билгеле. Шулай да тырышып карарга кирәк булган. Чынлап еласаң, сукыр күздән дә яшь чыга диләр ич. Әсәрнең кайбер кисәкләрендә аерым башламнар артык сузылган кебек. Мәсәлән, романда Сәйфелмелеков фамилияле бер бик матур эшләнгән образ бар. Фашистлар үлем карары чыгаргач та, палач балтасының күтәрелгәнен көтеп яткан чагында әлеге иптәш үзенең бала чагы, бер кызга гыйшык тотып йөрү маҗаралары турында бик озак сөйләнеп утыра. Моның кирәге бармы икән! Кысарга мөмкин иде кебек. Мин уйлыйм: «Муса» романы белән рус укучысы да кызыксынмый калмас. Чөнки, беләсез, сүз безнең Муса турында бара бит. Бу зарурлык та әсәрне кыса төшү проблемасын куяр.

Әсәрнең теле бай, ул мавыктыргыч язылган һәм җиңел укыла. Болары турында эзләнү-тикшеренүләрне галимнәребез карамагына калдыру яхшы булыр. Сүзне очлап шуны әйтәсе бар: романны укыйсың һәм үзеңне Муса белән бергә хис итәсең, аның белән яши башлыйсың. Колак төбендә герой шагыйрьнең җыры яңгырап тора кебек:

...Гомерем минем моңлы бер җыр иде,
Үлемем дә яңгырар җыр булып!

Герой шагыйрь турында шагыйрь әсәре әнә шул җырны раслап тора.

**Галим РЯБКОВ.**

# ХАЛКЫБЫЗНЫҢ УЕН-БИЮ ҖЫРЛАРЫ

1940 елларга кадәр татар халык лирикасын дүрт юллы кыска җырлар белән чикләү гадәте бар иде. Хәзер исә матбугат битләрендә тарихи һәм лирик җырлар да, уен-бию һәм йола җырлары да, шулай ук кыска җырлар да әледән-әле күренгәләп тора. Зур күләмле махсус җыентыклар да чыккалый. 1965 елда «Татар халык җырлары. Лирик озын җырлар, йола җырлары» исемле җыентык дөнья күргән иде. Күптән түгел китап киштәләрендә «Татар халкының җырлы-биюле уеннары» дигән җыентык урын алды[1].

Китапның тышкы күренеше, эшләнеше игътибарны тартып торырлык түгел. Шуңа күрә, биредә нинди байлык, нинди хәзинә булыр икән! — дип шикләнеп тә куясың. Һәм әлеге сорауга җавап эзләп, китапның эчен актарырга тотынасың, эчтәлегенә карыйсың, искәрмәләргә күз төшерәсең. Шул рәвешчә актарына, укый торгач, әкренләп баштагы шик-шөбһәләр дә тарала башлый.

Кереш мәкаләдә китапның фәнни редакторы И. Надиров уен-бию җырларының Идел буе татарларында таралган иҗтимагый бәйрәмнәр, борынгы йолалар, төрле гореф-гадәтләр белән бәйләнешен, ягъни аларның шактый еракка сузылган тарихи тамырларын ачыклый. Әйтик, Казан тирәсендәге авылларда уздырыла торган «Чәчәк бәйрәме», «Җиләк бәйрәме», «Җуа аткасы», шулай ук элекке татар авылларында киң таралган «Аулак өйләр», ниһаять, гаилә бәйрәмнәре — боларның һәммәсендә дә җыр, уен-бию, көй-музыка шактый зур урын алып торган. Һәм мондый борынгы йолалар, иҗтимагый һәм гаилә бәйрәмнәре җырлы-биюле уеннарның килеп чыгуында, халык арасына таралуында, һичшиксез, зур роль уйнаганнар икән.

Татар халкының җырлы-биюле уеннары ниндирәк тарихи юл үткәннәр соң? Бу сорауга җавап бирү җиңел түгел, әлбәттә. Ерак заманнарның уен-биюләре, җыр-такмаклары безнең көннәргә үзгәрешсез килеш җитә алмаган. Гасырлар буена халык күңелендә, халык телендә йөреп, алар төрле үзгәрешләр кичергәннәр. Мәсәлән, безнең көннәрдә язып алынган «Нардуган», «Җимчәчәк» кебек уеннарда һәм җырларда борынгылыкның тик аерым детальләре генә саклана. Шулай да, төрле чыганакларга таянып, И. Надиров җырлы-биюле уеннарның борынгы чорлардагы яшәү үзенчәлекләрен күз алдына китерердәй мәгълүматлар бирә. «Болгар чорында уеннар чагыштырмача иркен шартларда, күмәк рәвештә башкарылганнар булса кирәк,— дип яза ул.— Шул чорга караган риваятьләрнең берсендә Кама буенда кызлар уйный торган махсус урын булуы турында әйтелә. Кызлар уенын карар өчен анда Болгар ханы да килә торган булган. Андый урыннар, күрәсең, берәү генә булмаган. Тарих битләрендә яшьләр җыелып ял итә торган урыннарның «Кыз-тау», «Кыз каласы» дип аталуы турында мәгълүматлар бар».

Авторның бу фикере белән килешми мөмкин түгел. Чөнки Болгар чорында җырлы-биюле уеннар гына түгел, халык иҗатының башка төрләре дә җәмгыять тормышында шактый зур урын биләп торган, күрәсең. Шул заманнарның гүзәл әсәрләреннән «Хан кызы Алтынчәч», «Янмый торган кыз», «Иделнең Акбикәне урлавы», Аксак Тимернең Болгарны алуы» турындагы риваять һәм легендалар, мәзәк һәм бәетләр, Болгар чорына яки аннан да борынгырак дәверләргә караган күп санлы мәкаль-әйтемнәр, табышмаклар, халык иҗатының гарәп һәм көнбатыш сәяхәтчеләре әсәрләрендә, рус елъязмаларында сакланып калган сюжетлары, образлары, детальләре нәкъ әнә шуны раслый.

Патша заманының колониаль политикасы, ислам дине руханиларының рәхимсез кысуы нәтиҗәсендә, XVI—XIX йөзләрдә татар халкының рухи тормышында җырлы-биюле уеннар билгән урын шактый тарайган. Шулай да халык иҗатының гүзәл бер өлешен тәшкил иткән уеннар һәм уен-бию җырлары бөтенләй юкка чыкмый, аларның ерак гасырлардан килгән традицияләре халык күңелендә яши бирә.

Бөек Октябрь социалистик революциясеннән соң әнә шул традицияләр яңадан кабынып китә. Тарихи тамырлары Болгар культурасына, хәтта аннан да борынгырак чорларга барып тоташкан уеннар һәм уен-

[1] «Татар халкының җырлы-биюле уеннары». Төзүчесе Х. Батина. Казан. 1968 ел.

бию җырлары зур активлык белән үсеп, чәчәк ата. Идел буе татарлары арасында исә алар аеруча нык таралалар.

Кереш мәкаләне укыгач, татар халкының җырлы-биюле уеннары үткән тарихи юл әнә шулайрак булып күз алдына баса. Әйтергә кирәк, җырлы-биюле уеннарның төрләре, уен-бию җырларының шигъри үзенчәлекләре турындагы юллар да матур тәэсир калдыра. Шуның белән бергә мәкаләдә уйландыра торган урыннар да бар. Авторның төп игътибары халык уеннарына юнәлтелгән. Шуңа күрәдер, ахры, кереш мәкаләдә ул уеннарның аерылгысыз өлеше булган җырлар турында беркадәр каршылыклы фикерләр дә очраштыра. Безнеңчә, уен-бию җырлары — татар халык лирикасының мөстәкыйль бер төре, үзенчәлекле бер жанры. Аның үзенә генә хас сыйфатлары бар. Китапка кергән конкрет әсәрләр моны бик ачык күрсәтә. Әмма кереш мәкаләдә уен-бию җырлары халык лирикасының башка төрләре белән аралашып китә кебек. «Әйлән-бәйләннәр вакытында яңгыраган иҗтимагый-лирик җырлар күбебезгә электән таныш,— дип яза автор.— Аларның байтагы, кыска җырлар буларак, төрле җыентыкларда әүвәл дә басылган иде». Уен җырларының яшьлек, дуслык, мәхәббәт турындагылары хакында язганда, шул ук фикер тагын бер тапкыр кабатлана: «Мөстәкыйль кыска җырлар буларак, аларның күбесе безгә шулай ук электән мәгълүм». Әгәр бу фикерләрне алга таба дәвам иттерсәк, уен-бию җырларының төп өлеше бер исем астында берләшкән кыска җырлардан тора, дигән нәтиҗә килеп чыгар иде. Кайчандыр «Зөләйха», «Рәйхан», «Рамай» кебек лирик җырларыбызга карата да шундый фикерләр әйтелә иде. Уен-бию җырлары турындагы мәкаләдә дә шул ук тенденция сизелеп куя. Шуңа күрә биредә, авторның уңай фикерләрен беркадәр киңәйтү, тулыландыру йөзеннән, халык лирикасының башка төрләре белән уен-бию җырлары арасындагы уртаклыкларга һәм аермаларга, уен җырларының специфик үзенчәлекләренә тукталып үтү сорала.

Китаптагы әсәрләрне халык лирикасының башка төрләре белән чагыштырып карагач, халык җырларының аерым төрләре арасында үтмәс чик юк икән, дигән нәтиҗәгә килергә мөмкин. Һәм ул закончалык совет чоры җырларында аеруча ачык күренә. Ә элеккерәк дәверләрдә халык лирикасының төрләре бер-берсеннән шактый нык аерылып торган, күрәсең. Ул чорларда уен җырларының да специфик сыйфатлары күзгә күренеп торырлык дәрәҗәдә ачык булган булса кирәк. Безнең көннәргә кадәр килеп җиткән традицион уен җырлары нәкъ әнә шуны раслый. Аларның эчтәлеге гадәттә бик конкрет. Чөнки алар уенның яки йоланың хәрәкәтләре турында сөйлиләр, шуларны оештыралар. Революциягә кадәрге уен-бию җырларының поэтикасы да гади, төрле шигъри образлар, эпитет-чагыштырулар аларда сирәгрәк очрый. Шул яклары белән алар халык лирикасының башка төрләреннән аерылып торалар.

Совет чорында исә борынгы уен җырларының кайбер үзенчәлекләре юкка чыга бара[1]. Бу процесс XIX йөздә үк, ә бәлки, аннан да иртәрәк башлангандыр. Югарыда телгә алынган «Нардуган», «Җимчәчәк» кебек борынгы әсәрләрдә үк җыр сүзләренең уен хәрәкәтләреннән беркадәр читләшүе, мөстәкыйльлек ала баруы күзгә ташлана:

Нардуганым[2] нарына,
Бакма кеше ярына;
Кеше яры яр булмас,
Үз яр гынаң ят булмас.

Уен яки йола хәрәкәтләреннән аерылу нәтиҗәсендә, җырларның эстетик мөмкинлекләре киңәя, җыр эчтәлегенең мөстәкыйльлеге, гомумиләштерү көче арта бара. Уен хәрәкәтләре белән җыр сүзләре арасындагы бәйләнешнең йомшара төшүе жанрның үсеш мөмкинлекләрен, иҗтимагый функцияләрен киңәйтә. Совет чорында туган уен җырларының төп өлеше конкрет уеннар, хәтта халык бәйрәмнәре, сабантуйлар белән дә бәйләнмәгән. Аларны клубта һәм урамда, мәктәптә һәм үзешчән сәнгать концертларында, радио һәм эстрадада, кыскасы, төрле җирләрдә һәм төрле

[1] Совет чорында аерым фольклор жанрларының активлашуы, ә икенчеләренең, киресенчә, пассивлаша төшүе турында түбәндәге хезмәтләрдән укырга мөмкин: Н. Исәнбәт. Татар халык мәкальләре. I том. Казан. 1959 ел. 68 бит; Х. Ярми. Татар халкының поэтик иҗаты. Казан. 1967 ел. 258 бит; Ф. Урманчеев. Совет чоры бәетләре. «Казан утлары» журналы. 1966 ел. 6 сан. 110—119 битләр; М. Мәһдиев. Халык иҗатына бер караш. «Казан утлары» журналы. 1968 ел. 11 сан. 134 бит; И. Надиров. Бөек Ватан сугышы чорында татар халык иҗаты. «Татар теле һәм әдәбияты» исемле җыентык. Казан. 1959 ел. 249 бит. һ. б.

[2] Нардуган — яңа чыккан кояш.

вакытларда ишетергә мөмкин. Мәсәлән, «Ай йолдызым», «Гөлгенә», «Кәймә генә килә генә» кебек җырлар, кайда гына һәм кайчан гына башкарылсалар да, бик матур һәм заманча яңгырыйлар.

Уен җырларының шулай киң таралуы аларның потенциаль мөмкинлекләре, иҗтимагый әһәмияте белән бәйләнгән. Күтәренке рух, кешеләрне коллективка туплау, аларның арасын якынайту, дуслаштыру мөмкинлекләре совет чоры җырларында аеруча ачык күренә. Әгәр уен җырларының эчтәлеге уен яки йола хәрәкәтләре, тормыш-көнкүреш тематикасы белән чикләнгән булса, алар яшьләрнең гаять киңәйгән һәм тирәнәйгән рухи ихтыяҗларына җавап бирә алмаган булырлар иде. Яшәү формаларының үзгәрүе, иҗтимагый-эстетик функцияләренең киңәюе уен җырларының тематикасын да баета. Совет чорында уен җырлары зур иҗтимагый яңгыраш ала. Аларда туган илгә һәм халыкка мәхәббәт, илне индустрияләштерү һәм коллективлаштыру, Бөек Ватан сугышы, Совет Армиясе турында бара.

Биек тауның башларында
Шаулап үсә пар каен;
Чәчәкләнә туган илем,
Матурлана көн саен.

(«Юллар ача, гөлләр чәчә»)

Халык тормышына социализм алып килгән яңалыклар уен җырларында аеруча матур чагыла. Иҗтимагый тормышның үзгәрүе, колхоз-совхозлардагы күмәк тормыш, халыкның фидакарь хезмәте, илебезнең чәчәк атуы өчен даими көраш — совет чоры уен җырларының тематик эчтәлеген әнә шулар тәшкил итә.

Уен җырларында зур урынны тормыш-көнкүреш лирикасы алып тора. Аларда тормышның гүзәллеге, бәхетле яшьлек һәм мәхәббәт җырлана. Тематикасының киңәюе, эчтәлегенең үзгәрүе белән уен җырларының поэтикасы да үзгәрә, традицион йола-уен җырларыныкыннан беркадәр ераклашып, лирик һәм кыска җырлар поэтикасына якынлаша. Безнең заман уен җырларында традицион шигъри алымнар, эпитет, чагыштыру, символлар бик киң кулланыла. Аларның күпчелеге халык лирикасының төрле жанрлары өчен уртак булып китә. Хәтта аерым куплетлар да җырның бер төреннән икенчесенә күчеп йөри. Халык лирикасының гаять хәрәкәтчән, динамик төре булган кыска җырлар бу юнәлештә аеруча зур активлык күрсәтә. Аларның аерым үрнәкләре уен-бию, лирик, хәтта йола җырларына да үтеп керә. Нәтиҗәдә хәзерге уен-бию җырларының төп өлеше безгә элektән мәгълүм булган кыска җырлардан тора дип уйлау мөмкинлеге туа.

Әмма кыска җырлар халык лирикасының бер төреннән икенчесенә ничек булды шулай күчеп йөри алмый. Чөнки халык лирикасының һәрбер төренә хас сыйфатлар, һәрбер төрнең үз спецификасы бар. Бу — уен җырларына да хас күренеш. Совет чорындагы уен җырлары, үзләренең кайбер специфик билгеләрен югалтып, лирик һәм кыска җырларга якынлашсалар да, аларны уен җыры иткән төп үзенчәлекләр саклана. Лирик җырлар тормыш вакыйгалары, тормыш күренешләре турында җитди тон, билгеле бер моң белән сөйлиләр. Еш кына аларның эчтәлегенә тирән драматизм яки уйлану, борчылу хас. Ә инде уен-бию җырларының характеры башкача. Алар яшьләрнең күңел ачу, күңел күтәрү моментлары белән бәйләнгән. Шуңа күрә уен җыры беркайчан да драматик яки трагик характерда була алмый. Ил тормышының нинди генә авыр чаклары, әйтик, Бөек Ватан сугышы турында сөйләсә дә, уен җыры һәрвакыт искиткеч оптимистик яңгырый: «Егетнең эзләкләре», «Татарстан кызлары...»

Эчтәлегә күтәренке рухлы булгач, уен җырларының стиле дә матур, саф һәм җиңел була. Аларда шатлык, яшьлек, мәхәббәт символлары булган традицион образлар еш очрый. Җәйге көннең сихри матурлыгы, тулган ай һәм сандугач сайравы, кызарып чыккан кояш нурлары һәм язгы таң җиле, якты кояш һәм чәчәк аткан шомырт, Идел дулкыннары һәм урман аланы кебек шигърияткле образлар уен җырларында төп урынны алып тора. Аларда авыр тормыш, кайгы-хәсрәт символы булган кара болыт һәм күзгә ачы җил, кара урман һәм ялгыз сукмак, шиңгән гөл һәм агачыннан аерылган алма кебек образлар юк диярлек:

Зәйтүн гөле арасында
Кына гөлем бер генә;
Зифа буйлы, ал чәчәкле
Ул кына гөл син генә.

(«Бас эзенә генә»)

Искиткеч матур эпитет, чагыштыру, символлар уен җырларын үзенчәлекле шигърият белән бизи, яңгырашын матурайта. Аларның күтәренке рухлы, матур һәм

күңелле көе-музыкасы да шуңа ук хезмәт итә.

Композицион яктан уен-бию җырлары лирик җырларга шактый якын тора. И. Надиров дөрес күрсәтүенчә, уен җырларының иң оригиналь һәм үзенчәлекле элементы дип аларның кушымтасын әйтергә кирәк. Алар гадәттә 7—8 иҗекле юлларга нигезләнәләр. Җырның лейтмотивы, рухы еш кына әнә шул кушымталарда чагыла:

Их, су агулары,
Матур су алулары;
Пар чиләген иңгә салып
Китеп югалулары ла,
Озатып калулары.

(«Их, су агулары»)

Җырның үзенчәлекле ритмы кушымталарда аеруча ачык күренә. Халык лирикасының бу төренә хас сыгылмалы форма — төгәл ритм, тулы рифма һәм ачык строфикага нигезләнә. Безнең заман уен җырларын уен җыры итүдә аларның бик киң гомумиләштерүгә нигезләнгән эчтәлегенә карaганда музыка-көй ярдәмендә гәүдәләнгән ритмы, җитдирәк урын алып тора дип әйтергә дә мөмкин.

Халык лирикасының бу төрендә форманың зур роль уйнавы ритмда гына түгел, башка кайбер үзенчәлекләрдә дә күренә. Әйтик, җырның эчтәлегенә мөнәсәбәте булмаган формаль элементлар аларда киң таралган. Күп кенә уен җырларының исемнәре үк эчтәлексез сүз тезмәләреннән тора: «Илләйлә-ләйлә», «И, дүдәме, дүдәме» «Рәм-рәм-рәмилә». Шундый ук тезмәләр уен җырларының кушымталарында да шактый еш очрый:

Әлләләлем Зәлилә,
Гөлләләлем Зәлилә;
Зәңгәр чиләкләрен алып
Суга бара Җәмилә...

(«Зәлилә»)

Мондый тезмәләрне тискәре бәяләү, безнеңчә, һич тә дөрес булмас иде. Чөнки алар уен җырларының шигъри һәм музыкаль үзенчәлекләре белән бәйләнгән. Уен-бию — халык иҗатының синкретик төре. Фольклорның башка кайбер төрләрендәге кебек үк, анда көй һәм сүз бер-берсе белән гаять тыгыз бәйләнгән. Аларны аерым карау мөмкин түгел. Сәнгатьнең бер төре дә, шул исәптән музыка да, эчтәлексез, мәгънәсез була алмый. Димәк, уен-биюнең эчтәлеген ачуда җыр сүзләре беренче урында тора алган кебек, көе-музыкасы да алгы планга чыга ала. Уен җырларындагы эчтәлексез сүз тезмәләренең үзеннән-үзе җырлап торуы, аларга күтәренке рух, күңеллелек бирүе нәкъ әнә шуны раслый:

Импаира-тиритур,
Импаира-тиритур.
Су буенда ат эчерә
Комсомол егет бит ул.

(«Импаира-тиритур»)

Уен җырларында шактый киң таралган мондый тезмәләр жанрның табигатенә туры килә, аның матур үзенчәлекләрен билгели. Җырның формасын камилләштерүдә гаять зур роль уйный торган һәм матур яңгырашлы аваз тезмәләре бер җырдан икенчесенә күчеп йөрми, кабатланмый. Һәр җырда алар үзенчә һәм бик музыкаль яңгырыйлар: «Аллария-ләрия, гөлләрия-ләрия» яки «Алия-гөлия, гөлия-тирәккәем». Уен җырларында халыкның гасырлар буена камилләшә килгән, безнең көннәрдә гаять югары дәрәҗәгә күтәрелгән эстетик зәвыгы, эстетик тәҗрибәсе чагыла.

Рецензияне тәмамлар алдыннан, «Искәрмәләр» бүлеген тагы бер мәртәбә карап чыгыйк. Кызганычка каршы, искәрмәләрнең барысы да искиткеч бер төрле булып чыккан: аларның һәркайсында аерым җырларны кайчан, кайда һәм кем язып алганлыгы гына күрсәтелгән. Болары да кирәк. Әмма алар киңрәк булса, кайбер үзенчәлекле уеннарның һәм җырларның килеп чыгышы, борынгы йолалар, гореф-гадәтләр белән конкрет бәйләнеше, аерым җырларның тарихы турында киңрәк аңлатмалар бирелсә, һичшиксез, яхшырак булыр иде. Чөнки уеннар һәм уен-бию җырлары татар халык иҗатының гүзәл бер өлешен тәшкил итә. Халык алар белән кызыксына.

Узган ел «Социалистик Татарстан» газетасы битләрендә «Заман, гореф-гадәт, традицияләр» дигән темага фикер алышу барды. Кайбер иптәшләр аерым авылларда халык уеннары һәм уен-бию җырлары соңгы елларда акрынлап онытыла баруы турында борчылып яздылар. «Татар халкының җырлы-биюле уеннары» китабына әнә шундый уеннарның иң матурлары урнаштырылган. Авыл һәм шәһәр яшьләре арасында, клубта, урамда, паркта, елга буенда, аланда матур итеп оештырылган халык уеннары яшьләрдә халкыбызның шигъри-музыкаль байлыгына тирән ихтирам, гүзәллекне аңлый белү, дуслык, туганлык тойгылары тәрбияләүдә гаять зур роль уйнаячаклар.

Фатих УРМАНЧЕЕВ.

# *КЫСКА РЕЦЕНЗИЯЛӘР*

**КЛАРА БУЛАТОВА. Һәрвакыт янымда. Шигырьләр Казан. 1969 ел.**

Клара Булатова хатын-кыз язучыларыбыз арасыннан — поэзия жанрында иң актив эшләүчеләрнең берсе. Аның шигырьләре газета-журнал битләрендә әледән-әле басылып тора, композиторларыбыз тарафыннан көйгә салынган лирик җырлары даими рәвештә радио аша яңгырый. Ул шигырьләрдә һәм җырларда тормыштагы вакыйгалар, кешеләр күңелендә туган уй-фикерләр, аларның шатлык-куанычлары бер уку белән хәтердә калырлык поэтик детальләр, җылы хисләр белән сугарылган шигъри юллар аша сурәтләнә. Яшь шагыйрьнең күптән түгел Татарстан китап нәшриятында басылып чыккан «Һәрвакыт янымда» җыентыгына кергән шигырьләре — моның ачык дәлиле.

Җыентык «Бирегез канатлар», «Без кичердек моны» һәм «Йөрәк нишләсен» дип исемләнгән өч бүлектән тора. Беренче бүлеккә авторның «Юллар, таулар», «Шпаллар», «Токарь кыз», «Әнкәм җылысы», «Укытучы апаң йокламаган», «Постта торам», «Бирегез канатлар», «Гастрольләр, гастрольләр» һәм башка шигырьләре урнаштырылган. Исемнәреннән үк күренгәнчә, ул шигырьләрнең төрлесе төрле темага язылган һәм аларда тормышыбызны бизәп яшәүче замандашларыбызның фидакарь эшләре, олы теләкләре гәүдәләнә. «Без кичердек моны» дигән бүлеккә тупланып бирелгән шигырьләр туган җиргә, сине шул җирнең тулы хокуклы баласы итеп үстергән ата-анага, кыен чакта иңнәренә таяна алырлык дусларга карата әчкерсез мәхәббәт, гомер буе татулыкта, тынычлыкта яшәргә хыялланган кешелек өстенә зур афәтләр алып килгән сугышка, шул сугышны кабызучыларга каршы тирән нәфрәт хисе белән сугарылганнар. Ләкин бу бүлектәге «Әти кайтты», «Сугыштан соң...», «Юк, кайтмасын ул чор!» шигырьләре артык озынга сузылганнар, һәм шагыйрә аларда үз-үзен кабатлый. Бер шигырьдә инде әйтелгән матур гына фикернең һич тә үстерелмичә, шул килеш икенче шигырьләргә күчүе аның, ягъни ул фикернең тәэсир көчен кимetә, әһәмиятен югалта.

Җыентыкның соңгы бүлеге яшьлек һәм мәхәббәт турындагы шигырьләрдән тора. Андагы шигырьләр башка бүлектәге шигырьләрдән үзләренең кыска язылган һәм җырга тартым булулары белән аерылып торалар. Автор аларның кайберләрен үзе дә җыр дип атаган. Чыннан да бирелдәге «Төштә күрдем», «Синең белән», «Бәлки, син «үзе»дер», «Яр буйларын томан урата» шикелле шигъри парчалар үзләренә композиторларыбызның мөрәҗәгать итүләрен көтәләр.

«Һәрвакыт янымда» — Клара Булатованың икенче китабы. Моннан ике ел элек басылып чыккан «Язлар алда» җыентыгы белән чагыштырганда, аның бу китабы тематик яктан да, андагы шигырьләрнең поэтик эшләнешләре ягыннан да шактый өстен тора. Бу исә шагыйрә иҗатының һаман камилләшә һәм аның каләменең торган саен чарлана баруы турында сөйли.

**ЕГОР УТКИН. Төнге яшен. Шигырьләр. Казан. 1969 ел.**

Яшь шагыйрь Егор Уткинның беренче китабы 1967 елда «Беренче карлыгачлар» сериясендә басылып чыккан иде. Быел укучыларга ул «Төнге яшен» исемле икенче җыентыгын тәкъдим итте. Анда тупланган шигырьләр, нигездә авыл кешеләре тормышына, игенченең тырыш хезмәтенә, илебезнең яна төзелешләрендә эшләүчеләргә һәм тынгысыз бу заманда планетабызның иминлеген, кешелекнең бәхетен яклап, алгы сафта атлаучы көрәшчеләргә багышланып язылганнар. «Дулкыннары күчкән күңелдән», «Күргәзмәдә», «Печән өсте», «Пенсиягә чыга Харис бабай», «Күңелләрдә яулап алгансың», «Сабан тургайлары», «Мәхәббәт каласы салалар», «Әткәм истәлегенә», «Ишетмәсен иде» кебек шигырьләрендә автор әнә шул югарыда әйтелгән темаларга мөрәҗәгать итә.

Минә аның «Ишетмәсен иде» дигән шигыре. Сиртмәле бишегендә изрәп йоклаган сабый төшендә дә көлеп-елмаеп куя. Әйтерсең, ул төшендә шүрәлеле әкият урманын күреп ята. Кан һәм күз яшьләре аңа әле таныш түгел. Ә тышта, ди шагыйрь, җилме, атом шартлавыннан тетрәп, җирне авыр көрсенә. Шигырь һәркемнең изге теләген чагылдырган һәм сугышка каршы көрәшкә чакыру авазы булып яңгыраган түбәндәге юллар белән тәмамлана:

> **Берни сизми сабый. Ә мин уяу.**
> **Таң сызылып килгән мәл менә.**
> **Бомбаларын,**
> **сугыш,**
> **ятимлекне**
> **Эх, җирләргә иде мәңгегә.**

«Яшь солдат», «Бишек сиртмәсе», «Сабый чакны сугыш тартып алды», «Алмагачым хәтерләтте мина» шигырьләрендә дә шул ук фикерләр үстерелә.

Беренче китабындагы кебек үк, икенче җыентыгында да Егор Уткин туган як табигатенең матурлыгын тасвирлаган шигырьләргә шактый урын биргән. «Ай-йолдыз юк...», «Кинәт килде дә...», «Август төне...», «Көмештәй ялтырап...», «Урамда тулы дәрт-

ле аваз...», «Март бураны купме дуламасын...», «Тау итәге», «Хәтфә арасыннан...» дип башланган шигырьләр күңелдә аеруча җылы тәэсир калдыралар. Ул шигырьләрнең барысы да диярлек, «Этюдлар» дигән баш астында, аерым бүлеккә тупланып бирелгәннәр. «Йогты», «Язгы серенада», «Принципиаль» бригадир» шигырьләре яшь шагыйрьнең сатира-юмор өлкәсендә эшләргә дә сәләтле икәнлеге турында сөйлиләр.

Егор Уткин Менделеевск шәһәрендә, химия заводы эшчеләре арасында яши һәм үзе дә шул заводта эшли. Әмма аның бу җыентыгында эшчеләр тормышын, аларның уй-тойгыларын, теләк-омтылышларын чагылдырган бер генә шигырь дә юк. Шагыйрьнең киләчәктә язылачак шигырьләрендә урын алачак геройлар арасында укучы авторның якташларын да күрергә тели.

**НӘҖИП МАДЬЯРОВ. Чәчәк күрдем. Шигырьләр. Казан. 1969 ел**

Калын кар белән капланган урман аша кышкы юл үтә. Якты эзләр калдырып, шул юлдан узган чанада ике юлчы бара. Аларның берсе, олы яшьтәгесе, күзләрен еш-еш йомып, әле шигырь сөйли, әле авыз эченнән генә нәрсәдер көйли. Юлаучы малай исә, юлдашының уйларын бүлдерүдән куркып, тын да алмыйча аны тыңлап бара. Юлчыларның берсе — Арча поездына ашыгучы шагыйрь Әхмәт Фәйзи, икенчесе — аны озата баручы һәм соңыннан бу олы әдипкә багышлап «Үтә юл урман аркылы» исемле шигырь язачак Нәҗип Мадьяров.

Нәҗипнең әлеге шигыре аның күптән түгел Татарстан китап нәшриятында басылып чыккан «Чәчәк күрдем» исемле җыентыгына урнаштырылган. Шигырь ихлас күңелдән язылган һәм хисләргә бай булуы белән сине үзенә җәлеп итә. Хискә, кечерешләргә корылган мондый шигырьләрне җыентыкта байтак очратасың. «Күкрәгемдә тирбәлә көй», «Медаль», «Вөҗдан газабы», «Гыйшык утлары кабынса» һәм «Игенченең хисе...» дип башланган шигырьләрен укыганда Нәҗип Мадьяровның үз тавышын ишетәсең. Бу шигырьләрнең бөтенесе дә китапның «Уйлый күңелем тәрлесен» дип исемләнгән бүлегенә тупланып бирелгән. Моннан тыш җыентыкта «Сонетлар», «Сигезьюллыклар» һәм «Дүртьюллыклар» дигән бүлекчәләр бар. Аларга сайлап алынган шигырьләр авторның иҗади эзләнүе, каләмен төрле юнәлештә сынап каравы турында сөйлиләр. Аның дүртьюллык һәм сигезьюллык шигырьләре фәлсәфи рухта язылганнар.

> **Көчсезләнә кайгы, бүлешкәндә**
> **Иптәшләрең белән бергәләп.**
> **Ә шатлыкның көче арта, аны**
> **Дусларына бирсәң бүлгәләп,—**

ди шагыйрь әле дүртьюллыкларының берсендә. «Тау елгасы кебек», «Шагыйрьләр дә шулай», «Гомер» шигырьләрендә дә шундый ук матур фикерләр әйтелә. Ә менә «Чыбыркы», «Иске фикерле кеше», «Мактанчык» шигырьләренә карата моны әйтеп булмый. Бу шигырьләрендә Нәҗип үз сукмагыннан читкә чыга, башкалар тарафыннан инде күптән салынган һәм шактый таптаган юлга кереп китә. «Сигезьюллыклар» бүлекчәсендәге «Мин кырларда үстем», «Язгы ташкын шавы сагындырды», «Малай чакның бик күп шуклыклары» шигырьләрен укыганда да күңелдә канәгатьсезлек тойгысы кала. Ә гомумән, җыентыкта поэзия сөючеләр кызыксынып укырлык әйбәт шигырьләр өстенлек ала. Җыентыкның әһәмияте, барыннан да элек, әнә шунда.

**ДИФГАТЬ СИРАЙ. Кушнарат. Поэма һәм шигырьләр. 1969 ел**

Дифгать Сирайның «Кушнарат» исемле җыентыгы басылып чыкты. Җыентыкка авторның соңгы ике-өч ел эчендә язган яңа шигырьләре һәм Бөек Ватан сугышы каһарманы, Советлар Союзы Герое Хафиз Сабировка багышланган «Хафиз батыр» дигән поэмасы кергән. Китаптагы шигырьләрнең күбесендә лирик геройның туган ягына, аның табигатенә, хезмәт сөючән тыйнак кешеләренә булган мәхәббәте, гомерләрен халык бәхете өчен биргән көрәшчеләрнең үлемсезлеге, җирдә тынычлыкны саклап калу өчен барган көрәшнең кискенлеге гәүдәләнә. Моны, барыннан да элек, «Бу җирләрдә», «Әткәм мирасы», «Тамчы», «Көн кузгалган», «Бер һәйкәл бар Кама аръягында», «Чордашлар», «Тын син, давыл» шигырьләренә карата әйтергә мөмкин. Үзенең бу шигырьләрендә Дифгать, теге яки бу фикерне әйтү өчен, укучының күңеленә керен калырлык гади һәм тирән мәгънәле сүзләр, матур-матур поэтик детальләр сайлап алырга тырыша. «Тын син, давыл» шигыре, мәсәлән, менә мондый юллар белән тәмамлана:

> **Тын син, давыл,**
> **Тын син мәңгелеккә!**
> **Хаҗәтең юк синең, кирәгең...**
> **Йоклыйк әле, баш астына салып**
> **Әнкәйләрнең йомшак мендәрен.**

Дифгатьнең күпчелек шигырьләре кыска һәм җыйнак. Алар аңлаешлы, җиңел тел белән язылган. Ул шигырьләрдә син үз йөрәгеңнең тибешен ишеткәндәй буласың. «Әткәм мирасы», «Давылларга чәчәм бәхетемне», «Үлмәм кебек», «Чәчәкләр», «Кошлар оча» шигырьләрен укыганда күңелдә әнә шундый матур тойгылар кала.

Җыентыкка кергән кайбер шигырьләрнең кимчелекле ягы итеп шуны әйтергә кирәк: аларда урыны-урыны белән ритмик кытыршылыклар, авыр инверсияләр, «читтә — гөрләвеккә», «ташларга — дошманга», «башка— штыкларга» шикелле уңышсыз рифмалар күзгә ташлана. Болар Дифгать Сирайның шигъри фикерләрен кәгазь битенә күчергәндә вакыт-вакыт ашыгучанлык күрсәтүе, шигырьнең һәр яктан нәфис булуына игътибар бирен җиткермәве турында сөйлиләр. Хәлбуки, моңа кадәр инде ике җыентык чыгарган яшь әдипнең әлеге кимчелектән котылу, һәм фикере, һәм техник эшләнеше ягыннан укучыны канәгатьләндерә алырлык поэтик әсәрләр иҗат итү өчен тәҗрибәсе дә, сәләте дә җитәрлек.

# ГАЗЕТА УКУЧЫЛАРЫБЫЗ ИГЪТИБАРЫНА!

Килгән хатлардан күренгәнчә, «Социалистик Татарстан» — яратып укыла торган газеталарның берсе. Редакция коллективы аны киләсе елда тагын да яхшырту чараларын билгеләде. Бу турыда сүзне бераз соңгарак калдырып, кадерле укучыбыз, сезнең хатларда куелган сорауларга кыскача җавап бирәбез.

Газетабыз турында, аның 1970 елга планнары, аңа язылу тәртипләре турында беләргә телисез. Рәхим итегез, хөрмәтле иптәшләр! «Социалистик Татарстан» — КПСС-ның Татарстан өлкә комитеты, ТАССР Верховный Советы һәм Министрлар Советы органы. Ул 1918 елның 12 нче мартыннан бирле Казанда чыга. Аны киң илебезнең төрле почмакларында алалар. Газетаның тиражы хәзер 121 меңгә якынлашты.

1970 ел — ике зур юбилей елы. Республикабыз хезмәт ияләре В. И. Ленинның тууына 100 ел тулу көнен һәм Татарстан АССРның 50 еллыгын билгеләп үтәчәкләр. Шушы ике зур вакыйганы лаеклы каршылау өчен хәзерлек «Социалистик Татарстан» битләрендә кызыл җеп булып барачак. Бу темаларны яктыртуда газета махсус план нигезендә эш итә.

«Социалистик Татарстан» битләрендә Ленин тематикасы тагын да күчлерәк яңгырасын өчен безгә иҗади хезмәтебезне икеләтә, өчләтә арттырасы бар. Татарстанда һәм киң илебезнең Ильич булган урыннарыннан кызыклы, бай, тирән эчтәлекле материаллар бирелер.

Совет Татарстанына 50 яшь тулуга хәзерлек тә үзәк темаларның берсе булачак. Совет власте елларында Коммунистлар партиясе җитәкчелегендә һәм халыкларның тату семьясында Татарстан танымаслык булып үзгәрде. Татарстан үзенең алтын туена барган бу көннәрдә халкыбыз зур рухлану белән хезмәт итә. Менә нефтьчеләрне генә алыйк. (Ә бит бу профессия Совет властена кадәрле бездә бөтенләй юк иде.) Алар ун елдан артык ярышта җиңүчеләр булып баралар — илебездә чыгарыла торган нефтьнең өчтән бер өлешен бирәләр. Елга 300 миллион тонна нефть бирү инициаторлары да алар булдылар.

Ә авыл хуҗалыгы?! Халык хуҗалыгыбызның бу тармагы да үсә, чәчәк ата. Кырларыбызның уңыш бирүе, шулай ук терлекчелек продуктлары алу елдан-ел арта. Боларның барысы һәм алтын куллы патриот колхозчыларыбыз турында тулырак, кызыклырак итеп язылган очерклар, зарисовкалар, мәкаләләр укырсыз. Газета битләрендә галимнәр, авыл хуҗалыгы белгечләре, совет һәм хуҗалык органнары работниклары, производство алдынгылары чыгыш ясаячак. Хәбәрче хатларына киң урын биреләчәк.

Газета укучыларга рухи азык та мул булыр. Аның һәр санында әдәбият-сәнгать эшлеклеләренең яңа әсәрләре урнаштырылачак. Аларның иҗат портретлары биреләчәк. Гадәттәгечә, атна саен әдәбият һәм сәнгать сәхифәсе биреп барачакбыз. Татар совет әдәбиятының һәм сәнгатенең торышына, үсеш проблемаларына кагылышлы мәкаләләр, тугандаш әдәбият вәкилләренең әсәрләре дә шактый урын алыр. Язучылардан Мирсәй Әмир, Гомәр Бәширов, Габдрахман Әпсәләмов, Атилла Расих, Фатих Хөсни, Риза Ишморат, Хәсән Туфан, Сибгат Хәким, Зәки Нури, Хәсән Хәйри һәм башка бик күп иптәшләр, композиторлардан Нәҗип Җиһанов, Җәүдәт Фәйзи, Рөстәм Яхин, Заһид Хәбибуллин, Әнвәр Бакиров, шулай ук рәссамнарыбыз үз әсәрләрен газетабызны укучыларга тәкъдим итәрләр. Культура-агарту учреждениеләренең эше турында, үзешчән сәнгать коллективларына ярдәмгә методик мәкаләләр бирү күздә тотыла.

Октябрьның 53 еллыгы уңае белән революция һәм гражданнар сугышы, шулай ук хезмәт ветераннары турында очерклар басылачак. Революцион көрәш истәлекләренә зур урын бирелер, илебез киң-

лекләре буйлап журналистлар эстафетасы дәвам итәчәк, ягъни күрше республикалар, тугандаш милләтләр тормышы турында мәкаләләр урнаштырылыр. Шулай ук пропагандистларга һәм тыңлаучыларга ярдәмгә материаллар биреп барылачак. Газетада фәнни-атеистик темаларга кызыклы мәкаләләр, алдынгы лекторлар, агитаторлар, пропагандистлар турында зарисовкалар, очерклар укырга мөмкин булыр.

Җәмгыятьтә һәм көнкүрештә үзен үрнәк тотучы иң югары мораль сыйфатларга ия булган иптәшләребез турында газета күбрәк һәм гыйбрәтлерәк итеп язарга исәп тота. Ә хулиганнар, эчкечеләр, әрәм тамаклар, алга баруыбызга зыян китерүче һәртөрле кимчелекләр көчле тәнкыйть утында көйдерелер.

Газета алдагы елда җирле Советларның суд һәм прокуратура органнарының, медицина учреждениеләренең, сәүдә һәм транспорт оешмаларының, халык контроленең эшен яхшыртуда күп урын бирәчәк.

Былтыр һәм быел редакция Казанда, авыл районнарында күп кенә укучылар конференцияләре, очрашулар үткәрде. Анда журналистлар, үз хәбәрчеләребез редакциянең эше, киләчәккә планнар турында сөйләделәр. Бу очрашуларда әйтелгән акыллы киңәшләр редакция тарафыннан өйрәнелде, үзегез укып-күреп барасыздыр, алар инде тормышка да ашырыла. Сатира-юмор почмагы даими чыгып тора. «Аналар, сеңелләр, сезнең өчен» дигән хатын-кызлар сәхифәсе бирелә, «Казан һәм казанлылар» бүлеге ачылды һәм ул айга бер тапкыр биреп барылыр. Бик күп укучылар соравы буенча акча-әйбер лотереясы отышлар тиражын урнаштыруны дәвам итәчәкбез. Менә шулай, кадерле дуслар, сезнең теләкләрегезне, үтенечләрегезне редакция игътибарсыз калдырмый.

Баласы булган һәркем яхшы белә: куанычлы да, мәшәкатьле дә, бик кыен да баланы тәрбияләү. Аны ничек намуслы һәм эш сөючән кеше итеп үстерергә? Ата-аналарны әнә шул сораулар кызыксындыра. Хатын-кызлар сәхифәләрендә газета бу сорауларга җавап бирергә омтыла. Моннан башка газета битләрендә «Укытучы трибунасы», «Семья өстәле янында» дигән рубрикалар астында педагогларның, врачларның балаларга әхлак һәм хезмәт тәрбиясе бирү мәсьәләләренә багышланган чыгышлары урнаштырылыр. Киләсе елда бу темага ата-аналар үзләре дә ешрак язарлар, дип уйлыйбыз. Мәктәпләр, вузлар, техникумнар, фәнни-тикшеренү учреждениеләре эше тулырак яктыртылыр.

Газета республикабыздагы, туган илебездәге, җир шарындагы яңа вакыйгалар белән үзенең укучыларын киң һәм оператив рәвештә таныштырып барачак. Республикабыз хезмәт ияләренең хезмәт эшчәнлекләрен, культура һәм тормыш-көнкүрешләрен эзлекле яктыртачак. Көндәлек очрый торган яңалыклар, сирәк очрый торган гадәттән тыш хәлләр турында язып тору планлаштырыла. «Фотоаппарат белән республика буйлап», «Яңалыклар, вакыйгалар, хәбәрләр», «Фән һәм техника яңалыклары», «Спорт», «Сез беләсезме?» «Файдалы киңәшләр» дигән бүлекләр һәм башка рубрикалар газета битләреннән төшмәячәк.

Хөрмәтле укучыларыбыз! Газета Татарстан тормышын тулы яктырту белән генә чикләнеп калмаячак. Редакциягә алынган хатларда күп кенә иптәшләр туган ил, халыкара хәлләр турында бик кызыксынып укуларын язалар. Без аларның теләкләрен дә искә алдык.

1970 елда халыкара тормыш тагын да киңрәк яктыртылыр. Алар «Дөньяда ниләр бар?», «Дөнья хәбәрләре», «Телеграф тасмасыннан», «Җир йөзендә ниләр булмый?» дигән һәм башка исемнәр астында туплап биреләчәк.

1970 елда газетада нәрсәләр язылачагын бәйнә-бәйнә санап чыгу кыен, хөрмәтле иптәшләр! Кыскасы, киләсе елда газета тагын да эчтәлеклерәк, кызыклырак булачак. Газетага язып, укы, язып тор. «Социалистик Татарстан» газетасына язылу өчен бернинди чикләү дә юк. Аңа почта бүлекчәләрендә, үзегез эшләгән яки укыган урыннарда языла аласыз.

Газетага язылу бәясе: бер елга — 6 сум, ярты елга — 3 сум.

Күрше һәм тугандаш өлкәләрдә яшәүче иптәшләр! Әгәр үзегез яшәгән урында подписка кабул ителмәсә, акчагызны менә шушы адрес белән җибәрегез:

**Казань, ул Куйбышева, 17/25. Областной отдел «Союзпечати» для газеты «Социалистик Татарстан».**

# ӘДӘБИЯТ һӘМ СӘНГАТЬ ЯҢАЛЫКЛАРЫ

## ГАСТРОЛЬЛӘР ҖӘЕ

Казан тамашачылары быел да тугандаш халыкларның театр сәнгатен яратып карадылар. Алар июнь башында Башкорт дәүләт академия театрын каршыладылар.

Симферополь шәһәренең М. Горький исемендәге Кырым дәүләт драма театрының килүе дә зур куаныч булды. Ижевск музыкаль драма театры шәһәребез халкына удмурт, рус һәм дөнья классиклары әсәрләренең үрнәкләрен күрсәтте.

Июль аенда Казанга Мәскәү оперетта театры, Киров драма театры килде. Ә бу айда без Новгородлылар сәнгатен күреп сокландык. Новгород драма театрының репертуарында татар драматургы Риза Ишморатның «Муса Җәлил» драмасы да бар иде.

## КИҢӘШМӘЛӘР, УТЫРЫШЛАР

Май азакларында Әлмәт шәһәрендә нефть районнарында яшәүче яшь язучыларның ике көнлек семинары уздырылды. Семинарда 40 ка якын яшь язучы, 12 СССР язучылар союзы члены катнашты. 15 яшь авторның әсәрләре тикшерелде. Семинарда язучылардан Әмирхан Еники, Марс Шабаев, Равил Фәйзуллин, КПССның Әлмәт шәһәр комитеты секретаре С. Хәкимова, «Татнефть» берләшмәсе начальнигы урынбасары Ү. Сәттаров иптәшләр чыгыш ясады. Семинар азагында Әлмәт район Техника йортында әдәби кичә уздырылды.

* * *

27—29 майда Душанбе шәһәрендә Урта Азия һәм Казагыстан тәнкыйтьчеләренең региональ киңәшмәсе уздырылды.

Бу киңәшмәгә Мәскәү шәһәреннән, Украина, Әзербайҗан, Әрмәнстан, Литва, Эстония, Грузия республикаларыннан һәм Көньяк-Осетия, башкорт һәм татар автономияле республикаларыннан да вәкилләр килде. Казан тәнкыйтьчеләреннән филология фәннәре докторы, профессор Ибраһим Нуруллин һәм «Казан утлары» журналында тәнкыйть бүлеген алып баручы Фарваз Миңнуллин катнашты.

Зур кызыксыну белән «Хәзерге заман совет тәнкыйтенең методологиясе», «Милли республикаларда әдәби тәнкыйтьнең үсеш юллары», «Вакытлы матбугатта рецензия», «Тәнкыйтьче-публицистның осталыгы», «Әдәби тәнкыйть һәм проблемалы мәкаләләр», «Өлкә әдәби газеталарында тәнкыйть», «Тәнкыйть һәм әдәби процесс» дигән докладлар тыңланды. Фикер алышуларда Ибраһим Нуруллин да чыгыш ясады.

* * *

Июнь аенда РСФСР язучылар союзы Россия Федерациясендә чыга торган әдәби журналларның тәнкыйть һәм библиография бүлегенең мөдирләрен Мәскәүгә киңәшмәгә җыйды. Киңәшмәнең көн тәртибендә В. И. Ленинның тууына 100 еллыкка әзерлек һәм әдәби тәнкыйть бүлегенең бурычлары, журнал редакцияләренең яшь тәнкыйтьчеләр белән эшләве, РСФСР язучыларының III съездына әзерлек мәсьәләләре тикшерелде.

«Казан утлары» журналының тәнкыйть бүлеге мөдире Фарваз Миңнуллин фикер алышуларда катнашып, журналыбызда тәнкыйтьнең торышы һәм яшь тәнкыйтьчеләр белән эшләү турында сөйләде.

## ҖӘЙГЕ СӘЯХӘТЛӘР

В. И. Ленинның тууына 100 ел һәм республикабызга 50 ел тулган көннәрне каршылап, Татарстан язучылары зур дәрт белән яңа әсәрләр язалар. Шуның өчен алар бик еш кына төрле җирләргә сәяхәт итәләр, язылачак геройлары белән очрашалар, әсәрләренә өстәмә материаллар җыялар.

«Казан утлары» журналының баш редакторы, шагыйрь Зәки Нури июнь азакларында Польшада булып кайтты. Ул В. И. Ленин исеме белән бәйле булган урыннарны — Варшава, Краков, Поронино шәһәрләрен күрде, Польша хезмәт ияләре белән очрашты, тугандаш дәүләтнең казанышларын күреп йөрде.

* * *

Бөек юлбашчының исеме язучы Газиз Мөхәммәтшинны Саян таулары итәгенә, бөтен дөньяга билгеле булган Шушенскига алып килде. Язучы кайчандыр В. И. Ленинның сөрген урыны булган, ә хәзер зур, матур калага әйләнгән Шушенскины карап йөрде, музейда булды, Себернең кырыс табигате, йомшак күңелле кешеләре белән танышып кайтты.

* * *

Шагыйрь Нури Арсланов Казагыстанның Павлодар шәһәрендә булды. Музейларны, шәһәрнең гражданнар сугышы вакыйгалары белән бәйле урыннарын карап йөрде. Павлодардан алып кайткан тәэсирләре шагыйрьнең язылып ята торган поэмасында һәм яңа шигырьләрендә чагылыш табачак.

* * *

Язучы Әхсән Баянов Яр Чаллы һәм Минзәлә районнарына иҗади командировкага барып кайтты. Ул Кама электр станциясе төзелешендә эшчеләр, инженерлар белән очрашты, аларның эшләре, көнкүрешләре белән танышты. Авылларда колхозчылар белән сөйләште. Минзәлә педагогия училищесы студентлары белән очрашып, аларга татар совет поэзиясендәге яңалыклар хакында сөйләде.

* * *

Алабуга районы хезмәт ияләренең республикабыз язучылары һәм шагыйрьләре белән очрашулары гадәткә керде. Әле күптән түгел генә бирегә язучы Хәсән Сарьян һәм шагыйрь Рәшит Гәрәй килеп китте. Алар районның Орджоникидзе, Ильич, Калинин, Тукай, Азин, «40 лет Октября», Ленин исемендәге колхозларында чыгышлар ясадылар. «Труд» һәм «8 март» колхозларында булдылар. Бу очрашуларга Алабуга шәһәрендә яшәүче язучы Э. Касыймов һәм яшь шагыйрь Е. Уткин да катнашты.

* * *

Тугандаш Башкортстан республикасының әдәбият һәм сәнгать яңалыкларын Татарстан хезмәт ияләре һәрвакыт зур кызыксыну белән һәм яратып күзәтәләр.

Июнь азакларында Казанга килгән башкорт шагыйрьләре Әнгам Атнабаев һәм Рафаэль Сафин да аларга зур куаныч китерде. Шагыйрьләр республикабызның Буа районы хезмәт ияләре алдында чыгышлар ясадылар. Казан шәһәренең культура сарайларында, күп кеше катнашы белән, әдәби кичәләр уздырдылар.

## ТАТАР ЯЗУЧЫЛАРЫ ТУГАНДАШ ХАЛЫКЛАР ТЕЛЕНДӘ

Казагыстанда яшәүче татар язучысы Ибраһим Сәләховның «Кукчатау далаларында» романы казакъ телендә басылып чыкты. Аны Алма-Ата шәһәренең «Язучы» нәшрияты 35 мең тираж белән чыгарды. Романны татарчадан казакъ теленә язучы Өмәрҗан Оспанов тәрҗемә иткән.

* * *

Шул ук «Язучы» нәшрияты Гайшә Шәрипованың «Гафурның семьясы» дигән романының икенче китабын рус телендә басып чыгарды. Гафур Коләхметов семьясына багышлап язылган зур күләмле бу роман хезмәт ияләрен богаулап торган дини һәм социаль йолаларның җимерелә баруын, халык бәхете өчен көрәшүче яшь буын сафларының какшамас булып ныгуын оста итеп сурәтли.

## КОМПОЗИТОРНЫҢ ИҖАТ КИЧӘСЕ

Мәскәүдә татар халкының яраткан композиторы Сара ханым Садыйкованың иҗат кичәләре булды.

Концертларда РСФСРның халык артисты Фәхри Насретдинов, Татарстанның атказанган артисткасы Разия Тимерханова, артистлардан Нәҗия Теркулова һәм Габдулла Рәхимкулов Сара ханымның яңа әсәрләрен башкардылар. Измайлов паркында, Фәнни атеизм йортында һ. б. урыннарда үткәрелгән бу кичәләргә халык күп йөрде, авторның җырларын алкышлап каршыладылар.

## ХЕЗМӘТКӘ — ХӨРМӘТ

РСФСРның Верховный Советы Президиумы Указы белән совет культурасы өлкәсендәге хезмәтләре өчен Татарстан АССРның Казандагы А. М. Горький музее директоры, язучы Мария Николаевна Елизаровага **РСФСРның атказанган культура работнигы** дигән мактаулы исем бирелде.

## ДИҢГЕЗЛӘР, ТАУЛАР АША

Язучы Рафаэль Мостафинның «Муса Җәлил» теплоходында йөзүен журнал укучылары белә инде. Менә аның юлдан җибәргән телеграммасы:

«Корея Халык Демократик республикасына ашыгыч йөк илтүче «Муса Җәлил» теплоходы үзенең рейсын уңышлы дәвам итә. Изге Надежда борыны безне әче көзге җиле һәм шаулы дулкыннары белән каршылады. Мадагаскар атавы тирәсендә судно штормга эләкте. Палубага бәргән дулкыннардан судноның корпусы калтырап тора. Авыр шартларга да карамастан, экипаж вахтада тыныч тора, алга баруны дәвам итәбез. Коллектив зур кызыксыну белән Муса Җәлилнең тормышы һәм иҗаты турында тынлый. Хәзер Һинд океанының тропик суларына керәбез. Каләмдәш дусларыма һәм журнал укучыларына кайнар сәлам. Эшләрегездә уңышлар телим.

**РАФАЭЛЬ МОСТАФИН».**

Бәясе 50 тиен
Цена 50 коп.

# КАЗАН УТЛАРЫ (ОГНИ КАЗАНИ)

Ежемесячный литературно-художественный и общественно-политический журнал

ОРГАН СОЮЗА
ПИСАТЕЛЕЙ
ТАТАРИИ

ИНДЕКС 73210